Равил Фәйзуллин

**Илбагар уйлар**

Фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-4:95
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф91

**Фәйзуллин, Р.Г.**

Илбагар уйлар : фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар / Равил Фәйзуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 414 б.
ISBN 978-5-298-01921-7

Бу китапта Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның соңгы елларда иҗат ителгән публицистик язмалары тупланды. Алар чор-заман, милләт язмышы, халкыбызның күренекле шәхесләре турында эссе-уйланулардан гыйбарәт.
Китапта шулай ук Татарстан Язучылар оешмасы турында күләмле документаль хезмәт һәм гыйбрәтле сәяхәтнамәләр дә урын алды.

УДК 821.512.145-4:95
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01921-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Фәйзуллин Р.Г., 2011

**I**

*Без еш кына үзебезне мең еллык әдәби мирас вәкилләре дип һаваланырга яратабыз. Мираска, варислыкка хакың бар икән, аңа хуҗа булырга да кирәктер.*
*Хуҗа була белгәннәрнең генә абруе зур...*

## *ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫРЛЫК ҮТКӘН ЮЛ*

*(Татарстан Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан
кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар)*

Татарстан Язучылар оешмасына 70 ел... «Мең еллап тарихы булган татар әдәбияты оешмасына 70?!» дип уйлап куяр кемдер. Әйе, нигезе совет чорында корылган һәм әле бүген дә структур асылы шул ук калган язучыларның рәсми оешмасына нәкъ 70 ел. Дөрес, бер Татарстанга гына килгән юбилей түгел, безнең күрше республикаларга да, элек союздаш саналып йөртелгән бүтән халыкларның күбесенә дә кагыла торган юбилей бу. Үткәннәргә мөнәсәбәтнең һәм тарихи хәтернең ниндилегенә карап, төрле җирләрдә төрлечәрәк билгеләп үттеләр әлеге датаны. Әлбәттә, һәр халык тарихны үзенчә аңларга һәм аңлатырга хаклы.

Иҗат оешмалары хакында нинди генә фикерләр (иҗатчыларның үзләре арасында да андый берлекләргә скептик караучылар бар) булмасын, реаль фактны танымый мөмкин түгел: иҗат союзлары, ягъни берлекләре (төрле чорда төрлечә әйтелгән, сүз сөрешенә карап һәм синоним буларак, язмабыздагы бу сүзләр һәр икесе дә кулланылыр), соңгы җиде дистә ел эчендә әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынты ясаучы мөһим бер фактор булып торды. Әйтик, яңа заман татар әдәбияты елъязмасын Язучылар берлеге тарихыннан башка күз алдына китерү кыен. Оешма XX гасырның байтак дистә елларында язучыларның иҗади хезмәтен оештыруда һәм бәяләүдә үзгә бер идеологик үзәк ролен үтәп килде.

Мәгълүм хакыйкать: иҗат эше күңел халәтенә – илһамга бәйле үтә индивидуаль хезмәт, хәтта аны интим шөгыль дип тә әйтеп буладыр. Оешма, сүзнең тамырыннан күренгәнчә, күмәклекне белдерә, ә иҗат итү дигәч, нигездә, ялгыз калып эшләү күз алдына килә. Бөек әсәрләрне – җырмы, көйме, рәсемме – исегезгә төшерегез – күбесен талантлы Шәхес ялгызлыкта – Дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән бит! Әсәр туу – үзе бер тылсым! Аны өстән яки кырыйдан әмер биреп, кушып тудырып булмый. Андый очракта тудырганың да ясалма, гарип чыга. Попугайны нәрсәләрнедер кабатларга өйрәтә алсаң да, сандугачны көчләп сайратып булмас, бөркетнең канатларын сындырсаң да, күз карашын кисә алмассың. Иҗат – асылы белән ирекле шөгыль. «Иҗат иреге» дигән гыйбарә тикмәгә генә тумаган! Шулай да...

Әйе, шулай да, нинди генә индивид һәм индивидуалист булып, «Аллалар белән генә сөйләшә торган» ялгыз халәттә калып, үзең өчен бөек тоелган нинди генә әсәр тудырсаң да, син аны үзең өчен генә иҗат итмисең. Күңел җимешен кемнәр беләндер бүлешәсе килә. Язучы икәнсең – әсәреңне китап итеп чыгарасы, кешеләргә ирештерәсе килә, рәссам икәнсең – эшләреңне җыеп, күргәзмә ясап күрсәтәсе, артист икәнсең – сәхнәне иңлисе килә... Менә шунда инде кешеләргә елышасың, аңлашуга өметләнеп, коллегаларыңа барасың, теге яки бу мәсьәләне чишәр өчен хакимнәргә, оешмаларга мөрәҗәгать итәсең... Ялгызың иҗат итеп булса да, ялгызың гына яшәп, тормыш итеп булмый. Булса да, бик кыен. Ә дөньялыкта адәм баласына, һай, күп кирәк!

Очрашу-аралашу урыны да, иҗатың турында кеше сүзен ишетү яки бүтәннәр турында үз фикереңне белдерү өчен трибунасы да, нәрсәгәдер дәгъва итеп белешмә-тәкъдимнамәсе дә... Ахыр килеп, яшәештә түбә-куыш та кирәк бит әле, үлем-каза килгәч – озату-саубуллашу мәшәкатьләре дә... Ә кая барасың?..

Озынга сузылырга охшаган бу язмамны нигә дип яза башладым соң әле? Акыллыга сабышып, бүтәннәрне нәрсәләргәдер өйрәтергә, сабак бирергә теләгем юк, кемнәрдер алдында кемлегемне күрсәтү ихтыяҗы юк. Хаҗәте дә юк. Яшьлектә максат итеп куелган үрләремнең күбесенә менелде... Нәрсә өчен язып, бастырып чыгарырга ниятлим соң алайса? Мөгаен, иң әүвәл үзем куйган сорауларга үзем җавап эзләп азаплануымдыр бу. Алга таба әдәбиятыбызның язмышы ничек булыр? Без элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны алга этәр өчен кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Бу сораулар күпләрне борчыйдыр дип уйлыйм (шулай булса, димәк, язуым аклана). Язучылар оешмасының бу юбилей датасы уйлану-фикерләшү өчен бер сәбәп кенә. Төп мәсьәлә – безнең рухи киләчәгебез. Киләчәк турында төпле фикер йөртер өчен, үткәннәрне белеп, гыйбрәт алу, бүгенгене хәл кадәри анализлау фарыз. Алда әйткәнемчә, соңгы чор әдәбиятыбыз тарихы Язучылар оешмасы белән тыгыз бәйләнгән. Бу язманың авторы буларак искәртеп узыйм, минем дә бу Оешма белән гомерем тоташкан, аның өчтән ике өлеше турыдан-туры аңа бәйле. 40 елга якын Язучылар союзында әгъза булып торып, шуның 37 ел дәвамында тоташтан шушы Оешманың идарә әгъзасымын (хәзер инде 43 ел. – *Р.Ф., 2010*). Уйлап баксаң, үзе бер гомер. Шуңа күрә Язучылар оешмасы, аның эшчәнлеге турында уйланып фикер әйтергә хакым бар шикелле. Күрәсең, мемуар-истәлекләр язар чак та җиткәндер. Беркөн язучылар исемлеген актарып аптырабрак калдым: миңа кадәр СССР Язучылар союзына кабул ителгән язучылар нибары 5–6 гына калган... Теләсәң-теләмәсәң дә, әдәби хезмәт вахтасында ветеран булып чыгам икән...

Иң әүвәл шуны ассызыклап узыйк: СССР дигән держава яшәгән чорда иҗтимагый әһәмияте зур булган иҗат берлекләре – иҗат союзлары эшләп килде. Шул оешмаларның иң зурысы һәм иң абруйлысы Язучылар союзы булды. Әгъзалар саны ягыннан да, дәрәҗәсе ягыннан да дөньяның бүтән илләрендә андый оешма юк иде. Язучылар союзы әгъзасы булу иҗат кешесе өчен зур казаныш саналды. Югары гыйльми дәрәҗә алулардан бер дә ким түгел иде бу әгъзалык. Алай дөньяда тиңе булмаган нинди оешма соң бу, нинди максат белән төзелгән дә нинди идеалга һәм нинди даирәгә хезмәт иткән? Профессионаллар берләшмәсе дияр идең, мәдәният, шул исәпкә язучылар да кергән аерым профсоюз системасы бар иде, Союз эчендә аның бүлекчәләре бар иде әле... Үзара ярдәмләшү, социаль яклау берләшмәсе дияр идең, бу функцияләрне башкаручы Россиядә тарихы XIX гасырга ук тоташкан Литфонд (Әдәби фонд) бар... Әйе, иҗат союзларының, бигрәк тә Язучылар союзының социаль функциясе бүтәнрәк, тирәнрәк. Аны аңлау, асылына төшенү өчен, объектны, мотлак, шул

иҗтимагый чор идеологиясе аша, үтелгән вакыт призмасы аша карап анализлау мөһим. Чишмә башын, тора-бара аңа кушылган бүтән чыганакларны белсәң генә, елганың зурлыгын, агышының куәт-көчен чамалый аласың.

СССР Язучылар союзы төзелү 1934 елдан саналса да, аның башлангычы 1932 елга – ВКП(б) Үзәк Комитетының 23 апрельдә чыгарган карарына тоташа. Язучылар союзын оештыру мәсьәләсе, нигездә, шул елны хәл ителә. 1934 елга кадәрле калган ике ел әзерлек эшләренә китә. Үзәктә һәм республикаларда бу юнәлештә кызу эшләр башлана. Шул ук елның маенда Татарстан совет язучыларының бердәм союзын төзү буенча Г.Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты төзелә. Комитетның максаты – төрле төркемнәргә бүлгәләнгән (ТАПП, СУЛФ, «юлаучылар» һ.б.) язучыларны бер максатка юнәлтеп берләштерү. Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: башлангычы «Безнең юл» булган журнал да ул елларда, бүлгәләнеп, «Яңалиф», «Атака» исемнәре белән чыккан иде. Алар урынына «Совет әдәбияты» исемле журналның чыга башлавы әнә шул берләштерүнең бер чагылышы иде.

СССР Язучылар союзының нинди максат белән, нинди социаль нигезгә салынуын аңлау өчен, әйткәнемчә, шул чорның атмосферасын күз алдына китерергә тырышыйк. Октябрь инкыйлабы үтүгә – 15 ләп, СССР төзелгәнгә 10 еллап вакыт үткән. Советлар Союзында моңарчы дөнья күрмәгән хәл – сыйныфсыз җәмгыять төзелә. Шәхси милек юк дәрәҗәсендә: завод-фабрикалар күптән национализацияләштерелеп дәүләткә күчкән, җирләр башта алпавытлардан, соңрак крестьянның үзеннән дә тартып алынып, күмәк хуҗалыклар-колхозлар төзелгән. Авылның хәлле кешеләре сөрелгән. Пролетариат, юксыллар, социализм сүзләре гегемоник яңгыраш алган мохиттә милек, мөлкәт төшенчәләре бөтенләй контрсүзләр булып кабул ителә. Олы-кечененңме, наданныңмы, укымышлыныңмы колак төбендә яңгыравыклы шигарьләр: «Иске дөньяны штурмлау бара! Капитализм җәмгыяте бетәчәк!» (Шул заманда капиталистик мөнәсәбәтләрнең 60–70 елдан соң СССР киңлекләренә янәдән кайтачагын, уртак байлыкның талап-урланып, халыкның аз сандагы бик байларга, күп сандагы бик хәерчеләргә аерылып бетәчәген күз алдына китерүчеләр булдымы икән?!) Кешелек капитал изүеннән азат ителәчәк! Яшәсен бөтен дөнья революциясе! Яшәсен коммунизм!.. Интеллигенция аптыраашта! Дворян тәрбиясе, университет белеме алганнарның байтагы эмиграциядә, бер өлеше тавыш чыгармый, дәшми, сагаеп нидер көтә, бериш аумакайлар партия җырын җырлап көн үткәрә... Вазгыять бер дә көлке түгел. Европа, гомумән, тышкы дөнья арасына «тимер пәрдә» корылган. Демократия сүзе архаик төшенчәгә әйләнгән. Аны кирәксенүче дә бик юк... Ни гаҗәп, бәлки, парадокстыр: дөнья җәмәгатьчелегенең СССРга игътибары гаять зур. Планетаның алтыдан бер өлешендә бөек социаль экспериментлар бара! СССРда һәркем тигез: сыйныфсыз, гадел җәмгыять төзелә. Кешелекнең хыялы бит бу! Капитализм – берәүләрнең хәләл хезмәте бәрабәренә икенче берәүләрнең череп баюына корылган капитализм, гасырлар буе байтак акыл ияләренең нәфрәтенә юлыккан строй. Советлар Союзына сирәк булса да дөньякүләм мәшһүр язучылар килә. Ромен Роллан, Анри Барбюс, Бернард Шоу һ.б. Алар Сталин һәм башка дәүләт җитәкчеләре белән очрашалар. Россия, Советлар Союзы турында гаять зур фикерләр, канәгатьлек хисләре белән кайталар туган илләренә. СССР турында матур-матур интервьюлар бирәләр, социалистик стройның өстенлекләре турында сөйлиләр, язып чыгалар. Зур талантлар икейөзлеләнмәс: алар күңелдәгеләрен ихлас сөйләгәннәрдер дип уйлыйм. Күрәсең, аларны чыннан да яхшы каршылаганнар: ул шәхесләр яхшыны гына күргәннәр, яхшыны гына ишеткәннәр дә. Дөньякүләм мәшһүр язучыларның СССР турындагы фикерләре ил башлыклары өчен, әлбәттә, зур сәяси отыш булган. Илдә яшәгән күпсанлы язучылар армиясен шундый рухта – максат итеп алынган идеологиягә хезмәт иттергәндә, әлбәттә, сүз – зур көч. Язучылар – «кеше рухының инженерлары». Безгә без күрергә теләгән җәмгыятьтә без күрергә теләгән масса кирәк... Шулай уйлаганнар хакимдарлар. Менә шундый вазгыятьтә оеша башлый СССР Язучылар оешмасы.

*** * ***

1934 ел. 17 август. Мәскәү. Союзлар йортының Колонналы залы. Әдәбиятлар тарихында моңа кадәр тиңе булмаган язучылар җыены. 52 милләт вәкилләрен тәшкил иткән 591 делегат.

Кунак сыйфатында төрле континентлардан килгән 40 чит ил язучысы. Совет язучыларының I Бөтенсоюз оештыру съезды ике атнадан артык (!) дәвам итә. 17 августта ачыла, соңгы – 26 нчы ябылу утырышы 1 сентябрьдә була.

Бу урында Мәскәүдә үткән грандиоз съезд турында беразга тукталып торып (алда бу хакта тәфсилләбрәк сөйләү булыр), шул чорның үзебезнең җирлектәге иҗтимагый-сәяси вазгыяте һәм әдәби мәйдан-мохит турында берничә сүз әйтеп узыйк.

Татарстанда солтангалиевчелекне «фаш итү» тәмамланган чор, татарның байтак акыллы башлары юк ителгән, зыялы катлам өркетелгән, куркытылган чор... Әдәбият дөньясы да таркау, чуар; өстәвенә зур фигуралар аренадан китеп бара... Г.Исхакый – эмиграциядә, Такташ инде юк, Г.Камал яңа гына вафат, Г.Ибраһимов – авыру, Казаннан еракта, Кырымда яши, Г.Газиз – Бакуда, Г.Кутуй, Н.Исәнбәтләр, җидегәнчелектә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, Г.Бәширов, С.Баттал, Ә.Еникиләр әле яшь, башлап язучылар санала... Шулай да шәхес буларак колоритлы язучылар шактый әле Казанда. Татарстанда туып үскәннәр дә җитәрлек, төрле төбәкләрдән килеп кушылганнар да байтак. 1934 елның беренче яртысында СССРның төрле почмакларында – республикаларда, өлкәләрдә – язучыларның корылтай-съездлары үтә, җирле оешмалар төзелә, ил күләмендә узачак зур съездга вәкилләр – делегатлар сайлана. Татарстанда да башкарыла бу эш.

Язучыларның беренче җыены рәсми рәвештә Совет язучыларының I бөтен Татарстан съезды дип аталган. Съезд Татар дәүләт академия театрында 1934 елның 25 июлендә ачыла һәм, Мәгариф эшчеләре йортында дүрт көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла. Беренче оештыру съезды, шул заманнарга хас булганча, тантаналы һәм патетик рухта үтә. Почетлы президиум, плакатлар, котлаулар, көчле кул чабулар... Съездны кыскача кереш сүз белән язучы К.Нәҗми ача. Язучылар союзын оештыру комитеты председателе Г.Ризвановның өч сәгатьтән артыкка сузылган доклады тыңлана. Съездда иҗат мәсьәләләре буенча Г.Гали, Г.Нигъмәти, К.Тинчурин, Р.Ишморат, Ф.Кәрим докладлары тыңлана. Чыгыш ясауларда Г.Кашшаф, Х.Рахман, Г.Толымбай, Ф.Бурнаш, Ә.Фәйзи, М.Әмир, Ш.Усманов, И.Салахов, Х.Туфан, М.Җәлил һ.б. катнаша. Съездның оештыру эшләре мондый нәтиҗә белән тәмамлана: Татарстан Язучылар союзының беренче идарә составына 9 кеше сайлана. Алар: К.Нәҗми (председатель), К.Тинчурин, Г.Гали, Г.Толымбай, Х.Туфан, Л.Гыйльми, Г.Ризванов, В.Красный, К.Төхфәтуллин (секретарь). Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына. Бу 12 делегатның 9 ы әле саналган идарә әгъзалары, калган 3 есе идарә әгъзалыгына кандидатлар: И.Гази, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы. Аерым исемнәрне искә алмаганда, нигездә, мәгълүм шәхесләр, татар әдәбиятыннан хәбәрдар булган кешеләр өчен билгеле язучылар. Ул вакытта алар әле яшь: 30–40 лар тирәсендәге гайрәтле ир-егетләр. Алдагы 10–15 елда нинди әсәрләр язарлар да, үзләренә нинди язмыш язылыр?..

Совет Язучылар союзы оешу турыдан-туры М.Горький исеме белән бәйле. Ул – аның идея җитәкчесе, фактик оештыручысы. Бу грандиоз башлангычны күтәреп җибәрер өчен, әлбәттә, дөньякүләм абруйлы бер бөек шәхес кирәк булган. Ул – М.Горький. Язучылар арасында аңа тиң кеше юк ул заманда. Шуңа күрә дә, оештыру комитеты рәисе буларак, Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездын ул ачып җибәрә дә. Протокол тәртибе буенча, ВКП(б) ҮК секретаре А.Жданов нотыгыннан соң төп докладны да М.Горький ясый.

Ул көннәрнең язма рәвештәге иң ышанычлы шаһиты – съезд стенограммасы. (Съездда катнашкан берәр кеше исән микән әле? Исемлектә миңа азмы-күпме таныш фамилияләрне барлап чыктым – очрамады. Бу җыенда яшь журналист яки язучы булып катнашкан берәрсенең исән булуы да мөмкин.) 50 басма табакка якын күләмле документ. Үзе бер энциклопедия! Булмый ни, чыгыш ясаучыларның саны гына да 224 кә җитә. Котлау-тәбрикләүдә катнашучыларны да исәпләсәң, трибунадан 300 дән артык кеше нотык тота! Без бу стенографик язмалардан цитата рәвешендә кайбер чыгышлардан өзекләр, җөмләләр китереп узарбыз. Факттан да дөресрәк факт юк. Алар, нигездә, СССР Язучылар союзының Уставын тәшкил иткән тезислар. Ә Устав инде үзенчә бер канун дигән сүз.

М.Горький, съездны ачканда, беренче җөмләсендә үк мондый сүзләр әйтә (кайбер цитаталарны съездда сөйләнгәнчә, рус телендә бирергә булдык. – *Р.Ф.*): *«...разрешаю себе сказать несколько слов о смысле и значении нашего съезда. Значение это в том, что прежде распыленная литература всех наших народностей выступает как единое целое перед лицом*

*революционного пролетариата всех стран и перед лицом дружественных нам революционных литераторов».*

М.Горький доклады һәркем өчен, бигрәк тә язучы өчен, бүген дә кызык һәм гыйбрәтле. Бөек язучы күтәргән кайбер мәсьәләләр бүген дә бик актуаль. Әйтик, ул Көнбатыш әдәбиятчыларының күп әсәрләрендә кешенең түбән инстинктларын уята торган мотивларны: үтерү, көчләү, талау, зина кылу фонында каһарман итеп сурәтләнгән персонажларны тәнкыйтьли (Дәрдемәнд әйтмешли, «нә дәригъ», бүген китап базарларыбыз шундый «әсәрләр» белән тулган!), дөнья барышының үзәген тәшкил иткән гади хезмәт кешесен олыларга өнди. Докладның иң төп тезисларының берсе – халык иҗатына игътибарны юнәлтү. Һәр әдәбиятның нигезендә фольклор ята дип саный Горький. Бу дөрес фикер, аксиома кебек хакыйкать, бик вакытлы яңгырап, язучылар өчен дистә еллар буена директива, үзенә күрә бер күрсәтмә булды. Бигрәк тә яңа туып яки тернәкләнеп килүче әдәбиятлар өчен файдалы булды бу девиз. Күп кенә халыклар рухи тарихларыннан – халык иҗатыннан – үзләренең мифик яки реаль геройларын «казып» чыгардылар, нәфис әдәбиятларына нигез салдылар.

М.Горький докладында күпләребез, бигрәк тә безнең өчен, бик тә кадерле, чын мәгънәсендәге интернациональ рухлы фикерләр тагын бар. Ул, мәсәлән, болай ди: «Мы не имеем право игнорировать литературное творчество нацменьшинств только потому, что нас больше. Ценность искусства измеряется не количеством, а качеством. Если у нас в прошлом – гигант Пушкин, отсюда еще не значит, что армяне, грузины, татары, украинцы и прочие племена не способны дать величайших мастеров литературы, музыки, живописи, зодчества...».

Гомумән, «тормыш университетлары»н тирән үзләштергән, яшәешендә төрле милләт вәкилләренең төрле катламнарын яхшы белгән Горький җир йөзендәге халыкларга тирән ихтирам белән карый. Татар халкын аеруча якын күрүе аның һәм әсәрләрендә, һәм җәмәгать эшчәнлегендә ачык сизелә. Ул үзенең бу докладында да, милләтләр турында сөйләгәндә, татарларны гел искә ала. СССРдагы дүрт-биш милләтне санаган чакта татарны телгә алмый калмый. Бер татар язучысы менә нәрсә язган, дип, докладында өзек тә укып күрсәтә (ул үзе машинкада 1,5 бит булыр). Йә, хәзер кайсы рус язучысы безнең хакта дөньякүләм трибунадан шулай әйтер микән? Солженицынмы? Распутин яки Беловмы?.. Юк, алар әйтмәсләр, бүтәннәре дә әйтергә охшамаган.

Бу съездда Татарстаннан 12 вәкил катнашканын искәртеп узган идек. Аларның тавышы ишетелгәнме бу җыенда? Гомумән, татар әдәбияты турында нинди сүз булган? Моңа җавап ачык: татар язучылары съезд эшендә актив катнашкан һәм татар әдәбиятының рейтингы югары булган. Дәлил рәвешендә шуны гына әйтү дә җитә: съездда милли әдәбиятлар буенча украин һәм белорус вәкилләреннән соң өченче итеп сүз Татарстан Язучылар союзы рәисе Кави Нәҗмигә бирелә, һәм ул татар әдәбиятының торышы турында зур доклад белән чыгыш ясый (грузин, әрмән, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, таҗик әдәбияты вәкилләренә сүз әле соңрак бирелә. Гомумән, милли әдәбиятлар буенча, М.Горький докладын санамаганда, нибары 9 халыкның әдәбияты турында гына махсус докладлар ясала. Кызык, 70 елдан соң, хәзер шундыйрак халыкара форум булса, безгә сүзне кайчан бирерләр, гомумән, бирерләр иде микән?). Шуңа өстәп тагын бер татар язучысы чыгыш ясый әле бу съездда. Ул – К.Тинчурин. Бу хакта белүчеләр аз. К.Нәҗми һәм К.Тинчурин чыгышлары турында шәрехләп сөйләп тормыйм – аларны үзеңә уку кирәк – берничә сүз белән генә төп фикерләрен әйтеп узам. К.Нәҗми, Язучылар оешмасы рәисе буларак, татар әдәбиятының шул чордагы торышы турында тәфсилле сөйли, заманы, дөресрәге, партия кушканча, элекке тормышны, буржуазия вәкилләрен, милләтчеләрне, әлбәттә, яхшы ук сүгә. Шулай ук замандашлары Г.Ибраһимов, Г.Камал, Ш.Камал, Ф.Бурнаш, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ш.Усманов, К.Тинчурин, М.Әмир, И.Гази, М.Җәлил, Ф.Кәрим һ.б. турында уңай фикерләр әйтә, иҗатларын югары бәяли. К.Тинчурин съездда партиясез делегат сыйфатында чыгыш ясый, күбрәк татар драматургиясенең хәле, үсеш перспективалары турында сөйли. Һәр ике оратор да, партиягә бирелгәнлекләрен демонстрацияләүгә дәлил итеп булса кирәк, сыйнфый нәфрәт белдереп, Г.Исхакыйны каты тәнкыйть итәләр... Ничек кенә булмасын, зур трибунадан алар татар халкы, аның язучы вәкилләре булып чыгыш ясаганнар. Ялгышларын Алла ярлыкасын, әмма аларның файдалы гамәлләре дә сагынып искә алырлык.

Мандат комиссиясе белдерүе дә игътибарга лаек. Делегатларның милли составы ягыннан караганда, хәл болайрак: руслар – 201 (алар арасында яһүдләр дә шактый булган дип исәпләргә кирәк), украиннар – 30, грузиннар – 28, татарлар – 19 (бу санга бүтән өлкәләрдә яшәүче татарлар да кергән. Мәсәлән, Г.Теләш – Чиләбедән), әрмәннәр – 19, үзбәкләр – 12, төрекмәннәр – 5... Икенче бер момент – яшь ягы (бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу бик мөһим): съездда катнашкан делегатларның уртача яше – 35,5 яшь! Ә менә хатын-кыз депутатлар бу съездда аз булган: нибары 21 кеше. Эмансипация, күрәсең, әле уянып кына килгән чор...

Шулай итеп, август уртасында башланган съезд сентябрь башында эшен тәмамлый. Докладлар укылган, нотыклар сөйләнгән, котлаулар яңгыраган, Сталинга, партиянең башка җитәкчеләренә сәлам-антлар юлланган... Чыгышлар турында өстәп шуны гына әйтәсе килә: шул чорның иң күренекле язучылары катнашкан һәм сүз әйткән бу съездда. Совет чорының классиклары саналганнардан – М.Горький, М.Шолохов, С.Маршак, А.Толстой, К.Федин, А.Фадеев, Л.Сейфуллина, Н.Тихонов, А.Сурков, А.Серафимович, И.Эренбург, Б.Пастернак, К.Чуковский, И.Бабель, Л.Соболев, М.Шагинян...; милли әдәбият вәкилләреннән – С.Айни, М.Бажан, К.Нәҗми, Т.Табидзе, И.Кадыйр, С.Стальский, С.Сәйфуллин, Я.Колас...; чит ил язучыларыннан – Луи Арагон, Жан-Ришар Блок, Рафаэль Альберти, Антал Гидаш, Андре Мальро, Мартин Андерсен-Нексе... Төп һәм кызыклы докладларның тагын берсе турында әйтми узсак, дөреслеккә хилафлык булыр. Ул – Н.Бухарин докладь. «Поэзия, поэтика һәм СССРда поэтик иҗат проблемалары». Коммунистлар партиясенең югары эшелонындагы бүтән берәр кешенең шигырь турында шундый характерда доклад ясаганы, мөгаен, тарихта бүтән юктыр.

Әйе, съезд тәмамлана. М.Горький йомгаклау сүзе белән чыга (нишләптер стенограммадан берничә гыйбарә хәтергә нык сеңеп калды: «Мы живем и работаем в начале первого акта последней трагедии трудового человечества». Монысы – сискәндергәне. Икенчесе – күңелгә ятышлысы: «Не менее важно знание нами языков армян, грузин, татар, тюрков...» Съездда 101 язучыдан торган идарә сайлана. Идарә әгъзасы итеп Татарстаннан К.Нәҗми кертелә. Аерым докладлар буенча (М.Горький, К.Радек, С.Маршак) махсус резолюцияләр кабул ителә... Иң мөһиме: бөтендөнья пролетариаты Ватаны – СССРда рәсми рәвештә Совет Язучылары союзы оеша һәм аның төп кануны – Устав кабул ителә. Еллар узып, аз-маз үзгәрү-редакцияләнүләр кичерсә дә, бу Устав ким дигәндә ярты гасыр кагылгысыз булды, 1934 елда кабул ителгән маддәләр XX гасырның 90 нчы елларына кадәр язучылар өчен канун булып яшәде.

Уставның асылын аңлар өчен, аннан берничә маддә-өзек китереп узу мәслихәт булыр: *«Писатели Союза Советских Социалистических Республик, стоящие на позициях Советской власти, желающие активно участвовать своим творчеством в классовой борьбе пролетариата и в социалистическом строительстве, решили объединиться в единый Союз советских писателей».*

*«Союз советских писателей ставит генеральной целью создание произведений высокого художественного значения, насыщенных героической борьбой международного пролетариата, пафосом победы социализма, отражающих великую мудрость и героизм коммунистической партии. Союз писателей ставит своей целью создание художественных произведений, достойных великой эпохи социализма».*

Бу съездда шулай ук совет әдәбиятының үзәге, дөресрәге, принцибы саналган «социалистик реализм» дигән термин тәмам формалашып канунлаштырыла. Бу хакта Уставта болай диелә: *«Социалистический реализм обеспечивает художественному творчеству исключительную возможность проявления творческой инициативы, выбора разнообразных форм, стилей и жанров».*

Менә шушы дөньякүләм идеологик акциядән соң язучылар мохитен – шул 70 еллык чорны – ничегрәк итеп системалаштырырга соң? Нинди принциптан чыгып, нинди периодларга бүләргә? Бу мәсьәлә галим-голәма өчен дә, әлбәттә, актуаль булып кала. Әйтик, «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 томлыгын карасаң, анда үзенчә бер тәртип: дистә елларны иҗтимагый-сәяси вакыт берәмлегенә карап бүлү һәм бәяләү күзгә ташлана. Ә әдәбиятның үз үсеш-торгынлык чорларын исәпләп системалаштырсаң, бүтәнчәрәк бүленеш килеп чыга. Чоры катлаулы һәм болганчык булгач, бернинди бүленеш тә фәнни объектив кысаларга сыеп бетә алмый. Шулай да, үзем тоемлаганча һәм аңлаганча, дүрт периодка бүлеп карар идем бу

70 елны: *1934 елдан сугыш ахырына кадәрге еллар; сугыш соңыннан башлап 50 нче еллар ахырына кадәрге еллар; 1960–1990 еллар; 90 нчы еллардан бүгенге көнгә кадәрге еллар.* Әлбәттә, мондый бүленеш тә шартлы һәм ясалма. Ә миңа, үз фикеремне белдерер өчен уңай булгач, тагын нәрсә кирәк?

Әйдәгез, шул шартлы бүленеш кысаларында татар әдәби хәрәкәтен, шул нисбәттән яңа оешкан Язучылар союзы эшчәнлеген күз алдыннан кичереп карыйк.

**I**

Әйе, зур тарихи съездан рухланып, канатланып кайта язучыларыбыз. Эшкә тотыналар... Ә алда? Фаҗигаи еллар, сугыш афәтләре... Шуны гына әйтү җитә: зур съездда яхшылар рәтендә макталган язучыларның яртысыннан күбесе репрессия корбаннарына әверелә! Гарәпчә – мантыйкка, грекча логикага сыймас хәлләр...

Шулай да Язучылар союзы оешу мөнәсәбәте белән әдәби хәрәкәттә җанлану нык сизелә. 1934 ел – тоташы белән Язучылар союзын оештыру елы. Әйтик, май аенда «Кызыл Татарстан»да СССР Совет Язучылары союзының Уставы басыла. Июнь аенда Совет Язучылары союзына кабул итү үзәк комиссиясенең утырышы була. Союзның беренче әгъзалары кемнәр соң? Менә алар: Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, К.Нәҗми, К.Тинчурин, Ш.Камал, Г.Гали, Г.Толымбай, Ф.Бурнаш, М.Әмир, Х.Туфан, М.Җәлил, Ф.Сәйфи-Казанлы, М.Гали, И.Гази, М.Крыймов, Ә.Фәйзи, И.Туктаров, М.Максуд, Ф.Кәрим, С.Баттал, Т.Госманов (Хатип Госманның абыйсы). Совет Язучылары союзына кандидат итеп Ш.Усманов, Р.Ишморат, Б.Зернит, А.Шамов, Галимҗан Мөхәммәтшин, Т.Гыйззәт, Ә.Ерикәй, Н.Баян тәкъдим ителә. Алда әйтеп үтелгәнчә, июль ахырында Татарстан совет язучыларының I съезды үткәрелә... Соңрак Язучылар союзы инициативасы белән төрле секцияләр оештырыла, яшь язучылар белән эшләү буенча консультация бюросы төзелә. Язучылар төрле юбилей чараларында актив катнаша (Пушкинның үлүенә 100 ел, Тукайның тууына 50 ел, Горький, Г.Камал, Ш. Камал, Такташка багышланган кичәләр һ.б.)... Әлбәттә, җыелышлар (гомумиләре дә, партиялеләрнеке дә) үтә, мотивлары «татар совет әдәбиятының яңа үсеш баскычлары» дигән яки шуңа охшашлы формулировкадагы докладлар сөйләнелә... Союзның шул чордагы эшчәнлегендәге бер үзенчәлекне искәртеп үтү кирәк: тәрҗемә эшенә, нигездә, русчадан татарчага тәрҗемә итүгә бик нык игътибар бирелә әлеге чорда. Бу аңлашыла да. СССР Язучыларының I съездында ил халыкларының әдәбиятларын тәрҗемә аша пропагандалау төп мәсьәләләрнең берсе итеп куелган иде. Горький докладында да, башка чыгышларда да күп әйтелә бу хакта. 1934 елда ук Татарстан Язучылар оешмасы каршында тәрҗемәчеләр секциясе эшли башлый. Җитәкчесе – И.Гази. Бу вакытта Казанда инде Марксизм-ленинизм институты оешкан. Ул, нигездә, Ленин, Сталин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнде (бу җәһәттән татарлар, илдәге күп халыкларны уздырып, – милли республикалар арасында бердәнбер түгел микән әле? – Ленинның ул заманда русча чыккан бөтен әсәрләрен татарча бастырып чыгарды. – *Р.Ф.*). Татарстан китап нәшриятында оператив рәвештә М.Горькийның татарча өчтомлыгы дөнья күрә. М.Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»е, Ф.Гладковның «Энергия» исемле романы, А.Корнейчукның «Эскадраның һәлакәте» дигән пьесасы, А.Гайдарның «Мәктәп» повесте басылып чыга... Тәрҗемәчеләре А.Шамов, Ш.Камал, Ф.Бурнаш, С.Әдһәмова һ.б. «Совет әдәбияты»ның шул еллардагы саннарын алып карасаң да, журналның иң күп өлеше тәрҗемә әсәрләргә бирелгән. Күрәсең, директив күрсәтмә арттырыбрак үтәлгән. Бер яктан, татар укучысы рус әдәбиятын туган телендә укый алган. Әсәрләрнең идея-художество дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, телне саклау җәһәтеннән бу гамәл аклана да кебек. Әмма... Хәрәкәт бер яклырак булган шул. Дөрес, «Огонек», «Литературная газета» битләрендә татар язучыларының кайбер кечкенә күләмле әсәрләре басылу очраклары да булган...

Болар, нигездә, 1934–1936 еллар, Язучыларның оештыру съездлары үткәннән соң беренче еллар. Ниһаять, ил тарихының шомлы 1937–1938 еллары. Әйткәнемчә, аңларга һәм аңлатырга авыр чор... Язучылар лидеры булып, Союзны оештырып йөргән яки бу башлангычны күңеле һәм гамәле белән хуплаган байтак әдипләр кулга алынып төрмәләргә утыртылган. Әле бер ел элек кенә 25 еллык иҗат бәйрәме үткәрелгән К.Тинчурин ябылуда, Г.Ибраһимов – төрмәдә... Вакыт аралыкларында бераз аерымлыклар булса да, шул ук язмышка дучар булган И.Салахов,

Ш.Усманов, Г.Толымбай, Г.Гали, М.Галәү, Г.Нигъмәти, Ф.Бурнаш, Г.Рәхим, Җ.Вәлиди, Ф.Кәрими, С.Сүнчәләй, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Нәҗми, Ф.Кәрим, М.Әмир, С.Рәфыйков, Л.Гыйльми, Х.Туфан... Исемлекне дәвам иттерергә була. Кайсылары юкка чыгарылган, кайсылары алтын гомерләре мәхбүслектә үткәч кенә кайта алган, кайсылары фәлән ай гына утырып, куркытылып, кушканны үтәүчеләр булып калган... Әдәби фигураларның байтагы кулга алынгач, көчләр таркатылгач, табигый, Союзның тулы канлы эшчәнлеге турында сөйләү кыен... Чор «таләбе» буенча Оешма җитәкчелегендә дә яңа «лидерлар» пәйда була. Т.Имаметдинов, И.Вахитов, Х.Җәмил... Бу исемнәрне өлкән буын язучыларының да бик сирәге ишетеп кенә белә булыр... Архив тарихында бар саналсалар да, әдәбиятта алар юк. Шулай да еллар хроникасына күз салсаң, оештыру эшләре бер дә бармаган дип әйтеп булмый. Әйтик, 1937 елның 28 апрель – 5 май көннәрендә Татарстан язучыларының гомуми җыелышы була (докладчы – Т.Имаметдинов), июнь аенда Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар» пьесасын укып тикшерү уздырыла, сентябрьдә иң яхшы опера либреттосына игълан ителгән конкурсның комиссия составына берничә язучы кертелә, «Совет әдәбияты»ның 6–7 нче саннары тулысынча диярлек М.Горький иҗатына багышлана. 1938 елның апрелендә Тукайның үлеменә 25 ел тулуга багышланган зур кичә үтә, июньдә язучыларның гомумҗыелышы уздырыла (докладчы – Н.Баян). 1939 елның башында яшь язучыларның зур бер төркеме Оешмага әгъза итеп алына (Ф.Хөсни, А.Шамов, Г.Бәширов, Г.Галиев, Г.Гобәй, А.Әхмәт, А.Алиш, Ә.Исхак, Р.Ишморат, Г.Хуҗи, И.Гази, Г.Кутуй, Н.Дәүли, Х.Госман, М.Бубеннов, С.Хәким, Г.Хәбиб, Г.Халит, Л.Җәләй, М.Вәдүт, М.Әблиев; ел ахырында бу төркемгә Н.Исәнбәт, Х.Садри, С.Урайский, Ә.Камал һәм тагын берничә айдан З.Солтанов, Ә.Ерикәй дә өстәлә), Язучылар союзының фольклор секциясе әзерләгән «Халык иҗаты» дигән җыентык басылып чыга, СССР Верховный Советы указы белән Ш.Маннур – «Хезмәт Кызыл Байрагы», Т.Гыйззәт «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнә, бер елдан соң Ш.Камалга СССРның иң зур ордены – Ленин ордены бирелә (соңрак «орденлы шагыйрь», «орденлы язучы» дигән сүзтезмә әлеге язучыларның исемнәренә озак дистә еллар синоним-тагылма булып йөриячәк). Язучылар оешмасы өчен бу елның иң мөһим вакыйгасы, мөгаен, Муса Җәлилнең Язучылар идарәсенең җаваплы секретаре, ягъни җитәкчесе итеп сайлануыдыр. Әдәби җитәкчелекнең очраклы кешеләрдән арынуы – бу инде репрессиянең бетүгә, илдә сәяси-рухи тормышның беркадәр савыгуга таба баруын күрсәткән фал иде. Гомумән, сугыш алдындагы ике елда татар җәмәгатьчелеге өчен күңел булырлык гамәлләр кылына башлый. Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла (беренче куелган тамаша Н.Җиһановның «Качкын» операсы. Ә.Фәйзи либреттосы). Татарстан хөкүмәте Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. СССР Халык Комиссарлары Советы карамагында Сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә Татар сәнгате декадасын үткәрергә планлаштыра... Югалтулар табулардан күбрәк булса да, нindидер стимул бар!

Шул чорда (яки беркадәр алданрак) язылган кайбер әсәрләрне хәтеребезгә төшермәсәк, сүз сөрешенең мәгънәсе тулы булмас. Алар – «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Кутуй), «Агыйдел» (М.Әмир), «Мәрҗәннәр» (К.Тинчурин), «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт), «Флейталар» (Ә.Фәйзи)... Бу әсәрләрне язуда Язучылар оешмасының тәэсире никадәр булгандыр, аны гүр иясе булган ул язучылар үзләре генә белгәннәрдер, без фәкать фараз итә генә алабыз. Хронология буенча шул елларга туры килә үзләре... 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Идегәй» дастанының дөнья күрүе үзе бер вакыйга була. Бу бөек дастан әдипләр, бигрәк тә шагыйрьләр өчен бик озак еллар осталык мәктәбе булып хезмәт итәчәк әле.

*** * ***

Сугыш еллары... Бөек Ватан сугышы еллары. Сугыш сүзе алдындагы эпитетларга гасыр ахырында төрле кешеләрнең төрлечәрәк фикере булса да, барыбер илдәшләрнең илбасарларга каршы сугышы иде ул. Шуңа күрә «Канга – кан, үлемгә – үлем!» дигән сүз шигар генә түгел, халык күңеленә иңдерелгән һөҗүмчән максат та иде. Менә шулай килеп чыга икән дөньяда: Татар сәнгате декадасы уздырасы Мәскәү шәһәренең иң әүвәл үзен саклыйсы бар икән әле! Шул бәйрәмдә катнашырга тиешле башкала язучыларын Казан вокзалында каршылап, Казанның үзендә, яшәү өчен аннан да аулаграк Чистай, Алабуга шәһәрләренә күчереп урнаштырышасы бар икән! Үзебезнекеләргә шинель киеп Карелия, Волхов, Украина

фронтларында карлы-бозлы окопларда ятасылар, атакаларга күтәрелеп ут астына керәселәр бар икән! Сөйлиләр бит: Свияжск станциясендә ике поезд очрашкан. Казан ягына баручы Мәскәү язучылары татар язучыларыннан сорыйлар икән: «Сез кая?» – «Фронтка!», «Ә сез?» – «Эвакуация белән Чистайга!..»

Шулай итеп, татар язучыларын 1937 еллар бер «чабып» ташлаган булса, икенче бер афәт – сугыш – янә байтагын кырып салды. Бүтән халыклар белән чагыштырганда, сан нисбәтендә язучылардан иң күп югалту татарда, диләр. Булгандыр, саный башласаң да, байтакка чыга бит: М.Җәлил, Ф.Кәрим, А.Алиш, Г.Кутуй, Н.Баян, Х.Мөҗәй, М.Вәдүт, Р.Ильяс, К.Басыйров, М.Әблиев, Р.Саттар, Д.Фәтхи, Х.Кави... Әзтабар-журналист, язучы Ш.Мостафин язып чыкканча, Ватан сугышында 104 татар язучысы һәм журналисты (яшь һәм башлап язучыларны да кертеп) катнаша, шуларның 31 е корбан була. Өчтән бере дигән сүз!

Исән булып кайтканнарның да күбесе фронт яраларыннан җәфаланып яшәде. Фронтовикларның кайберләре – Ә.Давыдов, Ш.Мөдәррис, З.Мансур, С.Урайскийлар һ.б. – 50 яшьләренә дә җитми дөнья куйдылар. Гомумән, физик яктан сау килеш теге яки бу формада фронтта булмаган татар язучысы бик аз.

Язучылар союзы эшчәнлегенә кайтыйк. Сугыш башлануның беренче көннәреннән үк Союз идарәсе утырышларында Оешманың эшен хәрби шартларга яраклаштыру мәсьәләсе карала. Тукай исемендәге кабинет (соңрак клуб дип йөртелгән зал ул елларда шулай аталган, аннан соң бу залда «Мәгариф» нәшриятының техник хезмәткәрләре – компьютерчылар, корректорлар эшләде) үзенә күрә бер штабка әверелә. ПВХО төркеме оештырыла, Мәскәүнең качак язучыларын үзенә сыендыра, интернационал составтагы язучылар җыелышлары уздырыла (мәсәлән, бу залда А.Фадеев «Совет язучылары Ватан сугышында» дигән доклад ясый), оборона фондына акчалар җыйнала (Т.Гыйззәт, Ш.Камал – 1000 әр сум, Г.Кутуй 650 сум акча кертә), сугыш шартларында язучының барлык иҗат эшләрен яңача кору, бөтенләе белән фронт өчен хезмәткә буйсындыру һәм активлаштыру, шуларга җитәкчелек итү өчен язучылар идарәсе каршында агитация-пропаганда бүлеге оештырыла (җаваплылар – Ш.Маннур, Т.Гыйззәт, Р.Ишморат, Г.Кутуй)... һәм 1942 елның 8 гыйнварында Казандагы совет һәм чит ил язучылары катнашында Тукай клубында М.Җәлилне фронтка озату була (Мәңгелек бөеклеккә озату! Җаны һәм бармаклары Ходай тарафыннан музыка өчен яратылган икенче бөек талантны – Фәрит Яруллинны, белмим, ничек озатканнардыр?!).

Татарстанга Мәскәүдән, эшелонлап дигәндәй (200 дән артык язучы үзләренең гаиләләре белән килә безгә), олуг-олуг язучылар килеп төшкәч, Казаннан тыш, Чистай да үзенчә бер әдәби мәркәзгә әйләнә. Шулай булмый ни! Кемнәр генә юк анда! К.Федин, Н.Асеев, М.Исаковский, Л.Леонов, Б.Пастернак, Л.Ошанин, К.Тренев, Д.Бедный, А.Сурков, В.Инбер, А.Тарковский, В.Боков... Тагын күп дистә исемнәр санарга мөмкин. Алар турында уйлаганда, сугыш чорында Чистайда яшәгән Л.Леоновның мәгълүм сүзләре искә төшкәли: «Если бы только и было суждено в жизни телом остановить пулю, летящую в сторону Родины, то и для этого стоило рождаться на свет».

1941 елның көзенә таба Чистайга Мәскәү язучыларының байтак гаиләләре дә күчеп килә. Аларның күбесе биредә ике еллап яши. Алар өчен Литфонд тарафыннан махсус ашханә ачыла. Гаиләләре янына фронттан А.Твардовский, А.Сурков, С.Щипачев, И.Сельвинский һәм башка күренекле шагыйрьләр кыска сроклы командировкаларга кайтып йөриләр. Чистайда СССР Язучылар союзы җитәкчесе А.Фадеев та берничә мәртәбә була. Чистайда яшәүче язучылар, мораль яктан булса да, фронтка ярдәм итүдә үзләренчә байтак эш башкаралар. Әдәби кичәләр, коллективларда, мәктәпләрдә очрашулар, матбугатта һәм радио аша чыгышлар... Иҗат һәм оештыру эшләре дә тукталып тормый: Л.Леоновның «Нашествие» пьесасы буенча премьера булып уза, Б.Пастернак Шекспир әсәрләрен тәрҗемә итә, Л.Ошанин СССР Язучылар союзына тәкъдим ителә... Эвакуациядәге язучылар тормышы турында Г.Мухановның 1987 елда Казанда чыккан «Чистопольские страницы» дигән китабында тәфсилле язылган. Чистайдагы Б.Пастернак музеенда да бу хакта шактый материал бар. Эвакуациягә килгән язучылар бер Чистайда гына яшәмәгәннәр. Әйтик, сугыш алдыннан гына «Спи, младенец! Не то злому псу – татарину отдам!» дигән юллар язган шагыйрә М.Цветаеваның гомере Татарстан җирендә – Алабугада очлана... Дөнья бу!

Ил өстенә килгән уртак афәт, һичшиксез, кешеләрне берләштергән, туганлаштырган – максат бер, күңел ачык булгач, тар җирне дә киң итеп качакларны сыендырган татар җире.

Кайбер Мәскәү язучылары татар язучысы гаиләләрендә дә сыену тапкан. Максат уртак – дошманны җиңү! Сугыш башында ук «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») «Бөтен көч – дошманны җиңүгә!» исемле редакцион мәкалә бастыра. Анда мондый юллар бар: «Йөз миллионнарча кешеләрнең ирке, бәхетле тормышы, якты киләчәк һәм намусы өчен бара торган бу бөек көрәштә культура фронтының бөтен армиясе бердәм булып фашизмга каршы аяусыз сугышка күтәрелде. Туры сүз массаларда дошманга каршы ачы нәфрәт, каты ачу тудырсын, миллионнарга үзенең туган иле каршындагы мөкатдәс бурычын төшендереп бирсен... Шагыйрьләрнең шигыре сугышчыларны геройлыкка рухландыра торган көчле чаң булып яңгырасын!..» Сүз уңаеннан билгеләп узыйк: сугыш чорында шигырь чаң булып кына яңгырамады, меңләгән укучылары аша дошман йөрәгенә ук булып кадалды, бәгырен ут булып өтте... Дистәләгән шагыйрьләребез иҗаты, беренче чиратта М.Җәлил һәм Ф.Кәрим иҗаты шуны дәлилли.

Шул еллар хроникасына янә күз салыйк. Нинди генә шартлар булмасын, фронттагы, тылдагы тормыш барыбер дәвам итә, үлем-хәсрәт тә, кайгы-яшь тә кешеләрнең яшәүгә омтылышын туктата алмый. Язучылар оешмасында да эш-хәрәкәт бара. Язучылар тарафыннан (К.Нәҗми, Г.Кашшаф, Х.Ярми) күмәкләшеп «Татар халкының фронтовик татарларга сәлам хаты» языла. Соңрак миллионнан артык кеше кул куйган бу хат «Правда», «Известия» газеталарында игълан ителә (1943, март), аннан соң республика һәм фронт газеталарында басылып чыга. Классикларның, бигрәк тә рус язучыларының төрле уңай белән (М.Лермонтовның үлүенә 100 ел, М.Горькийның тууына 75 ел, И.Крыловның үлүенә 100 ел, А.Грибоедовның тууына 150 ел һ.б.) юбилейлары уздырыла, апрель айларында Г.Тукайны искә алу кичәләре үтә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында «Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше» турында карар кабул ителә. Шул чор хроникасыннан искә алырлык тагын бер мөһим вакыйга: 1943 елның октябрь аенда СССР Язучылар союзы президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы махсус тикшерелә. А.Фадеев рәислегендә үткән бу җыелышта Казаннан – Т.Гыйззәт, К.Нәҗми, Н.Исәнбәт, Г.Кашшаф; шуларга өстәп фронттан чакырып кайтарылган Г.Кутуй, Ә.Ерикәй, М.Садри, Г.Галиев катнаша. Шул еллардагы татар әдәбияты турында Г.Кашшаф доклад ясый (сугыш елларында ул Казан әдәби хәрәкәтендә иң үзәк фигураларның берсе була. М.Җәлилнең васыять рәвешендә язган язмасында аның исеме беренчеләрдән булып аталуы тиккә түгел!). Татар әдипләренә М.Горький кебек туганнарча караучы А.Фадеев язучылар делегациясен ВКП(б) Үзәк Комитеты пропаганда һәм агитация бүлегенең җаваплы хезмәткәрләре белән дә очраштыра. «Авыр сугыш елларында татар телендәге әдәби журналның («Совет әдәбияты») саклануын партия Үзәк Комитетында хупладылар гына түгел, бәлки югары бәяләделәр: «Бу – сезнең каһарманлык!» Партия Үзәк Комитеты безгә тиражны өч тапкырдан күбрәк арттырырга (ул елларда журналның тиражы уртача 4 мең) һәм 10 мең данәгә кадәр җиткерергә рөхсәт итте һәм кәгазь ягыннан ярдәм күрсәтте» дип язды соңрак журналның шул еллардагы редакторы Гази Кашшаф.

Фронтта да байтак язучыларыбыз, каләмне штыкка тиңләп, алгы сызыктагы сугыш операцияләрендә катнашу белән бергә фронт газеталарын чыгаралар. Ул газеталарның тарихы болай: 1942 елның башыннан Германия идеологлары инициативасы белән СССР халыкларының күп телләрендә газеталар чыгарыла башлый, аларны совет сугышчылары арасында таратырга тырышалар. Мәсәлән, татар телендә «Идел-Урал», «Хәбәрче» исемле газеталар, «Татар әдәбияты» дигән журнал чыгарыла. Шуңа каршы җавап итеп ВКП(б) Үзәк Комитеты, ашыгыч рәвештә дигәндәй, «Матбугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары» дигән карар кабул итә, һәм тиздән милли телләрдә газеталар чыга башлый. 1942 елның июленнән башлап төрле фронтларда татарча уналты газета чыга: «Ватан өчен», «Алга, дошман өстенә!», «Сталин байрагы», «Совет сугышчысы» һ.б. Үз вакытында аларда Г.Кутуй, А.Шамов, М.Максуд, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, А.Әхмәт, Х.Госман, Ә.Исхак, Ш.Маннур, Г.Насрый, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, Б.Рәхмәт, Г.Галиев һ.б. язучылар эшләгән. Шулай ук Г.Бәширов, М.Әмир, Ф.Хөсни, Г.Иделле, Х.Хәйри һ.б., озак вакытлы командировкаларга барып, бу газеталарда эшләп-эшләп алалар.

Сугыш чорының бер төере булып зыялылар, шул исәптән язучылар аңына сеңеп калган тагын бер документ турында әйтми китеп булмый. Ул – 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитетында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм

идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» дигән карар. 1944 ел... Сугышның Советлар Союзы файдасына бетәчәге тәмам ачыкланган ел. Бөтен совет халкын, төрле милләт вәкилләрен рухландырып, уртак җиңүгә бер йодрык булып барасы иде дә... юк! Тагын репрессияләр. Тулы бер халыкларны көчләп үз илләреннән куалар: балкарлар, калмыклар, Кырым татарлары, чеченнар, греклар, карачайлар... Бу карар Идел буе татарларына да үзенчә бер мәгънәле «күз агы белән карау» иде. Карар иң беренче чиратта тарихчыларга, язучыларга юнәлтелгән, «тарихыгызны ныклап өйрәнеп, аннан каһарманнар эзләп маташмагыз! Тарихны кушылганча гына аңлагыз һәм аңлатыгыз!» дигән мәгънә ята иде бу документта. Карарның шаукымы шактый еллар барды. 60 нчы еллар башында без студентларга әдәбият белгечләре лекцияләрендә сабак-нәсихәт рәвешендә бу карардан цитаталарны бик мул китерәләр иде әле...

Гаделлек өчен 1944 елда булган позитив ике вакыйганы да искә алып үтик: шул ук август аенда Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештыру, Ш.Камалның квартира-музеен булдыру турында РСФСР Халык Комиссарлары Советы карары һәм икенчесе – Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу. (Татар әдәбияты-мәдәнияте тарихында бүлекнең әһәмияте әйтеп бетергесез. Бүгенге әдәбиятны тудыручылар, нигездә, университеттан, шушы бүлектән үсеп чыккан язучылар.)

Шул ук айда Берлинның Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең, Абдулла Алишның һәм тагын тугыз батырның башлары киселә. Берничә атнадан Дахауда Хәйретдин Мөҗәй мичтә яндырыла... Болары да сугыш чорының тетрәндергеч фактлары...

Менә без булдыра алган кадәр әдәби хәрәкәтнең, шул исәптән Язучылар оешмасы эшчәнлегенең дә бик тә катлаулы чорын үзебезчә күзаллап, күзәтеп чыктык. Шәхес культы һәм сугыш елларын, күп дистә миллионнарның фаҗигасен эченә алган бу чор – анализ өчен ифрат кыен чор. Кайбер нәтиҗәләрне киләчәк хакына уйланулар рәвешендә укучылар үзләре ясар. Күзәтү барышында аерым вакыйгалар яки факт-документлар нисбәтендә кайбер фикерләремне әйткәләдем. Бу чор әдәби хәрәкәтенә нәтиҗә ясап, берничә штрих кына өсти алам. Зур күтәренкелек, зур планнар белән төзелгән Язучылар союзы, яшәвенең беренче елларында ук бик нык сирәкләндерелсә, хәлсезләндерелсә дә, сугыш елларында авыр югалтулар кичерсә дә, барыбер Оешма булып сакланып кала алды, иҗат көчләрен мобилизацияләүче штаб ролен үтәде (бу очракта Язучылар союзының башында торган берничә шәхеснең исемнәрен атап үтү дөрес булыр: К.Нәҗми (1934–1937), М.Җәлил (1939–1941), Т.Гыйззәт (1942–1944)...). Автономик кысаларда, җитмәсә, экстремаль сугыш чорында, рухи терәк һәм бергәлекне тояр өчен генә булса да, татар язучыларының үз оешмалары, үз үзәкләре булуы уңай бәяләнергә хаклы.

Бу чорда «әдәбиятның әнкәсе» саналган поэзиянең көче, халыкчанлыгы, яшәүчәнлеге тагын бер мәртәбә расланды. Моңа дәлил итеп М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Ф.Кәримнең сугыш чоры әсәрләрен (әйтик, «Кыңгыраулы яшел гармун», «Идел егете») искә алу да җитә. Бүтән жанрларда, бәлки, ул кадәр үк казанышлар булмагандыр (табигый, сугыш чорында – фронттамы, тылдамы – киң полотнолы зур романнарның тууы икеле), шулай да кайбер әсәрләр язылып калынган. Әйтик, «Миңлекамал» драмасы (М.Әмир), «Йөзек кашы» (Ф.Хөсни)... Сугыш елларында ул чакта әле яшь, ә соңрак әдәбиятта зур урын тотачак байтак язучылар гыйбрәтле тормыш мәктәбе генә түгел, иҗади үсү мәктәбен дә үттеләр. Ә.Еники, Г.Әпсәләмов, Ә.Фәйзи, А.Шамов, А.Расих, И.Гази, Ш.Мөдәррис, Ә.Давыдов һ.б. шундыйлардан.

**II**

Сугыштан соңгы елларга күчик. Алдан әйтелгән бүленеш буенча, бу чор 1945–1960 елларны (60 нчы еллар башын) үз эченә ала. Алдагы дистә еллар белән чагыштырганда аңлаешлырак, тотрыклырак чор! Сугыш беткән, ачлык-ялангачлык хәттин ашса да (дистәләгән төрдәге салымнар, мәҗбүри заемнар...), кешеләр күңеленең өметле чагы: җимереклекне торгызабыз, илдә социализм – гадел җәмгыять төзибез, киләчәктә, һичшиксез, яхшы яшәячәкбез! Һәрхәлдә, күпчелек шулай уйлаган. Әмма шунысы бар: бу чор Сталин хакимиятенең иң «кикрикле» чагы, «Генералиссимус доктринасы»ның халыкара дәрәҗәдә санлаштыра торган чагы... Әлбәттә, реаль тормыш шартлары, куелган максат-шигарьнең

ясалма-декларатив булуы кемнәрдәдер протестлы тойгылар да уяткан. Юкса 50 нче еллар башында япь-яшь студентлар, башлап язучы талантлы егетләр – А.Гыйләҗев, Г.Тавлин, М.Рәфыйков, А.Тимергалин һ.б. – төрмә-зинданнарга юлыгыр идеме?

Язучылар союзы эшчәнлегенең төп этапларын, гамәл-нәтиҗәләрен, максат-юлларын билгеләүче төп маяк-ориентир ул – съездлар, соңгы дәвердәгечәрәк әйтсәк, корылтайлар. Чөнки съезд – Язучылар оешмасының идарә органнарын сайларга вәкаләтле иң зур җыен. Съездлар аша әдәби хәрәкәт дисбесенең төп төеннәрен (бу очракта тенденцияләрен) тоеп, чамалап була. Әйе, алда тәфсилләп әйтелгәнчә, беренче оештыру съезды Казанда да, Мәскәүдә дә 1934 елны узды. Шул ук елны СССР Язучылар съездында кабул ителгән Устав нигезендә язучылар съездлары өч елдан өч елга уздырылырга тиеш диелгән. Ә ничек килеп чыкты? СССР язучыларының II съезды нәкъ егерме елдан соң – 1954 елда гына җыелды! Ирексездән русларның «Закон как дышло...» дип башлана торган әйтеме искә төшә. Егерме ел бит! Сугыштан соң да ун елга якын вакыт үтә... Димәк, бу оешма, табигый ихтыяҗдан бигрәк, хакимиятнең ихтыяр көче белән идарә ителә торган оешма булып чыга.

Шулай да Татарстан язучылары 1950 елда үзләренең II съездын үткәрәләр. (СССР Язучылар союзының II съездыннан дүрт ел элек!) Үзәк кушуы беләнме, әллә җирле инициатива өстенлек иткәнме? Мөгаен, соңгысыдыр. 1950 елның язында КПССның Татарстан өлкә комитеты «Татарстан совет язучылары союзының эше турында» дигән махсус карар кабул итә. Бу инде үзенә күрә съезд алды прелюдиясе дигән сүз. Конкрет съездлар эшчәнлегенә кадәр сугыштан соңгы унбиш ел эчендәге кайбер факт, вакыйгалар белән танышып үтик. Тукайның 60 еллыгы зурлап билгеләнә (Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында тантаналы кичә үтә; Казан университеты һәм педагогия институты студентлары өчен Г.Тукай исемендәге стипендияләр билгеләнә; СССР Фәннәр академиясендә шагыйрьгә багышланган фәнни сессия уздырыла һ.б.). Татарстан Мәгариф комиссариаты һәм Язучылар союзы балалар өчен татар телендә язылган иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итә. Шагыйрь Ә.Ерикәй СССР Верховный Советына (1946), К.Нәҗми Татарстан АССР Верховный Советына депутат итеп сайлана. Чистай шәһәре музеенда «Язучылар Чистайда» дигән яңа бүлек оештырыла. Рус телендә «Литературный Татарстан» дигән альманах чыга (1947–1958). 1951 елда К.Нәҗминең «Язгы җилләр», Г.Бәшировның «Намус» романнары Сталин (соңрак аны Дәүләт премиясе дип тә йөрттеләр) премиясе белән бүләкләнә. 1953 елда М.Җәлил өстеннән «кара болытлар» алып ташлана, берничә елдан аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә, «Моабит дәфтәре» Ленин премиясенә лаек була. Сугыш елларында тукталып калган «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасы, «Чаян», «Пионер» («Ялкын») журналлары кабат чыга башлый. Хәзерге «Идел» журналының яралгысы саналырга тиешле «Үсү юлы» дигән альманах чыга (1950–1958). 1957–1958 еллар әдәби-мәдәни вакыйгаларга бигрәк тә бай. 1957 елның 24 май – 4 июнь көннәрендә Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгать декадасы гөрләп үтә (алда әйтелгәнчә, ул декада 1941 елның ахырына планлаштырыла, сугыш башлану сәбәпле булмый кала). 1958 елда «әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея-эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр өчен һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкарган өчен» Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе булдырыла. Шул ук елның 9 августында Казан үзәгендә Тукайга һәйкәл торгызыла (соңрак бу урын Тукай мәйданы дип йөртеләчәк). Бу еллар елъязмасының тагын бер кадерле сәхифәсе – шәхес культы корбаннары аклана. Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, М.Галәү, Г.Газиз, Ш.Усманов, Ф.Бурнаш, Г.Нигъмәти һ.б.ның әсәрләре кабат басыла башлый, зиндан-сөргеннәрдән исән калган Х.Туфан, И.Салахов, С.Рәфыйков кебекләр әдәби сафка кайта... 50 нче еллар ахырында соңрак халык язучылары, халык шагыйрьләре булачак, әле ул вакытта өметле яшь язучылар саналган Г.Ахунов, И.Юзеев, Ш.Галиев, Г.Афзал, Х.Камаллар әдәбиятта яңа буразналар сала. 1957 елны беренче мәртәбә Татарстан язучылары турында белешмәлек – биобиблиографик китап чыга (анда 126 язучы турында мәгълүмат бирелгән. Соңрак мондый характердагы китаплар 1970 һәм 1986 елларда дөнья күрде). Медицина институты студенты (!) Ш.Хөсәенов пьесасы буенча Г.Камал исемендәге Академия театрында «Профессор кияве» исемле спектакль куела...

Әйе, тыныч тормышка хас вакыйгалар хроникасы. Әйтергә кирәк, чагыштырмача матур хроника! Язучыларның төп җыены булган съездлар үткәрү дә билгеле бер тәртипкә салына башлый.

Татарстан язучыларының II съезды 1950 елның 13–15 июнь көннәрендә үтә. Съездда язучылардан тыш республика җитәкчеләре, СССР Язучылар союзы һәм үзәк нәшрият вәкилләре, фән эшлеклеләре, журналистлар, укытучылар, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче студент яшьләр катнаша. Татарстан Совет Язучылары союзы идарәсенең эше турында хисап докладын Г.Кашшаф ясый. Ревизия комиссиясе отчеты белән Г.Гобәй чыга. Фикер алышуларда 29 кеше катнаша. Алар арасында – Г.Әпсәләмов, К.Нәҗми, Н.Исәнбәт, Г.Гулиа (Мәскәү), С.Баттал, Ш.Мөдәррис, С.Кирьянов (Мәскәү), З.Мансур, М.Хөсәен, М.Максуд, И.Нуруллин, Ә.Давыдов, М.Елизарова, Х.Рәхмәтуллин (ВКП(б) өлкә комитеты секретаре), Г.Насрый, А.Гомәр һ.б.

Съезд Татарстан совет язучыларының эшен канәгатьләнерлек дип тапмый һәм киләчәктә эшне яхшыртуга юнәлтелгән карарлар кабул итә. Съездда яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылары союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана: Г.Гобәй, К.Нәҗми, Г.Бәширов, М.Әмир, Г.Халит, Р.Ишморат, К.Лебедев, Ә.Исхак, Н.Исәнбәт, И.Гази, С.Вәлиди (җаваплы секретарь). Идарә утырышында рәис вазифасы Г.Гобәйгә йөкләнә.

«Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп Г.Кашшаф раслана.

Шулай итеп, съездда Язучылар союзы идарәсе эше канәгатьләнерлек дип табылмый. Совет дәверендәге идарә механизмында болай бәяләнү сирәк очрак. Язучылар союзы эшенә съезддан бигрәк КПСС өлкә комитетының бәясе бу. Съездда әлеге бәя кабатлана, дөресрәге, кабатлаттырыла гына. ВКП(б) ҮКның 1944 елдагы алда әйтелгән карары, шул ук ВКП(б) ҮКның «Звезда» һәм «Ленинград» журналларын нык тәнкыйть иткән еллар бит (1946 елның 14 августында чыккан карар). Өстән директива бар! Каләм әһелләрен кысада тотар өчен, урыннарда да, бу очракта Татарстанда, нигә аналогик карар чыгармаска? Алда телгә алынган ВКП(б) өлкә комитетының «Татарстан Совет Язучылары союзы эше турында» дигән карар тулысы белән тәнкыйтькә корылган («зур кимчелекләр бар», «тиешенчә җитәкчелек итми», «өйрәнүдән читтә торалар», «бер-берсен тәнкыйтьләмиләр», «үсеш юлларын дөрес чагылдырмый», «ярдәм күрсәтмиләр», «буржуаз язучының чын йөзен ачмыйлар», «зур хаталар җибәрелә», «тирән анализ ясалмый», «тикшерүләр аз үткәрелә», «канәгатьләнерлек түгел» һ.б.). Арада дөресләре дә бар, әлбәттә. Ә язучыга шәхес культы, сугыш елларында киң полотнолы, хакыйкатькә хилафлык китерми торган әсәрләр язарга мөмкинлек булдымы соң? Бу чор өчен доклад ясаган Г.Кашшафның хәлен аңлап була: югары оешмаларга да ярарга кирәк, каләмдәшләр иҗатын да булдыра алган кадәр дөрес бәяләргә кирәк! Бу съездда 1945–1950 елларда идарә рәисе булып торган Ә.Ерикәй нык тәнкыйтьләнә. «Идарә (Ә.Ерикәй А.Шамов, М.Әмир, Б.Зернит, Х.Хәйри, Г.Кашшаф, Т.Гыйззәт), гомумән, язучыларның иҗат эшенә тиешенчә җитәкчелек итмәде» дип табыла.

Тагын дүрт ел үткәч, 1954 елда, янә бер съезд – Татарстан язучыларының III съезды үтә. Ике съезд арасында Союз эшчәнлеге шактый активлаша. Иҗат секцияләренең эше җанлана (проза секциясе җитәкчесе – Г.Әпсәләмов, поэзия секциясенеке – С.Хәким, драматургия – Р.Ишморат, тәнкыйть секциясенеке – Г.Халит), яшь язучыларның республика конференцияләре эшли, иң яхшы яңа әсәрләргә ябык конкурслар игълан ителә, җыелышларда конкрет әсәрләр тикшерү белән бергә теоретик мәсьәләләр турында дискуссияләр дә оештырыла.

Съезд 24–26 июнь көннәрендә Казанда үтә. Съездда төп ике доклад тыңлана. «Татар совет әдәбиятының торышы һәм бурычлары» (Г.Бәширов), «Татар совет әдәби тәнкыйте һәм бурычлары» (Г.Халит). Көн тәртибенең калган мәсьәләләре нигездә хисап һәм оештыру эшләренә бәйле: ревизия комиссиясе эшен тыңлау, идарә һәм II Бөтенсоюз съездына делегатлар сайлау. Шунысы игътибарга лаек: моннан 50 еллар элек тә әдәби тәнкыйть мәсьәләсе актуаль һәм әдәби җәмәгатьчелекнең күз уңында булган (ирексездән Тукайның «тәнкыйть – кирәкле шәйдер» дигән сүзләре хәтергә килә). Докладлар буенча фикер алышуда С.Хәким, М.Дудин (Ленинград), Г.Әпсәләмов, М.Әмир, Ю.Лебединский (Мәскәү), Ф.Хөсни, К.Нәҗми, И.Гази, Г.Мөсрепов (Казакъстан), М.Максуд, Х.Хәйри, Ә.Давыдов һ.б. (барлыгы – 28 кеше) катнаша. Яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылар союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана: Г.Бәширов (председатель), С.Хәким, Г.Кашшаф, Х.Хәйри, Ф.Хөсни, Т.Гыйззәт, Ә.Давыдов (җаваплы секретарь), Г.Әпсәләмов, Б.Зернит.

Игътибар иткәнсездер: хисап докладын алдагы съездда рәис булып сайланган Г.Гобәй түгел, ә 1953 елда аны алыштырган Г.Бәширов ясый. Г.Гобәй шул чордан идарә даирәсеннән китә, фәкать профессиональ иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Үз вакытында «Маякчы кызы», «Замана балалары», «Без үскәндә» кебек әсәрләре белән танылган язучы, соңрак «Коръән серләре» исемле «трактат» язып, дин тотучыларның бәддогасына юлыкты. Киң катлам укучылар арасында каршылыклы фикерләр тудырган бу әсәр заман идеологиясенә ярарга тырышып иҗат итүнең бер гыйбрәтле сабагы булып тора.

Бу съездда 1954 елның декабрь аенда үтәчәк Совет язучыларының II Бөтенсоюз съездына делегатлар да сайлана. Унбер кешелек делегация арасыннан Татарстан исеменнән чыгыш ясау янәдән К.Нәҗмигә йөкләнә. I съездда да татар әдәбияты турындагы докладны ул ясаган икәнне искә төшерсәк, нинди генә катлаулы чорда да К.Нәҗминең үз биеклеген саклап калуын, ныклыгын танырга туры килә.

Чираттагы IV съезд 1958 елда уза. 16 июнь көнне М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында ачыла һәм, дүрт көн дәвам итеп, 19 июньдә тәмамлана. Съездны Н.Исәнбәт (стенографик язмада ул күренекле карт язучыбыз дип теркәлгән. Аңа ул вакытта 59 яшь) ача. Съездда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше турында Г.Бәширов, татар поэзиясенең торышы турында С.Хәким, проза әсәрләре турында Х.Хәйри, драматургия турында Г.Кашшаф, Татарстанда яшәүче рус язучылары турында Г.Паушкин докладлар белән чыгалар. Татар язучыларының съездын котлап килгән кунаклар В.Кожевников (Мәскәү), Б.Кербабаев (Төрекмәнстан), С.Смирнов (Мәскәү), С.Кудаш (Башкортстан), Ә.Мохтар (Үзбәкстан), Җ.Мулдагалиев (Казакъстан) һ.б. чыгыш ясый. Докладлар буенча фикер алышуларда Ф.Хөсни, Н.Дәүли, Х.Госман, И.Пехтелев, С.Баттал, Ә.Ерикәй, Н.Фәттах, М.Максуд, Г.Ахунов, Х.Якупов, Җ.Фәйзи, Ш.Хөсәенов һ.б. катнаша. 19 июньдә Татарстан язучыларының IV съезды яңа идарә, ревизия комиссиясе һәм РСФСР Язучылар съездына делегатлар сайлый. Идарә составына түбәндәге язучылар кергән: А.Шамов (председатель), М.Әмир, С.Хәким, Г.Бәширов, Ф.Хөсни, Л.Ихсанова, З.Нури (җаваплы секретарь), Г.Кашшаф, Г.Паушкин, Г.Ахунов, А.Гомәр.

Шул ук көнне яңа сайланган идарәнең беренче утырышы була, рәис, җаваплы секретарь да шул утырышта сайлана. «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп А.Гомәр раслана.

Хроникаль рәвештә съездлар турында сөйли киткәч, бу урында янә бер җыен – РСФСР Язучыларының I оештыру съезды турында аерым әйтеп үтү кирәк. Моңарчы әле Үзәкнең бер югары җыены – СССР Язучылар съезды гына бар иде. 1958 елдан соң ул ике Үзәклегә әйләнде: русның атаклы уенчыгы «матрешка» принцибы барлыкка килде. СССР оешмасы, РСФСР оешмасы, ТАССР оешмасы. Кыскасы, күкәй эчләрендә күкәй... Бер караганда, Россиянең үз оешмасы булу кирәк тә булгандыр. Бу гамәл белән үзәктәге рус язучылары мәнфәгатен кайгыртуда яңа мөмкинлекләр ачылды, шулай ук аз санлы дистәләгән халыкларның әле яңа формалашып килгән профессиональ әдәбиятларын аякка бастыруда реаль адымнар ясалды. Әйтик, Төньяк Себер (эвенк, чукча һ.б.) яки Кавказ (карачай, авар, нугай һ.б.) халыкларының профессиональ язучылары барлыкка килде, җирле милли колорит белән сугарылган кызыклы әсәрләр язылды.

Россия Язучылар оешмасы төзелү мең еллык тарихы, ике гасырдан артык басма китап традицияләре булган татар әдәбиятына ни бирде соң? Уңай җавап әйтергә кыенсынам. Чынлыкта, без зур Союздан (СССР Союзыннан) кече Союзга (РСФСР) күчтек. Күчерделәр. Безнең рәсми статус – автономия, ягъни союздаш республикалар рәтендә тормый булып чыкты. Гәрчә зур Союз белән багланышлар өзелмәсә дә (кайбер абруйлы язучыларыбыз СССР язучылар дәрәҗәсендәге чараларда катнашып килде, хәтта югары органнарга да сайланды), һәммәбез СССР Язучылар союзы әгъзасы дигән таныклык йөртсәк тә, без инде рәсми рәвештә турыдан-туры РСФСР Язучылар оешмасына беркетелдек. СССР язучылар съездларына РСФСРдан делегатлар булып бардык. Зур съездларда безнең язучыларыбызның тавышы тоныграк, әсәрләребез турында сүзләр сирәгрәк ишетелә башлады. 1934 елдагыча, язучыларның илкүләм җыенында татар әдәбияты турында махсус докладлар тыңлау, тәфсилле чыгышлар ясау татлы истәлек булып калды. Зур съездлардагы төп докладларда татар

әдәбияты чуваш, башкорт, якут, бурят кебек әдәбиятлар белән бер яссылыкта телгә алына башлады.

РСФСРның бу I съездына Татарстаннан 11 кеше делегат булып бара (Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов, Г.Гобәй, Ә.Еники, Т.Журавлев, Н.Исәнбәт, Л.Ихсанова, Г.Кашшаф, И.Гази, З.Нури, А.Шамов. Бу төркемнән бүгенгә бердәнбер исән кеше – Ләбибә апа Ихсанова. Хәзер аңа 81 яшь (2010 елда – 87 яшендә вафат булды. – *Р.Ф.*), ул чакта 35 булган). Бу съездда Татарстан вәкилләре сыйфатында ике язучы чыгыш ясаган – Ф.Хөсни, А.Шамов. Ф.Хөсни чыгышы (стенографик язма буенча әйтүем) укыр өчен әле дә кызык, фикере искермәгән. А.Шамов Язучылар союзы рәисе сыйфатында чыгыш ясый, түрәләргә хас пафос, реверанс, рәсмилек... Шулай да чыгышта заманы өчен бик тә мөһим мәсьәлә – яшь язучылар өчен журнал кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга (ә мәсьәлә 30 еллап гомер үткәч, партия диктаты йомшап, демократик үзгәрешләр булгач кына – 1989 елда хәл ителде. Мәскәү йогынтысыннан тыш республика җитәкчелеге «Идел» журналын чыгаруны үзе хәл итте).

Татарстан язучыларының 1958 елда үткән IV съезды да, шулай ук РСФСР язучыларының I оештыру съезды да элгәреге җирле һәм бөтенсоюз съездларыннан үзләренең рухлары белән шактый ук аерылалар иде инде. «Алга! Коммунизмга!» кебек шапырынулы шигарьләр күп булса да («член СП СССР обязан всей своей творческой и общественной деятельностью активно участвовать в строительстве коммунизма»), шәхес культы елларына хас шомлылык, куркыну, «урра, Сталин!»лык юк иде. Җәмгыятьтә, эмбриональ хәлдә булса да, демократик чалымнар барлыкка килде. Партиянең ике ел элек (1956) үткән XX съездының нәтиҗәләре, Хрущев «җепшеклеге» рухи тормышта сизелә иде инде... Әмма... СССРның «тимер капкасы» әле ачылмаган диярлек (чит илләргә бик сирәк язучы чыга!). Сәясәттә ике идеология (берсе, әлбәттә, буржуаз идеология) бугазлаша. Кариб кризисына да ерак калмый... Рәсми иҗади оешмалар Пастернак һәм аның ише «декадент интеллигентлар»ның тетмәсен тетә...

Хуш, без үзебезнең хәлләргә кайтыйк. Үзебезнең җирлектә, үзебезнең әдәби хәрәкәт нисбәтендә сугыштан соңгы унбиш елга (шартлы рәвештә үзебез бүлгән классификация буенча) беркадәр гомумкүзәтү ясаганнан соң, кайбер йомгак-нәтиҗәләргә дә килик.

Әйе, үзенчә авыр чор бу! Бигрәк тә сугыштан соңгы еллар... Әмма халыкның рухы сынмаган, киләчәккә ышанычы ныгыган чор. Җиңү, шиксез, ышанычны ныгыткан. Ә уйласаң, ач-ялангач чор бит, авыл халкы «таяк»ка эшләгән чор, чабаталы чор, черек (туңган) бәрәңге чоры (соңрак бу еллар турында Н.Фәттахның «Артта калган юллар», А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» кебек әсәрләрендә ачык язылачак)... Әмма китаплы чор! Шул чорда ачлы-туклы яшәп, тырышып белем алган, китаптан аерылмаган буын XX гасыр ахырына кадәр дөньяның тоткасы булып тора алды да.

Алдарак бу чордагы (1945–1960 еллар) мәдәни-әдәби хроникадан вакыйга саналырлык кайбер фактларны күрсәтеп узган идем инде. Шуларга өстәп әйтергә була: «Татар поэзиясе антологиясе» чыга (1956), дөнья һәм рус әдәбияты классикасыннан йөзләрчә әсәрләр татар теленә тәрҗемә ителә (татар авылларында берничә буын, шул исәптән безнең буын да, шул китапларны укып үсте дә инде! Сүз уңаеннан әйтеп үтик: 60 нчы еллар башында башка телләрдәге матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча Татарстан – СССРда дүртенче урында, ә татар теленнән башка телләргә тәрҗемә ителү ягыннан бишенче урында торган).

Әдәбиятның, гомумән, язу эшенең дәрәҗәсе югары заман бу. Әдәбиятыбызның халыкара танылуына ике зур форсат чыккан еллар. Беренчесе, алда әйтелгәнчә, К.Нәҗминең «Язгы җилләр», Г.Бәшировның «Намус» романнарының Сталин премиясе алуы. Заманы өчен ифрат зур вакыйга. Шушы премия уңаеннан бу әсәрләр дөньяның байтак телләренә тәрҗемә ителделәр, татар әдәбиятының данын еракларга тараттылар. Икенчесе – М.Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме һәм Ленин премиясе бирелү. Җәлил поэзиясе татар шигыре данын тагын да югарырак күтәрде. Соңрак – кырык-илле ел эчендә талантлы әсәрләр байтак язылса да, аларның авторлары халыкара масштабта алай ук яңгырый алмадылар. Субъектив һәм объектив сәбәпләр булды бугай. (Хәер, соңрак, 60–70 нче елларда, Г.Әпсәләмов әсәрләре шактый ук популяр булып алды.) Без тикшерә торган сугыштан соңгы бу унбиш ел эчендә, табигый, әдәбият мәйданын ир уртасы егетләр, сугышта катнашкан фронтовиклар тотты. Төп әсәрләрне дә алар язды. «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Онытылмас еллар» (И.Гази), «Газинур» (Г.Әпсәләмов), «Суд залында» (С.Хәким), «Яшәү белән үлем арасында» (Н.Дәүли)... Һәр чор

әдәбиятының лидерлары була. 50 нче еллар әдәби хәрәкәтенең иң эре фигурасы, һичшиксез, Г.Бәширов. Сталин премиясе лауреаты. СССР Верховный Советы депутаты, Язучылар союзы рәисе... Тел остасы, фольклорчы, гомумән, аксакалларга хас зирәк кеше. Язучылыгыннан тыш оешма хуҗалыгын ныгыткан шәхес. Ярты гасырдан артык тарихы булган язучылар дачаларын – Аккош күле иҗат йортын оештырган, нигезләгән кеше дә шул ук Гомәр ага Бәширов («Аккош күле»ндәге иҗат йорты аерым бер язмага, андагы табигать күренешләре аерым альбомга лаек. Ярты гасырлык тарихы булган бу «Әдәбият бишеге»ндә кемнәр генә яшәмәгән дә, нинди генә әсәрләр иҗат ителмәгән! «Аккош күле»нә бәйле кайбер исемнәрне генә атап узыйк: Х.Туфан, Г.Бәширов, С.Хәким, И.Гази, А.Шамов, Ф.Хөсни, Р.Ишморат, Ш.Мөдәррис, Н.Дәүли, З.Нури, М.Рәфыйков, Х.Хәйри, И.Нуруллин, Г.Латыйп, Н.Юзиев, Г.Сабитов, М.Әгъләм, Р.Гаташ, Ф.Шәфигуллин, Г.Шәрәфетдинов, Ф.Сафин... Болары яшәп киткән язучылар. Әле исәннәрдән янә дистәләгән исемнәр санарга мөмкин. Бүгенге көндә дә биредә дистәдән артык күренекле язучылар яшәп иҗат итә). Ходай Гомәр аганың үзенә дә мәрхәмәтле булды: ул озак яшәп, 98 яшендә (1999 елда) иҗатының кадерен, халыкның ихтирамын тоеп дөньядан китте. Бу чордагы Язучылар оешмасының җитәкчеләрен дә янә искә төшереп үтик: председательләр – Ә.Ерикәй (1945–1950), Г.Гобәй (1950–1953), Г.Бәширов (1953–1958), А.Шамов (1958–1961), рәисләрнең урынбасарлары – җаваплы секретарь вазифаларын фронтовик шагыйрьләр Ә.Давыдов, З.Нурилар башкарган.

Сүз уңаеннан шуны да билгеләп узыйк: 50 нче еллар ахырында, дөресрәге, 1959 елның 18–23 май көннәрендә, зур съезд – СССР язучыларының III съездында Татарстаннан делегат булып җиде язучы (Г.Бәширов, М.Әмир, А.Шамов, Р.Ишморат, С.Хәким, З.Нури, Ш.Галиев. Араларыннан бүген исәне – Ш.Галиев, аңа хәзер 76 яшь) бара. Бу съездда татар язучылары исеменнән М.Әмир чыгыш ясый. Шул чорның, шул зур җыеннарның тагын бер характерлы ягы: СССР күләмендәме, Россия яки республикалар күләмендәме, язучылар съездына илнең иң югары постында торган җитәкчеләр төркеме белән киләләр иде, чыгыш-докладлар ясап, банкет-приемнарда да утыралар иде. Әдәбиятның, язучыларның дәрәҗәсе югары икәнен дәлилләүче күренеш. Әдәбиятка ил башлыкларының мөнәсәбәтен, игътибарын күреп, гади халык та, әлбәттә, язучыларны зурлый, олылый иде...

**III**

Бу өченче бүлектә, инде үзебез дә шаһит булган, шул мохиттә үзебез дә беркадәр әвәрә килгән елларга күчеп, 1960–1990 еллардагы әдәби хәлләргә күз салыйк. Әдәби хәрәкәтне шартлы рәвештә шәкли периодларга бүлүебез буенча, 1934 елдан сугыш ахырына кадәр 10 нан артык ел булса, икенче чор дигәнем сугыш соңыннан алып 60 нчы еллар башына кадәр – 15 ләп елны, бу өченче чор исә чагыштырмача озын – 30 еллап вакытны эченә ала. XX гасырның икенче яртысының саллы төп өлеше дигән сүз. Киләчәктә бу чорның бер-ике сүз белән генә әйтелә торган төгәл билгеләмәсе дә табылыр. Хәер, әйтә дә башладылар инде: «торгынлык» чоры (бу билгеләмә, минемчә, берьяклы)...

Әлеге чорны характерлый торган кайбер вакыйгаларны, тарихи фактларны, лозунг-шигарьләрне искә төшерик. Шул еллар әдәби хәрәкәтенең асылын аңларга җиңелрәк булыр. 60 нчы еллар башларында Хрущев вәгъдә иткән «коммунизм»ның төзелеп бетәргә тиешле чоры бу. 30 елның егермеләбендә Брежнев стабиль идарә иткән чор. СССРның, АКШ лидерлары тарафыннан «явызлык империясе» дип тамгаланса да, дөньякүләм мәйдан тоткан, табигать байлыкларын, бигрәк тә нефтьне ифрат күп чыгарып, нигездә, шуның хисабына милитаристик державага әверелгән чагы. Идеологик яктан да шактый катлаулы чор: тышкы сәясәттә – көч-тырышлык ике системаның көрәшенә (беренче чиратта хәрби потенциалны арттыру юлы белән) сарыф ителсә, эчке сәясәттә – төп игътибар халыкларның милли үзенчәлекләрен бетереп, бердәм совет (рус дип аңларга да була) халкы ясауга юнәлде. (Мәсәлән, Казанда татар мәктәпләре бөтенләй диярлек бетерелде, авыл мәктәпләренең күбесендә уку-укыту русчага күчерелде). Әдәбият хәлләренә килсәк, аның әле абруйлы чагы. «Иң күп китап укучы халык СССРда» дип әйтәләр иде. Дөрес тә булгандыр, өйдә-китапханәдәме, юлда-пляждамы дигәндәй, олысының да, кечесенең дә кулларында китап булыр иде. «Китап – белем чишмәсе» дигән канатлы сүзләр күпчелекнең аңында, күңелендә иде. Әдәбиятның дәрәҗәсе халыкның шигъриятькә мөнәсәбәтендә бигрәк тә ачык чагылды.

Халык ташкын булып, мәйдан-стадионнарны, мәдәният сарайларын тутырып шигырь тыңларга җыелсын әле! Кабатланмас еллар! Без дә – 60 нчы еллар башында әдәбиятка килеп, хәзер 60 яшькә җиткән буын – шигырь язып, иҗат итеп, дөньяны яхшыга үзгәртәбез дип нык ышандык ул елларда! Һәм шул ышаныч илһамландырды да, эшләтте дә, яшәтте дә. Кызыклы чор, парадоксларга бай чор. Бер яктан, «нык үскән социализм» илендә иҗат иреге турында тәкрарланса, икенче яктан, мәгълүм канун-кысаларга яраклы партияле иҗат таләп ителде. «Без йөрәгебез кушканча язабыз, ә йөрәкләребез партиягә бирелгән» дигән сүзләр еш яңгырый иде. Ялгышмасам, бу сүзләрне партия съездында М.Шолохов әйтте шикелле. Әдәбият белән җитәкчелек итүне партия беренче чиратта Язучылар оешмасы аша башкарды. Тулысынча партия идеологиясенә хезмәт иткән оешманың эш стиле дә, табигый, партия дисциплинасына буйсынган булды. Ул стиль шул система өчен уңайлы һәм шактый ук мөкаммәл дә иде. Язучылар съездлары, пленумнары Устав буенча төгәл вакытында үткәрелә (1960–1990 елларда V–XI съездлар, җәмгысы 7 съезд), партия оешмасы җыелышлары вакытында уздырыла, әдәби ел йомгаклары утырышлары зур вакыйгага тиң була (андый җыелышлар үткәрелә башлауга быел 40 ел тулды, ел йомгакларына багышланган беренче җыелыш 1964 елда үтте)... Булдыклы, талантлы язучыларның (дөрес, сирәк-мирәк кайбер әсәрләрдән идеологик «ялгыш» табып, басылмау очраклары булгалады) әсәрләре даими чыгып килде. Каләм хакы бәрабәренә заманы өчен яхшы гына яшәп, гаилә тотып була иде. Язучыларның китапларын бастырып чыгаруда Язучылар союзы реаль булыша алды. Оешма әгъзалары, аларның гаилә әгъзалары иҗат йортларына, курорт-санаторийларга барып иҗат белән шөгыльләнә, ял итә һәм дәвалана ала иде... 50–60 ел эчендә язучы халкы өчен Әдәби фонд аша меңләп путевка-юллама алынгандыр дип уйлыйм.

* * *

Янә съезд хәлләренә кайтыйк. Үземнең беренче мәртәбә Язучылар съездында катнашуым да шул чорда – 60 нчы еллар башында булды. Ул – Татарстан язучыларының V съезды. (Шуннан соңгы 40 елдан артык вакыт эчендә Татарстан язучыларының 10 съездында, СССР, РСФСР язучыларының 12 съездында катнашырга туры килде. Хәтер офыгында һәммәсе дә стенографик эзлеклелектә сакланмаса да, күбесендәге төп чыгышлар, шәхесләр, кызыклы эпизодлар әле һаман истә. Шуңа күрә соңгы берничә дистә еллар әдәби тормыш хәлләрен шәхси күзәтүләрем белән «сипләп» баруым табигыйдер. Тик шунысы бар: күбрәк белгән саен, белгәнеңнең асылын, төшен төгәл итеп кәгазьгә төшерү кыенлаша гына икән; берсе онытыла, икенче берсе төшеп кала кебек.)

V съезд 1963 елның 7 февралендә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында (бу – театр бинасында үткән соңгы съезд, калган җыеннар кечерәк – бүтән биналарда үткәрелә башлады) ачылды. Татарстан язучылары белән бергә кунак сыйфатында союздаш һәм автономияле республика вәкилләре, республиканың партия-совет җәмәгатьчелеге, сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнашкан бу җыен 8–9 февральләрдә үз эшен КПСС өлкә комитетының конференцияләр залында дәвам иттерде. Съездда «Татарстан Язучылар союзының идарәсе эше» (М.Әмир), «Бүгенге татар поэзиясе» (Н.Юзиев), «Татар балалар әдәбияты» (Җ.Тәрҗеманов), «Әдәби тәнкыйтебезнең торышы» (Г.Халит), «Татарстандагы рус язучылары иҗаты» (Г.Паушкин) турында докладлар тыңланды. Чыгыш ясауларда Г.Бәширов, С.Баруздин (Мәскәү), Г.Әпсәләмов, М.Кәрим (Уфа), С.Хәким, Г.Ахунов, Ш.Маннур, Ә.Давыдов, А.Шамов, Я.Ухсай (Чабаксар), Р.Мостафин, Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин һ.б. катнашты. Съездның 10 февральдә үткән соңгы утырышында 17 кешедән торган яңа идарә составы сайланды. Алар: М.Әмир (председатель), Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, Х.Туфан, Ф.Хөсни, З.Нури, Газиз Мөхәммәтшин, Р.Мостафин (җаваплы секретарь), Л.Ихсанова, Г.Ахунов, И.Юзеев, Х.Вахит, Х.Госман, А.Булгаков, Ш.Галиев, Г.Халит, Г.Паушкин.

Театр залында съездда катнашкан атаклы язучылар, кунаклар арасында Р.Харис, Г.Рәхим (Г.Родионов), Р.Мингалимов, Ә.Синугыл, Х.Хөснуллин, Р.Гатауллин (Р.Гаташ) кебек яшьләрнең дә «өлкән» йөзләре хәтердә калган. Халыкча әйтсәк, кеше арасына керә башлаган чаклар...

Шул ук 1963 елны Татарстан Язучылар союзының филиалы рәвешендә Әлмәттә Язучылар бүлеге оештырылды. Шул вакыттагы әдәбият үсеше өчен зур вакыйга. Бу төбәктә моның өчен җирлек һәм инициатива булган, димәк, югарыдан да тиешле булышлык-ярдәм күрсәтелгән. Әлмәт бүлегенең җитәкчесе, ягъни җаваплы секретаре итеп язучы Гариф Ахунов билгеләнә. Бу бүлек, Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче шактый күпсанлы талантлы каләм ияләрен туплап, иҗади рухландырып, шул регионның үзгә бер мәдәни-әдәби үзәгенә әйләнде. Әлмәт ул вакытта нефть башкаласы саналды. Илкүләм масштабтагы төрле чаралар – киңәшмәләр, слетлар, фестивальләр еш үтә иде анда. Татарстанга килгән атаклы язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре Әлмәткә сугылмый калмадылар. Алар, җирле язучылар һәм укучылар белән аралашып, Әлмәт оешмасының ныгуына уңай йогынты ясадылар. Язучыларның Әлмәт бүлеге саны һәм әдәби куәте ягыннан кайбер өлкәләрдәге язучылар оешмаларына караганда көчлерәк саналды. 70 нче елларны бүлектә СССР Язучылар союзы әгъзасы булган каләмдәшләрнең саны 25–30 га җитте, ә яшь һәм башлап язучылар 100 ләп исәпләнде. Нефть төбәге җирлегендә укучы яратып укырлык байтак күренекле әсәрләр – романнар, поэмалар, повестьлар, пьесалар язылды, күпсанлы җырлар туды. Ул әсәрләрне язган берничә язучы Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, соңрак Татарстанның халык шагыйре, халык язучысы исемнәренә лаек булды. 40 ел эчендә бу Оешма белән Г.Ахунов, Р.Фәйзуллин, Ә.Маликов, Ә.Гаффар, Н.Әхмәдиев, Р.Вәлиуллин җитәкчелек итте. Хәзер Әлмәт Язучылар оешмасында вазгыять бүтәнрәк: иҗади ялкынның сүрелә төшүе сизелә. Г.Афзал, С.Сөләйманова, Ә.Маликов, Ш.Бикчурин, Р.Төхфәтуллин, Э.Мөэминова, М.Хәсәнов, Ю.Әминов, Җ.Рәхимов, Ф.Гыйльми һ.б. эстафетасын дәвам итеп, татар әдәбиятын яңа үрләргә күтәрерлек яшь көчләр, кызганыч, бик аз... Өлкән буыннан бүген дә актив иҗат итүчеләрдән К.Булатова, Ә.Сәлахов һәм А.Хәсәнов кенә калып бара бугай...

Шул чор әдәби елъязмасында мөһим бер сәхифә булып калган факт: ул – «Совет әдәбияты»ның бүгенге исемдә – «Казан утлары» булып чыга башлавы (1965, июнь). «Совет әдәбияты» дигән гомуми исемне алыштыру өчен формаль сәбәп тә бар: ул заманда төрек-мәннәрдә дә «Совет әдәбияты» дигән әдәби журнал чыга иде. СССР күләмендәге каталогта икесе дә бер исемдә чыккач, төрле төбәкләрдә журналны яздырып алучылар арасында буталу очраклары булгалый иде. Язучылар арасында берәр ай журналга яңа исем эзләү мәрәкәләре булып үткәч, идарәдә (рәисе – М.Әмир) «Казан утлары» исеме кабул ителде. Нәкъ шул айда журналның баш редакторы итеп Рафаэль Мостафин билгеләнде (ул Газиз Мөхәммәтшинны алыштырды). Баш редактор эшне бик актив башлап җибәрде (тәмамланган фигыль белән сөйләвем шуннан: үзем дә бу журналда эшли башлаган идем инде). СССРның татарлар яши торган регионнарына – республика, өлкә газеталарына журналның исеме алышыну турында мәкалә-хәбәрләр җибәрдек. Шунда ук «сезнең өлкәдә фәлән мең татар яши, безнең журнал фәлән данә тарала ала» дигән күрсәтмә-аңлатма да бирергә онытмадык. Редактор кушуы буенча турыдан-туры шушы эш белән шөгыльләнгәч, хәтердә: 100 дән артык хат җибәрелде, шуның күбесе СССРда чыга торган республика, өлкә газеталарында басылып чыкты. Һәм... нәтиҗә дә яхшы булды. 1965 елда тираж 19 мең 246 булса, бер ел эчендә 18 меңгә якын артып, 1966 елны «Казан утлары» 36 мең 800 булып чыкты. Ә 1968 елны 64 мең данәгә җитте. Ул елларда журнал тарату белән Тәүфикъ Әйди бик нык шөгыльләнде. Велосипедка утырып, үз теләге белән күрше республикаларга чыгып йөргәне хәтердә калган. Яшь язучы Тәүфикъ Әйди ул чакта ук күпләргә үрнәк зат иде инде. (Юкса үзе ул вакытта редакциядә дә эшләми иде.) Журнал исеме алмашу уңаеннан күңелдә калган матур хатирәләр, матур нәтиҗәләр...

Шул ук 1965 елны (14–15 гыйнварда) Татарстан язучыларының чираттан тыш тагын бер җыены – сан буенча VI съезды булып үтте. V съездан соң ике ел үтүгә яңадан съездга җыелуның төп сәбәбе: РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлау. Без бит инде хәзер РСФСР Язучылар оешмасына буйсынабыз. Шуңа күрә аның Устав кагыйдәләрен үтәргә туры килә! Съездда Союз идарәсе председателе Мирсәй Әмир татар әдәбиятының торышы һәм бурычлары турында доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуларда Г.Әпсәләмов, И.Нуруллин, Б.Гыйззәт, Җ.Тәрҗеманов, И.Гази, А.Булгаков, Г.Ахунов, З.Мәҗитов, съездга кунак булып килгән Мәскәү язучылары Л.Соболев, С.Михалков, Б.Дубровин, чуваш язучысы Н.Ильбеков һ.б. катнашты. Съездда шулай ук КПСС өлкә комитеты секретаре З.Тутаев чыгыш ясады. Аннары съезд РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлады. Алар: М.Әмир,

Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, Р.Ишморат, Л.Соболев, Ф.Хөсни, С.Хәким, Ә.Исхак, Г.Ахунов, З.Нури, Г.Минский, С.Радзиевская, А.Расих.

Язучыларның VI съездында саналган кунаклардан тыш күренекле язучылардан А.Алексин, Л.Андреевская, М.Львов, Р.Моран һәм М.Кәрим катнашты.

РСФСР язучыларының II съезды алдыннан чираттан тыш үткәрелгән җыенда яңа идарә сайланмады, үткән V съездда сайланган идарә үз эшчәнлеген дәвам иттерде.

Бу съезд көннәре минем хәтергә тагын бер сәхифәсе белән сеңеп калды әле. Күптәннән килгән традиция буенча, Казанга килгән исемле шәхесләр, гадәттә, Казан университетына килми калмыйлар иде. Бу юлы да шулай булды: съезд кунакларын (Л.Соболев, С.Михалков, М.Кәрим, М.Львов, А.Алексин һ.б.) студентлар белән очрашуга чакырдылар. Бу әдәби кичә актлар залында узды. Студент яшьләр исеменнән кунакларны котлауны миңа йөкләделәр. Күрәсең, әдәби түгәрәк җитәкчесе, яшь шагыйрь саналып, инде китап авторы булуымны искә алганнардыр. Университет парткомы наказы бу! Русча-татарча котларга тиешмен. Йөкләвен йөкләделәр, әмма чыгышым гына үзем теләгәнчә булып чыкмады бугай: артык дулкынланудан каушадым, тирләп чыктым, җитмәсә, кәгазьсез-нисез сөйләп азапланам... «Татар әдәбияты вәкиле булып, үзебезне тиешенчә күрсәтә алмадым» дип, бик нык битәрләдем үземне. Кул чаптылар чабуын. Яшьлеккә ташлама ясаганнардыр инде... Хәзер дә, бу хәл искә төшкәч, сәер бер хис кичерәм.

*** * ***

Съездлар, корылтайлар – театр биналарында, зур залларда үтә торган рәсми һәм күпмедер дәрәҗәдә тантаналы җыелышлар алар. Шуңа күрә (кәбисә елы кешеләренең туган көннәре кебек) сирәк, гадәттә дүрт-биш елга бер тапкыр үткәрелләр дә (күзәтүләр шуны күрсәтә: билгеле бер чиге була ул съезд саннарының. Партияләрнекеме яки оешмаларныкымы, XXXX яки XXXXX съезд дигәнне тарихта ишеткән юк әле. Кем белә, бәлки, Язучылар оешмасының да корылтайлары фәләненче санда тукталып калыр?). Ә бит көндәлек иҗади хәрәкәт бүтән җирләрдә бара: эш бүлмәләрендә, газета-журнал редакцияләрендә, нәшрият кабинетларында... Каләм ияләрен җыя торган бер үзәгебез дә бар безнең. Кемнәрдер өчен «бар иде» дип тә әйтеп була... Ул – әлбәттә, атаклы Матбугат йорты. 30 нчы еллар уртасында архитектор С.Пэн проекты белән төзелгән бу бина 70 еллар буе чын мәгънәсендә татар матбугаты, татар китабы, татар әдәбияты учагы булды. Аның таш баскычларын таптамаган зыялылар сирәк булгандыр. Элегрәк Татарстанда чыккан бөтен газета-журналларның редакцияләре шунда тупланган иде. Гомер-гомергә дигәндәй, дүртенче катны Татарстан китап нәшрияты биләде. Язучылар оешмасы штабы – Союз да ярты гасырдан артык шушы бинада булды. Икенче кат. Баскычтан менү уңаеннан сулга борыласың, якты тәрәзәле коридор буйлап 10–15 адым атлаганда, «Азат хатын», «Ялкын» редакцияләре кала... Коридор төпкелендә – Язучылар союзы, Әдәби фонд. Шундук «Совет әдәбияты» («Казан утлары») редакциясе. Ничек сыйганнардыр! (Соңрак бинаның икенче катын «Мәдәни җомга газетасы биләде.) Дөрес, бишенче катта җыйнак кына, 200 ләп кеше сыешлы атаклы Тукай клубы бар. Безнең буынның (бездән алдагы буынның да) әдәбиятка чынлыклап аякка басуы шушы клубтан башланды да инде. Шәхсән үзем 1960 елдан – студентлыкның беренче айларыннан ук таптый башладым мин бу клуб баскычларын. Әдәби кичәдә шигырьләр укып беренче тапкыр чыгыш ясаулар да шушы клубта булды. Әсәрләрен дәресләрдә өйрәнгән язучыларны шушында күрдек. Г.Бәширов, Х.Туфан, М.Әмир, Ш.Маннур, А.Шамов, Ф.Хөсни, Г.Әпсәләмов, С.Хәким... Болары XX гасырда туган шәхесләр. XIX гасыр ахырында туган өлкән затлар белән дә беренче тапкыр биредә таныштык: Н.Исәнбәт, И.Рәми, Р.Газизов, Г.Бакир... Аларның замандашлары – солтангалиевчелектә гаепләнеп, теге заманнарда төрмә-сөргеннәр кичкән Б.Урманче, М.Бөдәйлиләрне дә шушы бинада күрдек. Аена бер-ике мәртәбә булына иде Тукай клубында. Традицион җомга кичәләре, Казанга кунак булып килгән атаклы язучылар белән очрашулар, студент яшьләрнең концертлары, юбилей кичәләре... Без яшь язучыларны иң кызыктырганы (тизрәк зур шагыйрь, язучы буласы килә бит!), әлбәттә, язучыларның җыелышлары иде. Бигрәк тә ел йомгакларына багышланган җыелышларны калдырмаска тырыша идек. Икешәр көн бара иде ул «йомгаклар». Күпме шәхесләр күрәсең, күпме чыгышлар тыңлап, күпме кызыклы фикерләр

ишетәсең! Чыннан да, әдәби җәмәгатьчелек өчен вакыйга иде ул җыелышлар. Яшьләр дә, зыялы өлкәннәр дә көнозын йотлыгып тыңларлар иде чыгышларны, тәнәфесләрдә чама белеп кенә бәхәсләшерләр, алган тәэсирләрен күңелләрендә озак йөртерләр иде. Күрәсең, ул заманда татар әдәбияты һәм сәнгате турында авыз тутырып ана телендә сөйләү, иркенләп фикер алышу өчен бүтән урын да булмагандыр...

Мәшһүр Матбугат йорты! Җитмеш ел эчендә дөньяның бик күп атаклы кешеләрен (сугыш вакытында бигрәк тә) күргән истәлекле бина. Хәзер дә син әле исән. Әле хәзер дә синдә ике нәшриятыбыз (Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф»), Китап палатабыз, «Мәдәни җомга» газетабыз гомер кичереп ята. Бирегә хәзер дә килгәләп йөрибез, фикердәшләр, наширлар белән күрешәбез. Шулай да күңелне тырнаган сорау бар: киләчәктә бу диварларда элеккеге милли рух, китап рухы сакланып кала алыр микән? Акшарлары купкан түшәмнәргә, тузган тәрәзә өлгеләренә, күгәргән торбаларга карап күңелгә моңсулык иңә... Кемнәр кулына калып, киләчәктә кемнәр хуҗа булыр бу тарихи Үзәктә!.. (Бу язма 7 ел элек язылган. Ни кызганыч, бу бина хәзерге көндә буш һәм ул җимерек хәлдә. Андагы оешмалар төрлесе төрле җиргә күченеп бетте. – *Р.Ф., 2010.*)

*** * ***

Татарстан язучыларының чираттагы (ул вакытта СССР Язучылар союзының яңартылган Уставы нигезендә съездлар биш елдан биш елга үткәрелә башлады) съезды 1968 елны үтте. Бу съездны да яхшы хәтерлим. Инде СССР Язучылар союзы әгъзасы булынган, берничә шигырь китабы чыгарылган, шигырьләрем турында байтак бәхәс-низаглар, мактау-тиргәүләр ишетеп шактый ук чыныгылган, гаилә корылган, солдат хезмәте үтелгән... Президиумга ук утыртып, идарә әгъзасы итеп тә сайладылар мине бу съездда. Гармоник фон тудырыр өчен, өлкәнрәкләр арасына бер яшь кешене сайлау гадәте бар инде ул!.. Ә болай, тәртип белән сөйләгәндә, VII съезд 1968 елның 25–26 март көннәрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында (хәзерге К.Тинчурин театры) узды.

Съездны аксакал язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Г.Бәширов ачты. Идарәнең ике съезды арасындагы (1965–1968) эшчәнлеге турында хисап докладын идарә рәисе буларак М.Әмир ясады. Ул, Язучылар ирешкән уңышлар һәм алда торган бурычлар турында сөйләп, язучылар оешмасының 25 кешегә артуын әйтте, СССР Язучылар союзы әгъзасы булган язучыларның саны 111 кешегә җиткәнен белдерде. Доклад буенча фикер алышуларда Г.Ахунов, Л.Татьяничева (Мәскәү), Л.Ихсанова, Ф.Хөсни, Г.Камалиев (нәшрият директоры), Р.Мостафин, Х.Гыйлаҗев (Уфа), Р.Харисов, В.Ганиев (Мәскәү), Ш.Рәкыйпов, Ә.Давыдов, А.Калган (Чувашстан), А.Расих, М.Сәлимҗанов (режиссер), Сәхип Җамал (гарәп язучысы), Җ.Тәрҗеманов һ.б. катнашты. КПСС өлкә комитеты секретаре М.Вәлиев нотык сөйләде. 26 мартта яңа идарә сайланды. Аның составына түбәндәге язучылар керде: И.Гази (председатель), М.Әмир, Г.Ахунов (җаваплы секретарь), Г.Бәширов, З.Нури, Р.Фәйзуллин, Х.Туфан, Ф.Хөсни, С.Хәким, А.Шамов, Р.Ишморат, Х.Госман, Г.Кашшаф, И.Юзеев, В.Синев, Л.Ихсанова, Р.Мостафин.

Шушы 17 кешенең бүген инде 4 есе генә (Л.Ихсанова, Р.Мостафин, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин) исән (И.Юзеев 2004 елда, Л.Ихсанова 2010 елда вафат булды. – *Ред.*). Безнең замандашлар булган нинди олпат затларыбызны югалтканбыз! Ирексездән шигырь юлларын кабатларга туры килә: «Кемнәр бар да кемнәр юк!».

Бу съездан тагын ике нәрсә күңелдә җуелмас булып хәтердә калган. Берсе – тәнкыйтьче, М.Җәлил иҗатын өйрәнүче Р.Мостафинның чыгышы. Чыгышның төп бер тезисы шул иде: 1913 елда татар китаплары сан буенча хәзергедән күбрәк чыккан. Әдәбият әһелләре арасында сөйкемле сөяк саналган, русча-татарча иркен сөйләшә һәм яза алган дәрәҗәле Р.Мостафинның бу чыгышы партия түрәләре өчен һич тә көтелмәгән хәл булды. Ничек инде революциягә кадәр шулай булырга тиеш ди (гәрчә тәнкыйтьче конкрет статистик саннар китереп, дәлилләп сөйләгән иде!)? Әнә бит республика җитәкчеләренең берсе «татарлар революциягә кадәр тоташ грамотасыз булган» дип бара! Нинди каршылык! Дөресрәге, партия линиясенә каршылык!.. Бу чыгышка рәсми реакция катгый булды: бер айдан Р. Мостафин «Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазифасыннан азат ителде... Икенчесе (монысын ул

заман өчен инцидент дип әйтеп була) – бер төркем яшьләрнең театр балконыннан татар яшьләре өчен әдәби журнал кирәк дигән эчтәлекле листовкалар очыруы. Зал өстеннән ак яфраклар кебек листовкалар очып әйләнгәндә, президиумда – янәшәмдә утырган югары урын биләгән түрәләрнең чырайлары ничек үзгәргәне һаман күз алдында. Каушау һәм аптырау! Нәрсә бу?

Листовкалар очырткан студент егетләрне (Разил Вәлиев, Зөлфәт, М.Мансуров) КГБ бүлмәләренә байтак йөрттеләр. Бу хәл (хәзерге күзлектән караганда гап-гади таләп) үзе һәм аңа булган реакция шул заман иҗтимагый тормышын характерлап торган бер күренеш иде.

*** * ***

1960–1990 еллар. Бу чор татар әдәбиятының алтын чоры булды бугай. Еллар ераклыгыннан шулай күренә. Р.Мингалимов әйтмешли, «ул шулайдыр әле, уйласаң». Әдәбиятның кадере булган чор. Язучы да үзен җәмгыятьнең кирәк һәм хөрмәтле кешесе санап, чагыштырмача иркен тоеп, көченә һәм киләчәккә ышанып иҗат итте. Нигә язмаска? Максатың бар, хезмәтеңнән ләззәт тою бар, иң мөһиме – әсәрләреңне көтеп торган күпсанлы укучылар бар. Әзме-күпме белемле кеше кибетләрдән яхшы китап эзли, күптомлы басмаларга берәр ел алдан язылып куя, таныш-белеш аша берәр дефицит китап юнәтсә, төлке тоткан кебек сөенә... Атаклы язучыларның яңа әсәрләрен вакытында укып бару зыялылык билгесе санала. Айтматовның «Ак пароход»ына фикерең ничек? Хемингуэйның соңгы романының русча тәрҗемәсе чыккан! Неруданың мемуар китабы кемдә бар икән? Исхакыйның «Зөләйха»сын берәү машинкадан чыгарган!.. Кызыксына, укый иде халык! 80 нче еллар башында «Казан утлары» журналының 100 меңнән артык данә белән таралуы күп нәрсәне аңлата («заманында трамвай бәясе дә 3 тиен иде» дигән шикелле, ул елларда миллионга якын тираж белән чыккан бөтенсоюз журналлары – «Новый мир», «Дружба народов», «Знамя» кебек журналлар – хәзер тиражлары безнең «Казан утлары»ннан ким булып – нибары 3–6 мең данә чыга). Әйе, укый иде халык. Татар телендә чыккан китапларның тиражлары да шактый югары: шигырь китаплары – 3–10 мең, проза китаплары – 10–30 мең, балалар китаплары 10–100 меңнәр була иде. Татар язучыларыннан, бездә генә түгел, илкүләм популярлары мәйданга чыкты. Шуларның иң күренеклесе, алда әйтелгәнчә, Г.Әпсәләмов булды. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы шикелле, Г.Әпсәләмов романнарын, беренче чиратта «Ак чәчәкләр»не, миллионлаган төрле милләт вәкилләре йотлыгып укыды... Татар-башкорт укучылары арасында Ә.Еники дә аерым бер урын тотты; аның «Әйтелмәгән васыяте»н укымаган зыялы зат калмагандыр... Саный китсәң, бар иде популяр әсәрләр. Ш.Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы», И.Юзеевның «Таныш моңнар»ы, Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт»е... Х.Туфан, С.Хәкимнәрнең шигырь-поэмалары, Г.Афзал, Ш.Галиевләрнең юмор-сатира, Роберт Әхмәтҗановның лирик шигырьләре... «Давыл хәбәрчеләре» сыман 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләр иҗатына игътибар аеруча зур булды. Республика газеталарында атна саен диярлек дискуссион характердагы зур-зур мәкаләләр чыкты. Традицияләр, новаторлык, формализм, «ирекле шигырь»... Мәш килде әдәби мохит!

Чорлар турында сөйләгәндә, табигый процесс – әдәбиятта буыннар алышынуы турында да искәртеп узу кирәктер. Чыннан да, өлкән язучылар (XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында туганнар) 70–80 нче елларда үзләренең дөньялыктагы гамәлләрен йомгаклап киләләр иде инде... Төп әдәби мәйданны исемнәре 50 нче еллар урталарында һәм бераз соңрак күренә башлаган буын яулады. Алар: прозада – Г.Ахунов, Р.Төхфәтуллин, Н.Фәттах, А.Гыйләҗев, М.Рәфыйков, Ә.Баян, Ш.Бикчурин, Б.Камал, М.Мәһдиев, Х.Камал, А.Тимергалин, Х.Сарьян, Э.Касыймов, М.Хуҗин, М.Юныс, Ф.Шәфигуллин, Т.Әйди, М.Маликова, М.Хәбибуллин, В.Нуруллин, Ә.Гаффар...; шигърияттә – алдагы абзацта әйтелгәннәрдән тыш Р.Гәрәй, М.Шабаев, Ш.Анак, С.Сөләйманова, Ф.Яруллин, Р.Фәйзуллин, К.Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов, Р.Харис, Р.Мингалим, Г.Рәхим, Р.Гатауллин, К.Сибгатуллин, А.Хәлим, М.Әгъләмов, Зөлфәт...; драматургиядә – Х.Вахит, Ю.Әминов, Ш.Хөсәенов, Т.Миңнуллин, Батулла, Р.Хәмид...; әдәбият гыйлеме һәм тәнкыйтьтә – Мансур Хәсәнов, И.Нуруллин, Ә.Кәримуллин, И.Ахунҗанов, Н.Юзиев, М.Госманов, А.Әхмәдуллин, Ф.Миңнуллин, Ф.Мусин, Т.Галиуллин, Ф.Галимуллин, Ф.Урманче, Х.Миңнегулов...

* * *

Бу урында сугыштан соңгы шактый дистә еллар буена татар әдәбияты барышына нык тәэсир иткән берничә фактор турында әйтү мөһим. Алар – Ватан сугышы, Татарстанда нефть чыгару, соңрак КамАЗ төзелү. Ватан сугышы, дөньякүләм фаҗига буларак, күп халыклар яшәешендә чагылыш тапса, ә нефть белән КамАЗ турыдан-туры Татарстан, бигрәк тә татар халкы язмышына кагылды. Республиканың – йөзе, кешеләрнең кальбе үзгәрде. Татарстанда читтән килгән халык күбәйде, яшь һәм көчле килмешләр армиясе хасил булды. Рәсми идеология индустриаль казанышларга дан җырларга өндәде. «Хезмәт кешесе образы» дигән ясалма термин туды (безнең әдәбиятның каһарманы гомер-гомергә хезмәт иясе булды лабаса!). Социалистик реализм методы алымнарына тугрылыклы булып, эшче сыйныфын, хезмәт романтикасын сурәтләгән (яки сурәтләргә тырышкан) байтак әсәрләр, китаплар чыкты. «Гади кешеләр» (И.Гази), «Хәзинә» (Г.Ахунов), «Томан аша» (Э.Касыймов), «Зәй энҗеләре» (А.Гыйләҗев), «Каты токым» (Ш.Бикчурин), «Ут һәм су» (Ә.Баянов), «Тау белән тау очрашмаса да» (М.Хәбибуллин)... Саналганнар – проза әсәрләре, бүтән жанрлардан да мисалларны китерергә була. Болар, нигездә, социаль заказ белән язылган әсәрләр. Бу күренешне яңа дип тә әйтеп булмый. 30 нчы елларда, бигрәк тә СССР язучыларының I съездыннан соң булган иде инде андый хәлләр. Язучылар иң әүвәл завод-фабрикалар тарихын язарга, «металл җыры»н яңгыратырга, «мотор гиганты»н сурәтләргә, «миллионнарның энтузиазмы»н күрсәтергә тиеш иде. Бу чорның ядкарьләре – Ш.Камалның «Матур туганда», Р.Ильясның «Горизонт» кебек әсәрләре...

Әлбәттә, республикадагы баш әйләндергеч үзгәрешләр, нефть һәм КамАЗ индустриясе белән бәйле контрастлар, уңай (заман технологиясен үзләштерү, халыкара бәйләнешләр ныгу, техник интеллигенция оешу, юллар салу, торакларны газлаштыру һ.б.) һәм тискәре (авыллар бетү, экологик кризис, миллилекнең асылы тоныклану, әхлаксызлык, ассимиляция, татар теленең кысрыклануы һ.б.) күренешләр язучылар иҗатында чагылыш табарга тиеш иде. Һәм ул шулай булды да. Әмма... Хикмәт шунда: чагылыш нинди дәрәҗәдә һәм нинди тирәнлектә булды соң? Дөресен әйтик, нигездә, авылдан чыккан татар язучысы ФТР (фәнни-техник революция) тудырган бу хикмәт-тамашалар алдында, табигый, югалып та калды. Югалырсың да, фантазия белән күз алдына китерик: идиллик-патриархаль тормыш белән яшәп ятучы авылның су тегермәне янына НЛО корабы төшсен дә, шуны аңлап-белеп кара әле! Вазгыять, халәт, әзерлек шулайрак иде. Әйткәнемчә, тырышмады түгел, тырыштылар язучыларыбыз. Алар, командировкаларга барып, буровойларда, кыр вагоннарында, тулай торакларда, баракларда булдылар, бораулаучылар, ташчылар, шоферлар, торбачылар белән (өстән юнәлтелгәнчә, нәкъ чын хезмәт кешеләре белән) аралаштылар һәм шулар тормышы турында яздылар да. Нишләтәләр бу җирне? Байлык кая китә? Бу гамәлләрнең ахыры ни белән бетәчәк? Бу хакта дөнья танырлык итеп язылмады, һәрхәлдә, язылып та дөнья күрә алмаган берәр зур әсәрне белмим мин.

Төзелешләр мәйданын хәтерләткән республика тормышында майлы киемле хезмәтчәннәрдән тыш идарәчеләр, югарыдан куелган стратегик максатны тормышка ашыручылар катламы – Табиевлар, Шмаревлар, Васильевлар, Шашиннар, Мингәрәевләр, Лемаевлар, Бехлар һәм тагын күпләр бар иде. Татар язучылары алар белән якыннан аралашып, якындагын гына түгел, ерак офыктагы булачакны фаразлап, җитәкчеләр белән бер дәрәҗәдә яки хәтта өстәнрәк торып иҗат итә алмадылар. Берәүне дә гаепләргә җыенмыйм. Әлеге әфәнделәр туры һәм күчерелмә мәгънәдә дә бүтән телдә сөйләшәләр иде шул...

* * *

Ватан сугышы 60–90 нчы елларда да әдәбиятыбызның төп темаларыннан берсе булып кала бирде. Фронтта катнашкан язучылар, хәтерләрен яңартып, яңа әсәрләр яздылар («Мәңгелек кеше» – Г.Әпсәләмов, «Дуга» – С.Хәким, «Муса» – Ш.Маннур, «Җимерелгән бастион» – Н.Дәүли, «Йолдызлар шаһит» – Ә.Галиев, «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» – Х.Камал, «Без дә солдатлар идек» – Ә.Еники, «Яшьлек утравым» – Ә.Маликов...). Сугыш чорын күреп үскән кайбер яшьрәк язучыларыбыз да өлкәннәр үрнәгендә хәрби-патриотик тәрбиягә өлеш кертәбез дип иҗат иттеләр («Кайдан син, Жан?», «Кызлар – йолдызлар» –

Ш.Рәкыйпов, «Легенда егетләре» – С.Шакир һ.б.). Бу әсәрләрнең күбесе сугыш темасына 50 нче елларда язылганнардан шактый ук аерылалар иде. Элгәргеләрендә сугыш (без яшь чакта күргән «Взятие Берлина», «Смелые люди» кинофильмнарындагы шикелле) күбрәк батырлык мәйданы кебегрәк күрсәтелсә, соңгыларында, кешелек фаҗигасе буларак, кеше язмышлары аша реаль чынбарлыкта чагылдырыла башлады. Башкача мөмкин дә түгел иде. Әдәбият сөючеләр бүтән халык язучыларының сугыш турында язылган әсәрләре белән дә яхшы ук таныш иде. Әйтик, В.Быковның «Сотников», К.Симоновның «Живые и мертвые», Й.Авижюсның «Потерянный кров», В.Астафьевның «Плацдарм», «Последний поклон» һ.б... В.Ажаевның «Мәскәүдән еракта», С.Бабаевскийның «Алтын Йолдыз кавалеры», М.Бубенновның «Ак каен»нарын уку заманнары үткән иде шул... Безнең буын яшь чакта сугыш турында күп укыды. Ялган пафос, ялган батырлык күп булган ул әсәрләрдә, ә кешеләргә дөреслекне белү кыйбат. Шәхсән мин үзем Х.Мөҗәйнең «Сугыш көндәлекләре» дигән документаль язмаларын сугыш турында язылган бик күп ясалма әсәрләрдән өстен саныйм.

Бу чорда, әлбәттә, татар әдәбиятының җанын тәшкил иткән авыл дөньясын, аның кешеләрен тасвирлау тагын да җанлана төште. Бу хакта дәлилле итеп күп сөйләп булыр иде, кайбер әсәрләрне атап китү белән генә чикләнәм. «Әйтелмәгән васыять» – Ә.Еники, «Артта калган еллар» – Н.Фәттах, «Берәү», «Язгы кәрваннар» – А.Гыйләҗев, «Шинельсез солдатлар» – В.Нуруллин, «Тау ягы повесте» – Ә. Баян, «Бер ананың биш улы» – Х.Сарьян... Сугыштан соңгы чордагы авыл турында язылган әсәрләрнең иң характерлыларын М.Мәһдиев иҗат итте дип беләм. Аның әсәрләрендә сугыштан соңгы авыл рухы бөтен нечкәлекләре белән чагылыш таба. Әсәрләренең берсен генә аерып искә алу килешми кебек. «Без – кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә»... Гомумән, М.Мәһдиевнең әдәби иҗатта үзен «мин 60–90 нчы еллар язучысы» дип тә әйтерлеге булды. 60 нчы еллар ахырында әдәбиятка килеп, утыз еллап иҗат итеп, ни аяныч, 90 нчы еллар уртасында үлмәс әсәрләр калдырып китеп тә барды...

Татарның бар дөньяга шауларлык тарихы булса да, дөресен әйтик, аны юньләп белгәннәр бик сирәк. Җиңелгәннәр үзенең чын тарихын яза алмый. Җиңгәннәр үзләренең үткәнен бөекләтеп язганда, аста калган халык тарихы юкка чыгарыла... Шулай да... халык тәне суынмаган бит әле! XX гасырның беренче чирегендә тарихи әсәрләр язу беркадәр башланса да, 30–50 нче елларда бу хәрәкәт туктап кала. Ниһаять, 60 нчы еллар башында әкренләп «боз кузгалды», «беренче карлыгачлар»дан Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур» әсәре булды. Бераздан шул ук авторның «Сызгыра торган уклар»ы язылды. Соңрак бу эшкә М.Хәбибуллин («Кубрат хан»), Җ.Рәхимов («Батырша»), Р.Батулла («Сөембикә кыйссасы»), Ф.Латыйфи («Хыянәт») кебек язучыларыбыз алынды.

Әдәбияттагы төп казанышлар турында сөйләгәндә, бу дәвердә Республиканың (соңрак Дәүләт дип әйтелә башлады) Г.Тукай премиясен алган әсәрләрне һәм аларның авторларын искә төшереп үтсәк, әдәби хәзинәбез тулырак күз алдына килер. Кырыктан артык лауреат язучының утызга якыны бу дәрәҗәле исемне 60–90 нчы елларда алган. Укучыларыбыз өчен мәгълүмат тулы бербөтен булсын өчен, еллар исәбен чигендереп, бүгенге көнгәчә булган лауреатлар исемлеген хронологик тәртиптә тулысынча санап китик: Ә.Фәйзи – «Тукай» романы өчен (1958) (Тукай премияләрен бирә башлау шушы елдан башлана), Г.Әпсәләмов – «Сүнмәс утлар» романы (1959), С.Хәким – «По зову Ленина», «Җил исми – яфрак селкенми» исемле шигырь китаплары өчен (1960), (1961–1965 елларда премия бирелү туктатылып торылды), Х.Туфан – «Сайланма әсәрләр» китабы (1966), Н.Исәнбәт – «Татар халык мәкальләре» дигән өч томлы хезмәт (1968), И.Гази – «Онытылмас еллар» роман-трилогиясе (1969), Ф.Хөсни – «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повесте (1972), Ш.Галиев – «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле йорт» китаплары (1972), Г.Ахунов – «Чикләвек төше» повесте (1973), М.Әмир – «Агыйдел» пьесасы (1974), Н.Юзиев – «Шигырь гармониясе», «Хәзерге татар поэтикасы» китаплары (1974), Д.Вәлиев – «Дарю тебе жизнь» пьесасы (1976), М.Шабаев – «Җикән камыш», «Онытма», «Сине эзлим» дигән шигырь китаплары (1976), Г.Афзал – «Айлы кичләр» китабы, «Борылам да карыйм» исемле шигырь циклы (1977), Р.Фәйзуллин – «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1978), Т.Миңнуллин – «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы (1979), И.Юзеев – «Таш диварлар авазы», «Өзелгән кыллар»

поэмалары (1980), А.Расих – «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Ямашев» романнары (1981), И.Нуруллин – «Тукай турында китаплар» (1982), А.Гыйләҗев – «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары (1983), Ә.Еники – «Повесть һәм хикәяләр» (1984), Г.Рәхим – «Кара йөзләр» операсы өчен либретто (1984), Н.Арслан – «Иделем – Илем» исемле шигырь һәм поэмалар китабы (1985), Х.Камалов – «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» китаплары (1986), М.Зарипов – «Поступь моей республики», «Выгодный оборот» исемле публицистик китаплары (1987), М.Хәсәнов – «Язгы аҗаган» романы (1988), М.Мәһдиев – «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» повестьлары (1990), Ә.Кәримуллин – «У истоков татарской книги», «Татарская книга XX века» һ.б. китаплары (1991), Г.Зәйнашева – «Илле җыр» китабы (1991), М.Әгъләмов – «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» исемле шигырь китаплары (1992), Р.Мөхәммәдиев – «Сират күпере» романы (1993), Н.Фәттах – «Сызгыра торган уклар» романы (1994), Ф.Яруллин – «Җан авазы» шигырь китабы (1995), Г.Бәширов – «И язмыш, язмыш» китабы (1996), Р.Харис – «Хисемнең җисеме» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы (1997), Р.Миңнуллин – «Күчтәнәч» исемле китап (1998), Ә.Баян – «Урланган ай» китабы (1999), Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) – «Ике урман арасы», «Йөрәгемне былбыл чакты» шигырь китаплары (2000), Р.Әхмәтҗанов – «Тургай тәрәзәсе», «Кичке кошлар» исемле шигырь китаплары (2001), Я.Зәнкиев – «Иртыш таңнары» романы (2002), М.Хәбибуллин – «Кубрат хан» китабы (2003), М.Юныс «Альбатрос язмышы», публицистик язмалар (2004). Җәмгысы – кырык дүрт язучы, илледән артык әсәр. (Бу исемлекне җентекләбрәк укыган кеше аңларга кыен моментларны да искәртер: әйтик, бу премияне Д.Вәлиев 1976 елда алса, Ә. Еникигә 1984 елда; М.Зариповка 1987 елда булса, Г.Бәшировка 1996 елда бирелә... Милли әдәбият зарурияттеннән караганда, бу язучыларның «авырлык категорияләре» төрле, бүтәнчәләп әйтсәк, пәри башка да җен башка! Мондый алогизмнар тагын бар әле бу исемлектә. Гомумән, Тукай премияләре тарихы – үзе бер патетик драма ул. Әгәр кырык дүрт язучы лауреат булса, иң киме тагын шул чама санда башка дәгъвачылар да булган бит әле, арасында лаеклылар да... Күпме эмоциональ киеренкелек, дулкынланулар, тетрәнүләр, сөенечләр, үпкә-рәнҗүләр! Язар өчен аерым бер тема.) Г.Тукай премиясенә лаек булган әсәрләрне иҗат итүдә Язучылар оешмасының тәэсире яки файдасы күпмедер – анысы бәхәсле, әмма өләшүдә, ягъни бирелү процессында роле шактый (тәкъдим итү, премияләр комитетында яклау), һәрхәлдә, моңарчы шулай булып килде. Дөрес, соңгы елларда Язучылар берлеге тәкъдим иткән кандидатлар лауреатлыкка бик «үтми» башладылар әле...

* * *

«Торгынлык» еллары... Кем ничек кенә бәяләмәсен, «җитлеккән социализм» чорының үз тәртибе хөкем сөргән тотрыклы да иде ул еллар. Коммунистлар партиясенең кайбер демократик алымнарны үзләштереп идарә итүенең үз апогеена җиткән еллары. Язучылар союзлары да, партиянең ышанычлы таянычы буларак (дөрес, язучы халкы арасында да төрлесе бар: диссиденты да, эзоп телендә язучысы да...), үз функциясен төгәл үтәп килә. Партҗыелышлар да, политукулар да, семинар-пленумнар да планлы рәвештә бара. Әлбәттә, язучыларның иң югары органы булган съездлар да. Мозаик пландагы язмамны бер үзәккә җилемләп торучы әнә шул съездларга янәдән кайтыйк. Бу дәвердә язучыларыбыз делегат булып өч төрле дәрәҗәдәге съездларда катнашалар: СССР, РСФСР, ТАССР съездларында (бу елларда СССРның биш – IV–VIII съездлары, РСФСРның биш – II–VI съездлары, Татарстанның җиде – V–XI съездлары үтте). Безнең әдәби хәрәкәт тарихы – үз съездларыбызда. Аларның байтагы турында информацион характерда гына булса да язып уздым инде. Хәзер чираттагылары турында да әйтеп үтим (бәлки, кемнәргәдер бу кадәр саннар, исемнәр, даталар санап китү ошап та бетмәс, әмма социологик эссе характерындагы язмамдагы фактик материалның әдәбият тарихын өйрәнүчеләр өчен киләчәктә кирәк булуы ихтимал).

Татарстан язучыларының VIII съезды 1974 елның 24–25 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында үткәрелде. Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 1968–1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын З.Нури ясады. Моннан

тыш проза турында Г.Ахунов, поэзия турында И.Юзеев, драматургия буенча Т.Миңнуллин, тәнкыйть турында Р.Мостафин, балалар әдәбияты буенча Л.Ихсанова, рус язучыларының иҗаты турында Т.Журавлев докладлары тыңланды. Ревизия комиссиясенең отчетын комиссия председателе Г.Гобәй ясады. 25 май көнне докладлар буенча фикер алышуларда Р.Ишморат, Ә.Баян, Ү.Саттаров, С.Хәким, Р.Фәйзуллин, Н.Җиһанов (композитор), Ф.Миңнуллин, Ш.Хамматов, Х.Госман, А.Әхмәдуллин, Ә.Маликов, Р.Җиһаншина (артистка), Ә.Тумашев (рәссам) һ.б. катнашты. Съездга килгән кунаклардан С.Михалков (Мәскәү), О.Савицкий (Минск), Ф.Гарин (Киев), Б.Байкабулов (Ташкент), А.Алиев (Ашхабад), А.Аетбаева (Фрунзе), И.Араз (Баку), Н.Дедушкин (Чабаксар), И.Пеняев (Саранск), С.Вишневский (Йошкар-Ола), Г.Сабитов (Ижевск) котлау чыгышлары ясадылар. Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М.Вәлиев речь белән чыкты. Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итте, Союзның җитәкче органнарын сайлады. Идарә составына түбәндәге язучылар сайланды: Г.Ахунов (председатель), Р.Фәйзуллин (җаваплы секретарь), М.Әмир, А.Әхмәдуллин, Г.Бәширов, Ә.Баянов, М.Зарипов, М.Маликова, Ә.Маликов, Т.Миңнуллин, З.Нури, В.Нуруллин, Г.Паушкин, А.Расих, Ш.Рәкыйпов, Г.Рәхим, Х.Туфан, М.Хәбибуллин (оештыру эшләре буенча секретарь), С.Хәким, М.Шабаев, И.Юзеев. Ревизия комиссиясе председателе итеп Р.Даутов сайланды.

Бу рәсми хроникага тартым белешмәгә тагын нәрсә өстәргә? Шул елларны характерлый торган кайбер фактлар, вакыйгалар. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулган еллар бу (VII белән VIII съезд арасын әйтүем). Шуңа күрә бу даталар уңае белән Казанда да, Мәскәүдә дә бик күп чаралар үткәрелгән. Конкрет язучылар тормышына караган вакыйгалардан – М.Җәлил турында «Ленфильм»да «Моабитская тетрадь» исемле кинофильм чыга; өлкән язучыларыбыздан Н.Исәнбәт, Х.Туфаннарның 70 яшьлек юбилейлары үтә; С.Хәкимгә РСФСРның М.Горький исемендәге премиясе бирелә; татар язучылары Донбасска барып Әдәбият көннәре үткәрәләр, шул ук җәйне (1972) Ворошиловград өлкәсеннән җавап визиты белән украин язучылары Татарстанга килә... Бу елларда Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премияләре булдырыла. Язучылардан беренче лауреатлар: И.Юзеев (1970), Р.Фәйзуллин (1972). Гомумән, ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк, 70 нче еллар башында яшь иҗат көчләренә хакимият тарафыннан игътибар зур булды. 1969 ел ахырында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында «Иҗади яшьләр оешмасы» төзелде, җитәкчесе итеп Р.Батулла билгеләнде. Шул елларда Актерлар йортында үтә торган «Ядкарь» кичәләрен өлкәнрәк буын иҗатчылар яхшы хәтерли булыр. Халыкара яшьләр лагере «Волга»да («Идел») һәр ел саен яшь язучылар, рәссамнар, композиторлар, актерлар катнашында бер атнага сузыла торган республика семинарлары...

VII–VIII съездлар арасында идарә җитәкчелегендә дә үзгәреш булды. 1968 елда Язучылар союзы җитәкчесе итеп И.Гази сайланган иде. Рәис статусында ул СССР Верховный Советы депутаты, РСФСР Язучылар союзы секретаре, КПССның өлкә комитеты члены, КПССның чираттагы съезды делегаты булды. Әмма... 1971 елның февралендә И.Гази көтмәгәндә вафат булды. Аның урынына З.Нури билгеләнде. Шуңа күрә Союз идарәсенең 1968–1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын ул ясады да. Рәислек елларында З.Нури да СССР Язучылар союзы секретаре булып эшләп алды.

Татарстан язучыларының IX съезды 1979 елның 23–24 май көннәрендә үтте. Анда өч йөзгә якын язучы, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар, Татарстанның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура хезмәткәрләре катнашты. Съездны шагыйрь С.Хәким ачты. Республика язучыларының иҗаты һәм идарә эшчәнлеге турында хисап докладын Г.Ахунов ясады. Ревизия комиссиясенең бишьеллык эше белән Р.Даутов таныштырды. Өстәмә докладлар – А.Расих (проза), Н.Юзиев (поэзия), А.Әхмәдуллин (драматургия), М.Мәһдиев (тәнкыйть), Ш.Галиев (балалар әдәбияты), М.Зарипов (очерк һәм публицистика), Г.Паушкин (рус язучылары иҗаты), И.Юзеев (яшь язучылар белән эшләү), Ә.Маликов (Әлмәт оешмасы эшчәнлеге) тыңланды. Фикер алышуларда З.Нури, Р.Мостафин, Ә.Гаффар, Ф.Мусин, К.Тимбикова, Ә.Тумашев (Рәссамнар союзы), В.Нуруллин, Ш.Хамматов (Журналистлар союзы), Ф.Газизуллин (комсомолның Татарстан өлкә комитеты секретаре,

соңрак Россиянең дәүләт милке министры булды), Ф.Әхмәтов (Композиторлар союзы) һ.б. катнашты.

Съезд кунаклары С.Михалков (Мәскәү), Ә.Мирзаһитов (Башкортстан), А.Мороз (Украина), Ш.Муртазаев (Казакъстан), Л.Прокша (Белоруссия), А.Емельянов (Чувашстан), О.Абдрахманов (Каракалпакстан), Н.Нефедов (Мәскәү), татар әдәбиятын олылап, коллегаларына тәбрик һәм киңәш сүзләрен җиткерделәр. Съездда шулай ук КПСС өлкә комитетының идеология буенча секретаре М.Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсен түбәндәге составта сайлады: Г.Ахунов (председатель), А.Әхмәдуллин, Ә.Баянов, Ш.Галиев, Т.Галиуллин, Ә.Маликов, М.Маликова, Т.Миңнуллин, Р.Миңнуллин, Ф.Миңнуллин (җаваплы секретарь), М.Мәһдиев, З.Нури, В.Нуруллин, Г.Паушкин, А.Расих, Х.Туфан, Р.Фәйзуллин, С.Хәким, Р.Харис, И.Юзеев. М.Хәбибуллин оештыру эшләре буенча секретарь итеп билгеләнде.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Р.Даутов, Әдәби фонд председателе итеп А.Әхмәдуллин сайланды.

Рәсми белешмә стилендә тагын бер съезд – X съезд турында да информация биреп узыйк. Алай эшләгәндә, бу ике съезд хисап биргән унъеллык (1974–1984) турында кайбер фикерләр әйтеп, гомумкүзәтүләр ясау җиңелрәк булыр. Ул елларны күз алдына китерү өчен анык ориентирлар: бу – Язучылар союзында рәис булып Г.Ахунов торган еллар. Партия өлкә комитетында идеология буенча җаваплы җитәкчеләр – секретарь (өченче секретарь дип йөртелә иде) М.Вәлиев, культура бүлеге мөдире М.Мусин, куратор-инструктор И.Хәйруллин. Минем үземә дә бу чорда – 1973–1977 еллар аралыгында Язучылар союзында җаваплы секретарь (рәис урынбасары) булып эшләргә туры килде. Шуңа күрә байтак вакыйгаларның турыдан-туры шаһитымын.

Татарстан язучыларының X съезды 1984 елның 21–22 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында үтте. Съездны шагыйрь С.Хәким ачты. Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм идарәнең ике съезд арасындагы бишьеллык эше турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе Г.Ахунов ясады. Съездның беренче көнендә өстәмә докладлар да тыңланылды: поэзия (И.Юзеев), проза (М.Мәһдиев), драматургия (Т.Миңнуллин), тәнкыйть (Т.Галиуллин), балалар әдәбияты (Ш.Галиев), очерк һәм публицистика (М.Зарипов), рус язучыларының иҗаты (Н.Орешина), тәрҗемәчеләр эшчәнлеге (К.Миңлебаев).

22 майда съезд эшен дәвам иттерде, докладлар буенча фикер алышулар булды. Чыгыш ясаучылар – С.Михалков (Мәскәү), Р.Вәлиев, Р.Мөхәммәдиев, Р.Мингалим, Р.Миңнуллин, Н.Доризо (Мәскәү), Р.Харис, Г.Шәрәфетдинов (Татарстан китап нәшрияты директоры), Б.Мөлеков (композитор) һ.б.

Татарстан язучылары форумын Ә.Мирзаһитов (Башкортстан), А.Емельянов (Чувашстан), Г.Имамвердиев (Азәрбайҗан), В.Карамазов (Белоруссия), К.Укаев (Кыргызстан), Т.Тула (Үзбәкстан), Н.Бәйрәмов (Төрекмәнстан), Т.Җумаморатов (Каракалпакстан), Н.Рыбаков (Мари Эл), С.Самсонов (Удмуртия) тәбрикләде. Съездда шулай ук КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М.Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады. Съездда сайланган идарә әгъзалары: Т.Миңнуллин (председатель), А.Әхмәдуллин, Г.Ахунов, Н.Алешков, Ә.Баян, Р.Вәлиев (председатель урынбасары), Ш.Галиев, Т.Галиуллин, Ә.Гаффар, А.Гыйләҗев, З.Маликов, Ә.Еники, М.Мәһдиев, М.Маликова, Р.Миңнуллин, Ф.Миңнуллин, Ф.Мусин, Р.Мөхәммәдиев, В.Нуруллин, Н.Орешина, Р.Фәйзуллин, М.Хәбибуллин (җаваплы секретарь), С.Хәким, Р.Харис, И.Юзеев.

Ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Р.Даутов сайлана. «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Р.Харис расланды.

Еллар агышына, эш барышына карап дигәндәй, тора-бара идарә составында да үзгәрешләр булды. Р.Вәлиев Республика китапханәсенә (хәзер Татарстан Республикасы Милли китапханәсе дип атала) директор итеп билгеләнгәч, рәис урынбасары вазифаларын Р.Хәмид башкарды, соңрак аны Г.Рәхим алыштырды.

* * *

70–80 нче еллар (үзгәртеп кору чорына кадәр), мөгаен, күпмилләтле совет әдәбияты дип йөртелгән әдәбиятның иң югары биеклегенә ирешелгән еллары булгандыр. Иң яхшы дип саналган әсәрләр Ленин, СССР Дәүләт премияләре белән билгеләнделәр. 80 нче еллар ахырында илкүләм танылган дистәләгән язучыга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирү хәлләре дә булып алды. Бөтенсоюз, хәтта бөтендөнья масштабындагы дан-хөрмәткә лаек булганнар арасында руслардан тыш бүтән халыкларның әдипләре дә бар иде. Гадәттә, һәр республикадан берәр зур шәхес күтәрелде яки күтәрделәр (Ч.Айтматов – Кыргызстан, Э.Межелайтис – Литва, Р.Гамзатов – Дагстан, М.Кәрим – Башкортстан, Д.Көгелтинев – Калмыкстан, С.Капутикян – Әрмәнстан, К.Кулиев – Кабарда-Балкар)...

Совет әдәбиятының балкыган чорында бу когортада татар әдәбиятыннан да берәр вәкил булуы көтелгәндер. Табигый хәл. Төрле тарафларга таралып, әле татарлыгын җуймаган милләттәшләргә дә горурлык хисе тудырыр өчен дә кирәк булгандыр әле андый шәхес. Әмма популярлыклары һәм рәсми танылуы буенча Р.Гамзатов яки Ч.Айтматовлар дәрәҗәсендәге шәхес бездә пәйда була алмады. Дөрес, заманында Г.Әпсәләмовны, Н.Исәнбәтне Социалистик Хезмәт Герое ясарга дигән фикерләр булгалады, С.Хәким Ленин премиясенә тәкъдим ителеп каралды... Барып чыкмады, шул заман өчен бездән «символ» табылмады. Юкса, яхшы әсәрләр тудырган һәм перспективасы булган әдипләребез бар иде шикелле. Берәү дә классик булып тумый. Биюченең итәкләре бии-бии кыскара дигән шикелле, әдип кеше дә шартлар, мөмкинлек һәм терәк булганда гына үсә ала. Бәлки, үзебезнең «милли менталитет»ыбыз – бер-беребезнең үсүен күпсенүебез комачаулагандыр; бәлки, биек сәяси олимптан татарларга бу чор өчен Муса Җәлил дә җитеп торыр дип исәпләгәннәрдер... Әмма ул чорда «бөтенсоюз аренасы»на чыгып, татар әдәбиятын бүтән халыкларга да белдерү нияте белән иҗат итүчеләр дистәләгән иде. Бу – нормаль хәл, һәрхәлдә, ул еллар өчен табигый хәл. Әсәреңне дөнья базарына чыгарып сынау теләге хәтта хуплауга лаек. Әмма бу ярышның үз тәртибе, үз кануннары бар: әсәрең дөнья телләренә, безнең шартларда беренче чиратта рус теленә тәрҗемә ителү мөһим иде. Бу чорда, чыннан да, байтак татар язучыларының әсәрләре Мәскәү нәшриятларында русча тәрҗемәдә чыкты да. Бер елда Үзәкнең төрле дәүләт нәшриятларында ун-унбиш, кайбер елларны егермеләп китап чыга иде. Араларында, урта кул авторларныкы очраштыргаласа да, нигездә, хәзинәбездә булганның иң яхшы дигәннәре чыкты. Әгәр тәрҗемә булмаса, шул ук Җәлилне яки Әпсәләмовны дөнья халыклары беләалыр идеме?

70–80 нче еллардагы әдәби хәрәкәтнең бер уңай күренеше (күрсәткече дияргә дә ярыйдыр) – язучыларыбызның бүтән әдәбият вәкилләре белән даими аралашуы, үзара йөрешүе. Әдәбият көннәре, әдәбият-сәнгать декадалары, бөтенсоюз яки региональ семинарлар, иҗади-фәнни конференцияләр, теге яки бу әдипнең юбилейлары... Аларның һәрберсенә диярлек Татарстаннан вәкил булып кемдер барды. Әлбәттә, андый җирләргә республика исеменнән сөйләрлек, әсәрләре киң җәмәгатьчелеккә билгеле, язучы буларак дәрәҗәлеләр бара иде. Заманында төрле республикаларга З.Нури, Г.Ахунов, С.Хәким, Р.Мостафин, Р.Харис һәм тагын кайберәүләр күп йөрделәр. Минем үземә дә СССРның бөтен республикаларын диярлек гизеп чыгарга туры килде, сирәгрәк булса да рәсми делегацияләр составында чит илләргә дә чыгылды, 1985 елда СССР Язучылар союзы делегациясенең җитәкчесе сыйфатында Италия кебек илләргә дә барып җителде. Чит ил димәктән, бу елларда татар язучылары төрле илләргә шактый еш чыга башладылар. СССР һәм РСФСР Язучылар союзларында чит ил эшләре комиссияләре язучылар өчен махсус туристик сәяхәтләр оештыра иде. Бүгенге белән чагыштырганда, символик бәягә атна-ун көн дәвамында Европа, Азия илләрен гизеп кайта иде язучыларыбыз. Ул елларда безнең байтак каләмдәшләр бу мөмкинлекләрдән даими файдалана белделәр. Язучы халкының кадере һәм мөмкинлекләре шактый иркен булган, димәк! Бу чорда драматургларның эшләре бигрәк тә яхшы барды (хәер, матди яктан алар һәр чорда да чагыштырмача яхшырак яшәделәр), төрле республикаларда, өлкәләрдә аларның пьесалары буенча спектакльләр еш куелды. Безнең театр коллективлары да бөтен СССР киңлекләрен гизделәр, аеруча Казакъстан, Урта Азия якларында җәй саен гастрольләрдә булып, халыкны туплау, рухи берләштерү юлында тарихи миссия башкардылар.

*** * ***

1980 елны Чаллыда Язучылар бүлеге ачылды. 60 нчы еллар башында Әлмәттә Язучылар оешмасы ачылуга Татарстанда зур нефть чыгу сәбәп булса, Чаллыдагы бүлек оешу КамАЗ төзелешенә бәйле. Бу ике оешманың төзелү-оешу тарихы Г.Ахунов исеме белән аерылгысыз. Әлмәттәге Язучылар оешмасының беренче җитәкчесе ул булды, ә Чаллы оешмасы аның Язучылар союзы рәислеге чагында ачылды. Әлбәттә, җирлек, тиешле зәмин юк җирдә оешма кадәр оешма төзеп булмас иде. Чаллы бүлеге шул төбәктә актив эшләгән ике төп әдәби берләшмә нигезендә барлыкка килде: берсе – Чаллыдагы «Ләйсән» (җитәкчесе – Р.Лотфуллин), икенчесе – Түбән Камадагы «Кама таңнары» (җитәкчесе – Р.Хисмәтуллин). Соңрак Зәйдәге «Зәй энҗеләре» (җитәкчесе – Р.Сәлимҗанов) берләшмәсе дә килеп кушылды. Чаллының җыелма халкы шикелле, Язучылар оешмасы да, нигездә, төрле тарафлардан килгән төрле язучылардан хасил булды. Берара җитәкчеләрне дә, Әлмәт мисалынчарак, Казаннан китереп кую хәлләре дә булды (Разил Вәлиев). Киләсе елга бу оешманың төзелүенә 25 ел тула. Үзенә күрә бер юбилей. Шул чакта күбрәк, тәфсилләбрәк сөйләрләр әле. Зур югалтуларны да кичерергә өлгерде инде бу оешма: төрле елларда бүлек эшен җитәкче булып җигелеп тарткан Э.Касыймов, Г.Кашапов, Я.Игәнәйләр инде гүр ияләре... Шулар рәтендә – С.Рәфыйков, Х.Хөснуллин, К.Сибгатуллин, А.Сафин, Н.Мадьяров, Р.Хисмәтуллин, З.Гомәрова... Шулай да әлегә шактый көчле каләмдәшләребез яши Чаллыда (А.Хәлим, Ф.Әмәк, Ф.Бәйрәмова, В.Имамов, Р.Бәшәр һ.б.). Әдәби хәрәкәтне берләштерүдә Чаллы язучыларының үз әдәби басмасы булу да бик мөһим. 1991 елдан гасыр ахырына кадәр «Аргамак» журналы чыкты, соңрак аны «Мәйдан» алыштырды. Бу журнал хәзер татар матбугатында, чыннан да, үзенең абруйлы мәйданын яулап килә.

* * *

Ул чорларда Язучылар союзы каршындагы партия оешмасының бик актив эшләвен әйтергә кирәк. Ай саен бер тапкыр тәгаен уза торган партия җыелышлары язучыларны үзенчә туплау, берләштерү ролен үтәп килде. Көн тәртибенә рәсмирәк мәсьәлә (әйтик, фәлән «съезд яки пленум карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар») куелса да, язучылар, партиялеме, партиясезме, барыбер, әдәбият турында, актуаль проблемалар турында җитди итеп сөйләшәләр, киңәшләшәләр иде, ниндидер проблемаларны хәл дә итәләр иде. Хәзер өлкәннәр үзгә бер ностальгик хис белән искә алалар ул елларны, ул җыелышларны. Язучыларның партия оешмасы бездә, күрәсең, шактый демократик булган. Мәсәлән, безнең оешмада композитор Сара Садыйкова, библиограф Асия Гыйниятуллина һәм башка тармакта эшләүче кайбер пенсионерлар да әгъза булып тора иде. Оешма булгач, аның җитәкчеләре – партоешма секретарьлары да бар, әлбәттә. Комиссарлар кебегрәк булып чыга инде. Ул елларның парторглары Г.Гобәй, Г.Минский, Л.Ихсанова, Р.Мостафин, В.Нуруллин, Т.Миңнуллин, Р.Мөхәммәдиев, Р.Кәрамиләр яхшы хәтердә. Партия таркалыр алдыннан соңгы парторг К.Латыйп булды.

Әлбәттә, төрлесе булды ул җыелышларда. Партия өлкә комитеты даирәләренең таләпләренә туры килеп җитмәгән әсәрләр басылган яки басылырга әзерләнгән очракта партияле каләмдәшләр, ишарә булу белән дигәндәй, андыйларны оператив рәвештә тәнкыйть итәргә һәрвакыт әзер иделәр. Ул елларда иң күп «тукмаклар» алган кеше, мөгаен, шагыйрь С.Баттал булгандыр. Аның «Батый ханга хат» дигән поэмага тартым озын шигыре тирәсендә генә дә сүз куертулар дистә елларга сузылды... Шулай ук Ә.Еники («Саз чәчәге»), Н.Фәттах («Сызгыра торган уклар»), М.Мәһдиев («Фронтовиклар»), А.Гыйләҗев («Өч аршын җир») әсәрләре дә үз вакытында актив коммунист иптәшләр тарафыннан шактый ук «чыбыркыландылар».

Партия заманында интернационализм дигән сүз киң кулланууда иде. Кызганыч, бу сүз сирәгрәк ишетелә башлады. Күпләр өчен интернациональлекнең иң яхшы билгесе – доллар яки евро хәзер. Интернационализм, минемчә, бөек төшенчә. Дөньяда халыклар дуслыгы дигән нәрсә булса, аның нигезе шушы төшенчә белән бәйле. Татарстан Язучылар союзы гомер-гомердән яхшы мәгънәдәге интернациональ оешма булды. Татар телле язучылар да, рус телле яки башка бүтән телдә язучылар да бердәм, тату иҗади хезмәттәшлектә яшәделәр. Татарстанда һәрвакыт рус язучыларының зур төркеме яшәде. Кайбер исемнәрне генә искә төшерик: М.Бубеннов, Т.Журавлев, А.Салмин, С.Радзиевская, Г.Паушкин, М.Скороходов,

Я.Винецкий, Ю.Белостоцкий, Н.Орешина, В.Корчагин... Шулай ук милләте белән татар, әмма рус телендә иҗат итүчеләр – И.Кәлимуллин, Р.Кутуй, И.Ахунҗанов, Д.Вәлиев, Р.Бохараев, М.Зарипов, Ә.Мушинский, Р.Кожевникова, Л.Газизова... Безнең оешма җирлегендә чуваш язучылары секциясе дә уңышлы эшләп килде (шунысы игътибарга лаек: бүтән республикаларда һәм өлкәләрдә яшәгән татар язучыларының беркайчан да диярлек ни оешмалары, ни иҗади секцияләре була алмады. Соңгы елларда Башкортстанда татар язучылары оешмасы борынлады борынлавын...). Дөрес, республикада чуваш телендә язучылар сирәкләнде хәзер. Шулай да без үз сафларыбызга кардәш халык вәкилләрен алуны дәвам итәбез. Мәсәлән, үткән ел чуваш Евгений Турханны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алдык.

Сүз төрле телләрдә иҗат итүчеләр турында баргач, бу урында рус телендә яза торган милләттәш язучылар хакында янә берәр җөмлә язып узыйк. Күрәсең, чынлыклап үз дәүләтең булмагач, гамәлдәге дәүләт телендә язарга омтылуны аңлап була. Дәлилле фактлар да җитәрлек. Еракка барасы юк, үзебезнең татар язучыларының иҗат сәләтенә ия балаларның кайберләре рус телендә язалар. Г.Кутуйның улы – Рөстәм Кутуй, Г.Әпсәләмовнең оныгы – Альбина Әпсәләмова, А.Расихның кызы – Фәридә Рәсулова, И.Юзеевнең улы – Салават Юзеев... Шуларга республикадан читтә яшәүче бүтәннәрне өстик: Роман Солнцев (Ренат Суфиев), Рауль Мир-Хәйдәров, Камил Таңгалчиев... Аларны татар язучысы итеп санаргамы? Бәхәсле нәрсә. Күбесе Татарстан Язучылар оешмасы әгъзалары булып тора. Иҗади потенциаллары зур булган актив шәхесләр. Минемчә, аларны татар әдәбияты хәрәкәтенә мөмкин кадәр ныграк тартырга кирәк. Әйтик, тәрҗемә эшендә, мөхәррирлек вазифаларында... Бу каләмдәшләребезгә читсенеп, үгисетеп карау әдәбиятыбызны тарайту булыр иде. Тараю ул үзе дә килә, ә менә киңәю, тирәнәю...

*** * ***

...Алдарак әйтелгәнчә, 1984 елны Язучылар союзы рәисе итеп драматург Т.Миңнуллин сайланды. «Торгынлык» еллары дип йөртелгән олы бер чорның соңгы рәисе Г.Ахунов җитәкчелек аренасыннан китте. Үзгәртеп кору еллары якынайган иде инде... Миңа калса, Г.Ахунов белән бергә әдәбиятның тулы бер чоры китте, ул гына да түгел, тиздән тарихи Матбугат йортыннан Язучылар оешмасы да күчеп китте...

Һич шик юк, Т.Миңнуллин җитәкче чагында Язучылар союзының Казандагы иң матур биналарның берсенә күчүе үзе бер тарихи вакыйга (дөрес, яңа бинага күчү мәсьәләсе егерме еллар элек үк күтәрелгән, һәм ул хәл ителергә тиеш иде). Ул мәһабәт бинаның адресы – Мөштәри урамы, 14 нче йорт. (Ул вакытта Комлев урамы дип йөртелә иде.) Яңа җир, борынгы булса да, яңа йорт, яңа хуҗалар, яңа тәртипләр... Язучылар оешмасының соңгы унбиш елы шушы бина белән бәйле. М.Галиевнең «Өмә» исемле юмор әсәрендә бу бинага яңа күчкән елларның бер хатирәсе бик матур сурәтләнгән.

Әйе, Язучылар оешмасына йомыш төшкәндә, без хәзер яңа бинага йөрибез. Ә Баумандагы (бу үзәк урам үзенең җисеменә туры килгән берәр исемгә кайчан алыштырылыр икән инде, бу хакта сүз күп булды бит!) Матбугат йортының күңелдән чыкканы юк. Нишлисең, хәтердән китеп булмый: яңа заман татар әдәбиятының, татар совет әдәбиятының дисәм дә була, яшьлеге, олпат тулы чагы шушы бинага бәйле шул. Соңгы дистә еллардагы хәлләргә күчкәнче, Матбугат йортына бәйле берничә оешма турында берәр кәлимә сүз әйтеп узыйм.

Андый оешмаларның берсе – Әдәби фонд, дөресрәге, СССР Язучылар әдәби фондының Татарстан бүлеге. Икенче катта коридор өлешен такта белән генә бүлеп алган кечкенә генә бер бүлмә. Кечкенә булса да, мәгънәсе белән төш кенә бүлмә! Язучының тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә караган байтак эшләр хәл ителә иде анда! Кайбер яшь һәм башлап язучылар, Оешмага кабул ителгәнче (ә бу процесс бик озак – дистә елларга сузылырга, сузылып та, кабул ителмәскә мөмкин), Әдәби фондка кереп, анда әгъза булырга тырыштылар. Чөнки Әдәби фонд әгъзасы язучыларга бирелгән ташламалардан (путевка-юлламалар, төрле пособиеләр, поликлиникаларга билгеләнү, ярдәм акчасы алу һ.б.) файдалана ала иде. Үз вакытында С.Сабиров, Ә.Шамин, М.Хөсәен, И.Рәми, Р.Ишморатова һәм тагын кайберәүләрнең язучылар тирәлегендә шул сыйфатта йөрүләре истә калган.

60 нчы еллар башында Әдәби фонд башлыгы Сөнгать ага иде. Фамилиясе Сафиуллин булганын соңрак белдек. Какча гына гәүдәле, ипле, тыныч кына сөйләшә торган эшлекле, сабыр кеше булып хәтердә калган. Соңрак (1964–1967 елларда) бу җаваплы урында язучылар Х.Сарьян, М.Шәрифуллиннар (икесе дә Башкортстаннан иделәр, икесенең дә гомерләре кыска булып чыкты: берсе 1978 елны – 48 яшьтә, икенчесе 1966 елны 38 яшендә вафат булдылар) эшләп алды. Әдәби фонд җитәкчесе булып иң озак (1967–1983 еллар) һәм нәтиҗәле эшләгән кеше – язучы һәм тәрҗемәче Л.Хәмидуллин булды. Соңгы егерме ел эчендә Әдәби фонд башлыгы булып тагын биш-алты кеше эшләде. 1996 елдан бирле директор – Д.Салихов, җәмәгать тәртибендә Әдәби фондның хәзерге рәисе – шагыйрь Г.Рәхим. Гомумән, Әдәби фонд тарихы һәм эшчәнлеге язучылар тормышында үзе бер аерым хезмәткә лаек сәхифә. Язучыларның кавышу-туй хәлләреннән башлап үлем-китем мәшәкатьләренә кадәр Әдәби фондның катнашы булды. Заманында язучылар һәм аларның гаиләләре өчен махсус сабантуйларга кадәр оештыра иде Әдәби фонд егетләре!

Матбугат йортында урнашкан, заманында уңышлы гына эшләп килгән тагын бер оешма – Татарстан Язучылар союзының Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы. 60 нчы еллар ахырында, М.Әмир рәислек иткән чорда оешты ул. (Дөрес, әдәбиятны пропагандалау гел актуаль булып килгән, язучыларның беренче съездларында ук күтәрелә бу мәсьәлә. 1953 елда җәмәгатьчелек тәртибендә берничә язучыдан торган (М.Садри, М.Хөсәен, Г.Шамуков) махсус бер бюро да оештырыла. Әмма аның юридик статусы булмаган, әлбәттә. Соңгы вакытта бу фактны оешма төзелүнең башы санап, ясалма юбилей да билгеләп йөрделәр әле.) Чынлыкта штатта кешеләре, реквизиты, тиешле бүтән атрибутлары булган оешма 1967 елда төзелде. Бер ел элек Мәскәүдә, СССР Язучылар союзында Бөтенсоюз пропаганда бюросы оешкан иде. 70–80 нче елларда Советлар Союзының күп республикаларында һәм өлкәләрендә бик тантаналы һәм рәсми рәвештә үтә торган Совет әдәбияты көннәрен (заманында Татарстанда да узды), нигездә, шушы Бөтенсоюз бюросы оештырды да.

Безнең пропаганда бюросының штаты өч кешедән гыйбарәт иде: директор, әдәби хезмәткәр, бухгалтер. Конкрет эшкә килгәндә, бюро төрле оешмалар, предприятиеләр, колхозлар белән хезмәттәшлек договорлары төзеп, шул килешү нигезендә берничә язучыдан (арада берәр популяр җырчы белән баянчы да була иде) торган бригада төрле аудиторияләр алдында чыгышлар ясый иде. Бюроның җитәкчеләре булып М.Шәймөхәммәтов (сәнгать буенча аспирантура үткән Сарман ягы кешесе. М.Газар псевдонимы белән шигырьләр дә яза иде), М.Шиһапов, Э.Гаделов, Р.Кәрамиләр, әдәби хезмәткәр булып төрле елларда М.Галиев, Ф.Сафин, Х.Халиков, К.Кәримов, Н.Хәсәновлар эшләде. Үзгәртеп кору дигән елларда алты-җиде ел бюроның эше тукталып та торды. 2000 елдан яңадан торгызылган бу оешманы хәзер Р.Сәгъди җитәкли.

Сүз дә юк, пропаганда бик кирәк нәрсә. Хәзерге заманда бигрәк тә. Реклама индустриясенең көннән-көн колачлана баруы тикмәгә түгел. Татар китабы (300 елга якын тарихы бар үзенең!) яклауга, пропагандага аеруча мохтаҗ. Пропаганданың ысуллары күп: радио-телевидение, газета-журнал, буклет-проспектлар, афишалар, төрле видео-аудио кассеталар... Әмма язучының үз укучылары, бигрәк тә мәктәп балалары белән очрашулары бөтенләй үзгә эффектка ия. Тере язучыларны күрү, алар белән аралашу бала күңелендә гомерлеккә калучан. Әлбәттә, сүз чын, зыялы язучының югары дәрәҗәдә үткән очрашулары турында бара. Зур мәгънәдә әдәби-әхлакый дәрес булган кичәләр, шөкер, бихисап булды. Шулай да әдәбият файдасына булмаган аралашу фактларын да таныйк. Берзаман әлеге бригадаларда урта кул яки үзешчән дәрәҗәдәге каләм ияләре күбәеп китте (чөнки зур язучылар очрашуларга бик еш чыга алмый, талант иясенең һәр сәгате исәпле). Урта кул каләм ияләре артыннан гөл үсеп калмый, әлбәттә. Минемчә, язучының төп вазифасы артык күренеп йөрү түгел, иҗат итү. Гарәпләрдәге бер әйтемне дә онытмыйк: «Мөгәйдинең үзен күргәнгә караганда, шигырьләрен ишетү хәерлерәк».

Матбугат йортындагы Тукай клубы! Алда аның турында әйтеп үткән идек инде. Тагын берничә сүз өстисе килә. Үзенең 50 елдан артык тарихында кемнәрне генә күрмәгән дә кемнәрне генә мөнбәреннән сөйләттермәгән ул! Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге үзебезнең бөек затларыбыз булган бу бинада: С.Сәйдәшев, Б.Урманче, Н.Җиһанов, Х.Әбҗәлилов... Үзебезнең классик язучыларыбызны әйткән дә юк! Ш.Камал, К.Тинчурин, К.Нәҗми, Х.Туфан, Г.Бә-

широв, С.Хәким... Казанга килгән бик күп атаклы шәхесләр дә язучылар белән очрашырга шушы клубка килгәннәр. Итальянлы Дж. Родари, композитор А.Хачатурян, артист А.Райкин, космонавт В.Терешкова, диңгезче Ә.Җиһаншин, атаклы шагыйрьләр М.Кәрим, К.Кулиев, С.Кудаш, Д.Көгелтинев, Е.Евтушенко, Б.Әхмәдуллина... Төрле елларда клуб директоры булып унга якын кеше эшләде. Алар арасында аеруча эш күрсәткәннәре: 60 нчы елларда фронтовик шагыйрь М.Саттаров, 70–80 нче елларда шагыйрь Ә.Рәшитов булды. Хәзер Тукай клубының адресы бүтән: Язучылар берлеге бинасының янкормасында ул. Хәзер анда бүтән кешеләр, бүтән рух... (Алда әйткәнемчә, хәзер инде ул бина буш. – *Р.Ф., 2010.*). Дөрес, анда да атаклы кешеләр булмый түгел, хәтта 1991 елда Россия Президенты Б. Ельцин да булып, язучылар белән очрашып китте.

Язучылар союзының шактый бай фондка ия үз китапханәсе дә бар иде әле. Ул әле дә бар исәпләнә. Хәзер яңа китаплар белән бик тулыландырылмый шикелле. Ул китапханәдә Брокгауз һәм Эфрон исемнәре белән йөртелә торган, алтын йөгертелгән фолиант томнар да барлыгы истә. Кстати, дип әйтик, яңа Союз бинасында, икенче катка менә торган баскыч култыгында, бер сәнгать әсәре – хатын-кыз сурәтләнгән матур бронза сын да бар иде...

Шул ук Матбугат йортында 80 нче елларда республикакүләм дәрәҗәдә Китап сөючеләр җәмгыяте дә эшләп килде. Хәзерге яшьләр өчен сәеррәк яңгырыйдыр бу сүзтезмә... Бу язмамны әзерләгәндә яшьләр газетасында бер кечкенә генә хәбәр укыдым да сискәнеп киттем: «Россия халкының 40 проценты бер дә китап укымый. 80 нче елларда илдә андыйлар 10 процент кына тәшкил иткән. 1990 елда Россиядә 18 мең китап кибете эшләгән булса, бүген алар 3 меңгә калган. Көндәлек газеталарны исә ил халкының 24 проценты гына укый. Чагыштыру өчен: финнарда бу сан 87 процентка тиң». Хәтердә: бу оешмада ул вакыттагы яшь язучылар Н.Акмал, А.Хәсәновләр эшләп йөрде... Менә хәзер – халык китаптан бизеп барган чорда кирәктер ул Китап сөючеләр җәмгыяте!

*** * ***

Хроникаль күзәтүнең «җеп очын» җуймыйча, X съезддан соңгы әдәби хәлләргә кайтыйк. 1984–1989 елларда, шиксез, байтак иҗади-оештыру эшләре башкарылды. Агымдагы эшләрдән тыш хәтердә җуелмаслыклары – Башкортстанда һәм Чувашстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Шул заманга хас колачлылык, патетик рух, бәйрәмчә тантаналар. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы, табигый, моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә яхшы үтте. Тугандаш республикалардан да байтак кунаклар килгән иде (1986 елның 26 апреле – Тукайның тууына 100 ел тулган көн – Чернобыльдәге коточкыч фаҗига көне белән дә тарихка кереп калды).

Туфан Миңнуллин җитәкчелек иткән чорда, «халык шагыйре», «халык язучысы» дигән мәртәбәле исем булдырылды. 1985 елда бу исем турында Татарстан Верховный Советы Указы игълан ителгәннән соң (хәзер ул Президент Указы белән бирелә), бүгенге көнгә кадәр «халык шагыйре», «халык язучысы» исемен йөрткән әдипләрнең саны 17 гә җитте. Күбрәк тә бугай бу сан. Шуларның 10 ысы мәрхүмнәр. Әдәбият тарихы белән кызыксынганнар өчен тулы исемлекне санап үтәм: халык шагыйрьләре – С.Хәким (1986), Г.Афзал (1991), И.Юзеев (1993), Ш.Галиев (1995), Р.Фәйзуллин (1999), Ф.Яруллин (2001), Р.Харис (2004), Ә.Баян (2004); халык язучылары – Г.Бәширов (1986), Н.Исәнбәт (1986), Ә.Еники (1989), Ф.Хөсни (1993), Г.Ахунов (1993), А.Гыйләҗев (1993), М.Мәһдиев (1993), Н.Фәттах (1998), Х.Камалов (2001).

1986 елның җәендә (24–28 июнь) СССР Язучылар союзының чираттагы һәм соңгы съезды булып үтте. I Бөтенсоюз съезды турында шактый тәфсилле язган идек, мантыйк буенча соңгысы турында да берничә сүз әйтеп узыйк. Татарстаннан делегат булып бу съездда түбәндәге язучылар катнашты: Ә.Еники, Н.Фәттах, Т.Миңнуллин, М.Госманов, И.Юзеев, Р.Харис, Н.Орешина, Т.Галиуллин, Р.Гатауллин. Делегат булып сайлансалар да, С.Хәким – каты авыру, Р.Фәйзуллин, ерак командировкада булу сәбәпле, бу съездга бара алмадылар.

I Бөтенсоюз съезды белән VIII съезд арасында 50 дән артык ел. Бу еллар эчендә әдәби вазгыять, әлбәттә, нык үзгәргән. 50 ел эчендәге идеологик сәясәтнең нәтиҗәләре ярылып ята. Милли әдәбиятлар турында сөйләгәндә, сүз, нигездә, союздаш республикалар әдәбияты турында. I съездда, М.Горький докладында булсын, чыгышларда булсын, татар әдәбияты СССР халыкларының әйдәп баручы әдәбияты итеп тәкрарланды. Ә бу съездда? Дөрес, СССР

Язучылар союзының беренче секретаре Г.Марков ясаган төп докладта бер исем (тыйнаксызлык саналмасын, ул Р.Фәйзуллин исеме иде. Әмма моннан, миннән гайре, бүтәннәргә ни юаныч!) башка халыкларның кайбер язучылары белән бергә саналып китә китүен. Ә тагын? Татар әдәбияты кадәр татар әдәбияты бит ул! Съездның пленар утырышларында (жанрлар буенча секция утырышлары аерым да булды) җәмгысы 73 кеше чыгыш ясаган. Иң соңгы сүз Т.Миңнуллинга бирелә... Ахырга иң яхшы җырчыны чыгаралар, дияр кемдер. Бу очракта, рус сүзен кыстырып әйтсәк, случай другой. Т.Миңнуллинның чыгышы яхшы булган булуын: стенография язмасыннан шулай күренә. Хәер, съездда катнашкан язучыларыбыз кулуарларда югалып калмаганнар калуын: «патша хатыны» (Генсек М.Горбачев хатыны Раиса Максимовна) белән фотога төшкәннәр. Бу хакта безнең матбугатта матурлап язып та чыктылар...

VIII съездны «СССР язучыларының соңгы съезды» дип язсам да, кемдер, бу бит дөреслеккә туры килми, дияр. Һәм, чыннан да, ул үзенчә хаклы булыр. Формаль яктан тагын бер съезд җыелды әле. Бу хәл 1992 елның июнь аенда булды. Әмма аны инде элеккеге мәгънәдәге СССР совет язучылары җыены дип әйтеп булмый. Партиянең беткән, СССРның тәмам таркалган чагы. Советлар Союзы җирлегендә дистәләп мөстәкыйль, яңа дәүләтләр оешкан. Кая ди анда коммунистлар партиясе җитәкчелегендәге, социалистик реализм нигезендәге күпмилләтле совет әдәбияты турында сөйләүләр!.. Өстәвенә бу съездда Латвия, Литва, Эстония, Молдова, Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗан язучылары бөтенләй катнашмады. Украина һәм Белоруссия вәкилләре күзәтүче сыйфатында утырдылар. Шулай булгач, нинди СССР Язучылары съезды була инде ул! Дөрес, Казакъстан, Үзбәкстан, Татарстан, Төрекмәнстан, Таҗикстаннан килгән язучылар кызып-кызып шактый сөйләделәр бу съездда. Төрки халыклар һәм рус язучыларының (Евразия тәгълиматына саллы мисал!) активлыгы белән үткән бу съездны үзбәк Т.Пулатов ачты, һәм Язучылар союзларының Халыкара берлеге (МСПС – Международное сообщество писательских союзов) рәисе итеп ул сайланды да. Биш-алты ел үткәч, бу шәхес язучылар олимпыннан төшерелде, каядыр юкка чыкты... Кыскасы, СССР язучыларының чын мәгънәсендәге съезды 1992 елда түгел, ә 1986 елны узган булып чыкты. 1934 елда старт алган Бөек башлангычның ахыры шулай тәмамланды.

(Язмамның беренче өлешендә, үз-үземә дигәндәй, сорау куйган идем: 1934 елдагы I Бөтенсоюз язучылар съездында катнашкан берәр исән кеше бар микән? Күптән түгел «Литературная газета» аша ачыкланды – бар икән! Ул – Екатеринбургта яшәп ятучы 95 яшьлек шагыйрә Елена Хоринская. Съездда яшь шагыйрә сыйфатында Бурят-Монголия вәкиле булып катнашкан. Татарстаннан делегат булып катнашкан Хәсән Туфан 1981 елны вафат булды. Калганнары яшьли диярлек һәлак булдылар, югалдылар...)

Фикер агышына ияреп, без берничә елга алга сикердек шикелле. Хроникаль эзгә төшеп, үзебезнең хәлләргә янә кайтыйк.

Татарстан язучыларының XI съезды 1989 елның 17 маенда В.И.Ленин Үзәк музееның Казан филиалында (хәзер милли мәдәни үзәк) ачылды, икенче көнне Язучылар союзының Г.Тукай исемендәге клубында дәвам итте (шул ук көнне Н.Дәүлине дә соңгы юлга озату булды)**.** Съездны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Ә.Еники ачты. Республика язучыларының иҗаты турындагы отчет-хисап докладын идарә рәисе Т.Миңнуллин ясады. Аннары жанрлар буенча өстәмә докладлар – проза (Ф.Миңнуллин), поэзия (Т.Галиуллин), драматургия (А.Әхмәдуллин), рус язучылары иҗаты (М.Скороходов), балалар әдәбияты (Р.Миңнуллин), очерк һәм публицистика (Г.Кашапов), «Казан утлары» журналы эшчәнлеге (Р.Харис), тәрҗемә (С.Шәмси) тыңланды.

Фикер алышуларда Р.Мөхәммәдиев, Н.Әхмәдиев, Разил Вәлиев, Р.Кутуй, С.Наметбаев (Кыргызстан), Р.Фәйзуллин, Ә.Рәшитов, Ә.Мәхмүдов, Ф.Мусин, И.Салахов, Ә.Гаффар, Р.Хәмид, Р.Мингалим, Ш.Янбаев (Башкортстан), Мансур Вәлиев, И.Нуруллин һ.б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре (хакимияттәге соңгы рәсми секретарь!) Р.Идиятуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе рәисе С.Михалков чыгыш ясадылар.

Съезд яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе итеп Р.Мөхәммәдиевне, «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Р.Харисны сайлады. XI съездда сайланган 23 кешелек идарә составы: Р.Мөхәммәдиев (рәис), Р.Батулла, Ә.Баян, Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Разил Вәлиев, А.Гыйләҗев, Ә.Еники, Ф.Зөлкарнәев,

Р.Зәйдуллин, Г.Кашапов, В.Корчагин, Р.Кәрами, М.Маликова (рәис урынбасары), З.Мансуров, Р.Мингалимов, Р.Миңнуллин, Ф.Миңнуллин, И.Нуруллин, Г.Рәхим, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Н.Әхмәдиев (соңрак, идарә карары белән бу составка Г.Ахунов, М.Мәһдиев тә кертелде).

Кызык, гыйбрәтле җыен булды бу съезд. Үзгәртеп кору дигән чорның үз пигына җиткән еллары. Партия дигән ат-арбаның дирбияләре тугарылып бетеп барса да, кемнәрнеңдер әле дилбегәне нык итеп тотарга тырышып тырмашкан чаклары... Шул ук вакытта җәмгыятькә демократик үзгәрешләр кергән еллар. Инде ничә ел рәттән халык ихластан шаккатып кәгазьсез сөйләүче түрәләрне күрә, халык депутатларының һәр чыгышын йотлыгып тыңлый. Килешә, ярсый, бәхәсләшә... Безнең бу съездда да демократик шытымнар чагылды, әлбәттә.

Съезд кабул иткән резолюциядә, мәсәлән, Татарстанга союздаш республика статусы бирү, татар телен дәүләт теле итеп игълан итү, татар язучыларының Бөтенсоюз ассоциациясен оештыру кебек мөһим проблемалар күтәрелде. Шулай ук бу съездда беренче мәртәбә рәис берничә кандидатура арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайланды.

**IV**

Ниһаять, язмамның соңгы бүлегенә килеп җиттек. 90 нчы еллардан башлап XXI гасырның беренче еллары, ягъни бүгенгегә кадәрге әдәби хәлләр. Өр-яңа тарих булып чыга инде. Чыннан да, хәзер генә кайнап-пешеп чыккан ризык шикелле кабаланып йотсаң... Суыныр өчен вакыт кирәк. Шулайдыр, юкса 2001 елда чыккан «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы VI томы 90 нчы еллар белән тәмамланмас иде. Шулай да соңгы ун-унбиш еллардагы әдәби хәрәкәт турында сөйли башларга, анализлап, сабак алып, кайбер нәтиҗәләр ясый башларга вакыт җитте кебек. Бу еллардагы җәмгыять тормышын берәү дә тулы итеп объектив бәяли алмас әлегә. Ә еллары нинди диген! Революцион үзгәреш, хөррият еллары диикме, халык милкенең бәгъзеләр тарафыннан үзләштерелү еллары яки ачыклык һәм болганчыклык еллары диикме?.. Бу елларга эпитетларның кайсы да – уңае да, тискәресе дә – бик ипле ябыша ала... Бу еллардагы иң зур үзгәреш, хәтта сенсацион үзгәреш, әлбәттә, СССРның таркалуы булды. Күпләр өчен көтелмәгән тетрәнү. Төп йорт таркалгач була торган хәлләр башланды илдә. Аерымланулар, бүлгәләнүләр, мал бүлешүләр... Бу процесс иҗат оешмаларын да читләтеп үтмәде. Иҗат оешмаларының иң көчлесе саналган Язучылар союзларында бу процесс бигрәк тә ачык күренде. Үзәк Әдәби фонд карамагында булган мөлкәт тирәсендә шау-шулар, суд-низаглар аеруча көчле булды. Чөнки байлык та бар иде шул! Атаклы иҗат йортлары гына күпме иде! Пицундада, Ялтада, Дубултыда, Переделкинода... Мал-мөлкәт тирәсендәге ыгы-зыгы (Мәскәүдә аның әле хәзер дә тынганы юк) бер хәл, язучылар үзләре дә, бүлгәләнеп бетеп, төрле төркемнәр булып оештылар. Башкаладан үрнәк алыпмы, үзләренең ихтыяҗы булыпмы, мондый хәлләр регионнарга да күчте. Мисалга ерак барасы түгел, күрше чувашларда язучыларның берничә оешмасы хасил булды... Ә бездә? Бездә андый бүлгәләнүләр булмады дип әйтеп була. Дөрес, 80 нче еллар ахырында Язучылар оешмасының кирәклеген шөбһә астына куйган фикерләр булгалады. «Язучылар колхозы»н тәнкыйтьләгән мәкаләләр күренгәләде. Әмма сүз, нигездә, оешманы бетерү турында түгел, оешманы яңача үзгәртеп кору, камилләштерү кирәклеге хакында барды. Язучылар оешмасының безнең өчен зарур булуы хакында XI съездда Т.Миңнуллинның хисап докладында да кистереп, дәлилләп әйтелде. Оешмабызның таркалмый-бүлгәләнми тотрыклы булып калуы, минемчә, бердәмлегебез, эчке көчебез билгесе. Дөрес, 1995 елда Татарстанда, Халыкара язучылар оешмасының бер тармагы буларак, ПЕН-үзәк төзелде. Әмма ул үзебезнең төп оешмадан аерымлануны түгел, киресенчә, язучылар коллективының иҗади-сәяси мөмкинлекләренең -зурлыгын гына күрсәтте. Чөнки ПЕН-үзәктә шул ук абруйлы язучылар, байтагы Татарстан Язучылар оешмасының идарә әгъзалары...

СССР таркалу белән сәяси вазгыять тә бик нык үзгәрде: милли үсеш максатлары шул ук калса да, ориентирлар алышынды. Әйтик, союздаш республика статусы алу максаты мәгънәсен югалтты. Үзбилгеләнүдә грузин, үзбәк, латышлар һәм башка халыклар дәрәҗәсен аласы булса, аерым мөстәкыйль дәүләт булырга омтылырга кирәк булып чыкты... Әгәр теге яки бу басма ачуга дистә еллар буе ялынып дигәндәй йөреп Үзәктән рөхсәт алу кирәк булса, хәзер андый рөхсәт-карарларның хаҗәте бетте. Оештыр үз республикаңда, үз өлкәңдә; кануннлаштыр, чыгар – бернинди каршылык юк. Һәм... кем әйтмешли, «процесс башланды!»,

буа ерылды... 1989 елның июленнән – яшьләр журналы «Идел» (ярты гасырлап хыялда йөргән басма!), 1990 елның мартыннан – «Салават күпере», 1991 елның сентябреннән – «Мирас», шул ук елның октябреннән «Аргамак» чыга башлады... Мөгаен, мәдәният-мәгариф өлкәсендә иң зур казанышларыбызның берсе – 1991 елда «Мәгариф» нәшриятының оештырылуыдыр (дөрес, мондый исемдәге нәшрият XX гасыр башында ачылып, 1922 елда ябылган булган). Бөтен татар дөньясын дәреслекләр, төрле методик әсбаплар белән тәэмин итеп торучы бу зур «рухи завод»ның башында безнең язучыбыз М.Вәлиев торды. Цензура бетерелде. Гомумкешелек гуманизмына каршы килмәгән теләсә нинди әсәрнең дөньяга чыгуына юл ачылды. Кайчандыр басылган булып та, совет заманында тыелган әсәрләр янәдән халыкка кайтты. Моңа Г.Исхакый иҗаты ачык мисал. (Асылда, бу эшнең башында И.Нуруллин, Л.Гайнановалар торды. Г.Исхакыйның күләмле әсәрләрен беренче булып яңадан чыгаручы журнал «Казан утлары» булды. «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Сөннәтче бабай» әсәрләре И.Нуруллинның кереш сүзе белән журналыбызда 1990 елның 1 нче санында басылып чыкты.) Әйе, хакимият органнары тарафыннан чикләү, тыюлар бетерелде. Моны мин, журналда эшләү тәҗрибәсенә таянып, белеп-ианнып әйтәм. Эш дәверендә, идеологик караштан чыгып, әдәби-эстетик кыйммәткә ия бер генә әсәр дә читкә тибәрелмәде. Киресенчә, безнең заман язучыларының элекке елларда басылмыйча калган шәп әсәрләре юк дәрәҗәсендә булып чыкты. Чыгарма булып, бәлки, С.Батталның «Я – Иванов Иван Иванович» дигән күләмле памфлеты гына санала аладыр... Күрәсең, безнең язучылар – конъюнктура законнарын яхшы үзләштергән прагматиклар, һәм алар, «баш китәрлек» әсәрләр язып, киләчәк буыннарны «бимазаламаска» булганнардыр...

* * *

«Атай үлде, хөррият килде!» дип әйткән, ди, имеш, бер малай. СССР таркалып, демократия дигән хөррият килеп алды алуын (Казансу ярында хәтта «Хөррият» исемле биек сын-стела да калкып чыкты!), әмма аның «ләкин»нәре дә безнең өчен күп икән шул! Чәчелгән, сибелгәнлекнең тагын бер «татлы» җимешен татыдык: байтак милләттәшләребез, тарихи Ватаныннан тәмам өзелеп, чит дәүләт-мәмләкәтләрдә калды... Үз туфрагында берегеп күмәкләшеп яшәгән халыклар үз дәүләтләрен корды, ә без, татарлар, тагын да азаеп, Россия карынында калдык... Казакъстан һәм Урта Азиядә күпләп яшәүче милләттәшләребез белән рухи аралашу бөтенләй диярлек бетте. Кая ди ул театрларыбызның ел саен Урта Азиягә чыга торган гастрольләре? Газета-журналларыбыз, китапларыбызның юлы кырт киселде. Элек «Казан утлары», «Азат хатын» («Сөембикә») журналларының өчтән яки дүрттән бере (ул 15–20 мең дигән сүз!) шул якларда таралса, хәзер алар өч-дүрт дистә данәгә калды... СССР таркалгач, татар матбугатының (бу хәл башка халыкларга, шул исәптән русның үзенә дә кагыла) тиражлары катастрофик дәрәҗәдә кимеде. Дөрес, Россиянең татарлар яши торган төбәкләрендә татарча газеталар ачылды ачылуын. Әмма алар, безнең район газеталары сымак, әдәбият-сәнгать үсешенә әллә ни тәэсир итәрлек дәрәҗәдә була алмадылар. Казанда чыга торган төп басмаларның таралуына да әллә ни булышлы тәэсир итмәделәр шикелле. Бәлки әле киресенчәдәдер: чөнки татарча укучылар катламы бик «юка», гомумтатар укучысының матди яклары кысынкы икәнлекләрен дә исәпкә алсак, әбүнәчеләр, гадәттә, берәр басмадан артыкка языла да алмыйлар. Кайберләре, бәлкем, әнә шул җирле газетаны алдырадыр... Кыскасы, татар телендәге басмаларның тиражы кимүе безгә – язучыларга – бик «кырын сукты», укучыларыбызның кискен кимүенә китерде. Ә язучының укучысы булмаса...

Газета-журналларның таралышы һәм иҗтимагый әһәмиятләре турында абстракт сөйләү бер хәл, аларны чыгарыр өчен иң мөһиме – матди җирлек, финанс чыганагы кирәк бит әле! 90 нчы еллар башында газета-журналларыбызны нәшер итү мәсьәләсе бик катлаулы һәм киеренке булды. Элек керем китергән басмалар, тиражлар нык кимегәч, үз чыгымнарын каплый алмый башладылар. Яңа чыганаклар эзләү ихтыяҗы туды. СССР таркалып, Россия үзенә үзбаш булып калгач, экономик, шуңа бәйле финанс яктан, бизгәк тоткан кешедәй, калтыраулы хәлдә иде. Элек сүзлекләрдән генә ишетеп белгән инфляция, дефолт кебек терминнар актив сүзләр булып китте... Хезмәт коллективларында киеренке хәлләр туды. Хезмәткәрләргә вакытында хезмәт хакы түләп булмый, авторлар символик гонорарларын да

яртышар ел күтәргә мәҗбүр. Мәскәүдә әдәби журналларның бөтенесе диярлек Язучылар союзы органы булудан туктадылар. Чөнки иҗтимагый оешма статусындагы (үзләре дотациягә, ярдәмгә мохтаҗ) Язучылар союзлары теге яки бу басма өчен бернинди финанс ярдәме күрсәтә алмый. Безнең «Казан утлары» журналы каршына да килеп басты бу проблема. Дистә еллар буе дәүләткә керем китереп, традицион рәвештә Татарстан Язучылар союзы органы саналып, җай белән генә чыгып килгән журналга базар мөнәсәбәтләре чорында нишләргә иде соң? Әбүнәчеләрдән җыелган акчага нибары берничә сан гына чыгарып була... Җир кемнеке булса, җыр шуныкы дигәндәй, кем түли, шул гамәлгә куючы була. 1991 елны Татарстан Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгы тарафыннан журналның оештыручылары булып Газета-журналлар нәшрияты, Татарстан Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы расланды. Ә ярты елдан соң журналның төп оештыручысы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты булуына ирешелде. Шулай итеп, 1992 елның башыннан бүгенгә кадәр «Казан утлары»н оештыручылар – гамәлгә куючылар булып Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы санала. Күрәсез, оештыручылар үзгәреп торса да, Язучылар берлеге алар арасында гел саклανып киленде. Моны журналның традицияләргә тугрылык билгесе, Язучылар берлегенең бердәмлеген саклауда өлеше дип санарга кирәк. Бу очракта шуны да әйтеп узу урынлы булыр: гамәлгә куючыларның берсе саналу – бер нәрсә, ә чын гамәли эш – икенче нәрсә. Язучылар берлеге «Казан утлары» эшчәнлегенә сизелерлек ярдәм дә итә алыр иде. Әйтик, журнал таратуны активрак оештыруда гына булса да... (Милли матбугатны, бу очракта төп әдәби журналны укучыларга җиткерү зур проблема хәзер. Халык дәррәү китап-журнал укыган заманда да Язучылар союзы җитәкчелеге бу мәсьәләне гел күз уңында тота иде. Язучылар коллективына, бигрәк тә идарә әгъзаларына махсус бурычлар йөкләнә, соңыннан аларның хисап-отчетлары тыңлана, тикшерелә иде. Хәзер бу гамәлләр онытылып бара... Ә бит, төптән уйласаң, хезмәте булган язучыларга һәм мораль, һәм матди, бүтәнчә әйтсәк, социаль яклау ягыннан хәйран гына булышып килә журнал. Гомумән, «Казан утлары»ннан башка татар әдәбиятын күз алдына китерү кыен.)

Бер ел элек республикада «Татмедиа» дип аталган массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оешты. Без әлегә шул агентлык канаты астында. Туктаусыз реформалар заманында алга таба журналны гамәлгә куючылар кемнәр булыр, нинди үзгәрешләр кичерелер, кистереп әйтү кыен.

Шулай да оптимист буласы килә: соңгы унбиш ел эчендә Татарстан хөкүмәте ярдәме белән журналыбызның өч юбилеен – 70, 75, 80 еллыкларын зур итеп үткәрә алдык, җитәкчелекнең әдәби җәмәгатьчелек белән берлеген тойдык. Вакыйгага әверелгән бу күңелле фактлар безгә алга таба да яшәячәгебезгә ышаныч тудыра.

* * *

Нинди генә икътисади кыенлыклар булмасын, 90 нчы еллар – Татарстан, гомумән татар тарихында кабатланмас бөек еллар! Халыкның үзаңы уянган еллар, Татарстан дөньяга ныклап танылa башлаган еллар! Суверенитет турында Декларация кабул итү, Татарстанның Президентын сайлау, Референдум уздыру, чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә Татарстанның вәкиллекләрен булдыру... Җиңүгә тиң бу казанышларда безнең каләмдәшләребезнең дә өлеше бар дип саныйм мин. Матбугатта чыгыш ясапмы, җыелыш-митингларда катнашыпмы, ачлык акцияләре оештырыпмы, депутат мөнбәреннән сөйләпме, бик күпләр ихластан Татарстанның киләчәге, аның бәйсезлеге өчен җан атып йөрделәр. Депутатларыбыз да күп эшләде ул елларда. Мандатлы вәкаләте булгач, табигый, эшләргә тиеш иделәр дә. Элегрәк язучылардан бер кеше, гадәттә, идарә рәисе югары органнарга (СССР, РСФСР, ТАССР Югары Советларына) сайлана иде. 90 нчы елда депутат булып алты кеше үтә алды (Р.Мөхәммәдиев – РСФСР Югары Советына, Ф.Бәйрәмова, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Р.Харис – Татарстан Югары Советына). Шул еллардан башлап бүгенгә кадәр язучылардан дүрт-биш кеше депутат булып Татарстан парламентына сайланып килә. Әгәр парламентта язучыларның көчле төркеме булмаса, милли мәнфәгатьләрне кайгырткан кайбер законнар, карарлар, мөрәҗәгатьләр, мөгаен, дөньяга чыга да алмас иде.

1989 елдан (язмадагы бүленеш буенча 90 нчы еллар башы дип алыйк) унбиш ел эчендә идарә рәисе вазифаларын Р.Мөхәммәдиев (1989–1999) һәм Ф.Галимуллин (1999 елдан) башкарды. (Ә 2005 елдан Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып шагыйрь Илфак Ибраһимов эшли – *Р.Ф.*). Идарәнең, гомумән Язучылар оешмасының эшчәнлеге күпмедер дәрәҗәдә рәиснең шәхесенә, аның әдәбияттагы абруена, оештыру сәләтенә, фидакарьлегенә бәйле. Р.Мөхәммәдиев Союз рәисе булуы дәверендә Россия Югары Советына сайланды һәм анда даими эшли торган комиссия җитәкчесе булды. Мәскәүдә йортлы-җирле булып дигәндәй, төп вакытын башкалада үткәрде. 1990–1993 елларда кайтып-килеп җитәкчелек итте. Оешмадагы төп оештыру эшләрен аның урынбасарлары З.Мансуров, М.Шиһапов алып барды (берара урынбасар вазифаларын Г.Гыйльманов, М.Маликова, Ә.Гадел, Р.Аймәт, Д.Салихов башкарды).

Иҗади һәм оештыру эшләре ничек кенә бәяләнмәсен, оешманың 90 нчы еллар башындагы эшчәнлегенең бер характерлы моментын искәртеп үтәргә кирәк: ул – Татарстан Язучылар оешмасының мөстәкыйльлеген тәэмин итеп, аны Халыкара язучылар бердәмлегенә кертү. Шул максатны күздә тотып, 1991 елның 15 мартында язучыларның съезд дип аталган бер җыены булды. Ул, асылда, ел йомгакларына багышланган җыелыш иде. СССР Язучылар союзының алда әйтелгән IX – соңгы съездына вәкилләр сайлау өчен, Устав кушканча, бу җыелышның съезд дип аталуы кирәк иде. Шуңа да бу җыелыш-съезд, чираттан тыш саналып, фәләненче санлы съезд булып исәпләнмәде дә. Шулай да бу җыелышта әле хәзер дә гамәлдә булган Татарстан Язучылар берлегенең Уставы кабул ителде. Шул ук елның октябрендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлеге арасында хезмәттәшлек килешүе» төзелде. Килешүнең беренче җөмләсендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге тигез хокуклылык шартларында һәрьяклап хезмәттәшлек итәргә килешенделәр» диелә. Тарих өчен кызык, гыйбрәтле документ. (Соңгы вакытта бәгъзе иптәшләрнең Татарстан оешмасын янә Россия Язучылар оешмасына буйсынулы итәргә омтылышлары булды. Безнеңчә, ашыгырга ярамый. Россия язучылары әлегә үзләре берничә үзәккә бүленеп беткән. Икенчедән, иске үзәккә кайтуның безнең өчен әлегә бернинди файдасы күренми. Чөнки Мәскәүдәге нәшриятлар һәм басма органнар Язучылар союзына карамый, элеккечә үзәктә китаплар чыгару мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Киресенчә, кайбер Мәскәү журналлары үзләре ярдәм сорап Татарстанга мөрәҗәгать итәләр... Иҗат эше сәнәгать тармагы түгел (анда чыннан да интеграциясез булмый!), безнең эш иреклеккә, демократик тигезлеккә корылган. Гомумән, чын дуслык, хезмәттәшлек тигезләр арасында гына була ала. Бу – аксиома).

Язучылар берлеге тарихына кагылышлы бу хезмәттә Союзның төрле еллардагы составы, сан-исәбе турында берничә сүз әйтмәсәм, язмам тулы булмастыр. Сүз Язучылар союзы әгъзасы саналган каләмдәшләр турында бара. Күптән түгел бер каләмдәшебезнең газетада чыккан мәкаләсендә мондый юлларына тап булдым: «Хәзерге көндә Язучылар берлегенә каләм тибрәтүчене алу кемне дә булса комсомолга алуны хәтерләтә. Таләпләр түбән дәрәҗәдә, шул сәбәпле Союз әгъзасы булып ни язганнары беркемгә дә мәгълүм булмаган каләм тибрәтүчеләр йөри, аларның күбесе хәзерге иҗтимагый тормыштан гына түгел, хәтта әдәбияттан да (әдәбият үзе иҗтимагый тормышның бер өлеше инде ул. – *Р. Ф.*) бик ерак тора». Бу юллар гаҗәпләнү яки берәр этәргеч реакция тудырды димим, шулай да көлемсерәү тойгысы уятты. Соңгы биш елда Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Кабул итү коллегиясе рәисе буларак, әлбәттә, мондый карашка үз фикерем, үз җавабым бар. Бу хакта бераз соңрак.

Алда әйтелгәнчә, әдәбиятны бернинди оешмалар тудырмый, әдәбиятның сыйфатын оешмадагы әгъзаларның саны билгеләми. Әдәбиятны талантлы аерым шәхесләр тудыра. XIX гасырда русларда махсус дәүләти әдәби оешмалар булмаса да, бөек әдәбият бар. XX гасыр башында Тукай, Исхакый, Ибраһимовлар мисалында бөек татар әдәбияты бар. Шагыйрь әйтмешли, әдәбиятның зурлыгын билгеләр өчен «бер Толстой җитә, бер Тукай»! Үткән гасыр башында, ягъни йөз ел элек, татар мохитендә язучы-мөхәррирләр, бердәм иҗади оешмада әгъза булып тормасалар да, бүгенгедән ким булмаган дип уйлыйм.

1934 елда, Татарстан Язучылар союзы оешканда, 30 лап язучы оешма әгъзасы саналган. Сугыштан соңгы елларда СССР Язучылар союзы таныклыгын йөрткән кешеләр 50 ләп исәпләнгән. Алда әйтелгәнчә, 1968 елда бу сан 111 гә җитә. 1990 елларда Союзга алу артыгы

белән активлаша. 10 ел эчендә (1989–1999) 126(!) кеше әгъза итеп кабул ителә (XI–XII съезд арасында 72 кеше, XII–XIII съезд арасында 54 кеше). «Кояш» сүзен язганда 5 хата җибәрүче кешеләр Союзга керә» дигән төртмәле сүзләр шул елларда чыкты шикелле. Шулай итеп, XXI гасыр башына гомумсан 280 гә җитә. Хәзерге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 302 әгъза. Уртача яшьләре – 59,7 яшь. Искә төшереп чагыштырыйк: СССР Язучыларының I съездында катнашкан делегатларның уртача яше 38,5 булган. Без пенсионерлар оешмасы булып чыгабыз түгелме соң?

«Кадрлар һәммәсен дә хәл итә» дигән бер искерми торган гыйбарә бар. Бу гыйбарә безнең эшкә дә кагыла. Язучылар берлегенә алганда төп роль Кабул итү коллегиясенә (комиссиясенә) йөкләнгән. Коллегия карарын идарә, гадәттә, хуплап раслый. Кире кагылган фактлар, гайре табигый хәл саналып, бик сирәк була. 90 нчы елларга кадәр соңгы мөһерне Мәскәү – СССР Язучылар союзы секретариаты суга иде. Соңгы 10–15 ел эчендә бу мәсьәлә үзебездә – Татарстан Язучылар берлегендә хәл ителә. Кабул ителгән каләм иясенә «Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы» дигән таныклык тапшырыла. Бар иде заманнар: теге яки бу халыкның, республиканың әдәби потенциалын, дөресрәге, оешма потенциалын саннар да билгели иде. Әле хәтердә: 60–70 нче елларда өлкән язучы агайлар: «Кара, үзбәкләр язучылар санын 300 гә җиткергәннәр, украиннар – 400 гә... Безгә дә арту кирәк», – диләр иде. Чыннан да, сан арттыруда мәгънә дә бар иде: язучылар исәбенә карап җирле Союзларга Үзәктән акча җибәрелә, торак төзелешләренә өстәмә чыганаклар бүлеп бирелә, санаторийлар, иҗат йортларына юлламалар күбрәк килә... Хәзер вазгыять бөтенләй бүтән: җирле бюджет хозурына һәм үз тырышлыгыңа карап үз көнеңне үзең күрәсең.

Ә инде «беркемгә дә мәгълүм булмаган (укып барырга да кирәк! Язучыларның күбесе бер-берсенең иҗатын игътибар белән күзәтеп бара дип әйтә алмыйм) каләм тибрәтүчеләр»не Берлеккә алу мәсьәләсенә килсәк, җавап мондый: Кабул итү коллегиясе әзме-күпме әдәби сәләте булганнар арасыннан, булган хәзинәдән иң яхшыларын сайлап алырга тырыша һәм шулай эшли дә. «Балкып торган 20–25 яшьлек фәлән иптәшне нигә һаман Берлеккә алмыйсыз?» дип беркем дә әйтә алмас. Бүгенге коллегиядә түбәндәге иптәшләр эшли: Р.Фәйзуллин (рәис), Ә.Баян, М.Хәбибуллин, В.Корчагин, Н.Хисамов, М.Галиев, Г.Зәйнашева, Г.Морат, Р.Зәйдулла, Ш.Мостафин. Орлыктан кибәкне генә аера белә торган иптәшләр дип беләм мин бу язучыларны. Элек тә Кабул итү комиссиясендә зур абруйлы язучылар эшләде: Г.Бәширов, С.Хәким, А.Гыйләҗев, Ш.Галиев... Шуны аңларга кирәк: вазгыять элекке белән чагыштырганда нык үзгәрде, язучының җәмгыятьтәге роле тонықланды... Чит төбәкләрдән түгел, үз республикабызда да яшьләр әдәбиятка ургылып килми. Сер түгел, бүтән өлкәләрдә яшәүче авторларга игътибарны күбрәк бирергә тырышабыз, аларга кайчак ташламалар да ясарга туры килә... Шунысы да бар: артык чикләүләр куеп, иҗади оешманы алып булмаслык крепость-кирмән дә ясарга кирәкмидер. Фикеремне ачык әйтеп бетерим: әйе, бездә 300 язучы юк, бездә оешмада саналган 300 ләп әгъза бар. Таныклык йөртү син әле коеп куйган язучы дигән сүз түгел. Әнә З.Хәкимгә язучылар таныклыгы йөртмәү драматурглар ярышында җиңүче булырга комачауламады бит әле! Язучылар оешмасы – демократик характердагы иректе иҗтимагый оешма. Бу оешмага керергә теләүчеләр бихисап булса да, аннан гариза биреп чыгарга теләк белдергән кешеләр дә бар. Хәтта идарә составыннан да...

Язучылар оешмасына кабул итүдә соңгы ун-унбиш ел эчендәге тагын бер тенденцияне ассызыклап узу мөһим: ул – Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләрне Казанга сыендыру, ягъни әгъза итеп алу. Андый хәл элегрәк тә бар иде, әмма хәзерге шикелле максатчан түгел иде. Бүгенге көндә бүтән төбәкләрдә яшәп тә, бездә хисапта торган язучылар ике дистәгә якын. Кайберләрен санап үтик: Х.Мөдәррисова, Р.Идиатуллин, Р.Чурагулов (Башкортстан), Р.Мир-Хәйдәров, Н.Кәримова, В.Юныс (2006 елда вафат булды – *Р.Ф.*), Г.Хантимерова, З.Фәтхетдинов, Ә.Саттар (Мәскәү), Иделбикә (Л.Садыйкова), Р.Хисмәтов (Ульяновск), И.Сабиров (Чиләбе), Һ.Аширов (Пермь), Д.Османов (Кырым), Р.Сүлти (Төркия), Р.Бохараев (Англия)... Табигый, әгәр Казан бөтен татарлар өчен уртак башкала саналса, Татарстан Язучылар оешмасы да бөтен татар язучылары өчен тартылу үзәге булып тора.

* * *

Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды 1994 елның 3 июнендә Казанның Актерлар йортында узды. Аны кыскача кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Г.Бәширов ачты. Идарә рәисе Р.Мөхәммәдиев Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 1989–1994 еллардагы эшчәнлеге турында доклад ясады.

Язучылар корылтаенда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев чыгыш ясады. Иң элек ул Татарстандагы бүгенге сәяси һәм икътисади хәлләр турында сөйләде. Аннары Президент Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамәгә һәм Б.Н.Ельцинның Татарстанга визиты йомгакларына кагылышлы фикерләре белән уртаклашты, татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру, татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре санын арттыру, газета-журналлар нәшер итү, китап бастыру, язучыларның матди хәлләрен җиңеләйтү турында сөйләде. Аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру мәсьәләләренә дә киң тукталды.

Аннары ревизия комиссиясе отчеты (Р.Даутов), төрле жанрлар буенча докладлар: поэзия (Г.Морат), драматургия (Р.Мингалим), балалар әдәбияты (Р.Миңнуллин), әдәби тәнкыйть (Ф.Зөлкарнәй), тәрҗемә (К.Миңлебаев), рус әдәбияты (В.Корчагин) тыңланды. Проза (Ә.Гаффар) һәм публицистика (М.Зарипов) буенча докладлар, тыңлаучылар таләбе буенча, тулысынча яңгырамады. Фикер алышуларда Р.Фәйзуллин, С.Михалков (Мәскәү), Ә.Баян, Ә.Еники, Ф.Баттал, Г.Ахунов, С.Баттал, Т.Галиуллин, Р.Хисмәтуллин, М.Нәзиров (Уфа), Р.Вәлиуллин, З.Зәйнуллин, М.Маликова, Т.Пулатов (Мәскәү), Х.Әшрәфҗанов катнашты.

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең төзелешен үзгәртеп кору хакындагы декларация кабул ителгәч, ачык тавыш бирү юлы белән яңа идарә әгъзалары сайлау булды. Алар: Р.Мөхәммәдиев (рәис), Г.Ахунов, Р.Батулла, М.Вәлиев, Ә.Баян, Ф.Бәйрәмова, Р.Вәлиуллин, Ә.Гадел, Ш.Галиев, Ф.Галимуллин, Т.Галиуллин, А.Гыйләҗев, В.Имамов, В.Корчагин, Р.Кәрами, М.Маликова, З.Мансуров (рәис урынбасары), Р.Мингалим, Р.Миңнуллин, Р.Низамиев, Д.Салихов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, З.Хөснияр, М.Шиһапов (рәис урынбасары), И.Юзеев, А.Әхмәдуллин, Х.Әюпов.

90 нчы еллар башына туры килгән XI һәм XII съездлар арасы, ягъни 1989–1994 еллар, Татарстан, гомумән татар халкы тарихында онытылмас еллар! Авыр, киеренке, әмма халык рухының күтәренке еллары. Суверенлык, мөстәкыйльлек турында хыялланып һәм ышанып авыз тутырып сөйләнгән еллар. Урамнарда халык ташкыны. Митинглар, Югары Советта кайнар бәхәсләр. Ниһаять, Татарстан Суверенлыгы турында Декларация! Президент сайлаулары, Референдум үткәрүләр... Бөтендөнья татарларының I конгрессы. Болгар җирендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган тантаналар. Татар энциклопедиясе әзерләнә башлау... Татарстан белән Россия арасында төзелгән тарихи Шартнамә...

Бу елларның рухи елъязмасында, кабатлап әйтәм, язучыларның өлеше зур. Татар халкы өчен хәлиткеч көннәрдә язучыларыбыз көрәш мәйданының уртасында булдылар. Кирәк чакта меңләгән халык алдында яндырып сөйләделәр, мәйданнарга чыгып ачлыкта утырдылар, шигарь булырлык кайнар шигырьләр яздылар, күпләргә фидакарьлек үрнәге күрсәттеләр.

XX гасыр ахырында чираттагы янә бер съезд булып узды. Анысы санау тәртибе буенча – XIII. Әнә шул XII белән XIII арасындагы (1994–1999 еллар) кайбер мәдәни-әдәби вакыйгаларны, фактларны искә төшерик. Г.Камал театрында Татарстан Язучылар оешмасы төзелүгә 60 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды (1994, ноябрь), Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Анда язучыларның зур төркеме катнашты (1995, июнь), атналык «Мәдәни җомга» газетасы чыга башлады (1995, июль). Баш мөхәррире – З.Мансуров. Г.Ахуновның – 70, Т.Миңнуллинның – 60 (1995), Г.Тукайның – 110 (1996), Мөхәммәдьярның – 500, Г.Кандалыйның – 200 (1997), Г.Исхакыйның – 120 (1998), Ә.Еникинең 90 (1999) еллык юбилейлары киң билгеләнеп үтелде. Шулай ук Бөтендөнья татарларының II конгрессы көннәрендә «Казан утлары» журналының 75 еллыгы бәйрәм төсендә үтте... Тарих булып калган хрониканы дәвам итәргә дә була...

*** * ***

Татарстан язучыларының чираттагы XIII съезды Казанның Актерлар йортында 1999 елның 28 маенда башланды. Корылтайны татар әдәбияты аксакалы – 90 яшьлек әдип Ә.Еники ачты. Ике корылтай арасында идарә тарафыннан башкарылган эшләр турында хисап докладын Язучылар берлеге рәисе Р.Мөхәммәдиев ясады.

Корылтай эшендә катнашкан Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев, җыенны котлап, җәмгыятебезне үзгәртеп коруга, әдәбиятыбызны баетуга керткән өлешләре өчен язучыларга рәхмәт белдерде һәм әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Корылтайда катнашучылар әдәбиятыбызның бүгенге прозасы, очерк һәм публицистикасы, шигърияте, драматургиясе, балалар әдәбияты һәм рус әдәбияты турында Ф.Галимуллин, Ф.Бәйрәмова, Ф.Яхин, Ю.Сафиуллин, Г.Гыйльманов, В.Корчагин докладларын тыңладылар. Фикер алышуларда Ә.Баян, Ш.Галиев, Т.Миңнуллин, Г.Ахунов, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, А.Хәлим, Р.Зәйдулла, Р.Батулла, Л.Ихсанова, Л.Шагыйрьҗан, З.Зәйнуллин, К.Булатова, Р.Җамал (Корбанов), М.Маликова, А.Хәсәнов, Ә.Гадел, Д.Салихов һ.б. чыгыш ясады.

Гадәттәге сценарий белән барырга һәм тәмамланырга тиеш булган бу съезд финиш алдыннан көтелмәгән «борылмалар һәм сикәлтәләр» үтәргә дучар булды. Җыен барышында идарә һәм аның җитәкчесе адресына тәнкыйть фикерләре байтак әйтелсә дә, «мунчаның чын пары» яңа җитәкчелек сайлаганда чыкты. Залдагы тамаша – сүз һәм хәрәкәт накалы – трагикомик спектакльләрдәге кайбер күренешләрне хәтерләтте. Съездга нинди нокта (яки – өндәү билгесе) куеласы анык булмаганга күрә, президиум, съездны вакытлыча өзеп, Язучылар берлеге идарәсен соңрак сайларга дигән нәтиҗәгә килде; һәм бу сайлаулар ике айдан соң, 27 июльдә узды. Идарә рәисе итеп бик үк фараз ителмәгән, җәмәгатьчелек арасында язучылыктан бигрәк, беренче чиратта радио дикторы һәм пединститут укытучысы буларак билгеле филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин сайланып куелды. Яңа идарә составына түбәндәге язучылар керде: Х.Әюпов, Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Р.Вәлиев, Р.Вәлиуллин, Ә.Гадел, М.Галиев, Ф.Галимуллин (рәис), Г.Гыйльманов (рәис урынбасары), Җ.Дәрзаманов, В.Имамов, Р.Кәрами, В.Корчагин, Л.Лерон, З.Мансуров, Г.Моратов, Ш.Мостафин (рәис урынбасары), Р.Низамиев, Г.Рәхим, Р.Рахмани, Д.Салихов, Н.Сафина, Р.Фәйзуллин, М.Хәбибуллин, А.Хәлим, С.Шәмси, Ф.Яхин.

Контроль-ревизия комиссиясе рәисе итеп язучы Л.Хәмидуллин, кабул итү комиссиясе коллегиясе рәисе итеп Р.Фәйзуллин сайланды.

Иҗат остаханәләре җитәкчеләре итеп С.Шәмси (проза), З.Мансуров (шигърият), Р.Рахмани, соңыннан Җ.Дәрзаманов (балалар әдәбияты), М.Вәлиев (әдәби тәнкыйть), К.Миңлебаев (әдәби тәрҗемә), В.Корчагин (рус әдәбияты), яшь каләм ияләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе итеп Ф.Әһлия билгеләнде.

Идарәдә Әлмәт Язучылар оешмасына Р.Вәлиуллин, Чаллы Язучылар оешмасына В.Имамов җитәкче итеп сайланды.

«Тамгалы» бу XIII съезд узганга да биш елдан артык вакыт үтте. Анда катнашкан кешеләр өчен гыйбрәт һәм сабак алырлык съезд булды ул. Кайбер чыгышларда әдипләргә килешеп бетмәгән дорфалык, субъективизм чалымнары булгаласа да, каләмдәшләр, күңелендәгеләрен яшермичә, ачыктан-ачык ихлас сөйләделәр, татар әдәбиятының киләчәге өчен борчылып чыгыш ясадылар. Демократиянең, сүз ирегенең безнең җәмгыятьтә дә беркадәр урнаша башлавына дәлил иде инде бу. Дөрес, бериш чыгышларда, «яхшы патша» кирәк дигән шикелле, шәп рәис сайласак, эшләребез гөрләп алга китәр, китапларыбыз тоткарлыксыз чыгып килер, каләм хаклары артыр, матди яклар яхшырыр дигән наив ышаныч мотивлары байтак яңгырады. Табигый хәл. Киләчәккә ышаныч булмаса, ничек язмак кирәк?! Әмма... вазгыять бүтән: дәүләт күзенә карап торган, иҗтимагый оешма саналган иҗат берлекләренең мөмкинлекләре хәзер бик чикле шул... Бу съездда, өстә ярылып ятмаса да, тагын бер хәлне күзәтергә мөмкинлек булды, ул – язучылык хезмәте һәм агымдагы сәяси эшчәнлек. Язучы иҗтимагый тормышта актив катнашырга тиеш (мәҗбүр) булса да, сәясәткә ул башы-аягы белән кереп йотылырга тиеш түгелдер. Язучының хезмәт җимеше – күңел аша үткәрелгән акыл һәм хис квинтэссенциясе. Ә сәясәттә кануннар катгый, анда күңел кичерешләренә, чын хисләргә урын тар... Уен тәртипләре бүтән. Элеккеге Берлек рәисенең эшчәнлеге әнә шундый уйлануларга этәрде. Шулай, съездларның, кайберләре, кара төнгә кадәр утырып, бер көн эчендә йомгаклана йә икешәр айлык тәнәфес ясап тәмамлана да ала икән.

* * *

Соңгы (әлегә) XIV съезд, яңартылган Устав нигезендә, гадәттәгечә биш елдан түгел, өч елдан соң үткәрелде. Ул 2002 елның 31 маенда Казанның К.Тинчурин исемендәге театры бинасында узды.

Корылтайда катнашучыларны Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев котлады. «Язучыларның зур җыелышы – Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга», – диде ул үзенең чыгышында.

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турындагы хисап доклады белән идарә рәисе Ф.Галимуллин чыкты. Ревизия комиссиясе хисабын Л.Хәмидуллин ясады. Әдәби жанрлар буенча Р.Әхтәмова (шигърият), Ф.Сафин (проза һәм публицистика), Р.Корбан (балалар әдәбияты), Д.Гыймранова (драматургия), М.Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Флера Сафиуллина (әдәби тел мәсьәләләре), Л.Газизова (рус язучылары иҗаты) өстәмә докладлар ясадылар.

Докладлар буенча фикер алышуда Г.Зәйнашева, Г.Рәхим, В.Имамов, Р.Вәлиуллин, З.Мансуров, М.Маликова, Р.Батулла, Ф.Бәйрәмова, Җ.Дәрзаман, Л.Шагыйрьҗан, З.Зәйнуллин, А.Хәлим, В.Лавришко, И.Хөснетдинов һ.б. чыгыш ясады.

Корылтайда альтернатив нигездә күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп янә Ф.Галимуллин сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар керде: Х.Әюпов, Ф.Бәйрәмова, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Р.Вәлиев, Р.Вәлиуллин, Л.Газизова, Ф.Галимуллин (рәис), Г.Гыйльманов (рәис урынбасары), Җ.Дәрзаман, В.Имамов, Р.Кәрами, З.Мансуров, Х.Миңнегулов, Г.Морат, Ш.Мостафин (рәис урынбасары), Р.Низами, Г.Рәхим, Д.Салихов, Р.Фәйзуллин, М.Хәбибуллин, З.Хөснияр, С.Шәмси.

Язучылар корылтаенда Ф.Зыятдинов җитәкчелегендә ревизия комиссиясе сайланды.

Вакыт котылгысыз алга ыргыла, еллар бер-берсен алыштырып кына тора. («Гомерләрне талкып еллар үтә!») XIV съездтан соң да ике ел ярымга якын вакыт үткән. Бу вакыт аралыгындагы әдәби хәлләр турында сөйләүгә әлегә хаҗәт юктыр. Алар күз алдында, хәтер офыгына күчәргә өлгермәгәннәр әле. Устав буенча, киләсе елның җәй башларында яңа съезд җыйналыр, Язучылар оешмасының эшчәнлеге турында тәфсилле сүз булыр.

*** * ***

Шулай итеп, чакрым баганаларын санагандай, без, чорлардан чорларга, съездлардан съездларга «тотынып барып» дигәндәй, язмабызның ахырына җиттек. Гадәттә, мондый очракта нәтиҗәләр сорала. Юк, катгый нәтиҗәләр ук ясарга җөрьәт итмим. Үземә андый бурычны куймадым да. Күзәтүче сыйфатында билгеле бер чордагы әдәбиятыбыз дөньясындагы хәлләрне үземчә барлап кына чыктым (укырга җиңелрәк булсын дип, язмамда кулланылган әдәбият һәм архив материалларының төрле чыганакларның исемлеге күрсәтелмәде). Шулай да, билгеле бер үргә менеп, еракtagы офык-манзараларны күзәткәндә, аерым бер урыннарга озаграк карап торасың, алар – биеклекме, агачлар куелыгымы яки шәрә тау итәгеме – карашыңны күбрәк җәлеп итә, уйландыра. Әлбәттә, еллар теземнәре аша артта калган әдәбият киңлекләрен күзәткәндә, минем дә теге яки бу вакыйга яки әсәр нисбәтеннән тукталып, уйланып калган чакларым булмады түгел. Алай гына да түгел, ул уйларның беришләре фикер төеннәре булып күңелдә утырып та калдылар. Кайберләрен укучылар белән бүлешсәм дә ярыйдыр.

Иң әүвәл шуны ачык итеп әйтергә кирәк: әдәбиятыбыз, шөкер, бай әдәбият. Гомумкешелек мәдәнияте мирасына керерлек әсәрләр бар. Теләк җимеше итеп әйтелгән сүз түгел, бу – хакыйкать. Әмма... бу хакыйкатьне беләләрме? Бүтәнчәрәк әйтсәк, дөньяда моны белүчеләр күпме? Кызганыч, күп түгел, һәрхәлдә, без теләгән дәрәҗәдә түгел. Өстәвенә белүчеләрдән танучылар һәрчак ким чыга бит әле!.. Минемчә, татар әдәбияты тарихын объектив өйрәнү һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Борынгысын әйткән дә юк (аны бармак белән генә санарлык кешеләр яхшы белә булыр), соңгырак чор әдәби мирасны да юньләп белмибез, һәм шуңа күрә дә әдәбият белемендә моңа кадәр булган критерийлар күп сораулар тудыра да. Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов (ул безнең Язучылар оешмасы әгъзасы да) моннан ун еллар элек үк тикмәгә генә мондый сүзләр язып чыкмады: «Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменең, гомумән татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Аның төп принцибы фәлсәфи категорияләрне

турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятның, сәнгатьнең, кеше рухи эшчәнлегенең мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш». Чыннан да, әдәбият тарихы буенча үткән гасыр ахырларына кадәр чыккан хезмәтләрнең абсолют күпчелеге сыйнфый караштан чыгып, сәяси күрсәтмәләр тәэсирендә теге яки бу идеологик схемаларга туры китереп язылганнар. Хәзер аларны уку кыен, чөнки алар тарихи аңны рәнҗетә, эстетик тоемны боза, чын әдәбияттан биздерә... Ә бит бер гасырга якын диярлек, методологик кулланмалар булып, алар берничә буынның әдәбиятка караш-мөнәсәбәтен формалаштырган... Хәзер, бәлки, хәлләр бик нык үзгәргәндер? Кызганыч, алай ук түгел шул, әзер шаблон схемалар белән эш итүне дәлилләгән күп мисаллар китерергә булыр иде. Язмамның тәмен җибәрәсем килми... Шулай да «Татар энциклопедиясе сүзлеге»ннән берничә цитата китерергә җөрьәт итәм. Коръәннән (энциклопедияне Коръән белән чагыштыру бик үк урынлы булмаса да, җитдиләрнең дә җитдие булган академик басма ул) ялгыш эзләп азаплануым түгел, мисалның да бик өстә ятканын, күзгә ташланганын гына китерәм, анда да сүз конкрет бер мәкалә турында гына булыр. Сүзлекнең 622 нче битен ачып, «Татарстан Республикасы» дигән мәкаләдән әдәбиятка багышланган кайбер юлларны укыйк: «60 нчы еллардан үткәннәргә яңача карарга, бүгенгене тасвирларга мөмкинлек туа (андый мөмкинлек элек тә булган, күрәсең, тулырак яки объективрак тасвирларга мөмкинлек туа дип әйтергә теләгәннәрдер инде. – *Р.Ф.*). Татар әдәбиятының бу этабында Р.Төхфәтуллин, Ә.Давыдов, А.Гыйләҗев, Ш.Мөдәррис, Г.Ахунов, Н.Фәттах, Х.Камал, Ә.Баян, Г.Афзал, Э.Касыймов, Ш.Бикчурин, М.Шабаев, Ш.Галиев, И.Юзеев, Ш.Хөсәенов, Б.Камалов кебек «алтмышынчы елгылар» үзләре яшәгән заманның мөһим иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрен күтәреп чыгалар». Бу саналган исемнәрнең берсен дә диярлек «алтмышынчы елгылар» дип санап булмый. Гадәттә, «фәләненче елгылар» дип әдәбиятка килү чоры белән бәйләнештә әйтәләр. Бу язучыларның беришләре әдәбиятка сугыш чорында аяк баскан, күбесе – 50 нче елларда күтәрелеп чыккан шәхесләр (Г.Ахунов, Г.Афзал, Ш.Галиев, Х.Камал, Р.Төхфәтуллин, Ш.Хөсәенов һ.б.). Чынында 60 нчы еллар буыны дип безнең буын (Р.Мингалим, Р.Харис, Рәшит Әхмәтҗанов, Г.Рәхим, Р.Гатауллин һ.б.) санала ала. Энциклопедиягә мәкалә язган авторларның яки авторның исенә төшерик: сез «60 нчы елгылар» дип санаган кайбер шагыйрьләр алтмышынчы елларда инде дөньяви тормышларын һәм иҗатларын тәмамлап мәңгелеккә китеп тә бардылар (Ш.Мөдәррис – 1964 елда, Ә.Давыдов 1968 елда вафат). Шунысы да игътибар иттерә: «Татар энциклопедия сүзлеге»нең русчасында (1999) бу абзацта 9 язучы саналса, шул ук Сүзлекнең (2002) татарча вариантында инде 16 исем. Аерма шактый! Бер үк материал, нинди телдә бәян ителсә дә, тәңгәл булырга тиештер. Хәер, бу ишәю, шул ук белешмә-мәкаләдә әйтелгәнчә, шуннан килеп чыгадыр: «әдәбият белеме исә берьяклы идеологик ысуллардан арына бара, әдәби күренешләргә һәм тенденцияләргә фәнни һәм объектив бәя бирергә омтыла». Гомумән, яхшы омтылыш... Дәвам итик. Шул ук мәкаләдә «...1970–1980 елларда И.Нуруллин, М.Мәһдиев, Т.Миңнуллин, Ф.Яруллин, М.Юныс, М.Хәбибуллин, Ә.Галиев, С.Сөләйманова, М.Хәсәнов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов, В.Нуруллин, Р.Батулла, М.Галиев, Ә.Гаффар, З.Хәким, Ә.Рәшитов, Л.Шагыйрьҗан, Х.Әюп, М.Маликова, Р.Гатауллин һ.б. (русча Сүзлектә исемнәрнең бу блогында 13 язучы санала, татарчасында – 25) иҗади активлык күрсәтәләр». Нигездә, дөрес. Ә төгәлсезлекләр? Әйтик, З.Хәким әдәбиятта 90 нчы еллар башында күренә башлады, Роберт Әхмәтҗанов һәм башкалар инде билгеле шагыйрьләр булып йөргәндә, З.Хәким әле тумаган да иде бугай... Саный белеп санауның да үз тәртибе бар бит. Әйе, саналганнар активлык күрсәткәннәр. А.Хәлим, Ф.Садриев, Р.Мингалим, Г.Рәхим һәм тагын кайберәүләр иҗади активлык күрсәтмәделәрме? 90 нчы еллар әдәбияты турында сүз барганда, ни өчендер тарихи темаларга язучы 3 каләмдәш кенә телгә алына (анда нигәдер Ф.Латыйфи төшеп калган). 90 нчы елларда 3 кенә кеше актив иҗат иткән булып чыга түгелме?.. Ул елларда бүтән язучылар да күп хезмәт куйдылар бит: З.Мансуров, Ф.Бәйрәмова, Р.Миңнуллин, Ф.Сафин (Ф.Әмәк), Р.Зәйдулла, Г.Морат... Һәммәсен кертеп бетереп булмый, диярләр. Алай дисәң, шул ук бик чикләнгән урында кайбер исемнәр икешәр мәртәбә кабатлана. Әйтсәң – сүз, төртсәң – күз дигәндәй, җитеп торыр. Язучыларны шәкли рәвештә «вакыт ояларына төгәл утырта» да алмагач, аларның иҗатларына иҗтимагый бәя биргәндә,

конкрет әсәрләренә фәнни-эстетик анализ ясаганда нинди «чытырманлы карурманнар» барлыгын чамаларга була. Бу фикерне очлап шуны әйтәсе килә: язучы исеме галим-голәмага, кайбер очракта мөтәгалимгә, уңайлы ясалма кысалар өчен иллюстратив рәвештә генә файдаланылмаска тиеш. Үткән тарихыбызны, бүгенгене үзебез өчен дә дөрес һәм ачык итеп аңлый алмасак, аны бүтәннәргә ничек аңлатмак кирәк?!

Без съездлар, юбилейлар, лауреатлыклар турында сөйлибезме, оешманың көндәлек эше турында сүз алып барабызмы – барыбер уйлануларыбызның төп мәгънәсе язучы хезмәтенең асылына – аның әсәрләренә барып тоташа. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Җитәкчеме син, урын биләмәгән каләм иясеме, язучы саналасың икән, байрак булып иң алдан әсәрең барырга тиеш. Укучы өчен, язучының шәхесеннән бигрәк, аның әсәре кадерле (бала чакта китапханәдән китапның, авторыннан бигрәк, исемен сорап ала идек; күрәсең, яшь чакның логикасы хакыйкатькә күбрәк якын булган). Миңа калса, хәзер, бигрәк тә соңгы 10-15 елда, хәл бүтәнрәк: игътибарыбыз күбрәк беренчелгә караганда икенчел факторлар тирәсенәрәк юнәлгән. Гадәттә, без фәлән әсәрнең язылуына (чыннан да, «Туган тел»нең яки «Моабит дәфтәре»нең вакыт-вакыт кайчан язылуларын җәмәгатьчелеккә белдереп торсак, тарихи хәтер өчен зыян булмас, һәрхәлдә, ниндидер графоманның фәлән елда туганлыгын белгертүгә караганда файдалырак булыр иде), фәлән китапның чыгуына фәлән ел димибез, фәлән язучы яки шагыйрьгә фәлән яшь, дибез. Без теге яки бу язучының яңа әсәрен укып-тикшерү утырышында яки китап укучылар конференциясендә булдык дию урынына күбрәк, фәлән язучының юбилеенда яки банкетында булдык, дибез. Юбилей димәктән, аларның иге-чиге юк. Хәер, уртача яше 60 тирәсе булган оешмада юбилярлар күп була инде ул – ел саен йөзәрләп җыеладыр. Шуңа өстәп, әдәби мирастан классик әдипләрнең истәлекле даталары (боларын, чыннан да, әдәбият файдасына дип әйтик)... Ә юбилейлардагы пафосның ниндилеген барыбыз да яхшы беләбез. Бу ыгы-зыгылы чаралар язучылар коллективының, бигрәк тә оешма аппаратының күпме җегәр-энергиясен ала! Әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт килеп чыга. Ә әсәрләребез турында кайда сөйлибез соң? Газета-журнал битләрендә. Табигый, беренче чиратта «Казан утлары»нда (китап күзәтүләр, рецензияләр, дискуссияләр һ.б.). Әмма бу гына аз. Әгәр көндәлек матбугатта чыккан материалларны анализласаң, аларның күбесе әлеге дә баягы юбилейлар, премияләргә тәкъдим ителү уңаеннан булыр. Әлбәттә, алар инде мактау, зурлау рухында... Иҗат секцияләрендә (хәзер аларны остаханә дип йөртәләр) дә яңа әсәрләрне укып-тикшереп анализ ясауга корылган җыелышлар сирәк үтә. Бу остаханәләрнең соңгы еллардагы төп эше теге яки бу авторны Язучылар берлегенә тәкъдим итү булды дип әйтергә ярыйдыр. Дөрес, хәзер хәл беркадәр үзгәрде: каләмдәшләрнең иҗатларына караш җитдиләнә төште, шул сәбәплеме җыелышлары да сирәгәйде бугай... Язучылар үзләре (бигрәк тә рәис үзе) өзлексез йөреп торалар. Җыелышлар, конференцияләр, сабантуйлар, юбилейлар, сайлаулар яки бүтән сәяси вакыйгалар уңаеннан агитбригада рәвешендәге «десант»лар... Чыннан да, хәрәкәт шактый көчле... Теләк шул: бу хәрәкәт, әйткәнебезчә, әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт кенә түгел, конкрет әдәби әсәрләр нисбәтендә укучыларга, шулай ук язучыларның үзләренә дә кирәк һәм файдалы хәрәкәт булсын.

Әйе, татар әдәбияты зур (аны белү өчен Мәскәүгә яки Орелга бару хаҗәт түгел), әмма аны дөнья без теләгәнчә танымый әле, дидек. Сүз, мантыйк буенча, үзеннән-үзе әдәби бәйләнешләргә, мирасыбызны пропагандалау мәсьәләләренә кайтып төшә. Алда әйтелгәнчә, үткән гасырның икенче яртысында ул багланышлар шактый нык иде. Соңгы дистә еллар эчендә, һәммәбезгә мәгълүм сәбәпләр аркасында (СССР таркалу, глобализм факторы һ.б.), әдәбиятлар, бигрәк тә гадәт буенча әйтелә торган милли әдәбиятлар (дөреслектә һәр әдәбият милли), беркадәр изоляциядә, үз кабыгындагы йомылуда калды. Билгеле бер вакыт аралыгы өчен бу хәл дә ярыйдыр. Бай тарихлы, бай мираслы әдәбият берара үзенең асылын ныграк өйрәнә, үзләштерә ала, үзенең эчке потенциалы хисабына яши ала. (Бу вазгыятьтә тарихи, тамыры булмаган «яшь» әдәбиятлар, гадәттә, «киселеп» кала.) Укучылары беркадәр кими төшсә дә, татар әдәбияты әдәбият буларак бу елларда әллә ни оттырмады дип уйлыйм. Кызыксынган кеше онытылган яки әле моңарчы күпләргә бөтенләй мәгълүм булмаган мирас белән таныша алды. Дөрес, бу заманда үзеңнең «эч мае»ң хисабына гына озак яшәп булмый. Гомумкешелек цивилизациясенә кушылып, бердәм хәрәкәттә катнашып кына, заманча әсәрләр язып, эстетик кыйммәтләр тудырып була. Димәк, бүтән халык әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнеш зарурият булып чыга. Тик шунысы бар: бер кергән агымсуга икенче кат

кереп булмаган кебек, әдәби багланышларда совет заманындагы ысуллар бик үк ярап бетмәс шул хәзер. Күпмилләтле совет әдәбиятына лаеклы өлеш кертәбез дигән заманнар үтте. Күпмилләтле Россия әдәбияты дигән сүзләр бик ишетелми. Безнең өчен багланышларның иң ышанычлы һәм дәлилле күрсәткече булган тәрҗемә эшенә дә бүген беркадәр бүтән яссылыкта карарга мәҗбүрбез. Элек тәрҗемәләр ике яклы иде: русчадан – татарчага, татарчадан – русчага. Хәзер күренекле әдәби әсәрләрне татарчага тәрҗемә итү юк дәрәҗәсендә. (Рус һәм чит ил әдәбияты үрнәкләрен берничә буын татарча тәрҗемәдә укып үсте. Бу – факт.) Ә татарчадан русчага? Бу процесс әзме-күпме бара әле. Барса да, элеккегечә эффектлы дәрәҗәдә түгел. Чөнки бүген атаклы рус язучыларының яки шагыйрьләренең дә китап тиражлары 2–3 мең данә (тиражлары зур булган детектив жанрындагы бестселлерларны чын әдәбиятка санамыйм). Ә аз санлы халыклар әдәбиятыннан тәрҗемә үрнәкләренә ни сан? Россиядә яңа Гамзатовларның мәйданга килүе бик шикле... Димәк, зур дөньяга чыгуның бүтән юлларын эзләргә кала. Рус кириллицасыннан тыш бу кояш астында бүтән имлялы телләр дә бар. Әйтик, инглиз теле, гарәп, испан теле... Бар компьютер, Интернет теле... «Тимер пәрдәләр» заманы түгел. Әлбәттә, традицион рәвештә үзебезнең тирәлектәге, элеккечәрәк әйтсәк, тугандаш әдәбият вәкилләре белән тыгызрак элемтәләр урнаштыру бик мөһим. Безнең республикада уза торган дәрәҗәле поэзия бәйрәмнәрендә (Тукай, Пушкин, Державин), сабантуйларда, классикларның юбилейларында, съезд-корылтайларда мөмкин кадәр күбрәк эшлекле кунаклар чакырырга кирәктер. Шулай ук Язучылар оешмасының 70 еллык тантанасына да... Мәхәббәт белән дуслыкка чикләр юк. Олы максат булсын да зур теләк булсын! Даими рәвештә инглиз телендә китаплар чыгарып килүче ПЕН-үзәк тә бу юнәлештә эшен тагын да активлаштырыр дип ышанырга кирәк. Һәрхәлдә, бу мөһим проблеманы чишү юлында һәммәбез өчен эшлисе гамәлләр тау кадәр.

Иң зур проблемаларның берсе, әлбәттә, яшь язучыларны үстерү. Оешманың төп бурычы дип тә әйтеп була моны. 70 ел элек, ягъни Язучылар оешмасы төзелгәч кабул ителгән Уставта да төп матдә итеп язып куелган ул. Яңартылган хәзерге Уставта да шулай. Табигый хәл. Дөнья шулай яратылган, киләчәгең – дәвамчыда. Без әдәбиятка килгәндә, артта үкчәңә басып килерлек яшьләр бар иде. Хәзер инде аларны яшьләр дип куштырнаклар эчендә генә әйтеп була, үзләре остаз булырлык, 40 яшьне узган ир уртасы кешеләр. Алар артыннан кемнәр килә, кемнәргә өмет баглыйлар алар, кемнәрне нинди традицияләрдә тәрбиялиләр? Татарстан Язучылар оешмасы яшь иҗатчыларны үстерү юнәлешендә байтак эш башкара: яшь язучылар конференцияләре үткәрү, күмәк җыентыклар чыгару, районнарда семинарлар оештыру һ.б. Шулай да, реаль вазгыятькә карап, оештыру эшләрен тагын да колачлырак итү, эш алымнарының яңа ысулларын табу ихтыяҗ икәнлегенә инанасың.

Татар әдәбияты дигән зур дәрья турында фикер йөрткәндә, гыйбрәтләр алып уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Кайчак шундый сорау да туа: бүгенге әдәбиятыбыз гомумтатар әдәбиятымы, әллә Идел-Урал регионының мәдәни үзәге булган Татарстан әдәбияты гынамы (онытмыйк: заманында яңа татар әдәбиятында беренче проза әсәрләрен Ростов, Пенза якларыннан чыккан шәхесләр язды бит. Әйтик, безнекеләр хәзер еш кына баргалап торган зур әлезәнлеләр тормышы татар әдәбиятының берәр сәхифәсе була алмас идеме? Бу җәһәттән бүтән төбәкләрнең исемнәрен әйтеп узарга була. Түбән Идел – Сарытау, Астрахань..., тоташ Урал – Пермь, Чиләбе, Җаек..., Урта киңлекләр – Рязань, Касыйм...). Без еш кына «әдәбиятыбыз берничә гасыр буе югалган дәүләт институтларының кайбер функцияләрен (мәгърифәт, мәдәният) башкарып килде» дибез. Бу хәл хәзер ничек? Милли аңны, милли идеяне халыкка җиткерүдә язучыларыбызның бердәмлеге бармы? (Әгәр язучылар, галимнәр арасында, сүз көрәштерүдән бигрәк, бердәмлек булса, имля мәсьәләсендәге дискриминацион хокуксызлыклар килеп тә чыкмаган булыр иде.)

Язмамның баштагы өлешендә сораулы җөмләләрем инде булган иде: әдәбиятыбызның язмышы алга таба ничек булыр? Элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Алдан ук куелган сорауларым күңелемдә, сөттә йөзгән елан кебек, язмам буе шомлы уй булып барды. Чыннан да, безне ниләр көтә? Әдәбият язмышы белән Оешма язмышын да күз алдында тотып әйтүем (Оешмасыз да әдәбият бетмәс бетүен).

Уйланырлык сәбәпләр бар. Язучылар берлеге – иҗтимагый оешма. Ә әлегә андый оешмаларның яшәешен билгеләүче канун юк. Димәк, юридик хәят – бар белән юк арасында.

Бүгенге көндә язучы хезмәтен социаль яктан гарантияләгән законнар юк (шуңа күрә дә Россиядә бик күп язучылар фәкыйрьлек дәрәҗәсендә. Бу уңайдан бездә дә матди яктан иркен яшәгән язучыларны бармак белән генә санарлык). Димәк, хәзерге прагматик яшьләр өчен әдәби иҗат өлкәсендә гарантияле тормышчан перспективалар күренеп тормый (шуңа күрә дә бүген шигъриятькә Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Җәлилләр урынына, үсмер егетләрдән бигрәк, кыз-кыркын килә дә инде). Ә Оешманың гомум уртача яше – 60. Фәкыйрь карт-корыны кайсы җәмгыятьтә үлеп яраталар икән? Дөрес, бездә, Россиянең бүтән регионнары белән чагыштырганда, хәлләр әлегә шөкер итәрлек. Әгәр республика булмаса, борынгыдан дәүләт тоткан хисне йөрткән затлы катлам булмаса, татарның ил-көн хәлен тойган Илбашы булмаса, эшләр бик мөшкелгә әйләнер иде.

Хәер, гомумән, нигә мөшкел булырга тиеш ди әле?! Талантлы булу фаҗига булырга тиешме? Талант – Күкләрдән иңдерелгән илаһи байлык, ил-халык байлыгы, дәүләт байлыгы. Без әлегә ил-дәүләтле булудан ваз кичкән халык түгел. Миңа калса, бүгенге көндә меңьеллык татар әдәбиятының бөек традицияләрен дәвам итәрлек, ким дигәндә, биш дистәләп талантлы язучыларыбыз бар. Бу – зур байлык. Язучы кеше – тел сакчысы. Ә тел – милләтнең төп билгесе. Халык, милләт булып сакланып калырга телибез икән, иҗат кешеләренең, шул исәптән заман елъязмачылары – язучыларның кадерен белик! Алар булганда, шәт, нинди генә рәвештә булмасын, иҗат оешмасы да яшәр.

*2004*

**II**

*Туган җирең чүл булса да,*
*Күңелдә ул гөл генә!*
*Ватан катлы-катлы булмый,*
Ватан була бер генә!

# ***КОЯШ АСТЫНДА БЕЗ ДӘ БАР***

Булсаң икән ул бер Ташбалбал да, җиргә береккән килеш утыр икән Җил-Вакыт дигәннәренә исең дә китмичә. Үтсен еллар, үтсен гасырлар, ә син, мәңгелеккә каккан казык кебек, битараф рәхәтлектә оеп утырасың... Бакый гомер җил-яңгырларның сыйпап иркәләүләре туйдыргач, бермәл ниндидер илаһи кодрәт белән җанланасың, кызык өчен генә булса да бу Күк гөмбәзе астында, Ай-Кояш яктысында Адәм балаларының мәш килеп ниләр майтарып ятканына күз саласың... Әһә, Дөнья дигән яшәү үзәнендә эшләр болайрак икән... Карыйсың-күрәсең, аңлыйсың-беләсең дә янәдән Ташбалбалга әвереләсең. Күпмедер ел-гасырлар үткәч, тагын бер җанланып, Тормыш дигәннәренә янә күз салып, үзеңчә анализ-нәтиҗә ясыйсың...

Бу уйлар – әкияти хыял. Безгә, бер саплам җеп озынлыгында гомер бирелгән Кеше атлы Адәм балаларына, мәңге яшәр таш сын да, шигырьдәгечә, «ак болыт булырга да язмаган»... Яшисең икән (бүтән чара юк! – «ирексездән туасың, гаҗәпләнеп яшисең, сагыш белән үләсең...»), уйланмый хәлең юк: борчыласың, хыялланасың, исәп-хисапларыңа муафыйк эш-гамәл кылырга тырышасың. Гадәттә, кылган эш-гамәлләр корган уй-хыялларның бик аз өлеше генә булып чыга...

Гаме булган Җан иясенә уйланыплар калыр өчен җай чыгып кына тора ул. Тиздән, тагын берәр елдан, Кешелек яңа гасырга аяк басарга тора. Хәер, гасырлар үлчәме – шартлы нәрсә. Миладичә 1999 ел булса, һиҗричә 1421 ел исәпләнә. Ә яһүдләрдә – 5759 ел. Яшәешебез шартларына бәйле рәвештә бездә инде байтак гомерләр григориан календаре исәптә йөри. Туу-үлемебез дә, гомер кичкәндәге төп вакыйга-даталар да шушы календарьдагы саннар белән билгеләнә.

Әйе, без XX дип йөрткән гасыр тәмамлануга бара. Алдагылары белән чагыштырганда җәһәтрәк, тизрәк үткәндер сыман тоела ул миңа. Җир Кояш тирәли кызурак әйләнмәгәндер, билгеле. Ә планетадагы Тереклекнең яшәү рәвеше, кеше гамәлләренең башкарылу тизлеге, вакыйгаларның үзара үрелеп агуы, ил-халыкларның бер-берсенә керешеп аралашуы ягыннан

бу гасыр, һичшиксез, «тыгызрак», динамиграк булыр. Чагыштырып карыйк: бу йөз елга якын дәвердә халык бик нык үрчеде, берничә мәртәбәгә ишәйде. Кытай кебек халкы миллиардлап исәпләнгән илләр хасил булды. БМО мәгълүматларына караганда, хәзер Җир йөзендә 6 миллиардлап кеше яши. Димәк, тыгызландык. Кояш астында тере күләгәләр күпкә артты, җирдән шуышып искән җилгә җанлы киртәләр күбәйде.

Элгәреге гасырларда кешеләр үзләре яшәгән җир өсте киңлекләрен биек тау башларына менеп манзара кылган булса, XX гасырда Адәми зат Җир шарын, Яшел Планета дип атап, галәм киңлекләреннән чыгып, «читтән капшап» карады, хәтта Айга җитеп, «Зөһрә кыз көянтәсен тотып кайтты». Җир-бишеккә мөнәсәбәт үзгәрде. Матдәнең «җанында» казыну көчәйде. Атомны таркаттылар. Ягъни кеше акылы макродөньяга да, микродөньяга да тирән үтеп керә бара.

Кеше, яман чир кебек сырхауларны (соңгы чорда алар рәтенә СПИД кебекләре дә өстәлде әле!) дәвалауга чарасыз булса да, тереклекне күпләп кыра торган атом, водород, нейтрон һәм тагын әллә нинди бомба-кораллар уйлап тапты. Җирнең өстен-астын үлем заводлары челтәрләде.

Диңгез-океаннарның төпләренә кадәр бүлгәләнде. Энергетик ресурслар – нефть, ташкүмер, газ бетүгә таба авышты. Озонлы биосфера катламы, тузган сүрү кебек, ертылырлык юка элпәгә калды. Табигать мәсхәрәләнде. Сугыш-эпидемияләрдән дә мәхшәррәк афәт – экологик афәт килде. Чын чиста сулар арктик бозлар куенында гына калды бугай инде. Җир-Су дигәч, ирексездән күңелгә «җирсү» сүзе килә. Табигый Табигатьне сагынып җирсү... Гасырыбызның 50 нче елларында телдән төшми йөргән «Без Табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз, аны аңардан тартып алу – безнең бурыч!» дигән лозунг-шигарьнең икенче өлешен «коммунистларча» шәп үтәдек бугай.

Кеше нинди генә көч-куәткә, аң-зиһенгә ия булмасын, ул иң әүвәл Табигать баласы. Вәхшиләрчә мөнәсәбәттән Табигатьнең эчке гармониясе бозылган икән, димәк, аның баласы – Кеше дә шул дәрәҗәдә үк камиллеген, игелеклелеген югалткан дигән сүз. Миңа калса, үтеп бара торган гасыр Кешенең кешелеген Яшәү сәхнәсендә шундый итеп сынады ки, һәм бөеклеген, һәм түбәнлеген, көзгедәге кебек, үзенә һәм җирдәшләренә бөтен нечкәлекләре белән күрсәтеп бирде. Шигырьдәгечә, «бөтен прогресслар фәкать регресс кына, кеше җаны череп таркалса...»

Меңнәрчә телләрдә сөйләшеп тереклек итүче халыклар (Җир йөзендә 5 меңнән артык тел һәм шивәләр бар дип исәпләнә) яшәешендә дә, ягъни дөньякүләм иҗтимагый тормышта да, Табигать-ана кичергән хәлләргә охшаш үзгәреш-тетрәнүләр, һай, күп булды бу үткән гасырда! Гасыр яшьтәшләре булган йөзьяшәр аксакаллар ул хәлләрне бөтен күзәнәкләре белән тоеп аңлыйлардыр. Әле безнең, чагыштырмача яшьрәкләрнең дә, ишетеп, укып, күреп, кичереп белгәннәре дә байтакка җыйнала.

Менә ул Тарих «капчыгыннан тырпаеп торган» кайбер тенденция-контурлар. XX гасырда бик күп халыклар милли бәйсезлекләре өчен көрәшкә күтәрелделәр, күп корбаннар бәрабәренә булса да җиңделәр, максатларына ирештеләр. Искә төшерик: Европаның төп баскынчы илләре – Англия, Испания, Франция – күпме колонияләреннән колак кактылар! Африкада, Азиядә бик күп яңа бәйсез дәүләтләр барлыкка килде. Димәк, кимсетелгән, изелгән, каһәрләнгән халыкларның күз яшьле каргышы «кыстырды» аларны. Ә Тормыш-Яшәү дигән бөек сәгадәтнең антиподы – «ихтыяҗи» сугышлар! XX гасыр бу яктан күрсәтте инде күрмәгәнне! Үзеге без яшәгән Европада кайнап чыгып, аннары бөтен кыйтгаларга да таралган Беренче бөтендөнья сугышы, янә Икенче бөтендөнья сугышы (исемнәре генә ни тора!), булуы ихтимал өченчесе... Тфү! Тфү!

Ихтимал, Күк җәнабларыннан җибәрелгән иң зур каһәр һәм сынау элеккеге Рус империясе, соңрак СССР, хәзер Россия дип йөртелгән җирләргә тигәндер... Инкыйлаб, гражданнар сугышы, җирне хуҗасыннан аеру – колхозлашу, сыйнфый дошман эзләү, искитмәле салымнар чоры, «коммунизм төзү» дәвере, «бөек» торгынлык һәм, ниһаять, янәдән килеп байлар белән хәерчеләргә бүленү еллары...

Бу гасырда Россия империясе элеккеге Рим яки Госманлы империяләре шикелле таркалды, дисәк тә була. Әлеге дә баягы шул «кысу» галәмәте бит бу. Гасыр башында Польша, Финляндия кебек илләр мөстәкыйльлек алып үзбашка чыкса, гасыр ахырында, зур тоташ киңлекләрнең кырыйларыннан кителгән язгы бозлар шикелле, хәзер шактый ук кечерәйгән

территориядә ярымач, ярымҗимерек, ярымисерек Россия утырып калды (шуның уртасында без...). Прибалтлар да юк, украин яклары да юк, Кавказ да, Урта Азия дә... Кояш астында алар бар. Әмма алар – бүтән! Гомумтенденция: халыклар, бер яктан, икътисади, сәяси җирлектә берләшергә омтылсалар (мәсәлән, Европа илләре бердәмлеге һ.б.), икенче яктан, мөстәкыйльлек, милли аерымлык, үз йорт-дәүләтен булдыру юлын сайладылар. Моның бер ачык мисалы гасыр урталарында Израиль дәүләте оешу булды. Тел вә дин ягыннан үзара кардәш төркемнәр тәшкил иткән халыкларда да үзенчәлекле зур эволюцион үзгәрешләр туды, әлбәттә.

Кемгә ничектер, миңа калса, төрки халыклар, әйтик, славян халыкларына караганда, тетрәнүләрне, катаклизмнарны күбрәк кичерделәр шикелле. Гасыр башында бөтен төрки халыклар диярлек, тарихи бәйсезлекләрен югалтып, аяусыз колониаль басымга дучар ителделәр. Егерменче елларда чагыштырмача көчле һәм мөстәкыйль булган Төркия дә бәйсезлеген югалта язып калды. Урта Азия ягы төркиләре бу гасырда мәгълүм бер тәрәккыяткә ирешсәләр дә, барыбер инкыйлаб китергән уртак нәтиҗәләрдән, уртак әйләнештән читтә кала алмадылар. Шул ук бер идеологик максат-принциплар, шул ук тоталитар идарә итү системасы, шул ук совет халкы (дөньядагы иң алдынгы!) рәвешендә урыслаштыру сәясәте... Сүздә никадәр генә ирекле һәм тугандаш саналмасын, «бәйдә тоту» принцибы шулкадәр мөкәммәл эшләнгән иде ки, хәтта бер генә республиканың да үзендә теге яки бу төрдәге тулы производство-җитештерү циклы булдырылмады. Төп деталь – двигатель – бер җирдә эшләнсә, ә бер бик тә кирәкле икенче бер шөреп меңәр чакрым ераклыктагы бүтән бер өлкә йә республикада ясала иде.

Әмма тарихи дөреслек өчен гадел булыйк: Урта Азия халыкларына бу үткән гасыр шактый ук «күн төште». Иҗтимагый формацияләрнең эволюцион үсеш чоры тизләнү сәбәпле, икътисадта алар урта гасырчылык мирасыннан шактый тиз арына алдылар. Нинди генә бәрелешләр, сугышлар, сынаулар булса да, халыкларның тарихи рухлары, нигездә, бетмәде, яшәү рәвешләренең төп принциплары сакланды, өмет-максатлары югалмады, һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба алар хакыйкый бәйсезлек тә алдылар. Күрәбез, беләбез: бүген алар зур икътисади кыенлыклар кичерә. Үтә торган авырлыклар бу. Иң мөһиме, «Аһ, татлы нәрсә шул ул Азатлык!» дигән шикелле, халыкның киләчәгенә гарантия булган мөстәкыйль дәүләтчелек барлыкка килде. Димәк, өмет бар!

Безнең җирлектә яшәгән өлкән һәм урта буын өчен XX гасыр тарихы ул, асылда, СССР тарихы. Ә СССР – ул Җир шарындагы коры җирнең алтыдан берен тәшкил иткән галәмәт зур территория. Шушы киңлек гел генә XX гасырның халыкларны «печү» полигоны булган икән дип уйлаучылар ялгышырлар. Байтак ил-халыкларга якты нур булып төшәрлек прогрессив идея-гамәлләр дә туган һәм тормышка ашкан җир дә бит әле ул Советлар Союзы. XX гасырның иң авыр сынауларын кичеп тә, рухлары сынмаган, талантлы халыклар яшәгән бу җирләрдә. Күп кенә бөек башлангычлар иле дә булган ул. Халкы ачлы-туклы яшәсә дә, киләчәккә иманы нык булган аның. Җаны сау булган. Конфуций әйткән, имеш: «Дәүләт белән идарә итәр өчен өч нәрсә кирәк: ашар-эчәр ризык, ил сакларлык корал һәм халык ышанычы». Аннан сораганнар: «Шуларның берәрсе булмаса, дәүләтне тотып буламы?» – «Коралсыз да була», – дип җавап биргән ул. «Әгәр шул өченең тагын берсе булмаса?» – «Хәтта ризыксыз да була, – дигән акыл иясе, – кешегә барыбер бер үләргә туры килә, ә менә халык ышанычын югалтса, бернинди дәүләт тә яши алмый»... Әйе, ышаныч, киләчәккә ышаныч бөек нәрсә ул! Дөрес, ышанычларның күбесе акланмаган... Халыкларның бөеклеге һәм фаҗигасе кардиограммасы. «Ул елларга инде кайтып булмый...» дигән шигырь юллары бар. «Сагынып кына була!» дип дәвам итәлә ул. Хикмәт ностальгиядә, сагыну-сагынмауда гына түгел, әлбәттә. Әмма бүгенге кискен контрастлар, дәүләти дәрәҗәдәге җинаятьчелек, эшсезлек, сәяси башбаштаклык... Әнә шулар үткәнне сагынырга мәҗбүр итә. Ә сагыныр нәрсәләр юк түгел: социаль гаделлек; хезмәткә, укуга, ялга, дәвалануга реаль хокуклар; билгеле бер әхлакый-этик нормаларның үтәлүе, канун-законнарның эзлекле ныклыгы...

Инде килеп үзебезгә – татар кавеменә кайтыйк. Ни гамәлләр кылынды бу дәвердә? Бүгенниләр майтарабыз? Киләчәктә нәрсәләр эшләргә җыенабыз? Сорауларны бирдем бирүен дә, ә җавап бирүләре, ай-һай, кыен. Яңа гасыр башланыр алдыннан бик күпләр уйлана-уйлана, кайта-кайта үзенчә җавап эзләячәк әле бу сорауларга. Шулай булгач, шул меңнәрнең берсе, бу очракта шушы гасырның икенче яртысын кичкән кеше, бүгенге әдип һәм мөхәррир буларак,

үземчә фикер йөртеп карау гаепмени? Сизенәм, мөгаен, субъективлыкта гаепләүчеләр дә табылыр. Халык язмышы турында фикерләшкәндә, бәхәсләр туу табигый хәл ич! дип кабул итәргә кирәктер. Иң элек күңелгә шуны киртләп куйыйк. Үтеп баручы гасырда без сан ягыннан (рәсми мәгълүматларга табынмаган хәлдә дә) әллә ни артмадык, үрчемәдек, ишәймәдек. Бүтән төрки халыклар белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык күренә. Сәбәпләрен һәркем үзенчә гөман кылыр. Заманында хәзер уртак ватан саналган иксез-чиксез киңлекләргә дәгъва кылган милләт XV–XVI гасырларда каршы як милләт белән бер чамадарак булган бит ләса! Нидән бу туктап әкренәю? Бар булып та, бүтән халыклар мохитендә балавыз күк изрәп «эрүебез» нәтиҗәсеме бу? Әллә сәбәп генофонд оеткысының сыеклануындамы? Әллә неомальтусчылык (неомальтузианство) (күп үрчү, янәсе, сыйфатка «бәрә», интеллект кимүгә китерә. Гадәттә, Африка һәм Азия илләре мисалында шулай аңлаталар) тарафдарлары булып киттекме? Әллә элегрәк прогрессив күренеш дип бик пропагандаланган катнаш никахлар җимешеме? Ни генә булмасын, факт инкяр итеп булмаслык факт булып кала. Димәк, санның сыйфатка әверелү ягыннан да без әллә ни алгарышка өметләнә алмыйбыз.

Каршылыклы тагын бер сорау туа: гасыр башында татарның матди һәм мәдәни хәле ничегрәк булган? Гасыр ахырында ничегрәк? Россия империясе кысасында нindирәк урын тотканбыз да хәзер шул ук ил-халыклар (хәзер статуслары бүтән булса да) арасында нindирәк рейтингта без? (Әлбәттә, һәр вакытка, һәр чорга чагыштырмача нисбәттә!) Без гасыр башында, бүтән халыклар белән чагыштырганда, баерак, зыялырак булганбызмы әллә?.. (Янәдән кабатлыйм: чагыштырмача.) Төгәл, кистереп җавап бирү кыен. Гомумконтурны ретроштрихлар белән генә чамаларга кала. Шунысы факт: заманасына күрә Россиядә – Дума җыелышларындамы, фабрика-завод цехларындамы, прииска-шахта тирәнлекләрендәме – татар факторы шактый көчле булган. Сәүдә дөньясы турында әйтсәсе дә юк. Халыкның билгеле бер катламында милли сәрмая, ягъни милли капитал тупланган. Хосусый кулларда булса да, бу капиталның шактый өлешен милли байлык дип тә әйтергә мөмкин. Моңа бер дәлил – меценатлык. Әгәр хәйрия оешмалары (бу хәрәкәтнең үзәгендә торган Хөсәенов, Кәримов, Яушев, Юнысов, Акчурин, Рәмиев кебек затларга дистә еллар аша рәхмәт!) булмаса, әйтик, мәгариф өлкәсендәге казанышларга (чагыштырмача уку-язу буенча татарлар урыс туганнарга караганда гыйлемлерәк тә саналганнар әле. Бу хакта Ленин да язып калдырган) ирешелер идеме? Матбага эше гөрләп тормаса, көчле әдәбият каян килер иде? Рухыбыз дөньясында бер Тукай феномены гына да күп нәрсәне аңлата.

Ул заманда безнең халык күпләп яшәгән һәр губерниядә, һәр төбәктә татар теленә, татар китабына, милли яшәү рәвешенә табигый көчле ихтыяҗ булган. Татар китабы, гомумән татар матбугаты, империянең дистәләгән регионнарында мул күләмдә, күп санда нәшер ителгән. Театр труппалары оешкан. Дини оешмалар һәм мәчетләр массакүләм рухи-идеологик үзәк миссиясен үтәгән... Кыскасы, рухи күтәрелеш булган. Дәрт тә, дәрман да булган.

Мәгълүм хакыйкать: һәр халыкның көчен-куәтен аның милли байлыгы билгели. Бүгенге дөнья байлыгы кайсы илләрдә һәм кемнәр кулында тупланган? Әйтәләр: «Кимендә 70 процент мәгълүм бер халык хозурында». Ә безнең милли байлыгыбыз (республика банкларының берсендә Татарстанның да үз алтыны – фәлән килолы бер кирпеч коелмасы бар, дип сөйлиләр) күпме дә һәм кемнәр кулында? Югары цивилизацияле илләр мисалы шуны күрсәтә: әгәр байлык чын мәгънәсендә уртак милли байлык булса, чын хөкүмәт аны әрәм-шәрәм итүгә, урлауга юл куймый. Хәер, бу кадәресе хәзерге Россиягә дә, Татарстанга да карамый шикелле.

Үткәнне мактыйммы? Һич юк. Булганын искәртәм генә. Бүгенге күзлектән караганда, ул заманның, сәнәгатендә булсын, мәгърифәтендә, сәнгать һәм әдәбиятында булсын, дөнья кадәр тискәре якларын табарга мөмкин. Ә бүгенгебез? Совет чорында чыккан йөзләгән фәнни-гыйльми саналган хезмәт-китапларны актарсак (аларда совет чорындагы бишьеллыкларның «уңышларын», гадәттә, нигәдер 1913 елгы күрсәткечләр белән чагыштыралар иде), теге заман белән чагыштырганда йөзәрләгән, хәтта меңәрләгән тапкыр үсеш турында күрсәткечләргә юлыгырбыз. Әйтик, матбугат турында сүз чыкса, әйтерләр, хәзер бер Татарстанда гына йөзләгән нәшрият бар. Шәһәрләрдә йөзләгән татар мәктәбе. Фәлән йөз язучы, фәлән мең мәдәният сарае, клуб... Ә заводлар, фабрикалар, промышленность предприятиеләре, бигрәк тә хәрби заводлар турында сүз китсә, үсеш темпларына шаккатып тел шартлатырга гына кала. Геополитик яктан Европа-Азия казанышларына ия Татарстан фәненең казанышларын шик

астына алырга теләмибез. Читтән караганда, чыннан да, милли аспект турында уйламасаң яки аны инкяр итсәң, без фәкать тәрәккыят аванпостында гына торабыз диярсең.

Ярый, без, каләм ияләре, гомерләребезне багышлап, күп гасырлы зур әдәбиятыбыз бар дип, эчке куаныч кичереп яшәүчеләр, бөек рухи чыганак – Галиҗәнап әдәбиятыбыз турында бүген ниләр уйлыйбыз соң? Өзек-төтек кенә белгән Болгар чоры, Алтын Урда, Казан чорларына кереп тормыйча, күпмедер дәрәҗәдә шаһиты без булган XX гасыр әдәбиятын күздән кичерик. Гасыр башы һәм гасыр ахыры чишмә башлары чыганакларын барлыйк.

Кайларда туып, кайлардан килгән соң талантлар татар әдәбиятына? Әлбәттә, Идел-Урал буе – Татарстан һәм Башкортстаннан, Самара, Сембер, Пенза, Нижгардан; Әстерхан, Тубыл, Сарытау, Оренбург, Троицк, Чиләбе, Курган якларыннан... Тагын дистәләгән шәһәрләрдән... Хәер, йөрәк яндырып санап торуның хаҗәте юк. Хәзерге әдәбиятыбызга әзме-күпме килеп кушылган яшьләр – үзебезнең Татарстаннан да Башкортстаннан. Калган регионнардан инде килмиләр диярлек. Мәктәпләр беткән, китапханәләрдәге рухны вакыт җилгәргән. «Киткән ватан белән сөт тә кипкәнме әллә?..» Әй мөхтәрәм зат Закир Рәмиев – иптәш Дәрдемәнд! Ямьле Юлык буйларында нинди варисларыгыз үсә? Сыркыдыда Такташ якташлары татар китаплары укыймы? Пенза якларында Г.Колахмәтов, К.Тинчурин, Ш.Усманов, Г.Кутуйлар рухы исәнме? Камышлы Әнвәр абый Давыдовны юксынамы?

Тагын кайсы якларга карап оран салыйк? Беренче татар романнары авторы З.Бигиев (Ростов), Ш.Камал, Г.Әпсәләмов (Мордовия), К.Нәҗми (Т.Новгород), Г.Сәмитова (Ташлыяр), Х.Госман (Пермь), А.Расих (Троицк), Н.Арслан (Кызылъяр)...

Театр, музыка, сынлы сәнгать дөньясыннан кайбер исемнәрне искә төшереп үтик: З.Хәбибуллин (Орск), Л.Фәттахов, Р.Ваһапов (Т.Новгород), Г.Кайбицкая (Уральск), Ф.Туишев (Сембер)... Хәзер, кызганыч, ул төбәкләрдән мондый олуг «йолдызларны» телескоп яки төнлә күрсәтә торган приборлардан карасаң да күреп-табып булмый инде...

Әдәбият китапсыз була алмый. Татар китабының, гомумән матбугатының, бүгенге хәле күңел күгәртерлек дәрәҗәдә мөшкел. Китап кирәксез товарга әйләнде. Үзенең кирәксезлеген тою – һәр талант, гомумән һәркем өчен, иң авыр тойгыларның берсе. Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла кебек, куларбага китап төяп ил буйлап йөрергә дә риза булыр идең дә хәтта, әмма бүгенге яшь-җилкенчәккә син язган җыру-моңнар кирәк микән? Ә бит XXI гасырга алып чыгарлык әдәби мирасыбыз бар, һәм ул әлегә өстәлеп тора! Аяныч. Мирасыбыз өчен түгел, бүгенге хәлебез өчен аяныч.

Хәзерге татар әдәбияты әлегәчә элеккеге «эч мае» хисабына (фольклор, классик мирас тәэсире, чирәмле авыл рухы, җыр-моң, балачак хатирәләре, табигый җир-су...) яшәп килде. Телебезнең бишеге булган авыл да, ай-һай, бик нык үзгәрде шул бу дистә елларда!.. Берничә буынны тәрбияләгән «Галиябану», «Агыйдел», «Йөзек кашы», «Туган ягым – яшел бишек» әсәрләрендәге каһарманнарның реаль оныклары укый микән әле бу гүзәл әсәрләрне? Шикләнәм.

Кыскасы, нигезебезне – авылны югалтып барабыз. Бәс, шулай булгач, сугыштан соң тирәлегебезне чорнап алган ВПК предприятиеләре, нефть промыселлары, КамАЗ, нефтехимнарның югары даирәдәге шәхесләре турында үз телебездә нинди югары художестволы әсәр туарга мөмкин! Базарың (бәяң) мәгънәсендә) булмагач, әдипнең дә кадере юк. Кадерсез әдип үзе дә сансызлана. Бүгенге көндә югары исемнәр йөрткән, яшьләре белән 70 ләрдән узган мөхтәрәм әдипләребезнең дә байтагының интеллектын гасыр башындагы С.Максуди, Й.Акчура, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимовлар интеллекты, зыялылыгы һәм затлылыгы белән чагыштыру кыен. Әмма үзен татар дип йөрткән, үзендә милли үзаң бар дип исәпләгән һәркем бер нәрсәне онытмаска тиеш: дәүләтчелек идеясе теге йә бу формада иң әүвәл Сүздә – гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә сакланды. Байтак гасырлар буенча дин беренче чиратта милләтне таркатмаска булышса, әдәбият иң мөкатдәс хисне – Азатлык, Бәйсезлек, Мөстәкыйльлек идеясен, йә ачыктан-ачык, йә эзоп теле белән, эчтән саклап, үстереп килде. Әйе, 90 нчы елларда беркадәр яуланган суверенитет-мөстәкыйльлегебезнең юл башы еррактарак... Шуңа күрә дә шул Олуг Әдәбият варисларының бүгенге көндә үз талантларына кирәк кулланыш таба алмаулары, кирәксезлекләре ил хуҗалары, дөнья чыгырын әйләндерүчеләр өчен оят булырга тиеш.

Халык рухының ышанычлы көзгесе булган әдәбият турында сүз кузгаткач, милләтне милләт иткән бүтән компонентлар турында да берничә сүз әйтми калып булмый. Ул – туган

тел язмышы, ул – милли тарих, ул – милли мәгариф системасы, ул – дин тәгълиматы... Бу олуг мәсьәләләрне бер язмада хәл итү түгел, чишелешен дөрес куя белү дә ифрат авыр. Теләгәндә дә, әзерлегем, көчем дә җитмәс иде. Кайбер күзәтүләр белән чикләнәм. Тел хакында сүзем кыска: ул сорау гына. Ана телендә гасыр башында күбрәк сөйләшкәнме татар халкы, әллә хәзерме? Өч алфавит кичкән халык яңа гасыр башын нинди имля белән башлар? Җавапларны укучы үзе табар. Дин өлкәсендә, кызганыч, махсус белемем юк. Шулай да, мәсьәлә артык зур булганга күрә, бу хакта һәркемнең үз фикере булу лязем. Әгәр динебез булмаса, бу дүрт-биш гасыр эчендә без милләт буларак күптән беткән булыр идек инде. Безне моңарчы дин, эчке иман саклап килде. Шуны аңлап, дәһшәтле кара көчләр төрле гасырларда динебезне юк итәргә ташландылар да инде!

Үтеп баручы гасырда, рухка иркенрәк еллар булгаласа да, нигездә, динебез, галимнәребез бик нык каһәрләнде, дин хадимнәренең күбесе җисми юк ителде. Болары һәркайсыбызга мәгълүм, һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба дин ирегенә юл бирелде. Күп җирләрдә, тирә-юньгә ямь биреп, манаралы мәчетләр калкып чыкты (дөрес, аларның күбесе ашык-пошык, зәвыксыз һәм фәкыйрь салынды. Хәер, әлегә алары да ярап тора). Ә халык йөриме? Ниятләнгән максатка ирешеләме? Динчеләребез әзерлеклеме? Дөресен әйтик, безгә чын мәгънәсендәге динле халык булырга ерак әле. Гади халык кына түгел, хәтта күп руханиларыбызның да гамәле, диннең асыл рухы һәм Аллаһ иңдергән тәгълимат белән иманланудан бигрәк, яшәешләре, гамәлләре, асылда, ритуал йола-гадәтләрен үтәүгә кайтып кала. Дин, алда әйтелгәнчә, бөек көч. Иншалла, киләсе гасыр дәвамында милләтне саклауда аның роле зур булсын иде.

Ә уку-укыту, гомумән мәгариф системасына килсәк, безнең өчен аеруча авыр дәвер булгандыр бу гасыр. Бигрәк тә алтмышынчы-сиксәненче еллар арасында татар мәктәбен ачыктан-ачык юк итү сәясәте алып барылды. Моннан егерме еллар элек Казан булып Казанның үзендә тулысынча татарныкы дип әйтерлек бер генә мәктәпнең дә калмавын искә алсак, бу хакта артык сүз куертуның кирәге юк. Милли мәктәпләрне үстерүдә соңгы еллардагы күтәрелеш беркадәр өметне уята уятуын. Тик болар әлегә үсентеләр, көзге болында калкып килүче курпылар гына... Булган милли рухны кире кайтарыр өчен генә дә берничә яңа буынның үсүе зарур. Бер сөргән болында янәдән тигез чирәм-бәбкә үләне булдыру өчен күпме вакыт кирәклеген күпләр белә булыр...

Үткәнебезне өйрәнүдә дә эшләр шулайрак. Егерменче елларда татар тарихы беркадәр өйрәнелә башласа да, соңгы илле-алтмыш елда ул партия идеологиясе басымында берьяклы, Мәскәү тарихына кулай кушымта булып «фәнниләште». Без, дөресен әйтик, дәүләтчелегебез тарихын, үсеш дәверләрен, аның хаким-шәхесләрен, алар кылган гамәлләрнең яхшы-яманын бөтенләй диярлек белми үстек. Хәзер генә, яңа туган песи баласыныкы шикелле, күзебез ачыла башлады. Тарихыбызны оныттыру, хәтерсезләндерү – XX гасырның (алдагы дүрт-биш гасырның дәвамчысы буларак, әлбәттә) безләргә кылган иң «саваплы» гамәлләренең берседер...

Ишеткәнем бар: янәсе, һәр гасыр башында зур социаль тетрәнүләр булып ала, һәм шул нисбәттә рухи дөньяда даһилар пәйда була. Миңа калса, мондый фараз кемнәрнеңдер, чынаяктагы кофены болгатып, язмыш юравы шикеллерәк нәрсә. Әмма халыклар язмышында (календарь тәртибе буенча түгел, билгеле) чоры-чоры белән ыргымнар, яңарышлар була тора. Безнең Татарстан мисалында да бу шулай. Соңгы ун-унбиш елда эчке үзгәрешләр бик күп. Җитмешенче еллардагы Татарстан обкомы чорлары белән туксанынчы еллар ахырындагы идарә системасы, элеккеге Верховный Совет белән хәзерге Югары Совет (Дәүләт Советы), элеккеге Конституция белән хәзерге Конституция арасындагы аерма аңлаган кеше өчен бик зур бит. Дөрес, җирле кануннар Үзәк тарафыннан бик нык «үтүкләнә» соңгы дәвердә...

Евразия үзәгендә Татарстан дигән республика барын хәзер бөтен дөнья белә. Бу – бик мөһим фактор һәм XX гасырда ирешкән зур казанышыбыз. Акча яки корбаннар бәрабәренә сатып алып була торган нәрсә түгел ул. Парадокс: бер яктан, ярлар тарая, ә агым көчәя генә; басым арта, бәреп чыгу дәрманы арта... Тик шунысы кызганыч: Татарстан ул әле бөтен татар халкы дигән сүз түгел шул... Гасыр башында империя киңлекләрендә татар өчен «күтәрәсе (уңыш бирәсе!) чирәмлекләр» шактый иде әле. Хәзер ул чирәмлекләр тупас төрән белән аннан-моннан сукаланган, аларга ашлама дип агу мул сибелгән (эчкечелек – шуның иң каһәрлеседер, мөгаен). Шулай да, акрынлап булса да, иман иңдерү бара. Соңгы җиде-сигез ел

эчендә үткәрелгән Бөтендөнья татар конгресслары... Исеме генә ни тора! Тупланырга, яһүдләрдән ким булмаганча, бер-беребезгә таяныч булырга бөек омтылыш бит бу.

Элек исемнәре дә як-якка каранып, пышылдап кына әйтелә торган чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән хәзер, кулга-кул бирешеп, киләчәктә ничегрәк яшәү турында иркенләп фикер алыша алабыз. Тоталитар режим балалары өчен бу да зур казаныш. Шәп, матур, тантаналы очрашулар үтә, мәгънәле генә карар-резолюцияләр кабул ителә. Делегатлар таралалар, һәм... үз җирләрендә киләсе җыелуларны көтеп яши бирәләр. Дөрес аңлашылсын, Конгресс комитеты эшләрен һич тә кимсетергә теләмим, хәл кадәри тырышалар, чит өлкәләргә чыгалар... Уяту һәм беркадәр уяну бар. Әмма кайчак шундый уй да килә: төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә сүнеп яткан учактагы күмерләрнең уңай исеп куйган җилдә беркавым җемелдәп алуы гына түгел микән бу олуг җыеннар?.. Әгәр татарлар ишле яшәгән җирләрдә милли-мәдәни мохтарият төзелми, федераль үзәктән җыелган салымнар бәрабәренә тиешле средстволар бирелми торып, милли хәрәкәт мактанырлык алга китә алмастыр.

Хәзер ерактагы һәм якындагы чит илләрдә Татарстанның уннарча вәкиллекләре бар. Алар, бәлкем, республика өчен зур эшләр башкара торганнардыр. Америка, Франциядәге кебек илләрдә дип әйтмим, әйтик, татарлар күп яши торган төрки дәүләтләрдә – Казакъстанда, Үзбәкстанда яшәп ятучы ул вәкиллекләр безнең рухи байлыгыбызны – китапларны, газета-журналларны – оешкан тәртиптә тарату эшенә алына алмыйлар микәнни? Татар матбугаты хәзер, нигездә, Татарстанда гына тарала. Урта Азия, Казакъстан белән бу җәһәттән аралар киселгән диярлек. Менә бит ул тараюлар каян килә! (Кайчак уйлап куясың: ул якларда милли җанлы эшмәкәрләр табылмый микәнни? Хәзерге заманда әллә нинди могҗизалар эшләп була бит. Әйтик, «Казан утлары» яки бүтән берәр басманың куен кесәсенә сыя торган бер-ике санлык дискетын ал да, шунда кәгазь табып, бастырып, таратып файдасын күр! Юк бит...)

Сүзне йомгакларга да вакыттыр. Без гасырны бераз иртәрәк төенлибез бугай. Шулай да берле (1) һәм дә тугызлы (999) саннар белән саубуллаштык инде. Аннан – икеле (2), нольле (0) саннар башланыр. XXI гасырга үз язмышына, үз тарихына һәр халык үзенчә аяк басар. Инглиз инглиз булып, француз француз булып, гарәп гарәп булып... Алар да, әлбәттә, бу үтеп баручы гасырда әллә ничаклы фаҗигаләр, регресслар, тантаналар, үзгәрешләр кичергәннәрдер. Әмма милләт буларак алар, фәкать чыныгу, сынау алып, шул ук тарихлы, шул ук телле, шул ук мәдәниятле халык-милләт булып калдылар. Ә без, татарлар, бер гасыр эчендә әллә нинди метаморфозалар кичереп, сыйфатый, әхлакый, генетик яктан бик-бик нык үзгәрдек. Үтеп баручы гасырда безнең күбебезгә, кәлтә еланы кебек, кирәк буыннарны да өзеп (теләп яки мәҗбүр ителеп) калдырырга туры килде. Ә шулай да, күпме генә сыкранып-сыктасак та, табигатьтә Бөек Хәят дәвам итәчәк. Ышанасы килә: дөнья халыклары арасында, дөнья цивилизациясендә Татар милләте булачак. Кояш астында Татар Иленең үзенә лаек урыны булыр, иншалла.

*1998*

## *КИТАП ГАСЫРЫ КИТӘМЕ?*

1999 елдагы тугызлы саннарның иякләре салынып түгәрәкләнгәч, язмаларыбызда рәттән симез өч нольләр күренгәч, яңа гасыр быел ук башлана дип уйлаучылар да булды бугай. Ашыкмыйк: өченче меңне башлаган яңа гасыр таңына тагын бер ел бар әле! (Бу хисап милади буенча. Һиҗри белән исәпләсәң, бөтенләй бүтән гасырда әле без!) Бәрәкәтсез тиз узса да, бер ел әллә никадәр хәл-вакыйгалар, көтелмәгән үзгәрешләрне үз эченә ала әле ул. Исән-сау булсак, яңа гасыр бусагасын атлаганда, укучылар белән уртаклашырлык яңа уй-фикерләр табылыр, бәлки. Ә хәзергә язма сүз, басма китап язмышлары, сүз сәнгатенә бәйле каләмдәшләрем хезмәте турында.

...Китап гасыры үтеп бара. Бу сүзләрне кәгазьгә төшерәм, ә җан бәргәләнә. Кул яза, күңел килешми. Ә нишлисең, Вакыт галиҗәнапларына каршы чара юк. XX гасыр информация-коммуникация ягыннан телефон, радио, самолет, телевизор, кибернетика гасыры булды. Фән казанышлары кешеләрнең рухи дөньясын бик нык үзгәртте. Шулай да дөньяны танып белүдә,

эстетик тәрбия бирүдә Китап төп чыганак булып кала бирде. Шулай булмый ни! Китап ничә гасырлар буе Кеше акылының могҗизасы саналды. Гомер бакый Кеше җанының сердәше булды. Ул уйлатты, елатты, сөендерде, нәфрәтләндерде, хыялландырды... Гомер буе сабак бирде... (Китап белән бергә хатлар язу, хат алышу гасыры да үтеп бара түгелме соң? Кызганыч... Ничәмә-ничә буын хат язып, хат көтеп хыялланып яшәде бит!) Ризасызланып булса да, килешергә туры килә: гасырыбызның соңгы чирегендә телевидение һәм компьютер системасы информация пространствосыннан басма Китапны шактый кысрыклады да. Бер генә мисал: кайчан гына яхшы язу машинасы булдыру турында хыяллана идек. Хәзер аларның хаҗәте бетеп бара... Фән акылы казанышларын гавами акыл үзләштерергә өлгерә алмый. Цивилизацияле дөнья компьютерның Интернет челтәре белән эш итә хәзер. Кешелек аңы тарихында үзе бер революция. «Виртуаль чынбарлык», «тинейджер» («компьютер җанлы» кешеләр) дигән төшенчәләр барлыкка килде. Меңәр чакрым ераклыктан кешеләр үзара мәгълүмат алу гына түгел, хәтта тәнни-хисси мөнәсәбәтләргә дә керә алалар, дип сөйлиләр... Йа Хода, илаһи дип йөргән Китабыбыз нишләр инде? Ахырзаман бәндәләренең аңа ихтыяҗы булырмы?

Дөресен әйтик, күңелдә тәшвишле уйлар булса да, Китап язмышы белән нисбәтән киләчәккә өметсез үк карамыйм. Халкыбыз Китапның үз язмышы икәнен аңлар дип ышанам. 200 еллап тарихы булган Америка өчен Китап бер нәрсә булса, 1000 әр еллык дәүләтле тарихы булган Европа илләре өчен, бәлки, икенчерәктер китапның миссиясе... Ә безнең өчен ул – төп байлык. Ул моңарчы безнең өчен дәүләт тә, дин дә, гыйлем чыганагы да булып килде. Элгәргеләребезнең бөек сүзләрен искә төшерик: «Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады... Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады (...), алар сәламәт әле, алар яңгырый әле» (Г.Тукай). «Иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият аның вөҗдан һәм ачу авазын ишеттерү өчен бердәнбер трибуна булып тора» (А.Герцен). Болар – үткән гасырларның хикмәти җан авазлары.

Әйе, без Китаптан аерылырга тиеш түгел. Әлегә «Йосыф-Зөләйха» кыйссаларыннан, «Идегәй» дастаннарыннан килгән рухи яктылык яшәтә. Китапларга салынган җегәр-көч бик тә кирәк әле безгә. Хәзерге рәсми статистика ягыннан карасаң да, алга киткән байтак халыклар нисбәтендә бүген дә югары белемгә ия кешеләр саны буенча без шактый түбән урында. Һәрхәлдә, киләсе гасырның байтак дистә елларында без Китап укучы халык булып дөньяга кереп калсак иде! Шушы урында бик тә мөһим бер нәрсәне ачыклау кирәк. Нинди китап белән киләчәккә бармакчыбыз соң? Кайларда алар? Кемнәр чыгара аларны? Авторлары кем? Укучылары кем һәм күпме? Чыннан да, чигәләреңне тотып уйланырлык хәл. Бер карасаң, Китапка дәрт кими бара, дибез, икенче яктан – дөнья тулган Китап белән. Зур форматлысы, кечкенәсе, ялтыравык тышлысы, рәсемлесе... Тик аларның күбесе, иң аз дигәндә өчтән икесе – псевдокитаплар, полиграфик ысул белән кәгазьгә төшкән опуслар, кеше җанын көчләүче язмалар, очсыз анекдот-мәзәкләр, хайвани инстинктны кытыклаучы детектив хикәяләр, порножурналлар... Югары кыйммәткә, тәрбияви әһәмияткә ия, эстетик зәвык белән чыкканнары да җитәрлек. Фәнни басмалар, белешмә сүзлекләр, дөнья классикасы үрнәкләре... Алар, кызганыч, азрак керә йорт түрләренә. Китапханәләр, китап кибетләренә караганда затлы банк биналары, коммерция офислары күбрәк төзелә хәзер. Әлбәттә, аларның үз дөньясы, үз китаплары, күбрәк табыш алуга файдалы методик әсбаплар... Татар дөньясының китап чыгару тарихына баксаң, бер уртак хәлгә тап буласың: гасыр башында да, гасыр ахырында да матбагада хөрлек булган: теләсә нәрсә чыгарып була! Ләкин аерма бар. Татар галәмендәге китаплар, нигездә, берничә төрдә: матур әдәбият (шул исәптән халык иҗаты үрнәкләре); дини әдәбият; дәреслекләр, фәнни-белешмә басмалар. Бәлки, китапчы-галим, академик Ә.Кәримуллин да шул фикердәдер. Ул чорда әдәпсез-оятсыз «әдәбият» үрнәкләрен таба алмыйсың. Шуңа күрә ул замандагы китап мирасы, нигездә, милләт киләчәгенә, аның мәгърифәтенә хезмәт иткән, милли үзаңны үстергән. Р.Фәхретдин, Г.Тукай, Г.Исхакый, Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов һәм башка әдипләрнең иҗаты шул хакта сөйли. Ә хәзерге вазгыять? Хәлнең ничеклеген алдарак беркадәр әйттем шикелле. Китап дөньясында хаос. (Рәсәйдәге яшәүнең көзгесе!) Күпләр нәрсәнең китап, нәрсәнең антикитап икәнен аера алмый. Парадокс: Китапны «китап» бетереп бара. Республикада, белүемчә, Китап чыгаруга лицензия-хокук алган йөзләгән нәшрият (!) бар. Нигә шулкадәр үрчегәннәр соң алар?

Аларның күплегеннән берәр нәрсә отабызмы? Төгәл җавап бирү авыр, күңел авазы «отмыйбыз» ди. Чөнки аларның туксан фәлән проценты ничек кенә булса да, нәрсә чыгарып булса да табыш алу максатын куйган басмаханәләр. Миңа калса, бүгенге көндә традицион тәртиптә төп ике оешма – Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» нәшрияты гына дәүләтчел сәясәт алып барып, киләчәкне күз алдында тотып эшлиләр. Һәрхәлдә, бу нәшриятлар чыгарган китаплар өчен, нигездә, оялырлык түгел. Кайбер чыгарма мисаллар табып була булуын. Әлбәттә, бу төп нәшриятлар тагын да нәтиҗәлерәк – күбрәк китаплар да чыгара алыр иде дә, әмма бюджет тарафыннан каралган суммаларның да өчле-тугызлы, ягъни ярым-йорты бирелүе сәбәпле, бөтен тулаем көчендә эшли алмый. Шул сәбәпле байтак авторлар очсызлырак чыгара торган коммерция басмаханәләргә мөрәҗәгать итәләр. Ә эшкуар басмаханәчеләр теләсә ни чыгарырга әзер! Андый авторлар мең бәла белән акча юнәтеп чыгарган китапларын үзләре сатып, үзләре урнаштырып йөрергә мәҗбүрләр. Дәрдемәнд, Акмулла яки кырыктартмачы... барысы бергә буталган...

Китапханәләргә кергәч, бөрешеп калам
Китап киштәләре алдында.
Бөек уйлар тулы изге сарайдан соң
Кичке күккә карыйм нарасыйланып.
Анда да мәңгелек йолдызлар...

...Булды заманнар, безнең халык Китапларны күмәргә дә мәҗбүр ителде. Яндырылудан саклап калганнарын, иманлы тормышка өмет өзгәч, кояш астында рәнҗетелгәнче, ичмасам, укымышлы затларның җәсәде белән изге туфракка иңсен дип, үз акыллары белән дә күмделәр аларны...

Безгә, минемчә, Китапларны, Чын Китапларны саклау, үстерү, аларны яңа буыннар рухына сеңдерү юнәлешендә кардиналь чаралар кирәк. Дәүләти максат һәм стратегик планнар белән.

Беренчесе, һичшиксез, булган бөек мирасны (шөкер, ул бар! Булмаса, нишләр идең!) җыеп-туплап, бастырып, һәрдаим халыкка җиткерү, ирештерү, аңына сеңдерү. Бу җәһәттән, ассызыклап үтик, байтак эшләр эшләнә дә. Тел, әдәбият, тарих институты (хәзерге Тел, әдәбият, сәнгать институты), Татарстан китап нәшрияты, соңгы ун елда барлыкка килгән «Мәгариф» нәшрияты, «Мирас» журналы... Халыкка ирештерелгән уникаль басмалар... Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, «Идегәй» дастаны, Мөхәммәдъяр поэмалары, Утыз Имәни, Кандалый әсәрләре...

Икенчесе – дин нигезләрен ныгытуга, әхлакый тәрбиягә ярдәм итә алырлык югары кимәлдәге әсәрләрне, икенче төрле әйткәндә, иманлы әдәбиятка өстенлек бирү. Бу – җәмгыятьне савыктыруның бер юлыдыр. Бездә хәзер төрле-төрле басмаханәләрдә дини әдәбият шактый күп басыла. Тик аларның төп өлеше әлегә кустарь дәрәҗәдә. Рәшидә абыстай (Р.Исхакова) чыгарган китап-брошюралар үз вакыты өчен ярап та куядыр, алар да кемнәргәдер кирәктер. Әмма... Дин тәгълиматы ягыннан да, художество-нәфислеге ягыннан да Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, М.Бигиев, Г.Баруди хәзрәтләренең хезмәтләре югарылыгына, һай, ерак әле бүгенге дин хадимнәренә!

Күңелдә иман булмаса,
мәчет ни дә, азан ни!
Җәһаләт белән сәрхушлек
безне әле озак җәзалар...

Өченчедән, борын-борыннан безнең халыкның Китапны изге дип санавын истә тотып, традицион мәгънәдәге әдәби әсәрләрнең сыйфаты камил булырга тиешлеген онытмаска тиешбез. Бу безгә, һөнәре итеп әдәбиятны сайлаган профессиональ язучыларга карый. Язучы исемен, кесәсендә шуның шәһадәтнамәсен йөрткән күпме каләм ияләренең күпме чүп-чар «әсәрләре» дөнья күрә! Үзебездән дә ояла белик! Таләпчәнлек җитми. Әзме-күпме иҗади процесска йогынты ясый алырлык иҗат оешмаларының, остаханәләрнең, әдәбият-сәнгать өчен җаваплы дәүләт хадимнәренең таләпчәнлеге җитми. Тумыштан килгән сәләт-талант – бер нәрсә, ә осталык – икенче нәрсә, аңа ирешер өчен гомер кирәк, үзеңне аямау кирәк.

Дөресен әйтик, чын мәгънәсендә туган телнең нечкәлекләрен белгәннәр дә сирәкләнеп бара... Төптәнрәк уйласаң, безнең Китапның башында дөнья цивилизациясенең җәүһәре, иң мөкәммәл Китап – Коръән тора. Шуны онытмаска иде!

Ярый, фәлсәфәбезне кыскартып, җиргә төшик, бүгенге яшәешебез хәлләренә, бүгенге реаль вазгыятькә килик. Менә дәверебезнең яңа бер елы башланды. Газеталар, журналлар язылган әбүнәчеләр саны буенча яңа тиражлар белән басылып чыга башлады. Яңа дигәч, гадәттә, күбрәк, мулрак итеп күрәсе килә дә бит! – ни хәл итмәк кирәк, – татар матбугатын быелга алдыручылар ишәймәде. Димәк, милли үзаңны үстерүче бер фактор кимеде. Димәк, үзбилгеләнүгә, дәүләтчелеккә, бәйсезлеккә (Декларация кабул ителүнең 10 еллыгында!) яңа адым атланмады. Хакыйкать: татар телендә чыгучы басмалар, асылда, милли идеяне халыкка сеңдерүче басмалар бит алар. Матбугатка язылуның сайлаулар кампаниясе вакытына туры килүе дә безнең өчен зыянга гына булды. Депутатлыкка үтү өчен берсен-берсе этеп-таптап, саташыр дәрәҗәгә җиткән кандидатларның (ә аларның абсолют күпчелеге эш башында торучылар) үз марафоны. Күбесенә китабың ни дә, журналың ни!.. Сүз дә юк, Китап алдыру, көндәлек матбугатка язылу матди җитешлеккә бәйле. Парадокс: җәмгыятьтә акча күп тә, акча юк та! Галәмәт күп баскычлы, күп пирамидалы идарә структурасы кешеләренә акча бар һәм мул бар, гади игенчегә – юк; хоккей, машина куу ярышлары өчен акча бар, милли университет ачарга, классикларның күптомлы китапларын чыгарырга – юк; башкаладан килгән ярымшәрә, ярымнаркоман «поп-йолдызлар»га астрономик суммалар бирер өчен акча бар, ә өлкән бер хөрмәтле (?!) язучыга каләмхак түләргә – юк... Бәлки, кәгазьгә кытлыктыр? Кәгазь чыганагы – шау урманнар кырылып киселә бара... Алай дисәң, дөнья кәгазь белән тулган. Шәһәр җирләрендәге почта әрҗәләрендә дыңгычлап тутырылган реклама газеталары... Тик татарчалары гына юк. Хәер, сайлау өндәмәләрендә андыйлары да очрый... Безнең матбугатны укучылар, шул исәптән «Казан утлары»н да, байлар, финанс магнатлары, елгыр малтабарлар (ярый ла бертуган Кашаповлар кебек, керемнәренең бер өлешен, әйтик, зәкят өлешен, халык өчен кирәк китаплар чыгаручылар булса!), бар вөҗүдләре һәм гамәлләрен фәкать өстәге идарәчегә яки идарәчеләргә карап эш йөртүче марионет җирле түрәләр түгел, ә тормышларын очын очка ялгап баручы гап-гади кешеләр – игенчеләр, авыл интеллигенциясе, пенсионерлар, укытучылар, студентлар... Алар, чыннан да, бүген ярлы катлам. Бик теләгәндә дә, языла алсалар, бер яки ике газета-журналга язылалар. Бу очракта җирле хакимият башлыкларыннан күп нәрсә тора. Халыкка, төрле юлларын табып (алдынгыларны бүләкләү, пенсионерларга бушлай яздыру, авыл мәктәпләренә, китапханәләргә шефлык итү һ.б.), рух хәзинәсен илтә алу саваплы да, мәгънәле дә булыр иде, хезмәт кешесенең күңелен яулау да булыр иде! Хаким кеше хәким дә булса икән! Тормышыбызда андый тәңгәллек мисаллары да бар: быел җәй Президент М.Ш.Шәймиевнең республика китапханәләренә яңа китаплар кайтару өчен 2 млн сум акча бирдерүе җәмәгатьчелек рухын савыктырып җибәрде. Дөрес, Президентның мөмкинлекләре гаять зур. Әмма түбәкләр җирлегендә район башлыкларының да дәрман-хокуклары шактый... Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: район башлыкларының туксан проценты Казанның авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларында (хәзергечә әйтсәк, академияләрдә) укып чыккан кешеләр. Күп нәрсә аларның интеллектуаль әзерлекләренә бәйле. Шулай булгач, бу югары уку йортларында тиешле гуманитар белем бирү дә көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Китап гасыры үтеп бара, дидек. Гасыры үтсә дә, Китап дигәннәре бездән кул болгап тиз генә үтмәс әле, боерган булса... Ел ахырында гына татар халкының рухи тормышында бер тарихи вакыйга булды: ниһаять, күп буыннар хыялланган «Татар энциклопедия сүзлеге» дөнья күрде. Олы казаныш. Әйтүләренчә, алдагы елларда биш томда энциклопедик басма чыгачак. Күпме генә зарлансак та, олуг әдипләрнең (мәрхүмнәрнең дә, исәннәрнең дә) күптомлыклары чыгып тора. Соңгы елларда татар тарихына караган, объектив мәгълүматларга бай булган саллы-саллы фәнни китаплар халыкка ирешге. Сәләтле яшь (чын мәгънәсендә яшь!) талантларның китаплары чыккалап тора. Милли мәгариф системасының тернәкләнеп килүенең бер мисалы бу. Киләчәккә өмет-ышаныч бар. Гасырлар буе тупланган генетик аңга, халык акылын һәм хакимнәрнең җегәр-куәтен кушып, бергә-бергә иҗтиһат иткәндә, киләсе гасырда да Китап безнең гомерлек юлдашыбыз булыр, шәт. Амин!

*1999*

## *ИМАН БЕЗНЕ ТАШЛАМАСЫН!*

Телибезме-юкмы, Язмыш тарафыннан бүген татар дип йөртелә торган халыкның дөнья буйлап сибелгән балалары без. Гыйбрәтле, озын тарихы, заманында шанлы дәүләте булган борынгы бер кавемнең варислары. Без әле, шөкер, бүген дә исән-сау, һәм, киләчәккә йөз тотып, Кояш астында мәңге яшәү нияте белән хәят кичереп ятабыз. Шундый уйлар белән яшисең икән, табигый, «без каян?», «ни кылабыз?», «кая барабыз?» дигән сораулар бимазаламый кала алмый.

Мәңгелек Кануннар катгый үзгәрешсез булса да, тора-бара, буыннар алышына-алышына, аңыбызда Вакыт һәм Киңлек төшенчәләре дә үзгәрә сыман: вакыт тизрәк ага, киңлек-пространство кысыла бара шикелле... Чынлап, ышанып та куярсың, үткән йөз елдагы үзгәреш-метаморфозалар шаккатарлык! Уйлап карыйк: Җирдә адәм баласы нык үрчеде (димәк, тыгызландык!); Табигать коточкыч таланды (үзебез утырган ботакны кисәбез!); фән-техника өлкәсендә фантастларның да башына килмәгән ачыш-табышлар булды (күбрәк бәхеткә тиендекме?); ил-халыклар арасында, минут-сәгать эчендә дигәндәй, кызу-тиз аралашу-бәйләнешләр урнашты (дуслык-туганлык ныгыдымы?)... Һәр конструктив хакыйкый фактка берничә контрсорау килеп баса. Парадокс: объектив шартлар һәм заманасына хас яшәү шартлары (техник казанышлар уртаклыгы, хәбәр-информация берлеге, максат юнәлеше...), бер яктан, төрле ил-халыкларны берләшү дәрәҗәсендә якынайтса, ягъни интеграцияләштерсә, икенче яктан, һәр халыкның үзенә генә хас тарихи гадәт-сыйфатларын ныгытып, телне саклап, аерым бер үзгә милләт булып калу тенденциясе, саклану инстинкты көчәя бара... Факт, бу процесс төрле милләттә үзенчәрәк: берәүләрендә әйдәүче көч империячелек булса, икенчеләрендә үзенә бәйсезлек яулау идеясе төп этәргеч булып тора.

XX гасыр татар милләте өчен аеруча авыр сынау гасыры булды. Алгарыш дәрәҗәсе, табу-югалтулар, стратегик ялгышлар, фаҗигаи язмышлар турында киләчәк үзенең хак сүзен әйтер әле... Акыл ияләре өчен бүген дә күп нәрсә ачык инде. Бу кыска язмада тирән тарих, сәяси төеннәр, тотрыксыз кануннар, катлаулы икътисад хәлләренә кереп тормыйча, без белгән рухи мирас – якындагы үткән һәм бүгенге әдәбиятыбыз турында чагыштырып уйлану рәвешендә кайбер фикерләребезне бәян итсәк, гайре табигый хәл булмастыр.

Әдәбиятыбыз байтак дәверләр дәвамында, соңгы гасырда бигрәк тә, милләтне саклап калуда, диннән кала (аларны аерып карап та булмыйдыр), иң төп фактор булды. Халык җаны догада, китап сүзендә, җыр-моңда сакланды. Нигездә, соңгы гасырда оешкан һәм беркадәр үсеш алган сәнгать төрләренең өлешен дә инкяр итәргә җыенмыйбыз – алар да зур рухи чишмәләр. Әмма төп чыганак барыбер әдәбият бит! Кемнеңдер «нишләр идек, фәлән булмаса!» дигәне шикелле, әдәбият (кульязма һәм басмадагысын, халык авыз иҗаты әсәрләрен дә кертеп) булмаса, татар нишләр иде икән дә кем булыр иде икән? Кимендә телсез калган, дөресрәге, ана телен күптән югалткан булыр иде. Шөкер, үткән гасырда кан кардәшләребез яшәгән төбәкләрдә татар китабы милләттәшләребезнең гомер юлдашы булып килде. Күп тә чыкты бит ул китаплар! Дистәләгән мең исемнәрдә, йөзәр миллион данәләрдә... Үткән гасырлардагы акыл ияләре өчен горурланып, авыз тутырып әйтә алабыз: төрки киңлекләрдә генә түгел, тәрәккыятле бөтендөнья масштабында татар әдәбияты дигән зур байлык-хәзинә бар! Бүтән халыкларга да белдерәсе иде, күрсәтәсе иде ул байлыкны, килер буыннар аңына сеңдерәсе иде!

Бүген күңелләрне борчып торган иң төп уйларның берсе шул: яңа гасырда әдәбият үзенең элгәреге миссиясен дәвам итә алырмы? Язучыларыбыз әсәренә ихтыяҗ калырмы? Тере сүзне ясалма аң – компьютер-тамга алыштырып бетермәсме? Әгәр телең югалса, әдәбиятың бетсә, сәнгатең йотылса, нинди мөстәкыйльлек, нинди суверенитет, нинди бәйсезлек булырга мөмкин икән? Бу урында шуны да искәртеп узу урынлы булыр: үзендә милли аң бар дип исәпләгән татар онытмасын иде – коллык кичергән халкыбызның гасырлар буена дәүләтчелек идеясе теге йә бу формада иң әүвәл Сүздә – гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә ачыктан-ачык йә эзоп теле белән эчтән сакланып, үстерелеп

киленде. 90 нчы елларда беркадәр яуланган суверенитет-мөстәкыйльлегебезнең юл башы – әнә шул еракта гы әдәби офыкларда.

Сер түгел, дөнья тоткан ил-дәүләтләр белән чагыштырганда, без, кызганыч ки, милли байлыкка ия халык түгел. Әйләнә-тирәдә күзгә күренгән хәзинә-байлык, асылда, безнең өчен рәшә генә. (Бер юлаучы, капка ачып, ишегалдындагы кешедән сораган, имеш: «Кем монда хуҗа?» Теге Хуҗа исемле кеше икән, әйткән: «Хуҗасын мин Хуҗа, ә йорт-җир – Идриснеке...».) Бүгенге көндәге вазгыять моны бигрәк тә ачык сиздерә. Төп байлыгыбыз – иман, акыл, рухи мирас... Аларның иң күп өлеше – гасырлар буе җыйналып килгән китапларда. Шуңа күрә дә олуг әдәбият варисларының – бүгенге язучыларның – җәмгыять, киләчәк алдындагы җаваплылыклары ифрат зур дип уйлыйм мин, һәм шушы уңайдан каләмдәшләргә дә искәртәсе килә: тарихи миссиябезне онытмаска, позицияне бирмәскә иде бит! Сүзнең җегәре заман басымына чыдарлык, кешеләрне әйдәрлек булырга тиеш. Юкса халыкның нинди вөҗданы ди син! Шуңа күрә, хөрмәтле каләмдәш, сиңа да, миңа да үзгәрергә, яңарырга, максат юлларын яңадан карап, барлап чыгарга туры киләчәк. Үзең өчен кадерле, әмма бүтәннәр өчен әллә ни әһәмияте булмаган күренешләрне, вакыйгаларны су буе итеп тасвирлау яки хикәяләү чорлары узды. «Фәтхулла хәзрәт»чә фәлсәфә кору дәверләре үтте... Фикерләү рәвеше, язу стиле үзгә булган яңа тип әдипләр заманы килде. Ә без аңа әзерме? «Мин – язучы, мин иҗат иттем, ә каләмхак түләү, китап чыгарып, аны тарату – бүтәннәр вазифасы» дип уйлаучылар күп әле безнең арада. Әйтеп куюлары да бар бит: «Ә кем язарга мәҗбүр итте соң әле сине? Инәлеп сорадыларммы?» Ата-ана үз баласының тормышта урын табуын гомер буе күзәтеп-барлап торган шикелле, язучы да үз әсәренең укучы күңеленә барып ирешүенә инангач кына беркадәр тынычлана аладыр. Шунысын да онытмыйк: без әлегә талантның халык байлыгы икәнен аңламаганнар мохитендә яшибез.

XXI гасыр хәтәр гасыр булырга охшап тора. Кояш системасындагы планеталарның Җир белән хәрәкәти мөнәсәбәтләреннән бигрәк (ахырзаман дигән тәгъбир күңелдән китмәсә дә), Табигать белән Кеше, илләр белән державалар, халыклар белән милләтләр (бу төшенчәләр еш бутала...) арасындагы мөнәсәбәтләрнең торган саен кискенләшә баруыннан туган уй бу. Кояш астында, бүтән халыклар арасында үз халкыбызның да үзенә лаек урын алуын теләү – табигый хис. Әмма гасырлар буе коллыкта иза чиккән кавемгә дәүләтле, тулы канлы милләт булу бәхете үзеннән-үзе күктән төшми. Әгәр безнең һәркайсыбыз җанында милли идея формуласы (ул әлегә күбебез аңында эмбрион хәлендә) юк икән, әгәр без тарихи нигезебездә бер йодрык булып тупланмыйбыз (без әлегә һаман таркау һәм дөнья буйлап чәчелгән) икән, безнең хыялларның буш куык булып калуы бар. Әйе, инкыйраз дигән хәвеф юк түгел. Шунысы куанычлы: булу ихтималы булган бу хәвефне булдырмый калырга көрәшүче көчләр дә бар. Димәк, алда өмет, ышаныч бар!

*2000*

## *ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР*

Җир кемнеке булса, җил – шуныкы.

Тел дигән бөек хәзинә турында яңа нәрсә әйтеп була икән? Читен эш. Ә әйтергә кирәк. Бүген әйтмәсәк, иртәгә соң булуы бар. «Сүзнең атасы – акыл, анасы – тел» дигәннәр борынгылар. Бар булган акыл белән, киңәш-табыш итеп уйлану-фикерләшү өчен, әнә шул Ана дигәннәренә, баш иеп дигәндәй, якынрак килеп карыйк әле...

Әйе, телне бөек хәзинә, байлык, диләр. Ә табигатьтәге һәрнәрсә үз урынында, үзенчә байлык түгелмени? Һәркайсының үз үлчәү-бәяләү берәмлеге. Тауларның биеклеге, җимешнең тәме, диңгезләрнең тирәнлеге, йолдызларның яктылыгы, далаларның киңлеге... Ә тел байлыгын, тел кыйммәтен ничек бәяләргә? Сүзләрнең күплеге, сөйләшүчеләрнең ишлелеге беләнме? Озак яшәүчәнлеге, кешелек тәрәккыятенә керткән өлеше беләнме? Бу әйтелгәннәр тел зурлыгын дәлилле тасвирласалар да, барыбер төгәл билгеләмә үк түгел. Һәр тел – үзенчә

бөек. Җәмгыятьтә урын тоткан һәр тел турында, бәлки, гади генә болайрак әйтеп буладыр: тел ул – иксез-чиксез, төпсез-кырыйсыз, хисапсыз-бәясез...

Җир йөзендә телләр бик күп. Аларның төгәл санын әйтү дә кыендыр. Бериш галимнәр алты мең ярым тел бар дип исәплиләр. Бар миллиардлап кеше сөйләшкән кытай, инглиз телләре, бар берничә мең, хәтта берничә йөз кеше сөйләшкәннәре... Мисалга ерак барасы түгел, үзебезнең Казаныбызда борынгы ассирия телендә сөйләшүче берничә дистә гаилә бар.

Төркем-төркем кошлар һавада!
Шуларның берәрсе
минем телдә сөйләшәдер күк.

Ә үзебезнең татар теле дип йөртелгән Туган телебез ни хәлдә соң бүген? Заманында халыкара телләрнең берсе булган, хәзерге көндә дә бөтен дөнья күләмендә сөйләшер өчен уңай ун-унбиш тел арасында саналган, җәмгыять яшәеше барышын бөтен тулылыгы һәм нечкәлекләре белән чагылдыра алырлык бихисап сүз байлыгы булган Ана телебезнең бүгенгесе ничек тә, киләчәге ничегрәк булырга охшый? Сораулар катлаулы һәм авыр. Әнә шул билгесез авырлык каләм алырга мәҗбүр итә дә инде. Телнең бөеклеге, байлыгы, үлемсезлеге, бердәнберлеге, көч-кодрәте, тылсымы турында абстракт фәлсәфә, рәхәт оета торган вәгазьләр чоры үтте. Әгәр телне милли үзаңны билгеләүче бер төп күрсәткеч дип саныйбыз икән, безнең хәлләр бүгенгә мактанырлык түгел. Халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул – тулы милләт, яртысы сөйләшә икән – ярым-йорты милләт, ә биштән бере сөйләшсә... Безгә хәзер, чаң сугып, «Уян, татар!» дип кенә түгел, «Тел сагына бас, Татар!» дияр чак җитте. Телебез аңлауга, ярдәмгә, яклауга мохтаҗ.

Көелә утларда,
сандалларда таптала,
ярыла сәяси тегермән-ташларда...
Имгәнә, сызлана, көрәшә,
яңгырый алыр хокук өчен.

Хакыйкатьнең күзенә карау җиңел түгел. Күп нәрсәләрне танып, тәкрарлау авыр булса да, моннан күп еллар элек бер студент шәригемә хатта әйткәндәй, «Ирләр булыйк!», реалист булыйк, дөресен әйтик. Дөньялыкта глобаль процесслар бара. Кеше дигән зат, Бөек Табигатькә зыян салып, яшәү сутын җимереп (иң аянычы, бер аңда яралган адәми кардәшләрен үтереп), экологик фаҗигагә – ахырзаманга юнәлеш алса, аналогик процесс Рух дөньясында бигрәк тә кызу бара. Гамьсез, ваемсыз җаннарыбыз әлегә артык сизми яки аны сизмәмешкә салыша. Сер түгел: үзләрен дөнья тоткасы санаган илләр, аз санлы халыклар телен үз «тегермәннәре» аша («на мельнице русской смололи заезжий татарский язык») үткәреп, бөтенләй таптап, бетереп бара. Кайбер «табышка» әверелгән фактларны (үзебезгә инъекция рәвешендә!) искәртеп үтик: Ана телебезнең бөтен нечкәлекләрен тойган, кабатланмас аваз аһәңе белән ләззәтләнгән укучылар катламы бик юкарды; чын әдәби китапларны (китап рәвешендә дөнья күргән чүп-чарны әйтмим) укучылар нык кимеде: милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдән әдәбият-сәнгатебезгә килгән яшь талантлар ифрат сирәгәйде...

Үткән XX гасыр тел җәһәтеннән (бөтен татар җәһәтеннән түгел микән?) безнең файдага булмады. Элегрәк заманнарны никадәр генә караңгы итеп күрергә тырышмыйк, кайтып булса да таныйк: милли тамырлар ул чакта ныграк, саурак булган. (Ерак Көнчыгыш, Кытай, Япон илләрендә яки Төркестан, Кавказ якларында, Урта һәм Түбән Идел буйларында үзенең икътисади базасы, мәдәни учагы, басма китабы, театры, мәхәлләсе булган тулы канлы татар даирәсен күреп буламы соң хәзер?) Татар конгрессларында, төрле милли җыеннарда берәм-сәрәм шытым-«курпылар» күренгәләп, чыгышлар ясаштыргаласалар да, чынында тамыр-зәмин, нигездә, корыган... Гомумтатар әдәби теленең барлык этник төбәкләрдәге үзенчәлекләрен бар тирәнлеге һәм байлыгы белән Идел-Урал, Казан төбәге тирәсендә генә саклау кыен... Соңгы елларда бар булган дәрман белән Казаннан читтә яшәүче кардәшләребезгә игътибар (шәмдәлләргә соңгы май тамызу булмаса ла!) артты артуын. Әмма

бу бөек миссиягә тартым хәрәкәт мәгълүм бер кампания уңаеннан гына булып, даими, эзлекле гамәл булмаса, уңай нәтиҗәләр бик чыкмас.

Йодрык – төен. Ул язылса,
аерылыр бармаклары...
Өчпочмаклар булып калыр,
өзсәң йолдыз канатларын.
...Бүлсәң бишкә бер халыкны,
аннан исем калыр бары...

Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел. Шуңа да ул байлык, хәзинә санала. Ә бүләкне, байлыкны, хәзинәне кадерләп саклый алу, күбәйтә-ишәйтә алу үзе бер батырлык сорый. Файдасын күреп яши белмәгәндә, тиз исраф итү, югалту бик җиңел аны. Телнең үз-үзен саклау «инстинкты» көчле көчлесен (диннәр алышынганда да тел калган!), әмма... Кояш астында һәр халык үзенә үзенчә урын даулый. Җир йөзендәге көрәш-тартышларның, орыш-сугышларның бер нигез сәбәбе, төптәнрәк уйлап карасаң, әнә шул телдә бит инде! Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җыр-моңын, матурлык өлгесен сакламакчы, үзенең яңа токымнарына тапшырмакчы. «Теле барлар – халык булган, теле юклар – балык булган» дигән сүзләр юктан тумаган. Әлбәттә, иҗтимагый күренеш буларак, тел объектив кануннарга буйсынып яши. Субъектив факторның, хәтта бик теләгәндә дә, роле ул хәтле зур була алмый. Әгәр тел сау-сәламәт икән, ул телдә җәмгыятьнең бөтен катламнары сөйләшә: ил башы да, бомж да, сырхау кеше дә, мәхбүс тә, шагыйрь дә... Тел үзенең иҗтимагый функциясен тулы кимәлдә башкара алганда гына мөмкин хәл бу. Әгәр тел кешенең тормыш ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алмый икән, ул аны киpәксенми, яхшы дигәндә дә, аңа битараф кала. (Аяныч булса да, искә төшерик: авылдан шәһәргә килгән сәләтле күпме татар яшьләре тел «казасы» аркасында югары уку йортларына керә алмый калды заманында!) Рухи байлык (бу очракта тел) матди байлык тупларга булышырга тиеш булып чыга. Бу процесс тормышта шулхәтле бер-берсенә керешеп беткән ки, кайчак кайсысының беренчел икәнлеге дә онытылып китә. Бу очракның мисалы шул: яһүдләр, кешелек матди байлыгының иң күп өлешен үз кулларына җыйгач, онытылып бетә язган «үле тел»не – ивритны тергезә алдылар, XX гасырга аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрделәр. Үзаң дигән төшенчәне аңлар өчен бик тә гыйбрәтле хәл бу.

Тел – диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас. Күңелдә сызланып йөргән уй-зарларны бер читкәрәк куеп, «ниләр эшләргә, ни гамәлләр кылып була» дигән сорауларга җавап эзләп карау дөресрәктер. Телебез халәтенә дөрес диагноз куярга сәләтле без бүген. Димәк, аны савыктыру өчен дәвасын да бергәләп табу ихтималыбыз бар. Фикри һәм гамәли хәрәкәтләр фарыз. Әлбәттә, уй-фикернең иң беренчесе һәм зурысы – дәүләтчелек идеясеннән баш тартмыйча, Республика статусын саклап калу. Тел язмышы шушы статуска бәйләнгән. Моның шулай икәнен үткән XX гасырның соңгы ун елындагы милли күтәрелеш бик ачык күрсәтте. Кыска гына вакыт эчендә тарихи геннар яңарып, байтак күркәм гамәлләр кылынды. Шул исәптән тел үсеше ягыннан да. Милли идеянең максаты һәм асылы булган дәүләтчелекнең ышанычлы нигезе ул, шиксез, мәгариф системасы. «Мәгърифәт – азатлык юлында беренче адым» дип тикмәгә әйтмәгән бөек әдибебез Г.Исхакый. «Мәгърифәт – киләчәккә күпер ул» дип өстәргә генә кала. Мәгърифәт белән һәрчак бергә үрелеп баручы дин тәгълиматыбыз да бар бит әле. Дин гомер бакый әхлакны һәм телне саклап килде. Соңгы вакытта диннең көчәюе, һичшиксез, телебез үсешенә дә уңай йогынты ясый ала. Дөрес, кайбер мәчетләрдә вәгазьләрне русча укучы имамнар да бар!.. Мәгърифәт, гомумән тәрбия турында сөйләгәндә, халкыбыз тарихында төп рухи роль уйнаган китап – Галиҗәнап Китап турында аерым әйтеп китү кирәк. Мең еллар буена безнең рухны китап яшәтеп килгән (күпләр өчен заман үрнәге саналган, тарихы нибары ике йөз ел исәпләнгән, җирле халыкны кылыч һәм туп белән кырган Америка җәмгыяте өчен китап нинди роль уйнагандыр, әйтү кыен. Гәрчә бөек язучыларын таныган хәлдә дә, алар инде тарихи мәгънәдәге китаптан җиңел генә ваз да кичеп киләләр шикелле). Китапта безнең тарих, безнең тел, безнең язмыш. Китап – татар өчен яшәү символы ул! Тел хәзинәсе сагында торган язучыларыбыз моны яхшы аңлыйлар. Халык язучысы Н.Фәттах болай язган: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең

берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым». Мондый хис әдипләрдә генә түгел, үзен татар дип санаган һәр кешедә булырга тиеш!

Киләчәкнең башы бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнендә –
онықларың сиңа рәхмәт әйтсә
матур итеп туган телеңдә!
*2002*

## *ЯҢА ЕЛДА ЯҢАРГАН УЙЛАР*

Һәр яңа адым аякларның бер-берсенә таянып алга ыргылганы кебек, һәр Яңа ел да искесенең алгарышка таба дәвамы ул. Яңа елда, кичәге-бүгенге мәшәкатьләрдән онытылырга тырышып, матур киләчәк турында күпме генә хыяллансаң да, үткән ел гамәлләре сине барыбер ычкындырып бетерми, ихтыяримы-юкмы, аларны янә бер күңелеңнән кичерәсең.

Үзгә бер алгысыну белән көтелгән, яңа бәхет-шатлыкларга өмет ителгән яңа гасырның беренче елы ничек үтте? Теләкләребез кабул кылындымы, фаразлаганнар тормышка аштымы? Һәркем үзенчә җавап бирер. Шулай да галәми-гавами фикер йөртсәк, болайрак әйтергә мәҗбүрбез: шомлырак башланып китте бу XXI гасыр дигәннәре. Бер кар китеп, икенче кар яткан аралыкта, бигрәк тә җәй-көз фасылларында, дөнья масштабындагы хәвефле, канлы вакыйгалар артыгы белән күп булды шул. «Глобаль катастрофалар булмагае» дигән шик күңелләргә үтеп керде, өченче бөтендөнья сугышы башлану чигенә җителде. (БМО мәгълүматларына караганда, җирдәге халык бер ел эчендә илле миллион чамасы кешегә арта икән. Димәк, җир тыгызлана, яшәү пространствосы кысыла, кояш астындагы урын өчен көрәш-дау көчәя, терсәккә терсәк ныграк тия, йөрәкләр ярсурак тибә!..) Тулы бер кыйтгалар, системалар, диннәр арасында нәфрәт пәйда булды. Американың һәм Көнбатыш христиан илләренең мөселман дөньясына элек-электән килгән кырын карашы үткән ел үзенең апогеена җитте. Илбасар-атаман державалар «терроргa каршы көрәш» сылтавы белән аерым бер халыкларны, дәүләтләрне юк итү гамәленә керештеләр. Сугыш, үлеш-кырылышлар, нигездә, диндәшләребез яшәгән җирләрдә бара. Ничә дистә елларга сузылган Әфганстандагы мәхшәр, Чечня-Ичкериядәге геноцид, ватаннары «диннәр бишеге» булган фәләстинлеләр язмышы. Шуңа өстәп Балкандагы албаннар, Кытайдагы уйгырлар, Һиндстандагы кашмирлыларның аяныч хәлләре... Һәр илнең, һәр халыкның үзгә ярасы, үзгә фаҗигасе. Тик бер уртаклык: атышлы-орышлы сугыш хәлләре, нигездә, таулы илләрдә бара. Янар таулар... Яралы халыклар... Ямаулы йөрәкләр...

Үз ватаныбыздагы үткән елгы вазгыять-хәлләрнең дә күбесе күңелләргә бәлзәм булып ятты димәс идем. Милли җанлы татар кешесенең дәртен сүндерерлек байтак акция-гамәлләргә, борчу-мәшәкатьләргә юлыктык. Моннан ун еллар элек күңелләребездә горур бөркет булып очкан мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә омтылыш хисе соңгы елларда күшегеп, бәләкәйләнеп, хәлсезләнеп калды. Татарстан күп дистә еллар буе СССРдагы союздаш республикалар хокукына дәгъва кылса (халыкара масштабта алар кая ыргылдылар да, без кайда калдык...), хәзер элеккеге автономия кысаларына (түбәнрәк булмаса!) тәмам әйләнеп кайтты бугай. Халык ихтыяры һәм парламент кабул иткән Конституциянең күп маддәләре (алар кырыктан артык) капылт үзгәртелсен, хәтта кайберләре мәхкәмәгә бирелсен әле! Хәтта Татарстандагы мәктәпләрдә татар теле укыту мәсьәләсе дә суд залларында күтәрелде. Кыскасы, 90 нчы елларда яулап алынган хокуклар кире тартып алынды, кануннар коллык психологиясенә туры килә торган итеп тәмам «тәңгәлләштерелде». Татар халкын рәсми рәвештә, ачыктан-ачык төрле этник төркемнәргә ясалма бүлгәләү бара. Хәтта нинди графикада язу-язмау кебек һәр халык фәкать үзе хәл итә торган мәсьәләләр дә «Ак патша» пайтәхете кулына күчте. Кайбер шовинистик сәясәтчеләр, үз башына ашкынган козгын кебек, Татарстанның республика булып яшәренә күп калмады инде, дип тә каркылдыйлар...

Дөньяга һәркем үз оя-мөнбәреннән бага, биеклегенә карап офыкларны ачыклый, ихтыяҗына күрә максат-таләпләр куя. XXI гасырның өермәле чатына чыгып җиткән татар язучысын, гомумән каләм ияләрен,ниләр борчый соң бүген, яңа һәм алдагы еллардан ниләр өмет итә ул? Гомумән, язучының җәмгыятьтәге роле нинди дә, хезмәтенең хаҗәте ни

дәрәҗәдә? (Без үскәндә «язучы булам!» дию хәтта якын кешеңә дә әйтергә базылмый торган татлы хыял иде! Бармы хәзер андый хыялый үсмерләр?)

Язучы – асылда, елъязмачы ул. Язучы үз халкының тарихын язарга тырыша, аны бүтән милләт-кавемнәрдән ким итеп күрмәскә тели. Әлбәттә, үзенең табигый миссиясен үтәү өчен аңа да кәгазь-каләмнән тыш тән-җан саулыгы, горур басып йөрерлек дәрман-барлык һәм ахыр чиктә киләчәккә ныклы ышаныч кирәк бит! Чын язучы милләт язмышы белән яши. Ә милләт кая бара? (Бәлкем, кеше дигән «homo sapiens» заты клонлаштырылган заманда бу төшенчә кемнәргәдер анахронизм булып яңгырыйдыр? Шулай да кытай, немец, япон, гарәп, һинд, инглиз кебек кавемнәр үзләренең кан белән яратылган исемнәрен һич тә онытырга теләмиләр бугай!) Безнең өчен әлегә җавапсыз иң кыен сораудыр бу. Ни өченме? Гомум ил күләмендә үткәрелә торган кайбер реформа-акцияләрдән туа бу сораулар. Әйтик, үткән ел федераль дәүләт төзелешенең асылын тәшкил иткән (Үзәк белән регионнар арасындагы демократик мөнәсәбәт күрсәткече) үзара шартнамәләр юкка чыгарылды диярлек. Федерация төзү үрнәген күрсәтә башлаган Татарстанның пионерлык әләме кыйшаеп авып кала язды... Янә бер факт: үткән ел Россиядә милли мәсьәләләр буенча министрлык (ул болай да күтәрәмгә калган, вәкаләтләре юк дәрәҗәдә булган идарә структурасы иде) бетерелде диярлек. Шомлы сигнал бу! Димәк, империя стратегиясенә андый идарә-мәшәкатьнең кирәге юк. Димәк, милли проблема да юк! Бүгенге Россиядә миллилеккә күпмедер дәгъва кылучылар кемнәр? Әлбәттә, беренче чиратта сан ягыннан икенче урында торучы татарлар... Өстәвенә, көтмәгән-уйламаганда, газета-журнал, басма-нәшрият әһелләрен аптырашта калдырып, Татарстанның үзендә Матбугат министрлыгы бетерелде. Безне, ягъни матбугат органнарын, аларда эшләүчеләрне, Элемтә министрлыгы карамагына тапшырдылар, авылдагыча әйтсәк, «пушта»га беркеттеләр. Матбугат – ничек кенә димәсеннәр, иң әүвәл идеология, тәрбия үзәге. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Матбугат – безнең шартларда дәүләтчелекнең нигезен тәшкил иткән милли идеяне формалаштыручы бер мөһим үзәк тә әле ул. Шуңа күрә элемтә, идеологияне үткәрүдә мөһим бер хуҗалык структурасы булса да, бу очракта рухи әйдәүче ролен һич тә үти алмый.

Хәер, бүгенге артык буталчык сәяси сәнәгать хәлләренә бик артык тирән кермичә, язучының төп хезмәт нәтиҗәсе булган китапка кайтыйк әле. Мәгълүм хакыйкать: китапсыз – язучы юк! Китапка мөнәсәбәт – язучыга мөнәсәбәт, һәм безнең шартларда тарихка мөнәсәбәт дигән сүз. Шөкер, теләгән кеше өчен бүген китап бар. Яхшылары да җитәрлек. Үткән ел, һәм классикадан булсын, һәм бүгенге әдипләр булсын, байтак яхшы китаплар дөнья күрде. Шулай да китап дөньясындагы проблемалар кимемәде. Беренчедән, нигездә татар яшәгән җирдә – авылларда – китап сәүдә системасының җимерелүе сәбәпле, китапларның укучыларга барып җитүе авырлашты. Икенчедән, китап дөньясы үзе бик чуарланды, художество-эстетик кыйммәте булмаган чүп-чар чын җәүһәрләр белән бер шүрлеккә менде (кыргый базар китапка килеп керде, җөмлә төзи беләме-юкмы, акчасы һәм амбициясе булган байтак адәм үзенең язмасын басма итеп тәкъдим итә башлады). Өченчедән, критерийларның югалуы, әдәби тәнкыйтьнең юк дәрәҗәсендә булуы әдәбият белән кызыксынучыларны, бигрәк тә яшьләрне авыр хәлгә куйды. Өстәвенә гомумтенденция – телевидение, компьютер системасы һәм башка замана могҗизалары китапны кысрыклавын да искә алсак, уйланырлык хәлләр күп. Безнең өчен китапны югалту – милли генетик мирасны югалту, киләчәкне югалту дигән сүз ул. Безнең өчен һәр ел Китап елы булырга тиеш. Һәм быелгы бу елыбыз да. «Без китаплы халык!» дибез үзебезне; әгәр ахырзаман килә торган булса, ахыргача китап белән бергә булыйк! Коръән сүрәсендәге сүзләр искә төшә: «Һәр халык үзенең китабы янына чакырылып китерелер...».

Яңа елда языла торган мондый баш сүз-язмалар, гадәттә, «ел буена җитәрлек» дәрт бирә торган оптимистик рухта була. Бәлки, ул шулай кирәктер дә. Минеке күңелләргә беркадәр гамь-шом сала торганрак булып чыкты шикелле. Нишлисең, бүгенге халәтебез, вазгыятебез, күрәсең, шулайрак. Әмма күңелләр төшенке үк димәс идем. «Көл, күңел! Дөнья моңы бер безгә генәмени!» Җанны беркадәр тынычландыра торган бер нәрсә – уртаклык. Ни булса да, ил белән, дөнья белән хәзер. Адәм балалары бер-берсе белән шулкадәр чәбәләнеп бәйләнеп беткән. Дөньяның бер читендәге яра икенче бер полюстагыларның җаннарында сызлау булып иңри. (Чечнядагы сугыш бөтен Россияне яраламадымы?) Бүгенге заманның тагын бер үзгә ягы: күңелләребездәгене ачыктан-ачык әйтә-белдерә алабыз. Шул җөмләдән халкыбыз

язмышы турында да. Әрни-әрни үзебезгә үзебезчә «диагноз» куя алабыз. Димәк, төзәлүгә, терелү-яңаруга өмет бар дигән сүз. (Ә безнең шартларда тулы бер буыннарга бөтенләй тәтемәгән ирек бит!) Әйе, без һәммәбез дөньяга сыналыр өчен яратылган. Һәр аерым затка гына түгел, милләт-халыкларга да карый бу. 2003 ел, һичшиксез, яңа сынау-сыналулар елы булачак. Җиңел булмастыр. Хәер, егылып-торып җиңәргә өйрәнгән халык бит без! Әнә, әле кайчан гына Казанның 800 еллыгы дигәнен күпсенеп үткәрүгә каршы төшкәннәр иде, хәзер 1000 еллыгын үткәрергә әзерләнеп мәш килебез! Моннан 20 еллар элек Кремль диварларыннан Кол Шәриф мәчете кебек гүзәл корылма күтәрелер дип кайсыбыз гына уйлый алды икән! Быел бөтен дөнья татарларының чираттагы конгрессы булачак. Бергә туплану, уртак максатларны барлауда мөһим бер этап булыр дигән ышаныч зур. Быел халык санын исәпкә алу да булачак бит әле. Ничек кенә санамасыннар, җир йөзендә татар кимемәс ул.

Әдәби хуҗалыгыбызда да быел истәлекле бәйрәмнәр, зур юбилейлар, киңәш-оештыру җыеннары узачак. Безнең өчен иң мөһим чараларның берсе ул – «Казан утлары»ның чыга башлавына 80 ел тулу юбилее. Бу дата милли матбугат үсешен күрсәтә торган зур бер әдәби-мәдәни бәйрәм булыр дип уйлыйбыз. Быел шулай ук татар язучыларының чираттагы корылтае узачак. Бу олуг җыенда да әдипләрнең әдәбият турында әдәпле фикер алышулары булыр, киләчәккә бару юллары ачыкланыр дип ышанасы килә.

Өстәп шуны да әйтеп узыйк: журнал үз укучыларын җуймыйча керде бу Яңа елга. Киләчәктә әбүнәчеләребезнең тагын да ишәюе насыйп булсын!

Кешене өмет яшәтә. Өмет ышаныч тудыра, ышаныч хыялландыра. Ә хыяллар тормышка ашса, бәхет шул инде ул. Ә бәхетле кеше илһамланып иҗтиһат итә: балалар тудыра, иген үстерә, йортлар төзи, үлемсез әсәрләр яза. Адәм баласының яшәү мәгънәсе дә Үлемсезлеккә омтылышта бит! «Күңел һаман алгысына – Матурлыкның алгысына!»

*2003*

## *ЙӘ, НИШЛИБЕЗ, ГАЗИЗ КАЛӘМЕМ?*

Йомшак кар явып үткән. Тирә-юнь ап-ак, шундый тын, чиста, пакь... Өстәвенә сихри яктырып ак каеннар тезелеп киткән... Бу аклыкны күңелләргә генә күчерәсе! Авыл өенең тәрәзәсеннән караганда, әнә шундый идиллик манзара. Яшәешнең шушы мәлендә, табигатьнең җанлы бер күзәнәге буларак, аклык эчендә рәхәтләнәсе, талгын гына тибрәнәсе, хәтта эреп югаласы килә... Аннарысы янәдән тереләсең, сабый бала күзләре белән тирә-юньгә карыйсың. Ә дөнья шундый гүзәл! Яшәү шундый бәхет! Тик баштагы уйлар гына менә...

...Янә берәү үз-үзен («камикадзе» диләрме әле?) шартлаткан. Соңгы чиккә җитеп, якты кояш белән хушлашкан. Кемдер аны террорист-бандит, ди, кемдер шәһит-патриот саный...

Вәгъдәләр ярминкәсе – сайлаулар үтте. Алда – яңалары... Аларга киткән чыгымнарны фәкыйрьләргә тотсаң, тормыш бераз яхшырыр иде... Нәни улымның иртән балалар бакчасына барасы килми, киреләнә, күрәсең, «шәхес иреге» кысыладыр. Ә халыкларныкы?.. Нишләптер Страсбург мәхкәмәсе искә төште... Рәссам Әхсән Фәтхетдиновның альбомын шүрәлеләрнең үзләренә дә күрсәтәсе иде, нишләрләр икән?.. Котыплар ел саен әкренләп җылына бара, имеш. Нух пәйгамбәр көймәләре кирәк булмагае... Сәйдәшнең бик матур һәйкәлен күрдем. Төштә. Ә чыны Высоцкийныкы булып чыкты. (Хәер, бу арада, хәтта бер ай эчендә, тагын һәйкәлләр куелды әле: «Бакыр бабай» – Г.Державин торгызылды, Әгерҗедә Т.Гыйззәт бюсты куелды, Кремль эчендә татар-рус осталары истәлегенә сыннар калыкты... Афәрин, хәрабәләр түгел, сыннар калка, тынычлык-иминлек, хәтерлелек билгесе бит!) Борынгы Багдадны янәдән утка тотканнар (моннан мең еллар элек безнең якларга ислам динен юллаган шәһәр!). Бу Америка дигәннәре кайчак теләсә кемне тукмап китә торган яшь, таза, кансыз урам бандитын хәтерләтә... Казаныбызның меңьеллыгы да җитеп килә. Ә бәйрәмгә кадәр башкарасы эшләр бихисап икән!..

Тышта ап-ак кар. Өстәлемдә ап-ак кәгазь. Кеше гомеренең сабый чагы кебек чип-чиста. Йә, синең ярдәм белән, Каләмем, ниләр төшәр икән бу ак кәгазьгә?! Хәер, каләм изгегә тартыр, диләрме әле, вөҗданы булган әдип җанның кешеләр күңеленә ниләр түгәсе мәгълүм инде. Гуманист булу, халкыңның асыл сыйфатларын үстерешеп, гомумкешелеккә хезмәт итү,

киләчәк буыннар язмышы өчен җаваплылык тою, үз чорыңның һәм халкыңның игелекле баласы булу... Мөмкин эшме бу? Әдәбиятның алтын гасырлары үтте түгелме? Үзен алыштырырлык роботлар ясаган, алай гына түгел, клонлаштырып, теләгән җан иясен укмаштырыр сәләткә ия XXI гасыр затлары өчен эмоциональ әдәби сүз, образлы сурәт кирәкме? Җәмгыятьтә әдәбиятка ихтыяҗ бармы? Ак кәгазьдәге язу буразналарын без дөрес сөрәбезме, Каләмем? Моннан йөз еллар элек тикмәгә генә әйтмәгәндер бит шагыйрь: «Шигырь бүтән дә, дөньяны әйләндерә торган чыгыр бүтән!» Гомумән, гуманлы әхлак хасмы бу заманга? Чыннан да, акча кодрәте белән дөнья чыгырын әйләндерүче идарә көчләр (алары да күктән төшмәгән, шул бер камырдан әвәләнгән адәмнәр ләбаса!) Кешелек дөньясы моңарчы тудырган хикмәтле китаплардан, аларда тупланган акылдан гыйбрәт-сабак алсалар, ахырзаман галәмәтләренә охшаш вәхшилекләр, сугышлар, геноцидлар, янау-талаулар, җәбер-золымнар, ашкынып коралланулар шаһиты булыр идекме? «Әй наив җан! – дияр кемдер, – каргалар шигырь укыса, күгәрчен булыр иде!»

Шулай да оптимист буласы килә. Эчке тоемым белән әдәбиятыбызның киләчәгенә өмет белән карыйм, аның үзенә йөкләнгән тарихи миссиясен югалтмаячагына ышанам. Әлбәттә, нинди генә көчле әдәбият булмасын, ул барыбер замана басымына дучар. Тамыры булмаган әдәбият юкка да чыгарга мөмкин. Зур традицияләргә, бай мираска ия булганнары тиз генә югала алмый. Элегрәк Җир шарының алтыдан бере дип исәпләнгән киңлекләрдә әдәбиятыбыз иң борынгылардан исәпләнә. Китап рухы – безнең геннарда. Әдәби сүз культурасы бүген дә югары дип исәплим мин. Әйтик, «әдәбият әнкәсе» саналган шигъриятебез дөньядагы теләсә кайсы халык шигърияте белән ярышырлык хәлдә. Проза яки драматургия жанрларында да югары сәнгать әсәрләре җитәрлек... Киләчәк турында уйланганда, иң кирәкле төп сорау туа: бармы бездә бүген талантлы язучылар? Иҗади учаклар дөрлиме? Аңлашыла торган табигый сорау. Кистереп «бар!» дип әйтер идем. Шөкер, әдәбиятыбызның горурлыгы саналырлык дистәләгән менә дигән язучылар, шагыйрьләр, драматурглар бар. (Дөрес, гасыр алышынган елларда байтак могтәбәр әдипләребезне югалттык. Ә.Еники, Г.Бәширов, М.Мәһдиев, Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Т.Әйди, Ш.Хөсәенов, Г.Афзал... Алар белән тулы бер чор, кабатланмас дөнья китте! Һәрчак сагындырачак шәхесләр!) Исемнәр атау гаять четерекле, үпкә-сапкага сәбәп хәл булса да, әйтелгән сүземә дәлил итеп, бүген исән-имин иҗат итүче кайбер каләмдәшләрем турында искәртеп китәм. Туфан Миңнуллин. Ул – бүгенге көннең иң абруйлы аксакалларыннан берсе. Хезмәте зур, иманы нык, холкы гаярь, дәрәҗәсе югары. Ә Нурихан Фәттах? Үткән әдәбиятыбызда мондый тарихчы әдип булдымы икән әле? Илдар Юзеев. Берничә буын шигырь сөючеләрнең Такташ кебек кумиры булып кара әле! «Без Фәнис Яруллинлы әдәбият» дип горурланып әйтә алабыз. Хезмәте белән кеше рухының бөеклеген раслаган язучы ул... Айдар Хәлим. Мондый публицист белән теләсә кайсы әдәбият горурланыр иде. Кирәксә – шигырьне, кирәксә прозаны коеп куя... Күпкырлы иҗаты белән поэзия, җыр, төрле музыкаль жанрлар, гомумән сәнгатьнең байтак төрләрен үстерүгә зур өлеш керткән Ренат Харис... Диңгезен, күген иңләп чын ир-егет булып яшәгән, тематик яктан әдәбиятыбызны баеткан Миргазиян Юныс... Иҗатлары белән үз шигъри дөньяларын тудырган, шул дөньяга байтак укучыларын кертә алган, шәхес буларак та үзләре үк бер кызыклы дөнья булган олуг шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов... Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, сүзләре үзләренә табигый ябышып торган, халык арасында популяр каләмдәшләребез Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим... Иҗаты һәм эшчәнлеге әлегә тулы бәяләнеп җитмәгән, эпик киңлекләрдә тирән сөрә алырлык фәлсәфи шагыйрь, матбугат хадиме Зиннур Мансуров... Кабатланмас стиле, юмор-сарказмы белән алыштыргысыз Марсель Галиев... Тәнкыйтьтә дә, прозада да ат уйнатучы олпат галим Тәлгат Галиуллин... Үзләренең публицистикасы белән күпләргә үрнәк булырлык Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла. Ә бит алар иң әүвәл кызыклы шагыйрьләр. Икенчесе өстәвенә менә дигән прозаик та... Шул ук буын вәкиле – Зиннур Хөснияр. Потенциаль мөмкинлеге зур булган прозаик, нәшер эшләрен заманча оештыручы уңган мөхәррир... Соңгы елларда әдәбиятта феномен саналырлык Мөслим егетләре төркемен кая куясың?! Флүс Латыйфи, Зөлфәт, Фоат Садриев, Харрас Әюп, Факил Сафин, Наис Гамбәр... Русча язып та, татар мәнфәгатен кайгыртып яшәүче язучыларыбыз – Рафаэль Мостафин, Рауль Мир-Хәйдәров, Равил Бохараев, Локман Закиров... Ир-атлар да көнләшерлек иҗат итүче Фәүзия Бәйрәмова, Нәбирә Гыйматдинова, Флера Гыйззәтуллина, Клара Булатова... Бөтен яктан да ил агасы саналырлык,

татар тарихы буенча энциклопедик гыйлемгә ия Миркасыйм Госманов. Милләтебезнең уникаль шәхесләре Рабит Батулла, Зәки Зәйнуллин. Яшьрәкләрдән – Рамис Аймәт, Луиза Янсуар... Берничә исем белән чикләнермен дигән идем дә, өч дистәдән артык исем саналган. Иҗатлары зур булган каләмдәшләребез, шөкер, байтак. Исемлекне тагын дәвам итәргә була. Әйтик, халык шагыйрьләре, халык язучылары исәбенә дә... Югарыда искә алып киткән каләмдәшләр үзләре дә бик төрле, бик катмарлы халык. Арада карашлары, холыклары, иҗат алымнары буенча берсе белән берсе сыеша алмый торганнары бар... Нишлисең, иҗат мәйданы шулай булырга тиештәдер. Шул төрлелек белән кызыклы һәм көчледер дә әле без. Безгә бергә, бердәм булмый ярамый. Төрекләрдәге мәгълүм сүзне үзебезчәләтеп болай дибез: татарның татардан башка дусты юк...

Димәк, әле базда дары бар! Ә укучылар бармы соң? Дары юешләнеп эштән чыкмасын өчен шарт – коры урын, ышык-ныгытма, учак дөрләсен өчен утын, аның өчен урман кирәк. Язучы өчен укучы кирәк. Алдыңда торган килеш, сырхау тәнеңә ризык үтмәсә, Галиябану кебек сылу булып үсеп тә, ярың табылмаса, бөек җыр туып та, аны башкаручы булмаса?.. Сер түгел, ни кызганыч, татар китабын укучылар кими бара (дөрес, юлын табып, авыруга укол ясаган шикелле, кешеләр күңеленә вакытында «китап вирусы» сала алсаң, күпләр, файдасын күреп, рухи савыгып, рәхмәтләрен әйтәчәкләр). Моннан ун еллар элек тикмәгә генә мондый юллар язылмагандыр:

Кичәрләр дип, озак еллар күпер салдым,
Эш беткәндә карап баксам, елгам кипкән...
Нур чәчәм дип, гомер буе җырлар яздым,
Томнар чыккач, карыйм: укыр җаннар беткән!

Ни өчен? Чөнки үз дәүләтең юк. Телебез декларатив рәвештә дәүләт теле саналса да, асылда ул үз функциясен үтәми. Телнең иясе – халык, хуҗасы – дәүләт. Нинди имля-графикада язасын да бүтәннәр хәл иткәч, чамалап була... Өстәвенә йотылу, ассимиляцияләшү процессына интеграция, глобальләштерү кебек замана хикмәтләре килеп кушыла... Социологик анализлар ни күрсәтәдер, белмим, минемчә, элек караңгы дип саналган Россия империясендә – Себердә, Идел буе төбәкләрендә, Азиядә – татарча сөйләшүчеләр күбрәк булган. Тел булгач, нигез-тамыр булган, шаулап тормаса да, рухи шытымнар булган. Ә хәзер?..

...Авыр сорау тугач, кәгазь буйлап йөгерек кенә барган Каләм арыган ат кебек тукталып кала. Мин дә урынымнан торып йөренеп алам. Тәннәр язылып китә. Янәдән тыштагы идиллик күренешкә карап торам. Гаҗәп: көч кереп, уй яктырып китә!

Миллилекне билгеле торган кайбер сыйфатлар югалып барса да, гомумән, җир йөзендә татар кимемәде дип уйлыйм. Бетә торган милләт түгел бу! Күбрәк сәясәт уенына корылган, дөрес үк булмаган җан-исәп алу буенча да хәйранга чыга әле ул! Татарны тикмәгә генә яһүдләр белән ярыштырып тиңләмиләр шул. Яһүдләр дигәннән, гыйбрәт-сабак алырлык охшашлыклар да бар бит. Һәр икәве дөнья буйлап сибелгән, байтагы телен җуя баруга дучар ителгән, гасырлар буе геноцид кичергән... Һәм шул яһүдләр, бер көн җыелып (әле бик ерак тарихта түгел, моннан 60–70 ел элек кенә), дәүләт кордылар, югалган дип әйтерлек алфавитларын торгызып, телләрен яңарттылар, бөтен дөньядан җыйган малларын милли байлык итә алдылар. Бу, мөгаен, гомумтарихта чыгарма хәлдер. Ә начар чыгармамыни?! Гаҗәп үзенчәлекле тарихи катаклизмнар кичергән татарның, чыгармалымы, чыгармасызмы, нигә үз юлы булмаска тиеш ди әле. Милли идеягә, югары үзаңга, олы максатка, бердәм хәрәкәткә ия чакта булмастай нәрсә юк ул! Әлбәттә, иң мөһиме – үзаң. Үткән гасырның совет дәверендә (кайбер халыкларның тәрәккыятен таныган хәлдә) үзаңы үсешенә иң нык киртә куелган халык, мөгаен, татар булгандыр. Чын мәгънәсендә торгынлык (бу сүз безгә бик туры килә) чоры. Шөкер, соңгы дистә елларда, үзаң терелеп, милли яңарыш башланды. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән сорауга анык җавап табылды. Ул уянган! Дәлилләрме? Уяну халәте булмаса, төрле кыйтгаларда яшәүче милләттәшләребез уртак мәсьәләләр турында фикерләшергә берничә мәртәбә Бөтендөнья татар конгрессына җыела алырлар идеме? Меңнәрчә мәчетләрнең манаралары кораб-ракетадай күккә төбәлер идеме? Милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә уртак бәйрәм – сабантуйлар гөрләп үтә алыр идеме? Соңлап булса да Урал буйларында (соңрак Башкортстан дип йөртелгән төбәк) яшәүче

татарларга игътибар артыр идеме (ә бит бу төбәктә татарның бик зур потенциалы)? - Республика көне оештырылыр идеме? Туган тел бәйрәмнәре (халык бәйрәме дәрәҗәсенә күтәрергә иде бу бәйрәмне. Латышлардагы «Җыр бәйрәме» кебек) үтәр идеме?..

Әйе, халык булып киләчәктә сакланып калу юнәлешендә җәмгыятьнең төрле катламнары арасында билгеле бер уңай аңлашу бар. Зур нәрсә бу. Җитәкчелек белән халыкның берлеге нәтиҗәсендә 90 нчы елларда кайбер биеклекләр яуланды да... Шул нисбәттә пропорциональ каршылык та җитәрлек. Хәтта артыгы белән. Шовинистик даирәләр (күрелмәгән хәл: матбугатта һәм радио-телевидениедә кайбер партия вәкилләренең ачыктан-ачык расистик, фашистик рухтагы чыгышлары еш булып тора хәзер) Россиядә рустан тыш милли факторны бөтенләй үк юк итмәкчеләр. Алда бераз әйтелгәнчә, бу мәсьәлә дөнья күләмендә җитди төс алды. Әйтик, Америка бөтен Җир шарын үзенчә әйләндермәкче. Синең телең, рухың, тарихың кирәкме аңа (әнә Иракны нишләттеләр! Кеше хокукларын яклау кирәкме? Юк, нефть кирәк! Бай Америкага тагын да күбрәк байлык кирәк!)? Бөтен дөнья халкын идентификацияләп, компьютер белеме (дөресрәге, үзләренә кирәк информация җыеп) биреп, алардан интеркосмополит көч – робот-коллар ясап, җиһангир булу, дөнья белән идарә итү кирәк. Һәр кеше код – «шөреп» исәбендә булгач, аларны автоматик рәвештә юк итү технологиясен эшләү дә җиңеләя бит!

Менә кайларга кереп киттең бит әле, газиз Каләмем! Сүз башы гадирәк – әдәбият хәлләре турында иде бит. Башы шулай иде дә, ә дәвамы, төбе әнә нәрсәләргә килеп чыкты. Милләт язмышы, балаларыбыз язмышы, тел язмышы... Бу хәл табигый дә. Әйтик, тел – минем эш коралым, ахыр чиктә яшәү чыганагым, язмышым... Тел – милләтне билгеләүче иң төп компонент. Ягез, туган телләреннән башка французны, немецны яки японны күз алдына китереп буламы? Юк, билгеле. Бу канун җирдәге бөтен халыкларга да кагыла бит! Ә телнең бакчасы ул – мәгълүм хакыйкать – Әдәбият. Кайчандыр дәүләтләрен югалткан, әмма яңарышка өметләнгән халыклар өчен бу бакча – Әдәбият – аеруча әһәмияткә ия. Аңа дәүләти институтлар башкарырга тиеш булган кайбер идеологик вазифалар да йөкләнә. Әйтик, бездә дәүләтчелекне тою хисе дүрт-биш гасыр буе югалмаган икән, иң әүвәл без Сүзгә, Язуга, Әдәбиятка бурычлы. (Дин факторын да исәпләми мөмкин түгел. Әйтик, телне, әхлакны саклауда аның роле ифрат зур. Соңгы вакытларда мөселманнарның да кайберләре Коръәнне дә русча укып өйрәнүләре генә сәеррәк.) Бәс, шулай булгач, Әдәбиятны саклау турыдан-туры милләтне саклау булып чыга түгелме соң? Бер шагыйрь әйтмешли, «ул шулайдыр әле, уйласаң»! Чыннан да шулай. Әгәр әдәби сүз бетсә, милли сәнгатьнең бүтән төрләре дә юкка чыга. Иң әүвәл театр бетә, музыка, рәсем һәм башка сәнгатьләр дә, табигый сүлен югалтып, космополитик дәрьяда эри, югала...

Менә шулай, газиз Каләмем! Син кодрәтле дә, хәвефле дә, көч тә бирәсең, исәп-хәсрәткә дә батырасың. Ил теленнән сүз җыеп, арыган чакларың да буладыр... Язучының эш нәтиҗәсе – Китап. Китап – әдәбиятның таҗы, язучының йөз аклыгы. Бездә гомер-гомердән Китап сүзе дигән төшенчә яшәп килә. Китап сүзе, ягъни кануни сүз. Коръәннең бер сүрәсендә «кыямәт көнендә һәр халык үз китабы белән кубарылыр» дип тә әйтелгән бит әле! Без үскәндә, һәр җәмәгать урынында, үткән гасыр термины белән әйтсәк, һәр кызыл почмакта, «Китап – белем чишмәсе» дигән шигарь-язулар эленеп тора, яше-карты шул өндәмәгә тугрылыклы булырга тырыша иде. Кызганыч, идеяләр, идеаллар үзгәрә-үзгәрә, акчага табыну иманга әверелә барган заманда хәлләр нык үзгәрде. Елында түгел, гомерендә бер генә татар язучысының китабын да укымаган (хәтта тәрҗемәдә дә!) бәндәләр ишәйде. (Шунысы көлке: шундыйларның кайбер активистлары татар зыялыларына нинди алфавитта язарга өйрәтеп маташа!) Татар мәктәбен бетереп, татар мохитендә яшәп, бүгенге әдәбияттан бөтенләй бихәбәр эреле-ваклы түрәләр ничаклы! Бер генә данә «Казан утлары»н алмаган татар авыллары бар. (Сүз уңаеннан әйтеп узыйк, Кама аръягы, Тау ягы районнарында әдәби журналлар, шул исәптән безнең журнал да начар тарала. Нәтиҗәсе хәзер үк күренеп тора: бу якларда яшь әдәби талантлар күренми диярлек. Димәк, җирле түрәләр, мәгариф һәм мәдәният җитәкчеләре тарафыннан әдәбиятыбызга мөнәсәбәт шуның кадәрле генә.) Хәтта әдәбиятның, бигрәк тә бүгенге әдәбиятның көзгесе булган журналыбызны кулына да алмаган татар теле һәм әдәбияты «укытучылары» бар. Әйе, «юк»тан да яманрак әнә шундый «бар»лар да җитәрлек шул. Вазгыятькә фаҗигаи төсмер бирергә теләмим. Сүз тәмен тоючылар, китап кадерен белүчеләр, әдәбиятның тәрбияви ролен тирән аңлаучылар да байтак. Шигырь

юлларын ташка, агачка чокып уючы ир-егетләребез, сүз энҗеләрен кулъяулыкларга, сөлгеләргә чигүче кызларыбыз да яши арабызда. Шөкер, туган телдә бишек җырларын көйләп, сабыйларын юаткан аналарыбыз бар. Дәүләткүләм бәяләргә лаек яңа әсәрләребез бар. Әмма...

Әгәр без бердәм булып Әдәбиятны (китапны) милләтне саклауда һәм үстерүдә иң төп чыганакларның берсе дип санайбыз икән, вазгыятьне һич кенә дә үз агымына куя алмыйбыз. Планета коммуникаль бәйләнеш ягыннан «кечерәеп» һәм «ачыгаеп» калганда (кирәксә, космостан авылдагы өеңнең морҗасын да күрәләр бүген!), халыкара аралашу тәртипләре, алда әйтелгәнчә, аз санлы яки державага ия булмаган халыклар өчен торган саен кырысрак, рәхимсезрәк төс ала башлады. Без Г.Исхакый юраган инкыйраз рас киләме-юкмы дип яки «уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк» җырын шыңшып, тез кочаклап, оеп утыра алмыйбыз. Максатчан актив хәрәкәт кирәк. (Җан башына туган телдә чыккан китап исәбе бездә алдынгы илләрдәгенекеннән шактый түбән икәнен дә онытмыйк!) Күрәсең, милли китап үсешен тәэмин итәрлек дәүләти махсус Программа булдыру зарурдыр (әйтик, тузган торакны бетерү кебек нәтиҗәле Программа). Китап чыгару, китап тарату, гомумән наширлек эше сәясәтен үз кулында тоткан махсус координацион Үзәк кирәклеге үзен бик нык сиздерә. (Дәүләт структураларында эшне белеп алып баручы милли рухлы җитәкче кадрлар җитенкерәми әле. Совет заманындагы кайбер эш алымнарының тәҗрибәсен өйрәнү дә һич комачау итмәс иде бүген.) Әлеге Үзәк (ничек дип аталуына карамастан) реаль ихтыяҗны өйрәнеп (элек нәшриятның тематик планнары буенча җирле оешмалардан реаль заказлар җыйнала иде, тираж комиссияләре эшли иде), мөмкинлекләрдән чыгып, халык ихтыяҗларын үтәү, тиешенчә тәэмин итү вазифаларын да башкарыр иде...

Гомумән, татар китабы – газаплы, авыр язмышлы, данлы тарих. Башлангычы да (XVIII гасыр башында басмаханәләр ачарга рөхсәт алгандагы кимсетелүле хәлләр турында мәшһүр галимебез Ә. Кәримуллин тәфсилләп язып калдырды), бүгенгесе дә... Язучы һәм башка сәнгатькяр дә, үз эшенең киләчәккә кирәклеген тоймаса, эшли алмый, иҗат итә алмый. Әдәбият-мәдәният өлкәсендә хәл итәсе мәсьәләләр күтәрелгәч, гадәттә, «базар» дигән сүз калкып чыга. Базар мөнәсәбәтләре хәзер, барысын да шул хәл итә, базар шартларында яшәргә өйрәнегез, диләр. Элек тә булган ул базар. Бар һәм булачак. Исәпләшми булмый: яшәешнең матди бер «чыгыры» инде ул. Әмма базарга иман кирәкми. Базар ансыз да яши. Ә кешегә кирәк, кешегә күп нәрсә кирәк. Җанлы сүзе дә, агымлы көе дә, күңел байлыгы да... Байлык димәктән, узган гасыр башында да булган ул байларыбыз. Булган төрлесе, булган мәгърифәтлеләре, булган «каралары». «Ак» байлардан хәтер булып мәдрәсәләр, мәчетләр, китапханәләр калган. Ә фәкать мал өчен генә яшәгәннәренең исемнәре дә нәмәгълүм диярлек. Тирәнтен уйлап баксаң, татарның төп байлыгы фәкать рухи мирас кына. Җырлар, көйләр, китаплар... Безгә мирас булып калган рух байлыгын тудыручыларны кемнәр ничек кенә санаса да, барыбер исемнәр бер тирәдә булыр. Алар – Тукай, Исхакый, Сәйдәш, Җиһанов, Урманче... Хәер, империя шартларында бүтән байлыкның, матди милли байлыкның, дип әйтүем, булуы да мөмкин түгел бугай (әнә Мәскәүдә Әсәдуллаев йортын татарлар һаман үзләренеке итеп бетерә алмыйлар әле). Ә бүгенге зур хосусый байлыкларга ия яшь байларыбызга килсәк, алар турында ниндидер фикер, бигрәк тә уңаен әйтергә иртәрәк әле. Күбесендә – «кыргый базар» шаукымында гади халыкның «күзен буып», алдап-йолдап җыйналган байлык. Капитал туплауның да үз кануни традицияләре, үзенә генә хас этик кысалары, әйтер идем, үз культурасы бар. Киресенчә икән, димәк, исраф итү культурасы да юк дигән сүз. Хәрам кергән малның, гадәттә, бәрәкәте булмый, тиз әрәм-шәрәм ителә яки «этләргә» кала... Бу хакта сүз куертып та тормас идек тә, юк шул, китап чыгару өчен дә чыгымнар, байтак чыгымнар кирәк. Ярый да хәзергә дәүләт өлешчә булыша, ә беркөн килеп андый мөмкинлек бетсә яки «бик өстән» бетерттерелсә? Ирексездән меценатлык мәрхәмәтенә өмет тотачаксың. Ә бармы соң ул бездә меценатлык? Меценатлык дәрәҗәсенә күтәрелер өчен, малтабар кеше үзе дә күңеле белән күпмедер дәрәҗәдә шагыйрь, музыкант, рәссам, артист булырга, һәрхәлдә, рух дөньясын, сәнгатьне тоярга, аңларга тиеш. Кайда сез, бүгенге Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Кәримовлар, Юнысовлар, Акчуриннар?

Сәнгать әсәре кем өчендер товар. Әйе, бер караганда, товар да. Оста тарафыннан бердәнбер данәдә ясалган (язылган) бәһале товар. Китап рәвешендә меңнәрчә тираж белән

чыгарылганнары чыннан да товар. Шул ук вакытта ул товар да түгел. Бөек әсәр бәясез ул! Уй-кичерешләрне, шатлык-кайгыларны үлчәр берәмлек юк.

Ике хәзинә бар дөньяда, саклагыз!
Каберстан – аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә – икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

Бүгенге көндә гомерен язучылык эшенә, әдәбиятка багышларга алынган кеше – фидакарь зат ул! Әшәкелек күзгә кереп торган заманда якты шигырь язу үзе бер батырлык! (Дөрес, кайбер спектакльләрдә, аерым әсәрләрдә – аңлапмы-юкмы – шагыйрьне ниндидер зәгыйфьрәк зат, наив, беркатлы итеп күрсәтүчеләр дә очрый. Күрәсең, андый иҗатчылар чын шагыйрьне белмиләр.) Үзен зур миссиягә әзерләгән кеше генә чын язучы була ала. Кемнәрнеңдер күзлегеннән караганда, яшәештәге рейтингы зур булмаса да, бай һәм тук яшәмәсә дә, шушы хаос, имансыз заманда халык күңеленең елъязмачысы, алай гына да түгел, халык рухының байракчысы булырга омтылу пәйгамбәрләргә хас сыйфат. Тарихи җаваплылыкны, авыр миссияне кемнәрдер алырга тиештер бит! Кемнәр соң алар? Җирле хакимият түрәләреннән берәрсеме? Депутатмы? Банкирмы? Шикләнәм...

Газиз Каләмем! Хискә бирелебрәк салулап китмәдеңме? Артык катгый сүзләр тезәсең түгелме? Халык рухының байракчысы!.. Бик зур сүзләр бит... Бәлки... Хезмәтең язмышыңа әверелгәндә, сайлаган юлыңны идеаллаштыру да булырга мөмкиндер. Әлбәттә, тарихи миссия кебек категорияләр белән сөйләгәндә, Шәхес факторы алга баса. Шәхес юк икән, әллә нинди юл, әллә нинди профессия сайла, һични барып чыкмас. Шәхес бар икән, яшәеше тормыш үзәгендә булып, халыкның иң мөкатдәс теләкләрен эшкә ашырып, киләчәк өчен бөек гамәлләр кыла икән, андый Шәхеснең байракчы саналуы гаҗәп түгел. Әйтик, Президентыбыз М.Ш.Шәймиев соңгы дистә елларда татар халкының байракчысы түгелмени?! Җир шарының төрле почмакларында ул халык вәкиле, аның илчесе булып татарны танытмадымыни? Шулай, Вакыт галиҗәнаплары билгеле бер илнең, билгеле бер дәвернең символ ияләрен үзе сайлый.

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.
Вакыт-Яу – иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны.
Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
данлы исемен алып кала.

Булды заманнар, теге яки бу халыкның байрак-символы итеп бөек шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, сынчылар, гомумән сәнгать кешеләре саналды. Итальян Данте, испан Сервантес, әзәри Физули, рус Пушкин, украин Шевченко кебек даһиларны искә алып китик тә, үзебез яшәгән чорда иҗат иткән, үзләре белән беркадәр аралашырга да туры килгән бөек язучыларның кайберләрен барлап узыйк. Алар да шул когортадан!.. Дөнья алдында үз халыкларының тулы вәкаләтле вәкилләре, илчеләре. Кыргыз Чыңгыз Айтматов, авар Рәсүл Гамзатов, калмык Давыт Көгелтинев, рус Александр Твардовский, башкорт Мостай Кәрим, казакъ Олжас Сөләйманов... Ә үзебезнең Тукай, Җәлил шул миссияне башкармадымы? Шөкер, маяк саналырлык үрнәкләр бар. Булган һәм булачак алар. Шәхес кенә бул, үлемсез әсәрләр генә иҗат ит! Вакыт кояш астындагы тарихи урыныңны үзе билгеләр ул!

Язучы исеме, язучылык хезмәте моңа кадәр һәр халыкта да дәрәҗәле саналды. Ерак гасырлардан бирле. Ул шагыйрь дип аталамы, чичән яки акынмы, халык аларны үз итте, хезмәтләреннән гыйбрәт-сабак алды, әйткәннәрен күңелендә йөртте, мирас-васыять итеп балаларына сөйләде... Килешмәгән, хәтта дошман очракта да хаким-хөкемдарлар санлашырга, исәпләшергә мәҗбүр булды алар белән. Юкса шагыйрьләрне хандай зурламаслар яки иленнән сөрмәсләр иде, төрмәләрдә черетмәсләр, асмаслар-кисмәсләр иде! Шулай да дөнья гел хәрәкәттә, гел әйләнештә. Мәңгелек дип саналган аксиомалар да үзгәреш кичерә. Язучы дигән атамада да мәгънәви үзгәрешләр бар. Инглизләрдә «writer» (райтэ) сүзе «язучы» дип тәрҗемә ителсә дә, мәгънә спектры үзгәрәк... Монысы бер хәл булса, үзебезнең халыкта да «язучы» сүзенә караш беркадәр үзгәрә башлады кебек. Сәбәпләре бар. Мәгълүм гыйбарәне үзгәртебрәк

әйтсәк, «килде бер көн, язучылар йөрер төркем-төркем». Дөресрәге, үзләрен язучы санаган графоманнар армиясе нык ишәйде. Андый төркемнең булуы гаҗәпләндерми дә, һәрчак булган алар (хәтта булырга тиешләрдәдер), ләкин пәри башка, җен башка дигәндәй, элек алар, гадәттә, үзешчән статусында иделәр. Көндәлек матбугатта, күмәк җыентыкларда басылгалыйлар иде, әдәби мохитнең күренеш-фонын тәшкил итәләр иде. Ә хәзер... күбесенең амбицияләре бөтенләй бүтән! Акча юнәтеп (өлгер, булган халык!), төрле басмаханәләрдә бер-бер артлы китапны чыгарып кына торалар! Калын итеп чыгаралар, яхшы кәгазьдә, матур бизәкле итеп... Аннан Язучылар берлегенә керүне максат итеп куялар. Язучылык билеты чын язучы итә дип уйлыйлардыр инде (әнә, кесәсендә язучы билетын йөртмәгән, Оешмада рәсми әгъза булып тормаган З.Хәкимнән Бөтендөнья татарлары конгрессында барлык язучылар, гомумән интеллигенция исеменнән чыгыш ясавын сорадылар, һәм ул менә дигән нотык тотты). Өстәвенә бу «актив язучылар»ның күбесе иҗат эшенә пенсиягә чыккач тотынган иптәшләр. Әйдә, җаны теләгән елан ите ашаган, язсыннар рәхәтләнеп, дияр идең дә... Алай да булмый. Халык алдында әдәбиятның дәрәҗәсе төшә, китапның абруе кими. «Кар башына кар җитә» дигән гыйбарә бар; шуның кебек, эшләр болай барса, «китап башына китап җитә» диярсең! Чүп үләне баскан басуны күргәнегез бардыр, кайда бодай анда, кайда сарут та билчән... якын килеп карамасаң, белмәссең дә,ерактан һәммәсе ямь-яшел булып үсеп тора!

Әдәби мохит, китап дөньясы чүпләнүнең икенче бер әшәке формасы да бар әле бездә. Ул кеше өстеннән әләк, шикаять, донос язу. Нинди генә негатив фактлар табылмый да кайларга гына (министрлыкларга, прокуратураларга, төрле дәрәҗәдәге президентларга...) язылмый алар! Дәүләт структураларында интеллектуаль өлкәдә аннан башка да бик аз сандагы җитәкче хезмәткәрләрнең күпме вакытын, күпме җегәрен ала ул «гаделлек сагында» торучы яла ягучылар! Мәхкәмәләргә дә тынгылык юк, процесс арты процесс... Әлбәттә, әдип кеше, талантлы кеше шөгыльләнми моның белән. Ул кирәген, күңелендәгесен ярым аноним шикаятьләр белән түгел, кешеләргә турыдан ярып әйтә. Шикаятьчелек белән әлеге дә баягы көнләшү катыш амбициядән чирләүче, русча әйтсәк, окололитературный контингент шөгыльләнә дә инде. Бу чир, кызганыч, галим-голәма арасында да җитәрлек икән. Бер-берсен хурлаган, хәтта дошманлашу дәрәҗәсендә ярсыган бәгъзе адәмнәрнең матбугатта (татарча гына җитми, күбрәк русча матбугатта «бугазлашалар», ишлерәк кеше укысын, татарның үзара талашын күбрәк кеше белсен!) чыккан язмалары укшыта кайчак... Кораб давыл-штормда бату хәлендә чайкалганда, кемнәрнеңдер «каюташханәдә тиешенчә ашатмыйлар, компотка җимешне җитәрлек салмыйлар» дип, коры җир – материкка жалу язуы белән бер бу гамәлләр. Күрәсең, рух-иман юлында, «кеше җаны өчен көрәш»тә, акыл-фикер бәрелешендә шайтан вәсвәсәсе булмый калмыйдыр. Иблис тә фәрештә санала түгелме соң? Бер яктан, әлеге тискәре күренешләр бик аяныч булса, икенчедән, язу эшенең, иҗат эшенең күпләр өчен никадәр кызыктыргыч мөһим, никадәр җаваплы һәм дәрәҗәле миссия икәнен дә күрсәтә. Ширбәте булган чәчкә тирәсендә генә бал кортлары оча, шулай ук чебен-черкие дә...

Иҗат итү – илаһи халәт, кеше акылының җиңүле тантанасы. Иҗат – илһам дигән күңел дәрте белән бәйле рухани акт. Шуңа күрә үтә индивидуаль, серле, тылсымлы шөгыль дә инде ул. Галимнәр арасында бөекләрнең иҗат лабораториясенең хикмәтләрен ачарга омтылучылар бар. Әлбәттә, иҗатның кайбер тенденцияләрен, алымнарын, стиль рәвешен һ.б. ачыкларга була. Әмма кош юлының эзен «тотып» булмаган кебек, иҗат процессының төбенә төшү дә мөмкин эш түгел. Еш кына автор үзе дә бер нәрсә турында язарга тотынып, башта уенда да булмаган әллә нәрсәләргә килеп чыга... Хикмәт! Шулай да Әдәбиятта сер булмаган тәртипләр, кагылгысыз традицияләр дә бар. Әдәбиятта иң элек әдәп булырга тиеш. Әдәбият багына, гыйбадәтханәләргә кергән шикелле, чиста күңел, изге уй белән керү мөһим. Бу бакчага кергәннәр нәрсә яхшы, нәрсә яман, нәрсә ярый, нәрсә тиеш түгел кебек сорауларга җавапларны алдан ук белеп керергә тиешләрдер. Сүз эстетик идеал, әдәби этика, профессионализм кебек төшенчәләр турында бара. Хәзер, сүз иреге дип, теләсә нәрсә турында теләсә ничек язгалаучылар барлыкка килде. Әдәбият бүген генә яралмаган, үткән юлы аның әллә ничә мең еллар. Татар әдәбиятының традицияләре дә, Аллага шөкер... Укы, бел, гыйбрәт ал. Әлбәттә, әйтелгәнчә, читтән яки өстән кушып, диктат белән иҗат итү мөмкин түгел. Өндәмә белән генә булса, совет чорында партиянең «әдәбият-сәнгатьне үстерү турында» чыккан бихисап карарларыннан соң әллә никадәр шедеврлар туар иде. Иҗатны стимуллаштырып була. Конкурслар, иҗади ярышлар, фестивальләр, премияләр... Әдәби

хәрәкәтне идарә итү (элек без ышанганча) мөмкин үк булмаса да, булган әдәби байлыкны анализлап, орлыгын кибәктән аерып, халыкка аңлатып, яшь талантларга булышып була. Бар әдәби җәмәгатьчелек, бар иҗади оешма, бар әдәби профильдәге журналлар... Бу өлкәдә һәммәбезгә дә эш җитәрлек. Бу корылтайлар, семинарлар, утырышлар кебек компания рәвешендә генә түгел, әдәбиятта үз җаваплылыгын тойган һәркем өчен көндәлек даими эш булырга тиеш.

...Алдымдагы кәгаземнең байтак битләре шыплап тулды. Ә тәрәз алдымдагы күренеш һаман шул: ап-ак килеш. Дөньяда Яңа ел икән бит! Күпләр шуның хозурында. Күңелем белән үзем борын заманнардагы ерак бабаларым көтеп алган Яңа ел – Нәүрүз ягында. Яңа елның яз булуы табигый. Шәрык илләрендә ул шулай да. Яз, чыннан да, яңа фасыл булып, яңарыш циклын башлый. Җиргә орлык чәчелә, кошлар кайта, табигать уянып, яшелләнә, күңелләргә яңа дәрт өстәлә, өмет-ышаныч арта. Зәмһәрир кыш уртасында, суыклар, бураннар котырган көннәрдә, менә, апай, пәрәмәч! дигәндәй, менә сиңа Яңа ел! Вакытны болай сындыру мизгелен шартлы рәвештә биле өзелергә җиткән кыска көннең тулыша башлау вакыты дип аңлатсаң гына инде... Хәер, аны Раштуа, Христос тууы белән бәйлиләр, европалылар гадәтен Россиягә Петр патша керткән, диләр. Шулайдыр. Күбебез бу хакта уйламый да инде. Яңа ел тек Яңа ел. Яшәгән дөньяң, бөтен тирә-юнең гөрләп мәш килгәндә, бәлки, безгә дә, бәйрәм рәвешен китереп, бераз ял итеп алырга ярыйдыр?

Шулай дип яздым да тәрәзәдән күренгән тышкы аклыкка карап алдым, аннары янәдән алдымда яткан кәгазьләремә текәлдем. Йә, нишлибез, газиз Каләмем? «Җиң сызганып эшлибез» дисеңме? Әйдә, шулай булсын!

*2004*

## *ЯЗУЧЫЛАР ӨЧЕН ДӘ МӘКТӘП БУЛДЫ*

Казан университеты кемнең дә булса данлавына мохтаҗ түгел. Аның шанлы исеме бөтен дөньяга мәгълүм. Шулай ук өлкән яшьтәге кешегә «мин фәлән-фәлән уку йортында укыдым, фәлән вуз тәмамладым» дип күкрәк кагу да (яшьрәк чакта ярыйдыр да) бик үк килешеп бетмәс. Ил алдында кылган игелекле гамәлең булса, аның үзеңә дә, янәшә-тирәлегеңә дә, туган йортыңа да, мәктәбеңә дә яктылыгы үзе төшә ул.

Университетка китап аша, китаплардан алынып тулышкан хыял аша килдем мин. Бала чакта һәрберебезнең тизрәк үсәсе, үсәсе дә тизрәк зур кеше буласы киләдер. Ул вакытта минем өчен иң зур кеше – язучы. Алар гүя могҗизага ия тылсымлы кешеләр. Алар бөтенесен беләләр: нинди каһарманнар турында язалар, нинди гыйбрәтле хәлләрне сурәтлиләр... Яшермим, минем дә классташлар көнләшерлек, авылдашлар горурланырлык зур кеше, ягъни язучы буласым килә! Ә максатка ирешү юлы бер – зур белемле булу. Моның өчен тырышып укырга кирәк, вузга керергә кирәк! Барыр җир билгеле – университет. Казан университеты. Бу уку йорты турында күпме яхшы сүз ишетелмәгән дә күпме матур җөмләләр укылмаган! Шик тә юк, дөньяның иң мәшһүр университетларының берсе инде ул! Ленин кадәр Ленин белән бәйле җирдә укып та, хыялың тормышка ашмаса!

1960 елны тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Ул елларны вузларга нәтиҗәдә берничә ел хезмәт стажы булган егет-кызларны алдылар, яңа мәктәп бетергәннәргә урын бик аз иде. Ялгышмасам, гомумсанның уннан бере чамасы. Шуңа күрә андый «яшел борынлы»лар группада, гадәттә, берничә генә була. Ниһаять, мин студент! Шунсы горурлык: бернинди танышсыз, ярдәм-мазарсыз үзебез керә алдык. Минемчә, сугыштан соңгы дәвердә фәкать үз көченә генә ышанган, идеалы һәм иманы булган буыннар җәмгыятьнең арка сөяге булып тора алды да.

Студентлык елларында эшкә бара торган сыман ике урыным булды: берсе – университет, анда белем алам; икенчесе – Матбугат йорты, анда «язучылыкка практика» үтәм. Газета-журналларда мәкаләләр, репортажлар, шигырьләр еш басылып тора. Димәк, хезмәтемә азмы-күпме ихтыяҗ бар. Димәк, университетта алган белемем иҗтимагый тормышта беркадәр чагылыш таба! Берничә ел университетның әдәби-иҗат берләшмәсенең җитәкчесе дә булырга туры килде. Ул вакытта университетта яшь иҗатчылар күп һәм көчле иде. Бездән әз генә алда

укып чыккан Р. Кутуй, Р. Солнцевлар үзәк матбугатта шау килә. Болар – рус телендә иҗат итүчеләр... Безнең туган телдә язучылар да җитәрлек. СССР Язучылар союзы әгъзасы булган укытучылар – Х.Госман, М.Хәсәнов, И.Нуруллин, З.Мәҗитов... Соңрак бу төркемгә М.Мәһдиев, М.Госманов, Т.Галиуллин, А.Яхин, Х.Миңнегуловлар килеп кушылды. Университетны элегрәк тәмамлаган язучыларның исемнәре дә гел искә алына: Н.Фәттах, Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, М.Хөсәен... Безнең чорда һәм соңрак университеттан чыккан язучылар бихисап. Бүгенге Язучылар оешмасының алар, мөгаен, яртысын тәшкил итәләрдер.

Университет һәм әдәбият. Минем өчен бу ике сүз, аерылгысыз ук булмаса да, бик якын тугандаш төшенчәләр. Чөнки бу уку йорты башлангычтан ук язучылар исеме белән мәшһүр: С.Аксаков, Н.Ибраһимов, Л.Толстой, В.Хлебников... Димәк, нигезе үк әдәбият белән бергә салынган. Бу матур традицияләр гасырдан гасырга күчеп алга таба да уңышлы дәвам итәр дияргә ышаныч бар.

Моннан 200 ел элек ачылган университетның кодекс-уставы бар. Ул, әлбәттә, Россия империясе мәнфәгатьләрен кайгыртып ачылган уку йорты. Казан җирендә XIX гасырда оештырылган төрле уку йортларын беләбез: духовная семинария, духовная академия, ветеринария институты, керәшен-татар школасы... Алар инородецларның, шул исәптән татарларның теле, мәдәнияте чәчәк атсынга ачылган дип уйлау беркатлылык булыр иде. Октябрь инкыйлабына кадәр – йөз елдан артык вакыт эчендә – университетта безнең халыктан нибары берничә дистә кеше укыганлыгы күп нәрсә аңлата. Шөкер, XX гасырда бу данлы университет чын мәгънәсендә интернационал уку йортына әйләнде. Татарстан тормышының төрле мөһим тармакларын университет тәмамлаган белгечләрсез күз алдына китереп булмый хәзер.

Шәхсән үзем, әгәр яшьлек хыялымдагы омтылышларның шактые тормышка ашкан икән, моңарга Казан университетына бурычлымын.

*2004*

## *УЗДЫ ШАУЛАП БӨЕК БӘЙРӘМ*

Әйе, безнең өчен бөек бәйрәм булды бу. Соңгы дәвердә тарихыбыз тоныкланып, башкалабыз Россиянең өлкә шәһәрләре рәтенә кереп бара иде. Хәтта «Казань городок – Москвы уголок» гыйбарәсе дә онытылып килә иде бугай... Импер максатлы, шовинист рухлы даирәләр өчен Казанның зур тарихлы, дәүләт тоткан халыкның башкаласы булуын оныттыру хәерлерәк иде. Казанның яшен чикләүгә, кыскартуга, борынгылыгын шик астына алырга тырышу омтылышлары үзе бер тарих. «Ятимнәрнең туган көне кемгә кирәк!..» Бу сүзләр моннан чирек гасыр элек тикмәгә генә каләм очына килмәгән инде...

Казанга мең ел! Шөкер, нинди олуг тантана белән үтте ул! Моннан ун-унбиш ел элек, шәһәребез юбилее дөнья масштабында уздырылыр, бәйрәмгә дистәләрчә ил башлыклары килер, бу җирләрдә моңарчы күрелмәгән тамашалар, үзенчә халыкара сабантуй булыр дисәләр, мөгаен, ышанмас идек. Халык гыйбарәсендә әйтелгәнчә, «булмас димә, дөнья бу!».

Һәр гамәл, асылда, киләчәк өчен, киләчәк хакына эшләнә. Йолалар да шулай, бәйрәмнәр дә. Туйлар да шулай: бәби туе, кавышу туе, хәтта озату туе... Киләчәккә, яңа буыннарга гыйбрәт, сабак, үрнәк өчен. Казан бәйрәме дә шуңа мисал. Тантаналарның төбендә «без – булган, без – бар, без – булачак!» дигән асыл мәгънә ята. Шунысы куанычлы: Казан бәйрәме, нигездә, татар бәйрәме, татар рухын күтәргән бәйрәм булып узды. Һәм күпләр тарафыннан шулай табигый кабул ителде дә. Чит ил башлыклары, килгән кунаклар Казанның данын, шул исәптән татар халкының үткәнен күтәреп сөйләделәр. Казан аша халыкны таныта алуда гаять хикмәтле ыргым булды бу.

Бәйрәм алдыннан Казан үзе дә нык үзгәрде – матурайды, баеды, көязләнде. Күк катларына менеп карыйсыңмы, Идел өсләреннән яки Арча яклары киңлекләреннән торып багасыңмы – шәһәр, билләһи, бер асыл мәрҗән инде! Шагыйрьнең «Сказаньем встает Казань!» дигән сүзләре бигрәк тә рас килә хәзер. Әүвәлге гасырларда Казанны күреп сокланган сәяхәтчеләр хәтергә килә. Аларның күбесе Казан турында сокланулы сүзләр әйтеп калдырган бит. Хәзерге сәяхләр дә шулай уйлыйлардыр.

Казан үзәгендәге манзараларны яхшырак күреп, шәһәрнең эчке җегәрен һәм рухын аңлар өчен тәүлекнең ике вакыты бик җайлы: берсе – таң белән, кешеләр әле уянмаган чакта буш урамнар, йорт-диварлар белән бергә-бер торып, «сөйләшеп» йөрү; икенчесе – кич вакыт, халык, бигрәк тә яшьләр кайнаган чак. Төрле төстәге утлар, авазлар, исләр вакханалиясе... Бу вакытта инде Казан чын мәгънәсендә «кайный». Тәнең сау, дәртең сүнмәгән булса, син үзең дә шул «казан»да рәхәтләнеп быгырдарга риза... Соңгы елларда корылган сарай-биналарның күплеге һәм аларның грандиоз мәһабәтлеге таң калдыра. Казаннан ун-унбиш ел элек китеп, хәзер кайтып күргән кеше күп урамнарны танымас та. Яңа метро, яңа күперләр, яңа мәйданнар, яңа һәйкәлләр, яңа сарайлар... Гел яңа, яңа, яңа...

Ә искеләр, борынгылар? Яңа төзелешләргә бәйле рәвештә бик күп борынгы корылмалар вәйран булды. Бигрәк тә агач архитектура үрнәкләре юкка чыкты. Кирпеч-таш – бер нәрсә, ә агач агач инде ул! Табигатьнең эчке җылылыгын сеңдергән, берсеннән-берсе кабатланмас, матур, яхшылап реставрацияләсәң тагын берничә гасыр торырлык уникаль биналар урамы-урамы белән кайтмаска югалды. Аларны бернинди акча бәрабәренә дә кайтарып булмый инде... Күрәсең, без әле борынгы яхшының хәзерге яхшыдан күпкә кыйммәтрәк икәнен аңлап бетермибез. Сәбәпләре ике: рухи ярлылык, матди фәкыйрьлек... Яңа, биек, бай йортларга карап, җырдагыча, «Яңа ярлар иске ярны онытты» дип юанырга кала. Шулай да күңелне төшермик: афәтләрнең нинди төрләрен генә күрмәгән ул Казан! Баскыннарның вәхши җимерүләрен дә, пожар-янгыннарның ялмап алуларын да... Булганына, торгызылганына (Кол Шәриф мәчетенең шәһәр символы булып яңадан калкуы үзе ни тора!) шөкер итәргә кирәктер.

Меңьеллык... Күптән язылган шигырь юллары искә төшә. «Безнең якта борынгыдан хәрабәләр генә. Чын тарихны азлар белә –хәбәрдарлар гына...» Чыннан да, меңләп ел элек булган чын хәлләрне бик азлар чамалый. Чын тарих ерак яшерелгән. Үз тарихыңны ят телдәге чыганаклардан өйрәнеп, тулы хакыйкатькә чыгу кыен. Шунысын да искәртик: кышы күбрәк була торган якта яшибез бит. Безнең җирләр ел әйләнә җылы кояш иркәли торган Урта диңгез буйлары түгел, кыя ташлы диңгез ярлары юк... Чын нык ташлар Урал тауларында гына. Менә бу бина-корылма мең ел элек салынган дип төртеп күрсәтү кыен... Андыйлар бөтен Рәсәендә дә бар микән? Булса да, бик сирәктер. Дөрес, ерак төрки бабаларыбызның Азау-Тын (Азов-Дон) яки Алтай-Янәсәй яланнарында әлегә кадәр сакланып калган таш балбаллары бар барын... Идел-Чулман буйларындагыларыннан, безгә якыннарыннан (чакрым үлчәве белән әйтүем) Алабуга янындагы «Шайтан каласы», Болгардагы корылмалар... Урал якларындагын исәпләсәк, серле Аркаим...

Меңьеллык ул – зур сан, биек сан. Безгә Казанның меңьеллык бәйрәмен күрү насыйп булды. Без һәм безнең балалар-оныклар горурлык белән «меңьеллык борынгы Казанда гомер кичерәбез!» дип әйтә алабыз, эчке тойгы белән Казанны дөньяның борынгы Рим, Истанбул, Афина, Сәмәрканд кебек шәһәрләре белән тиңләп чагыштырабыз. Таулар таулар белән сөйләшә, диләр бит... Шунысы да бар: биеклекнең үз кануннары. Биеклекне яулау бер авырлык булса, биеклектә кала алу – аерым бер җегәр сорый торган вазифаи авырлык. Казанның яше, бәлки, мең елдан да артыктыр... Әмма булган меңен дә әлегә саклый һәм ул статусны һәрдаим ныгытып тору хәерле. XVI–XVII йөзләрдә Идел-Чулманның бай җирләренә килеп урнашкан баскынчыларның утар-чиркәүләрен торгызып кына Казанның борынгылыгы артмас. Шуңа да иң әүвәл, әлегә азмы-күпме матди хәлебез бар чакта, мирасыбызның борынгы өлешенә – меңнең беренче өлешенә – күбрәк игътибар юнәлтергә тиеш булабыз. Бу очракта беренче чиратка, алга борынгы әдәби ядкарьләр чыга. Шөкер, аларның кайберләре исән-сау, шагыйрь әйтмешли, аларны «туплар да ватмады, уклар да кадамады». Әдәби мирастан кала, әлбәттә, материаль ядкарьләр. Шул ук Биләр-Болгар корылмалары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик һәйкәлләр... Болар һәммәсе мәдәни борынгылыгыбызны, Казан юбилееның, тәрәккыятебез үсешен күрсәткән табигый бер дата икәнен раслаучы дәлилләр. Әмма аларны киң дөньяга белдертәсе: күпләргә, бик күпләргә аңлатасы, ирештерәсе, сеңдерәсе, киң дөньяга күрсәтәсе бар.

Казан, университетлы шәһәр буларак, гасырлар буе Россия империясенең иң алдынгы шәһәрләреннән саналган. Юбилей уңае белән Казан үзенең бу статусын яңадан кайтарды: Россия шәһәрләренең беренче өчлегенә керә ул хәзер. Матурлыгы ягыннан да, интеллектуаль дәрәҗәсе ягыннан да. Ә татар кешесе өчен дөньяда беренче шәһәр, иң кадерле шәһәр ул!

...Яңгыр явып үткәннән соң, кичке Казан әкияти матур. Аяк астындагы җирдә – урам-мәйданнарда янә бер сихри күренеш – шәһәрнең чагылышы пәйда була. Болытлар таралып, күктә чалт йолдызлар да кабынса, бу илаһи сихрилек тагын да арта. Йолдызлар нуры аша ерак кыйтгаларда, чит-ят илләрдә яшәүче кардәш-туганнарыбыз сагыш һәм өмет белән безгә, шәһәребезгә сәламнәр юллый кебек: «Исән-сау бул, Казан! Яшә генә!»

*2005*

## *ЮЛЛАР ТЕКӘРӘК, ЕЛЛАР ҖАВАПЛЫРАК*

Вакыт дигәннәренең асылын аңлап бетерергә адәм баласының вакыты җитми шикелле. Шулай да, талкып, изеп, киптереп дигәндәй, Вакытның үзе аша үтүен бөтен күзәнәкләре белән сизә, тоя, белә терек иясе! Әле кайчан гына милади исәп белән яңа гасырга чыгабыз дип мәш килеп йөргән идек. Кичә генә булган шикелле. Инде килеп алты елы үткән дә киткән! Җиденчесенә аяк басабыз. Уйландыра. Яшәгән саен һәр үткән елның мәгънәсе күпмедер үзгәрә бара. Еллары да тизрәк уза шикелле. Шулай да ел кадәр ел эчендә, телибезме, юкмы, биниһая вакыйгаларның шаһитлары без. Гомумдөнья хәлләре турында, һәркемнеке кебек, минем дә кайбер уйлануларым бар барын, әмма алар турында зурдан кубып сөйләргә теләмим, мөгаен, булдыра да алмам, шуңа күрә үзебезнең Идел-йорттагы вазгыять турында уй-фикерләремнең беразы белән уртаклашып узмакчымын.

2006 ел Казанның 1000 еллыгыннан соң үткән беренче ел булды. Казан юбилеен матур итеп уздырып, дөньяның байтак ил-дәүләтләренә «Бу Кояш астында без дә бар!» дигәнне янә бер мәртәбә сизелерлек итеп белгертә алдык. Ярап куйды бу бәйрәм. Төбендә татар файдасына, безнең файдага булды. Казан Татарстанныкы гына түгел, бөтен татарныкы да бит. «Булдырабыз!» дидек. Һәм чыннан да абруйлы билгеле бер биеклек алынды. Ә биеклектән төшәсе килми ул! Минемчә, үткән 2006 ел биектә калу яки калырга тырышу елы булды. Ә югарыракка менү яки менәргә омтылыш булдымы соң, халык тормышы яхшырдымы, милли яңарыш көчәйдеме, диярләр. Бу катгый сорауларга төгәл кистереп әйтү кыен. Җаваптан бигрәк, күңелгә антоним мәгънәле уйлар килә. Җәмгыятьтә байлык арта, әхлак кими. Шәһәр үсә, авыл кечерәя. Татарстанның дәрәҗәсе үсә, дибез, ә Үзәк белән Шартнамә һаман яңартылмый («тарихи бу бергәлек» галәмәте). Мәчетләр төзелә тора, иманлылар бик артып тормый. Тел үсеше турында сүз сөйләү күбәя, чынлыкта татарча сөйләшүчеләр кими бара. Татарстан телевидениесенең техник мөмкинлекләре артты, ә радиобыз структур яктан үзгәреп бетте, бай традицияләр җимерелде... Әйтелгәннәр гомумирәк яңгыраса да, үткән елга бик хас алар. Ярый, каршылыклы фикерләрне тәкрарлау җитеп торыр. Ә биеклеккә килгәндә, үткән ел Казанның яңа үрләр яулау юнәлешендә тагын бер ыргымы булды әле! Башкалабыз тагын берничә елдан узачак Бөтендөнья яшьләре Универсиадасын үткәрү өчен реаль кандидат шәһәргә әверелде. Әгәр, барып чыкса, безнең халыкара дәрәҗә, һичшиксез, тагын да үсәчәк!

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Указы белән 2006 ел Республикада Әдәбият һәм сәнгать елы шигаре астында үтте. Бу уңайдан, хәтерегездәдер, әдәбият һәм сәнгатькә бүгенге көндәге мөнәсәбәт, киләчәктә башкарылырга тиешле эшләр турында журналыбызда (2006, № 3) Татарстан Президентының һәм баш мөхәррирнең тәфсилле әңгәмәсе басылып чыкты. Анда күтәрелгән мәсьәләләр, табигый ки, күпләрнең игътибарын җәлеп итте, уңай чишелешләргә ымсындырды. Әдәбият һәм сәнгать елының тарихында калырлык нинди сәхифәләрен атап китә алабыз соң? Иң әүвәл ике бөек шәхес – Г.Тукай һәм М.Җәлил юбилейлары күңелгә килә. Берсенең – 120, икенчесенең 100 еллыклары. Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә һәм чит илләрдә дә югары дәрәҗәдә һәм масштаблы үтте ул тантаналар. Элегрәк үткән юбилейлардан үзгә уңай гамәлләр булды. Әйтик, Петербургта Тукайга һәйкәл куелды, Уральскида музей ачылды, шагыйрьгә багышлап язылган яңа опера сәхнә күрде, рәссамнарыбыз хезмәтләреннән тупланган затлы альбом чыгарылды... Мәскәүдә М.Җәлилгә һәйкәл кую мәсьәләсе хәл ителеп килә. Татар халкының абруен күтәрүгә хезмәт итүче бу ике бөекнең варислары – бүгенге язучылар өчен аеруча горурлык: һәйкәлләрдә басып торучылар шагыйрь-әдипләр бит! Дәвамнары булырга тиешле бөек биеклекләр!

Музыка өлкәсенә күз салыйк. Мәшһүр композитор һәм җырчы С.Садыйкованың 100 еллыгы халыкчан көйләрнең онытылмас бәйрәме булып узды. Дөньякүләм билгеле икенче бер композиторыбыз С.Гобәйдуллинаның 75 яшьлеге уңаеннан аның исемендәге Халыкара пианистлар конкурсы, А.Ключаревның 100 еллыгына багышланган концерт зур уңыш белән үтте. Р.Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивале, елдан-ел камилләшеп, үткән ел яңа биеклеккә күтәрелде. Сентябрь аенда «Алтын мөнбәр» дип аталган мөселман киносы халыкара фестиваленең янәдән Казанда зур күтәренкелек белән үтүе дә 2006 елның күркәм сәхифәсе саналырга лаек. Җөмләдән, үткән елда Г.Камал театры коллективы Лондонга барып спектакльләр куеп кайтты. Әгәр Г.Камалга «бер гасырдан соң синең «Беренче театр»ың Бөекбритания башкаласында уйналачак» дигән булсалар, ул һич ышанмас иде. Татар театры оешуга 100 ел тулу уңаеннан, гомумән, бик күп эшләр башкарылды. Театр юбилее тантаналары быел да дәвам итәчәк әле. Рәссамнар дөньясында да җанлылык кимемәде, кызыклы-кызыклы дистәләрчә күргәзмәләр оештырылды. Музейчыларыбызның үткән ел башкарган эшләре аеруча мактаулы. «Татар халкы һәм Татарстан дәүләтчелеге тарихы» музее ачылу гына да ни тора! «Казан» милли мәдәни үзәгенең 15 еллыгы билгеләп үтелде. Бу Үзәкнең әдәбият-сәнгать өчен никадәр әһәмиятле икәнлеге тагын бер мәртәбә тәкъдир ителде. Милли үзаңны үстерүгә хезмәт иткән йөзләгән кичәләр үтте анда. Китап басу, нәшрият өлкәсендә дә уңышларыбыз бар. Халыкара ярминкәләргә алып барырлык китаплар басыла (кайберләре призлы урыннар, халыкара дипломнар ала), бүтән республика наширларын көнләштереп, классик әдипләребезнең күптомлыклары чыгу дәвам итә. Ата-бабаларыбыздан күркәм мирас булып калган Сабантуй, 2006 елда тагын да киңрәк колач алып, дөнья иңләп бәйрәм ителде. Ул сабантуйлар һәркайда әдәбият-сәнгать вәкилләренең актив катнашында уздырыла. Мисал өчен генә әйтеп үтим: минем үземә дә Татарстандагылардан тыш Мәскәү, Истанбул сабантуйларында катнашырга туры килде.

Язучыларыбыз өчен әдәбият һәм сәнгать елының иң мәгънәле сәхифәсе – «Казан утлары»ның меңенче саны чыгу булгандыр. Үз әсәрләребез басыла торган төп журналыбыз бит. Язучылар өчен генә түгел, татар мәдәниятенә бәйләнеше бар дип исәпләгән һәр зыялы кеше өчен чыннан да куанычлы вакыйга. Шунысын да искәртү кирәк: меңенче санга ирешкән бүтән әдәби журнал илдә юк. Журналның бу бәйрәме матбугат битләрендә, әдәбият көннәрендә, иҗат кичәләрендә һәм бүтән әдәби чараларда ел буе диярлек дәвам итте. 2007 елның башында «Казан утлары» бәйрәме Мәскәүдә дә узачак. Яңа елга аяк баскан көннәрдә журналыбыз елъязмасы саналырлык «Сүнмәс утлар балкышы» дигән зур күләмле хезмәт дөнья күрде. Бу китапта мең санлы хәзинәдән сайлап алынган әдәби әсәрләр, мәкаләләр, гыйльми язмалар, публицистик очерклар, истәлекләр, документлар тупланган. Күп көч сарыф ителеп, үзенчәлекле антология сыйфатында чыккан бу китап тиздән укучыларыбызга да ирешер дип уйлыйм.

Әле саналган эш-вакыйгалар (аларны казанышлар исемлеге диярргә дә ярыйдыр) турында кемнәрдер «бу юбилейлар, гастрольләр, тантаналар, әдәбият-сәнгать елы игълан ителмәсә дә, барыбер үтәр иде бит» дип тә куяр, һәм өлешчә хаклы да булыр. Әйе, байтагы, күнегелгәнчә, үз агымы белән дә үтәр иде. Тик ничек һәм нинди дәрәҗәдә бит? Минемчә, бик күп әдәби-мәдәни чараларның әдәбият һәм сәнгать елы шигаре астында үтүе һәм бу эшләрнең байтагына Татарстан Президентының турыдан-туры катнашуы уңай нәтиҗәләр бирде. Әлбәттә, аерым бер елга «тамга салып» кына дәверләр буена җыелып килгән мәсьәләләрне хәл итү мөмкин түгел. Максатлар югарырак булган саен, барыр юллар текәрәк, еллар җаваплырак, таләпләр кискенрәк. Шәхсән минем үземне (күпләрне дип уйлыйм) халкыбыз рухына кагылышлы мирасны саклау проблемалары борчый. Үткәндәге мирасын барлый, кадерли белмәгән халыкның киләчәге өметсез. Бу җәһәттән шөбһәле уйларга этәргән мисаллар байтак. Шул ук Казан мисалына әйләнеп кайтыйк. Мең еллык юбилейга әзерлек чорында (әлбәттә, аңа кадәр дә) шәһәр үзәгендәге күпме тарихи биналар, корылмалар юк ителде. Өстәге түрәләрнең берсе «Казанны Явыз Иван бер җимергән булса, икенче тапкыр шәһәр мэры җимерде» дип тикмәгә генә әйтмәгәндер. Биналарның кайберләрен генә булса да реставрацияләп яңартырга кирәк булгандыр да бит! Әллә никадәр акча түксәң дә, хәзер инде аларны кайтарып булмый... Казанда чагыштырмача болай да аз сакланган татар тарихы ядкарьләренә аеруча нык зыян килде. Болак арты һәм бистә якларын истә тотып әйтәм моны. Безнең өчен үтә дә кадерле, әлегә исән кайбер биналарның язмышы да анык түгел. Әйтик, «Болгар» номерлары, Матбугат

йорты... Икенчесенең язмышы аеруча борчый. Бу хакта язучыларыбыз матбугатта мөрәҗәгать белән дә чыгып карадылар. Соңгы 70–80 ел эчендә татарның (гомумән, республиканың) рухи учагы, әдәбият-сәнгать – тарихи-сәясәт тармакларын халык белән тоташтырган төп үзәк булып килде бит ул! Бу йорттан нәшриятларны, редакцияләрне, китапка бәйле булган бүтән оешмаларны чыгаргач, бина кемнәр кулына кала да, киләчәктә аңа кемнәр хуҗа булачак? Без белмибез. Белүчеләр бардыр, бәлки, әйтеп аңлатырлар? Әдәби мирас өлкәсендә дә хуҗасызлыкка, таркаулыкка мисаллар җитәрлек. Әйтик, татар телендә иҗат иткән М.Гафури, еллар уза-уза, башкорт әдәбияты классигына әверелде. Аннан шактый дәвер элегрәк яшәгән Акмулланы элегрәк татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак шагыйре санап йөри идек. Үзебезнең ваемсызлыгыбыз, бигрәк тә галимнәребезнең ваемсызлыгы, битарафлыгы аркасында ул да бездән ерагая бара... Без еш кына үзебезне мең еллык әдәби мирас вәкилләре дип һаваланырга яратабыз. Мираска, варислыкка хакың бар икән, аңа хуҗа булырга да кирәктер. Хуҗа була белгәннең генә абруе зур була.

Халыкта «чебешне көз көне саныйлар» дисәләр, без газета-журналларга бәйле кешеләр, үзебезнең «чебешләрне», ягъни әбүнәчеләр санын яңа ел алдыннан саныйбыз. Соңгы елларда, сер түгел, татар матбугаты тираж ягыннан гел үсү ягына бармый. Матбугат – телне, аның аша милли рухны саклаучы төп көчләрнең берсе. Икенчеләп әйтсәк, тиражлар күрсәткече – халыкның үзаңы үсеше (яки төшүе) күрсәткече ул. Укучы дигән сүз, Горький әйтмешли, горур яңгырый! Уку ул – ләззәт тә, хезмәт тә, хәтта иҗат та. Компьютерлашу (глобальләшүнең бер баскычы) халыкның рухи үсешен тәэмин итүгә һич кенә дә гарантия түгел әле ул. Милли матбугатны таратуның мөһимлеген халык белән эшли һәм идарә итә торган җитәкчеләр тирән аңларга тиешләр дип уйлыйм мин.

Һәр язучының үткән ел турында үз уйлары, киләчәккә үз планнары бардыр. Язучылык хезмәте беркайчан да җиңел булмады, хәзерге заманда елдан-ел авырая гына бара ул. Язучылык эше – вөҗдан эше. Максатсыз һәм имансыз иҗат итүне күңел кабул итми. Минемчә, каләмдәшләребезнең күбесе моны яхшы аңлый. Кайчак уйлап куясың: әгәр язучыларыбыз булмаса, безнең милли халәт шактый төшенке, телебезнең көче күпкә ким булыр иде. Шөкер, дистәләгән менә дигән язучыбыз бар (аларның әсәрләре һичшиксез зуррак тираж белән чыгып, күбрәк сандагы укучылар игътибарына лаек). Булсынга дип эшли торган оешмабыз бар. Мөстәкыйльлек өчен көрәш елларының бер нәтиҗәсе буларак, хөр фикер йөртә торган яшь талантлар үсеп килә. Киләчәктә рухи мәйданыбыз киң булсын дисәк, туган телебезнең сау булуы шарт. Ә ул көрәшеп яклауга, саклауга мохтаҗ... Бу көрәштә безнең өлеш – кешеләргә кирәкле, аларга ышаныч бирерлек камил әсәрләр иҗат итү. Әгәр безнең әсәрләргә ихтыяҗ бетсә, язып торуның мәгънәсе юк. Шуңа күрә дә начар язарга хакыбыз юк! Заманы шундый.

*2006*

## *ЮК, ҖИБӘРМИ МИНЕ ГАМЬЛЕ УЙЛАР*

Үтеп киткән елда зур сәясәт дөньясында да, мәдәният-матбугат өлкәсендә дә шактый гыйбрәтле хәлләр булды. Вертикаль хакимият түрендәге «шахмат уеннары»на яки сайлау кампанияләре хикмәтләренә дә тукталып тормыйча, үзебезнең матбугат хәятына кагылышлы ике вакыйганы гына әйтеп узам. Онытырлык түгел алар. Беренчесе – Казан үзәгендәге данлыклы Матбугат йорты белән саубуллаштык, икенчесе – республикада чыгып килгән бик күп басмалар, хөкүмәттән рәсми «котылып», ирекка, үзбашка чыкты, ягъни акционерлык ширкәте булып оешты. Бер җөмләгә сыйган шушы информациядә моңарчы күрелмәгән тарихи акцияләр төене ярылып ята. Мәгънәләрен тәфсилләп бәян итсәң, сүзем озынга китәр. Шулай да... Матбугат йорты – әдәбият, нәшрият, газета-журналлар, гомумән, мәдәни тормышның җитмеш еллап чорын үзенә сеңдергән тарихи бина, ничә буын талант ияләренең иҗади аралашып «кайнау» урыны иде. Аның бетүе символик мәгънәгә ия түгелме? Дөрес, бина бик нык тузган булып чыкты, нәшрият-редакцияләргә күченми мөмкин дә түгелдер. Алга

таба ни-нәрсә булыр ул урында? Шәһәр үзәгендәге күз кызыгырлык җир буш тормас, әлбәттә. Һәрхәлдә, рухи учак торгызылырга охшамаган.

Акционерлыкка күчү исә газета-журнал редакцияләре өчен көтелмәгән хәл булды. Үткән елның август аенда югарыдагы кабинетлардан чыкты ул карар. Акционерлыкка берләшү – үз көнеңне үзең күреп, булдыра алсаң, баеп яшәргә омтылу дигән сүз. Кыскасы, акча эшләү, мөмкин булса, күп итеп эшләү! Әгәр дөньяда идеология – милли идея, тел, әдәбият, сәнгать кебек төшенчәләр булмаса, акча эшләүгә көйләнү дөрестер дә. Әмма тарих гадел хөкемче: цивилизацияле дөньяда илләрнең, халыкларның дәрәҗәсен, югары сәнәгатьләре белән бергә, аларның рухи биеклекләре, фәнни казанышлары аша билгелиләр... Шунысын да онытмыйк: моңарчы матбугатны «дүртенче хакимият» дип тә йөрттеләр бит. Бүгенге көндә абсолют күпчелек басмалар, бигрәк тә милли (бу очракта русча булмаган) телләрдә чыккан басмалар үз-үзләрен асрый алмыйлар. Моның тарихи сәбәпләре бар. Табыш чыганагы булып торган реклама безнең матбугатта үзмаксат була алмый. (Сүз дәүләти идеологик тәрбиягә өлеш кертмәгән бульвар яки вулгарь басмалар турында бармый.) Ихтимал, узган гасырның 70 нче елларында кайбер басмалар (әйтик, «Казан утлары», «Азат хатын» («Сөембикә») үзбаш яши, хәтта табыш алып яши дә алган булырлар иде. Чөнки тиражлар йөзәр мең белән йөрде. Хәзер вазгыять бөтенләй бүтән. Сәбәпләре аңлашыла. Хөкүмәт үз ярдәменнән ташламаса, матбугатка кагылышлы заказларын акционерлар җәмгыяте (ОАО)  аша уздырса, беренче чорда, бәлки, әле ару гына яшәп тә булыр. Шулай дип өметләник. Әмма бу дәвамлы булырмы? Җитәкчеләр үзгәреп, карашлар үзгәрмәсме? Без барлы-юклы мөстәкыйльлегебезне җуеп (самоликвидацияләнеп, сүзе генә дә ни тора!), инде мәңге кире кайтып булмас чикне үтәбез бугай. Базар тотрыклылык символы түгел, ул сәгатьләп үзгәреп тора. Базар шулай ук тәрбия һәм әхлак мәйданы да түгел. Беркөн безгә «Чүкечегез булмаса, кадакны скрипкә белән кагыгыз!» дип әйтүләре дә бик мөмкин.

Соңгы дистә еллар эчендә без гел үзгәртеп корулар, тоташ реформалар, яңадан-яңа сәяси фиркаләр төзү эйфориясендә яшибез шикелле. Тарихи дәвамчанлык җитенкерәми димме?.. Үзебезнең матбугат тарихына күз салсак, анда азмы-күпме мантыйкый доктрина һәм табигый эзлеклелек дәвам иткән. Һәр тармак-өлкәнең үзенең максаты, сәясәте, шул нисбәттән үзенең идеологик-тәрбия органы булган. Әйтик, балалар һәм үсмерләр әдәбияты элегрәк – комсомол, соңрак яшьләрнеке дип йөртелгән министрлык эгидасында булган; әдәби журналлар эше белән, нигездә, Язучылар оешмасы җитәкчелек иткән; сәнгать өлкәсендәге газета-журналлар Мәдәният министрлыгына караган; мәктәп-тәрбиягә кагылышлы басмалар – Мәгариф министрлыгына... Алар әлеге басмаларның учредительләре – оештыручылары сыйфатында җитәкчелек иткәннәр. Аңлашыла һәм мантыйкка сыя торган тәртип. Өстәвенә әле бу басмаларның көндәлек һәм фактик яктан дөньяга чыгару буенча төп булышчысы, гомумхуҗасы – Матбугат һәм информация министрлыгы булган. Заманасында уңышлы гына эшләп килгән бу министрлык (совет заманындагы нәшрият, полиграфия эшләре һәм китап сәүдәсе идарәсе) моннан ун еллар элек бетерелде. Аннан соң газета-журналлар һәм нәшриятларның яңа хуҗалары пәйда булды. Берничә ел Элемтә (?) министрлыгына, аннан «Татмедиа» агентлыгына буйсынып яшәде мөхәррирләр. Хәзер без шул оешма җирлегендә оешкан акционерлар җәмгыятенә карыйбыз. Төгәлрәк әйткәндә, ачык акционерлык ширкәтенең филиаллары саналачакбыз. Гасырлар буе баш редактор-мөхәррирләр йөртелгән затлар шул филиалларның директорлары дип аталачак. Кызыклы метаморфоза. Тагын нинди реформалар булыр, әйтүе кыен.

Әле күптәнме XXI гасырга (милади белән санаганда) керәбез дип, дулкынланып, яңа хыял-ышанычлар белән янып йөргән идек. Яңа гасырның җиде елы инде үтеп тә китте. Сау кешегә ун елы да, бүтән еллары да тиз килеп җитәр. Нинди алгарышлар булды, өмет иткәннәребезгә ирешелдеме? Кояш астындагы җиһанда татар милләтен күбрәк таныта алдыкмы, дөресрәге, саклана алдыкмы? Фикерләр каршылыклы. Бер яктан, Казанның меңьеллыгы уңае белән горурлык хисләре уятырлык олуг гамәлләр булды. Казан дөньякүләм дәрәҗәле шәһәргә әверелеп бара. (Тик шуны да онытмыйк: без аны татарның башкаласы дип санасак та, ул бик күпләр өчен монастырьлар һәм икона-тәреләр шәһәре дә.) Казан – халыкара милли мөнәсәбәтләр, милләтләр язмышы турында җитди сөйләшүләр аренасы хәзер (татар конгресслары, Татарстан халыклары съезды, Бөтендөнья татар галимнәре җыены, федерализм

мәсьәләләре буенча югары дәрәҗәдәге халыкара форумнар, төрле илләрнең җитәкче даирәләре белән даими очрашулар һ.б.).

Болары бик әйбәт. Әмма күпләрне гомуми, илкүләм милли мәсьәләләрнең хәл ителмәве борчый. Россия халыкларының телләре аяныч хәлдә. Бу урында әз генә хәтер чигенеше ясап, РФ Президенты В.В.Путинның 2002 елның 30 августында Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгышыннан бер өзек китерәсе килә (очрашуда үзем дә катнашкан идем, ул мизгелләр бик хәтердә): «Абсолютно недопустимо, если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка». Кызганыч, Россия Президенты сүзләре белән Дәүләт Думасы законы берсен-берсе сызып ташлый. Дәлилләрме? Алар күз алдында. Әле күптән түгел (2007, 15 ноябрь) Дума безнең өчен гаять зур «бүләк» әзерләде (аның русча аталышы болай: «Закон, отменяющий национально-региональный и школьный компоненты в государственном общеобразовательном стандарте»). Шунысы сәер: бу законга Президент инде кул куйган (!) диләр. Мондый гамәлдән соң, әлбәттә, логика дигәннәре бик мескен хәлдә кала... Шундый закон кертелгәч, рус теленнән тыш башка милләт телләре «гөрләп чәчәк атачак» инде! Хәер, Дәүләт Думасының безнең телебезгә мөнәсәбәте билгеле: татар язуын латин графикасына күчерүне тыйган депутатлар җыены бит ул! Ә менә мәктәпләрдә православие дине фәнен укытуга бик тә лояль үзләре. Гаҗәпләнергә кирәк тә түгелдер, байтак республикалардагы рәсми һәм иҗтимагый оешмаларның күп тапкыр мөрәҗәгатьләренә карамастан, күпмилләтле Россиядә координацион үзәк – милли мәсьәләләр буенча министрлык та юк бит. Аның урынына милли төсмер бирелмәгән Региональ үсеш министрлыгы төзелде. Күрәсең, Ак патша варислары, СССР таркалгач, милли мәсьәләләр бетте дип уйлыйлардыр... Әмма милли мәсьәлә ул мәңгелек! Чөнки Ходай биргән яшәүдә үз-үзеңне саклау теләге инстинктив табигый хәл.

Мәгълүм хакыйкать: милләтнең милләт буларак төп билгесе – аның теле. Тел булмаса, милләт тә юк. Безнең, бәлки, көчле милләттә булырга тиешле кайбер нәрсәләрне башкарырга хәлебездән дә килмидер. Тарихи үткәннәр рухны шактый какшаткан. Әмма, теләк һәм үзаң көчле булганда, телне саклауда һәр кешенең үз мөмкинлекләре бар. Моның өчен көчле ихтыяр кирәк! Ә ихтыярны сындыру яки аны бөтенләй булдырмау өчен шартлар җитәрлек. Кайберләрен югарыда әйтеп тә уздык. Хәтерегезгә төшерик: моңарчы гасырлар буе безнең телне халык, нигездә, фольклор, язма әдәбият һәм дин (мәчет-мәдрәсәләр) саклап килде. Соңрак боларга театр, матбугат, радио кушылды. Үткән гасыр урталарына кадәр татарлар яшәгән бөтен җирдә туган телебез, моң-көйләребез яңгырап торды. Мәктәпләрдә уку ана телебездә барды. Хәзер күрәбез: гомуммасштабта алганда, телебезнең таралыш чикләре күзгә күренеп тарайды. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессының күптән түгел генә үткәрелгән корылтаенда да ачынып сөйләделәр. Татар дип саналган мәктәпләргә килеп карасаң, укучыларның нинди телдә күбрәк сөйләшкәннәрен яхшы күрәсең. Татарлар төзегән мәчетләрдә еш кына вәгазьләрне дә русча гына ирештерә кайбер дин әһелләребез. «Шунысы хак: фәкать туган телдә иман иңә кеше җанына!» Эфир-экраннардан, сәхнә түрләреннән «Татарча солянка»ларны еш ишетергә туры килә... Шулай да, минемчә, телебезне саклап калуда бөтен мөмкинлекләр ябылып бетмәгән әле. Шуларның берсе – татар телендәге басмаларны, бигрәк тә иҗтимагый әһәмияте булган әдәби-нәфис басмаларны халыкка мөмкин кадәр күбрәк тарату. Әдәби телнең чыганагы, саклану мәйданы шуларда бит! Кемнәрдер татар матбугатының кыюлыгын, заманчалыгын шик астына да алмакчы була. Татарча чыккан төп басмаларны җентекләп укып баручы буларак, андый фикер белән килешеп үк бетмәс идем. Халыкның үзаңын үстерүгә ярдәм итәрлек бик тә җитди, бик тә төпле язмалар дөнья күрә татар матбугатында. Хикмәт шунда: кемнәр укый аларны, һәм алар күпме? Безнең газета-журналларны, нигездә, анда күтәрелгән мәсьәлә-проблемаларны күптән аңлаган бер үк зыялы даирә укый. Ә фикерләр беренче чиратта ул проблемаларны аңламаган яки аңлап бетермәгән даирәләргә юнәлтелгән! Язмалар төп адресатка барып җитми булып чыга яки ул кешеләр аларны туган телдә укымый... Дәүләт оешмалары, учреждениеләре офисларында, хәтта урам киоскларында татар телендәге газета-журналлар юк дәрәҗәсендә. Булмаганны ничек укымак кирәк! Җитди сүзнең түмгәктән яки биек мөнбәрдән әйтелүендә аерма зур. Кайда һәм кем тарафыннан әйтелүе дә бик мөһим. Фикер матбугатның биш йөз данә чыга торган басмасыннан әйтеләме, әллә биш йөз мең данәлесендә әйтеләме? Минемчә, тарихи тамыры, милли рухы булган басмаларның тиражы кимендә илле мең данәләр булырга тиеш. Ә хәзергә

аларның әбүнәчеләре әйтелгәннән җиде-сигез тапкырга кимрәк. Әйтик, хөкүмәт карамагында калган берничә рәсми басманың татарча гомумтиражы егерме меңнән дә артмый. Фәлән миллион татар кешесенә шуны бүлеп карагыз! Тираж ул – сәясәт, ул – тел язмышы. Бу эшне үз агымына кую – кичерелмәс ваемсызлык. Эшне дәүләти кайгыртучанлык белән оештыра белгәндә, резервлар җитәрлек. Татар теленең дәүләт теле булып саналуы турындагы канунның гамәлдән чыгарылганы юк бит әле!

Тел хәзинәсенең төп асыл бакчасы, әлбәттә, әдәбият, беренче чиратта классик әдәбият. Төптәнрәк уйлап карасаң, төп байлыгыбыздыр әле ул. Җисми байлыкларның, гадәттә, милләте булмый. Алар, яуланып яки таланып, кулдан-кулга күчеп йөри. Әдәбиятны үзләштерү-урлау (милләтләр арасында андый хәлләр дә булгалый!) кыенрак. Әнә шул әдәби байлыгыбызны саклар өчен дә кирәк әле ул туган телебез! Көндәлек матбугат һәм китап басу эше, бергә үрелгән асыл бау шикелле, аерылгысыз. Газета-журналларга кагылышлы проблемалар (тираж, укучылар даирәсе) нәшриятлар эшенә дә хас. Дөрес, республика җитәкчелеге китапның иҗтимагый әһәмиятен ярыйсы ук яхшы аңлый. Китапка мөнәсәбәт начар булса, төп нәшриятларыбыз йөзләгән исемдә яхшы китаплар чыгара алмас иде. Бу хәзергә шулай. Эш башына туган телне белмәгән, татарча бер китап та укымаган, бер җөмлә дә төзи белмәгән яңа буын килсә, эшләр ничек булыр?

Телнең хуҗасы халык булса, калыплаучысы – язучы. Чын язучы талантлы әсәрләр язып, алда әйтеп үтелгән төп байлыгыбызны арттыра. Шөкер, бүген әле безнең классик дәрәҗәдә иҗат итәрлек берничә дистә язучыбыз бар. Табигатьтән бирелгән халык байлыгы бит алар! Саклыйсы, тиешле шартлар тудырып, иҗат иттерәсе генә... Гомер бакый әдәбиятның мәктәпләрдә махсус фән булып өйрәнелүе дә аның төп рухи байлыгыбызның берсе икәнлегенә дәлилдер. Шуңа күрә җан авазы – телнең язучы өчен ни дәрәҗә газиз икәнлеге аңлашыла да. Тел бетсә, әдәбият бетә, әдәбият бетсә, сәнгатьнең күп төрләре юкка чыга. Хәзерге чорда телне саклау өчен көрәш, ул, асылда, милләтне саклау өчен көрәш. Бетерүче факторның басымы арткан саен, каршы тору көче дә бермә-бер арта, көрәш кискенләшә генә. Авар халык шагыйре Рәсүл Гамзатов тикмәгә генә «Әгәр бүген телем бетсә, иртәгә мин үләргә әзер» димәгән инде. Икенче бер халык язучысы, үзебезнең Нурихан Фәттах болай дип язып калдырган иде: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә ник яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым». Әйе, көрәшергә, көрәшергә! (Җәяләр эчендә булса да әйтеп узыйк: әнә, безнең күзлектән караганда, яшәве гарантияләнгән дип саналган телне, ягъни рус телен ничек яклап көрәшәләр. Чит илләрдә, әйтик, Балтыйк буе илләрендәге берәр мәктәптә рус теленә әз генә кагылышлы хәл булса, бөтен дөньяга шаулыйлар!) Ә бездә? Бездә... хәлләр бүтәнчәрәк шул. Бездә һәр ел, һәр көн Туган телне яклау елы, Туган телне саклау көне булырга тиеш тә бит!.. Халык арасында төрле холыклы кешеләр булган кебек, язучыларның да төрлесе бар. Кемнәрдер, бәлки, туган тел кысылса да, әсәрләремне бүтән телләргә тәрҗемә итеп, үземне, халкымны бар дөньяга күрсәтә алам дип тә уйлыйдыр. Ай-һай! Ашы-зәмине булган туфракта гына кешеләр күзе төшәрлек нәфис гөлләр шыта ала.

Туган тел, милли әдәбият язмышы турында язу җиңел түгел. Кайчандыр дәүләтен җуйган милләт баласы өчен бигрәк тә. Каләм йөгергән һәр сүз, һәр җөмлә астында күңелдән саркып чыккан әллә никадәр әрнү, өмет катыш, гасабилану ята... Кайчак уйлап куясың: бу борчулы фикерләрне тезеп утырганчы, бер шәп шигырь язсаң соң! Дөньяда объектив глобаль процесслар бара, барыбер әллә ни кыра алмыйсың... Юк!.. Йон баскан күңелләрен тынычландырып, пошмаслыкларын, битарафлыкларын аклап, андый гәп куертучы «акыллы башлар» бездән башка да җитәрлек. Кояш астында аерым кеше буларак та, милләт буларак та лаеклы урын дауларга теләк бар икән – гамь белән яшәргә, көрәшергә туры килә.

*2007*

## *РУХИ ЕЛЪЯЗМА*

Берәү, галәмәт озын аркан алып, тауның иңен-биеклеген үлчәп, аның авырлыгын белмәкче булган, имеш. «Казан утлары»ның мең санын барлап, аның халык тормышындагы иҗтимагый әһәмиятен ачыкларга тырышу – әнә шул тау авырлыгын үлчәргә тырышуга охшаштыр. Мең сан чыгу дәвере сиксәннән артык елны тәшкил итә. Әгәр татар әдәбияты дигән Олуг Тауның мең еллык тарихы бар дип әйтәбез икән, безнең өчен аның соңгы йөз елга караган өлеше, басма китаплы өлеше аерым әһәмияткә ия. Аны Олуг Тауның бүгенге пигы-түбәсе дип тә санап буладыр.

«Казан утлары»ның мең санлы тупланмасыннан, безнеңчә, бүген дә иҗтимагый әһәмиятен, әдәби кыйммәтен җуймаган әсәрләрдән төзелгән күләмле бу китап-антологиянең кереш сүзендә журнал тарихы турында беркадәр мәгълүмат биреп китү урынлы булыр. Иң әүвәл шуны искәртеп узыйк: милли матбугат кайчан барлыкка килгән булса, иҗтимагый-әдәби басмалар да шул елларда ук чыга башлый. Кагыйдә буларак, һәр басма тирәсенә әдипләр, журналистлар тупланучан. Халык арасында танылуга йөз тоткан һәр басма оста каләм ияләренә, сүз тылсымчыларына мохтаҗ. XX йөз башында чыккан милли матбугатыбызны Р.Фәхретдин, Г.Тукай, Һ.Максуди, Ф.Кәрими, Г.Камал, Ш.Мөхәммәдов, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Дәрдемәнд, Җ.Вәлиди, С.Рәмиев һ.б. исемнәреннән башка күз алдына китерү кыен. Үткән ел татар җәмәгатьчелеге көндәлек милли матбугатның 100 еллыгын билгеләп үтте. Татар әдәби журналларының чыга башлавына да 100 елга якын. Мин моны «Казан утлары»ның башлангычы саналырга тиеш «Әлгасрелҗәдид», «Шура», «Аң» кебек басмаларны күз алдында тотып әйтүем.

Әйе, бүгенге укучы белгән «Казан утлары»ның башлангычын совет чорыннан – 1922 елда чыккан «Безнең юл» журналыннан исәпләү гадәткә кергән. Болай исәпләгәндә дә 84 ел гомер үтелгән. Калын әдәби басмалар арасында 1000 саны дөнья күргән башка журнал илдә юк. Журнал беренче санда ук үзенең колачлы зур басма – аерым җөмһүрият кысаларында гына чикләнмәгән киң даирә басма икәнлеген ассызыклап узган. «Безнең юл» идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә (сөючеләргә. – *Р.Ф.*) мөрәҗәгать» дигән язмада болай диелгән: «Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы Татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без, эчке Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде».

Әйе, озын, катлаулы юл үтелгән. Чор-дәвере дә үтә четерекле, фаҗигале төсмерләргә бик тә бай. Халык ниләр генә кичермәгән дә нинди генә сынаулар үтмәгән бу еллар эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; ак-кызылларга аерылып пычакка пычак килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләреннән нәсел-ыру белән кырылулар да; яңаны төзим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, дин кануннары белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имлаларны кат-кат алыштыра-алыштыра, кыйбласыз, имансыз калулар да; диктаторлардан, сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре «шөреп-винт» хәленә калып, миллионнарның яуларда, сөрген-лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм халык мәнфәгате белән исәпләшмичә, җир-суны мәсхәрә итеп, «бөек-бөек» төзелешләр, хәрби промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял-коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кылып, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә – һәммәсе, һәммәсе булган бу дәвердә!

Яңа, яшь буын вәкилләре бу катлаулы тарихны каян белә алыр соң? Әлбәттә, төп чыганаклар аша. Алар – архив документлары, көндәлек тормышны яктыртып барган газеталар, журнал төпләмәләре. Журналлар димәктән, татар рухын, әдәби-мәдәни тарихын өйрәнүчеләр өчен безнең журнал, һичшиксез, алгы урында булыр. Гаҗәп түгел. Телибезме-юкмы, аңа шундый тарихи миссия насыйп булган. Елъязмасында үз чоры идеологиясе шактый ук чагылыш тапса да, ул, сәясидән бигрәк, беренче чиратта иҗтимагый-әдәби журнал. Икенчедән, журналны тормыш елъязмасын чагыштырмача гадел итеп яза алырлык талант ияләре – язучылар, әдипләр чыгарган; өченчедән, журнал гасыр дәвамында диярлек бер͏өзлексез, тукталмыйча чыгып килгән. Президентның 1000 нче сан чыгу уңаеннан безгә

юллаган котлавында бу хакта бик урынлы әйтелгән. Тагын шунысы да бар: замананың теге яки бу хәлләре, тормыш күренешләре, характерлы типажлары чын әдәби әсәрләрдә төгәлрәк һәм образлырак булып чагылып калучан.

Журнал 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. 30 нчы елдан «Безнең юл», икегә бүленеп, «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы) исемнәре белән басылган. 1933 елдан 1965 елга кадәр – «Совет әдәбияты», ә соңгы дәвердә «Казан утлары» атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, Совет язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты, редакциянең хезмәт коллективы...), титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; сәясәт, сәнгать, экономика һәм әдәби тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да, редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торган. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып килende – «әдәби» һәм «иҗтимагый».

Журналның «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака» исемнәре белән чыккан чоры 1922–1932 елларга карый. Чагыштырмача кыска булса да, ил тормышының үзенчә катлаулы чоры. Революция һәм Гражданнар сугышыннан соңгы авыр вазгыять, Сталин диктатурасының ныгый башлавы, интеллигенциянең аптыраулы хәләте, диннәргә каршы актив һөҗүм, солтангалиевчелекне фаш итү шаукымы, күмәк хуҗалыклар төзү хәрәкәте, әдәби даирәдәге чуарлык һәм таркаулык... Табигый, журнал битләрендә бик ачык чагыла бу хәлләр. Чын әдәби әсәрләргә караганда агымдагы сәясәткә бәйле материаллар күбрәк урын алган заман. Дөресен әйтергә кирәк, әдәбиятның алтын фондына керерлек әсәрләр мулдан түгел бу елларда. Шулай да журнал битләрен зур исемнәр бизәп тора: Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Ш.Камал, Ш.Усманов, М.Җәлил, Х.Туфан, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Ф.Хөсни... Нинди генә чор, нинди генә сәяси тетрәнүләр булмасын, чын талантлы каләм иясенең әсәрендә өлешчә булса да хакыйкатькә тугрылык сакланып калынылa.

1922–1932 елларда, журнал «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака» дип исемләнгән елларда, җитәкче – баш мөхәррир булып Г.Мансуров, М.Бурундуков, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Нигъмәти, Г.Гали торган. Кайбер саннарда исә җитәкчелек «җаваплы редактор – редколлегия» дип тә бирелгән.

Журналның «Совет әдәбияты» чоры 1933–1965 елларга карый. Ил тормышының янә бер катлаулы, драматик чоры. Хәер, Россиядә катлаулы булмаган чор юк та бугай. Халык хәтерендә тетрәндергеч фаҗига булып калган этаплы вакыйгаларны искәртү дә җитә. Репрессия дәвере. Ватан сугышы. Халыкның икмәккә туймаган еллары. Соңрак бераз җиңеллек – Хрущев «җепшеклеге», демократик чалымнарның тормышта чагыла башлавы... Мәгълүм булганча, репрессия һәм сугыш елларында күп басмалар чыгудан туктый яки ябыла. Әмма татарның әдәби журналы яшәвен дәвам итә. Язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклап кала. Соңрак мәшһүр милләтпәрвәр Гали Акыш бу хакта тикмәгә генә болай дип язмагандыр: «Социаль-мәдәни тетрәнүләр фаҗигасен башыннан кичергәндә дә бирешмәгән, сау-сәламәт яшәргә тырышкан һәм шактый дәрәҗәдә шуңа ирешкән журналыбызның эшчәнлеген зур каһарманлык, могҗиза саныйм». Бу сүзләр журналның төрле исемнәрдә чыккан төрле чорларына да карый дип уйлыйк.

Журнал һәрдаим халык тормышы мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәде. Ил язмышы – аның язмышы. Журнал авторларының күбесе сугышта катнашты, байтагы яу кырларында ятып калды. Журнал редакциясе фронтовик язучылар (М.Җәлил, Ф.Кәрим, Н.Баян, А.Алиш, Г.Кутуй, Х.Мөҗәй, М.Максуд, Г.Насрый, Ш.Мөдәррис, И.Гази, Г.Әпсәләмов, Ш.Маннур, А.Шамов, Г.Галиев, Г.Бакиров, Р.Ишморат, Х.Госман, М.Садри, Ә.Маликов, З.Нури һ.б.) белән тыгыз элемтәдә тора, укучыларын аларның әсәрләре белән даими таныштырып бара.

Бу хакта Г.Әпсәләмов фронт хәлләре турында язган мәкаләсендә искә алган бер солдат хатыннан өзек китереп узыйк: «Бүген самолетлардан почта ташладылар... Юеш капчыктан минем исемгә сез җибәргән «Совет әдәбияты» журналы килеп чыкты. Мин аның һәр битен учак җылысында киптереп чыктым, аннары иптәшләр белән бергә җыелышып укый башладык».

Сугыш тәмамлангач, тыныч тормышка сусаган язучылар, киләчәктә якты тормыш буласына нык ышанып, рухланып яңа әсәрләр иҗат итәләр. Г.Әпсәләмовның «Ак төннәр»е (1947), «Алтын йолдыз»ы (1949), «Газинур»ы (1951), М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклына кергән шигырьләре (1953), Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1957), Ш.Маннурның «Муса» (1965) романнары, С.Баттал, С.Хәким, З.Нури, Ә.Маликов һ.б. поэмалары һәм шигырьләре журнал укучыларына җиткерелә.

Илне төзекләндерү чорында журнал сәхифәләрендә халыкның күркәм мораль сыйфатларын, аның тарихи үткәнен, хезмәт сөючәнлеген чагылдыручы яңа әсәрләр – Г.Бәшировның «Намус» (1948), К.Нәҗминең «Язгы җилләр» (1948) романнары, И.Газиның «Онытылмас еллар» (1949), М.Әмирнең «Ялантау кешеләре» (1953), «Саф күңел» (1959), Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» (1959), Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1961), Г.Гобәйнең «Без үскәндә» (1963), Ә.Еникинең «Йөрәк сере» (1958), «Рәшә» (1963), Г.Ахуновның «Хәзинә» (1962), А.Расихның «Ике буйдак» (1964) романнары, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Ш.Хөсәенов, Х.Вахит, Ю.Әминов пьесалары, Х.Туфан, Н.Арсланов, С.Хәким, Ә.Давыдов, З.Мансур поэмалары һәм шигырьләре журнал аша үз укучыларын тапты.

Журналның «Совет әдәбияты» чорының баш мөхәррире булып (бу очракта еллар дәвамында эшләгән язучылар атала. 32 ел дәвамында төрле елларда берничә яки күбрәк санга баш редактор булып кул куйган кешеләр унга якын) К.Нәҗми, Г.Кашшаф, Г.Иделле, А.Гомәр, Г.Мөхәммәтшин эшли.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә җәмгыятьтәге чиктән-чиккә ташланулар, пародокс хәлләр күренеше матбугатта да беркадәр чагылыш тапмый калмады. Бу елларда сүз иреге килгәч, нинди генә газета-журналлар, нинди генә басмалар чыкмады! Укучылар күңелен яуламак булып, «бульвар» яки «вульгар» басмалар ишәйде. Шулай ук байлар һәм түрәләр акчасы бәрабәренә «түр басма» булырга омтылучылар пәйда булды, «без – элит басма!», «без – республиканың визит карточкасы!», «без – академик басма!» дип шапырынучылар да юк түгел. Әйе, танышканда ялтыравыклы визит карточкасы да кирәк була, әмма тормыш иткәндә, хакыйкатьне ныклабрак белергә теләгәндә, хезмәт кенәгәсе кирәк! Үтелгән юлның мәгънәсе анда язылган. Бу яктан, шөкер, «Казан утлары», үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча, очсыз реклама-шоудан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, акча кубызына биемичә, милләтебезнең әхлак кодексына лаек әсәрләр язып, халкыбызның төп җитди журналы булып кала алды. «Казан утлары» – чын мәгънәсендә халык журналы, игенчеләр, укытучылар, эшчеләр, укучы яшьләр, зыялылар журналы. Журнал чын мәгънәсендә халык тормышын чагылдыра, аның язмышы халык язмышы белән тәңгәл бара. Юкса ачлы-туклы елларда да, илне «боз суккан» чорларда да ул сакланып кала алыр идеме? Сугыш кырларында иң кадерле хатлар белән бергә поход сумкаларында йөртерләр идеме? Котып тарафларында яки чүлле Караком якларында, шахта баракларында яки тайга киңлекләрендә күпсанлы милләттәшләребез аны туган як сәламе, ана телебез аһәңе итеп, зарыгып көтеп алыр идеме? Ә инде балачакта ук үзен әдәбиятка багышларга, газетада яки журналда беренче нәни мәкаләсен йә шигырен бастырырга хыялланган яшь җаннар өчен «Казан утлары»ның бәһасен әйтеп торасы да юк...

1000 нче саны чыгу уңаеннан журналыбызның абруен никадәр генә күтәрергә тырышсак та, алдарак әйткәнчә, танырга кирәк: адәм хатадан хали булмаган кебек, заман басымы астында хаклык юлыннан тайпылулары да булгалаган. Гуманизм критерийларына, эстетик идеалларга хыянәт иткән сәхифәләр дә очраштыргалый. Олы талант ияләрен «буржуа ялчылары» дип бәяләүләр дә, чын милләт хадимнәрен «халык дошманнары» итеп фаш итүләр дә, «оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көрәш»ләр дә, коммунизмга алып баручы «юлбашчы»ларга мәдхия укулар да, җирле халык киләчәге өчен шикле һәм куркыныч АЭСларга дан җырлаулар да... Әмма шушы еллар эчендә һәрберсе шактый калын (җыелма бер том!) басма булып дөнья күргән 1000 санның (барлык тиражын җыйсаң, үзе бер галәмәт зур тау булыр иде!) дәрәҗәсен һәм кыйммәтен әле әйтеп узган саташулар билгелиме соң? Юк,

әлбәттә. Соңгы 80 еллар эчендә бар булган иң күренекле әсәрләребез нәкъ менә шушы журналда дөнья күрде, укучыларга, халыкка барып иреште. Сугыштан соңгы әдәби хәзинәбезгә карата бигрәк тә рас килә бу. Йә, шушы журналга мөнәсәбәте булмаган яки әсәрен анда бастыруны дәрәҗә санамаган берәр татар әдибен табып була микән? Яки «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә зур иҗат мәйданында танылу алган берәр язучы булдымы икән? Шунысын да искәртеп узу урынлы булыр: журнал, иң әүвәл әдипләр басмасы буларак, байтак язучыларыбыз әсәрләрен монда бастырып, каләмхак алып, күпмедер дәрәҗәдә матди яктан да файда күреп яши алдылар; журнал үзенә күрә бер социаль яклау үзәге дә булды.

Журнал – әдәби-мәдәни тормышыбызның тарихи елъязмасы, дидек. Әйе, бу чынлап та шулай. Журнал беренче нәүбәттә татар язучыларының иң яхшы яңа әсәрләрен киң катлам укучыларга ирештерә. Бу аның тарихи традициясе һәм бүгенге статусы буенча куелган бурычы. Әмма рухи тормышыбыз әдәбият белән генә чикләнми. Шуңа күрә дә журналга төрле тармакларга «таралып җигелергә» туры килә. Нәфис әдәбияттан тыш мисалга фән дөньясын гына алыйк: гуманитар өлкәдә, бигрәк тә әдәбият, тарих, тел белеме фәннәрендә академикларыбыз, йөзләгән фән кандидатлары һәм докторларыбыз бар икән, моңа кадәр аларның күбесе шушы журналда язышып, хезмәтләрен бастырып, гыйлем үрләрен яуладылар. Аяныч, әле моңарчы театр, музыка, рәсем сәнгате, гомумән, мәдәният тарихы буенча махсус басмаларыбыз булмады диярлек. Шуңа күрә рәссамнар, композиторлар, артистлар, гомумән, сәнгать кешеләре иҗатына журналда шактый мул урын бирелә. Безнең республика шартларында бу вазифаны журнал үзенең бурычы дип санады һәм хәзер дә шул фикердә.

Табигый ки, бер генә халык та фәкать үз кабыгында, үз рухи биләмәсендә генә яшәп зур тәрәккыяткә ирешә алмый. Шуны истә тотып, журнал чит ил һәм күрше-тирә кардәш халыклар әдәбиятының гомумкешелеккә, гуманизмга хезмәт итә торган иң яхшы үрнәкләрен дә хәл кадәри яктыртып килә. Бездә чыккан Жорж Амаду, Гарсиа Маркес, Акутагава һ.б. әсәрләре шуңа мисал. Совет әдәбияты классиклары саналган М.Ауэзов, Я.Купала, И.Эренбург, К.Симонов, К.Кулиев, М.Кәрим, П.Хузангай, Д.Кугелтинов, Р.Гамзатов, Ч.Айтматовларның да кайбер әсәрләре белән укучыларыбыз иң әүвәл безнең журнал аша танышты.

1000 санның яртысы чамасы (489) соңгы 40 елда чыккан «Казан утлары» өлешенә туры килә. Еллар буенча исәпләгәндә, 1965 ел уртасыннан бүгенгегә кадәр. Бу инде безнең заман, күпләребез шаһит булган заман, үзенчә кызыклы, гыйбрәтле, хәтта беркадәр аңлаешсыз заман. Нәрсә белән характерлы соң бу чор? Чагыштырмача тыныч чор: локаль бәрелешләр (сугышның тынып торганы юк аның!) туктамаса да, илкүләм гарасат – зур сугыш афәте булмады; торгынлык һәм үзгәртеп кору еллары кичелде; СССР таркалды; совет хакимияте вакытында тупланган байлык бер тар даирә кулына күчте, «кыргый базар» мөнәсәбәтләре тамыр җәйде, социализм чорында шактый ук нык булган мораль-әхлак принциплары җимерелде. Яңа гасырга күчелде... Чор елъязмачылары саналучы язучы халкы өчен материалга бай, искитмәле кызык чор. Иң мөһиме – сүз ирегә бар, күңелеңдәген курыкмыйча әйтеп була, язып була. Бу кырык елда язучылар гаиләсе эчендә дә табигый алмашыну-яңару процессы барды. Гасыр башында туып, инкыйлаб һәм репрессияләр, Ватан сугышларын кичергән буын (гаҗәп колоритлы буын!) гомер һәм иҗат юлларын тәмамлап, фани дөньяга күчте, алар урынын сугыш чорында үсмер булган буын алып, үтә бер үҗәтлек белән иҗат иттеләр (инде алар да сирәгәеп бара), төп мәйданны 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән буын тота хәзер, инде, үкчәләренә басып, яңа буын аларны да алыштырып килә... Әйткәнемчә, әдәбиятыбыз өчен ифрат бәрәкәтле чор. Бу кырык елның беренче яртысында, шул чор идеологиясе, социалистик реализм методы кысалары (хәер, талант кысаларга сыя алмый!) ирек биргән кадәр, үзләренең иң яхшы әсәрләрен иҗат иттеләр, ә соңгы 15–20 ел эчендә, демократик ирекләр киңәйгәч, төрле жанрларда байтак әдәби җәүһәрләр туа алды. Аларның бөтенесе диярлек иң әүвәл «Казан утлары»нда дөнья күрде. Тулылыкка һич тә дәгъва кылмыйча, шушы чорда төп жанрлар буенча кайбер әсәрләрне күзаллап үтик: прозадан «Туган ягым яшел бишек» (Г.Бәширов), «Әйтелмәгән васыять» (Ә.Еники), «Ямашев» (А.Расих), «Әтил суы ака торур» (Н.Фәттах), «Тау ягы повесте» (Ә.Баянов), «Фронтовиклар» (М.Мәһдиев), «Идел кызы» (Г.Ахунов), «Җиләкле аланнар» (Р.Төхфәтуллин), «Каты токым» (Ш. Бикчурин), «Биектә калу» (М.Юныс), «Язгы аҗаган» (М.Хәсәнов), «Тайгак кичү»

(И.Салахов), «Иртеш таңнары» (Я.Зәнкиев), «Бер ананың биш улы» (Х.Сарьян), «Кубрат хан» М.Хәбибуллин), «Безне өйдә көтәләр» (Х.Камал), «Йөгез, бер дога» (А.Гыйләҗев), «Божра» (Т.Әйди), «Батырша» (Җ.Рәхимов), «Шинельсез солдатлар» (В.Нуруллин), «Җилкәнне җилләр еккач» (Ф.Яруллин), «Хыянәт» (Ф.Латыйфи), «Яра» (Ә.Гаффар), «Сират күпере» (Р.Мөхәммәдиев), «Афәт» (Г.Тавлин), «Сөембикә» (Батулла), «Каргышлы этаплар» (Р.Кәрами), «Таң җиле» (Ф.Садриев), «Тәүбә» (Т.Галиуллин), «Иртәләгән сагыш» (Р.Мир-Хәйдәров), «Караболак» (Ф.Бәйрәмова), «Гөлнәзирә» (М.Әмирханов), «Фидая» (М.Маликова), «Утлы дала» (В.Имамов), «Ат караклары» (З.Зәйнуллин), «Догалы еллар» (М.Галиев), «Ком сәгате» (К.Кәримов), «Албастылар» (Г.Гыйльманов), «Татар вакыты» (А.Хәлим), «Саташып аткан таң» (Ф.Сафин). Шуларга өстәп, С.Сабиров, М.Хуҗин, Р.Фәизов, Җ.Дәрзаманов, Р.Сибат, З.Хөснияр, Ә.Салахов, А.Хәсәнов, Р.Габделхакова, Р.Зәйдулла һ.б. повесть һәм хикәяләре... Татар прозасының үзгә бер антологиясе бит бу әсәрләр! Ә шагыйрьләр? Күп гасырлык татар әдәбиятының нигезен алар салмаганмы? «Әдәбиятның әнкәсе – Шигърият» дип тикмәгә генә тәкрарламыйбыз югыйсә! Көчле шигърият һәрвакыт әдәбиятның үсеш дәрәҗәсен күрсәтеп килгән. Журналыбыз тарихында да ул шулай.

Бу урында журналыбызның поэзия елъязмасын бизәгән кайбер шагыйрьләребезнең исемнәрен искә алып үтик: Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, Ә.Исхак, Н.Арслан, Г.Афзал, И.Юзеев, Ш.Галиев, Ә.Баян, С.Сөләйманова, М.Шабаев, Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, Г.Рәхим, Р.Мингалим, Р.Гаташ, Р.Харис, Ә.Рәшитов, К.Сибгатуллин, Зөлфәт, М.Әгъләм, Р.Вәлиев, А.Хәлим, Ф.Гыйззәтуллина, Х.Әюп, К.Булатова, Р.Юныс, Л.Шагыйрьҗан, Р.Миңнуллин, З.Мансуров, Н.Әхмәдиев, Г.Морат, Р.Зәйдулла, С.Гәрәева, И.Гыйләҗев, Н.Гамбәр, М.Мирза, Ш.Гаделша, Р.Газизов, Р.Корбан, Г.Садә, Г.Мөхәммәтшин; яшьрәкләрдән И.Ихсанова, Р.Аймәт, Л.Янсуар, Г.Бәйрәмова, Л.Шәех... Җөмләдән журнал сәхифәләрендә урын тапкан кайбер күләмле шигъри әсәрләрне дә укучыларыбыз хәтерендә яңартып узыйк: «Чирмешән буйларында (С.Баттал), «Могикан» (Х.Туфан), «Кырыгынчы бүлмә» (С.Хәким), «Йолдызстан» (Роберт Әхмәтҗанов), «Сәйдәш» (Р.Фәйзуллин), «Бүре күзе» (Р.Харис), «Иртәгә» (Р.Мингалим), «Биш таш» (Рәшит Әхмәтҗанов), «Мәңгелек дастан» (Зөлфәт), «Колшәриф» (Ә.Рәшитов), «Тукайдан хатлар» (М.Әгъләмов), «Ике еглау» (З.Мансуров), «Ике мөһаҗир» (Р.Низами), «...Америка фаҗигасе» (Л.Шагыйрьҗан) һ.б. поэмалар, шигъри цикллар...

«Казан утлары»ның актив авторлары—драматурглар Х.Вахит, Т.Миңнуллин, Ю.Әминов, Ш.Хөсәенов, Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, З.Хәким, Д.Салихов... Публицист язучыларыбыз – А.Хәлим, Р.Мостафин, М.Зарипов, Т.Әйди, Р.Юныс, С.Шәмси, Л.Хәмидуллин, Р.Шәрәфиев, Н.Гариф, Р.Хисмәтуллин, Ф.Дунай, М.Әхмәтҗанов... Мәшһүр язучылар, шагыйрьләр белән беррәттән журналның редколлегия әгъзалары булып торган яки үзләренең мәкаләләре, рецензияләре, бәяләмәләре белән әдәби хәрәкәттә актив катнашкан күренекле галимнәр: Р.Нәфыйгов, Х.Госман, Н.Юзиев, Г.Халит, М.Хәсәнов, Ә.Кәримуллин, И.Таһиров, М.Зәкиев, Ә.Борһанов, Ф.Хатипов, И.Надиров, Р.Әмирхан, Ф.Урманчиев, Н.Хисамов, А.Әхмәдуллин... Бүгенге редколлегия әгъзаларыннан – М.Госманов, М.Мәхмүтов, Т.Галиуллин, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Р.Сверигин... Рәсми фәнни дәрәҗәләре булмаса да, академик исемен йөртерлек әдип-галимнәр Н.Исәнбәт, А.Тимергалин, Р.Даутов... Урта һәм яшьрәк буын галимнәреннән Ә.Шәрипов, Ф.Яхин, Р.Рахмани, Д.Заһидуллина, Р.Рахман, Ф.Хәсәнова... Төркиядә яшәүче Н.Дәүләт, Ч.Зариф... Гомумән, бу очракта Татарстаннан читтә яшәүче авторларыбызны аерым бер игътибар белән билгеләп үтү дөрес булыр. Гомумтатар журналы буларак, милләттәшләребез күпләп яши торган урыннарда язучы авторларыбыз булу табигый. Әйтик, Мәскәүдә гомер-гомергә татар язучылары яшәгән; элгәрегеләрдән М.Галәү, Ә.Фәйзи, Ә.Ерикәй, М.Максуд... бүгенге көндәге авторларыбыздан – М.Юныс, Н.Кәримова, Ә.Саттар... Бүтән төбәкләрдә яшәгән яки бүген дә яшәп иҗат итүче авторларыбыздан: С.Кудаш, Н.Нәҗми, Ә.Атнабаев, Р.Идиятуллин, Х.Мөдәррисова, М.Кәбиров (Башкортстан), И.Салахов, Ә.Хәмидуллин (Казакъстан), Р.Вәлиев, И.Сабиров (Чиләбе өлкәсе), Р.Сибат (Киров өлкәсе), Б.Рафиков (Троицк), Ә.Синугыл (Ташкент), Ф.Мортазин (Кырым), Иделбикә (Ульяновск), И.Аширов (Пермь өлкәсе), И.Хуҗин (Свердловск өлкәсе). Янә чит илләрдә яшәүче авторларыбыздан Н.Измайлова (АКШ), Л.Садри (Австралия). Үзем кәгазьгә җанга якын таныш исемнәрне тезәм, үзем ирексездән кайчандыр язылган шигырь юлларымны кабатлыйм: «Кемнәр бар да кемнәр юк!..»

Бу чорда чыккан әсәрләрне барлаганда, аларны язган язучылар үзләре күз алдыма килеп басты. Аларның һәммәсе белән диярлек таныш икәнмен. Нәкъ 1965 елны, «Совет әдәбияты» «Казан утлары» булып чыга башлаганда, мин редакциядә штатта идем инде. Кемнәр эшләде соң бу кырык ел эчендә редакциядә? Н.Арслан, Л.Ихсанова, И.Юзеев, Ә.Баян, Ф.Миңнуллин, Я.Халитов, М.Хәмитов, В.Нуруллин, К.Тимбикова, Г.Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф.Бәйрәмова, Т.Әйди, Мөдәррис Вәлиев, Р.Мөхәммәдиев, Х.Зарипов, Ә.Гаффар, М.Галиев, С.Шәмси, З.Мансуров, Р.Миңнуллин, Җ.Миңнуллин, Н.Акмал, А.Сәләхетдинов, К.Сәгъдәтшин, Ш.Маннапов, Ф.Латыйфи, М.Шабаев, Н.Гамбәр, М.Хуҗин, Ш.Мостафин, Ф.Сафин, Г.Гыйльманов, Ә.Рәшит... Бу язучыларның унга якыны инде арабызда юк...

...Журналыбызның «Казан утлары» чоры баш мөхәррирләре: Р.Мостафин, Г.Ахунов, З.Нури, Р.Харис, Р.Фәйзуллин.

Бүгенге көндә дә журналыбыз редакциясендә танылган язучылар эшли. Р.Гаташ, Р.Юныс, Р.Низамиев, Мансур Вәлиев, К.Кәримов, А.Гыймадиев, М.Закир, Р.Мәрдәнов, Р.Сәгъди... Шуларга өстәп янә җиде кешелек тәҗрибәле гамәли хезмәткәребез бар. Шунысы характерлы: «Казан утлары»нда бер эшли башлаган кеше хезмәт урынын алыштырырга җыенмый диярлек, еллар буе басылып эшли бирә. Арабызда утыз-егерме еллар эшләгән хезмәттәшләребез бар. Шунысы да игътибарга лаек: заманында гамәли яки штаттан тыш хезмәткәр булып эшләгән сәләтле кайбер яшьләр үзләре үк язучылар булып китте. Мисаллар җитәрлек. Үзем дә, шактый еллар бу журналда хезмәт итеп, әлеге 1000 санның 200 енә баш мөхәррир сыйфатында кул куеп чыгарганмын икән. Яшермим, эчке бер горурлык хисе уята торган сан бу минем өчен. Шушы зур китап чыгу уңаеннан, кем булып эшләсә дә – типографиядә яки компьютерда хәреф җыючымы, әллә баш мөхәррирме, бүлек мөдиреме яки корректормы, сәркатип яки хисапчымы, редколлегия әгъзасы яки шофермы, бүгенге яшь хезмәттәшебезме яки ветеранмы, исәнме, әллә гүр иясеме – һәммәсенә рәхмәт әйтәсе, искә аласы килә.

Тыелган яки онытылган әдәби мирасны халыкка кире кайтаруда журнал эшчәнлеген әйтми узсак, язмабыз тулы булмас иде. Бер генә исемне аерып әйтү дә күп нәрсәне аңлата булыр: бөек әдип Гаяз Исхакый. Аның төп зур әсәрләре бүгенге укучыларга иң әүвәл безнең журнал аша барып ирешә. Бу исемгә өстәп – С.Максуди, Й.Акчура, Г.Баттал, Г.Газиз, С.Җәләл кебек олуг затларның иҗат үрнәкләре. Борынгы мирастан – «Йосыф кыйссасы», «Идегәй» дастаны... Саный китсәң, алар үзләре күптомлыкларга җыелыр...

Кайчак күңелгә шундый самими уй килә: безнең журнал турында тәфсилләп сөйләп торуның хаҗәте дә юк, аны бөтен татар дөньясы белә! Әйе, бу – дөрескә якын хакыйкать. Чыннан да, үзен зыялы, мәгърифәтле дип санаган, милли җанлы һәр татар гаиләсенә барып ирешә торган басмага әверелгән иде ул. Йөзәр мең тираж белән чыккан чаклары булды, дөньяның татарлар яши торган бөтен кыйтга-төбәкләрендә алдырдылар аны, укучылары да миллионлап исәпләнде. Әмма бу күрсәткечләр, ни кызганыч, инде үткән гасырга карый. Объектив дип әйтерлек җитди сәбәпләр дә җитәрлек. Күреп торабыз: соңгы дистә еллар эчендә кешелек дөньясы искитмәле үзгәрешләр кичерде. Фән һәм әхлак өлкәсендә бу үзгәрешләр бигрәк тә нык сизелә. Аларның уңае да, тискәресе дә һәммәбезгә – тулы бер халыкка да, аерым индивидиумга да кагылмый калмады, билгеле. Компьютер заманы китапны, басма сүзне кысрыклый башлады, иҗтимагый тормышта әдәби сүз көченә ихтыяҗ кими төште... Өстәвенә, СССР таркалгач, геополитик хәл нык үзгәреп, татарлар күпләп яши торган регионнар республикалардан аерым мөстәкыйль дәүләтләргә әверелгәч, мәдәни бәйланышлар кимеде, татар телендәге басмалар ул җирләргә ирешә алмый башлады... Шулай да бирешергә исәп юк (ярамый да!), бүгенге көндәге тиражыбыз Россиядә чыгып килә торган калын әдәби журналлар белән чагыштырганда шактый югары әле. Әмма... «безнең журналны бөтен татар дөньясы белә!» дип сөрән салу беркатлылык булыр иде. Шуңа күрә, бу язмамда безнең басманы электән белгәннәрнең хәтерен яңартып, яңа буыннарга сабак-гыйбрәт булсын дип, журналыбыз тарихы турында беркадәр бәян итүне кирәк санадым.

Әйе, озын-озак еллар ераклыгыннан караганда, халык тормышында журнал үзенең асыл функциясен үтәгән. Әмма «яңа заман, яңа җырлар» дигәндәй, һәр чор һәркем алдында яңа бурычлар, яңа таләпләр куя. Иҗтимагый тере организм буларак, журнал алдында да тора ул бурычлар. Глобальләшү киң колач алган дәвердә үз халкыбызның кабатланмас йөзен, рухи мирасын саклау, аны цивилизацияле ил-халыклар рәтендә киләчәккә алып бару, телне, әдәбият-сәнгатьне үстерү, әлбәттә, журналның төп бурычларыннан берсе. Шуңа күрә дә

Татарстанның дәүләтчелеген яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруда ярдәм итүне «Казан утлары» иң җаваплы бурычларның берсе дип саный. Әгәр Казан бөтен дөньяга сибелгән татарларның тартылу кыйбласы булса, «Казан утлары» – туган телне хөрмәт иткән барлык милләттәшләребез өчен мәгърифәт, гыйлем учагы. Шуңа күрә дә милли бердәмлек сыналган, «кеше җаны өчен көрәш барган» заманда, китап сүзенә игътибар кими төшкән дәвердә без – язучылар – бу журналда чорның югары таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр язарга тиешбез.

Сүземнең ахырын янә шушы китап турында әйтеп төгәлләргә телим. Төзүченең кереш аңлатмасында беркадәр әйтелгәнчә, без бу китапны (бөтен әдәби хәрәкәтне, шәхесләрне, әсәрләрне колачлап бетерә алмасак та) татар тормышына караган гасырга якын дәвернең рухи елъязмасын күз алдына китерерлек уникаль басма булырдай итеп чыгарырга тырыштык. Китаплы халык варисларында мондый теләк булуы табигый, әлбәттә. Хәзер, шөкер, яхшы китаплар шактый чыгып килә. Дөрес, элегрәк тә вакыйга булырлык басмалар булмады түгел. Мәсәлән, «Татар поэзиясе антологиясе» (1957), соңрак – тулыландырылган икенче басмасы (1992), Н.Исәнбәт төзегән «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгы (1959–1967), «Татар хикәясе антологиясе» (2001) үткән гасыр ахырында, ниһаять, милләтнең мәдәнилек дәрәҗәсен чагылдырган татар энциклопедиясе томлыкларын күрүгә ирештек. (Сүз уңаеннан әйтеп үтик: энциклопедияләргә кергән байтак белешмә-мәкаләләрнең ныклы бер ышанычлы чыганагы «Казан утлары» журналы булды.) Саналган җыйнама-фәнни китаплар һәрберсе кабатланмас вакыйгаи басма саналырга хаклы. «Казан утлары»ның 1000 нче саны чыгу уңае белән нәшер ителгән «Сүнмәс утлар балкышы» китабы да күп меңләгән укучыларыбызның китап киштәләре түрендә урын алыр, иң мөһиме – рухи мирасыбыз белән, әдәбият тарихы белән кызыксынган һәр кеше өчен кирәк һәм файдалы әсбап булыр дип ышанабыз.

*2007*

## *ЕЛЛАР УЗГАН САЕН, ГАМЬ АРТА*

«Ахырзаман алдыннан кырык ел кырык көннән дә тизрәк узар» дип ишеткәли идек бәләкәй чакларда. Гомернең бик тиз узуын үзеңдә тойгач, гасабиланып, кайчак ышана язасың бу сүзләргә. Дөрес, сырхау кешеләргә, зиндандагыларга, кавышу көннәрен көткән гашыйкларга вакыт бик озак үтә кебек тоеладыр... Әле кайчан гына, яңа XXI гасырга аяк басабыз дип, мәш килеп йөрдек, инде бу гасырның да сигез елы үтеп киткән... Сау кешегә унынчы елы да җитәр, егерменчесе дә...

Яңа елга кергәндә, һәр кеше, үткәнен, соңгы елларда кылынган гамәлләрен искә алып, киләчәктә ничек яшәү турында ниндидер хыял-планнар кормый калмыйдыр; үз дөньясындагы хәлләрне бүтәннәрнеке белән чагыштырып, гыйбрәтләр аладыр, китапчалап әйтсәк, үзенең җәмгыятьтәге урыны хакында да уйланадыр. Табигыйдер, мин дә уйланам, соңгы вакытларда ешрак уйланам. Гомерлеккә дип сайлап алган һөнәр-эшемнең нәтиҗәсе бүтәннәргә кирәкме? Кирәк булса, ни дәрәҗәдә кирәк, һәм ул ничек бәяләнә? Шәхсән үзем рухи һәм матди канәгатьлек табаммы? Ахыр чиктә, бер шигырьдәгечә әйтсәк, «бәхетлеме кеше дөньяда?..» Мондый уйланулар иҗат кешеләре өчен аеруча хас булса кирәк.

Мин ярты гасыр чамасы татар әдәбиятының үзәгендә кайнаган кеше. Шуңа күрә Яңа ел алдыннан язылган бу мәкаләмдә дә төп сүз әдәбият турында, аның нигезен тәшкил иткән Туган тел турында, аның дәрәҗәсен билгеләгән Галиҗәнап Китап турында, аны илһамланып тудырган иҗатчылар турында булыр.

Безнең буын – Китапны (бу очракта иң әүвәл әдәби китапны истә тотып әйтәм) изгеләштереп, аны могҗизага санап яшәгән бәхетле буыннарның берсе. Без Китапка табындык, ул да үзен олылаганнарга мәрхәмәтле булды, аң-белем бирде, дөньяны танып белүдә маяк булды, тәрбияләде, кеше итте. Хәтерлим: студент елларында берәр яхшы китап кулга эләксә, кош тоткан кебек сөенә идек. Моннан утыз-кырык ел элек, берәр зур язучының яңа әсәре журналда басылса яки китап булып чыкса, аны укыр өчен китапханәләрдә озын-озын чиратларга язылалар иде. Атаклы язучының теге яки бу яңа әсәрен укымасак, ничектер уңайсызлык тоеп, үзебезне зыялы саный алмый идек.

Гомумән, Китап безнең халык тормышында аерым бер зур урын тоткан. Шуңа күрә дә, үткән гасыр мәгълүматларына караганда, татарлар китап бастырып чыгару буенча Россия империясендә иң алдынгы урыннарның берсендә булган. Күрәсең, хакимлеген җуйган халыкта китап күпмедер дәрәҗәдә дәүләти (әйтик, мәгърифәт өлкәсендә) функция дә үтәп килгән. Хәзер вазгыять бик нык үзгәрде. Күпләр аңында китап байлык саналмый бүген. Хакимият тә аны инде артык көчле идеологик коралга исәпләми. Дәүләт карамагындагы китап сөючеләр җәмгыятьләре гөрләп эшләп торган заманнар узды. Күпләр китаптан йөз чөерде. Китапның статусы төште, ул асылда товарга әйләнде. Әдәбиятны чүп басты. Акчасы булган һәр теләгән кемсә «китап» чыгара башлады...

Япон яки немец кебек халыкларда китапка мөнәсәбәт ничектер, белеп бетермим, ә безнең шартларда чын әдәбиятның хәле менә шулайрак. Китапханәләрдә ачып та каралмаган басмаларны, нәшрият складларында сатылмыйча яткан өем-өем китапларны күргәч, җан әрни... Сәбәпләрен төрлечә аңлаталар. Берәүләр моны телевизор, Интернет нәтиҗәсе ди, берәүләр яшь буынны битарафлыкта, әхлаксызлыкта гаепли. Һәркайсында күпмедер хаклык бардыр, бәхәсләшмим... Шулай да бу хәлгә төшүебезнең иң төп сәбәбе – идеологик ориентирларның тиз вакыт эчендә капма-каршы якка үзгәрүе, минемчә. Кичә генә коммунизм төзергә әзерләнүчеләр капылт кына капитализмның күндәм тарафдарлары булды да куйды! Базар мөнәсәбәтләренә күчтек, дидек бит. Ә базарның Алласы, әлбәттә, әхлак түгел, акча. Моннан берничә ел элек биш яшьлек улым әйтеп куймасынмы: «А» хәрефе акчадан башлана... Менә шулай...

Бер шагыйрьнең мондый юллары бар: «Бөтен прогресслар да регресс була, әгәр Кеше эчтән таркалса...» Уйландыра. Фәннең иң бөек казанышлары, асылда, Кешенең үзен харап итүгә юнәлтелгән. Хәрбиләр, Җир шарын пеләш итәрлек көч бар, дип мактана. Ә китап, бу очракта әдәбият, гомумән сәнгать, моңарчы кешене Кеше итүгә хезмәт итте. Китап – цивилизация казанышының бер билгесе, халыкларның күп гасырлар, мең еллар буе җыелып киленгән бөек хәзинәсе. Китап – хәтер ул. Кешелек үз хәтерен җуймаска тиештер бит инде!..

Язучылык хезмәте турыдан-туры тел белән бәйле. Ул аның «эш коралы», яшәү чыганагы, язмышы. Хәер, үзен туган халкы вәкиле дип санаган һәркем өчен тел язмыш булырга тиеш. Төптән уйлап карасаң, тел – безнең иң төп байлыгыбыз. Анда безнең рухыбыз, тарихыбыз, иманыбыз, хәтеребез... Ул – үзенә һәммәсен туплаган бөек көч. Заманында җиңелгән халыкның бар байлыгын талап ала алганнар, илләрен җимереп тузгытканнар, яндырганнар, изге җирләрен мәсхәрәләгәннәр... Әмма тел дигән төп байлыкны тиз генә юк итә алмаганнар. Чөнки «тел» дигән төшенчә «үлемсезлек» дигән сүз белән янәшә, үзенчә аның синонимы. Туган телебезнең тарихи язмышы гаять катлаулы, аянычлы. Кайчандыр дөнья тоткан халык-ара дипломатик телләрнең берсе булган хәзинәбезне бетерер өчен әллә ничә гасырлар буе рәхимсез һөҗүм бара. Шулай да, күпсанлы инквизация чорларын үтеп, һаман исән кала алган үзе. Наҗар Нәҗми әйткәнчә:

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере...

Хәзер дә әле, галимнәр әйтүенчә, төп дөнья телләренең ундүрте арасында исәпләнә ул. Әмма...

Моннан бер ел чамасы элек, 2007 елның декабрендә, Россия халыкларының (рустан тыш) телләренә янә бер җимергеч удар ясалды, үзенә күрә бер Яңа ел «бүләге» булды. Ул да булса – Дәүләт Думасы карары һәм Президент В.В.Путин имзасы белән мәгариф стандартларыннан милли-төбәк компонентын төшереп калдыру турында 309 нчы сан белән беркетелгән антиконституцион федераль закон. (Бу җәһәттән Президентның Казанда 2002 елда ясаган чыгышындагы сүзләре хәтергә килә: «Абсолютно недопустимо, если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка».) Мәгънәсе – милли телләрне мәктәпләрдән сөрү. Максаты – балаларда гомумроссия үзаңы тәрбияләү. Икенче төрле әйткәндә, алардан рус ясау. Мин моңарчы гомумроссия үзаңын башка милләтләрнең үзаңыннан (үзаңны телдән башка күз алдына да китереп булмый) укмаша дип уйлый идем. Шунысы сәер: аларча, җирле элита мәктәпләрне үз сәяси максатларына ирешү өчен файдалана, мәктәпләрдә милли телдә укыту Россиянең бердәмлегенә яный икән! Таныш нәрсә – кириллицадан бүтән имлага күчү

мәсьәләсендә дә мондый «дәлилләр» яңгыраган иде инде (чынында менә шундый законнар Россияне таркатуга этәрергә мөмкин). Кеше хокукларын боза торган мондый канунның соңгы чорда булганы юк иде әле. Әйтик, совет чорында туган телдә укымау яки укытмау турындагы фикер башка да сыймый иде. Ә болай, статистикага баксаң, милли мәктәпләрне бетерү процессы бик «хутлы» бара икән. Моннан өч ел элек илдә 712 татар мәктәбе саналса, хәзер ул 490 га калган... Әмма шунысы гаҗәп: безнең чиновниклар биргән хисап-отчетларда туган телдә укыту гөрләп бара. Татарча укытыла торган мәктәпләр республикада 59 % тәшкил итә икән! Татарча укый торган балалар саны 1991 елда 12 % булса, 2008 елны ул 53 % ка менгән! Кәгазьдә әйбәт бит! Мәскәүне сискәндерерлек дәрәҗәдә әйбәт. Мәктәп классларындагы тәрәзәләр татарча авазлардан зеңләп тора!..

...Канашевич заманнары хәтергә килә. Телен онытсаң, тарихын җуйдырсаң, көй-моңнарыннан биздерсәң, үзаңын бетерсәң, чукындыру да күпкә җиңел булачак. Татар гаиләләрендә нәсел шәҗәрәләренең иң өстәге үсентеләренә игътибар итсәң, аларда чиркәү күңеленә хуш килә торган исемнәрне шактый күреп була. Үз илеңдә, тарихи туган җиреңдә үзеңне икенче сортлы итеп сизү кыен. Татар фамилиясе йөртеп тә, үз халкы мәнфәгатьләрен күптән оныткан кешеләр, бәлки, үзләрен алай хис итмидер, ә Туган тел варисларының бу мәсьәләгә фикере бердәм һәм катгый. Бу җәһәттән моннан нәкъ бер ел элек Татарстан Язучылар берлеге идарәсе белдерүеннән кайбер өзекләр китерү урынлы булыр: «Дәүләт думасы һәм Федерация Советы тарафыннан кабул ителеп Россия Президенты кул куйган әлеге закон Россиядәге милли мәктәпләрдә туган тел һәм әдәбиятны укытуны, туган халык тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүне, нигездә, юкка чыгаруга корылган.

Федераль закон моңа кадәр Россиядәге милли мәктәпләрдә әлеге фәннәрне укыту һәм өйрәнүдә милли-төбәк компонентын юкка чыгара, икенче төрле әйткәндә, ул Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешен чикли.

Әлеге законны тормышка ашыру милли мәктәпләрнең ябылуына, гамәлдә мәгариф системасының кире «җитлеккән социализм» чорына кайтуына тиң. Бу исә халыкара закончалык актларын, милли республикалар законнарын, Россия Федерациясенең үз Конституциясен тупас бозу.

Нәтиҗәдә меңьеллык тарихы булган татар әдәбиятына алга таба үсүеннән тукталу куркынычы яный».

Күрәсең, югары даирәдәгеләр Россиядә милли мәсьәләләр инде хәл ителде дип уйлыйдыр. Юкса Президент юлламаларында, җитәкчеләрнең илкүләм чыгышларында, күңел хакы өчен генә булса да, милли мөнәсәбәтләр, милли мәдәният, әдәбият-сәнгать турында хет бер кәлимә-сүз әйтерләр иде! Совет чорында «формасы белән милли, эчтәлеге белән интернациональ» дигән кагыйдә сыман тәгъбирләр сәясәтчеләрнең һәрдаим телендә иде. Элек СССР составында яшәп, соңрак мөстәкыйльлек алган халыкларда безнең алга карачкыдай килеп баскан әлеге законнарның, проблемаларның булуын күз алдына китерү мөмкинме? Юк, әлбәттә. Ә бит күптән түгел генә күпмилләтле держа250ның, арттарак булса да, гомумсафында идек. Соңгы вакытларда, рус кына түгел, «россия милләте» (америкалыларга иярептер инде) дип тә сөйли башладылар. Шулай икән, димәк, Координацион үзәк – милли мәсьәләләр буенча министрлыклар да кирәк түгел булып чыга. Әмма берәүгә дә шуны онытмаска иде: милли мәсьәләләр – алар мәңгелек. Гомумяшәеш, көндәлек тормыш шуны раслап килә.

Җире уртак, дибез, эше, таңы...
Ә шулай да
һәр кавемнең
аерым-аерым каберстаны.

Тукай сүзләре искә төшә:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хаккыбыз уртак Ватанда шактый ук!

Әйе, хакыбыз яки хаккыбыз зур. Нәселем тарихыннан бер генә мисал: минем ерак бабам, ягъни әтинең бабасы патша армиясендә егерме биш ел хезмәт иткән. Бабам Гражданнар сугышында һәлак булган. Әти Ватан сугышында яраланып, гарип булып кайтты. Үземә дә солдат шулпасын чөмерергә туры килде. Улым Себер якларында хезмәт итте... Без әле яллы казаклар яки гаскәриләр династиясеннән түгел, нигездә, игенчеләр нәселеннән. Берничә буын шушы уртак Ватанны саклаган, яклаган, ил-күз алдында бурычлы булып калмаган. Мондый мисалларны миллионнар китерә алыр иде. Ватан сугышы чорындагы Советлар Союзы геройлары арасында татарларның алгы сафларда булуы да искә төшә. Соңрак, СССР дигән илнең нык үсешендә Татарстанда – минем ил-җиремдә чыккан кара алтын – нефтьнең хәлиткеч роль уйнаганы да хәтергә килә. Мине, шушы җирнең хакыйкый гражданы һәм халык язучысы буларак, телемне кысрыклый һәм кимсетә торган мондый мәкерле кануннар рәнҗетә. Россия «индеецлары» булып саналасы бер дә килми. Балаң дәүләт мәктәбендә фәннәрне туган телендә укый алмасын да, туган телемдә язган әсәрләремне укучылар бетерелсен дә, ничекләр итеп илһамланып иҗат итәргә кирәк? Каләмең үзеннән-үзе кулыңнан төшәр...

Үзеңне япа-ялгыз итеп сизсәң, ул шулай булыр иде дә. Әмма бу мәсьәләдә без ялгыз түгел. Гавам-халык дәррәү күтәрелеп чыкмаса да (милли аң түбәнрәк шул!), бик күпләрне кузгатты әлеге кыланмыш. Җавапсыз кабул ителгән канунга җавап таләп ителә башлады. Төрле милли республикаларда, өлкәләрдә яшәүче сәясәтчеләр, зыялылар кузгалды... Ноябрьдә Казанда узган зур киңәшмә шуны күрсәтте. Монда Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләре, әлеге законны әзерләүчеләр дә катнашты. Россиядә яшәүче егермедән артык төбәкнең дәрәҗәле вәкилләре бу законсыз законга бердәм каршы чыкты. Шунысы факт: хәрәкәт башында Татарстан торды, аның җитәкчеләре үзләренең саллы дәлилләре белән Мәскәү вәкилләрен дә уйга салды. Горурлык хисе кичердек җитәкчеләребез өчен. Бәхәсләрнең ахыры ничек булып бетәр, әйтүе кыен. Үз араларында Жириновский кебекләр һәм башка шовинистлар өере шактый булган Думаның үз сүзен кире алуы икеле. Шулай да яхшыга юрыйк.

Миңа калса, татарның бүгенге көндәге иң мөһим бурычы – туган телне саклап калу. Тел исән булса, сәнгать тә, көй-моң да, әхлак та сау калыр. Шуңа күрә тел сагында торган кешеләр фидакарь саналырга, аларның кылган хезмәтләре тиешенчә бәяләнергә тиеш. Телебезне, милли рухыбызны читтән килеп сакламаслар. Әдәбият-сәнгать спорт түгел. Спорт димәктән, уенчылар хөрмәттә хәзер. Сәясәт уен булгач, югары даирәләргә, бәлки, уйлаучыларга караганда уйнаучылар күбрәк ошыйдыр? Мин үзем дә спортка мөкиббән кеше, әмма шунысын беләм: спортчыга Ходай Тәгалә физик һәм ихтыяр көче бүләк итсә, иҗатчыга илаһи көч насыйп әйләгән! Кайсы зуррак? Тарих соңгысын тамгалый. Заманында гладиаторларны да халык шашып тамаша кылган. Чорлар узгач, алар онытылган. Ул чорларның истәлеге булып сәнгать әсәрләре калган. Әгәр Спартакны беләләр икән, аны да халык хәтере аша, миф-легендалар, сәнгать аша беләләр. Безгә, татарстанлыларга, күпчелек халык мохтаҗ яшәгән елларда, зур акчалар бәрабәренә сатып алынган (бу очракта чит-ят спортчылар белән төзелгән контрактларны әйтүем) җиңүләр белән артык шапырынырга яки беркатлы фанатларча эйфориягә бирелергә кирәкмидер. Легионерлар килер дә китәр, ә менә тел сагында торучы фидакарь затлар ахыргача үз халкы белән булып, ахыргача аның шатлык-кайгысын уртаклашыр. Шау-шулы Олимпиадалар да, Универсиадалар да булыр, Сөләйман пәйгамбәр әйтмешли, барысы да үтәр... Әгәр тарихи туган җиремдә телем, моң-көем юкка чыкса, андагы зиннәтле корылмаларның, күктерәр биналарның минем өчен ни кызыгы булыр икән?

Яшәешнең, халык тормышының кайсы ягы турында уйлансам да, уй-фикеремнең очы Туган телгә барып тоташа. Күрәсең, эшем-һөнәрем, профессиям белән дә бәйледер инде бу. Күп еллар элек бер танышым, Тукайның «Туган тел»ен бераз үзгәртеп, болай дип укып биргән иде:

И Туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп кыен күрдем син Туган тел аркылы!

Аптырагач әйткәндер инде... Чыннан да, соңгы дәвердә татар теле тулы хокуклы булып яңгырасын өчен, иҗтиһат итү юлында күпме асыл башларның маңгайлары ярылды! Чагыштырмача кыска гына вакытта берничә тапкыр алфавит-имла алыштырып кара әле! Юкка дип әйтерлек күпме көч-җегәр сарыф ителгән! Мәдәният-мәгърифәт тарихында

парадоксаль-уникаль күренеш. Ә «әткәм-әнкәмнең теле» дигәнгә искәрмә өстәргә туры килә хәзер. Телебез, әйтик, синең белән минем өчен әткәм-әнкәм теле булса, хәзерге күпчелек яшьләрнең әнкә телләре бүтән бүген!.. Сабыйның теле башка телдә ачыла, чөнки аның әти-әнисе туган телен оныткан инде. Телебездә без аңлаган Ана теле (мәктәп көндәлекләрендә шулай яза идек) дигән гаҗәеп матур сүзтезмә югалып бара...

Гомумән, татар теле генә түгел, бүтән телләр дә алынма яки чит-ят сүзләр хисабына гаҗәеп үзгәрешләр кичерә хәзер. Бу үзгәрешләрне гел яхшы якка дип әйтмәс идем. Мисал өчен унбиш-егерме сүз язып үтим: президент, бизнес, дефолт, толерантлык, СПИД, казино, инфляция, шоу, стресс, интернет, фонограмма, террор, мафия, наркоман, риелтор, рейтинг, сепаратизм, банкомат, саммит, рэкет, олигарх... Тагын йөзләрчә сүз тезәргә мөмкин. Боларны без, радио-телевидение тапшыруларыннан яки газет-журналлардан булсын, көнозын ишетеп торабыз. Моннан утыз-кырык ел элек аларның кайберләрен ерак илләрдә яңгырый торган, атама-терминнар итеп кенә белә идек, кайберләре безнең сөйләмдә гомумән юк иде. Төптән уйлап карасаң, дөрестән дә, алар бит безнең бүгенге чынбарлыкны чагылдыра. Аның каравы балачактан ук безнең өчен газиз сүзләр, әйтик, намус, әхлак, вөҗдан, тәүфикъ, инсаф, әманәт, самими, шәфкать, мәрхәмәт... кебек сүзләрне көннән-көн сирәгрәк ишетәбез. Хәер, болар турында сөйләү үзе бер аерым тема.

Уйландыра: бүгенге көндә телебез кайларда саклана, нинди даирәләрдә яңгыравын дәвам итә соң? Әлбәттә, гаиләдә. Әлбәттә, мәктәптә (дөресрәге, булырга тиеш). Хезмәт-эш урыннарында (шәһәрдә – азрак, авылда – күбрәк. Халыкның иң зур күпчелеге – шәһәрдә, авылда яшәүчеләр елдан-ел кими). Тагын кайларда? Радио-телевидение каналларында. Сәхнәдә – театрларда, тамаша-концерт залларында... Дин йортларында – мәчет-мәдрәсәләрдә. Базар-мазарларда... Әмма затлы, классик телнең нигез-куышы – әдәбият, матбугат. Халыкның гасырлар буе җыйналып, чарланып килгән асыл җәүһәрләре – аларда. Бәс, шулай икән, милли матбугатка – китапларга, газета-журналларга аерым бер игътибар, нәшриятлар, басмаханәләр җитештергән рухи кыйммәтләрне киң халык массаларына җиткерүдә аерым бер дәүләти караш булырга тиештер бит инде. Татар телендә чыккан матбугат бик аз тарала. Безгә һәр данә кадерле. Әгәр гаилә өстәлендә туган телдәге берәр газета-журнал ятса, аны яше-карты, берсе булмаса, икенчесе укый, карый ала. Тиражлар үткән дистә еллар белән чагыштырганда көлке дәрәҗәдә аз хәзер (элегрәк йөзәр мең, яртышар миллион белән чыккан журналларның тиражы күп дигәндә ун мең данә). Димәк, күпме рухи һәм матди чыгымнар тотылган хезмәт нәтиҗәсенең файдалы эш коэффициенты түбән булып чыга. Ә сәяси яктан? Төрле дәрәҗәдәге эш башында утырган идарәчеләрнең мотлак күпчелеге татар телендәге матбугатны укымый. Бик үк югары даирәләргә сикермичә, әйтик, министрлык яки район җитәкчеләреннән Россиядә иң абруйлылардан саналган безнең «Казан утлары» журналын кемнәр генә яздыра һәм укый икән? Ә бит егерменче елларда, милләтнең совет чорындагы күтәрелеш елларында җитәкчеләр һәммәсе укыган, контрольлек иткән, юнәлеш биргән, кирәк чакта тәнкыйтьләгән, киңәшкән. Матбугат алар эшенең табигый бер өлеше, кайчакта ориентир да булган. Эш – үткәнне сагынуда түгел, бүгенге өчен әрнүдә. Ә кызыксынган, укыган кеше өчен шактый ук югары кимәлдә безнең татар матбугаты! Тирән эчтәлекле, хакыйкатькә тугры, кыю фикерле мәкалә-чыгышлар җитәрлек аларда. Укы, чагыштыр, гыйбрәт ал. Тармак яки хосусый басмалар гына түгел, рәсми газета-журналлар да заманча, халыкчан рухта чыга бүген. Газеталардан берничәсен генә әйтеп узыйм. Зур тарихлы «Ватаным Татарстан»да, шулай ук аның яшь аркадашы «Мәдәни җомга»да еш кына милләт гамен кайгырткан гаҗәеп кыю материаллар дөнья күрә. «Шәһри Казан» да бер-ике ел эчендә укып туймаслык газетага әйләнде. Яше-картының яраткан газетасы, демократик рухлы, чагыштырмача күп тиражлы «Татарстан яшьләре» күпкырлылыгы, халыкчанлыгы белән үз югарылыгында кала бирә. Балалар һәм үсмерләр газетасы «Сабантуй» да дөньяны танып-белергә өйрәтә торган бай материаллары белән күпләрне җәлеп итәрлек. Әлеге дә баягы бер генә бәла: тиражлар аз. Мәскәүне дә куркытырлык «күп татар мәктәпләре»н исәпләгәндә, бу газетаның тиражы бик зур булырга тиеш иде кебек, ә ул нибары 7 мең чамасы (60 нчы еллар ахырында газетаның элгәре – «Яшь ленинчы» 100 меңнән артык данә белән чыга иде). Бүген шулай. Югарыда әйтелгән милли телләрне кысрыклауга юнәлтелгән әлеге мәкерле закон үз көченә керсә (ул 2009 елның сентябреннән гамәлгә ашырыласы), нәрсә була?!

Җыйнап әйткәндә, матбугатыбызны таратуда, халыкка җиткерүдә бик күп кадерле вакытны, форсатларны кулдан ычкындырдык... Русларда да тиражлар бик зур түгел бит, дияр кемдер. Пәри башка, җен башка, ди халык. Державалы, күпсанлы халыкның матбугаты югалмас ул... Ә безнең өчен матбугат – дәүләти институт та, милли университет та, таяну ноктасы да. Инде ун елдан артык республикада татар телен дәүләт теле сыйфатында тормышка ашыру Программасы эшләп килә. Татар матбугатын халыкка күпләп җиткерү – бу Программаның үзәк өлеше булырга тиеш иде. Кайберәүләр, игътибарны матбугаттан читкәрәк юнәлтеп, күпләрне Интернетка юлламакчы. Интернет белән туган телне үзләштерү яки үстерү, М.Мәһдиев әйтмешли, едва ли! Үткән гасыр урталарында, көндәлек тормышта телевидение пәйда булгач, экраннардан фильмнар, спектакльләр күрсәтелгәч, кайбер акыллы башлар, театрлар бетәчәк, дип сөрән салды... Тормышка ашмады андый фаразлар. Экран экран булып, спектакль тере тамаша булып үз урынында калды. Кешенең китап белән аралашуы, берлеге дә мәңгелек дип уйлыйм мин. Нәтиҗә – үземчә аксиома шул: телне саклыйм дисәң, төп шартларның берсе – милли китапны, матбугатны саклау.

Яңа елда, табигый, яхшыга өметләнеп, үткәннән дә күңелгә хуш килердәй вакыйга-фактларны искә төшереп канатланасы килә. Бу уңайдан конкрет вакыйгалар санаганга кадәр, шунысын ачык итеп әйтү кирәктер: ни аяныч, соңгы елларда зур югалтулар кичерсәк тә, шөкер, бүгенге көндә күп гасырлык татар әдәбиятын заманча үстерерлек кимәлдә иҗат итүче берничә дистә зур язучыбыз бар. (Ә калган йөзләгәннәре? дияр кемдер. Борчыласы юк: биек таулар ялгызак калкып тормый, Урал тавы тезмәләре кебек, алар бер-берләренә елышып, үзләре дә бар булып, зурракларына терәк-таяныч булып тора.) Бу – зур көч!

Шулай ук җитмеш елдан артык язучыларны үзара аралаштырып, берләштереп яшәтә торган оешмабыз – Язучылар берлегебез бар. Ул уңышлы гына эшләп килә (кемнәрдер, бәлки, аның эшчәнлегеннән канәгать үк тә түгелдер... Әгәр аны җуйсак, сагынырга калмасын! Соңгы дәвердә Берлексез яшәп караган юк бит әле!). Белүемчә, безнең Берлек кебек эшләгән оешма элеккеге СССР киңлекләрендә сирәк.

Әдәбиятыбызның нигез журналы «Казан утлары»на яңа әсәрләрнең мул килеп торуы да шатлыклы хәл. Бөтен кульязмалар да югары таләпләргә җавап биреп бетермәсә дә, аларның күпчелеге ил-халык гаме белән сугарылган. Иң мөһиме – соңгы елларда яшь көчләр ишәйде. Бигрәк тә шигърияттә. Моны 90 нчы еллардагы милли күтәрелешнең шифалы кайтавазы дип уйларга кирәк.

2006 елда, журналыбызның мең саны нәшер ителү уңаеннан, «Сүнмәс утлар балкышы» дигән энциклопедик характердагы зур күләмле китап чыгарган идек. Ул елдан-ел халыкка күбрәк ирешеп, укучылар күңелен яулый бара. «Казан утлары» журналының тәртип саны инде 1050гә якынлаша. Яңа меңнәр насыйп булсын!

Үткән ел язучыларыбыз белән укучылар арасында аралашулар күп булды, бәйләнешләр шактый ныгыды дип уйлыйм. Үткәндәге классик һәм бүгенге күренекле әдипләребезнең үзебездә һәм бүтән төбәкләрдә дистәләгән онытылмаслык кичәләре, йөзләгән очрашулары узды. Димәк, очрашыр халкың бар, укучыларың бар. Бер генә мисал: үткән елның сентябрь аенда Ульян каласының үзәгендә бөек шагыйрь Кол Галигә һәйкәл ачылды. Зур мәгънәгә ия тарихи вакыйга. Бу уңайдан Бөтендөнья татар конгрессының халкыбыз үзаңын уятудагы, әдәбиятыбызны пропагандалаудагы эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Конгресс оештырган чараларда безнең язучылар да еш катнаша. Алар ерак сәфәрләрдә булып илләр гизә, дөнья буйлап чәчелгән милләттәшләребезнең рухи мирасын барлый, үзләренең иҗат офыкларын киңәйтә. Халыкара «Алтын Мөнбәр» кинофестивалендә тәкъдим ителгән тулы метражлы чын татарча «Өч аяклы ат» фильмы үткән елның якты бер бизәге булды. Безнең авторның (А.Хәлим) иң әүвәл безнең журналда басылган әсәре буенча (режиссер Н.Җамали) эшләнгән фильм ул. Димәк, әсәрләребез сәнгатьнең бүтән өлкәләрен үстерүгә дә өлеш кертә. Үткән ел Татарстан китап һәм «Мәгариф» нәшриятларында язучыларыбызның йөзгә якын китабы дөнья күрде...

Мәгълүм хакыйкать: халык кояш астында тулы тормыш белән яшәргә теләсә, аңа өч нәрсә кирәк – хезмәт сөяргә, тарихын һәм талантларының кадерен белергә. Беренче шартны безнең халык яхшы ук үти шикелле. Әмма соңгы икесе турында кистереп уңай җавап бирү кыен. Бигрәк тә хәзер, бик күпләрнең күзләре акча күләгәсендә томаланган чакта. Элегрәк әдәбият-сәнгать турында сүз барганда Ленинның мондый сүзләрен еш әйтәләр иде: «Талант – сирәк

нәрсә!» Чыннан да, иҗатчы, әйтик, шагыйрь бөек шигырь язса, композитор берәр үлемсез көй чыгарса, рәссам мәңгелеккә калырлык картина-сурәт ясаса, алар бит бернинди акчага да биргесез илаһи ачышлар, табышлар була бит инде! Әгәр бүгенге җәмгыятьтә алар бәһаләнми икән, монда иҗатчының гаебе юк. Әйтик, бер шагыйрь татар яки чуаш телендә гаҗәеп шигырь яки поэма иҗат итте ди, ә халык, бу очракта укучы, аны бар дип тә белми икән, уйланырга гына кала. Талантлы шәхес үзенә тигәнен эшләде – бөек әсәр тудырды... (Язмамны тәмамлар алдыннан очраклы рәвештә «Звезда Поволжья» дигән газетадагы баш мәкаләгә күзем төште. Мәкалә ахырында болай диелгән: «В общем, дорогие татарские писатели, выхода не остается – будете писать на уровне Шекспира, Достоевского, язык сохранится, а не сумеете выдержать планку, похороните язык своим серым творчеством». Килешәм: бөек язучылар иҗатына тиң әсәрләр язарга кирәк. Безгә Тукай дәрәҗәсендә язганда да ярап торыр иде. Әйткәнемчә, кемдер үз ана телендә бүгенге заманның бөек әсәрен иҗат итте ди. Ә аны кем бәяләр соң? Мәкалә авторы Рәшит Әхмәтовмы? Мәсьәлә, кемнәрдер уйлаганча, бер каптырмалы гына түгел шул. Теге яки бу телдәге әсәрне беренче чиратта әнә шул әсәр туган телнең варислары бәяләргә тиеш. Ул иң чын, гадел бәя булыр. Бигрәк тә шигъри әсәрләрне бәяләгәндә.) Җәмгыять, бәлки, иртәме-соңмы аны бәяләр дә, ә бит әле дөньяның бүгенгесе бар! Дөресен әйтим, хәзерге заман иҗат кешесенә яшәү һәм иҗат итү шактый авыр. Әдәбият-сәнгать дөньясындагы төрле буын кешеләре белән аралашудан чыгып әйтәм мин бу сүзләрне. 2008 елның май аенда үткән Язучылар корылтаенда җитәкчеләрнең һәм делегатларның чыгышларыннан соң каләмдәшләр аннан рухланып, күңел күтәренкелеге тоеп чыкты дип әйтә алмыйм. Һәр иҗат оешмасының, һәр аерым иҗатчының дөнья кадәр мәсьәләләре бар. Язучылар һәм матбугат әһелләре өчен бу соңгы елларның һәммәсендә дә берәр күчеш, үзгәреш, чигенеш булмый калмады бугай... Бик күп газета-журналлар дәүләт карамагыннан акционерлар җәмгыяте химаясенә күчәргә мәҗбүр булды. Төп нәшриятлар шәһәр үзәгеннән читкә – Архангель зираты кырыена күчерелде. Үткән елда да булды хәлләр! 2008 ел Тукай рухы рәнҗетелү елы да, дияр идем. Бөек шагыйрь яшәгән «Болгар» кунакханәсен җимереп, җир белән тигезләделәр. Бу вандаллыкка прелюдия шикелле, язын Тукай исемен йөрткән премияләр дә, Дәүләт бүләгенең дәрәҗәсен төшереп, нигездә, үзешчәннәргә бирелде. Тукай рухы рәнҗегәндер үткән ел, рәнҗегәндер...

Бүген кая барма, кемне генә очратма, глобаль кризис турында сөйлиләр. Язгы болыт кебек тиз генә узып китәргә охшамаган, озакка сузылыр, диләр. Шулайдыр, аңлаганнар белеп әйтәдер. Аның каты канаты, әлбәттә, һәркемне сыйпап узар. Шулай да әллә ни югалтырлыклары булмаган иҗат кешеләрен бигүк куркытмый да ул кризис. Алар инде күнеккән: төрле яктан байтак еллар буе кризис кичерәләр... Ничек кенә авыр чор булмасын, бер үтәр ул кризис дигәннәре. Акча таулары өстендә ләззәтләнеп кызынып ятучы дөнья магнатлары үзләре башлаган «уен»нарыннан бер туяр... Ә менә күңелләргә кара юшкын булып утырган рухи кризис... монысы аның чыннан да хәтәр инде!

Менә шулай мажор белән башлыйсың да уйлана-уйлана еш кына үзеннән-үзе минор халәткә күчәсең, күчәргә мәҗбүр буласың. Кемгә ничектер, кайчак йокысыз кара төннәрдә башка шомлы уйлар килә. Һич кенә дә куып җибәреп булмый аларны. Хәтта куркыныч та булып китә. Сәгатьләр үтә, ниһаять, таң беленә, офыклар алсулана. Шыксыз уйлар, ниһаять, кача. Күзгә яктылык нурлары иңә. Торасың. Хәрәкәт-яшәү башлана. Дөнья ямьләнә. Үзеңнән дә шуңа яңа ямь өстисе килә... Моннан нәкъ кырык ел элек мондый бер шигырь язган идем. Шул искә төште.

### Нинди бетмәс ышаныч бу?

Янган-көенгән чакта,
башың иелгән чакта,
кайгың өелгән чакта, –
беттем! дисең... Күзең ачсаң,
Вөҗданың белән беррәттән
Ышаныч тора сакта, –
кешелегеңне саклап.

Нинди үлмәс Ышаныч бу!

Үтерергә теләп аны
эзли Мәкер, Өметсезлек, –
бетереп бар дөньяны.
Ә ул исән һәм сине әйдәр:
«Утыр, – дияр, – канатыма!
Югалма, туган, яшәрбез,
тормышны ярат кына!»

Нинди бетмәс Ышаныч бу!
Инде юктыр ул дисәм,
упкыныма тау була ул
һәм яр сала: «Без исән!»
Тураям шундук, зурая
мәгънәм һәм максатым.
Илһамланам, бар җиһанга
таралыр күк яхшы атым!
*2009*

## *БЕРДӘМ БУЛСАК — ҖИҢӘРБЕЗ*

Әгәр Әмирхан Еники исән булып бу трибунадан чыгыш ясаса, мондый сүзләр әйтер иде шикелле: «Так сказать (нигәдер бу сүзтезмәне ул еш әйтә иде), язучылык хезмәтенең кызыгы бетеп бара...» Ихтимал, бу фикергә Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек классик әдипләр дә кушылыр иде. Чыннан да, үткән дистә еллар белән чагыштырганда вазгыять безнең файдага түгел. Әдәбиятның җәмгыятьтәге дәрәҗәсе түбәнәйде, шул нисбәттән тәрбияви роле дә кими төште. Язучы үзе дә социаль яклауга мохтаҗ категориягә әйләнде. Дөньяви масштабтан караганда, һәр җирдә дә бәлки, алай түгелдер, әмма Россия һәм элеккеге СССРның күпчелек дәүләтләрендә хәл нәкъ әйтеп үтелгәнчә. Җитди классик әдәбиятны аз уку, тиражлар кимү – шул ук матди бөлгенлек... Кеше өчен, бигрәк тә нечкә тоемга ия талантлы кеше өчен иң авыры – киләчәккә ышанычның кимүе.

Конфуций дигән акыл иясе әйткән, диләр, «Дәүләт тоту өчен өч нәрсә кирәк: ашар-эчәр ризык, ил сакларлык корал һәм халык ышанычы». «Шуларның берәрсе булмаса, Дәүләт тора аламы?» дип сораганнар аннан. – «Коралсыз да була, чөнки кеше үзе корал». –«Әгәр шул өчнең тагын берсе булмаса?» – «Хәтта ризыксыз да була, кешегә барыбер бер үләсе. Ә менә халык ышанычын югалтса, бернинди дәүләт тә яши алмый».

Язучылык хезмәте турыдан-туры халыкның тарихы, гореф-гадәтләре, теле-моңы, гомумән, рухи дөньясы белән, матди байлыктан бигрәк, ата-бабаларыбыз мирас итеп калдырган рухи байлык белән бәйле. Безнең миссия – әнә шул байлыкны мөмкин кадәр арттыру, үстерү, үз халкын бүтән халыклар арасында ким итмәскә тырышу. Тел белән бәйле безнең хезмәтебез. Тел, үзегез беләсез, милләтне милләт итүче иң төп билгеләрнең берсе. Гомумән, һәр халыкның мәдәни нигезен сүз сәнгате тәшкил итә. Язучы кеше – турыдан-туры тел сагында торучы зат. Күреп торабыз, безнең телгә Ак патшаның империячел даирәләреннән соңгы вакытта эзлекле һөҗүм бара. Мәктәпләрдә укыту процессыннан милли компонентны бетерү буенча кануннар чыгардылар... Аңа кадәр нинди имляда язу хокукын бездән тартып алдылар... Әгәр классик мирас һәм синең язганнарың укылмый, укытылмый, өйрәнелми икән, ничекләр итеп илһамланып язмак кирәк. Менә шундый, Ышаныч дигәнең офыкта югала барган, еш кына «колмак батып, таш йөзгән» дәвердә безнең язучыларыбыз әле дә менә дигән талантлы әсәрләр иҗат итәләр. Сокланырлык хәл. Рәхмәт аларга! Шөкер, без бүген үзебезнең арада берничә дистә классик мәгънәдәге зур язучы, шагыйрь, драматург бар дип әйтә алабыз. Зур көч, зур хәзинә бу әлегә.

Нинди хәлләр, гамәлләр булды соң бу өч-дүрт ел эчендә? Аянычларыннан башлыйм.

Кабатланмас зур талантлар арабыздан китте. Алар урынын тутырырлык яңа көчләр килдеме? Кистереп әйтү кыен.

Ана телебездә укучылар кимеде. Китап, газета-журналларның тиражы шуны раслый. Без 300 язучыбыз бар дибез, ә киләчәктә, берәребезнең китабы чыккач, ябырылып укучы 300ләп укучы табылырмы?

Мөгаен, соңгы еллардагы зур яңалык шул: республика басмаларының статусы үзгәрүе – алар ААЖга (үз көнен үзе күреп, булдыра алса, табыш алып яшәүче берләшмә) керделәр, дөресрәге, кертелде. Милли басмаларның абсолют күпчелеге рәсми яктан дәүләтнеке саналмый хәзер. Ярый ла әлегә без күпмедер дәрәҗәдә дәүләт заказын үтәүче саналабыз. Ә алга таба? Гарантия юк бит! Өстәвенә матбугат белән идарә итүчеләр арасында татар тарихын, әдәбият-сәнгатен, телен белүчеләр юк дәрәҗәсендә. Безнең мохиттә генә түгел, бүтән җитәкче структураларда да шулай бу. Шуңадыр да Казанда татар тарихына кагылышлы җисми тарихи ядкарьләр бетеп бара. Ә болай читтән күзәтүчегә хәрәкәт бөтенләй юк түгел түгелен. Баратынский яшәгән йорт яңартылды, Аксенов йорты торгызыла... Ә менә Тукай яшәгән «Болгар» номерлары һаман хәрабә хәлендә...

Безнең хезмәт нәтиҗәсе – китап. Һәр хезмәт бәһаләнергә тиеш. Безгә кагылышлы гонорар – каләмхак турында уйланганда моннан күп еллар элек язылган сүзләр искә төшә.

Якты йөзе...
Мәгънәле сүзе...
Талант – үзе!

...Илһамлы каләме өстеннән
гомере буе
карап торды ипи күзе...

Без, нигездә, ипи телеменә ялманып иҗат итә торган кавем. Кызганычка каршы. Мохтаҗ кешегә масштаблы фикер йөртү кыен. Әдәбият тарихына баксаң, – Гарептә булсын, Шәрыктә булсын – классик әдәбиятны матди җитеш, хәтта әйтер идем, бай катлам тудырган. Бездә чагыштырмача мул яши торган язучылар бер кул бармакларына сыеп бетә бугай.

Мин бу трибунадан, язучы булудан тыш, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире һәм кабул итү коллегиясе рәисе сыйфатында да чыгыш ясаганлыктан, журнал һәм Берлеккә әгъза итеп алынганнар турында берничә сүз. «Казан утлары» турында тәфсилләп сөйләп тормыйм: аны һәркем белә, чөнки журналны бергә чыгарабыз, бөтенебезнең диярлек яңа яхшы әсәрләре анда дөнья күрә. Журналның соңгы еллардагы эшчәнлеге турында корылтай делегатларына таратылган белешмәдә дә шактый тулы мәгълүмат бирелгән. Өстәп шуны гына әйтәм: 2006 елда Россиядә һәм элеккеге СССРда әдәби журналлар арасында беренче булып 1000 нче санны чыгардык. Бу безнең өчен, һәммәбез өчен горурлык! Мең сан хәзинәсеннән үзебезчә яхшы һәм гыйбрәтле дип санаган әсәрләрне туплап, «Сүнмәс утлар балкышы» дигән күләмле (90 басма табак) антологик характердагы китап чыгардык. Мондый басма әдәбиятыбыз тарихында юк иде дип беләм. Бу китапны тәкъдир итү кичәләре Татарстаннан тыш Мәскәүдә, Пермьдә, Ижау һәм башка шәһәрләрдә гөрләп узды. Бу китапның кайбер данәләре чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез кулына да барып иреште. Белгән кешеләр «Казан утлары»н Россиядәге иң яхшы әдәби журналларның берсе дип әйтәләр. Ышанасы килә. Безнең бу корылтайда да, докладларда булсын, чыгышларда булсын, асылда, безнең журналда басылып чыккан әсәрләр анализлана.

Кабул итү коллегиясе эшчәнлеге турында. Коллегия әгъзалары – күренекле, тәҗрибәле язучылар. Күпсанлы каләм ияләре арасыннан иң өметлеләрен сайлап алырга тырышабыз. Ике корылтай арасында 39 кеше Берлеккә кабул ителде (23 язучы вафат булды). Шулар арасында яше 30 га җитмәгәннәре фәкать 5 кенә. Дөресен әйтергә кирәк: балкып торган талант ияләре сирәк. Язучылар берлеге – иҗтимагый оешма. Аңардан массоннарныкы кебек ябык оешма ясап булмый һәм кирәкми дә. Максат – талант очкыны булган кешеләргә ярдәм итү. Татарстаннан читтә яшәүче каләм ияләре аерым игътибар үзәгендә. Бу еллар эчендә читтән 10 кешене әгъза итеп алдык. Сүз дә юк, киләчәктә таләпләрне, критерийларны көчәйтү кирәк. Безнең өлкәдә сан дигәннәре гел генә сыйфатны билгели алмый. Шунсы да борчый: Россиядә әлегә кадәр иҗат оешмалары турында закон кабул ителмәгән. Кануни тәртипләр булмау аерым әдәбият өчен дә, халыкара аралашу, бердәм туплану өчен дә һич файдага түгел.

Сүземне йомгаклап болай дияр идем: әлбәттә, татар язучысы алдында проблемалар хәттин ашкан. Тарих шаһит: язучылар кавеме нинди генә чорларда нинди генә авырлыклар кичермәгән, әмма көрәшкән, кулыннан каләмен төшермәгән, җиңеп килгән... Язучыга бүген дә җиңел түгел. Әдәбиятыбызның меңьеллык тарихы бар дип, күкрәк кагу гына аз. Кемнәргәдер бер көч куеп алынганны безгә ун көч куеп алырга кирәк. Шунсыз булмый. Шөкер, булган куәткә көч бирүчеләр бар. Республика җитәкчелеге әлегә безнең хәлләрне аңлый, булдыра алганча ярдәм итә (нәшриятлар исән-сау яшәп килә, классик әдипләребез мирасы чыгарыла, Берлек эшчәнлеге финанслана, төрле юбилей чаралары үтә, китапларыбызны төрле төбәкләрдә таратуда булыша... Өстәп кенә әйтәсе килә: СССР Язучылар берлегенең 70 еллык бәйрәме дәүләти масштабта Татарстаннан тыш тагын кайсы илдә яки республикада үткәрелде икән?). Аңлашып, бергә-бергә хезмәттәшлек тә иҗат иткәндә хәл итмәслек мәсьәләләр юк ул. Һәрхәлдә, мин шуңа ышанам.

*2008*

## *СҮТЕЛӘБЕЗМЕ?*

Сентябрь ахырында ун көн чамасы Казаннан еракта – командировкада булырга туры килде. Кайткач, Чаллыдан танышым шылтырата. «Сиңа бик авыр хәбәр җиткерергә туры килә бит әле...» Нәрсә булды икән? «Берәр газиз кеше вафат булганмы?» дигән уй йөрәгемне ярып узды... «Болгар» номерларын җимереп, җир белән тигезләгәннәр...» ди ерактагы тавыш. Катып калдым, ышанмадым, «булмас, булмас... йөгереп үзем барып карыйм әле, дөресен хәбәр итәрмен» дип мыгырдана-мыгырдана чарасыздан трубканы куйдым. Шулай да, урамга атылып чыкканчы, иң әүвәл атна-ун көн буена җыелып килгән почтаны карап чыгарга булдым. Татарча газеталарда әллә ни борчулы хәбәрләр юк. Гадәттәгечә, бар да яхшы. Бәлки, ишеткәнем дөрес түгелдер?.. «Звезда Поволжья»ны (2 октябрь, 2008) ачам. Әһә! Беренче биттә кыска гына хәбәр. Ул мине бөтенләй өнсез итте. Текстны, русча басылганча, тулысынча китерәм. «Казанская интеллигенция в шоке. Снесено под корень историческое здание дореволюционной гостиницы «Булгар» (перекресток ул. Татарстан – Московская), где творил Габдулла Тукай. Кто отдал приказ? Ранее обещали, что здание будет реставрировано. «Отреставрировали». Позор! Название перекрестка звучит симптоматично. Взаимопересечение судеб татарского народа. И вот здание, центр Татарской Слободы, где жил лучший татарский поэт, порушили. Почему татары не встали стеной на защиту исторической реликвии? Работники и актеры театра Камала, который находится напротив, сотрудники ТГГПУ были потрясены. Все равно, как если бы в России уничтожили бульдозерами Михайловское (место, где творил великий Пушкин) или Болдино. В России за такие дела посадили бы на 25 лет. У нас тишина. Построят на разрушенном «сладком» центровом месте очередной торговый центр или ресторан. А ведь это был символ татарского ренессанса. Безусловно, это преступление против татарской нации, проведенное с особым цинизмом, с корыстным интересом. Откровенно наплевали на татарскую культуру и вытерли ноги. На Западе из-за подобных событий летят в отставку правительства. Вряд ли случайность, скорее всего это сознательная провокация, что здание, где творил Тукай, было разрушено именно перед проведением Дня памяти защитников Казани».

Кискен һәм көчле язылган! Өстәп нәрсәдер әйтүе дә кыен. Шулай ук «Вечерняя Казань» да (3 октябрь, 2008) кимен куймаган: «Процессу уничтожения исторических памятников в Казани нет конца и края. То буквально на наших глазах от старой Казани практически ничего не осталось, – это результат жадности, невежества и безразличия. Последней жертвой вандалов в законе стали номера «Булгар». Шул ук санда Миркасыйм Госманов, Ринат Закиров, Салават Юзеев кебек күренекле шәхесләрнең дә бу акциягә мөнәсәбәтле чыгышлары бирелгән. Һәммәсенең фикерләре протестлы, аптырашлы... Шул ук көннәрдә галим Искәндәр Гыйлаҗевнең дә җан ачысы белән язылган «Мы верим...» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Ул да кабатланмас, инде кайтарып булмый торган мирасны һаман саен югалтуга рәнҗүен белдерә...

Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романындагы беренче җөмлә искә төшә: «Фәхрине үтереп ташладылар...» Бу очракта «Болгар»ны җимереп ташладылар!

«Туйдан соң дөмбер! – дияр кемдер, – элек ни карадыгыз?» Моны әйткән кеше хаклы да, хаксыз да. Шәһәр үзәгендәге бу истәлекле бина турында җәмәгатьчелек күптән тукып килде. Аны тизрәк реставрацияләп, саклау турында әйтелмәде түгел, күп әйтелде, күп сөйләнде. Хакимият башындагыларның гына ишетәсе килмәде. Ничә дистә еллар буе бина әкренләп җимерелә барды... һәм менә – финал! Мондый аяныч финалның сәбәбе – бездә гражданлык җәмгыятьнең булмавы яки бик зәгыйфь булуында, күрәсең. Өстәвенә милли аң дигәннәре дә бездә бик чамалы... Сәясәтче Рафаэль Хәкимов моннан берничә ел элек мондыйрак сүзләр язып чыккан иде: «Казанны Явыз Иван бер җимергән булса, икенче тапкыр Камил Исхаков җимерде». Галим бу очракта Казанның элекке мэры исеме белән байтак идарәче даирәләрне дә күз алдында тоткандыр дип уйлыйм. «Болгар» кунакханәсе фаҗигасен татар җәмгыятьчелегенең авыр кичерүен аңлап була. Бик күп югалтулардан әрнегән күңел касәләренә тамган соңгы тамчы булды бу җимерү: ризасызлык-протест тышка ташып чыкты. Уйлап карагыз: берничә дистә ел эчендә җанга якын күпме тарихи ядкарьләр вәйран булды! Алар урынына заманча яңа йортлар калыкты. Ул йортлар никадәр генә ыспай һәм уңай булмасыннар, җир йөзендә, дөньяның төрле кыйтгаларында алар – миллионнар! Ә сүтелгән, җимертелгән йорт-биналарның күбесе бердәнбер кабатланмас ядкарьләр иде. Кешеләр өчен, бигрәк тә читләрдән килгән туристлар өчен әнә алар кызык та. Төрле гасырларда төрле фаҗигаләр кичерү сәбәпле, тарихи һәйкәлләр бездә болай да бихисап түгел. Шуңа күрә дә алар икеләтә, өчләтә кадерле булырга тиеш иде. Моны аңлаучылар күбәер ул, әмма инде соң булыр... Ихтимал, кемнәргәдер Казанның татар тамырлы булуы кирәк тә түгелдер...

Ачынулы чыгышлар белән беррәттән матбугатта рәсми хакимият вәкилләренең дә белдерүләре булгалады. Төп фикер: борчылырлык хәл юк, бина мемориаль үзәк итеп яңадан төзеләчәк. Бу эшне «Татнефть» ААҖ башкарачак икән! Бирсен Ходай! Әлбәттә, бинаны җимергәнче үк белдерергә иде моны халыкка, киңәшләшергә иде, һичьюгы, җәмәгатьчелекне психологик әзерләргә, тынычландырырга иде. Стресс кимрәк булыр иде. Рәсми вәгъдәләргә бик ышанасы килсә дә, күңелдә шикләр зур. Яңа бинада искесенең бөтен архитектура үзенчәлекләре сакланып калырмы? Корылма (әйтик, кунакханә) шәхси кешенеке яки аерым оешманыкы булгач, анда мәдәни-рухи тормышка урын табылырмы? (Шунысы гаҗәп: миллионнарның күңеленә кереп урнашкан матур бу бина махсус саклана торган архитектура һәйкәлләре исемлегенә дә кермәгән (?!), имеш. Бу инде инвестор-хуҗа өчен зур козырь. Ул үз бинасын үзе ничек тели, шулай төзи ала.) Әйе, шикләр юк түгел. Авызы пешкән өреп кабар дигәндәй, вәгъдәләрнең төрлесен күп ишеткән токым без. Яңадан төзеп торгызу дигәннәре кайчан башланып (классик архитектура кануннарын саклап эшләсәң, озак процесс) һәм ничекләр булып бетәр бит әле! Нәтиҗә өчен кем һәм кемнәр алдында (андый хәл булса!) хисап тотар? Дөньялар шактый болганчык. Гарантияләр гарантияләнмәгән. Әлегә бинага бәйле беренче эш этабы – җимерү этабы «уңышлы» үтте. Казанның татар ягы ятим калды. Монысы – факт. Алга таба шикләнүләребез дөрескә чыкмаса иде дә бит! Һәрхәлдә, күңел шуны тели.

«Болгар» номерларының юкка чыкканын ишеткән көнне, күңел тулып, ярсып бер шигырь дә яздым әле мин. Ул, бәлки, шигырьдән бигрәк калыпка салынган публицистик чыгыштыр. Ихтимал, артык эмоциаль халәттә язылганга күрә, кискен юллар да бардыр. Кемнәргәдер ошап җитмәскә дә мөмкин. Бигайбә. Теләгем: бу юллар «Болгар» номерларын торгызганда берәр генә кирпечне иплэбрәк куярга булыша алса иде!

## Әрнү

2008 елның сентябрь ахырында
татар халкы өчен изге булган
бинаны заманында Тукай яшәгән
«Болгар» кунакханәсен җимереп,
җир белән тигезләделәр.

*Бирелә, каядыр якында*
*Тукай җаны бәргәләнәдер.*

Без Тукайны саттык. Булдырабыз!
Толерантлы «бөек» халык без!
Бу очракта күлеп мыскылларлык
бәяләмәләргә лаек без.

Үткәннәргә төкереп, вандаллыкның
үрнәкләрен күпкә уздырдык.
Горурлык дип йөрткән даһи затның
күшеккәндә җанын җылыткан
соңгы оясын да туздырдык.

Бөек шагыйрь миллион күңелләрдә
шигырь сарайлары салса да,
үзенә йорт сала алмаган шул...
Вакытлычасы да... вәссәлам!

Җанда әрнү. Ваемсызлык өчен.
Көрәшмәгән өчен үкенү.
Төшләремдә яңгырый: дивар ава,
бульдозерлар, яман үкерү...
Бу җимерү гади җимерү түгел,
бу – тарихка, телгә, моң-көйләргә,
символ булган Җанга төкерү.

Күпме халык ихлас табыну белән
иелеп уза иде бу йортка!
Нигә «Туган тел»ең, «Тәфтиләү»ең
рок-поп буынына – манкортка!

Нәрсә булыр монда? Бер бардакмы
йә заманча толчок-мазармы?
Акча иман булып йөргән чакта,
бар дөньясы – колхоз базары.

Әйдә, байлар тагын баесыннар...
Изге җирдә маемласыннар!..
Тукайҗаннан курыкмасагыз да,
Ходай хөкеме сезне бер сынар!
Рәнҗешләре төшәр, төшми калмас,
каргасалар мең-мең юксыллар!..

Беткәнне дә төзеп бирәбез бит
космолит килмешәкләргә.
Баскын варислары уйлыйлардыр:
«Шулай кирәк сез – ишәкләргә!»

Күпме милли ядкарь вәйран булды!
Җирләре «этләргә кала» ла!..
Күктишәр манаралар үрлиләр
тамырсыз меңьеллык калада.

«Болгар» номерлары...
Кырыгынчы бүлмә. Шигъри учак...
Килеп кара: урыны – тап-такыр...

Дәүләти ятимлегеңне шунда
кичерерсең тагын бер тапкыр.

Шагыйрь җаннар, уйламагыз, мине
урап узар диеп бу хәлләр.
Тукай кирәкмәгән чорда
безне,
сайлап-сайлап, аерым бөгәрләр!..

Без Тукайны саттык! Дөресрәге,
үзебезне саттык... Купмегә?
...Тамырларың бетсә, кала бары
Изге дога белән Күк кенә.

*2008*

## *ТЕЛ БИРМӘК — ҖАН БИРМӘК*

Тикмәгә генә «тел бирмәк – ил бирмәк» димәгән халык. Телне саклау – гомер-гомердән, сугышларда җиңү-җиңелүләргә тиң, иң авыр вазифа-бурыч булган. Сан ягыннан азчылык халыклар өчен бигрәк тә. Әнә руслар да, дәүләтле, сан-исәп ягыннан ишле булсалар да, чаң сугалар: Балтик буе илләрендә яки дөньяның бүтән бер җирендә рус телен кысалар, диләр. Дискринимация, диләр. Әйе, тел мәсьәләсе байтак халыкларның йөрәк ярасы. (Испаниядә – каталоннар, Төркиядә – көртләр, Кытайда – уйгырлар, шулай ук Россия җирлегендә дә тел мәсьәләсендә иза чигүче халыклар бихисап.)

Телнең сакланышы аның җәмгыятьтәге ихтыяҗына бәйле. Ихтыяҗ булмаса, тел дә кирәкми. Әлбәттә, халыкның үзаңы дәрәҗәсенә дә бик бәйле бу хәл. 90 нчы елларда – суверенитет игълан ителгән елларда – телебез дә күзгә күренеп тернәкләнеп алды. Кешеләр иркенләп туган телдә сөйләшә башладылар. Шул исәптән үзебезнең кайбер җитәкчеләребез дә. Бу очракта мин иң әүвәл туган теле «зәгыйфьрәк» булган Ф.Мөхәммәтшинны, З.Вәлиеваны күз алдында тотам. Күрәсең, ана телен камил белгән М.Шәймиевнең дә уңай йогынтысы булгандыр. Шулай да кайберәүләр «бирешмәделәр», һаман искечә – «агач рәсми» телдә карьера яулый бирделәр. Хәтта бер елны Путин үзе дә бер зур җыелышта татарча сөйләп карады. («Абсолютно недопустимо если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка». Тик шунысы кызганыч һәм сәер, шул кеше мәктәпләрдә милли компонетларны бетерүче мәгънәсез указга ашыгыч рәвештә кул куйды.) Татар теле төрле чорлар кичерде. Хәтердә: Табеев 60 нчы еллар башында «Сезнең татар телегез 20 елдан бетәчәк» дигән иде. Шөкер, әлегә исәнбез! Күрәсең, андыйлар бер нәрсәне оныта: кайчандыр дәүләт тоткан халык – илен, телен алай тиз генә бирми әле ул!

Заманында үз дәүләтләре булмаган, аз санлы халыкларның хәлләре тагын да аяныч, әлбәттә. Моннан егерме еллар элек булган бер вакыйга, бер күренеш хәтергә килә. Ул заманда ук Удмуртиядә удмурт телендәге мәктәпләр бетерелгән. Ә Татарстанда Балтач, Кукмара якларында удмурт телендә укытыла торган берничә мәктәп калган булган. Удмурт язучысы Гай Сабитовны (ул татарча да бик яхшы белә иде) шул мәктәпләрнең берсенә очрашуга алып барганнар. Ул, дулкынланудан мәктәпкә керә торган ишегалдындагы туфракны үбә-үбә: «Монда бит минем туган телемдә сөйләшүче балалар укый!» – дип ятып елаган. Туган телен югалтучы җанның тетрәндергеч фаҗигасе!

60 нчы еллардан тагын бер мисал. Без бер төркем яшь шагыйрьләр, яңа татар шигъриятен тудырабыз, һичьюгы, аны яңа баскычка күтәрәбез дип, беренче китапларыбызны чыгарып очынып йөргән еллар. Беркөнне композитор Әхмәт Хәйретдинов (Луиза Хәйретдинованың әтисе, милләт җанлы кеше иде, мәрхүм) очрады, куанып, яңа чыккан юка гына китабымны күрсәттем. Ул өлкән кеше, бер китапка, бер миңа карап әйтеп куймасынмы! «Равил, кем генә укыр икән соң синең бу шигырь китабыңны? Татар мәктәпләре ябылып бетә бит...» Мин аңа тыныч кына (эчтә ризасызлыктан давыллар ярсый иде, әлбәттә) кистереп җавап бирдем:

«Кайгырма, Әхмәт абый, укучы табылмаса, үзем укырмын! Өйләнергә йөрим, хатыным укыр, аннан – балаларым... Яхшы әсәр язу кирәк әле башта!» Үз-үземә нык ышанып әйткән сүзләрем күңеленә хуш килде булса кирәк, «Молодец!» дип, кулымны кысты. Бу хәлгә 50 еллап вакыт үтте. Төрле телләрдә күп китапларым чыкты. Гомумтиражы миллионга якын. Бер дә бетәргә исәп тотмыйбыз әле. Гәрчә борчулы проблемалар хәттин ашкан...

Тел, дибез, телебез зур, бөек, дибез. Ул шулайдыр да. Без язучылар шул бөек телнең мөмкинлекләрен белеп, бөтен хасиятләрен, нечкәлекләрен белеп, үзебезнең мөмкинлекләрдән чыгып нинди әсәрләр язабыз соң? Без әйткән, язган сүзләр дөньялыкка бик кирәкме, тансыкмы? Бүтән телләргә тәрҗемә итсәң, сүзләребезнең мәгънәсе, олылыгы кимиме? Ана телендәге сүзебезнең бөеклеген беренче чиратта без – язучылар расларга тиеш түгелме? Бу безнең яшәвебезнең төп мәгънәсе дә түгелме соң? Бөек әсәр язу – телне саклау, аның бөеклеген раслау дигән сүз ул.

Телнең яшәү даирәсе – гаилә, мәктәп, хезмәт эш урыннары, сәхнә-театрлар, тамаша-концерт заллары, базар рәтләре... Әмма затлы классик телнең нигезе-бишеге ул – әдәбият, матбугат. Халыкның гасырлар буе җыйналып, чарланып киленгән асыл җәүһәрләре аларда. Шуңа күрә киләчәккә өмет белән караган халык телен, әдәбиятын, сәнгатен күз карасы кебек сакларга тиеш тә. Төп милли басмаларның берәр генә данәсен булса да үзен татар дип санаган һәр гаиләдә булдыру – яшәүнең табигый бер кагыйдәсе булырга тиеш ләбаса!

Матбугат һәм шигърият. Кызганыч, без бүген «Казан» яки «Татарстан» журналларында татар телендә чыккан әсәрләрнең тел үзенчәлекләре турында сөйли алмыйбыз. Сәбәбе бер: бу журналларның русчалары гына чыга бирә, татарчалары тукталып калды. (Татар өчен газиз сүзләр «Казан», «Татарстан» исемнәрендәге милли журналлар чыгудан тукталды... Уйландыра торган хәл!) Әкренләп татарчалары ябылып бара. Сәер хәл: бер караганда урын зур, икенчеләп әйтсәк, мөмкинлек юк. Кайбер басмалар шигырьне басмыйлар («Татарстан яшьләре»), кайберләре талымсызлык күрсәтеп кирәгеннән артык чыгара («Сабантуй», «Шәһри Казан»). Түләү юк дәрәҗәсендә. Без студент чакта матбугат бик кысан иде. Газета яки журналда бер-ике шигырь чыгару ул үзе бер вакыйга иде. Аптырагач, район газеталарына җибәрә идек шигырьләребезне, кайберләре баса иде. 1–3 тәңкә гонорар килә! Күпмедер стимул! Ә бит Тукай заманында бер яхшы шигырь бәрабәренә ат алып булган, диләр!

«Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән» дигән борынгы бер акыл иясе. Әдәбиятның әнкәсе булып моңарчы шигърият саналды. Бу соңгы елларда байтак зур шагыйрьләребезне югалттык. Шулай да хәлебез ул кадәр мөшкел түгел. Йокымсыраган карт арысланның бер сарыкны буып йотар хәле була, диләр. Шәп яшь шагыйрьләр бар әле! Хәтергә беренче булып килгән унлап исемне генә атап үтик: Янсуар, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Рүзәл Мөхәммәтшин, Йолдыз Миңнуллина, Гөлнур Корбанова, Ләйсән Фәтхетдинова, Лилия Гыйбадуллина, Рөстәм Галиуллин...

*Кайбер тәкъдимнәр:*

– Татар газета-журналының Республиканың барлык китапханәләрендә булдырылуын Дәүләт тәэмин итсен иде (Китапханәләр Б.Ельцин яисә Ә.Кәримуллин исемен йөртәләрме – анысы әлегә ул хәтле мөһим түгел). Кызганыч, бүгенге көндә матбугатка табигый язылыш сүрән. Авыл халкының зыялы өлешенең акчасы юк. Тираж булмаса – укучы юк, укучы булмаса – язучы юк дигән сүз.

– Бөтендөнья Универсиадасына әзерләнәбез. Сүзлекләр, белешмәләр, тел өйрәткечләр (разговорниклар), төрле формадагы реклама буклетларында безнең тел дә лаеклы үз урынын алсын иде. Глобальлек заманында яшибез икән, аннан глобаль файдалана да белик! Нишләп Казан мэриясендә инглиз телен белү белән рәттән татар телен дә белүне шарт итеп куймаска?

– Моннан нәкъ 50 ел элек нәшер ителгән, Н.Исәнбәт төзегән өч томлык «Татар халык мәкальләре»н ким дигәндә 50 мең данә итеп бастырырга һәм дөньяга таратырга. Аларда дәүләт тоткан халык кулланган бихисап сүз байлыгы тупланган. Татар халкының кемлеген күрсәтә, зурлыгын раслый торган басма.

– Матбугатыбызда төрле атама-исемнәрнең бертөрле язылышын булдыруны тәэмин итүче үзәк булдырырга. Кайчак бер үк атаманы яки предметны 3–4әр төрле язу гадәткә керде. Әйтик, Россия – Рәсәй, Русия; Косово – Кәшәвия, Кәшәү; Оренбург – Оренбур, Ырынбур; компьютер –кәмпитәр, кампитр... Мисалларын йөзләрчә китерергә мөмкин.

Чыгышымның башында, тел язмышы халыкның дәүләтле булуына бәйле, дигән идем. Әйе, бу шулай. Шуңа өстәп халыкның тарихи үзаңы булу да бик мөһим бит әле! Халыкның байтак зур өлеше туган телен оныттыру хисабына балаларын зур кеше итеп күрәсе килә. (Күрәсең, мисаллары да бардыр, кемдер әйткән ди бит, имеш, китап укымадым әле, ә зур кеше булдым, дип!)

Бу уңайдан тагын бер мәсьәләгә фикеремне белдереп узасы килә: ул да булса Интернет челтәре. Интернет – бүгенге яшьләрнең мавыгу эпогеясе. Күпләр Интернетсыз яшәүләрен күз алдына да китерә алмый. Бәлки, ул Интернет дигәннәре ахырзаман казанышыдыр. Шундый сорау да туа, моннан 15–20 ел элек (бәлки, әз генә элегрәктер) Интернет булганчы, ничекләр итеп шулкадәр «артта, консерватив яшәп» бөек сәнгать, бөек әдәбият, бөек рухи мирас тудыра алганнар икән соң? Минемчә, хәзер дөньяда Интернет белән берьяклы мавыгу бара. Шул исәптән бездә дә. Бу техник могҗизаның кешелек цивилизациясенә күпме файда, күпме зыян китергәнен Вакыт әйтер (Атом бомбасын уйлап табу да кеше акылының бер бөек казанышы булган.) әле. Кайберәүләрнең кәгазьдә басылган китапны Интернет – электрон сәхифәләр алыштырачак дигән фаразларын мин көлемсерәп кабул итәм. Әлегәчә беркемнең дә компьютер аша «Шекспирны, Толстойны, Исхакый яки Еникине укып чыгып ләззәтләндем» дигәнне ишеткәнем юк. Моңарчы чын китап укымыйча гына җитәкче даирәләргә эләккән кешеләр генә күбрәк электрон дәүләт, «электрон китап» турында гәп саталар...

Шунысы хак: бер телне камил белгән кеше, бүтән телләрне дә хөрмәт итә, мөмкин булганча өйрәнә. Татарстанда ким дигәндә өч тел белү кирәклеге алга куелган. Монда татар теле иң уртада булырга тиеш дип уйлыйм мин. Туган телен белмәгән, белергә теләмәгән кеше ата-бабасы каберенә төкергән кеше кебек тоела миңа.

Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,
Туган телең үги калмаса.
Җанын салып әйткән әнкәң сүзен
Синең аша балаң аңласа.

Киләчәкнең башы бүгенгедә,
Нинди шатлык картлык көнендә
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,
Матур итеп туган телеңдә.

*2009*

**III**

*...Нечкә җанлы, чын иманлы*
*булып тууың кирәк.*
*Шатлык-кайгыңны аңларлык*
*җирлек булуы кирәк.*
*Шагыйрь булсаң, дөнья өчен*
*давың, януың кирәк.*
*Януыңны күп халыклар*
*күмәк тануы кирәк...*

## *ҮЛЕМСЕЗЛЕК СИМВОЛЫ*

*(Ул – мөнбәр тәрәзәбез)*

Без яшәгән гасырның башыннан ахырына кадәр (алга таба да бу хәл, һичшиксез, шулай дәвам итәчәк) халык Тукайны олылый, бөекли, инде әллә ничә буын, аңа иман китереп, күңелен түгә. Ни өчен? Хикмәт нәрсәдә?

Һәр милләт, һәр халык, кавеменең исәбе-санына, җиренең зурлыгы-киңлегенә, үткән юлының гомумтарихта ни дәрәҗәдә беркетелеп калуына карамастан, Кояш астында тулы хокуклы яшәвен расларга һәм киләчәктә дә җир йөзендә лаеклы урыны барлыгына һәм булачагына дәгъва кыла. Шуны Тарих алдында, бүтән халык-илләр алдында раслар өчен, аңа таяныр нокталар, инандыргыч дәлилләр, рухи генетик потенцияне күрсәтә алырлык шәхесләр, бөек затлар кирәк.

Заманында миңа байтак халыкларның бөек саналган шәхесләренә багышланган тантаналарда катнашырга туры килде. Русларның – Пушкин, казакъларның – Абай, латышларның – Райнис, украиннарның – Шевченко, әзәриләрнең – Физули, төрекләрнең – Юныс Әмрә, кыргызларның – Токтогул, чуашларның – Иванов бәйрәмнәре... Татар әдәбияты вәкиле булып бу юбилейларда чыгышлар да ясадым. Фейерверклы рәсми тантаналардан соң ялгыз калгач, күңелгә төрле уйлар да килгәли иде. Ни өчен бу шәхесләргә пәйгамбәр күреп табыналар да, аларны Илаһ күкләренә күтәрәләр соң әле? Ярый, гомер кичеп зур иҗат калдырганнар. Ләкин бит алар моннан фәлән йөз ел элек булган биеклекләр. Ни өчен алар безнең өчен, киләчәк өчен гел өлге булырга тиеш соң әле? Һәркемнең үз йолдызы дигәндәй, иң әүвәл алар үз халыкларының газизләре, нигә аларга бөтен дөнья баш ияргә тиеш? Өстәвенә, адәм заты булып яшәү рәвеше буенча, бер генә каләм иясенең дә Тукай яки Шевченконың, Мәгарри яки Достоевскийның шәхси тормыш-хәятта кичергәннәрен кабатларга теләгәнен ишеткәнебез юк... Әмма... гомер кичкән саен, яфраклары коелган урманда ерактагы агач силуэтлары да ачыграк күренгән сыман, яшьлектәге өермәле уйлар тынып-утырып калгач, фикерләр дә үзгәрә төште. Кирәк икән, бик кирәк икән үткән заманның кабатланмас затлары! Чөнки алар – Бөек! Бусы – бер. Ә һәр Бөек шәхес ул – гомумкешелек хәзинәсе. Әгәр Бөек булсаң:

Нечкә җанлы, чын иманлы
булып тууың кирәк.
Шатлык-кайгыңны аңларлык
җирлек булуы кирәк.
Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны күп халыклар
күмәк тануы кирәк.

Икенчедән, югарыда әйтелгәнчә, милләтне милләт итеп раслар өчен кирәк аларны олылау. Үзеңне үз милләтең баласы итеп, Кеше итеп тояр өчен кирәк икән! Шулай булмаса, үзләрен зур милләт итеп дөньяга таныткан, тарихта тирән эз калдырган милләтләр, әйтик, алманнар үзләренең Гете, Шиллер, инглизләр – Шекспир, Байрон, испаннар – Сервантес, итальяннар Данteларын шулай планета масштабында күтәрмәсләр иде. Болары – Гареп цивилизациясеннән. Ә Шәрык дөньясыннан күпме бөек исемнәрне атап булыр иде!

Билгеле хакыйкать: күтәрердәйне генә, булганны гына күтәреп була. Максат куеп чөяр өчен мәгълүм масса-авырлык кирәк. Кош мамыгын ыргытып булмый. Аны җил кая тели, шулай өреп йөртәчәк. Рухи сабантуйда, яңа буыннар киләчәккә алып барыр өчен, үлемсез Иҗат булу фарыз. Үлемсезлек турында уйланырга безнең өчен Тукай – иң кулай мисалларның берседер.

Үлемсезлек – бөек мәгънәгә ия сүз. Ул, мөгаен, Кешелек хыялының иң биек ноктасыдыр. Үлемсезлек юлын беркем дә тәгаен генә кистереп күрсәтә алмас. Юкса әкиятләрдә Әбелхәят суын эзләмәсләр, Фаустлар алданмас, Ләйлә-Мәҗнүннәр харап булмас, Гайсә пәйгамбәрләр кадакланмас, фидакарьләр утларга ташланмас иде... Шулай да без аңлаган асылында үлемсезлек юлына баруның кайбер төп нигез принциплары бар ул: ул заманның чын мәгънәсендәге гадел һәм зирәк баласы була алудан, ягъни дәвереңнең төп проблемаларын чишү үзегендә булудан, үз халкыңның мәнфәгатьләрен кайгыртудан (Вакыт галиҗәнаплары

күзгесендә һәр халыкның үз хәлләре), киләчәкне анык күрә алудан гыйбарәт. Тукай, минемчә, бу принципларның һәммәсенә дә туры килгән шагыйрь.

Халык күңеленең тагын бер ягын онытмыйк: дөньялыктан пәйгамбәрләрчә яшьли янып китү – мәңгелеккә баруның тәгаен бер ышанычлы юлы. Безнең халык яшьли фаҗигале үлемгә дучар булган кызга яки егеткә тикмәгә генә җыр-бәетләр чыгармаган. Тукай бу яктан да Үлемсезлек кодексына бик туры килә.

Һәм, ниһаять, бер Бөек затны тану, аның олуглыгын бәяләү өчен, чорына лаек замандашлары булуы, илаһи рухны киләчәктә дә саклап, олылап бару өчен оныклары кирәк – яңа буыннарның тууы кирәк. Сандугач тавышын аерыр өчен, бихисап кош сайравын тою-белү кирәк... Бу җәһәттән дә Тукай бәхетле шәхес. Чөнки аның иҗат чоры гаҗәеп дәвергә – халкыбызның гасыр башындагы олуг күтәрелеш – Ренессанс чорына туры килә. Халык бөеклегенең рухи маякларын төгәл ачыклау, барлау заманы ул. Аннан соңрак дәвер буыннары рухи биеклекне тану, бәяләү буенча тагын да зирәгрәк булдылар – Тукайны бөек итеп танып, аны киләчәккә илттеләр. Ни генә димик, бу очракта бөеклекнең төп сәбәпчесе, әлбәттә, Тукай үзе, гаҗәеп иҗаты; XX йөз башында Россия киңлекләрендә шагыйрьләрдән бердәнбер диярлек уникаль шәхес бит ул. Ятим үсеп, дәүләт уку йортлары күрмичә тәрбияләнеп, бик аз гомер яшәп, ятимлек һәм ялгызлык кичереп, биш-алты томлык мәңгелек әсәрләр язган иҗатчы дип ул чорда тагын кемне атап була соң?

Хәер, үз бәһасен Тукай үзе дә яхшы белгән. Бу җәһәттән кечкенә генә лирик чигенеш. 1974 елның июнендә Михайловскоеда Пушкин бәйрәме үткән көннәрдә куен дәфтәремә мондый юллар язылган:

Йолдыз, Кояшларны күрми торып,
ничек белмәк кирәк бу Айны!
Мин, Пушкинның торган җирен күреп,
бөеклеген тойдым Тукайның.

*(«Михайловскоеда»)*

Һәм, ниһаять, бу кереш сүзне язган чакта, янә бер мәртәбә Тукай томлыкларын актарганда, аның «Пушкин вә мин» дигән шигырендәге мондый сүзләргә юлыктым:

...Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннан түбән;
Тугры күз салсаң эшенә – ул үзе миннән түбән!

Мин берәүне дә түбән йә югары санарга теләмим. Әмма – сүз әйтелгән!

Инде шагыйрьнең 100 еллыгына чыккан китап турында. Аңа йөзгә якын авторның Тукайга багышланган шигъри әсәрләре тупланган. Гомумән, Тукай хакында шигырь язмаган бер генә татар шагыйре бармы икән? Ул гына да түгел, башка халык шагыйрьләре, әдипләре дә аның турында үзләренең ихлас фикерләрен әйтеп калдырганнар, шигырьләр иҗат иткәннәр. Шуларны туплап, 1976 елда, төзүче буларак, «Тукайга чәчәкләр» дигән бер җыентык чыгаруда катнашкан идем. Менә 20 еллап гомер үткәч янә бер китап. 20 ел эчендә Тукайга багышлап язылган шигырьләр никадәр ишәйгән! Аларда инде яңа төсмерләр, киләчәккә төбәлгән яңа мотивлар. Элек язылган әсәрләрдә «сүнде йолдыз», «калдырды үксез милләтен», «һәммәбезгә син әрәм» кебек тәгъбирләр өстенлек итсә, соңгы чорларда «Тукай безнең белән», «син яшьтәш тә, замандаш та», «Тукай үлемсезлеген син озайтырга бурычлы», «мин Тукайга барам» кебек күтәренке рухлы юллар хас.

Әйе, безнең халык та кояш астында үзенә урын даулый. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән сорау, шөкер, хәзер юк инде! Уянып торып баскач, нишләргә? Ничек хәрәкәт итәргә? Менә төп тойгы – хис-уй! Тернәкләнеп, үз хакыңны даулау чорында Тукай иҗаты үзе бер таяныч! Үзаңы уянган халык вәкилләре, бу очракта шагыйрьләр, Тукайга багышланган шигырьләре аша үзләренең иң мөкатдәс, иң изге идеалларын ачыклыйлар шикелле. Ул – югалган дәүләтчелегебезне кайтару. Ул – дөньяның иркле халыклары гаиләсендә булу. Бу хыял-максатка ирешү юлында Тукай үзе бер юл күрсәткеч, үзе бер тәрәзә. Без шул мөнбәр тәрәзә аша, күзләребез яшьле булса да, кояш ягына таба карыйбыз.

*1995*

## *Ә ГОРУРЛЫК ХИСЕ ҺАМАН ШУЛ...*

Төрле елда – төрле янулар.
Ә горурлык хисе – һаман шул!

Быел зурлап билгеләп үтелә торган әдәби юбилейлар байтак. Әле яңа гына Ф. Әмирханның 110 еллыгы булып узды, бу айда җәмәгатьчелек М.Җәлилнең 90 еллыгын яд итә, апрельдә Г.Тукайның 110 еллыгы. Шуңа өстәп исән-имин әдипләребезнең төрле дистә еллар уңае белән үткәреләчәк иҗат бәйрәмнәре...

Сөенергә генә кирәк! Билгеләп үтәрлек, кешеләргә күрсәтерлек, әсәрләре белән мактанырлык шәхесләребез, әдипләребез булмаса нишләр идек?.. Уйлап баксаң, һәр юбилей тантанасы – горурлык тойгысы кузгатучы Хәтер тукталышы бит ул.

Әхлак, этика, эстетик идеал кебек төшенчәләр, асылда, тотрыклы булып, тиз генә үзгәрмәсәләр дә, барыбер һәр заманның шул ук категорияләргә үз бизмәне, үз мөнәсәбәте, үз сурәте. Олыларны хөрмәтләү мәсьәләсенә дә кагыла бу.

50 нче елларны хәтергә төшерик. Ул вакытта да юбилейлар, төрле тантаналар, искә алу кичәләре уздырыла иде. Шул исәптән әдәби тантаналар да. Кемнәрнеке? Әлбәттә, Тукайныкы. К.Насыйри, Г.Камал, Ш.Камал, Һ.Такташ кебек шәхесләргә игътибар зур иде. Фронтта һәлак булган Ф.Кәрим, Г.Кутуй иҗатлары да киң пропагандаланды. Шул елларда бу рәткә Сталин премиясе алган язучылар – Г.Бәширов, К.Нәҗми килеп кушылды. Ул вакытта Г.Ибраһимовлар, К.Тинчуриннар, Х.Туфаннар юк. Бәйрәмнәре генә түгел, исемнәре дә «онытылган» иде.

Менә берчак, тоталитар режим тетрәнеп китеп, җәмгыятьтә демократик шытымнар күренә башлаган 1956 елларда, татарларның әле мондый шәхесе дә бар! дигәндәй, Муса Җәлил пәйда булды. Җәлилнең кайтуы татар әдәбияты өчен илаһтан иңгән вәхи кебек кабул ителде. Әдәбиятыбызны дөньяга танытуда зур ыргым ясалды. Җәлил исеме белән халкыбызның иҗтимагый рейтингы күтәрелде. Фани дөньяда кырык ел да яшәмәгән Җәлил инде менә кырык ел (каһарман шагыйрьгә әверелгән чорыннан бирле. Хәер, аның сугышка кадәр язган иҗаты да данлы сәхифә) буе, әдәбиятыбызның байракчысы булып, сафыбызның алдында бара.

Дөрес, соңгы дистә ел эчендә безнең тарихи-рухи хәзинәбез бермә-бер баеды. Инкыйлаб еллары вакытында аударылган «алтын баганалар» яңадан торгызыла. Халыкка бөек Гаяз Исхакый иҗаты кайтты. Бүгенге татар аңына Р.Фәхретдин, С.Максуди, Г.Баттал кебек акыл ияләренең фикер-идеяләре сеңә башлады. Бәрәкалла, машалла!

Йолдызлар бер-берсен капламыйлар. Аларның күләгәләре юк. Рухи күгебездә Җәлил дигән йолдызның күзәнәкләргә үтә торган үз нуры, үз яктысы бар. Җәлил безгә шәхес буларак та, шагыйрь буларак та, каһарман буларак та бик кирәк, һәр заман өчен. Безнең өчен.

*1995*

*P.S.* Шушы төштә нокта куйгач, элегрәк елларда Җәлил турында уйланып, кыска-кыска гына тезмә һәм чәчмә формадагы публицистик язмаларым искә төште. Аларны да укучыларыма тәкъдим итәргә булдым.

*** * ***

Үлемнәре белән үлемсезлек
Яулап ала безнең шагыйрьләр.
Кемдер сорар: кая дәлилең?
Мин эндәшмим.
Каберләре әйтсен,
Тукай,
Кәрим,

Кутуй,
Җәлилнең...
Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау –
Бердәнбер юл түгел тормышта.

*1968*

*** * ***

Горурлык. Яшәүнең мәгънәсен, шәхеснең кешелек дәрәҗәсен билгели торган төшенчәләрнең берсе бу. Горурлык сүзенең фәлсәфи асылын аңлаган зат Җирдә күкрәк киереп нык басып тора. Башын югары йөртә; Кояш һәм Күк астында үзен тулы вәкаләтле хуҗа итеп тоя; дөньяга, яшәешкә үз сүзен әйтә; инанган идеаллары өчен көрәшә, сугыша... Җенес яки аерым шәхес горурлыгы, гаилә-ыру горурлыгы, профессия яки һөнәр-кәсеп горурлыгы, ил-халык горурлыгы, дөнья горурлыгы...

Күпләр кебек, бүген мин дә горурмын. Чөнки горурланыр өчен ныклы нигез, хаклы сәбәпләр бар. Горурландырырлык шундый исемнәрнең берсе – Муса Җәлил. Сокланулы хисләр кичереп һәм таң калып, инде ничә дистә еллар күп илләр, күп халыклар искә ала аны.

Зур залларда тантаналы кичәләр үтә.

Илнең төрле почмакларында туганнарының истәлекләре, көрәштәшләренең тетрәткеч сүзләре яңгырый.

Типография конвейерларыннан шагыйрьнең яңа басмалары агыла.

Укучы балалар, ил чигендә торучы солдатлар, диңгез-океан киңлекләрендә йөзүче матрослар, акыллы машиналар төзүче эшчеләр, кыр хуҗалары – игенчеләр, студент-яшьләр мәктәп классларында, кызыл почмакларда, тулай торакларда аның шигырьләрен йотлыгып укыйлар.

Дистәләгән тәрҗемәчеләр аның шигырьләрен төрле телләрдә яңгырата.

Мәгърур көйләр чыгарып, оркестрлар уйный. Аңа атап язган җырлар, симфонияләр, опералар күңелләрне айкый, үз җырлары бәгырьләрне телә, уйландыра, көрәшкә әйди.

Экраннарда аның образы.
Мәйданнарда сурәтләре.
Һәйкәле янында кешеләр агымы.
Тере чәчәкләр...

...Әйе, бу үзгә бер бәйрәм, зур тантана. Бу – без шаһит булган бүгенге көн. Ә аңа хәтлесе, бүгенге тантананың ерак яралгысы, моннан утыз елдан артык элеккесе – газаплы көрәш, үлем белән якалашу, рухи ныклык, корыч ихтыяр. Туган илгә тугрылык, җиңүгә ышану. Палач балтасы астында үткән еллар, айлар... Бүгенге тантана тавышлары концлагерьлардагы әсирләрнең теш кысып ыңгырашу авазларына, бүгенге затлы кәгазьләргә матур хәрефләр белән басылган юллар фашист өнендә аннан-моннан тапкан кәгазь кисәкләренә карандаш белән тырналган сүзләргә барып тоташа. Кимлек-хурлыкларда, салкын таш капчыкларда, гильотина балтасы асларында сынмаган рух, бүген бөтен халык рухына әйләнеп, бөтен зурлыгында, бөтен иркенлегендә тантана итә.

Үзенең иң яхшы сыйфатларын хәлиткеч сынауларда егетләрчә күрсәтә алган улларына халыкның рәхмәте чиксез. Халык андый шәхесләрнең исемнәрен мәңгегә йөрәгендә саклый. Күңеленнән ташып чыкканын Җирдә – Кояш астында материальләштерә. Табигатьтән ул шәхес-зат төсләр ала, кәгазьләргә, киндерләргә аның сурәтен төшерә, аның исемен ташларга уя; җилләрдән, камышлардан, диңгезләрдән тавыш-авазлар алып, музыка аша, җырлар аша аны данлый; ком-ташларны өеп, биналар, урамнар, проспектлар, калалар төзи дә аларга аның исемен бирә; таулар күкрәгеннән гранит-мәрмәр ташларын алып шомарта да аның сынын мәйданнарга бастырып куя; килер буыннарга батырлык васыяте итеп аның сүзләрен китаплар рәвешендә дөньяга тарата... Муса Җәлил – халыкның әнә шундый зурлавына лаек булган кеше.

Ә аның батырлык чыганагы кайдан килә соң? Әлбәттә, халыктан. Ул – халык улы, хезмәт һәм икмәк тәмен яхшы белгән катлаудан – түбәннән күтәрелгән талант, халыкның рухи ихтыяҗын яхшы тойган әдип, ул үз талантын һәрчак ил ихтыяҗы белән бергә бәйләп алып бара алган шәхес. Ул һәрвакыт тормышның, көрәшнең алгы сызыгында. Ул – яшьләр хәрәкәте үзәгендә, ул – культура революциясе елларында интеллигенциянең алгы сафында, ул – Язучылар оешмасының башында, ул – антифашистик хәрәкәтнең иң хәвефле урыннарында... Менә корыч ничек чыныккан!

Мин горурмын. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк: «Бер горурлык хисе яна миндә». Муса Җәлил – шагыйрь. Зур илнең төрле почмакларында, ерак-ерак авыл-калаларында йөргәндә, чит мәмләкәтләргә сәяхәт вакытларында башка милләт вәкилләре белән очрашканда, үзеңнең кем, кайдан икәнлегеңне белдерергә кирәк булганда, башта ук әйтелгән сүзләрнең берсе итеп Җәлил исемен телгә аласың. Бу исемне әйткәч, күп нәрсә ачыклана төшә. Бу исем, читләрдә йөргәндә, татар халкын белгертә торган үзенә күрә бер пароль, паспорт шикелле яңгырый. Шагыйрь исеме аркылы халыкны таныйлар, исәпләшәләр, бәялиләр. Безгә, татар әдәбиятының бүгенгесен дәвам итүчеләргә, ифрат зур бер дәрәҗә һәм гыйбрәт бу. Шул ук вакытта уйга калдырырлык җаваплылык та. Менә чын язучының иҗтимагый тормышта тотарга тиеш урыны! Муса Җәлил – аның бер өлгесе. Заманның алгы сафында бул, фидакарь хезмәт ит, ян, олы идеаллар өчен көрәш, кирәксә, башыңны куй...

Ил Муса Җәлил юбилеен билгеләп үтә. Телләрдә – батыр шагыйрьнең исеме. Шулай да бу хосусый тантана гына түгел. Без Муса Җәлил белән бергә аның көрәштәшләрен дә, ил азатлыгы өчен гомерләрен биргән миллионлаган патриотларның исемнәрен дә искә төшерәбез, сугыш кырларыннан кайтмый калган бабаларыбызны, әтиләребезне, якыннарыбызны да яд итәбез. Батырлык япа-ялгыз була алмый. Горурлык та шулай ук. Без бүген күмәк горурланабыз. Чөнки бу уртак горурлык, миллионлаган кешеләрнең гомум горурлыгы. Иң куанычлысы: горурланырлык кешеләр тудыручы халык бар, ул – мәңгелек, аның рух чишмәсе бетмәс-төкәнмәс.

*1976*

*** * ***

Хәтердә: моннан берничә ел элек Җәлил көрәштәшләренең берсе белән Кремль калкулыгыннан – хәзерге 1 Май мәйданыннан – Казансу елгасына, Елан тавы ягына, Идел киңлекләре тарафына сүзсез генә бик озак карап торган идек. Вакыт – кичке чак, шәфәкъ чагы. Тын, моңсу вакыт. Кабаланмаган кеше өчен уйландыра торган вакыт. Офыкта кызгылт төсләр мәхшәре, һәм шул алсу кызыллык Казансу суында үзгә бер киң коридор ясап сузылган да ак Кремль диварларына кадәр күтәрелгән. Бөтен тирә-юньдә әлеге шул алсу кызыллык чагылышы – Җәлилнең бронза сынында да, агач ябалдашларында да, ак манарадагы сәгать телләрендә дә, сөзәк дамбаның шомарып беткән ташларында да. Скверлардагы кызыл гөлләр, үзләренең кызыллыкларына яңа кызыллык өстәлгәч, бөтенләй яңа бер кайнарлык белән дөрлиләр шикелле, һәммә җирдә кызыллык. Без басып торган һәм шул мәгърур һәйкәлне күтәреп торган туфрак-җир үзе дә кызыл төстәдер кебек... Хәер, символик мәгънәдә болай фараз итүдә дөреслек тә бар. Күп яуны сынаган, күп кан сеңдергән туфрак бит ул. Тарих түрләрендә дә, безнең гасырның шанлы революция елларында да. Ветеран агайның йөзенә күз сирпеп алам. Минем уемда – менә шушы кызыл төсләр һәм шул төсләр аша ассоциатив чагыштырулар, параллельләр... Соңрак мондый тезмә юллар да язылды:

Казан Кремле янында
сүзсез басып тордык
бер җәлилче ветеран белән.
Кан өстендә – Җәлил һәйкәле.
Казансуда,
Иван явы килгән якта –
кызыл офыкта –
канлы Кояш.

Ә менә гомерендә күпне күргән, күпне кичергән бу агай ниләр уйлый икән? Теләгемне күңеле белән сиздеме, әллә үз уеның табигый агышы шулай идеме, ветеран агай, борылмыйча, үз турына караган килеш, салмак һәм нык тавыш белән әйтеп куйды: «Муса турында менә шулай биектән торып уйларга кирәк шул!..»

Чыннан да, Җәлил язмышы һәм иҗаты, аның кылган гамәле һәм батырлыгы хәзер дөньяның иң биек мөнбәрләреннән торып, кешелек акылы ирешкән иң югары фәлсәфи категорияләр белән анализланырга, бәяләнергә тиеш. Еллар үтә. Төрле рухи һәм җисми үзгәрешләр кичерә-кичерә, кешелекнең янә бер гасырын очлау ягына барабыз. Шунысы ачык: еллар үткән саен, халыклар күз алдында Җәлил күтәрелә генә бара... Исем түгел, эш күтәрә аны, Матурлык һәм Батырлык елъязмасына керткән өлеше күтәрә... Әйе, еллар үтә. Җәлилнең һәм көрәштәшләренең үтерелүләренә дә инде байтак гомер үтте. Аның үзен күргән, аралашкан, якын белгән кешеләр дә көннән-көн азрак калып бара. Хәзерге яңа буыннар – яшьләр өчен, гәрчә алар шагыйрьнең тормыш юлын китаплар һәм башка чыганаклар аша шактый ук яхшы белсәләр дә, Җәлил беренче чиратта рухи яктан – тарихи каһарманлык эшләгән кеше буларак якын һәм кадерле. Еллар үтү белән шәхеснең бәндәлеге онытыла, рухы кала, игелеге, кешелеклеге кала, батырлыгы, фидакарьлеге, тугрылыклыгы кешеләр хәтерендә яңа яхшы төсмерләрдә яңара. Җәлилнең тормышы һәм үлеме хәзер инде яшәеш факты булып кына түгел, ә тарихи вакыйга булып танылды.

Муса Җәлил бөеклек баскычына шагыйрь фидакарьлеге һәм солдат батырлыгы күрсәтеп күтәрелде. Шагыйрь батырлыгы. Солдат батырлыгы. Үлемсезлек өчен, ихтимал, берсе генә дә җитә кебек. Ике төр батырлык. Ә Җәлил мисалында бу батырлыклар – органик бербөтен, алар гүя аның асылын ача торган ихтыяҗи чаралар. Җәлил, гомумән, күпкырлы, күпьяклы шәхес. Ә кирәк чакта, хәлиткеч сынау вакытында, ул үзенең иң асыл ягы белән ачыла: бөтен көчен һәм рухын бер максатка – Илгә һәм Поэзиягә тугрылыклы булып калуга юнәлтә. Кайчак, сирәк кенә булса да, Җәлил турында мондыйрак фикер дә ишетелгәләп куя: ул – герой да, шагыйрь дә, геройлыгы зурмы, шагыйрьлегеме? Янәсе, геройлык күрсәтмәсә, иҗаты белән Җәлил бөек шагыйрьләр рәтендә йөрер идеме? Мондый сорау һәм бербөтен күренешне аерым бүлеп карау, әлбәттә, шагыйрьнең иҗтимагый тормышын һәм мирасын тиешенчә белмәгән очракта гына туарга мөмкин. Муса Җәлилгә табигать күпне биргән. Шуңа өстәп Җәлил үзе дә табигать бүләкләренең ни бәһа икәнен яхшы аңлаган, саулыкның, вакытның, хезмәтнең кадерен һәм ләззәтен бик яхшы белгән. Сез аның күптән түгел генә чыккан дүрт томлык китапларын ешрак ачып укып карагыз! Дөньялыкта шактый аз яшәп киткән шагыйрьнең безгә калдырган рухи һәйкәле бит алар! Шигырен укыйсыңмы, мәкаләсен яки публицистик чыгышынмы, Җәлилнең кабатланмас шәхесе күз алдына килеп баса. Ул – тынгысыз, ул – эш кешесе, ул – һәрвакыт динамик хәрәкәттә, ул – оптимист, ул үз эшенә нык инанган... Әлеге томнарда Муса Җәлилнең татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге титаник хезмәте һәм, гомумән, культурабыз тарихындагы урыны бик ачык күренә.

Күп эшләгән шагыйрь!
Нык янган!
Ташка басып чыгарганы –
Йөзләп табак...
Дүрттомлыгы тора киштәмдә,
күзне иркәләп,
җанга рух биреп.
Ә калган томнары –
төрмә, вәхшәт йотканнары –
күңелемдә йөри әрнешеп...

Муса Җәлилнең әдип буларак зурлыгы, олылыгы бәхәссез нәрсә. Очраклы хәлме: илнең иң зур бүләге булган Ленин премиясен шагыйрьләр арасында беренче булып Җәлил шигырьләре алды бит! Бу аның поэтик батырлыгын ил һәм дөнья күләмендә тану һәм билгеләү булды.

Әйе, Муса Җәлил батырлыгының мәгънәсе вакытлар үтү белән һаман зурая бара. Аның батырлыгы – үткән өчен генә түгел, хәзер дә, киләчәк өчен дә бик кирәк батырлык, ихтыяҗи батырлык булып чыкты. Җәлилчеләр көрәше – Кешелекнең фашизм кебек афәтне җиңә алу мөмкинлегенең бер дәлиле, җиңә алу тантанасының бер чагылышы иде. Әмма тынычланырга

әле иртә. Фашизмның да, шовинизмның да беткәне юк. Киләчәк өчен төрле социаль системалар, кыйтга-континентлар, ил-дәүләтләр арасында аяусыз көрәш бара. Тупас көчнең канаты һаман җәюле. Геноцид хәлләре, яман чир кебек, аз санлы халыкларның җанын кимерә бирә... Көрәш кискенлегенең, рухи киеренкелекнең кимегәне юк. Димәк, көрәшчеләр кирәклеге, Җәлил кебек гуман, сәнгатен һәм гомерен салып көрәшә алырлык шәхесләрнең күбрәк кирәклеге торган саен ныграк сизелә. Кешелекне кешелеклегенә чакыру, аның вөҗданын уяту, җир йөзендәге җаннарның мөмкин кадәр күбрәген бөек идеалларга хезмәт иттерү... Тере материянең йөрәген саклау, җанын пакьләү... Менә хәзер безнең яшәеш килеп терәлгән глобаль проблемалар. Мондый проблемаларны кешелек файдасына чишәр өчен Җәлил кебек интернациональ күңелле, көчле рухлы чын көрәшчеләр кирәк. Миңа калса, менә шуның өчен дә төрле милләтнең акыл ияләре – дәүләт эшлеклеләре, философлары, шагыйрьләре Җәлил турында үзгә бер патетик тойгы йөртәләр. Үзебездә бер хәл, инде шушы соңгы дистә еллар эчендә тугандаш халыклар телендә Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында күпме җыр, шигырьләр, пьеса, поэмалар, повестьлар туды, күпме сынлы сәнгать һәм сәхнә әсәрләре иҗат ителде. Хикмәт Җәлилчеләрнең батырлыгына дан җырлау гына түгел, төп максат – киләчәк буыннарда Җәлил кебек ватанчыл, илсөяр тойгылар тәрбияләү, аларны чын кешеләр итеп үстерү.

Җәлил – татар халкының бер газиз улы. Әгәр ул бөтен дөнья таң калырлык батырлык үрнәге икән, димәк (батырлык та, чын сәнгать тә буш урында, нигезе булмаган җирдә туа алмый), аны тәрбияләп үстергән халык үзе дә – олы халык, чын сәнгать тудырырга һәм үлемсез батырлык күрсәтергә сәләтле халык, рухи потенциаль мөмкинлекләре зур халык.

Безнең өчен – бүгенге татар әдәбиятын үстерү эшенә күңелләребез белән алынган кешеләр – язучылар өчен, Җәлил шагыйрь һәм әдип буларак аеруча кадерле. Җәлил – зур тарихи поэтик мирасны нык үзләштергән, поэтикабызны яңа шартларда үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән шәхес. Әгәр аның шагыйрьлек һәм гражданлык батырлыгы турында олы сүзләр сөйләп, аның традицияләре турында бик еш яза килеп тә, бүген аның юлын, иҗтимагый идеалларын конкрет эшебездә, конкрет хезмәтләребездә дәвам иттермәсәк, без берьяклы һәм рухи яктан фәкыйрь кешеләр булыр идек. Шөкер, бүгенге татар поэзиясе туктаусыз үсештә. Тукай, Җәлилләр эстафетасын яңа буыннар ышанычлы адымнар белән яңа сыйфатларда дәвам иттерә. Без бүген, иманнарыбызга хилафлык китермичә, хәзерге заман поэзиясенә үзләреннән лаеклы өлеш кертә алырлык байтак исемнәр саный алабыз. Димәк, Җәлил шагыйрь буларак та һаман безнең белән, ул – күңелләрдә, йөрәкләрдә, рухы һаман исән, сау-сәламәт!

*1980*

## *ХАЛЫКЧАН ШАГЫЙРЬ*

Әлмәттә, шәһәр читендәге биек таш йортларның берсендә шагыйрь Гамил Афзал яши. «Шәһәр читендә» диюем бик дөрес үк тә булмас, чөнки берничә елдан хәзергә «кырый, чит» саналган бу урам-чатлар шәһәрнең үзәгенә әйләнәчәк. Әгәр ул чагында аның турында берәр нәрсә язарга насыйп булса, беркадәр горурлык белән: «Шагыйрь Гамил Афзал яши шәһәрнең үзәгендә», – диярбез. Биш катлы йортның иң өстәге чат бүлмәсе – шагыйрьнең эш урыны. Бу бүлмә, миңа калса, тыштан шактый шыксыз күренгән шушы таш йортның иң тынгысыз, иң ялкынлы җире, йөрәге урнашкан төшедер шикелле.

Биредә шигырьләр туа. Биредә Яхшылык белән Яманлык күзгә-күз очраша. Таһир-Зөһрәләр утында янучы гашыйклар өзгәләнә, ил явында авып калган уллар, терелеп, телгә килә, кышкы бураннарда сыерчыклар әйләнеп кайта, борынгы алмаз кылычлар, айбалталар уйный, абагалар чәчәк ата, космонавтлар ял итәргә туктый. Биредә шигырь туа! Биредә төннәр буе, «таң нурлары җиргә тамганчы, халкына нур көлтәсе бүләк итәргә» хыялланып, шагыйрь иҗат итә. Ул «матурлык эзли, ил туена сүздән чәчәкләр җыя»! Яхшы җыр, яхшы шигырь туган җир – изге җир ул!

Шагыйрь бүлмәсендәге тәрәзәдән карасаң, Зәй әрәмәлекләре, Бигеш кырлары, Урсал таулары, арырак күз атсаң, күкселләнеп, томанланып торган офык читләре күренә, аста

Чистай–Казан якларына таба тасма юллар сызылып китә. Бу күренеш, бу панорама байтак татар шагыйрьләренә, каләмнәрен әле яңа тибрәтә башлаган бик күп яшь авторларга таныш дип беләм. Казан яки күрше-тирә районнардан Әлмәткә килеп тә, Гамил Афзалларга керми киткән язучы сирәктер... Аңа киләләр, гаиләсен күреп чыгалар, хәл-әхвәл сорашалар, шигырь укыйлар, чәй эчәләр... Бер уйлаганда, гаилә-көнкүрешкә генә караган бу хәлнең икенче бер мәгънәле ягын күрәм мин, күптән эчтә йөртә торган уема терәк, дәлил табам: кешеләрне сөйми, ялгызак, үз-үзенә бикләнгән кеше яхшы шагыйрь була алмыйдыр; эчкерле, хөсетле, эгоист, заман һәм халык уй-тойгыларына битараф кеше, хәтта талантлы булса да, шагыйрь түгел ул. Шагыйрь күңеле энә күзе кебек тар була алмый. Тар күңелгә ваклык, мәкер сыя алса да, халыкның шатлык-кайгыларына бөтән күңел, киң, ачык күңел кирәк. Кешеләрне ярату, аларны чыннан да табигать таҗы итеп күрү, акылына инану кирәк. Бер шагыйрь үзенең китабына автограф итеп болай язган иде: «Кешеләрне ярату, һай, кыен эш! Шул эштә без чын кешеләр булып калсак икән!» Еллар үткән саен, бу сүзләрнең мәгънәсен тирәнрәк тоя барасың. Г.Афзалның да кешеләр турында мондый юллары бар:

Йөз кабат сөртенәм, абынам,
Йөз кабат таянам кешегә.
Йөз кабат кимсенәм, алданам,
Йөз кабат ышанам кешегә.
Йөз кабат читсенәм, шикләнәм,
Йөз кабат кизәнәм кешегә.
Йөз кабат сөенәм, хушлашам,
Йөз кабат сокланам кешегә.

Яки менә икенчесе:

Язам-сызам, язам-уйлыйм, ярармы, дим.
Кешеләргә файдамы бу, зарармы, дим.
Хурлыйммы мин, зурлыйммы мин аларны, дим.
Ак намусым күзен тутырып карап тора.

«Ак намусың күзен тутырып карап торганда», кеше күңеле түрендәген туры итеп әйтми кала аламы соң! Менә Г.Афзалның «Үзем турында» дигән шигыре:

Күзләремнең нурын,
Йөрәгемнең моңын
Кураема салып җыр итәм.
Йөзем аклыгы да,
Күңел шатлыгы да
Минем өчен шаян җыр икән.
Бәхет балкыр заман.
Ә мин ятып язам.
Күпме сагыш килде өелеп!
Үзем сүнеп ятам,
Үзем көлеп ятам,
Кеше бәхете өчен сөенеп.

Гамил Афзалга килгән кеше аның язу өстәлендә, китап шкафларында яткан амбар кенәгәләренә игътибар итми калмыйдыр. Аларда булачак шагыйрьнең өйрәнчек шигырьләре дә, татар шигърияте хәзинәсенә керерлек нәфис эшләнгән соңгы дәвер шигырьләре дә бар. Алар 16 данә. Һәммәсендә борынгы язма китапларга хас пөхтәлек белән тигез юллар тезелгән. Дөресен әйткәндә, ул кенәгәләр мине башта бераз сәерсендергән дә иде, айга менгән заманда, язу эше белән шөгыльләнгән һәр кешенең диярлек «Оптима» яки «Эрика» кебек язу машиналары булган чорда, дебит-кредит графалары сызылган соргылт-сары битле бу шыксыз кенәгәләр гаҗәпләндергән иде. Хәзер инде алай түгел. Хәтта аерым-аерым битләргә караганда бар язганың бергә теркәлеп бару ягыннан хуп та күрәм.

Шулай да беркөн, ярым шаяртып:

– Гамил абый, бу амбар кенәгәләрен каян табып бетерәсең? – дигән идем, ул, балаларча җитди һәм беркатлы итеп:

– Менә бусын, кызыл тышлысын, балдыз Урта Азиядән алып кайтты, ә менә бу икесен үзебезнең секретарь Миңнур биргән иде, – диде.

Әйе, кемнәрдер акча ясарлык шыгырдап торган кәгазьләргә, кемнәрдер амбар кенәгәләренә яза. Ул кәгазьләргә төшкәннәрнең чын бәясен киләчәк әйтер. Кем белә, килер буынның Альберт Фәтхи кебек китапчы-галимнәре, 60 нчы еллар татар шигърияте өйрән-гәндә, бәлки, беренче чиратта әнә шул амбар кенәгәләрен бик кадерле кульязмалар итеп өйрәнерләр, һәрхәлдә, шулай булсын иде, диик, шуңа юрыйк.

Г.Афзал 1921 елда Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туа. Нәни Гамилнең дөнья белән таныша башлавы җирнең шушы ноктасыннан башлана. Монда тел ачылган, чишмәләрнең серле чылтыраулары тыңланган, күзләргә беренче күргән таңнарның нурлары иңгән, беренче такмаклар әйтелгән.

Гамилгә өч яшь тулгач, әнисе вафат була. Унынчы яшькә чыккач, Афзаловлар семьясы Урал-Магнитка якларына күчеп китә. Малайның Одиссеясе! Беренче мәртәбә идәне дә, стенасы да, түшәме дә таш йортларны күреп шаккатулар, «электр» дигән керосинсыз лампаларга ис китүләр, киң, коточкыч тирән Кама-Чулман елгасы, андагы ап-ак пароходлар, челтәр күперләр, чуен юлларны кыздырып үтүче паровозлар... Туган авылдан китү – булачак шагыйрь Гамилдә мәңге онытылмаслык кичерешләр тудырып, онытылмаслык хатирәләр калдырган. Әле быел гына язылган, беркадәр Г.Тукайның «Исемдә калганнар»ын хәтерләткән, «Юл башы» дип аталган автобиографик язмасында автор гомеренең бу көннәрен тормышының кискен бер борылышы – зур дөньяга чыккандагы юл башы дип саный. «Бөтен халык утырып беткәч, паровоз ак парлар чыгарып бер-ике пошкырды, озын итеп «Ки-и-и-т-тек!» дип кычкырды да ләштер-ләштер кузгалып китте. Уралга барабыз, Уралга! Урманнар, кырлар, күгелҗем офыклар, кечкенә инешләр, телеграм баганалары артка йөгерәләр. Без ак болытларга каршы, биек тауларга каршы йөгерәбез. Вәсилә апа әкрен генә, борын эченнән генә җырлап бара:

Телеграм баганасын
Санайсым калган икән;
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән...

Без Уралга барабыз. Авыл урамнары, кычытканлы читән буйлары, тыкрык әрекмәннәре, какылы ындыр артларыннан башка берни күрмәгән авыл малаена бу сәяхәт киң дөньяга чыгу иде. Үсеп килә торган, барын да күрергә, барын да белергә тырышкан балага дөньяны тану, тормышны өйрәнү өчен сикәлтәле юллардан йөрү бик кирәк икән. Бәрелә-сугыла йөреп, күп михнәтләр күрсәм дә, язмышка бер тамчы да үпкәм юк, үземчә бик кызык булды минем тормышым. Мин бик бәхетле кеше».

Яңа җирләрнең үзгә матурлыгы һәм кырыслыгы, төрле мәктәпләрдә белем эстәп йөрүләр... Башта – Магнитогорскида җидееллык мәктәп. Аннан – Троицк педагогия училищесының беренче курсы, аннан – металл кою заводлары, Мартен мичләре, һәвәскәрләр белән «Галиябану», «Ак калфак»ларны сәхнәләрдә уйнаулар. Тагын завод. Бу юлы инде сугыш ихтыяҗына эшләүче заводлар. Үзгә киеренкелек, үзгә ритм. Үсмер чакта ук аягын имгәткән Гамил 50 нче еллар башында тәмам түшәккә егыла.

Сизәм, сызлыйм, сөенәм, тынмыйм һич тә.
Бөтен дөнья сыйган минем эчкә.
Мин түшәмгә карап уйлап ятам
Иртә дә, көндез дә, кич тә.
Аксын әле, егет, синең кулда
чәчеп ялкын!
Шушы ташкын җиңү алып барды
Эльба ярларына,
Шушы ташкын ирек алып барды
Карпат тауларына.
Корыч кошлар илнең күкрәгендә,
Корыч линкор диңгез өсләрендә –
безнең куллар көче.
Мин үзем дә завод цехларында
тимер юнган кеше.

Сугышта Кавказ таулары итәгендә ятып калган яшьлек дусты, яшь шагыйрь Касыйм Таһиров истәлегенә язылган «Табылдык дәфтәр» шигырендә шагыйрь ул дәһшәтле сынау елларын тагын бер кат хәтеренә төшерә:

...Авыр сулап валлар ухылдады,
Боерык булып килде бар нарядлар:
– Снарядлар кирәк, снарядлар!
Отпуск та, ял да сораучы юк,
Атып үлү яхшы, кол булганчы!
Кара таңны кара төнгә ялгап,
Сменалар эшли егылганчы.

Авыр еллар, сынау, чыныгу еллары барыбер гомернең бик газиз еллары... Сау бул, Урал!

Бодай кырларына тарта йөрәк,
Гудокларга күңел күнсә дә;
Болыннарның саф һавасы кирәк
Гөлләр исен сөйгән үпкәгә.

Теге яки бу дәрәҗәдә шәхси тормышы белән авылга бәйләнмәгән, җиргә мөнәсәбәте булмаган татар шагыйрен табу, гомумән, кыен. Берәүләр туган җире – авылын яшел бишек, берәүләр алтын бишек, диләр, һәркем үзенчә хаклы. Эпитетларны һәркем үзенчә сайлый, сүзнең төбе, мәгънәсе бер: авыл, чыннан да, күпләребез өчен бишек. Г.Афзалның яңадан авылга, табигатькә, ике дистә елдан артык аерылыбрак торган җир кешеләренә әйләнеп кайтуы аның рухи тормышында икенче бер зур борылыш булды.

1954 елга кадәр, Башкортстанның ямьле табигать кочагында утырган Шәрип авылына күчеп кайтканга кадәр, булачак шагыйрьнең тормыш университетлары чоры, аның кеше, гражданин буларак чыныгу чоры, туачак әсәрләренә хәзинә-материал туплау чоры. Г.Афзалның «Магнитогорск» дигән беренче шигыре матбугатта 1937 елда ук басылса да, 1955 елларга кадәр шагыйрь үзен таныта алмады. Дөрес, ул язмый тормаган, язган, шигырьләрен газета-журнал редакцияләренә, шагыйрьләргә (бигрәк тә С.Хәкимгә) җибәреп торган... Күрәсең, талантының әдәбиятка бәреп керерлек көче әле максатлы хәрәкәткә килә алмаган, ниндидер яңа шартларга кадәр тыелып торган. Бу җәһәттән шагыйрьләр мәйданына чыгар алдыннан бик зарур – кайнап торган әдәби мохитнең булмавы, махсус әдәби белемнең җитенкерәмәве дә, һичшиксез, сәбәп булмый калмагандыр. Г.Афзал гомеренең бу чорын сагыш катыш көлемсерәп, сагынып, беркадәр горурланып искә ала:

Көрсенмә син, күңел,
Көрсенмә!
Йөгереп үткән якты елларыңның
Эзсез диеп булмый берсен дә,
Төссез диеп булмый берсен дә.

Яки:

Бишьеллыкның данлы төзелешләре
Урал даласында еракта...
Күзем йомсам, күз алдымда тора,
Гөрелтесе шаулый колакта.

Дөрес, болар соңрак язылган шигырьләр. Ләкин алар ул вакыттагы тәэсирләрнең, ул чордагы уй-хисләрнең нәтиҗәсе, дистә еллар соңыннан кире кайткан яңгырашы. Ил белән бергә, халык белән бергә булганда, Ватан хакына, җиңү хакына көрәшкәндә ничек итеп ул елларны эзсез, төссез дип әйтеп булсын!

Дулап-дулап кызыл улак буйлап
Кызыл ташкын ага,
Бөгелмәдем,
Бирелмәдем чиргә.
Моңын җиңеп кайгы-сагышның,
Тешем кысып,
Шушы туган җиргә
Ун тырнагым белән ябыштым.
Һәм

Җир бирде миңа Салсал көчен,
Иркен сулыш өрдe үләннәр...

Ә дөнья шундый матур, шундый киң! Табигатьтә мәңгелек хәрәкәт, мәңгелек яшәү! Яңадан, балачактагыдай, язлар килә, сыерчыклар бала чыгара... «Җир яшәрә сугышлардан туеп, гашыйк булган үзе кояшка!» Яшәргә! Яшәргә!

Чөнки:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә ярым,
Сөйгән ярым гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!
Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дус янында кем ятим?!
Күктә нурлар, җирдә шатлык,
Җирдә бәхет гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Авылда бераз яшәп савыга төшкәч, ниһаять, Гамил Афзалның да шушы «матур, киң дөньяның» шигърият атлы симфониясендә үзенчәлекле авазы яңгырый башлады. «Авыл, табигать тәнемә сихәт, күңелемдәге уйларымны кешеләргә илтер тел бирде», – ди шагыйрь. 1955 елда аның бер цикл шигырьләре балалар өчен язылган шигъри әсәрләргә конкурста премиягә лаек булды. Аларның күбесе шагыйрьнең «Кар сулары» исемле китабында 1957 елда басылып чыкты. Магнитка якларына китү киңрәк тормышка юл башы булса, бусы инде зур әдәбиятка юл яру иде. Шуннан соң унбиш елга якын гомер үтте, һәм шагыйрьнең татар телендә унбиш китабы басылып чыкты. Ул китаплар кибет киштәләрендә кадерсезләнеп, тузанланып ятмадылар, аларның күбесе күңелләрдә урын тапты. С.Хәким дә аның бер китабына язган кереш сүзендә: «Ул әдәбиятка үзеннән алда кергән кайбер өлкән буын шагыйрьләренә караганда да үзенең укучыларын тизрәк тапты», – ди. Хәзер, шагыйрь татар поэзиясендә нык урын алгач, аның иҗаты турында уйланып, үзеңне кызыксындырган кайбер сорауларга үзең үк җавап эзлисең. Шагыйрьнең илһам чыганагы, таяну ноктасы кайда? Остазлары кем? Иҗатының нинди сыйфатлары укучыга газиз? Чагыштырмача тиз арада шигырьләрнең популярлашып китүенең сәбәбе нәрсәдә?

Шагыйрьгә, гомумән, теләсә нинди жанрда иҗат итүче әдәбият кешесенә талантының үрләп китүенә төп шарт – рухына, җанына муафыйк табигый җирлек, табигый мохит булу. Г.Афзал – авыл баласы, табигать баласы. Табигатьне бөтенебез яратабыз. Ләкин үз яратуы бүтәннәргә дә кучәрлек итеп ярату, аның гүзәллеген, сафлыгын кешеләр күңеленә күчерә алырлык дәрәҗәдә җырлый алу талантларга гына бирелгән. Г.Афзал табигатьне бик нечкә тоеп, садә һәм халыкчан итеп тасвирлый ала, тасвирлап кына калмый, аны кешеләр күңеленә якынайта яки кешенең үзен табигатькә күзгә күренмәс җепләр белән бәйли, аларның берлеген искәртеп тора. Аның тугайлары, болыннары, тирәкләрендә рәшә булып кешенең шатлык-сөенечләре уйный, томан булып сагыш иңә, әрем-куакларны иркәләп искән талгын җилләренә кеше тоемы ияреп йөри. Менә берничә мисал:

Соры дулкын булып арыш җитә,
Болыннарда зәңгәр моң йөри...

Яки:

Урман буйларында соры юрган,
Галиябану монда арыш урган.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Көтү үткән тугайларга тулып,
Минем моңым агыла томан булып.

Яисә:

Кырлар яшел, күкләр зәңгәр сатин,
Таңнар комач кебек...
Гомер буе карап торсаң да син
Күреп туймас кебек.

Г.Афзалның 50 нче еллар ахырында әдәбиятка үзенең юмористик һәм сатирик шигырьләре белән омтылышлы керүе – аның үз геройлары арасында яшәвендә, авыл кешеләренең гадәт-психологиясен нечкәләп белүендә, аларны аңлый алуында. Ул алар турында яратып, сөеп яза. Күпчелек очракта ул кешеләр аңа рухи якын, үз кешеләр. Шагыйрьнең аларга кешелекле эчке бер җылы хисе бар. Юкса ул аларның рухына, эчке дөньяларына үтеп керә алыр идеме, алар теле белән, алар булып яза алыр идеме?! 50–60 нчы еллар колхоз авылының байтак кызык, кабатланмас типларын үзенчә буяулар белән калку итеп күрсәтеп бирә алды шагыйрь. Аның геройлары билгеле бер төбәкнеке, әйтик, Шәрип авылы тирәләренеке генә түгел, гомумән, Урта Идел, Урал буйлары татар авылларыныкы. Алар типик геройлар. Алар һәр авылда бар. Кайберләрен генә исегезгә төшерегез: ат караудан зур юаныч табучы колхозчы Сабирҗаннар, яшьләрне чак кына сүгеп, картлыкның да яхшы якларын табып, җаннарын тынычлатучы Фәтхелсәлим агайлар, махра урап, политика сүткәннән соң, янки-чәнкиләргә ачу итеп, «печтек кенә салгалап» кәефләнүне дә читкә куймаучы Гаптелислам агайлар, өй борынча сүз җыеп, сүз чәчеп йөрүче Мәүҗидәттәйләр, хәрам малга кулы ымсыныбрак тора торган Сәлимгәрәй җизниләр, бераз мактанчыграк Сәләхетдин бабайлар, теленнән – очкын, кулыннан ут уйнатып, көләч йөзле кодачаларга ялт иттереп мич чыгаручы җор Шиһабетдиннәр, ава-түнә йөрүче бригадир Ахуннар...

Г.Афзалның авыл кешеләре турында елмайта-көлдерә торган шигырьләре матбугатта чыгу белән, укучы үзенең танышларын, күршеләрен, авылдашларын күрде, бик оста язылганнарын ятлап алды, сәхнәләрдән сөйләде, көйгә салды. Чөнки ул шигырьләр тормышчан иде, халыкчан иде. Шагыйрь халыктан алганны, күңеле аша үткәреп, тәртипкә, көйгә салып, янәдән халыкның үзенә кайтарып бирде.

Шагыйрьнең китаплары турында, авылча, халыкчан теле турында, гомумән, юмористик һәм сатирик шигырьләре турында моңа кадәр матбугатта байтак язылды. Бу төр шигырьләрнең художество үзенчәлекләре хакында махсус мәкаләләр дә булды. Җыйнап әйткәндә, Г.Афзалның 50–60 нчы еллардагы юмористик һәм сатирик шигырьләре татар поэзиясендә кызыклы, мәгънәле күренеш иде.

Г.Афзал югары уку йортларында махсус белем алган кеше түгел. Ул тумыштан нечкә хисләргә бирелеп, көйләр тыңлап, халык арасында рухи чарланып, хикмәтле сүзләр ишетеп, түбәннән күтәрелгән табигый талант. Ләкин тормышта тиктомалдан гына могҗиза ясалмый, сәбәпсез нәтиҗә булмый. Г.Афзалның да шагыйрь булып китүенә күп факторлар сәбәп. Аның да өйрәтүчеләре, остазлары булган. Шагыйрь нечкә тоемлы күңелгә, чичәннәрнекедәй телгә ия. Ул, беренчедән, бу байлыгы белән табигатькә һәм гасырлар буена мирас-хәзинә булып килгән уй-фикерләрне садә итеп, ягымлы, тапкыр һәм төзек итеп әйтеп бирергә сәләтле халык теленә бурычлы. Икенчедән, шәхси остазларга бурычлы. Г.Афзал өчен алар – Г.Тукай, Ш.Бабич, Һ.Такташ... Хәзерге көндә Тукай традицияләрен тугрылыклы рәвештә дәвам иттерүчеләрнең берсе, һичшиксез, Г.Афзал. Бу жанрлар ягыннан да, тематик яктан да раслана. Мәсәлән, Н.Исәнбәткә багышланган шигырьләр циклында мондый юлларны укыйбыз:

Мин бу җирдә төпле хуҗа, туган,
Рәхмәт әйтеп алдым әзерне.
Тукай, Бабич кулы сыйпап узган
Һәр чәчәге миңа кадерле.
Миңа илләр, еллар сере ачык,
Төсен таныйм акның, караның.
Даһиларның иңбашына басып,
Заман үрләренә карадым.

Тукай, Бабичлар үзләренең мираслары – гүзәл шигырьләре белән рухландырып, көч өстәп торсалар, Г.Афзалның әдәбият мәйданына чыгуында күренекле шагыйрь С.Хәкимнең роле бик зур. Ул аның өмет дусты – киңәшчесе һәм укытучысы.

Бүгенге әдәбиятта Тукай традицияләрен дәвам иттерүче булып саналучылар яки саналырга әзерләр байтак табылырга мөмкин. Ләкин аңа лаек булу кирәк бит әле! Тукай традицияләрен дәвам иттерү беренче чиратта заман һәм халык улы була алу, ил алдында торган иң актуаль мәсьәләләрне үз итеп кабул кылып хәл итәргә алыну, чын гражданин булу. Әлбәттә, бу олы бурычларны үтәргә талант кирәк, идеаллы максат кирәк, йөрәк кирәк.

Фәлсәфәне ничек кенә боргалама,
Берәр генә өч нәрсә бар бу дөньяда.
Иң кадерле,
иң мөкатдәс,
иң изге зат:
Туган илең,
Туган телең,
Туган ана.

Р.Кутуйның «Ленинга карап» исемле новелласы бар. Анда балаларча беркатлы, әмма рухы нык, күңеле нечкә берәүнең, урта яшьләрдәге авыл кешесенең Мәскәүгә беренче тапкыр килгәч, кешеләр торганчы, иртүк, бәйрәмчә киенеп, Ленин янына мавзолейга баруы сурәтләнә. Әсәрдә исеме күрсәтелмәсә дә, ул – Г.Афзал. Моннан өч-дүрт ел элек бер төркем язучылар Мәскәүгә барып татар әдәбияты көннәре үткәреп йөргәннәр иде. Шагыйрь Р.Кутуй Г.Афзал белән «Украина» гостиницасының бер бүлмәсендә тора. Рөстәм аны натурадан кәгазьгә күчергән. Укып карагыз, көлке шигырьләрен яратып укыган шагыйрегезнең лирик җанын беркадәр аңлый төшәрсез! (Шунысы да кызык, Г.Афзал үзе дә мавзолейны күрү тәэсиреннән нәкъ шул ук исемдә шигырь иҗат итә.)

Шагыйрьнең 15–20 еллык иҗатын яңадан күздән кичереп, китапларын кат-кат укып, анализлап карагач, бәй, дип куясың – юморист Гамил янында лирик Гамил бер дә ким түгел ләбаса! Г.Афзалның 50 нче еллар урталарында язылган «Дөнья матур, дөнья киң», «Матурлык эзлим», «Шиһабетдин», «Коммунист йөрәге турында баллада», «Ана», 60 нчы елларда иҗат ителгән «Идел ага», «Ел буе», «Моң» һәм соңгы елларда басылып чыккан «Ленин булып уйлап кара», «Фәлсәфәне ничек кенә боргалама», «Ак күгәрчен», «Үткәннәрне онытырга кирәк», «Искән җилләр сөйли» һәм башка бик күп лирик-публицистик, лирик-интим шигырьләре моңа яхшы дәлил була алырлар иде. Шуңа өстәп республикабызның күренекле композиторлары тарафыннан көйгә салынган «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары», «Гөлмәрьям», «Газинур», «Әлли-бәлли», «Очрашу» кебек җырларын күрсәтеп үтү дә әле әйтелгән фикерне куәтли дип уйлыйм. Шулай да лирик һәм сатирик Г.Афзал хакында уйлаганда, яшьтәш шагыйрьләремнән берсенең күптән түгел генә әйткән сүзләре хәтергә килә. «Миңа, укучы һәм әдәбият кешесе буларак, сатирик Афзал кирәгрәк тә, якынрак та. Иҗатындагы һәр ике якның уңышларын инкарь итмәстән, шуны әйтәм: безнең әдәбиятта аның кебек сатирик юк диярлек, ә аның белән тигез яки аннан көчлерәк лирикларны бармакларны бөгеп санарга була...» Нигездә, төпле фикер бу. Ләкин шунысы бар: шәхеснең, шагыйрьнең объектив иҗади эволюция процессын теләү, кушу яки боеру белән генәкапыл үзгәртеп булмый. Инде сүз Г.Афзалның юмор-сатира өлкәсендәге эшчәнлеге турында икән, минемчә, соңгы еллардагы бу юнәлеш шигырьләре 50–60 нчы елларда иҗат ителгәннәреннән өстен түгел. Кемгә ничектер, минем өчен аның «Мыек борам», «Өф-өф итеп», «Кызыл балчык» артелендә», «Тотып җибәр, апаем» кебек әсәрләре соңгы елларда басылып чыккан «Бөркет», «Мине картайткан, йөзне саргайткан өч нәрсә», «Шомакойрык белән Сарытырнак диалогы», «Автор киңәш итми», «Кара песинең этлеге» исемле шигырьләренә караганда көчлерәк. Элегрәк язылганнарының көлдерү хасияте белән бергә мәгънәләре тирәнрәк, социаль яңгырашлары үткенрәк, көчлерәк иде. Мәгълүм нәрсә: көлүнең, сатираның объекты, гадәттә, конкрет, һәм шуңа да сатираның үсеше, шәхеснең талант дәрәҗәсе белән бергә, җәмгыятьнең, тормышның конкрет үсеш этапларына, күренешләренә һәм типларына бәйле. Тәвәккәл әбиләр, бригадир Ахуннар конкрет бер заманның типлары иделәр. Инде ул чорлар узды. Колхозлар үзгәртелде, кешеләре үзгәрде. Ләкин «һәр заманның була үзенә күрә сволочы (каһәр суккыры!)» дигәндәй, бүгенге көндә дә сатираның үткен угына бик лаек типлар бар. Андыйларны авыл җирендә дә, шәһәрдә дә табып була. Тик аларны таный белергә, иң характерлы, гыйбрәтле якларын тотып, җәмгыятьнең алга барышына комачаулаучы көч икәнлекләрен фаш итеп, көлдерә белергә кирәк. Ә аларның үзләрен, психология-гадәтләрен, мохит-җирлекләрен белмәгәндә, ничек фаш итмәк кирәк?! Бу – асылда, анык хакыйкать – тормышны тирән белүгә, өйрәнүгә кайтып кала. Бу безнең бөтенебезгә, шулай ук «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигәндәй, Г.Афзалга да карый.

Шагыйрьнең сатирасы һәм лирикасы турындагы фикерне түгәрәкләр алдыннан тагын шуны да әйтү кирәк булыр: лириканың һәм сатираның төп функциональ аермаларыннан тыш,

тәэсир итү формалары да шактый үзгә. Юмор-сатира гаять тиз тәэсир итүчән, чөнки сүз – конкрет, объект – конкрет, тасвирлау, сурәтләү чаралары – эффектлы, бай. Шуңа да уңышлы сатирик шигырь сәхнәдән яңгырауга, зал алкышларга, шаркылдап көлүләргә күмелә. Шигырь шартлый, бенгаль утлары кебек ахырынача янып бетә. Кабатлый башласаң, эффект югала, кими, тагын кабатласаң – тагын күбрәк кими... Бәлки, шуңардыр, авыл сәхнәләреннән бик күп яңгыраган «Ир бала яхшымы, кыз баламы?», «Тәвәккәл әби», «Әсмабикә җаным, ахирәт»ләр хәзер алай ук тәэсир итми. Чөнки күп тыңланган, күп ишетелгән. Ә менә лирик шигырьнең табигате башкачарак, үзгәрәк. Ул сәхнәдән дә бүтәнчәрәк кабул ителә: озаграк, салмаграк, ләззәте дә «күңелнең хис тартмачыкларына» туфракка сеңүче тамчылар кебек әкрен юл ала... Ни хикмәттер, шагыйрь йөрәгеннән чыккан җитди шигырьләр беркайчан да туйдырмыйлар, кабат укыган саен, алар сиңа нидер өсти, яңа кичерешләргә этәрә, яңа ассоциацияләр тудыра. Тукайның «И мөкатдәс моңлы сазым...» яки «Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата...» кебек юлларын инде уннарча кабат укыган булсаң да, һаман күңелнең иң нечкә кылларына кагылып тәэсир итү көчен югалтмыйлар. Г.Афзалның «Дөнья матур, дөнья киң», «Моң» кебек башка байтак җитди шигырьләре дә искерер өчен язылмаганнар шикелле.

Г.Афзал, үзе әйткәнчә, бәхетле кеше, бәхетле шагыйрь. Әдәбият мәйданына үз яшьтәшләреннән соңарып килсә дә, ул татар поэзиясенең күренекле иҗатчысы, халыкның популяр шагыйренә әверелде. Бу соңгы дистә еллар дәвамында үз репертуарларына Г.Афзал шигырьләрен яки җырларын кертмәгән татар сәхнәсе, мөгаен, юктыр. Китапларыңның куллардан кулларга, язганнарыңның күңелләрдән күңелләргә күчеп йөрүләрен тою – һәр иҗат кешесе өчен зур куаныч. Г.Афзал шул куанычка, шул бәхеткә ия шагыйрь.

Соңгы елларда шагыйрь нәрсәләр язды, хәзер нинди әсәрләр иҗат итә, дип сорарлар. Әлмәттә яшәү дәверендә, алты ел эчендә, ул унга якын шигырь китабы чыгарды. Күпсанлы лирик һәм сатирик шигырьләр белән беррәттән «Искән җилләр сөйли», «Сөембикә сылу», «Назыйм Хикмәт» кебек эпик пландагы озын шигырьләр иҗат итте. Үткән елда Г.Афзал чәчмәдә дә үзенең каләмен сынап карады. Унбиштән артык кечкенә күләмле сатирик хикәяләр язды. Язган берсен диярлек безгә – каләмдәшләренә күрсәтеп килә, җыелышып укыйбыз, кызыксындырырлык хикәяләр! Кайберләре инде «Чаян» журналында басылып та чыкты! Әйе, шагыйрь иҗат итә, үзен төрле жанрларда сынап карый.

Г.Афзалның 16 нчы амбар кенәгәсендә кыска гына бер шигыре бар. Ике юлы болай:

И Ходаем, хур итәргә теләмәсәң,
Шагыйрьләргә байлык бирмә, власть бирмә!

Әле моңарчы татар шагыйрьләренә байлык дигән афәтнең куркыныч булып килеп басканы юк, һәм, мөгаен, басмас та, – аннан бик вәсвәсәләнгән юк, минем курыкканым бүтән: берүк, Ходай, шагыйрьләргә тынычлану, битарафлык бирә күрмә, «классиклык чирен» йоктыра күрмә, күңелләренең илаһи пакь чагында язганнарына тугры итеп калдыр!

Шигырь булып туды әманәтем,
Шигырь булып чыкты хәсрәтем,
Матурлыкка – чиксез мәхәббәтем,
Явызлыкка – чиксез нәфрәтем! –

ди безнең Гамил.

Шагыйрь үсештә. Ә үскән саен, үрләр биегрәк. Алда дөнья кадәр эшләр тора! Галиябануларны (шагыйрьнең яңа туган кызының исеме) үстерәсе бар. Үскәч алар да «Дөнья матур, дөнья киң!» дип җырлый алсыннар өчен, ил тормышы – тыныч, имин, халык күңеле – көр һәм кешелекле, шигърият баскычы һәрчак гүзәл булсын һәм җимешле булсын өчен күп көч куеп бергәләшеп иҗат итәсе бар. Яңа уңышлар, яңа иҗади шатлыклар сиңа, шагыйрь дустыбыз Гамил Афзал!

*1970*

## *ОЛЫ ШАГЫЙРЬ, КИҢӘШЧЕ ШАГЫЙРЬ*

Чор. Шәхес. Шагыйрь. Шушы өч төшенчә торган саен ешрак уйландыра. Безнең эшнең асылын аңлау, иҗатчының иҗтимагый кыйммәтен бәяләү фәкать шушы төшенчәләр, алар арасындагы эчке бәйләнеш аша гына мөмкин. Әйе, хикмәт шушы бәйләнештә. Шуңа карап шагыйрьнең олылыгы, кешелеклелеге, батырлыгы, гражданлыгы беленә. Тумыштан талантлы кешеләр байтак. Шигырьгә дә сәләтле яшьләр, шөкер, килеп тора. Яхшы гына башлыйлар. Еллар үтә. Карыйсың, әйе, шомарган, чарланган, оста яза, ә әдәбиятта үз йөзе, үз эзе юк. Бу нидән? Баксаң, аның чорга, яшәешкә кеше буларак үз ачык мөнәсәбәте, үз иҗади платформасы юк икән, язганында үз шәхесе, үз гражданин «мин»е юк икән. Аның иҗат итүе, тырышуы табигый булган беркадәр сәләтен ничектер эффектлырак итеп, үзен ничек тә даһилык чалымнары булган берәү итеп күрсәтергә генә тырышу икән! Бәхеткә каршы, бездә очраклы хәл һәм очраклы күренеш бу. Шагыйрьләр полкында, өлкәннәр арасыннан булсын, яшьрәкләр арасыннан булсын, чын мәгънәсендә талантлы, чорны аңлап, илнең шатлык-кайгылары белән яшәүче, үз фикере, үз сүзе булган, җанындагын яшерми-нитми кешеләр белән уртаклаша алучы гражданин шагыйрьләр байтак, һәрхәлдә, алар төп көч, шигъриятнең үсеш юнәлешен билгеләүче намуслы көч. Бу – Тукай, Җәлилләрдән килә торган традиция. Ә традиция үзеннән-үзе генә дәвам итми, үзеннән-үзе генә үсми. Аның үсеше өчен дә көрәшергә, даулашырга кирәк. Бу көннәрдә – татар совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләреннән берсе Сибгат Хәкимнең иҗат бәйрәме көннәрендә – әнә шулар турында уйландым мин. Аның шигырь, поэмаларын тагын бер кат карап чыктым. Кулда булган публицистик язмаларын күздән кичердем. Әйе, олы шагыйрь безнең Сибгат агабыз, зур шәхес, үткәне, бүгенгесе, киләчәге бар әдип. Бүгенге поэзиябез гөмбәзен тотып торучы бер мәрмәр колонна-баганага тиңләргә мөмкин аның иҗатын. Традицияләр үсешенең яхшы үрнәкләре аңарда. Шагыйрь һәм шәхес буларак аның әдәбиятта абруе, хакимлеге зур. Шәкертләре күп. Әгәр безнең урта һәм яшь буын шагыйрьләре чор турында, шагыйрь турында, аның җәмгыятьтәге урыны турында җитди уйланалар, һәм бу уйланулар аларның иҗатларында чагыла икән, монда өлкән шагыйребез Сибгат ага шәхесенең, аның иҗатының шифалы йогынтысы аз түгел.

Сибгат Хәкимнең татар поэзиясендә, киңрәк итеп алганда, халыкның рухи тормышында тоткан урыны һәркемгә ачык, билгеле хакыйкать. Татар совет поэзиясенең сугыштан соңгы үсеш юлларын өйрәнүче һәр әдәбият белгече аның иҗатына мөрәҗәгать итми кала алмый. Сибгат Хәким иҗаты турында диссертацияләр, байтак диплом эшләре язылган, мәкаләләр, иҗади портретлар тудырылган, алар алга таба да булырлар. Әлбәттә, иҗатының төп асыл сыйфатларын калкурак күрсәтә торганнары, шагыйрьнең иҗат лабораториясе серләрен ачарак төшә торганнары күбрәк булыр. Миңа шагыйрьнең бу юбилей алды көннәрендә, аның турындагы гыйльми хезмәтләрдән бигрәк, шагыйрьләрнең аңа багышлап язылган шигырьләрен күздән кичерергә туры килде. Кызык, кемнәр генә аңа багышлап язмаган! Х.Туфан, Н.Арсланов, Н.Дәүли, Н.Нәҗми, Г.Афзал, Х.Камал, Ә.Баян, С.Сөләйманова, Р.Гәрәй... Боларга күпсанлы яшь һәм башлап язучы шагыйрьләрнең дә Сибгат Хәкимгә багышланган язмаларын өстәсәң, аның үзенең самими җырларын, шигырьләрен укып, тыңлап моң һәм дәрт алган бихисап күп укучыларның аңа карата булган рәхмәт сүзләрен җыйсаң, тулы бер китап, антология килеп чыгар иде. Юк, бу заказ биреп яки кушып яздыру түгел, – күңелгә боерып булмый. Бу – халыкның үз улына, үз җырчысына табигый мәхәббәте. Бу – ил мәхәббәте.

Сибгат Хәким яшь һәм башлап язучы шагыйрьләргә иң якын торган өлкән шагыйрь. Бу бүтән аксакал шагыйрьләр яшьләр белән якын мөнәсәбәттә түгел икән дигән сүз түгел. (Киресенчә, әгәр бүгенге поэзиябезнең кайбер уңышлары бар икән, ул, һичшиксез, төрле буын шагыйрьләренең органик дуслыгына бәйләнгән.) Үзләренең бай тәҗрибәләрен һәрчак уртаклашырга, киңәш бирергә, булышырга әзер киң күңелле шагыйрь әдипләребез бар. Ләкин шулар арасында Сибгат ага аерым урын тота. Соңгы ун-унбиш ел эчендә әдәбиятка килеп, Сибгат аганың булышлыгына һәм ярдәменә юлыкмаган берәр талантлы шагыйрь бармы икән? Мөгаен, юктыр. Чын дуслык араларның тигезлеген ярата, үзара мөнәсәбәтләрнең тугрылыгына нигезләнә. Әгәр С.Хәким үзенең иҗаты һәм кылган игелекле эшләре белән яшьләр иҗатына уңай тәэсир итә икән, үз чиратында яшьләр дә өлкән шагыйрьне яшәртәләр, иҗатына дәрт һәм яшьлек өстиләр кебек миңа. Чөнки С.Хәким һәрчак яшь талантларның үзәгендә, ул бүгенге Тукайларны эзли; шуңа да сәләтле каләм ияләренең баштагы иҗатлары

бөтенләе белән диярлек Сибгат ага аша уза. Ә инде нурлы һәм мәгънәле шигырь синең күңелең аша үтә икән, ул сине зурайтмыйча, баетмыйча кала алмый.

Соңгы җиде-сигез ел эчендә әдәби хәрәкәткә беркадәр катнашып килү миңа бер хакыйкатьне танытты. «Бу халыклар аралашкан зур чор»да, һәр кешенең җәмгыять алдында тау кадәр җаваплылыгы булган заманда, шагыйрьне чын-чыннан аңлау өчен шигырен уку гына җитми, аның үзен, шәхесен дә белергә кирәк, көндәлек иҗтимагый эшләренә дә шаһит булу кирәк икән. Яшермим, унсигез-унтугыз яшьлек студент вакытта минем С.Хәким шигырьләренә мөнәсәбәтем бераз үзгәрәк иде. Миңа аның шигырьләре артык басынкы, моңлы, артык гади тоела иде. «Англиягә барып кайт син, диләр» шигыре аңлашылмаган каршылыклы сәер тойгылар уяткан иде... Әгәр ун елдан соң әдипнең иҗатына карата фикерләр үзгәргән икән, гаҗәп түгел, һәм шул ук вакытта мин иртә яшьлегемдәге әлеге халәтемнән, уйларымнан да баш тартырга яки ялгышканмын икән дип әйтергә дә җыенмыйм. Яшьлекнең үз логикасы. Әдәбиятка ашкынган яшь җанның теләге аңлашыла. 60 нчы еллар башында совет әдәбиятын яңа үрләргә күтәргән төрле миллләт язучылары Ч.Айтматов, Р.Гамзатов, Э.Межелайтислар бөтен дөньяга яңгырап алганда, күп гасырлык традициясе булган татар әдәбияты вәкилләрен дә шулар рәтендә күрәсе килүдән, исән татар шагыйрьләренең дә авазлары Җәлилләрнеке кебек бөтен дөньяга яңгырауларын ишетәсе килүдән уянган хисләр алар. С.Хәкимнәрне дә Англияләрдә йөртеп кайтарасы килүдән туган хис, бүтән халыкларны да баета торган яхшыны, гүзәллекне күбрәк таратасы килүдән туган хисләр иде... Хәзер исә С.Хәкимне иң алдынгы һәм күренекле совет язучыларының берсе дип саныйм. Моны мин аның бай иҗатын, көндәлек әдәби тормыштагы эшләрен, халык күңеленә йогынты ясау дәрәҗәсен – барысын күз алдында тотып әйтәм. Безнең һәрберебездә гүзәллекне тагын да күбрәк күрергә теләү хисе яши. Бу нәфес эше генә түгел, бу – табигый хис. Ләкин һәр үрнең, биеклекнең чиге бар. Бу рухи тормышта да шулай. С.Хәким биеклеге – халыкның рухи биеклеге дәрәҗәсендә. Ә безнең халыкның рухи биеклеге – югары биеклек.

Сибгат Хәким иҗаты соңгы елларда тагын да күтәрелебрәк, шәбәебрәк, күпкырлырак булып китте. Бу хәл – ил-йортның сау-имин торуының, тормышыбызның көннән-көн ямьлерәк, баерак була баруының, әдәбиятыбызның һаман өскәрәк үрләве һәм аның өметле киләчәге булуының, ниһаять, шагыйрьнең үзенең тәмам зур оста булып җитешүенең, эшенең, хезмәтенең бөтен ил күләмендә тәкъдир ителүенең һәм тагын күп факторларның уңай нәтиҗәсе. Сибгат ага шигъриятенең офыклары киңәю белән бергә, аның публицистикасы да үткенрәк һәм куәтлерәк була башлады. Әдәби хәрәкәт яки каләмдәшләре хакында язган мәкаләләре, чыгышлары, истәлекләре торган саен мәгънәлерәк, кирәгрәк һәм әдәбият өчен зарури ихтыяҗлы була баралар. Әле яңа гына басылган С.Хәкимнең «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле истәлек-язмаларын дулкынланып укып чыктым. Ул шигырь дә, сагыш та, сафлык та, кисәтү дә...

С.Хәким үзенең бөтен вөҗүде белән Тукайга бәйле шагыйрь. Туган ягы белән дә, иҗаты белән дә. Ул шагыйрь турында заманында «Шагыйрьнең балачагы», «Пар ат» исемле поэмалар язган булса, хәзер исә бөек шагыйрьнең Казанда яшәгән чорын тасвирлаган яңа зур әсәр тәмамлады. Әгәр «Татар поэзиясендә Тукай традицияләрен кемнәр дәвам иттерә?» дип сорасалар, һич икеләнмичә, беренче итеп С.Хәким исемен атар идем. Әгәр Тукай үзе хакында «Мин... коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин – дипломат, политик, җәмәгать эшлеклесе дә бит...» дигән булса, шагыйрь С.Хәким турында да шушы ук сүзләрне әйтергә мөмкин.

...Иртәнчәк яки кичкырын Казанның үзәгендә – Ирек мәйданы, Ленин бакчалары тирәләрендә – урта буйлы, башын үзенә генә хас бер горурлык белән югары тотып, салмак кына атлаучы шагыйрьне очратырга мөмкин. Ул уйланып йөри. Ә шагыйрь өчен уйланыр нәрсәләр күп. Бәлкем, беренче күргән кешегә ул йомшак табигатьле, басынкы, сабыр, хәтта беркадәр юаш кебек күренергә дә мөмкин. Ә асылда, һич юаш, йомшак түгел, иң дөресе – нык ул, усал ул безнең Сибгат ага! Ул гаделсезлеккә, хаксызлыкка усал, халык күңелен олыламаучыларга усал. Әдәбиятны кәсеп итеп карауучы халтурщиклар моны белеп торсын. Сабыйларча саф күңелле кешегә, нечкә күңелле шагыйрьгә, икмәкнең һәм тирнең ни икәнен бик яхшы белгән җир кешесенә, солдатка, җәмәгать эшлеклесенә, кирәк чакта, чак кына усал булу килешә ул. Хаклыкны эченә җыеп та, эндәшмичә, йомыкый яшәүче йомшак кешеләргә караганда, үз хәлеңчә хакыйкать сагында торучы гадел усал кешеләр күбрәк кирәк бу тормышта.

*1977*

## ОЧРАШУЛАР

Һай, гомер! Бу Шәриф Хөсәенов дигәннәрен дә егерме биш еллап беләм икән ләбаса! Акча алыштырган саен бәрәкәтсезләнә барган шикелле, еллар торган саен җитезрәк йөгерәләр, йөгерәләр генә түгел – очалар! Әле моны яше кырыкка да җитмәгән кеше әйтә: ә җитмешкә, сиксәнгә җиткәннәр ни генә уйламыйлардыр... 50 нче еллар урталары иде бугай, Казанда «Профессор кияве» дигән спектакль куйганнар дигән хәбәр безнең якларга да килеп ишетелде. Башкалага барып, спектакльне күреп кайткан берәр укымышлырак кеше әйттеме, әллә укытучыларның берәрсеннән ишеттемме, әллә радиодан өзек-мазар тыңлап истә калганмы, – хәтерләмим. Ни генә, ничек кенә булса да, безнең үсмер колакларга да килеп җитте бу хәбәр! Дөресен әйтим, спектакль, бу очракта пьеса үзе әсәр буларак ул кадәр үк кызыксындырмады, ә менә исеме! – анысы инде шаккатырды. Кияү дигәнен беләбез, анысын өй-урам тирәсендә көненә йөз ишетәсең, ә менә «профессор»ны күрү түгел, ишеткән дә бик сирәк. Киноларда йә бик хикмәтле русча китапларда гына. Менә бит дөньяда ниләр бар! Казанда «Профессор кияве» дигән татарча спектакль куелган, ди бит. Нишлиләр икән ул профессорлар? Ничегрәк итеп сөйләшәләр икән? Профессор хәтле профессорлар турында язган кеше үзе кем икән? Тизрәк мәктәпне тәмамлыйсы иде дә, авыл читендәге үр юлларны үтеп, киңрәк дөньяга чыгасы иде! Бәлки, ул зур дөньяларны да күрербез әле!.. Шәриф Хөсәенов дигән исем миңа әнә шулай унике-унөч яшьләрдә бераз серле, әмма зур һәм якты, хыялларны үстереп җибәрә торган исем булып хәтергә сеңеп калды.

Шуннан соң үткән егерме елдан артык вакыт эчендә чын профессорларны, әйтергә кирәк, төрле дәрәҗәдәгеләрен, байтак күрергә туры килсә дә, малай чакта күңелне кытыклаган «Профессор кияве» спектаклен тәки карарга туры килмәде. Соңрак пьеса кайта-кайта укылды, билгеле. «Төзәтелергә тиеш спектакль», «Спектакль төзәтелгәч» дигән сәеррәк исемле рецензияләр белән дә танышылды. Заманында Татарстанда, шулай ук тугандаш халык сәхнәләрендә зур уңыш белән барган бу пьесаның яше белән егермедән әз генә өстә булган студент, медицина институты студенты тарафыннан язылганын ул чакта белгән булсам, ихтимал, гаҗәпләнү һәм соклануым тагын да арткан булыр иде. Хәер, бу тойгының хәзер дә кимегәне юк. Татар дәүләт академия театры кебек зур сәхнәдә шулай яшьли пьеса куйдыра алган бүтән авторны мин белмим.

Бу исем белән икенче тапкыр очрашу көтмәгәндәрәк булды. Кайда дисезме? «Татар халык мәкальләре» дигән китапта очраттым мин бу Шәриф Хөсәенов дигән исемне. Күпләрнең хәтерендәдер: халык телендә бик хаклы рәвештә академик саналган Нәкый Исәнбәтнең 1959 елны мәдәниятебез тарихында сөенечле вакыйга булып «Татар халык мәкальләре» дигән фундаменталь хезмәтенең беренче томы басылып чыкты. Кереш сүзенең бер җирендә Нәкый ага болай дип яза: «Язучы Шәриф Хөсәеновның Буа районыннан җыйган бер мең чамасы мәкаль һәм әйтемнәре дә... шушы томга керәләр... Аңа рәхмәт белдерүне бурычым дип санаймн». Бу юлларны укыгач, бу кешегә, табигый, ихтирамым бермә-бер артты, бу исем үзем өчен тормышта үрнәк алырга лаек дип санаган исемнәр рәтенә күчте. Шул ук вакытта – инде әзрәк каләм тибрәтә башлаган чак – бу исә яхшы мәгънәдә көнләштерде дә. Бар бит кешеләр! Үзе медик, үзе драматург, үзе халык иҗатын җыйган фольклорчы. Ә без?.. Эшләргә! Тырышыбрак, көч-дәртне җыя төшебрәк эшләргә!

Очрашуның нәүбәттәгесе тагын бер ел үткәч булды. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы 1960 елда үзенең 4, 5, 6 нчы саннарында Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» повестен бастырып чыгарды. Бик күп әдәбият сөючеләр өчен бәйрәм китергән әсәр булды ул. Дөрес, кемнәргәдер ул ошап та бетмәде бугай, тәнкыйтьләүчеләр дә табылды, повесть аерым китап булып биш-алты ел үткәч кенә чыга алды... Нишлисең, әдәбиятта булгалый андый хәлләр. Әмма Матбугат йорты тирәсендәге агай-эне ничек кенә бәяләмәсен, укучы үлеп яратты бу повестьны. Авылда булсын, шәһәрдә булсын, әле үз теле белән исәп-хисапны өзеп бетермәгән зыялы һәр татар укучысы укып чыккандыр. Күңелне чистарта

торган нәзакәтле әсәр ул «Мәхәббәт сагышы»! Мәхәббәт-сөю хисен татыган һәр яшь кеше Хәбир белән Мәдинә мисалында күпмедер дәрәҗәдә үзен күрде, үз кичерешләрен таныды. Хикмәт повесть каһарманнарының кемнәр һәм вакыйгаларның кайда, ничек баруында гына түгел, хикмәт мәгълүм бер чор, әйтик, 50 нче еллар яшьләренең рухын ачуда, күңел тибрәнешләренең тәңгәллеген сиздерүдә, уртак кылда уйный алуда! Өстәвенә гаҗәп халыкчан тел белән затлы стильдә язылган бу әсәр. Шул елларда, икенче кат укыганда булса кирәк, повестьтан үземә ошаган байтак җөмләләрне аерым бер дәфтәргә язып куйганмын. Хәзер укып карыйм да, бик дөрес эшләгәнмен, дип куям. Чөнки алар хәзер дә дулкынландыра. «Казан урамнары нинди кыска!» (сөйгән ярны тиз генә өйләренә кертәсе килмәүне кайсыбыз гына кичермәгән!); «Күңелләр мөлдерәп тулган, сүзләр иреннәргә бал булып сыланган»; «Мәдинәләр өендә берәү дә кычкырып еламый» (безнең халыкның рухи халәтен күрсәткән бер сыйфат түгелме соң бу?!); «Аягың аксаса, таякка таянырсың, күзләрең күрми башласа, күзлек киярсең, сусасаң, су эчәрсең, арысаң, утырып ял итәрсең, ятып йокларсың... Мәхәббәтең сүрелә башласа, нишләрсең?»; «Ләкин бу гасыр, фәннең һәр казанышын, даһилыкның һәр чагылышын җимерү өчен генә файдаланырга исәп итүче кешеләре дә булган бу замана – сәнгать заманымы соң?»; «Бу рәхәтлек болай да мөлдерәп тулган. Аның бөтен татлылыгын тою өчен дәшмәү кирәк»...

«Мәхәббәт сагышы» белән мин 1967 елның көзендә тагын бер мәртәбә көтмәгәндә очраштым. Куйбышев шәһәрендә хезмәт иткәндә, солдат казармаларының берсендә бер татар егете «Мәхәббәт сагышы» дигән китаптан ниндидер сүзләрне, ниндидер җөмләләрне үзенең куен дәфтәренә күчереп утыра иде. Шулчак үземне үзгә бер шатлыклы хис чорнап алган иде. Менә бит ул – дөньяның җандаш кемнәре юк дисең! Ул көнне полкның шактый ук шыксыз ишегалды да хәйран гына матур булып күренгән иде...

Еллар үтте. Очрашулар ешая төште. Очрашу шул: бер-бер артлы (дүрт-биш ел ара калдырып булса да) Шәриф Хөсәеновның ике пьесасы сәхнәдә куелды. Хәзерге татар драматургиясенең асыл әсәрләреннән саналырга лаек ул әсәрләр – «Зөбәйдә – адәм баласы» һәм «Әни килде». Бу әсәрләр җәмәгатьчелеккә киң мәгълүм әсәрләр, алар турында күп сөйләнгән, күп язылган, халыкның ихтирам мөһере сугылган... Зөбәйдә образын иҗат иткән Наилә Гәрәева һаман күз алдында, Галимә ханым Ибраһимова башкаруындагы Ана мәңге онытылмаслык. Тамашачыны уйландырды ул спектакльләр, урыны-урыны белән сискәндерде, оялтты, искәртте, өндәде, кече күңелле һәм олы җанлы булырга чакырды. Бу әсәрләр заманның төп проблемаларыннан берсе булган әхлакый тәрбия эшендә шактый ук игелек күрсәткән булып чыктылар. Шуңа күрә булса кирәк, аларны илебезнең төрле почмакларында байтак театрлар бик теләп һәм яратып сәхнәләштерде. Шәриф Хөсәенов әсәрләренең үзенә тарта торган тагын бер күркәм ягы бар: аның пьесасындагы персонажлар – катнашучылар диикме – табигый мохиттә, табигый ситуациядә, табигый халәттә сөйләшәләр, хәрәкәт итәләр, яшиләр. Әсәрнең халыкчанлыгын билгеләүче төп сыйфатларның берсе түгелме соң бу? Тормышыбыздагы гомумиләштерүне «сорап торган» вакыйга-хәлләрне һәм типик характерларны «тотып» алып, аларны ышандырырлык рәвештә халыкчан телдә бәян итү өчен, әлбәттә, чынбарлыгыбызны тирәнтен белү, үткен күзле һәм зирәк акыллы булу шарт. Гомумән, сәнгатьтә табигый була алу инде талантка, осталыкка, хикмәткә ия булу галәмәте. Еш кына фикерле генә драматургларыбызның әсәрләренә нәкъ шул табигыйлек җитенкерәми дә. Кайбер спектакльләрдәге геройлар, әйтик, җыештыручы апайлар, каравылчы агайлар, балта осталары рәхәтләнеп сәхнәдә язучының үз лексиконы белән сөйләшәләр. Шулкадәр оста һәм дөрес, фәнни итеп сөйләшәләр ки, инде ахырга таба тәмам ышанмый башлыйсың. Тимерче агайга дирижер фрагын кидерткән шикелле килеп чыга... Бу яктан, шөкер, Шәриф Хөсәенов әсәрләренә тел-теш тидерерлек түгел. Соңгы елларда Казан телевидениесеннән еш кына тапшырыла торган «Генеральная уборка» спектаклен генә искә төшерегез, персонажларның сөйләм телләренә игътибар итегез. Никадәр тормыш дөреслеге аларда!

Язмыш, һәр теләгәнне кулыңа китереп тоттырмаган кебек, күңел сусаган һәр очрашуны да гел насыйп итеп тормый. Шәриф Хөсәенов иҗаты белән очрашулар да шулайрак. Кайчак еллар буе бу исем матбугат битләрендә күренми. Юксына башлыйсың. Шулай да ул, рәхмәт төшкере, бөтенләй үк югалып бетми: йә берәр журнал битендә берәр хикәя, йә үзе хөрмәт иткән берәр сәнгать остасы турында язма бастырып куя... Быел яз башында иде бугай, аның белән тагын бер мәгънәле очрашу булып алды. Бусы эфир аша. Күренекле җырчыбыз Мәрьям

ханым Рахманкуловага багышланган борынгы җырлар белән бергә үрелеп, әңгәмә рәвешендә барган бу радиотапшыруының авторы Шәриф Хөсәенов иде. Тапшырулар шактый күп булып торган кебек, тапшыру-сценарий авторлары да байтак булырга мөмкин. Шуңа күрә тапшыру авторы булу факты әле әллә ни гайре табигый нәрсә түгел. Нинди тапшыру бит! Шунда хикмәт! Зур җырчының иҗаты нисбәтендә халкыбызның җыр сәнгате, тарихы һәм үсү перспективалары турында югары дәрәҗәдәге тирән анализлы, уйландыра торган зур сөйләшү иде ул. Мәрьям ханым башкаруындагы «Кызыл төлке» кебек шедевр җырлар белән беррәттән авторның җырларны комментарияләү рәвешендә сөйләве, ягымлы һәм хөр авазы хәзер дә колак төбендә, һәр сүздә, һәр фразада, һәр җөмләдә авторның җырны, көйне тирән белүе, музыкада зур мәгълүматка ия булуы сизелеп тора иде. Күбрәк музыкаль терминнар белән эш итәргә яратучы кайбер музыка белгечләре бер кырыйда торсын!.. Быел җәй көне матбугат битләрендә Шәриф Хөсәенов исеме тагын бер күренеп алды. ТАССР Верховный Советы Указы белән аңа «Татарстанның атказанган врачы» дигән мактаулы исем бирү хәбәре чыкты. Бусы үзе менә дигән очрашу бит инде! Медик булып, бигрәк тә язучы булып тарихта калган Чеховлар, Вересаевлар искә төште. Шул ук вакытта уйланырга да мәҗбүр итте бу хәбәр. Хәзер безнең әдәбиятта бер үк төрле биографияле (гадәттә, мәктәп – филологик профильдәге вуз – газета-журнал редакцияләре), бер үк почерклы стереотип яшь язучылар шактый күбәеп китте... Бер үк ысул белән эшкәртелгән, бер үк төрле орлык чәчелгән җирдән бертөрле уңыш чыгуы бер дә гаҗәп түгел. Ә тормыш бит үзе гаҗәп күпкырлы! Тормышның көзгесе – әдәбиятка килү һәм игелек күрсәтү юллары да күптөрле бит. Әйтик, Шәриф Хөсәенов мисалы шуны күрсәтмимени? Хәер, бер ул гынамы соң? Әдәбиятта андый мисаллар бер дә юк түгел: комиссар Шамил Усманов, очучы Салих Баттал, галим-химик Җәвад Тәрҗеманов, галим-ветеринар Атилла Расих, диңгезче Миргазиян Юныс...

Сүземнең ахырында өстәп шуны гына әйтәсе килә: мин Шәриф Хөсәеновның үзен күреп белмим диярлек. Инде егерме елдан артык әдәби мохиттә азмы-күпме катнашып килүче буларак, мин бөтен исән язучылар белән беркадәр аралашкан кеше. Ә менә Шәриф Хөсәенов белән аралашырга туры килмәде. Дөрес, аны берничә мәртәбә ачалак-йомалак күреп тә калганым бар... Хәтта бик озын өстәлле бер мәҗлестә бер түбә астында утырдык та шикелле. Әмма ул кеше белән махсус беркайчан да очрашканым булмады. Шулай да менә инде чирек гасыр мин аның белән, аның иҗаты белән очрашып, һәр очрашуга куанып яшим. Иҗади очрашудан, уй-хисләр уртак булып кушылып китә алудан да зуррак очрашу мөмкинме соң!

*1979*

## *АК РОЯЛЬ ХУҖАСЫ*

Җиһанның Нәҗип ага Җиһансыз яшәвенә дә инде ике ел ярым вакыт узды. Исән булса, олуг шәхесләребезнең берсе буларак, аның 80 еллык юбилее зуррак һәм тантаналырак рәвештә узар иде. Дөрес, бу дата җәмәгатьчелек тарафыннан болай да киң билгеләнеп үтелә. Шулай тиеш. Әле узган декабрь аенда гына Салих Сәйдәшевнең 90 еллыгы гөрләп узды. Бер кыш эчендә ике мәшһүр, – хәтта бөек дип әйтүдән дә курыкмаскадыр, – композиторыбызның юбилей даталары. Төптәнрәк уйлап карасаң, гыйбрәтле һәм сөенечле хәл бит бу! Йә, кайсы халыкның, бигрәк тә төркиләрнең, шулай янәшәләтеп дигәндәй, зурлап яд итәрлек, бәйрәм итәрлек олуг композиторлары бар икән? Ихтимал, шул чордан болар рәтенә әзәрләрнең (азәрбайҗаннарның) Гөзәер Хаҗибәковны («Аршин мал алан» операсы авторы) гына куеп буладыр...

Һәрбер юбилей иясе нинди өлкәдә хезмәт итсә беренче чиратта табигый, аның иҗат бәйрәме шул өлкәнең, шул даирәнең бәйрәме булып уза. Әгәр хезмәте, иҗаты үзеннән соң килгән буыннарны да дулкынландыра, рухландыра икән, ул юбилей инде гомумхалык бәйрәменә әверелә. Бу очракта да шулай булды. Сәйдәшев һәм Җиһанов юбилейлары уңае белән без яңадан 50–60 нчы елда узылган музыка дөньябызга экскурс ясадык. Байтак мәкалә-истәлекләр укыдык, көйләре, җырлары белән бергә замандашларының хатирәләрен тыңладык, яңа мәгълүматларга ия булдык. Горурландык, кайчакта офтандык та... Үткәннәрне үзебезчә анализлап, киләчәккә барыр юлларны дөресрәк билгеләргә тырыштык. Мәрхүмнәргә дан да,

мал да кирәкми. (Нәҗип Җиһановның үлү хәбәрен мин 1988 елның 4 июнендә Башкортстанның Мәләвез каласында ишеттем. Безгә, әдәбият-сәнгать көннәрендә катнашучыларга, бу кайгылы хәбәрне Татарстан партия өлкә комитеты секретаре Наил Кадермәтов җиткергән иде. Ул да инде (әле яшь иде) ике ел элек гүр иясе булды. Кабере – Нәҗип аганыкыннан биш-алты адым ераклыкта гына.) Аларның дөньялыкта калдырган гамәлләре исәннәр хөкемендә.

Юбилейларга әзерлек чоры кампаниясендә – матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында, аерым җыелышларда – татар музыкасы өчен горурлык уяткан тойгылар белән бергә, беркадәр ризасызлык кузгатырлык сәбәпләр дә булмады түгел. Шуларның берсе – иң рәнҗеткәне: кайберәүләрнең бу ике бөек композиторны бер-берсенә каршы куярга теләве, берсен күтәребрәк, икенчесен төшеребрәк күрсәтергә тырышуы. (Татар әдәбияты тарихында булып узды андый хәлләр! Тукайны – Дәрдемәндкә, Ибраһимовны – Исхакыйга, Такташны Кутуйга... каршы куеп сөйләшүләр. Вакытлар узгач, һәммәсенең үз урыны табыла, асыл бәясе бирелә барды.) Бу акыллы караш түгел, милләт алга барсынга эшләнә торган юл да түгел. Зирәк халык һәр зур талантның, һәр зур иҗатчының (алар сирәк туа!) уңай ягын әләм итеп күтәрә, аны көч санап, үзенең рухын көчәйтә, үзаңын арттыра... Әлбәттә, бер адәм дә, шул исәптән зур иҗатчы да, фәрештә була алмый. Берәү дә хатадан хали түгел.

Бер шагыйрь әйтмешли:

Беләсең:
Бик тигез салмадык эзне дә.
Без дә бит бу Җирнең баласы,
еллар сагынып безне дә!

Мин шәхсән үзем Нәҗип ага белән шактыйдан ук таныш булып, соңгы ун-унбиш ел эчендә дустанә аралашып яшәдем дип әйтә алам. Үз вакытында аның тормышы һәм иҗаты турында бер әдәби хезмәт тә язарга исәбем бар иде. Ул үзе дә бу ниятемне белә иде. Шуңа күрә өендәме, эшендәме яки берәр бүтән җирдәме аның белән еш кына очрашырга туры килде. Ул үзе дә бу очрашып-күрешүләргә бик тә разый иде шикелле. Атна-ун көн күрешми торсак, «Нигә югалдың әле?» дип, өйгә дә шылтыраткалый иде. Күрәсең, миңа ышаныч күрсәтеп, эше, иҗаты, тормыш рәвеше турында күбрәк белүемне теләгәндер, мәрхүм. Шәхси архивының байтак өлешен бергәләп актарып чыгарга да вакыт тапкан идек. Ул мине иҗатын аңларга сәләтле дип уйлаганмы (ә болай музыканы аңлавым чамалы), фикердәше дип таныганмы, тәгаен белмим, әмма аталарча якын итүен сизә идем. Күңел булсын диптер инде, шигырьләремне дә мактап куйгалый иде. Ихлас әйтүе дә бар: бу хакта шулай сөйләгәннәрен кешеләр аша да ишеткәләдем. Шулай «ахири» булсак та, без уртак бер генә көй дә, бер генә җыр да язмадык. Мин тәкъдим итмәдем, ул сорамады...

**Нык ихтыярлы максатчан шәхес.** Күңелеңдә нинди зат булып калды дисәләр, тагын шул ук сүзләрне кабатлар идем: нык ихтыярлы максатчан шәхес. Әгәр шул сыйфатлары булмаса, ул тау кадәр хезмәт калдыра да алмас иде. Андыйлар турында кала интеллигенты – «титан!», ә авыл агае «эш аты!» дип әйтер иде. Хезмәт җитештерүчәнлеге дигән производство терминын куллансак, бу яктан татар музыкасында бүтән андый кеше юк (әдәбиятта – Н.Исәнбәт, рәссамнар дөньясында Б.Урманче белән тиңләп булса гына). Хезмәтләренең тау сырты кебек күренеп торганнарын гына санап узыйк: сигез опера, унҗиде симфония, өч балет (һәрберсенең партитураларын гына язып чыгар өчен айлар, еллар кирәк!), берничә симфоник поэма һәм кантата, дистәләгән вокаль-инструменталь әсәрләр, җырлар... Эстетик байлык күләм белән бәяләнмәсә дә, чагыштыру өчен әйтеп узыйк: мәшһүр Д.Шостаковичның опера һәм симфонияләр саны күпкә кимрәк.

Дөресен әйтим, кайчак язгы ташулар аккан кояшлы көннәрдә яки ямьле җәй сәгатьләрендә аны һаман саен ак рояле артында утыруын күреп, кызганып, җәлләп тә куя идем. Бу кадәр эшләп бер дә дөнья рәхәтен күрми, ахры, бу абзый! Бәлки, ялгышамдыр. Ул, әлбәттә, эшеннән, нәтиҗәсеннән, җиңүеннән, данынннан һәм хезмәте китергән тагын әллә нәрсәләрдән тәм һәм ләззәт алгандыр. Ә шулай да...

Шундый бер тәгъбир бар: җирдә теге яки бу миссияне башкару өчен, Ходай миң-тамга салган кешеләр була, имеш. Нәҗип агага күктән, белмим, ниләр иңдерелгән булгандыр, әмма татар музыкасының соңгы ярты гасырлык язмышында аның миссиясе гаять зур. Музыка дөньябызда этап булырлык төп тарихи вакыйгалар аның исеме, аның иҗаты белән берегеп калган. 1939 елда яңа оештырылган опера һәм балет театры Н.Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла, соңрак – Татарстан дәүләт филармониясе үзенең беренче эшен Җиһанов әсәре белән башлап җибәрә. 40 нчы елларда Татарстан Композиторлар берлеген оештыруда ул башлап йөрүче була, Берлек барлыкка килгәч, утыз елга якын аны җитәкли. Казанда консерватория ачылу көненнән башлап (1945) гомеренең соңына кадәр (1988) ул аның ректоры иде...

Ялгышмасам, татар композиторлары даирәсеннән профессор исемен йөрткән беренче кеше дә Җиһанов булды шикелле. СССР халык артисты. Өч тапкыр СССР Дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Татар әдәбияты һәм сәнгате дөньясында Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән беренче карлыгач... Беренче, башлап йөрүче, тәүге... Гел иң беренче... «Ах, беренче зөфаф кичәсе!» дигәндәй, һаман-һаман беренче булу, мөгаен, күңелне гел котырта, нәфселәндерә, ярсытадыр... Хәер, иҗат бәйгесендә кемнең койрыкта сөйрәләсе килсен икән. Әмма беренчелек ул – горизонталь яссылыктан бигрәк, вертикаль биеклек төшенчәсен дә үз эченә ала. Болытларга тиеп торган биек тауларның очына якынайган саен, җилләр көчлерәк һәм суыграк. Югары дәрәҗәгә ирешкән саен, җаваплылык хисе арифметик кына түгел, геометрик прогрессиядә арта гына. Андый кешенең ялгышы да, кояшлы көндә тау өстендәге кешенең күләгәсе ерак-еракларга төшкән шикелле, күпләргә кагылып үтә...

Әйе, Нәҗип Җиһанов – кабатланмас зур шәхес. Иш ише белән дигәндәй, Бакый ага Урманче да аны, якын итеп: «Безнең Нәҗип! Безнең Җиһан!» – дип әйтергә ярата иде (сүз уңаеннан әйтеп узыйм: миңа калса, аның иң уңышлы портретын да Бакый ага иҗат итте). Йолдыз белән йолдыз, таулар белән таулар сөйләшә, диләр. Тауларның калкулыклар, түмгәкләр белән үз мөнәсәбәте булуы табигый. Һәр биеклекнең үз хакыйкате. Мондый табигый хәлне табигый рәвештә, шулай булырга тиеш дип кабул итәргә кирәктер.

Нәҗип аганы да музыка дөньясына әзме-күпме катнашы булган һәр кеше олуг, бөек дип кабул иттеме соң? Һич юк! Яшәве дәверендә аны яратмаган, аңа каршы кешеләр дә байтак булды, һәм алар хәзер дә җитәрлек. Аларның да үз дөреслекләрен расларлык дәлилләре бар. Чыбык озын булган саен, очы нечкәрәк була. Зур шәхес өчен кичерерлек объектив каршылыклар белән бергә, ихтимал, аның традицион кануннарга (ташламаларга) сыеп бетмәгән үзенең «авторски» хаталары да булгандыр. Шәхси һәм иҗтимагый тормышында аның да байтак драматик тетрәнүләре булган һәм булды. Җәмәгатьчелеккә билгеле булган ул фактлар үз эзен калдырган, әлбәттә. Миңа калса, Нәҗип ага үзенең иҗатында үзе тудырган киң масса «кара халык»ның ихтыяҗларына һәм зәвыкларына тиешле игътибар итеп җиткермичә, аларның реаль көчен тулы ук бәһали алмады бугай. Үзәк – Мәскәүнең югары музыкаль даирәләре белән бер дәрәҗәдә торып, җирле хакимият вәкилләре белән артык конфронтациягә кермичә фанатикларча эшләү аның төп кредосы иде шикелле. Бар каршылыклары белән ул үз заманын, үз чорын чагылдырган зур шәхес.

Нәҗип Җиһановны өнәп бетермәүчеләрнең аргументлары тагын мондыйрак. Ул, янәсе, Салих Сәйдәшевне көндәш итеп, аны күләгәдә калдырган, яңа талантларны үстерүдә җитәрлек тырышмаган... Мөгаен, бу гаепләүнең икенчесендә өлешчә хаклык та бардыр. Татар республикасы үзәгендәге консерваториядә моңа кадәр татар музыкасы кафедрасы да булмау (андый кафедра үткән ел ачылды) үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Консерваториянең педагоглар составында да татар халкы вәкилләренең аз булуын да аклап булмый. Беренчедән, укыту программалары РСФСРдан моңарчы автономия булып килгән Татарстанга рус өлкә шәһәрләрендәге консерваторияләрендәгечә, диктат рәвешендә өстән тагылган, икенчедән, ректорның да милли музыканы үстерү проблемаларына игътибары җитеп үк бетмәгән, күрәсең. Ә менә Салих Сәйдәшевне кыерсыту мәсьәләсе, минемчә, уйдырма. Сәйдәш иҗаты белән таныш кешеләр беләбулыр: Салих аганың иҗади пигы 30 нчы елларда була. Шәхес культының канлы куллары К.Тинчурин кебек иҗатташларын, фикердәшләрен буып юк иткәч, Сәйдәш иҗаты да сүрелүгә таба бара. Үзеннән 10 яшькә кече Җиһанов бит әле ул чакта аренада юк иде... Татар музыкасы тарихындагы бөтен негатив якларны бер Җиһановка гына

аудару дөрес булмас. Кемнең хыялына ирешүдә ихтыяр көче җитеп бетмәгән, кемнең гаиләсендә фаҗига булган, кемнең бүтән бер кайгысы... Дөнья бу! Базар гайбәтен иҗтимагый фикер мөнбәренә күтәрмик!.. «Сәйдәш» поэмасын язганда, мин күп мәртәбә Нәҗип агага мөрәҗәгать иттем, киңәшләр сорадым. Ул һәрвакыт Сәйдәш турында ихтирамлы сүзләр әйтеп килде. Аның юбилей мәҗлесләрендә олы сүзләр сөйләде. Хәтердә шагыйрьләр секциясенең «Сәйдәш» поэмасын укып-тикшерү җыелышына да килеп утырган иде. Архив документларында Нәҗип аганың Салих Сәйдәшевне кыерсытканын дәлилләгән документлар таба алмассыз. Кыскасы, чәкештермәскә кирәк иде ике бөек затны!

Нәҗип ага ак рояль артына утырып иҗат итә иде. Менә инде ул рояльнең хуҗасы юкка өченче ел китте. Кемнәрдер уйлаганча, «Татар музыкасын басып торган «Җиһангир – Җиһан» юк инде. Тынычланыйк. Йә, музыкаль тормыш җанланыбрак киттеме? Татар музыкасы дөнья аренасына киңрәк чыгамы? Яшь композиторлар гөрләп үсә башладымы? Хәер, әле мондый сораулар куярга иртәрәктер, үзгәрешләр, әлбәттә, булыр. Ә хәзергә үзгәрешләр шул: элек Опера һәм балет театры үз сезонын традиция буенча татар композиторы Н.Җиһанов операсы яки балеты белән башлап җибәрә иде, ә бу сезонны «Иоланта» белән... Симфоник оркестр да дистә еллар буена сезон ачылу концертында Н.Җиһановның яңа симфониясен яңгырата иде, бу юлы – яңа милли симфония әзерләнмәгән, бүтән – интернациональ программа...

Тукай шагыйрь булып җитешкән Җаекта (Уральск) туып, ятимнәр йортында үсеп, таланты һәм тырышлыгы белән Казан, Мәскәү калаларын таң калдырып, татар музыкасы вәкиле буларак, үз иҗатын Европага, Азия киңлекләренә яңгырата алган Нәҗип Гаяз улы Җиһанов ак рояльдә уйнап иҗат итә иде. Дөньяда ак рояльләр күптер ул. Әмма аларда бөтен дөнья тыңларлык әсәрләр иҗат итүчеләр генә сирәк.

Соңгы сүз итеп, бөек затка багышланган шигырем:

**Ак җилкән**

Биләүләрнең аклыгына кунгач
ятимлекнең кара канаты –
саклап калды мине Әниемнең
күңеленнән иңгән нур-якты.

Чаган* өсләреннән ак томанны
ак болытлар төшеп алырмы?
Кай як офыклары тартыр икән
ак хыяллы сабый җанымны?

Ап-ак күлмәгемнең изүендә
күз яшьләрем түгел, сәдәп лә...
Күпме булды ул чак өметемнең
ак канатын кисәр сәбәпләр!

Бу дөньяның ак көйләрен җыеп
тибрәттем күңелем кылында.
Тыелгысыз дәрт-көч алып чыкты
ак чәчкәле илһам юлына!
Хак эш өчен җан аямас ирнең
шәүләсе дә, имеш, ак кына!
Тормышымда көйне корал иттем
җирдә аклык, сафлык хакына.

Сынмады Рух Замананың төрле
җил-давылы сынаган чакта.
Мин, капланып, Җиргә хезмәт иттем
һәм Җиһанны күрдем ак атта!

Ак тауларга мендем, биек җилләр
иркәләрме, егып китәрме?
Ак дулкынга кереп, каршы бардым,
сулышларым озакка җитәрме?

Һәм ышандым: иманың нык булса,
төз калырга дәрман җитә ул!
Ил йөзендә ак эшемне күргәч,
халкым мине үзе күтәрде.

...Гомер күкләрендә ак яшендәй
үтә еллар, үтә яшьнәр чак...
Күпме генә җанга кер кунса да,
бу дөнья барыбер ап-ак, ак!

Ак чәчләрем җилдә җилфердиләр.
Ак җилкәндә инде хәзер мин.
Киләчәкнең ап-ак Хәтеренә
күчәр өчен җаным әзерлим.

*1980*

# *ЕГЕТ ӘДИП*

Аның эш бүлмәсеннән Казансу күренеп тора. Балконга чыксаң, җиләс җил биткә бәрелә. Җил үзе белән яр буе таллыкларының, җиләк-җимеш агачларының хуш исен алып килә. Элегрәк андый матур урыннарны «Швейцария» дип атаганнар. Моннан утыз еллар элек ике коры елга ярына бакча утырттылар, ике рәт итеп дүрт-биш катлы йортлар салып куйдылар. Исемен дә таптылар: Новаторлар урамы. Казанлылар бу урынны үзара «Куба» дип тә йөртәләр.

Әмма Казан елгасы, Идел дәрьясына койган урынында бик киңәйсә дә, исемен дә, үзәнен дә алыштырмады. Ул мең еллар элек ничек аккан булса, хәзер дә шулай ага, Идел-ана белән очрашырга ашкынып килә. Әгәр уңга борылып карасаң, моннан 70 чакрымнар ары, әнә теге офыклар артында олуг язучыбыз Гариф Ахуновның туган җирләре. Мөмкин була торган булса, дулкыннар буйлап кына йөгереп китәр иде. Казан елгасы бит аның туып үскән якларыннан башлана...

Гариф ага Ахунов әле күптән түгел генә «Идел кызы» трилогиясенең икенче китабын тәмамлады. Зур хезмәт. Авторның ун ел вакытын суырып алган хезмәт. Икенче китапның соңгы ноктасы куелган инде югыйсә, ә чынлап торып борчылу яңарак кына башлана төсле. Ничек булып чыкты икән? Укучылар күңеленә хуш килерме? Романдагы утызынчы еллар һәм дәһшәтле сугыш еллары ышандырырлык сурәтләндеме икән? Тәҗрибәсез яшь әдип борчылу бер хәл, инде каләм остасы борчыла икән, бу – бөтенләй башка нәрсә. Заманында «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары өчен дә шулай борчылгандыр ул. Соңыннан бу әсәрләр, безнең әдәбият дөньясында шаулап, үзләренең лаеклы урыннарын алдылар, татар телендә һәм рус телләрендә күп мәртәбәләр басылып чыктылар.

– Кыска документаль повестьлар сериясен уйлап йөрим әле, – ди Гариф ага. – Күңелемдә язылып та бетеп киләләр инде, кәгазьгә генә төшерәсе бар. Берсе Әлмәт егете – нефтьче инженер Үзбәк Саттаров турында. Минем өчен ул нефть-химия индустриясеннән аерылгысыз. Бик тә акыллы, төпле кеше иде. Иртәрәк китеп барды... Икенчесе – колхоз председателе, укытучы баласы Мирбат Хәстиев. Холкы йомшак, мөгамәләсе ягымлы, әмма аңарда сүз белән әйтеп биреп булмый торган әллә нинди бер көч бар... Тагын бер бик якын дустым бар әле минем: ул – Борһанов Тимерхан. Гаҗәеп кеше. Искиткеч оста гармунчы. Язмышы да бик гыйбрәтле. Тимерхан дус дип йөртәм мин аны. Аның турында да бер әсәр өлгереп килә. Бәлки, дәвамлы документаль повесть булыр ул...

...Без сүзне Казансу тезмәләрендәге тау башында учак янында дәвам итәбез. Елга өсте караңгылана бара. Елганың теге ягындагы биек йортларның тәрәзәләреннән ут баганалары сузылды. Учактагы утны таяк белән кузгата-кузгата, миңа күз дә салмастан, Гариф ага сөйләвен дәвам итә:

– Әле бүген генә Биектау районыннан кайтып төштем. Уңыш мул быел. Авылларның тышкы күренеше матур. Терлекчелек комплекслары, механикалашкан ындырлар төзелгән, культура сарайлары, мәчетләр... Йортлар алтапочмаклы, калай яки шифер белән ябылган. Болар әле байлык яралгысының тышкы билгеләре генә. Иң мөһиме: безгә җир кешеләренең күңел муллыгын онытмаска кирәк. Әгәр бүген бер гаиләнең бер кешесе яхшы эшли икән, бу – бер биеклек, әгәр гаилә тулаем үрнәк эшли белә икән, монысы – икенче биеклек, әгәр бөтен хуҗалык бер гаилә балалары булып яхшы эшли ала икән, монысы – өченче биеклек; инде килеп, районның барлык колхозлары бер сулыштан кабынып эшлиләр икән, монысы дүртенче, хәлиткеч биеклек булыр. Әхлакый климат әнә шулай туа. Биек тау әнә шулай хасил була. Биеклеккә омтылырга, шул биеклекне алу турында район җитәкчеләре хыялланып яшәргә тиешләр...

Ул әкрен генә, үз уена сәҗдә китеп, аксакалларча сөйләп утыра. Күңелдәге уйларыңны башкаларга җай гына күчерә белү, күрәсең, остазлар эшедер.

Олуг елга буенда утырганда, аргы якка да багасың. Төпкел агымны җуймас өчен, күңелдә генә булса да ярларны очраштыру кирәк. Менә бу мәлдә Казан елгасының теге ярындагы биек бинада – Матбугат йортында (хәзерге «Идел-Пресс»)– әңгәмәдәшем хакында дөнья кадәр мәкалә-мәдхияләр баса торганнардыр. Татар иле Гариф Ахуновның тууына – 60, әдәби-җәмәгать эшчәнлегенә 35 ел тулуны сентябрь аенда үткәрә. Моңа әдипнең хакы да бар. Филология фәннәре докторы Ә.Кәримуллин төзегән библиографияне игътибар белән укыган кеше сизми калмас дип беләм. Романнар, повестьлар, пьесалар, хикәяләр, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре, әңгәмәләр, публицистика. Төрле елларда, төрле төбәкләрдә төрле дәрәҗәдәге матбугат органнарында ул Толстой һәм Шевченко, Шолохов һәм Ибраһимов, Купала һәм Такташ, Ойунский һәм Цадаса, Хәмзә һәм Айни, Гамзатов һәм Айтматов, Исәнбәт һәм Мостай Кәрим турында мәкаләләр бастырды. Татарстан китап нәшрияты чыгарган томлыкларының соңгысында каләмдәшләре һәм классикларыбыз хакында аның утыздан артык әдәби портреты басылган. СССР һәм РСФСР язучыларының пленумнарында, күчмә утырышларында, Әдәбият көннәрендә, конференцияләрендә һәм симпозиумнарда ул үзбәк һәм якут, башкорт һәм Дагстан, Төньяк Кавказ һәм Урта Азия әдәбиятлары турында чыгышлар ясады. Монда бер нәрсәне онытырга ярамый: боларның барысы Татарстан Язучылар союзы аппаратында зур эшләр алып барган кеше тарафыннан эшләнде бит. Ун ел буена ул Татарстан Язучылар берлеген җитәкләде, Әлмәт һәм Чаллы Язучылар оешмаларын төзүнең төп инициаторы булды, «Казан утлары» журналында ун еллап эшләде – әдәби хезмәткәрдән башлап баш редакторга тикле!

Иҗаты аның күптармаклы. Әдәби тәрҗемәләрне генә алып карыйк. 200 табактан артык тәрҗемә әсәре. Алар арасында М.Шолоховның «Тын Дон» романының ике китабы, А.Чехов һәм Р.Тагор хикәяләре, А.Макаренконың «Педагогик поэма», В.Закруткинның «Йөзмә станица», Н.Шундикның «Боланнар илендә» романнары, А.Островский, Н.Погодин, К.Финн пьесалары. Болар үзләре генә дә бер профессиональ тәрҗемәче гомеренә җитәрлек. Уйлап карыйк: бүгенге яшьләр аның менә дигән тәрҗемәче булуын юньләп белә микән? Шикләнәм. Күпләр аны танылган романчы, талантлы повестьлар авторы, драматург, сценарист, шәп публицист, принципиаль әдәби тәнкыйтьче итеп таныйлар.

Һәркемнең үзе өчен кадерле, канат ныгыткан чоры була. Гариф Ахуновның ул чоры 60 нчы елларга, Әлмәттә яшәгән дәверенә туры килә. Олуг иҗатының нигез ташлары шул чорда салынган да инде. «Кара алтын»ның фонтан булып аткан дәвере бу. Татарстанның СССРда чыккан нефтьнең өчтән берен биреп торган заманы. Нефтьчеләрнең ул чордагы эшләре хакында читтән күзәтеп кенә язу мөмкин түгел иде. Язган геройларыңны яхшы белергә, алар белән аралашырга, аларның язмышын үзеңнекедәй кабул итәргә кирәк иде.

Гариф Ахунов шул эшне эшләде дә. Әлмәттә ун елдан артык яшь гомерен уздырды. Ә бит аның Казанда да бик әйбәт эше бар иде. Гаделлек хакына шуны да әйтик, «халык тамырына» юлыкканчы, «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарын, «Хыялый Хәйрүш егетләре», «Канатлар кая илтә?», «Артышлы тау буенда» повестьларын, «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта» пьесаларын язганчы, аңа җитмеш җиде кат тир түгәргә туры килде. Аның «Җир куенында» исемле драмасы зур бер сәхнәдән дөбер-шатыр җимерелеп төште. Әмма ул аңардан үзенә тиешле нәтиҗә ясый белде. Ахыр чиктә тимер-томырга түгел, кеше күңеленә юл алды.

Аның иҗатында көчле кешеләр, хезмәт яратучы намуслы кешеләр яши. Шулай булмаганда, беренче бишьеллыкларның легендар баһадиры Мирсәет Ардуанов хакындагы повесть язылыр идеме? Яки «Чикләвек төше» повестен алыйк. Заманында бу әсәргә Мостай Кәрим югары бәя бирде. «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен әдип Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Хезмәт ярату һәм кешене ярату. Язучы өчен кирәкле төп сыйфатлар. Бәхетледер, Гариф агада алар кечкенәдән үк булган, әнә шул асыл сыйфатлар аңа күпмилләтле совет әдәбиятының олы юлына чыгарга ярдәм иттеләр.

Без учак янында утырабыз. Мин аның юбилеена чыккан «Чишмәләр белән сөйләшү» исемле китабының төп героен күз алдыма китерәм (юл уңаенда әйтеп узыйк, бу китапка тирән эчтәлекле, акыллы сүз башын күренекле башкорт прозаигы Әхияр Хәкимов язган).

– И улым-балакаем, берни дә белмисең бит син, – ди борынгы карт Сәйфелмөлек. – Газиз башкайлар ниләр генә күрмәде! Җир казырга кирәкме, көрәкнең зурысын Сәйфелмөлеккә тоттыралар. Кама елгасыннан сал агызырга кирәкме, Иделдә баржалар бушатасы бармы, әлеге дә баягы Сәйфелмөлек. Аркадагы грузчик «мендәренә» бер капчык тозны китереп салган чакта, умырткалар шыртлап китә, аяк астындагы басмачалар сыгылып килә. Әнә нинди заманалар барые! Син әйтәсең, язачак китабыма герой эзлим, дисең. Эзләп торырга кирәкмени аны?! Дөньядагы иң зур, иң глауный герой халык бит ул.

Әгәр халык үз гомерендә көрәк белән казыган үзәнгә су салсаң, яңа бер Идел дәрьясы җыелыр иде, билләһи әгәр! Әгәр Рәсәй шахталарында халык чыгарган ташкүмерне бер урынга җыйсаң, яңа бер Урал тавы калкып чыгар иде!

Гариф Ахуновның «Идел кызы» трилогиясе хакында уйлый башлагач, минем күз алдыма тагын Сәйфелмөлек карт килеп басты. Бу төп китабы өчен Гариф ага Ахунов халык тормышының тирән катламнарын өйрәнеп чыкты, бер милләт язмышында, бу очракта татар халкы язмышында, илле ел эчендә нәрсәләргә ирешкәнен, ниләр югалтканын күрсәтеп бирүне максат итеп куйды.

Минем уйларымны белгәндәй, Гариф ага янә дә сүз башлады:

– Чит илләрдәге коллегаларыбыз белән очрашканда, әңгәмәләр вакытында миңа үзебезнең халык турында анохроник төшенчәләр ишетергә туры килде. Янәсе, татарлар әле һаман тирмәләрдә яшиләр, кыргый атларны чаптырып йөриләр. Көлке дә, көенечле дә бу хәлләр. Мин үзебезнең Татарстаныбыз турында русча ике китап чыгардым. Күрәсең, ул гына җитми, гел язып, дөньяның исенә төшереп торырга кирәк. Без кем идек тә, кем булдык! Аз язабыз, язсак та, үтемле итеп язмыйбыз, ахрысы...

Каләм остасы үз эшеннән канәгать түгел икән, димәк, безне алда яңа ачышлар, яңа геройлар көтә дигән сүз. Остаз кеше хакны, дөресне әйтер.

*1985*

## *ЗУРАЕП КАЛУ*

*** * ***

Яшәсен! –
ирләрнең, кеше рәнҗетми,
якты хәтер калдырганы.

Ни-нәрсәдән мәхрүм калганыңны югалткач кына аңлыйсың. Исән чакта, теге дә, ул да, бу да, мин дә дигәндәй, кайчандыр бер-беребездән мәңгегә аерылачакны белсәк тә, ул вакытта хис-тойгы әле шактый томанлы, абстракт, югалтуның ачы хәсрәте сәгате суккач кына йөрәккә төшә икән. Гариф абый Ахунов үлемен ишеткәч тә шулай булды.

Гыйбрәтле хәл: берәүләр киткәч, алар хәтер офыгы томанында шундук эреп югалалар, берәүләр, киресенчә, тагын да зураеп күңеленне билиләр; шәхеснең яшәештәге бәндәлеге

онытыла, мәңгелеккә дәгъва иткән изге эшләре, олылыгы гына кала. Гариф абый Ахунов бакый дөньяга җиңел күчте дип беләм. Озаклап хаста булып үзе дә интекмәде, бүтәннәргә дә борчу салмады. Үлемнең – табигый, Яшәүнең үзгә дәвамы икәнен раслагандай, тыныч кына китеп барды. Һәм, әйтергә кирәк, Бөек Күчештән соң аның исеме, рухы фани дөньялыкта зураеп, үсеп калды. Бу зураю, үсү күп меңләгән кешеләрнең күңелләре, сыкрау-әрнүләре, сагыну-сагышлары аша зураю булды. Озаккамы?

* * *

Яшәсен! –
егетләрнең бик түбәннән
күтәрелеп дан алганы.

Соңгы ярты гасырлык татар әдәбиятын Гариф Ахуновсыз күз алдына китерү кыен. Язган әсәрләре – китаплары буенча да, әдәби хәрәкәтне оештыруда кылган гамәлләре буенча да. Аны, мөгаен, татар совет әдәбияты классигы дип атау дөрес буладыр. Шушы чор сәяси тормышның, әдәби барышның бөтен позитив һәм негатив яклары чагылыш таба аның иҗат эшчәнлегендә. Бер яктан, Г.Ахунов шул чор идеологиясенең күндәм хезмәтчесе (КПСС съездлары делегаты, СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе секретаре...), икенче яктан, татар милләте, татар әдәбияты мәнфәгатьләрен армый-талмый кайгыртучы фидакарь халык улы булды (зур полотнолы әсәрләр авторы, Әлмәт Язучылар оешмасын оештыручы, йөзләгән яшь каләм ияләренә фатиха бирүче, татар әдәбиятын башка халыклар арасында үтемле пропагандалаучы, ару-талуны белми иҗат итүче...). Әле санап әйтелгәннәрнең һәрберсе турында бит-бит тәфсилләп язып булыр иде. Әмма андый хаҗәт юк: Гариф Ахунов бик билгеле шәхес һәм аның эшчәнлеге дә халыкка яхшы мәгълүм.

Кояш астында үз урыныңны алып, җирдә ышанычлы нык басып яши алу, шуңа өстәп зур хезмәтләр һәм шанлы исем калдыру, һай, җиңел түгел бу дөньяда! Г.Ахунов – түбәннән күтәрелгән шәхес. Ятим балачак, сугыш уты өткән яшьлек... Югалып калырга, сынарга, бозык юлдан китәргә дә мөмкин... Әмма Гарифҗан Ахунҗан улы югалыр өчен яратылмаган булган шул. Үзәк ныклык, үҗәтлек, черәшеп эшли алу, халыкның киләчәгенә ышану, сүз кодрәтенә табыну аны олуг әдип иткән. Төрлесе булган гомерендә, төрлесе кичерелгән. Төрмә сәкеләре дә күрелгән, патша табыннарында да утырылган...

* * *

Яшәсен! –
дус-ишләрнең көнләшмичә
якын итә торганнары.

Гариф Ахуновның дуслары күп иде. Егетлек, ихласлык, юмартлык, ярдәмчеллек хас иде аңа. Бу сыйфатлар күпләрне әсир итәрлек асыл сыйфатлар шул. Шәхсән минем үземә дә утыз елдан артык Ахунов мохитендә яшәргә насыйп булды. Әдәбиятка ныклап аяк басуда аның шифалы йогынтысы зур булды. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә әдәбиятта ул кичкән хезмәт юлын үтәргә туры килде. Әлмәт Язучылар оешмасы, Татарстан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы... Бер үк постларны диярлек биләдек. Аңа алдарак, миңа соңрак насыйп булды бу миссия. Киңәшләшеп, ярдәмләшеп, әдәбиятыбыз тәрәккыятле милләтләрнекеннән ким булмасын дигән ният белән эшләргә тырыштык. Шөкер, кайбер игелекле эшләр башкарылды дип уйлыйм. Хәер, аның кешелеклелеген тойган, хәер-фатихасын алган, олылау сүзен ишеткән каләмдәшләр бихисап. Кемнәр турында гына язып чыкмады да кемнәр турында гына зур-зур трибуналардан сөйләмәде Гариф абый! Йөзләгән-йөзләгән мәкаләләр, иҗат портретлары, рецензияләр, тәкъдим-рекомендацияләр... Бүгенге Язучылар берлегендәге өч йөз илледән артык каләмдәшебезнең, ихтимал, яртылабы теге яки бу формада аның булышлыгын алганнардыр дип уйлыйм. Каләмдәшләр генәме соң? – артисты да, рәссамы да, игенчесе дә, нефтьчесе дә...

* * *

Яшәсен! –
исәннәрнең үлгәннәргә
чардуган кора алганы.

6 июньдә Гарифҗан Ахунҗан улын Арчаның татар зиратында җирләп кайттык. Моннан нәкъ ике ел элек без – «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре – әдипнең туган авылы Өчиле җиренә барып, табын корып утырган идек. Ул авыл инде юк, кайбер нигез урыннары гына беленеп тора. Әмма зират исән калган. Гариф абыйга бик моңсу иде бугай. Аның тау итәгеннән ургып аккан чишмәгә озак карап торганы хәтердә калган. Кайткач, куен дәфтәренә шигырь сыман мондый юллар язып куелган.

**Сәхрәләргә чыккан идек бер...**

Бу җирләрне яд итәргә
төркем булып килдек каладан.
...Авыл күптән беткән.
Тау битендә
зират та чишмә калган.
Яктык учак. Кыздырдык шөшлек.
Тостлар яңгырады телдән телгә күчеп.
Янда бөтерелә иясез бер көчек.
Фанилыкны искәртә талгын җил исеп
зират ягыннан.
...Бу адәмнәрнең дә күбесен юк дип була,
йөрсәләр дә монда ашап-эчеп.

...Арча зиратын үзенең калку урынында калдырып, Казанга кайту юлында сагышлы, борчулы уйлар биләде күңелне. Арча җиреннән чыккан әдәбиятыбызның имәндәй баһадир әдипләре китеп-бетеп бара. Г.Бәширов, М.Мәһдиев, Г.Ахунов... Боларсыз татар прозасын күз алдына китереп буламы соң? Биш-алты ел элек кенә бергә аралашып йөргән идек бит әле!.. Аларны кемнәр алыштыра? Аларныкы кебек тормыш тәҗрибәсе һәм тел байлыгы булган яңа буын язучыларыбыз бармы?

Әле күптән түгел генә дөньякүләм мәшһүр әдипләр, төрки халыкларның уртак горурлыгына әверелгән язучылар Ч.Айтматов белән О.Сөләйманов, Казанда булып, татар язучылары белән очраштылар. Кызыклы гына әңгәмә булды. Шунысы да сискәндереп куйды, бәй, бу зур затлар белән аралашкан, бер-берләре белән кочаклашып күрешерлек язучыларыбыз юк дәрәҗәсендә икән. Янә Гариф абый искә төште. Ул арада булсамы?!

* * *

Яшәсен! –
ирләрнең көчле булып та,
сабыйлыгын җуймаганы.

Гариф Ахунҗан улы Ахунов безнең күңелләрдә сабый күңелле, көчле ихтыярлы ир-егет булып калды.

*2000*

# *ХӘЗИНӘЛӘР ХУҖАСЫ*

Заманыбыз турында үз эш-шөгыленә, үз аңлау-инануына карап, һәркем үзенчә фикер йөртә. Берәүләр, космос-кибернетика заманы, ди, берәүләр, иҗтимагый стресслар яки тәрҗемәләр заманы, ди, геноинженерия заманы, дип тә әйтәләр... Кем ничек кенә әйтмәсен, бер нәрсә ачык мәгълүм: заманыбыз – мәгълүмат-информация заманы, халыкара аралашу

заманы. Бу җәһәттән библиография фәнен өскә куеп сөйләү дөрес булыр. Тарихи хәзинәләрне барламый торып, киләчәккә ышаныч белән барып буламы? Гасырлар буена тупланган байлыкны беренче чиратта язма хәзинәне киң дөньяга чыгара алганда гына теге яки бу халыкны чын мәгънәсендә тәрәккыятле, цивилизацияле дип санап буладыр. Библиография – халык акылына, халык гыйлеменә, халык тарихына ышанычлы юл күрсәткеч ул. Галим Әбрар Кәримуллин – нәкъ менә үз мәйданында, библиография өлкәсендә, бүтән халыклар да күрерлек, танырлык итеп, халкыбыз тарихында рухи баганаларның бик тә олыларын утырткан кеше.

Сер түгел бит: «Язучы мин!» дип йөргән күбебез (без генә микән?), бар булган архивыбызны да йә ялкаулык, йә оешмаганлыктан тиешле тәртипкә китерә алмыйбыз. Үзебезне аклау өчен, әлбәттә, мең сәбәп табабыз. Янәсе, киләчәктә ул эшләрне кемнәрдер (мифик!) бүтәннәр башкарачак әле. Русча әйткәндә, «увы!..» Ярый, монысы һәр кешенең үз эше, диик. Ә менә гасырлар буена җыелып килгән, меңнәр тарафыннан иҗат ителгән уртак китап хәзинәсе белән нишләргә? Алар бит тау-тау. Ул китапларның ияләре, язган-тудырган вакытта, без исәннәр үз әсәрләребез турында уйлаган кебек, алар да үз язганнары турында бөек фикердә булганнардыр... Ике гасыр ярым гомер-биографиясе булган татар китабы тарихында кемнәр генә язмаган да, нинди генә китап чыкмаган! Күбесе халык хәтереннән дә югалган бугай инде. Вакыт тузанын кагып якты кояш астына чыгармасаң, әллә нинди асыл җәүһәрләрнең дә мәңгегә күмелеп калуы бар. Кемдер, үзендә хуҗа тойгысы сизеп, билгеле бер тәртипкә китерергә, бер төенгә төйнәргә тиеш бит ул байлыкны. Безнең Әбрар абыебыз, үзе теләп, әнә шул зур тарихи эшкә алынган асыл затыбыз.

Белмим, галимнең үз иҗаты буенча төзелгән үз библиографиясе нинди хәлдәдер, әмма аның матбугатта басылган йөзәрләгән хезмәтләре, ике дистәгә якын китаплары зыялы укучыларга яхшы таныш дип беләм. Әлегәчә басылмаган хезмәтләре дә байтак. Дөнья күргәннәреннән кайберләрен санап үтик: «Татар әдәбияты: фольклор, әдәбият белеме һәм әдәбият тарихы», «Татар матур әдәбияты», «СССР һәм чит ил халыклары әдәбияты, фольклоры һәм сәнгате: татар теленә тәрҗемәләр», «Татарская литература в переводах на русский язык»... «Татар сәхнәсе» дигән зур библиографик хезмәте үзе генә ни тора! Ә аерым әдипләр – К.Насыйри, М.Җәлил, Х.Туфан; бүгенгеләрдән – Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, С.Хәким, Г.Ахуновлар иҗаты буенча аерым библиографик күрсәткечләр... Исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин. Библиография – түземлелек, бөртекчәнлек, сирәк кешеләргә генә хас ихтыяр көче сорый торган эш. Эскерткә өелгән саламнарны берәмтекләп бер тәртипкә тезеп кую белән бердер ул. Күпме эзләнергә, күпме кәгазь тузаны йотарга, күпме исәп-хисап алып барырга! Зур максат белән алынып, күп көч куйган гамәлнең әҗере-нәтиҗәсе дә олыдан шул: татар дөньясы тарихында Ә.Кәримуллинның иң өлкән, иң фидакарь библиограф-елъязмачы икәнлеге бәхәссез хакыйкать.

Ихтимал, библиография буенча кылган хезмәтләре генә дә галимнең исемен төрки әдәбиятлары тарихында җуелмас итәргә җитәдер. Әмма гаҗәп дәрәҗәдә эш сөючән бу шәхеснең фәннең бүтән өлкәләрендә башкарган эшләре дә сокланырлык. Ул да булса – матбагачылык тарихы. Бүтән өлкә дисәм дә, әлбәттә, библиография белән китап тарихы янәшә, бер-беренә үрелеп бара торган фәннәр. Әмма соңгысы тарихка күбрәк карый, бүтәнрәк үлчәүләр белән эш итүне сорый. Китап тарихы ул, асылда, халык тарихы. Язма әдәбиятны белмичә, бигрәк тә басма китапларны барламыйча, халык тарихына төшенү мөмкин түгел. Ә татар китабы тарихы исә халык язмышына иш рәвештә үтә четерекле, авыр, гыйбрәтле тарих. Әбрар Кәримуллинның рус телендә чыккан «У истоков татарской книги» (1971), «Татарская книга начала XX века» (1974), «Татарская книга пореформенной России» (1983), татар телендәге «Китап дөньясына сәяхәт» (1979) исемле китаплары әнә шул олы миссияне уңышлы башкарып чыгуына бик тә саллы дәлилләр. Алар халкыбызның иҗтимагый үзаңы үсүенә булышкан кадерле китаплар. Алар Ә.Кәримуллинны илкүләм мәгълүм китапчы галим итеп күтәрделәр. (Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: галимнең докторлык диссертациясе дә татар китабы тарихы турында. Ә андый китапчы галимнәр СССРда бармак белән генә санарлык.) Бу китаплар республикабыз һәм үзәк матбугаттан тыш чит илләрдә дә югары бәя алдылар.

Хәзер рәсми формада фәнни дәрәҗә йөрткән кешеләр бик күп. Казанның үзендә генә дә фән докторлары биш йөздән артык. Татар әдәбияты һәм филологиясе өлкәсендә генә дә берничә дистә фән докторы, йөзләгән фән кандидатлары исәпләнә. Һәр эштәге кебек, әлбәттә,

арада төрлеләре бар. Берәүләр, моңарчы билгеле булган ачышларны билгеле бер системага салып, калыплап, тематик фокуска туплап, үзләренчә трансформациялап, Фән дигән бөек храмга үрмәләп маташалар, икенче берәүләр исә, тормыш ихтыяҗыннан чыгып, әле моңарчы кул тимәгән өлкәләрне сөреп, яңа катламнар күтәрәләр, яңа буыннар өчен дә ачыш булырлык мәгълүматларны фәнни хәрәкәткә кертәләр. Әбрар Кәримуллин – әнә шул соңгыларыннан. Татар әдәбияты тарихын, бигрәк тә аның соңгы дәверләрен җентекләп өйрәнергә алынган кеше, һичшиксез, Ә.Кәримуллинның китап тарихына караган хезмәтләренә мөрәҗәгать итәчәк. Димәк, Әбрар абыйның кылган эшләре яңа фәнни хезмәтләр тудырачак. Фән кешесе өчен чын бәхетнең үзе бит бу! Халык тарихын, аның рухи үсеш баскычларын аңларга теләгәннәр өчен алар үзгә бер мәктәп булырлык басмалар.

Библиограф һәм китап тарихчысы булудан тыш Ә.Кәримуллин шәхесе әле тагын байтак фәннәргә килеп тоташа. Этнография, археография, этимология, палеография, этнонимия... Йөзәрләгән, төрле характердагы, төрле күләмдәге хезмәтләр арасында нинди генә мәсьәләләргә караган материаллар юк дисез! Теге яки бу халыкның гореф-гадәтләре турындамы, төрки телләр белән Көньяк Америка индеецларының тел уртаклыклары турындамы, нәкыш бизәкләре һәм тәрҗемә нечкәлекләре турындамы, графика яки борынгы сәяхәтчеләр турындамы... Кайберәүләре, әйткәнемчә, матбугатта чыккан, кайберләре әлегә кульязма хәлендә.

Әбрар Кәримуллин эшчәнлегенең тагын бер үзенчәлеген ассызыклап әйтеп китмәү дөрес булмас. Ул – халыклар дуслыгын ныгытуга бик зур өлеш керткән әдип. Казакъ, үзбәк, төрекмән һәм башка төрки телләрдә дөнья күргән беренче басмаларны барлауда тиңдәшсез галим ул.

Дөнья гамәлләренең төрле өлкәләрен колачлаган кешеләрне энциклопедист галим дип әйтәләр. Әбрар Кәримуллин – шундыйлардан. Адәм баласы төрле яктан никадәр генә талантлы булмасын, барыбер аның нечкәләп белгән бер эше була. В.Дальнең гомерлек эше – рус теле сүзлеге, К.Баронның – латыш җырлары, Н.Исәнбәтнең – татар фольклоры. Ә.Кәримуллинның исә иң беренче чиратта – татар китабы тарихы. Ул шул ягы белән көчле дә, зур да, бердәнбер дә.

Безнең бәхетебезгә язган әнә шул олуг кеше кайларда туып-үсеп, нинди шартларда шундый зур галим булып җитешкән соң? Баксаң, Саба районының гади бер татар авылыннан чыгып күтәрелгән кеше икән ул безнең Әбрар абыебыз! Биографиясе гади, әмма шактый гыйбрәтле. Колхозчы, сугышчы, студент, китапханәче, фәнни хезмәткәр. Сугышчы дигәненә аерым басым ясап әйтми булмый. Яшьли сугышка китеп, Европа һәм Ерак Көнчыгышларны урап, яраланып, орден-медальләр тагып туган якларына кайткан кеше ул. Гади солдат булып сугышның иң хәтәр җирләрендә була. Курск дугасы, Днепр кичүләре, Гоби чүлләре, Хинган таулары... Фронтовиклар гына түгел, бик күп замандашларның коточкыч һәлакәтләр итеп искә төшерә торган атамалар алар... Шулай итеп, мең үлемнән могҗиза белән исән-сау калып, туган якларга әйләнеп кайткач кына укырга, фән белән шөгыльләнергә туры килә аңарга. Яшәүнең никадәр зур бәхет икәнен, тыныч хезмәтнең бөек куаныч икәнен бөтен күзәнәкләре белән аңлап кайткан шул ул. Үзе теләгән эшенә кадалып ябышкан ул. Шуңа күрә ил тарихында калырлык хезмәтләр тудыра алган да.

Башкарган эшләре тау кадәр булса да, гел генә дә дан-шөһрәткә коенып, мал-мөлкәткә тиенеп яшәде дип әйтмәс идем мин аны. Гомере буе диярлек китаплар, картотекалар, кәгазьләр белән тулган кечерәк кенә фатирда яшәде, балалар үстерде, үземне күрсәтим дип, чәчрәп уртага чыкмады, милләт хадиме булып эшләде дә эшләде. Олы эшенә әдәплелек, тыйнаклык юлдаш булды. Үз гомерендә төрле имлялардагы бик күп басма китаплар күргән, аларга күпме күз нурын түккән кешегә, әйдәгез, без дә матбугат аша үзебезнең ихтирамыбызны белдерик, саулык һәм иҗат уңышлары телик. Моннан унбиш еллар элек хөрмәтле галимебезгә атап язылган менә бу шигырь дә әлеге теләкләргә куәт булсын:

Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез аның.
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!
Чор-заманнарны үтәли
куралган зирәк ирләр,

сезнең үлчәү берәмлекләр –
гасырлар да дәверләр!
Кемнәре юк бу дөньяның!
Тиңсезе, ятимнәре...
Рухи мирас бакчасының
сез – хуҗа, хакимнәре!
Еллар аша ничек күренә
безнең эшләр, янулар?
Бәләкәйме? Әйтәсезме:
«Бичаралар, фанилар...»
Әйе, кылганнар аз, мыскал...
Шулай да бер сүз – бездән:
«Без фанидыр, фаниерак –
максатсызлар, йөзсезләр!»
Хаклыкка якын торучы,
әй, халык галимнәре!
Ил-йортның эшчән уллары,
милләтнең хадимнәре!
Дөнья бәһасе язу да,
мәкале, әйтеме дә,
мирасы – мәшһүр бинең дә,
бер дәрвиш хәкимнең дә –
язмыш сезнең хөкемдә!
Сезнең үлчәү берәмлекләр –
гасырлар да дәверләр!
Сезгәме соң тыңләшә ала
өч көн көчле Дәү ирләр!
Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез анын!
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!

*1985*

## *ГОРУРЛЫГЫБЫЗ*

Ил иҗатчылары арасында 90 яшькә җитеп исән-имин йөрүче, актив иҗтимагый тормыш алып баручылар бик сирәк. Белгәннәремнән – Мәскәүдә генерал Я.Чанышев, Уфада шагыйрь С.Кудаш, бездә – рәссам һәм сынчы Бакый ага Урманче... Ихтимал, мондый олуг яшьтәгеләрнең юбилей тантаналарын уздыруда безнең оештыру һәм этик тәҗрибәбез дә җитенкерәмидер. Инде күптән дөнья куеп, хәзер генә 70 яки 80 яшьләре, сирәгрәк булса да 90, 100 еллыклары җиткән классикларыбызның туган көн бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә, шәт, өйрәндек шикелле. Сәхнә түрендә портретлары булыр, халык алдында доклад-нотык сөйләнер, истәлекләр... Сүз, гадәттә, бер юнәлештә, портретка карап дигәндәй, җавап кайтара алмый торган үткәнгә төбәп сөйләнелә. Ә менә исән-сау юбиляр, 90 яшьлек егет алдында, үзе алдында ни сөйләргә?

Кыскасы, халык улы, халык рәссамы Бакый ага Урманчега 90 яшь! Һималай тавына ымсынып карап торучы яшь альпинист халәтендәге бер хис миндә. Ни дисәң дә, арада ярты гасырдан артык гомер ята! Аның хакында моңарчы чыккан язмаларны караштыргалыйм, төрле буын рәссамнарының сүзләренә колак салам, замандашларын тыңлыйм. Әнә бит «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе буенча сабакташы, 88 яшьлек Нәкый ага Исәнбәт Урманче турында ни дигән. «Яңа татар поэзиясендә һәм татар музыкасында нигез салучылар кемнәр?» дип сораганда, «Беренчесе – Тукай, икенчесе – Сәйдәш» дип җавап бирсәк, «Татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем?» дигәндә, «Бакый ага Урманче!» дип, бүген хаклы рәвештә әйтә алабыз.

Бу сүзләр әйтелгәннән соң егерме еллар үткәч, икенче бер зур әдибебез Ә.Еники дә шул ук фикерләрне янәдән тәкърарлап язып чыкты. Димәк, бу фикер – очраклы рәвештә әйтелгән

эффектлы тәгъбир генә түгел, ә халык күңелендә төенләнеп килә торган фикер. Чөнки, өлкән әдип Гомәр ага Бәширов әйткәнчә, «Бакый Урманче үз әсәрләрендә татар халкының бай мәдәниятен, аның эстетик карашларын озак еллар буенча гәүдәләндереп килде».

Бакый Урманченың 90 яшьлеге – сәнгатебез тарихында, һичшиксез, уникаль бәйрәм, һәр җәһәттән кызыклы һәм мәгънәле бәйрәм. Юбилярның, шәхес буларак, үзе һәм иҗаты – мәдәниятебез тарихы, аерым алганда, сынлы сәнгатебезнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйландыра. Мәгълүм: вак нәрсәгә юлыксаң, үзең дә бәләкәйләнәсең, булган фикерләрең таркалып кечерәя, ә зурлыкка тап булсаң, ныклы нигез сизсәң, уйларың да үзеннән-үзе зурая, колачлана, киләчәккә төбәлә. Иңкүлектә килгән уй белән мәгърур тау башында торып уйланганнар шактый аерыла шул! Феноменаль күренеш дип санарлык Бакый Урманче шәхесе һәммәбез өчен, бигрәк тә яшь иҗатчылар өчен ифрат кызык һәм гыйбрәтле. Иң әүвәл, шундый олы яшькә җитеп (ирексездән хәтергә Б.Шоу, С.Коненков, П.Пикассо, М.Сарьяннар хәтергә килә), аек акылда булып, һәрдаим иҗади халәттә тора алу – үзе бер батырлык, үзе бер егетлек. Егетлек, бәлки, эстетик категория саналмый торгандыр, әмма зур әхлакый мәгънәгә ия тормышчан төшенчә ул. Икенчедән, Бакый ага Урманче таланты гаять күпкырлы: ул – рәссам, сынчы, педагог, публицист, тарихчы, филолог-полиглот, җырчы, шагыйрь... Һәм, ниһаять, җыйнап әйткәндә, киң мәгънәдәге җәмәгать эшлеклесе, халык ихтыяҗларын кайгыртып яшәүче. Өченчедән, классик мәгънәдә чын интеллигент. Ул синең белән үз итеп шундый ихлас һәм гади сөйләшер, яшь аерымлыкларын һич сизмәссең. Безнең даирәдә югары белемле, рәсми рәвештә фәнни дәрәҗәләргә ирешкәннәр шактый күп, әмма чын зыялылар, интеллигентлар алай ук ишле түгел. Кешелеклелек белән интеллигентлык бик дефицит нәрсә ул хәзер. Һәм, ниһаять, Бакый ага эшкә бирелгәнлек үрнәге дә. Дан Тулпарын тырышлык дигән көмеш йөгән белән авызлыклаган Ир ул.

Уйлап баксаң, бик күп асыл сыйфатларны үзенә туплый алган бит бу шәхес! Андый сыйфатларны үзендә булдырган хәлдә дә аларны гомер буе саклап, һаман үстереп бара алу, ай-һай, җиңел түгелдер!.. Табигать бүләге – таланттан тыш корыч ихтыяр, ныклы иман, максат ноктасына бара белү, тән һәм җан җегәре, һәм тагын байтак нәрсәләр дә кирәктер! Бу җәһәттән Бакый ага Урманче яшьләр өчен тормыш итә белү, яшәү һәм иҗат итә белү мәктәбе бит! Иҗат итә алу, кеше нинди яшьтә генә булмасын, ул – яшьлекне җуймау дигән сүз. Моның сере нәрсәдә соң? Бу серне белү безгә, иҗатның нинди төре белән шөгыльләнсәк тә, бик тә, бик тә кирәк бит! Моңа өлешчә җавапны Останың Гомәр ага Бәширов белән әңгәмәсендә («Казан утлары», 1987, № 2) укып, аны үземә бер ачыш дип кабул иттем. Ул болай ди: «Шәхес буларак, үзеңнең кадереңне белеп, вакытыңны һәм көчеңне вак-төяккә сарыф итмичә, зур максатларга омтылып яшәргә кирәктер...» Әйе, кадерсез булмыйк, бүген үк кадерсез булсак, киләчәк буыннарның да исе китмәс. Әйе, вакытны һәм көчне юкка сарыф итмик, юкса ил өчен зур эшләр майтара алмабыз... Бу уйлар бигрәк тә бүген, җәмгыятебездә зур үзгәрешләр барган чорда бигрәк тә актуаль яңгырый. Ахыр чиктә җәмгыятьтә талантның, иҗат интеллигенциясенең абруе халыкның рухи климатын да билгели бит әле!

Бакый ага Урманченың иҗат хәзинәсе бик бай. Белгечләр язуынча, аның берничә мең график, өч йөздән артык нәкыш әсәре, йөздән артык скульптура сыннары бар. Бу мәгълүматлар дүрт-биш ел элек игълан ителгәннәр иде. Хәзер бу саннар тагын да ишәйгәннәрдер. Хикмәт, бәлки, саннарның ничә урынлы булуларында да түгелдер, халык күңеленә керер өчен дистәләгән чын әсәр дә җитә. Дөресен генә әйткәндә, без Бакый ага иҗат иткән әсәрләрнең байтагын белмибез дә. Кайберләре инде аның җыелган, кайберләре ил буйлап сибелгән. Үзеннән башка ул эшләрнең һәммәсен күргән кеше, ихтимал, дөньяда юктыр. Идел буенда яшәүче замандашлары, асылда, аның соңгы утыз елдагы иҗатын гына белә. Дөрес, 30 нчы еллардагы яки сугыш чоры әсәрләрен альбомнардагы репродукцияләр аша бераз чамалыйбыз, хәтта әле кайберләребез аларны анализлап мәкаләләр дә яза. Әмма оригиналларын күрмәгәч, бу омтылышлар тәрәзә аша табигать белән хозурлану шикеллерәк булып чыга. Минем өчен шәхсән Бакый ага иҗаты – киндергә яки картонга төшерелгән рәсемнәре, портретлары һәм мәрмәрдә, бронзада, бетонда, агачта уелган сыннары белән кадерле. Ул – Кол Гали, Тукай, Җәлил, Ямашев, Кариев, Мәрҗани, Насыйри, Дәрдеманд, Ибраһимов, Көгелтинов сыннары. Ул – «Сагыш», «Язгы моңнар», «Сөембикә», «Наз»лар... Ул – композитор Н.Җиһанов, шагыйрь Х.Туфан, художник Ч.Әхмәров, архитектор И.Гайнетдинов, язучылар Г.Бәширов, М.Әмир, табиб Г.Терегулов, генерал Г.Сафиуллин

портретлары. Ул – майлы буяу белән язылган «Салтык болыны», «Уралтау эргәсендә» дигән күренеш-картиналар... Тагын боларга өстәп Урта Азия җирлегендә язылган дистәләрчә сыннар, портретлар, пейзаж-этюдлар... Бу соңгылары ир уртасы дәверендә, иҗат дәрте аеруча ташып торган елларда иҗат ителгәннәр. Хәтта репродукция сурәтләре аша танышканда да алар көчле тәэсир итә. Ә Тукай-Кырлайдагы мемориаль музей комплексы да тулысы белән диярлек Б.Урманченың иҗат җимеше бит. Бу комплекстагы хезмәтләре генә дә аның халык алдында үзенең рәссамлык бурычын үтәве булып саналырга мөмкин. Татар мәдәниятенең күренекле шәхесләренә багышланган сыннар галереясы һәм Тукай-Кырлай музее комплексы, ихтимал, Оста гомеренең төп хезмәтләредер. Һәрхәлдә, туган төбәк, туган халкы өчен бу шулай.

Бәхәссез, татар милли сынлы сәнгатен ныклы нигезгә салган кеше – Бакый Урманче. Әмма шушы тарихи миссиянең Урманче тарафыннан гамәлгә ашырылуына алшарт булып торган кайбер хезмәтләрне һәм аларның ияләрен дә онытып бетермик. Әйтик, инде 1893 елны ук Петербургта махсус художество белеме алган, гомере буе диярлек Эрмитажда скульптор-реставратор булып эшләгән М.Байкеев 20–30 нчы елларда ук Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Вахитов сыннарын ясаган булган. Шулай ук Бакый ага белән бер чордарак югары белем алган С.Ахунның да 30–40 нчы елларда эшләгән скульптура эшләре мәгълүм (С.Ахун – 1958 елны Казан үзәгендә ачылган Тукай һәйкәле авторларының берсе). Инде ераккарак, Болгар чорларына китеп карасак, безнең борынгы бабайларның да ташка бизәк, орнамент ую сәләте шактый ук югары булуына инанасың. Аларның кайберләре борынгы корылмаларда һәм эпиграфик һәйкәлләрдә безнең көннәргәчә сакланган. Әмма тарихи сәбәпләр аркасында озак дәверләр буе бу традицияләрне тергезүче, яңа шартларда дәвам итүчеләр булмаган. Һәм, ниһаять, Вакыт, Замана үз кешесен тудырган. Бакый ага, үзенә багышланган тарихи миссияне тоеп, анда-монда сибелеп яткан ташларны җыйды да, билгеле бер тәртипкә китереп, милли сынлы сәнгатьнең гаҗәп диварын корды... Бер уйласаң, гаҗәп: без белгән скульптура сыннарының күбесен, асылда, пенсия яшенә җиткәч, соңгы 30 ел эчендә ясады бит! Туган җир туфрагы аның икенче яшьлеген кайтарды шикелле. Бу феноменаль хәл аның шәхесенә замандашларының тирән ихтирамын тудырды. «Гаҗәпләнәм безнең Бакыйга! Һәр әсәре аның вакыйга!» – дип язып чыкты Сибгат Хәким. Әйе, болары шулай. Соклану бу очракта Бакый ага мисалында аклана, чөнки горурланырлык ныклы нигез бар. Ә гомумән алганда, безнең рәсем сәнгатендә, бигрәк тә сынлы сәнгать өлкәсендә, тынычланырга, бик югары биеклекләргә ирештек дип әйтергә иртә әле. Дөньяда Луврлар, Прадолар, Уффицилар, Эрмитажлар, Ватикан музейлары бар, төрле кыйтгаларда меңәр еллап тарихлары булган гүзәл сыннар бар...

Бакый ага үзен бәхетле язмышлы кеше дип саный торгандыр. Тәгаен, шулайдыр. Яшәү шатлыгы, хезмәт ләззәте белән, халык мәхәббәтен тою белән... Күпме җир-су күрелгән, күпме кешеләр белән аралашылган, хәят чишмәсеннән ачысы да, төчесе дә күп татылган. Күрәсең, гомер яланын үткәндә сибелү-чәчелүләр дә булган. Бу аның урын алыштырып төрле-төрле җирләрдә яшәвендә дә, һәрберсенә кимендә берәр гомер кирәк булган жанрларга алынуында да чагыла. Сәнгатьнең бер төренә нигез салырга алынган кешенең шул нигез тирәсендә гомер буе басылып эшләве дә табигый булыр иде. Нишлисең, «Сибелә чәчәк» җырындагы шикелле, сибелү-чәчелүгә дучар булган халык язмышы аны да читләтеп үтмәгән... Кызганыч, кайбер фундаменталь хезмәтләре инде кайтмаска югалган. Әйтик, заманында Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе павильоннарындагы монументаль композицияләр, диарамалар, рельефлы бизәкләр. Балхаш бакыр заводы сарайларындагы бизәкләр һәм сыннар да нык таушалганнардыр инде... Ата кеше үзенең ишле балалары белән бергә булганда аерата горур һәм мәһабәтле күренгән кебек, иҗатчы да үз «балалары» – әсәрләре исән-имин бер ышанычлы төштә тупланган очракта көчлерәк. Һәрхәлдә, Бакый аганың замандашлары булган Пикассо, Сарьян, Дали, Эрьзялар мисалы шул хакта сөйли. Әлеге бөек художниклар нәселеннән булган Бакый ага Урманченың да меңләгән әсәрләрен сыйдырырлык, аңа һәрвакыт халык килеп йөрерлек берәр бина табылыр әле Казанда. Әйтик, Кабан күле тирәсендә җыйнак кына берәр бина калкыр. Моның чынга ашуына бик тә ышанасы килә.

Һәр зур иҗатчы Мәңгелек белән әңгәмәләшергә омтыла. Халыкка хезмәт итү ул – Мәңгелеккә омтылу дигән сүз дә. Остага исемне дә Бакый – «мәңгелек» дип кушканнар. Бик белеп кушканнар. Һәм ул гомере буе шушы исемгә лаек булырга тырыша. Без, Бакый ага,

Сезнең талантыгызга сокланучылар, гомер һәм иҗат бәйрәмегез белән котлап, инде ерак калмаган 100 яшьлегегезне дә бергә-бергә үткәрү уе белән яшибез, дөньяда яшәвегез, хезмәтләрегез өчен рәхмәт әйтеп, замандашыгыз булуыбыз белән горурланабыз.

*1987*

## *ЯНУ ЙӨРӘКТӘН БАШЛАНА*

Татарстан китап нәшрияты әле күптән түгел генә «Чистопольские страницы» исемле калын бер җыентык чыгарды. Анда сугыш чорында эвакуациядә яшәгән язучыларның Чистайда иҗат ителгән әсәрләре, туганнары, якыннары белән язышкан хатлары, истәлекләре урнаштырылган. Үзләренең фоторәсемнәре дә, яшәгән йортларының сурәтләре дә бар. Арада зур, мәшһүр исемнәр шактый. Дөресрәге, шул хәвефле елларда исән-сау калып, совет әдәбияты елъязмасына ныклап кереп урнашкан кешеләр. Күп көч куеп, шактый мул искәрмә-комментарий белән баетылып, яхшы кәгазьдә 45 мең данә итеп чыгарылган бу басма, һичшиксез, игътибарга лаек. Хәер, матбугатта бу китапны хуплаган рецензияләр басылгалады да инде.

Шушы китап геройларының Чистайдагы тормыш рәвеше белән танышу дәвамында икенче бер параллель уй миемне бимазалап торды: ә бу вакытта турыдан-туры сугыш кырында, алгы сызыкта, партизан отрядларында көрәшкән яисә концлагерьларда газап чиккән иптәшләрнең, шул җөмләдән язучыларның хәлләре ничегрәк булды икән? Сугыш дигән үлем уенында тормыш, яшәү, киләчәк өчен көрәшкән кешеләр беренче чиратта алар бит! Нинди генә экстремаль шартлар булмасын, туплар тынган арада алар да иҗат иткән, көндәлекләр язган, туганнарына, дусларына хатлар, истәлек фотоларын җибәргән... Турыдан-туры сугышта катнашкан – ил өчен бердәнбер гомерен биргән яки җиңү шатлыгын татып, исән кайтырга насыйп булган өлкән каләмдәшләребезнең фронт чорларын чагылдырган материаллардан (әсәрләр, хатлар, мөрәҗәгатьләр һ.б.) бер күркәм басма чыгарырга иде бит. Иң беренче булып әнә шул китап дөнья күрергә тиеш иде, безнеңчә. Байтак республикаларда йөреп-күрүемнән чыгып әйтәм: безнең язучылар сугышта чагыштырмача иң күп санда катнашкан. Кайтмый калып, мәрмәр тактага уелганнарның исемнәре шактый ук озын безнең... Әйе, бүгенге тыныч тормышыбыз өчен шәһит киткән әтиләребез, бабаларыбыз хатирәсен онытырга һич тә хакыбыз юк. Көрәш һәм үлем кырларыннан безгә ирешелгән һәм әлегәчә сакланып калган һәр документ, кәгазьгә төшкән һәр сүз яңа буыннар өчен изге васыять саналырга тиеш.

Күңелне әнә шундый уйлар биләгән көннәрнең берсендә «Казан утлары» журналының 10 нчы санында (1987) басылган бер яңа әсәргә тап булдым. Ул – шагыйрь Зиннур Мансуровның «Балкыш» дигән поэмасы. Автор төп исем янына кечерәк хәрефләр белән болай дип тә өстәгән: «Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар». Димәк, әсәр Х.Мөҗәйгә бәйләнешле. Мөҗәй... Әдәбият тарихын белгән кешеләр өчен таныш исем, якты исем. Шагыйрь Мөҗәй. Полковник Мөҗәй! Ул әле генә исемнәрен атамый гына әйтеп узылган каһарман улларыбызның берсе бит, халык горурланырлык шәхесләребезнең берсе! Димәк, әлегә хәтеребез исән, легендар затларны онытып ук бетермибез икән. Соңгы 10–15 елдагы әдәби елъязмабызга әйләнеп карасак, батырларча һәлак булган фидаи каләмдәшләребез турында беркадәр әсәрләр барлыгын күрербез. Әйтик, Р.Харисның Җәлил һәм аның көрәштәшләренә, Ф.Кәримгә багышланган шигырь цикллары, И.Юзеевның шул ук Мөҗәй турында «Язылмаган поэма»сы...

Мин әле бу очракта тезмә үрнәкләрнең кайберләрен генә искә төшердем, һәм менә тагын Хәйретдин Мөҗәй исеме белән бәйле яңа әсәр. Чыннан да, яңамы ул, рух хәзинәсен баетыр дәрәҗәдәме? Ни әйтсәң дә, инде моңарчы матбугатта басылып чыккан көндәлектән җимләнеп язылган бит. Әнә шундый шикләнү катыш кызыксыну белән укыдым мин бу поэманы. Бер укыдым, тагын берничә кабат күздән кичердем. Чын мәгънәсендә кызыксындырды. Үзегенә дә үтеп керә алдым шикелле. Материалны күбрәк белү теләге уянып, Х.Мөҗәйнең «Сугыш язмалары»н яңадан җентекләп өйрәндем, берочтан аның бик үк зур булмаган әдәби мирасы белән дә янәдән танышып чыктым. Шуннан соң гына поэманы тирәнтен аңлый алдым, үземчә бәяләдем дип исәплим. Файдалы, мәгънәле шөгыль булды бу минем өчен. Беренчедән, Х.Мөҗәй шәхесенең зурлыгына, зирәклегенә инандым; икенчедән, Зиннур Мансуровның

шагыйрь буларак яңа якларын, яңа мөмкинлекләрен ачтым, үзенә генә хас фикерләү рәвешенең камилләшә баруын күреп сөендем.

Бу очракта шунысын да әйтеп узарга кирәк: безнең әдәбиятта сугышның алгы сызыгыннан торып язылган, югары иҗади кыйммәткә ия булырлык әсәрләр бик үк күп түгел. Алар – беренче чиратта М.Җәлил, Ф.Кәрим шигырьләре, Г.Әпсәләмов, Г.Кутуйларның хикәя һәм нәсерләре... Әлбәттә, кайбер исемнәр белән әлеге исемлекне озынайтып та булыр иде. Әмма бүгенге укучы кулына килепирешкәннәре күп түгел. Ә менә чын мәгънәсендәге сәргаскәр, зур хәрби дәрәҗәле өлкән офицерның язмалары безнең өчен аеруча әһәмияткә ия. Андый затның күзәтүләре, теге яки бу хәрби ситуацияне бәяләве, гомумиләштерүләре үзгәрәк кабул ителә. Максатлар бер – җиңүгә омтылу булса да, рядовой солдат белән полк командирының идарә итү, перспективаны күзаллау һәм җаваплылык җәһәтеннән аерымлыклары да аз түгел. Өлкән командир масштаблырак күрә, дәрәҗәсенә карап, әгәр ул хикмәт иясе дә булса, сугыш кебек фаҗигаләр аренасында яшәү белән үлем турында тирәнрәк фәлсәфи нәтиҗәләр ясый. Бу уңайдан Х.Мөҗәй командир һәм язучы буларак безнең горурлыгыбыз саналырга хаклы. Кайбер халыклар, әгәр андый каһарманлык күрсәткән уллары булса, аларның исемнәрен мәңгеләштерү буенча күп нәрсәләр эшләр иде...

Әнә шул легендар шәхесне янә искә алып, аны тагын бер мәртәбә халык күңеле мәйданына чыгарып, Зиннур Мансуров бик кирәкле изге эш башкарган. Кешеләрне чын яратып, аларның каһарманлыгын әләм рәвешендә күтәреп кенә яңа рухи үрләр яулап була. Дөрес, шагыйрьнең максаты Х.Мөҗәй шәхесенә игътибар юнәлтү генә түгел. Әлеге әсәр – моннан 45 еллап элек язылган сугыш көндәлегенең хуҗасы белән бүгенге көннән торып әңгәмәләшү, каһарманның гакыллы сүз сөрешен дәвам иттерү; ул вакытта бер яссылыкта булып та, хәзер исә бүтән төсмерләр алган проблемалар турында уйлану, яшәештәге мәңгелек сорауларга җавап эзләү... Гомумән, Зиннур Мансуров – мәңгелек темалар – рух проблемалары турында киңәеп уйланырга омтылучан шагыйрь. Иҗатчының мондый сыйфаты аның күпсанлы мәкалә-эсселарында да ачык тоемлана. Яшәешнең байтак мәсьәләләрен колачлаган «Балкыш»та исә каләмгә иркенлек киң бирелгән.

Жанры ягыннан поэма-рулада дип исемләнгән әлеге әсәр шигърилек җәһәтеннән тыгыз, укучыга беркадәр яңа информация бирә торган кыска гына кереш сүздән һәм унбер бүлектән тора. Һәр бүлеккә эпиграф-башлам рәвешендә Х.Мөҗәй көндәлегеннән берничә җөмлә китерелә. Алар – шигъри бүлек-кишәрлекләргә ни чәчелгәнен белдерүче язулы флагчыклар, үзенә күрә юл күрсәткечләр шикелле. Әмма шагыйрь әлеге кишәрлекләргә беренче чиратта үз уйларын, үзенең шатлыклы яки борчулы фикер орлыкларын чәчкән, шулай итеп үзенең иҗтимагый-эстетик карашларына ярашлы шигъри басуын тудырган. Поэманың тел төбе бүгенгегә тоташкан, байтак кына канатлы тәгъбирләр үткәннәр аша киләчәккә төбәлгән. Әйтик, рәсем-сурәтләре безнең көннәргә килеп җитмәгән бөек шәхесләр – Кол Гали, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйриларны искә төшерә дә, шагыйрь болай дип әйтеп куя: «Кара шәүләң катып калса үлмәс халык күзендә?!» (Киная, кисәтү бит бу!) Икенче бер урында Х.Мөҗәй көндәлегендә язылган окоптагы ак әтәч турында уйланып, шагыйрь борынгы Кырымдагы фаҗигаи хәлләрне искә төшереп ала. Яки солдатларның, кырдагы салам эскертләрен яндырып, шулар төтене ышыгында дошман күзеннән эз яздыруын күз алдына китереп: «Илеңдәге төтенгә дә була икән таянып!» – ди. Мәгълүм хакыйкать: фидакарь җаннар өчен һәр заманда да көрәш мәйданы киң.

Яный барлык шагыйрьләргә
бәрелешнең яңасы.
Ватан исән калсын өчен
кемнәргәдер – атыласы,
кемнәргәдер – асыласы,
кемнәргәдер – янасы...

Ә яшисе дә килә! Һәр җан иясе өчен иң кадерлесе яшәү бит. Яшәү, мәхәббәт, сәгадәт... «Ташбилгем дә калмас, бәлки, ядка алып еларга. Яратудан янды, диеп, я-ра-ту-дан ян-ды, диеп аңлатырсыз елларга!..» Көрәшченең гомере тоташ яну. Бу мәгълүм аксиома Хәйретдин Мөҗәй мисалында көчерелмә мәгънәдә түгел. Шуңа күрә дә Зиннур Мансуров бу тетрәндергеч фаҗига турында төрле аспектта, кайта-кайта ассызыклап яза: «Безне күмер хәлендә дә

танучылар табылыр», «Йокса йоксын тәнгә корым – каралтмасын күңелне», «Без... яңадан яралганнар мәгъмүр Болгар көленнән!», «Тамырларым, бикфорд кебек, янып килә йөрәккә!..» Әйе, йөрәк маен сыздырып, эчтән янып язылган юллар болар.

Максатлы фикер үсешенә һәм драматик ситуациягә буйсындырылган уңай мисалларны тагын бик күп тезәргә мөмкин. Китерелгәннәре дә җитәр кебек. Максатым поэманы сүтеп-җыеп анализлау түгел, әсәрне уку халәтендә алган тәэсирләремне уртаклашу гына. Миңа калса, Зиннур Мансуровның бу әсәре аның бүтән поэмаларына караганда халыкчан теле, анык, төгәл стиле, кешелекле-гуманистик рухы белән үзгә бер уңай якка аерылып тора. Гомумән, «Балкыш» шагыйрь иҗатының үсешен күрсәтерлек әсәр булып чыккан. Поэманы уку процессында авторга әйтәсе килгән киңәш-теләкләр дә уянгалады. Әйтик, авыллар язмышы турында уйлану рәвешендә язылган бер бүлек булса да начар чыкмас иде. Х.Мөҗәй язганча, сугыш бәрелешләре күбрәк авыллар, хуторлар тирәсендә бара. Күпме авыллар кырыла!.. Сугыш бетеп, 30–40 еллар үткәч тә, тыныч вакытта да бик күп вак авылларны массовый төстә бетердек бит... Гомумән, авыл турында бергәләп уйга калырлык фәлсәфә чыгарып була. Сугыш язмаларында да андый бүлеккә ярарлык отышлы юллар бар.

Хәйретдин Мөҗәй үзенең атаклы сугыш язмаларын кырык яшен тутыргач язган («Җилкәдәге кырык яшем җитәр әле, хуш, әйдә, ахыр чиктә газиз халкым гомеренә кушарга»). Ә Зиннур Мансуровка әле кырык ук тулмаган, әмма инде бу чиккә якынлашып килә. Түгәрәкләп әйткәндә, яшьтәшләр, кырыктагылар уйлануы алар: көндәлек үзе дә, яңа язылган поэма да. Тик бу яшьтәшләр арасында ярты гасырга якын вакыт ята. Замана бүтән, шартлар бүтән, буыннар бүтән. Шулай ук һәр ике язмада да уртаклыклар байтак: ил, халык язмышы турында, киләчәк хакында уйлану...

*1987*

## *БАР ШУНДЫЙ БЕР БАТУЛЛА...*

Моннан ике айлар элек Академия театрының иске бинасында яңа спектакль күрсәтелде. Татар дәүләт драма һәм комедия театрының чираттагы премьерасы. Чираттагы булса да, бик үк гадәти дә түгел иде ул, чөнки спектакль бөек Тукай турында (шагыйрь турында уңышлы зур әсәрләр әлегә аз), икенчедән, әсәрнең авторы да, режиссеры да бер үк кеше – театрның баш режиссеры, күренекле язучы Батулла. Шуңа күрә дә, табигый, кызыксыну көчле иде.

Пьеса әллә ни мавыктыргыч сюжет-вакыйгага корылмаган. Бөтен бер спектакль бер урында – Тукай бүлмәсендә («Болгар» номерларының берсендә) бара, катнашучыларның да тормыш тәҗрибәләре бер чамадарак, һәммәсе дә диярлек 20–30 яшьлек кешеләр, замандашлар. Алар алай шаккатырлык тамаша да кылмыйлар, экстремаль ситуацияләр дә кичермиләр, бер үк мизансценада дигәндәй, шул бер бүлмәгә керәләр, сөйләшәләр, чыгалар, янәдән керәләр... Тамаша вакыт ягыннан да чикле – Тукай гомеренең берничә көне. Шулай да тәнәфессез сәгать ярымга сузылган спектакльне тамашачы, шылт та итми, дикъкать белән карый, күңеле белән сәхнә геройларының язмышын кичерә.

Тамашачыны шундый әсирләнгән халәттә нәрсә тота соң? Вакыйгалар өермәсеме? Юк шикелле. Дөрес, вакыйгасыз спектакль булмас, алар Батулла әсәрендә дә бар. Әмма бу очракта хикмәт – фикердә, фикер динамикасында, фикер сюжетында. Бөтен спектакль буенча лейтмотив булып бара торган төп фикер – халыкның киләчәге нинди булыр? Мондый фикер, аңы ни югарылыкта булуына карамастан (әгәр инде ул бөтенләй үк маңкорт булмаса), һәркемне теге яки бу дәрәҗәдә борчый, уйландыра. Спектакль персонажларының бөтенесенең диярлек сүз сөреше, асылда, шул хакта. Хәтта тискәрерәк дигәннәре дә халык киләчәге турында үзенчә фараз итә, үзенчә юрый. Тукай, Ядкәр (Х.Ямашевны хәтерләтә), Анабәк (Ф.Әмирхан күз алдына килә) халык язмышы мөнәсәбәтенә бер платформада булсалар, шул ук мәсьәләгә Байның үзгә карашы, Ханымның аңлавы бүтәнчәрәк... Әмма берсе дә битараф түгел, һәрберсенең үз карашын акларлык дәлилләре дә бар. Менә шушы бер мәсьәләгә – халык язмышы проблемасына төрле карашларның бәрелешүе, көрәше спектакльне спектакль итә, тамашачыны киеренке хәлдә тота да. Ирексездән сорау туа: төп каһарман Тукай образы

ничек бирелгән соң? Җавабы үзенә бер катлаулы. Чөнки Тукайның шәхесе, кыска гомере һәр җәһәттән шактый җентекле өйрәнелгән, һәрберсенең күңелендә аның үзебез белгән, үзебез аңлаган образы бар (Ә.Фәйзинең «Тукай» драмасы һәм шул ук исемдәге романы, И.Нуруллинның шагыйрь турындагы җитди хезмәте, Т.Миңнуллин, Р.Ишморат, И.Юзеев пьесалары аша бөек шагыйрьнең без шактый ук җанлы образын чамалый алабыз инде). Миңа калса, «Сират күпере» драмасында драматург һәм уйнаучы артист шагыйрь гомеренең соңгы көннәрен ышандырырлык, табигый итеп күрсәтергә ирешкәннәр. Гасабилана шагыйрь, гомер чигенең котылгысыз якынлашуын сизә, яшәештә кылган гамәлен барлап йомгак ясамакчы, яшәвенең мәгънәсен аңламакчы була, идеалларының һәм мәхәббәтенең челпәрәмә килүен тоеп тетрәнә, шул тетрәнүләрен кешеләрдән яшермәкче дә була. Дөнья бәясе торырлык шәхеснең гомер шәме сүнеп килә... Яшь артист Рафил Сәгъдуллин (бу аның баштанаяк сәхнәдән чыкмый уйнала торган беренче зур роле) үз ролен уңышлы башкарып чыкты дияр идем. Рафилнең Тукайга тышкы охшашлыгы, ихласлыгы, тырышлыгы үз эшен эшләде, сәхнәдәге Тукайга без ышандык. Әҗәл угы төбәлгән чакта да Тукайның көрәшче рухы җиңелергә теләми. Тукай – үз чорының Бөтенроссия масштабында иң зур шагыйрьләрнең берсе. Моны сәхнәдә ныграк тоясы килә. Яшь артистның мондый зур рольне камил итеп башкарып чыгарга тормыш тәҗрибәсе, эрудициясе дә җитеп бетмидер. Бәлки, драматургның үзенә дә шагыйрь образын тагын да баетыр өчен кайбер кирәкле штрихлар өстәргә дә мөмкиндер.

Тукай образының уңышын тәкъдир иткән хәлдә, спектакльдәге иң отышлы һәм хәтердә кала торган образны мин Шәүлә дип санар идем. Провокаторлык, шымчылык, хыянәтнең гомумсимволын белдергән җыелма образ ул Шәүлә. Дистә еллар буе сәхнә түреннән муллалар һәм комганнар белән шактый җитди көрәшсәк тә, Шәүлә кебек куркыныч көчне бөтен тулылыгы белән күрә алган юк иде әле сәхнәдән. Шәүлә – чыннан да мәкернең мәкере, дошманның дошманы! Тарихи яссылыктан караганда, Шәүлә һәрвакыт безнең яшәешебездә булды, төрле битлекләргә кереп, халыкның фидакарь уллары белән янәшәдә яшәде, җаен туры китереп, аларны чагып торды. Халыкның бөек уллары галереясын күздән кичерик. Шул ук Тукай, Ямашев, Кариев, Ибраһимов, соңрак Тинчурин, Туфан... Безнең мәдәният тарихын Шәүләләрсез күз алдына китереп булмый. Тормышчан тип, безнең сәхнәләр өчен яңа тип. Ихтимал, Шәүлә монологларында бәхәсле моментлар да булырга мөмкин. Ни генә булмасын, Шәүлә спектакльдә иң көчле образ булып чыккан. Артист та оста башкарды аны. Марсель Җаббаров бу рольдә үзенең талантлы, җитди артист икәнлеген тагын бер кат раслады. Без караган спектакльдә катнашкан байтак артистларның яхшы уеннары турында әйтергә мөмкин. Исламия Мәхмүтова, Фатин Фәтхуллин, Тимер Зиннуров... Спектакльне тәфсилләп анализлаган, артистларның уеннарына, рәссам Әхәт Закировның эшенә чын бәя бирә алырлык белгечләрнең абруйлы рецензияләрен алга таба, шәт, укырбыз әле. Спектакль турында фикеремне пьесаның бер каһарманы сүзләре белән, дөресрәге, гарәпләрнең «тәсмәгы бин Мәгайди хәйрен мин эн тәраhе» дигәннең киресен белдергән «Мәгайдыйне, күреп белүгә караганда, ишетеп белүең яхшырак» дигән сүзләр белән тәмамлап, бу спектакльне үзегезгә барып карау кирәк, дип әйтәм.

«Сират күпере» – Р.Батулланың соңгы, дөресрәге, чираттагы соңгы әсәре, театр сәнгате өлкәсендәге билгеле бер уңышы, исемен драматургиядә тагын да ныгыткан җитди хезмәте. Бу көннәрдә Батулланың иҗат эшчәнлегенә 25 ел тула. Әдәбият һәм сәнгатькә сарыф ителгән чирек гасыр гомер! Шушы уңай белән әйтелгәннәргә өстәп, замандашым турында, шәхесе һәм иҗаты турында янәдән бер-ике сүз әйтергә телим.

Галиҗәнап Табигать Батуллага күпне биргән. Буй-сынны да, саулыкны да, сәләтне дә. Теләсә, сыздырып гармун уйнап җибәрер яки курай тартыр, теләсә, җыр сузар яки эч катарлык көлке мәзәкләр сөйләр, теләсә, пьеса язып «тиятр» куяр, кирәк дисә, әкият чыгарыр яки хикәя-повестьлар язар, хаҗәтен күрсә, мөгаллим булып студентлар укытыр... Бүтәнчәрәк, рәсмирәк әйткәндә, ул – язучы, драматург, режиссер, артист, педагог... Шулай күптөрле эшләрне, һөнәрләрне җиренә җиткереп, заманына лаек итеп башкарып чыгып була микән соң, диярләр. Әнә бит, янәсе, каз да йөзә дә, оча да, җирдә дә йөри... Әйе, Батулла төрле якка сибелеп, төрле-төрле жанрларда эшләп «чәчелә», диючеләр дә бар. Моңа каршы килеп, күпкырлы талантка ия шәхесләр булмыймыни дияр идем. Тарихта бар бит андыйлар да. Батулла – әнә

шундый бәхетле өлешкә ия кеше, вакытның кадерен, хезмәтнең тәмен белеп эшли белүче булдыклы кеше, егет кеше. Кайсы өлкәдә рейтингы өстен икәнен Вакыт галиҗәнаплары әйтер.

Батулла иң әүвәл үзен хикәяче итеп танытты. Аның беренче дөнья күргән китаплары да – проза әсәрләре. Хикәя өлкәсендә ул үзенең шактый оста язучы икәнлеген исбат итте. Ләкин ни өчендер аның кыска, әмма тирән мәгънәле хикәяләре тәнкыйть игътибарыннан читтә кала килде. Батулланың бөтен хикәяләре дә диярлек кинаяле, аларның һәрберсендә дә тел төбенә яшеренгән бер сер ята. Әнә шуны ача алсаң гына, хикәяләрнең төп мәгънәсенә төшенә аласың. Мисал өчен «Мираж» дигән хикәясен генә алыйк. Бер карасаң, бензиннары бетеп, чүл уртасында калган ике шоферның адашып йөрүләре генә сурәтләнә кебек. Ачыккан, хәлсезләнгән бу ике кешенең уйлары бер: бу чүл тозагыннан, үлемнән ничек тә котылу. Ә менә ничек? Берсе, бер юлдан китик, ди, икенчесе, миражга, офыкта күренгән матур «шәһәргә» таба барыйк, ди; анда бәхет, рәхәтлек, җиләк-җимеш, салкын су булыр, ди. Берсе шул миражга ышана, алдана, ә икенчесе алдагы матур шәһәрнең ялган икәнен белә, белгән килеш матур ялганга таба барырга мәҗбүр була... Яки аның «Соңгы чабыш» исемле кыска гына хикәясен хәтерлик. Әти-әнисен, авылдашларын сагынып кайткан Җәгүрне (Егорны) туган авылын капылт ташлап китәргә нәрсә мәҗбүр итте соң әле? Әллә хикәя кайчандыр бәйгеләрдә баш бирмәгән, бүген инде йончу хәлгә калган карт алаша турындамы? Хикәяне өстән генә укыган кешегә шулай тоелырга да мөмкин. Әмма хикәянең төбенә төшеп уйласаң, әсәр халык язмышы турында бит.

Батулла берзаман әкиятләр язарга ябышты. Бу өлкәдә дә аның байтак уңышлары бар. «Исемем минем Дүрткүз», «Куян баласы Нуяк», «Үлемсез егет», «Ташсуар патша» әкият-повестьларын яхшы дигән әсәрләр рәтенә керткән хәлдә, мин Батулланың иҗат югарылыгы, әдәбиятыбыз өчен үзенә бер ачыш булган «Алып батыр» маҗараларын аерып куяр идем. «Алып батыр» – әкият, олылар өчен дә, балалар өчен дә гыйбрәтле фәлсәфи әсәр. Һәр бүлек үзенә күрә бер проблема күтәрә. Бу әкиятләр төркеме повесть дип аталса да, роман хокукындагы күләмле проза. «Алып батыр» – татар халкының узганы, бүгенгесе, киләчәге турында уйлану ул. Бу әсәрне тел ягыннан да, этнография һәм тарихи яктан да, күтәрелгән актуаль фәлсәфәсе ягыннан да өйрәнерләр әле дип уйлыйм.

Соңгы 20–25 елдагы әдәби-мәдәни процессны Батулласыз күз алдына китерү кыен. Һәрхәлдә, безнең буын өчен бу шулай. Батулла әдәбият-сәнгать мохитенә 60 нчы еллар башында килеп керде. Ул елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр турында инде күп сөйләнде. Ә бит ул чордагы күтәрелеш бер шагыйрьләр иҗатында гына чагылып калмады. Сәнгатьнең бүтән өлкәләрендә дә көчле дулкыннар туды. Алыйк Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлап кайткан яшьләрне. Яңа бер сәхифә ачтылар алар театрыбыз үсешендә. Исемнәрен генә атап үтү дә күп нәрсә сөйли. Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Гөлсем Исәнгулова, Нәҗибә Ихсанова, Фирдәвес Әхтәмова, Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев... Тегe яки бу сәбәпле театрда артист булып төпләнмәгәннәре дә икенче җирлектә, икенче яклап бәреп чыкты. Шул когортадан Туфан Миңнуллин халык горурланырлык драматург булып үсеп җитте. Миргалим Харисов үз юлын журналистикада, әдәбиятта – тәрҗемә эшендә тапты. Батулла да әнә шул көчле төркемнән бит. Сәхнә тутырып уйнаучы артист булып китмәсә дә, барыбер театрдан, тамашачылыктан аерыла алмады Батулла. Миңа калса, ул нәрсә генә иҗат итсә дә, язганын йөзәрләгән, меңәрләгән тамашачы күзе белән карый, меңәрләгән тамашачы күңеле аша үткәрә кебек. Камерный түгел аның сәнгате. Аңа мәйдан кирәк, халык кирәк. Бу сыйфат аңа эчтә яткан асылы – артистлыгыннан килә булса кирәк. Әкият язса, әйдә телевизорга, мәзәк-миниатюра булса – эстрадага, озын пьеса икән – олы сәхнәгә... Шуңа күрә дә аның драматурглык ягы соңгы елларда аеруча үсте. Иҗади бәйрәмен дә ул сәхнә әсәрләре тупланган егерме биш табаклы калын китабы белән каршылады. Бу китапка аның халык арасында киң мәгълүм «Кичер мине, әнкәй», «Өчәү чыктык юлга», «Туйлар узгач» кебек әсәрләре тупланган. «Кичер мине, әнкәй» спектакленең язмышы аеруча бәхетле булды. Ул инде әллә ничә еллар буе ил театрларында куелып килә. Академия театры кебек олы сәхнәдә генә дә ул 500 тапкыр куелды инде. Җитди пьеса өчен үзенә күрә бер рекорд!

Әйе, исәпләсәң, кылган эшләре аз түгел икән Батулланың. Унбишләп китап чыгарган, егермедән артык пьеса язган, телевизордан дистәгә якын ел эчендә йөзәрләгән әкиятләр сөйләгән, режиссер сыйфатында дистәләгән әсәр сәхнәләштергән... Шуларга өстәп үз инициативасы белән җәмәгатьчелек тәртибендә башкарылган эшләр – популяр ШТМның

(шаяннар, тапкырлар мәҗлесе) хуҗасы-тамадасы, онытылмас «Ядкәр» кичәләрен оештыручы һәм башлап йөрүче, байтак каләмдәшләренең иҗат кичәләрен алып баручы... Җәмәгать эше өчен яну көчле Батуллада. Кушып, өстән әйтеп кенә булмый; әйткәнне, кушканны, яхшы дигән очракта, үтәп, теге яки бу дәрәҗәдә башкарып чыгып була. Батулла кушканны күндәм үтәп-башкарып утыручы түгел. Ул янып, бирелеп, фидакарьләрчә эшләргә яратылган кеше, бүтәннәрне үзе белән әйдәргә, аларның да йөрәкләрен үзенеке кебек яндырырга алынган кеше. Тынгысызлык, бирелгәнлек, иманлылык хас аңа. Батулла – безнең буынның бер бизәге, арабызда аның булуы үзе зур бер куаныч.

*1988*

## *АНЫҢ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ*

Яшь аермалары шактый булса да, университетта без бер чорда укыдык. Ике генә курска алда иде ул. Шулай да аралашып яшәдек дип әйтә алмыйм. Хәер, андый шәриктәшлек өчен мөмкинлек тә, андый хаҗәт тә булмаган аңарда. Бик табигый: без әле яңа гына мәктәп бетереп килгән, малайлыгы чыгып җитмәгән унҗиде яшьлек егет кисәкләре... Ә ул инде (60 нчы еллар башында) яше белән утыз ягына авышкан, күп җир-сулар күргән, төрле халыклар арасында яшәп, телләрен, гореф-гадәтләрен үзләштергән, кыскасы, бу дөньяның шактый «лаеш шулпасын чөмергән», азау теше чыгып, акыл утырткан ир-егет иде. Үз группаларындагы яшьтәшләре белән дә артык әвәрә килеп йөрмәде шикелле. (Ә яшьлектә күңелнең күңелен күреп, заяга вакыт уздыру өчен җайлар күп инде ул!) Тулай торакларда яшәп мәшәкатьләнмәде, әдәби түгәрәкләрдә яки кыз-кымыз җыелган җирләрдә, кайберәүләребез кебек, «даһи шигырьләр» укып йөрмәде...

Йөргән җире аның бүтән: фәнни китапханә иде. Көндәлек мәшәкатьләренә сарыф иткән вакытыннан тыш иң күп гомерен ул шул мирасханәдә – кульязмалар, борынгы китаплар дөньясында уздырды. Шуңа күрә ул студент булып бик хәтердә дә калмаган. Белеме белән дә, үз-үзен тотышы белән дә ул – укытучылар составы вәкиле сыман тоела иде. Безне укытып йөргән өлкән укытучы, доцент кебекләрдән аерылмый диярлек иде. Аерылса да, тарихи белеме, үткәнне һәм киләчәкне күзаллавы белән, фәкать уңай якка гына аерылгандыр.

Мәгарәгә бикләнеп белем алган Әбүгалисина белән Әбелхарисларны хәтерләткән аның бу үҗәт максатчанлыгы ул чакта без – яшьләр өчен бераз сәеррәк тоела иде. Әмма хәзер – еллар аша карагач, Миркасыймның бу яшәү рәвеше, омтылышы бик тә аңлашыла.

Аның тарих-филология факультетының татар бүлегендә уку белән генә чикләнмичә, өченче-дүртенче курслардан соң тарих буенча да белгечлек алуы, шул рәвешчә ике бүлекне бетерүгә ирешүе дә бүген яхшы аңлашыла. Халыкның узганын, хәзергесен аңлар өчен аның телен, әдәби фикерен белү никадәр мөһим булса, тел-әдәбиятның серләрен ныклап төшенер өчен шул халыкның тарихын да төпченеп өйрәнү зарур. Нәтиҗәдә Миркасыйм Госманов университетны һәм филолог, һәм тарихчы буларак, ягъни ике белгечлек алып тәмамлый. Бу исә аңа борынгы кульязмалар дөньясына иркенләп керергә мөмкинлек бирә.

Күңелләр ачык, өметләр зур булса да, мөмкинлекләре бик тә тар ул заманнар өчен мондый максатчанлык, фанатикларча фәнгә бирелү икеләтә, өчләтә зарур иде. Рус колониаль политикасының «прогрессивлыгын», совет чорында СССР халыклары ирешкән «казанышларның» әһәмиятен күперткән мөтәтарихчылар өчен шәп еллар иде алар. Каганлык, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын объектив өйрәнеп, тарихи дөрес бәяләмә биреп аңлату мөмкин дә түгел иде диярлек.

Кытайда туып үскән, Тянь-Шань тауларын айкаган, казакъ далаларын иңләгән, Борынгы Ефәк Юлларын кичкән, төрки халыклар тарихы буенча шактый «белем биштәре» булган «яшь студент»-галимгә нишләргә кала? Тагын да белемне тирәнәйтергә, фәнне-фән, тарихны тарих санап, хакыйкатьне расларга. Булган белем, җыелган акыл бер бәреп чыгар әле!

Һәм чыкты да! Без бүген Миркасыйм Госманов турындагы белешмәләрдә менә мондый мәгълүматлар укыйбыз. Ул – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, фәнни-тикшеренү археографик лабораториясенең гыйльми җитәкчесе, республикада чыга

торган абруйлы басмаларның редколлегия әгъзасы... Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Европа, Азия, Америка илләренә барып, төрле фәнни конференция-җыеннарда лекция-докладлар ясаучы халыкара масштабта мәгълүм галим. Ә бит 1958 елны Казанга килгәндә, аның монда бер таныш-белеше дә булмый. Казандагы гомерен, аның беренче төнен вокзалның көтү залындагы такта эскәмиясендә кунып уздырудан башлаган кеше ул («Казан утлары», 1992, № 4).

Бүгенгегә кадәр исән-имин яшәп, алтмыш еллык гомеренең кырыклап елын татарның рухи дөньясын өйрәнүгә багышлаган галим-әдипнең хезмәтләрен, берьяклы гына килеп, бертөсле бизмән белән генә үлчәп, бәһаләп бетерү һич мөмкин түгел. Хезмәтләренең бөтен нечкәлекләрен кертеп колачлап бетермәсә дә, Миркасыйм Госманов эшчәнлеген төп өч өлешкә бүлеп карарга була шикелле. Язма истәлекләрне, әдәби-тарихи чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару, ягъни археограф эшчәнлеге; популяр әдәби китаплар авторы буларак (ул 1970 елдан Язучылар берлеге әгъзасы), язучылык эшчәнлеге; һәм, ниһаять, фәнне оештыру буенча административ җитәкчелек эшчәнлеге.

Шушы шартлы схема буенча иң элек төрле җирләрдә, төрле елларда басылып чыккан кайбер китап исемнәрен атап китү дә урынлы булыр бу очракта. «XVII–XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары», «XIV–XVI гасыр Җүчи Улусының ярлыкау актлары», «Хөсәен Фәезхановның изге хыялы», «Каурый каләм эзеннән», «Үткәннән – киләчәккә»... Боларның кайберләре үтә фәнни стильдә язылса, кайберләре әдәби-популяр телдә иҗат ителгән. Шунысын да искәртеп узыйк: Миркасыйм Госманов татарча да, русча да, хәзергечә әйтсәк, ике дәүләт телендә дә иркен яза ала торган кеше. Миңа калса, бу китапларның иң мөһим ягы шунда: галим татар тарихын ничек булганча объектив яктыртырга тырыша.

Без хәзер үзебез дә әкренләп – кыйтгалардан кыйтгаларга җәелеп, ерак гасырлардан килә торган тарихыбызның тар Болгар җирлегенә генә сыя алмавын аңлый башладык шикелле инде. Бу юнәлештә безнең буыннар өчен башлап сүз әйтүче кешеләрнең берсе Миркасыйм Госманов булды. Җүчи Улусына, ягъни Алтын Урда чорына караган документаль истәлекләр хакында 1979 елда ук – татар болгарчылыкны күпләр дин-иман иткән заманнарда ук – зур күләмле фундаменталь монография язып, аны бастырып чыгару үзе хакыйкатькә омтылу юлындагы бер кыюлык иде.

Академик әзерлек һәм 30 еллап төрле архивларда, халык арасында йөреп, кульязмалар җыеп өйрәнү практикасы галимгә әдәби мирасыбыз, фольклор байлыгыбызның яңа катламнарын күтәрергә мөмкинлек бирә. «Хан кызы», «Яр-яр» җырларының яңа вариантлары, «Түләк-Сусылу» дастанының борынгы тексты табылу үзе ни тора!..

Язма хәзинәләребезгә тирән керү, элекке мәдәни хәятыбызны киңрәк иңләү, аның күренешләрен дөресрәк аңлау өчен җирлек тудыра. Бу хәл үз нәүбәтендә аңа табигый рәвештә татар тарихындагы байтак бөек шәхесләрнең мирасларына яңача караш ташларга, алар хакында торгынлык елларында да кыю-кыю фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Габделҗаббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла, Габдеррәхим Утыз Имәни, Ризаэтдин Фәхретдин, Сәит Вахиди... Бу бөек затларның шактый күләмле китапларының яки алар хакында махсус хезмәтләрнең дөнья күрүендә Миркасыйм Госмановның роле зур. Ул бу басмаларның кайберләренә кереш сүз язды, кайберләрен җыеп туплады, аларны текстологик яктан редакцияләде, искәрмәләр белән шәрехләде, кайберләре турында аерым китаплар язып чыкты.

Җегәре ташып торган бу талантлы шәхес әгәр төп вакытын әдәбиятка гына багышлаган булса, һичшиксез, данлыклы язучы булыр иде. Хәер, яшьрәк чакта – 1960–1970 елларда язылган китаплары да аның чын әдәби каләм иясе булуын раслый. Язучыларга багышланган белешмә китабында Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге хакында мондый сүзләр бар: «...язучы-галим, укучы яшьләр арасында тарих фәнен киңрәк пропагандалау максаты белән, фәнни-популяр жанрга мөрәҗәгать итеп, «Киек сукмакларында», «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китапларын бастыра. Халкыбызның борынгы тормышын өйрәнүче тарихчы-археологларның хезмәте, кызыклы табышлары, ачышлары хакында сюжетлы хикәяләр рәвешендә язылган бу китаплар укучыга тарих, археология буенча киң фәнни мәгълүмат бирүләре белән әһәмиятле». (Совет Татарстаны язучылары: биобиблиографик белешмә / төз.: Р.Н.Даутов, Н.Б.Нуруллина. Казан : Тат. кит. нәшр., 1986)

Үзебездән өстәп әйтсәк, яшьләр өчен үтә мавыктыргыч, өлкәннәр өчен бик гыйбрәтле китаплар алар!

Фәнне оештыру буенча җитәкчелек эшчәнлегенә килгәндә, табигый, һәр зур галим үз тарафдарларын, үз шәкертләрен, үз мәктәбен булдырырга тиеш. Ә мәктәп кадәр мәктәп булдырыр өчен, әлбәттә, тиешле шартлар һәм күпмедер дәрәҗәдә хакимиятлек тә кирәк. Өлкән укытучы, доцент, профессор, кафедра мөдире, проректор, академик... Болар – фәнни оештыру, үстерү эшендә зарур баскычлар. Хикмәт – кемнең күпме баскычка күтәрелеп, үз биеклеген ала алуында. Миңа калса, Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге өчен аның татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, бигрәк тә Казан университеты проректоры булып эшләгән еллары аеруча мәгънәле һәм нәтиҗәле булды. Ул – университетның җитәкче постында эшләгән елларда татар тарихы фәнен, гомумән, мәдәниятен үстерүдә байтак игелекле эшләр башкарылды. Турыдан-туры аның инициативасы һәм актив катнашы нәтиҗәсендә бу мәшһүр югары уку йортында «Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре» дип йөртелгән аерым факультет оешты. Милләттәш студентларыбыз ишәйде. 1988 елда КДУда махсус археографик лаборатория булдырылды. Шуның нәтиҗәсендә берничә дистә еллар халык арасыннан төрле шәһәрләрдәге архивлардан бөртекләп җыелган дистә меңләгән борынгы язма истәлекләренең сакланып калуына, өйрәнелүенә ирешелде. Саный китсәң, ул кылган яхшы гамәлләр байтакка җыйнала.

Галим белән бергә эшләгән, аның белән аралашкан, йөрешкән кешеләр яхшы белә булыр: ул – бик актив, холкы белән шактый кызу һәм кискен шәхес. Бер уйласаң, андый хәрәкәтчән, тынгысыз кеше бүгенге сәяси катаклизмнар заманында төрле социаль төркемнәр арасына керешеп, җәмгыять буталышының эпицентрында булырга тиеш тә кебек. Юк, Миркасыйм Госманов андыйлардан түгел. Аны фани сәясәтнең – сәяси кампанияләрнең теге яки бу ягына аудара алмассың. Ул көндәлек ыгы-зыгы күбеге белән мәңгелеккә кала торган кристалларны бик яхшы аера. Хәер, вакыйгаларны һәм тарихи төшенчәләрне объектив бәяли алмаган зат нинди галим була соң?! Ул бит белә: бөек империяләр һәм бөек шәхесләр булган. Алар туган, яшәгән, беткән... Дөньяны тетрәткән Каганатлар, Алтын Урдалар, гүзәл Сарай шәһәрләре булган – барысы да вәйранга чыкканнар...

Шул ук вакытта аерым халыкларның гына теләгенә, аерым төркемнәрнең мәнфәгатьләренә буйсынмыйча, буыннардан буыннарга күчеп кала торган, әһәмиятләрен югалтмый торган фактлар һәм факторлар да бар. Ниһаять, теләсә нинди шәхесләрдән, лозунг һәм тәгълиматлардан өстен хакыйкать, объективлык дигән нәрсә дә бар дөньяда. Иҗтимагый хәятның, тарихның эзлеклелеген, дәвамлылыгын шулар тәэмин итә. Болар белән дә кемдер даими шөгыльләнергә тиеш, уңга-сулга тайпылмыйча дигәндәй... Минемчә, Миркасыйм Госманов шундыйрак иманны тота. Өстәвенә профессор-остаз, мөдир-администратор өчен бу болганчык, нәфесләрне аздыргыч заманнарда моңарчы булган гыйльми кадрларны саклау, аларга алмашка яшьләрне әзерләү эше дә мөһимнәрнең мөһиме. Аерым предприятиеләр, институтлар гына түгел, төгәл бер дәүләтләр, империяләр җимерелгән, таркалган шартларда...

Болгавыр замана әледән-әле алга яңа сораулар куя. Болары аз дигәндәй, дөньяның үзе төсле искеләрен дә яңарта: безнең бүгенге яшәвебездән, кылган гамәлләребездән тагын берничә дистә, йөз еллардан соң ниләр калыр икән? Гомумән, без бик ерак дип санаган, моннан биш-алты йөз еллар элек булган хәлләр, чыннан да, бик еракмы соң?

Бер генә мизгелгә уйлап багыйк: сиңа кырык, илле яки алтмыш яшьме? Озын гомер кичтем, дисеңме? Юк бит, күз ачып йомганда үткән дә киткән!.. Шуңа күрә, Тарих дип әйтәбез икән, без аны син үзең күреп белгән бабаң яки атаң туган, яки фәлән инкыйлаб, социаль тетрәнү елларыннан гына түгел, иң кимендә меңәр ел элек булган чорлардан башлап өйрәнергә тиешбез. Бик гади, наив, әмма мәңгелек хакыйкать – үткәнсез бүгенге юк, бүгенгесез киләчәк юк.

Әгәр халык үзен җиһан танырлык милләт булып яшәргә тели икән, тагын бер бәхәссез хакыйкатьне искә төшерик: андый халык хезмәт итә белергә, тарихи истәлекләрен, бүгенге талантларын саклый, бәһали алырга, һәм, ниһаять, үзенең узганын бик яхшы белергә, киләчәген күзаллый алырга тиеш.

Безнең замандашыбыз, олуг шәхес, галим-әдип Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның бөтен иҗаты, ул барлап, саклап калырга тырышкан мирас байлыгы безне әнә шуңа өнди.

*1994*

## *ТУҢМА, ТУГАН!*

Кайчак миңа дөньяда ике Мөдәррис яши кебек тоела. Берсе – шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов (таныклыктагыча – Әгъләметдинов), икенчесе – гап-гади Җир улы Мөдәррис («мудрец», «әкә», «нәни гигант» дигән кушаматлары да бар). Утыз елдан артык миңа шуларның «икесе» белән дә даими аралашырга туры килә. Бу хәлгә мин офтанмыйм, киресенчә, сөенәм, үземчә язмыш бүләге дип кабул итәм.

Татар җаны булган һәр кешегә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов исеме таныштыр дип уйлыйм. Белеп җиткермәгәннәр булса, белерләр. Милләт буларак сакланып калырга һәм үсәргә теләсәк, рухи ориентирларны чамаларга тиешбез.

Мөдәррисне каләмдәш буларак шактый ук яхшы белеп, иҗаты турында үземчә бер фикер-мөнәсәбәт булса да, бу очракта аның хәяттагы һәм иҗаттагы төп остазларының берсе Рәис Даутов сүзләрен искә төшереп үтәсе килә.

«М.Әгъләмов – 70 нче еллар башында татар поэзиясенә үз шигъри аһәңе белән килеп кергән, традицион формада язса да, фикерләүдә һәм тасвирда индивидуальлеккә ия булган һәм шуны даими үстерә барган шагыйрьләрнең берсе. Аның поэзиясенә музыкальлек, классик поэзия һәм халык иҗаты традицияләреннән үсеп чыккан табигыйлек һәм эчке бер моң хас. Кечкенә генә поэтик деталь аша ул туган ил, халык язмышы, аның үткәне һәм киләчәге турында фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга омтыла һәм күп очракта моңа ирешә дә. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле табышлар белән аерылып тора. Форма ягыннан М.Әгъләмовның шигырьләре төгәл ритмикалы, шома, йөгерек телле».

Әйе, бу бәяләмәдә шагыйрь иҗатының төп сыйфатлары шактый төгәл әйтелгән. Мөдәррис Әгъләмов, утыз елдан артык татар шигъриятенә тугры хезмәт итеп, Тукай, Бабич, Туфан традицияләрен үстереп, үзен танымаска һәм санлашмаска мөмкин булмаган талант иясе икәнен раслады. Кайберәүләр кат-кат талпынып та үрелеп алалмаган Тукай бүләге билгесен дә беренче әйләнештә үк, китереп дигәндәй, күкрәгенә беркеттеләр аның. Юкка түгел, җырдагычарак әйтсәк, «юкка түгелдер». Миңа калса, аңа бу олуг бүләк милли идеяне эстетик идеал иткәне һәм шуны сәнгатьчә оста гәүдәләндергәне өчен бирелде («Тамыры кайда – безгә гөл шунда; Халкыбыз кайда – безгә ил шунда»; «Чит җирләрдә су коенам, И Туган Идел генәм! Чит җирдә су коенсам да, йөрәгем синең белән»; «Була вакыт: актарылып, яшьнәп, Болыт сыман шашып бушанабыз. Алдансак та, мәхшәр кичерсәк тә, Илгә, Киләчәккә ышанабыз!»).

Татарстан китап нәшриятында әле яңа гына чыккан «Иман тәрәз шакый» исемле сайланма шигырьләр китабын күздән кичергәч, бу фикерем ныгый гына төште. Мәгълүм хакыйкать: нинди генә акыл иясе булып, күңелеңдә нинди генә асыл фикерләр, хикмәтле уйлар йөртсәң дә, әгәр җаныңдагын кешеләр күңеленә күчәрлек итеп әйтеп бирә алмасаң, синнән Илгә-Җиргә әллә ни фәтва (мәгънә-файда) юк. Талант, бәлки, күңелеңдәген бүтән күңелләргә уйдырып сала белүдер әле ул. Мөдәррис – югары кимәлдәге профессиональ Шагыйрь, чын безнеңчә талантлы милли Шагыйрь, зур Шагыйрь!

Шагыйрьлекне белү өчен шагыйрьнең китабын уку җитә. Һәм, чыннан да, шул бик җиткәндер дә. Шагыйрьне кеше, адәми зат буларак белү шулхәтле хаҗәтмени? Ә белсәң һәм дә шактый ук яхшы белсәң? Адәмлек белән шагыйрьлекнең бер заттагы гармониясен күзәтү, әлбәттә, үзе бер кызык нәрсә. Мөдәррис Әгъләмовның шәхес буларак безнең даирәдә үзенең югары рейтинглы имиджы бар. Ул – әдәби мохитнең үзенчә бер Хуҗа Насретдины, Мюнхгаузены. Аның холкы, яшәү рәвеше, әйткән-сүткәннәре, язган-сызганнары турында мәзәкләр чыгаралар, мәҗлесләрдә сөйлиләр, «ул әйткән!» дип көләләр, тел шартлаталар... Хәтта кайчак кирәк-кирәкмәгәндә дә аның исеме белән авыз чайкыйлар. Әлбәттә, күп сүз арасында төрлесе була, кешене гел күтәреп әйтелгәннәр генә булмый... Кыскасы, Мөдәррис шәхесе күпләргә кызык табу өчен җирлек бирә. Күпләргә көлеп-елмаю өчен әнә шул кызык җиткән дә инде. Аларның кеше җанын тирәнтенрәк аңлар өчен вакытлары да, әллә ни теләкләре дә юктыр, бәлки. Шагыйрьнең яшәү рәвешен беркадәр белгән, мөмкинлеген һәм чикләнгәнлеген чамалаган кеше – аның язмышының шактый ук трагик контурларын да

күзалларга мөмкин. Замандаш каләмдәшләр арасында Ул – ялгызлыкның һәм сәях ireклелекнең бөтен төсмерләрен тойган, ләззәтен һәм газапларын йөрәге аша кичергән кеше.

Кайбер укучыларыбыз, мөгаен, экзистенциализм дигән фәлсәфи билгеләмәне беләбулыр. Ялгызлыкның, гомумән, ялгыз яшәү рәвешенең, Ялгыз Рухның үзенә күрә бер моделе ул. Нигә Аккош күленең үзенең берәр Сартры, Камюсы яки Бердяевы булмаска тиеш ди әле! Гыйбарә бар: Кеше ирексездән туа, гаҗәпләнеп яши, сагыш белән үлә. Һәрхәлдә, ике инстанциядә – Килүдә һәм Китүдә – Ул барыбер ялгыз. Фәкать гаҗәпләнеп, дөньяны танып-белеп яшәгәндә генә Ул үзе кебек кемнәрдер арасында...

Күз алдына китерегез: көзге төн, урман шавы, шомлы җил... утын һәм тәмәке төтене белән ысланган такта өй. Япа-ялгыз. Мич суынып бара... Нинди генә уйлар килмәс кешегә! («Төнлә уянам да... кинәт әле Барлыйм юкны-барны: Ашамлыкны барлыйм, киемнәрне – Әллә картаяммы? Хатларны да өр-яңадан укыйм, Укыйм шигырьләрне – Өр-яңадан сөеп, кача йокым, Әллә яшәрәмме? Әллә инде... Мәчегә бирәм сөт, Сөяк бирәм эткә. Бәлки, шулай баралардыр китеп Мәңгелеккә, мәңгелеккә...») Казаннан ун-унбиш чакрымда гына булсаң да, аерым бер Ялгызлык планетасындагы кебек хис итәсеңдер. Яки янә бер күренеш: кыш, су юк, газ-мазар юк, кисәк-кисәк электр уты да бетеп ала... Бөтен өмет сөремләнгән, яргаланган, әмма тышка зәңгәр төтене чыга торган бәләкәй мичтә, мич алдындагы җәйдән әзерләнгән коры каен утыннарында...

Хәер, хәлне алай ук драмалаштырмыйк әле! Аккош күле – болай үзе табигатьнең гүзәл бер почмагы ул. Ә Мөдәррис – аның хуҗасы! Язучыларның кечкенә генә авылчыгында кышын ул төп хуҗа. Ул монда хәят кичергән егерме ел эчендә әдәбиятыбызның нинди генә затлары яшәмәгән биредә! Х.Туфан, И.Гази, Г.Бәширов, С.Хәким, А.Шамов, Р.Ишморат, Н.Дәүли, З.Нури, А.Әхмәт, М.Мәһдиев, Р.Харис, Р.Мостафин, Р.Гаташ, М.Рафиков, Г.Рәхим, Ф.Шәфигуллин, Н.Юзиев... Ә яшьрәкләр, бүген актив иҗат итүчеләр ничаклы! Шагыйрь буларак Мөдәррис шушы Аккош күлендә «пешеп» җитте. Алда саналган язучылар анда «пропискада» яшәсәләр, алар янына кемнәр генә килеп йөрмәгән дисез! Сәйфи Кудаш, Мостай Кәриме дә, Фәридә Кудашева, Илһам Шакировы да, Михаил Львов, Давыт Көгелтине дә... Мөдәррис аларның кайберләре белән табындаш, әңгәмәдәш булган кеше. Кем белә, бәлки, ул кайчан да булса Аккош күле тарихын язып та чыгар әле! Әдәбиятыбызның байтак сәхифәләре анда язылган бит. Уйланганым бар: Мөдәрриснең, күңеле сәях булса да, иҗат йортларына, рәсми ерак сәфәрләргә чыкмавында (үземнең дә сәфәрләргә димләгәнем булды. Тукайның 100 еллыгында Әстерханга алып барырга теләдем, бармады. Бүтән тәкъдимнәр дә булды...), бәлки, Аккош күле аурасы гаепледер? Бәлки, шулай, кораб түшенә ябышкан кабырчык кебек, бер җиргә берегеп ятуның иҗатта үзгә мәгънәсе – нәтиҗәлелегә бардыр? Бусы бәхәсле булса да, ул бер нәрсәдә тәгаен хаклы: чәчелмәде Мөдәррис. Дулкынга кунып йөргән акчарлак кебек, бер жанрдан икенчесенә сикереп күчкәләк булмады. Шагыйрь булып килде әдәбиятка, шул юлын ныгытты, лазер нуры кебек, Шигырьдә үтәләй тиште. Яшьрәкләргә бер мисал булып гыйбрәт алырга ярый моннан.

Алда әйткәнемчә, без Мөдәррис белән утыз елдан артык бергә уралып яшибез. Соңгы елларда Аккош күлендә без иң күп аралаша торган каләмдәшләр бугай. Җәйләрен очрашмый, әңгәмәләшмәгән көн сирәк була. Шагыйрьнең төрле чагын күргәнем бар. «Җен алыштырган» чакларына да шаһит. Әмма соклану тойгысы күбрәк. Кайчак аның «вилла»сына керәсең (ишек ачык. Гомумән, үзе өйдә булмаганда ишегендә йозак торса да, ачкычы шул йозак янында ук булыр), йоклап ята Шагыйрь. Тимер караватта, бала ук булмаса да, үсмерләргә хас какча гәүдәле «нәни гигант». Йомышың булса да, уятырга кыймыйсың. Чыгып киткәч уйлап куясың: шушы малай сымак кына Шагыйрьнең юка иңнәрендә халык уй-гамьнәренең ничаклы йөге ята!

Гомумән, безнең гаиләгә ул табигый рәвештә үз кеше булып керде. Ятим булгангадырмы, акыллы, зирәк булгангадырмы, әти-әни аны үз баласыдай кабул итте, 60 нчы еллар башында Казанның Әмәт тавы итәгендәге йортыбызда Мөдәррис, «Коймаклар» шигырен шартлатып укый-укый, әнием пешергән коймаклар белән сыйлана иде. Соңрак, егерме еллап үткәч, Балык Бистәсендә ул бездә (дөресрәге, энекәшем Илдус хуҗа булган йортта) атналап, айлап яшәп-яшәп ала иде. Әти-әниләр мин кайтканга күбрәк сөенгәннәрдерме ул вакытта, әллә Мөдәррис кайткангамы, кистереп әйтә дә алмыйм. Әти-әни аны бик хөрмәт итте. Һәрхәлдә, Тукай бүләге алган китапны ул бездә торып язды, төзеде. Хәзер инде әни гүр иясе. Сөйләшкәндә, әти-әни

турында сүз чыкса, ул да аларны, минем кебек, «әти», «әни» дип искә ала. Шул чакта күзләрем дымлана...

Мөдәррис дустым! Менә Сиңа да 50 яшь тулды. Ирләр буларак турысын әйтик – байтак яшь бу! Бу очракта Сиңа «кояш гомере дә тели» алмыйм, бәхетне «кояш сүнсә дә, Әминә Җәлилне көткән шикелле» көт дип тә әйтә алмыйм. Алда салкыннар аяк киенгән черек көздә болай дим: «Туңма, туган! Туңма, рухдашым!» Синең җаның өшергә тиеш түгел. Әдәбият-сәнгать дөньясында Сине хөрмәт иткән дусларың күп. Күңел учаклары белән генә булса да без бер-беребезне җылытырга бурычлы. Шулай тиеш.

*1996*

## *ЧАТЫРТАУ — БИЕК ТАУ...*

*** * ***

Һәр кешенең күңелендә күпмедер шигырь-җыр ята. Шулай да чын мәгънәсендәге шагыйрьләр санаулы гына. Сүз шигырьне намус эше итеп, җәмгыять тормышының бер бик мөһим һәм үтә җаваплы бер эше итеп күрүчеләр, шул миссиягә фидакарьләрчә алынучылар турында бара, билгеле. Әдәбият – җаныңның олылыгын, иманыңның ныклыгын сынау мәйданы. Бу рухи сынау безнең шигърияттә аеруча үзгә дәрәҗәдә. Чөнки татар шигърияте – күпләрне күргән, төрле хәлләрне кичергән шигърият. Ул байтак гасырлар буена Вакыт Галиҗәнапларының мәрхәмәтсез җилләрен дә, халыкларны кан-яшькә батырган хан-патшалар дәверләрен дә үткәргән, яу-көрәшләрне, яну-тузуларны да күргән... Аның бүгенгесендә дә бүтән халыклар шигъриятенең куәтле вәкилләре белән алышырлык көчле шагыйрьләре бар. Бу гасырның соңгы чирегендә татар шигъриятенә килеп, үзенчә аваз салырга, булган хәзинәгә аз гына булса да өлеш кертергә батырчылык иткән һәр яшь кеше үзенең нинди зур сынау мәйданына килгәнлеген анык белергә тиеш. Марсель Галиев, миңа калса, моны яхшы аңлый кебек. Болай уйларга нигез бар. Беренчедән, ул шигърияткә шактый әзерлек белән килә; икенчедән, шигырь эшенең зурлыгын һәм четереклелеген тоеп, артык кабаланмый, ашыкмый, чәбәләнми; өченчедән, мөгаен, иң мөһиме – аның кешеләр белән бүлешәсе, шушы дөнья, тормыш өчен кирәк булган сүзләре, фикерләре, бай күңеле бар. Шагыйрь язмышының ил-дөнья язмышыннан аерылгысыз икәнлеген аңламаса, үзенең бер шигырендә ул болай дип әйтмәс иде: «Гел беренче булып Заман төби Шагыйрь белән чыккач дуэльгә!»

Марсель – Азнакай якларыннан. «Чал Уралның соңгы дулкыны булып, зәңгәр пирамидадай торган Чатыртаулар» (бу – Кырым Чатыртавы түгел, безнең төбәктәге Чатыртау!) төбәгеннән. Биографиясе – заманга һәм үз буынына хас биография – мәктәп, армия хезмәте, нефть предприятиеләрендә эшләү, университет... Соңгы биш ел эчендә Марсель Галиев – Татарстан Язучылар союзы каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре. Марсельнең поэзия эшенә ихлас күңел куеп, җитди рәвештә шөгыльләнә башлавына ун ел чамасы. Хәтердә: Марсель Азнакайда эшләгән елларында язучыларның Әлмәттәге бүлегенә еш килеп йөри иде. Кабинетта яки бакчадагы чирәмгә чыгып утырып шигырь укулар, фикер алышулар, киңәшләр, бәхәсләр һаман истә. Яшьлекнең тыелгысыз ашкынулары, татлы хыяллар, беренче шигырьләрне матбугатка чыгарасы килү теләге... Бик тиз генә бик күп итеп яхшы шигырьләр язып, бик тиз генә китап чыгарам дип йөргән беркатлы саф еллар инде артта калды. Бертөрле рәхәт кызышып, аҗаган кебек беренче балкып алулардан беренче китапка кадәр дистә ел чамасы вакыт үтте... Бәлкем, бу кадәр вакыт бераз озаграктадыр, чөнки гомер дигәннәре дә әллә ни озын түгел бит. Әмма Марсель өчен заяга узмады ул еллар. Бу елларда ул төпле белем алды, әдәби традицияләрне өйрәнде, кешеләрнең язу тәҗрибәләре аша үзенең иҗади мөмкинлекләрен ачыклады. Вакытлы матбугатта да шактый нәтиҗәле эшләде ул. Байтак санда мәкаләләр, зарисовкалар, рецензияләр, хикәяләр, шигырь цикллары бастырды. Алар арасында «Март», «Яшел соната» кебек парчалар белән беррәттән «Кар абагалар», «Ул чакта» кебек күләмле повестьлар да бар. Республикабыз матбугаты битләреннән тыш аның әсәрләре «Волга» журналында, «Молодая гвардия»

чыгарган альманахларда да урын алды. Шулай ук яшь язучыларның илкүләм зур җыеннарында (Яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсе, яшь шагыйрьләрнең X Бөтенсоюз фестивале һ.б.) катнашулар да аңа әдәбият турында да җитдирәк уйларга һәм иҗат офыкларының киңәя төшүенә булышлык иткәндер. Болар һәммәсе дә үзенә күрә беренче зур сынауга, беренче китапка китерә торган үсү баскычлары булды.

Безнең бүгенге шигърияттә төрле-төрле, үзләренең иҗат йөзләре булган талантлы шагыйрьләр күп. Аларның һәрберсендә үзенә генә хас берәр көчле як бар. Берәүләр сурәтләү чараларының бай, шигъри тукымада нәфис бизәкләрнең күп булуы белән кызыклы, икенче берәүләр телнең, хәтта аерым бер сүзнең мәгънә төсмерләрен, яңгырауларын оста файдаланалар, өченчеләр фикер-хис агышының эчке эмоциональ мөмкинлекләрен ачалар. Әлбәттә, эзләнүләрнең нәтиҗәлелеге беренче чиратта шагыйрьнең талантына һәм замана, җәмгыять куйган проблемаларга җавап бирерлек дәрәҗәдәге гражданлык позициясенә бәйле. Марсель Галиев шигырьләре рәсемле, сурәтле шигырьләр, уйлы-гамьле шигырьләр («Шүрәлеләр булып каеннарда уйнаклады учак шәүләсе...», «Таҗларына йомып ак кояшны, күл төбенә чумган төнбоек...», «Бу җаныңны чайкап алыр өчен, дөнья гүя сулар яраткан...», «Күңелемә сыйган бөтен Тарих убылып китә, һава упкыннары үткәндә...» һ.б.). Ул – интеллектуаль поэзия вәкиле. Примитив шигырьләр аңарда юк дәрәҗәсендә. Ул дөнья поэзиясенең яхшы үрнәкләре нигезендә иҗат итәргә омтыла. Дөрес, кайбер шигырьләрендә ул әлеге теләгән максатына ирешеп тә бетә алмый. Аерым бер шигырьләрендә инде моңарчы поэзиядә булган авазлар да ишетелгәли. Ләкин болар үзеңнең индивидуаль йөзеңне ачыклау процессындагы котылгысыз нәрсәләр. Нечкә тоемга, рәссам күңеленә ия булган Марсель Галиевнең нәкъ үзенеке генә булган байтак яхшы шигырьләрен дикъкатьле укучы аның китабын укыгач күрер, тиешенчә бәяләр дип уйлыйм.

Марсель Галиевнең беренче китабы. Авыр, ләкин татлы, газаплы зур иҗат юлына чыга егет. Хәерле юл аңа! Зур максатлар гына зур юлга чыгара ала. Һәр шагыйрь үз халкының бөтен рухи куәтен, бөтен рухи матурлыгын һәм бөеклеген күрсәтә алырга омтылырга тиеш. Шагыйрь – көрәшче дә, матурлык арттыручы да бу дөньяда. Кешелекле матурлык бик тә кирәк Җир йөзенә!

*1978*

*** * ***

Моннан шактый еллар элек бер өлкән каләмдәшем үз китабын мондый сүзләр язып бүләк иткән иде: «Кешеләрне ярату – авыр эш. Бу хезмәттә без фикердәшләр булып, бер юлда булсак икән!». «Эш» һәм «хезмәт» сүзләренең астына сызылган иде. Еллар узган саен шуңа инанам: бик тә дөрес әйтелгән бит! Безнең агай-эне өчен бигрәк тә... Әйе, әдип кешеләрнең кешелеген күреп, аны хөрмәтләргә, ихтирамларга, яратырга тиеш. Хәтта, әйтер идем, яшәргә котыртырга тиеш! Марсель Галиев моны бик яхшы аңлый! Кемдер, бәлки, җилкә җыерып, йөзен чытып әйтеп куяр: шул тәкәббер, эгоист Марсельме? Үтеңне чыгарырлык сарказмлы Марсельме? Шул «купык» мактанчыкмы? Әйе, шул Марсель Галиев. Шагыйрь, эссеист, прозаик, сатирик Марсель Галиев. Чынлап та, күпләребезгә караганда кеше рухын югарырак кимәлдә олылый белә ул! Әйдәгез, иҗатына багып (ә иҗат – критерий!), җыр текстларын гына искә төшерик: «Һаваларда торна тавышлары», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Көзге моң» – кеше рухының нинди генә тибрәнешләре юк аларда. Гомумән, болар классик җырлар, киләчәккә барачак затлы җырлар. М.Галиев соңгы елларда шигырьләрне сирәк яза. (Дәрдемәнд тә күп язмаган!) Әмма язганнары – җитлеккән чын шигырьләр. Юморист-сатирик буларак, кайбер язмаларына күз салыйк. Менә «Өмә» әсәре. Язучылар йорты янында өмә мәш килә. Кемнәр генә юк анда! Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Хәйдәр дә, Фәннур Сафин, Камил Кәримов, Рөстәм Мингалимов та... Күбесен чеметеп ала Марсель, берничә сүз белән характер чалымнарын сурәтли, кыскасы, көлә! Һәм яратып көлә!

Күптән түгел генә «Мәдәни җомга»да чыккан «фәлсәфи төкерек»не, бәлки, укыгансыздыр. Сүз, бер караганда, татар Мюнхгаузены, «нәни гигант» Мөдәррис турында гына шикелле, ә бит, асылда, юморескада бүгенге көннең актуаль мәсьәләләре күтәрелә, әдәби казанда

кайнаучы күпме шәхесләрнең холык-фигыльләре ачыла. Ә язмышы! Ирексездән елмаясың, иреннәрең генә түгел, кендекләреңә кадәр көлә! Дөньялар яктырып китә! Шуннан соң аны ничек кешеләрне яратмый дисең. Шулай шул, мәгълүм хакыйкать: үзеңне зурлауларын теләсәң, кешеләрне олыла; бергә-бергә үскәндә, илең дә зураер, куәтләнә-көчәя барыр.

«50 яшемә «Гасырлар китабы»мны әзерлим» дип берничә ел әйтеп йөрде Марсель. Ул китап менә-менә чыгып җитә булса кирәк. Ул әсәрнең журналда чыккан («Казан утлары», 1997, № 9; 1998, № 1, 2. – *Р. Ф.*) өлеше дә әдәби вакыйга булырлык. Миңа калса, шәхесләрнең әдәби портретларын мондый нечкәләп нәфис итеп иҗат иткән әдип юк иде әле бездә. Мәгънә дисәң мәгънә, образ дисәң образ бар... Ә теле? Аңлаган кеше өчен ул – яңа Фатих Хөсниебез бугай... Журналыбызның яңа саны белән танышып, аның туган ягы, Казанга, укыган университетына багышланган эссе-уйлануларын, Р.Яхин, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Р.Нуриев, Х.Сарьян һәм башкаларны иҗат кешесе һәм шәхес буларак тасвирлаган портретларын, нәкъ менә портретларын (бу очракта Марсельнең ару гына рәссам булуының да хикмәте бардыр) укыгач, әйткәннәремнең хак булуына ышанырсыз дип уйлыйм.

Моннан 30 еллар элек, 60 нчы еллар ахырында – әле Марсель беренче әдәби тәҗрибәләр ясый башлаган чорның шаһиты булырга туры килде миңа. Күпмедер йогынтым да булды бугай. Аның 1979 елда чыккан «Еллар чалымы» дигән беренче шигырь китабына язган кереш сүземдә мондый юллар бар иде: «М.Галиев – интеллектуаль поэзия вәкиле... Ул дөнья поэзиясенең яхшы үрнәкләренә йөз тотып иҗат итәргә омтыла». Шөкер, ялгышмаганмын. Дөрес, хәзер аның колачы киңрәк, шигырь белән бергә проза үрелеп бара, аларга фәлсәфи эсселары һәм юмор әсәрләре кушылып китә. Булсын, иң мөһиме: фикри һәм шәхси яктан алар зәгыйфь, мескен түгел, провинциаль түгел. Заман дәрәҗәсендә. Егерменче йөз ахырында язылган «Гасыр китабы» киләсе гасырда да дәвам ителер дип ышанасы килә.

Ә тәкәбберлеккә килгәндә, бу сүзне ничек аңлыйсың бит. Кемдер горурлыкны тәкәбберлек дип, күңел байлыгын бушатуны мактану дип аңлавы мөмкин. Әйе, Марсель үзгә холыклы шәхес. Кайчак бөердән юан тавыш чыгарып, каты бәгырьле кеше сыман күренгәләсә дә, белегез, бу – аның тиз яраланучан күңелен саклау чарасы буларак, үзенә күрә бер панцирь-калкан гына. Мин аның яшьле күзләрен дә күргәнем бар. Гомумән, ул бу дөньяны күбрәк дымсу күзләр аша күреп иҗат итә бугай...

*1996*

## *ҖИҢӘРГӘ ЯРАТЫЛГАН*

1963 елны Татарстан китап нәшрияты дәфтәр калынлыгындагы гына бер китапчык чыгарган иде. 36 битлек бу җыентыкка (титул битендә «балаларга шигырьләр язучы яшь көчләр җыентыгы» дип куелган) унике авторның, ягъни унике яшь көчнең шигырьләре (үзенә күрә иҗат үрнәкләре!) тупланган. Һәр авторга уртача өчәр бит туры килә. Кемнәр соң бу яшь шагыйрьләр? Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин (китаптагы тәртип буенча саныйм), Хәкимҗан Халиков, Рөстәм Мингалимов, Харис Әшрәфҗанов, Илсөяр Җәләлетдинова, Җәүдәт Тәрҗеманов (Дәрзаманов), Мөдәррис Әгъләмов, Зәки Хәнәфиев, Айдар Сәләхов, Рәдиф Тимершин, Фаяз Әгъзамов... Хәзер – бу басманың чыгуына кырык еллап гомер узгач – уйлап куясың: җыентыкны төзүче Җәвад Тәрҗеманов һәм Кыям Миңлебаев дигән агайлар шактый нәрсәне алдан тоеп, булырдайны алдан күреп, ышанып, талантлы яшьләрнең байтагына фатиха биреп, үз вакытында бик тә изге гамәл кылганнар икән! Исемлектәгеләрнең күбесе бүгенге әдәбиятыбызны хәрәкәткә китерүче төп көчләр булып үсеп җиткәннәр бит! «Җырчы чишмә» – безнең өчен бик кадерле җыентык: исемең, күмәк йолдызлыкта булса да, беренче мәртәбә китап хәтле китапта дөнья күрсен әле!

Бу китапта Фәнис Яруллин шигырьләре беренче булып бара. Күләме дә бүтәннәрнекеннән күбрәк. Гомумән, ул елларда Ф.Яруллин исеме бик популяр иде. Әдәби мохиттә бигрәк тә. Нинди ихтыяр көченә ия кеше! Татарның Николай Островские! Армиядән каты имгәнеп кайтса да, тормышта үз урынын, үз бәхетен тапкан! – университетта укый (дөресрәге, укытучылар килеп укыта), өйләнеп гаилә корган, менә дигән шигырьләр яза... Мәктәпләр,

аерым оешмалар шефлык итте аңа, фатирыннан төркем-төркем укучы балалар өзелмәде... Ни гаҗәп: бер елларда яза башласак та, милләт, әдәбият мәсьәләләрендә, күп очракта фикердәш, мәсләктәш булсак та, миңа Фәнис Яруллин белән тормышта аралашып, әңгәмәдәш, табындаш булып утырырга туры килмәде диярлек. Бәлки, яшәеш-хәятның бу ягы бик мөһим дә түгелдер, безнең эштә иң кирәге – хезмәт берлеге, максат берлеге.

Кайчакта шундый уй да килә: әгәр Фәнис Яруллин фаҗигагә юлыкмаса, физик яктан типсә тимер өзәрлек ир-егет булып яшәсә, бу тормышта ул нинди юл белән китәр иде икән? Бүгенге татар әдәбиятының мәшһүр Фәнис Яруллины булыр идеме? Мәсьәләне болай куюның этик яктан хилафлыгы бар барын. Шулай да... Шәхсән минем моңа ачык җавабым юк. Әмма бер нәрсә анык: арабызда булган Фәнис Яруллин чыннан да каһарман-батыр шәхес! Кешенең бөеклеген, аның чиксез мөмкинлекләре барлыгын тагын бер мәртәбә раслаган көчле зат! Сау-таза килеш төшенкелеккә, сәрхушлеккә, мескенлеккә бирелгән байтак бәндәләрне оялтырлык, тәүбәгә иңдерерлек үрнәк Кеше! Беренче басылып чыккан шигырьләр китабының исеме дә бик тә мәгънәле – «Мин тормышны яратам!». Ә адәм баласы, ирексездән дөньяга килгәч, ирекле булып яшәп китәргә тиеш! Әлбәттә, тормышны яратып, яраттырып...

Фәнис Яруллин – төрле жанрларда уңышлы иҗат итә торган нык каләмле, киң колачлы язучы. Шагыйрь, прозаик, драматург... Бөтен язганнарын җентекләп беләм дип әйтә алмыйм, әмма шигъри әсәрләрен эзлекле күзәтеп барам. Зур шагыйрь ул! Тормышчан шагыйрь, кешеләр өчен кирәк шагыйрь.

Шигырьләренең тәрбияви әһәмияте турында уйлаганда, әдәбият галиме, күп кенә дәреслекләр авторы Азат Әхмәдуллинның үзара сөйләшкәндә әйткән сүзләре искә төшә. «Теге яки бу темага үрнәк әсәрләрне Ф.Яруллиннан теләсә күпме табып була, ә менә кайбер шагыйрьләрнеке, хәтта бик үзенчәлекле талант булсалар да, һич кенә дә дәреслек таләпләренә туры килми». Агымдагы дәреслек-әсбапларга иллюстратив материал булып керү-кермәү – әдәби әсәрне бәяләүдә иң төп критерий түгелдер дә, бәлки. Шулай да күп нәрсәне аңлата ул. Дәреслекләрдә, гадәттә, классик әсәрләр басыла.

Фәнис Яруллин – бүген дә популяр, әдәбият сөючеләрнең яраткан язучысы. Алда әйткәнемчә, ул 60 нчы елларда бик билгеле иде. Әмма ул еллардагы популярлык белән кырык ел үткәч, гасыр ахырындагы популярлык, минемчә, икесе ике нәрсә. Баштагы елларда халык аны беренче чиратта тән газапларын җиңүче көчле рухлы зат, егетләр егете дип үз итсә, соңгы елларда, бернинди ташлама ясамыйча, зур язучы-әдип итеп кабул итте. Әйтергә генә ансат: ул – утыздан артык китап чыгарган кеше. Соңгы елларда «Татнефть» АҖ ярдәме белән дөнья күргән өчтомлыгы бүгенге әдәби процесста үзе бер зур вакыйга...

Еллар үтте, буыннар алышынды, укучылар үзгәрде, бүгенге кайбер яшьләр язучының тәрҗемәи хәлен, үткәнен белмәве дә бар. Иң мөһиме – аның әсәрләрен укыйлар, шигырьләрен ятлыйлар, пьесаларын спектакль итеп куялар... Язучы буларак бу җиңү инде! Фәнис Яруллинның икенче җиңүе – төп җиңүе.

Менә безнең әлегә рәсми тәкъдирләнмәгән халык шагыйре, халык язучыбыз бар!*

*1999*

## *ӘЛЕ БЕЗ ҺАМАН ДА ЗАМАНДАШ*

Тарихчы-археолог Равил Фәхретдиновка 50 яшь тулганда, ягъни моннан 10 ел элек, ул вакыттагы «Социалистик Татарстан» газетасында «Замандашым-адашым» дигән бер язма бастырган идем мин. Язмам мондый сүзләр белән башлана: «Равилнең исеме студент елларында ук билгеле бер даирәгә яхшы ук таныш иде инде. Равил Фәхретдинов – Тукай, соңрак Ленин стипендиаты, оста баянчы, яхшы спортчы, хор җитәкчесе, төрле экспедицияләрдә катнашучы, өстәвенә килеш-килбәте ягыннан да сөлек кебек егет. Бар ягы да килгән, андый сәләтлеләр, гадәттә, һәр уку йортында берничә генә була... Хәер, боларны хәзер хатирә итеп искә төшерү, ул чаклардан соң утыз еллап гомер узды инде. (Хәзер янә ун! – *Р.Ф.*)

Шулай була бит, яшьлектә үк күңелгә берегеп калган кешене гомер буе күз уңыннан ычкындырмыйсың. Инде үзебезгә – «кем булырга теләгән идек тә, кем була алдык?» дип

сорау куя да алабыз. Яше белән ир уртасына җиткән Р.Фәхретдинов – күренекле тарихчыларыбыздан берсе. Ул – 5 китап авторы (икесе – академик характердагы хезмәт, калганнары – фәнни-популяр басмалар). Тарих фәннәре кандидаты. Докторлык диссертациясе әзерләнеп беткән...»

Бүген Равил Фәхретдинов – тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр Академиясе Тарих институтының баш гыйльми хезмәткәре, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә республикабызның Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан, Идел буе һәм, гомумән, Көнчыгыш Европаның урта гасырлар археологиясе һәм тарихы буенча югары класслы белгеч, 12 китап (коллегалары белән берлектә язганнарын да кушсаң, 22 була икән), 200 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкалә авторы.

Ун ел өчен галимгә күпме бу, азмы? Фән дөньясы үлчәмнәренә мин күнекмәгән, бездә, шагыйрьләрдә, алар икенчерәк. Әмма, күптөрле авырлыкларны күкрәге белән ерып барып, һәртөрле хөсетле адәмнәр белән көрәшеп фәнне яклаучы, милләт тарихын тудыручы Равил Фәхретдиновлар өчен аз түгелдер, киресенчә, күптер дип уйлыйм. Әмма эш мактаулы исемнәрдә, китап саннарында гына да түгел. Миңа калса, ул шактый тирәндә – галимнең профессиональ һәм интеллектуаль акыл югарылыгында, фәнни принципиальлегендә, үз намусы алдында саф булып калуында, зур ихтирам көченә ия булуда, аның гражданлык батырлыгында.

Мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиевнең бер язмасында мондыйрак сүзләр укыганым бар. Әдип заманында үзенең шактый зур кыенлыкларга очраганын, докторлык диссертациясенең намуссыз кешеләрнең көнчелеге-үчлеге аркасында якланмый калганлыгы турында яза һәм, бүтән ул эшкә әйләнеп кайтырга үземдә көч таба алмадым, кулымнан эш төште, ди. Ә менә Әгъдәс Борһанов һәм Равил Фәхретдинов, аларның да докторлык диссертацияләрен башта яклатмасалар да, югалып калмадылар, барыбер фән докторлары булдылар, үз эшләренә намуслы булып калып, эшкә тагын да дәртләнеп тотындылар, ди.

Хатирәләргә кереп киткәч, тагын берсе искә төшә. Без, Татарстан язучыларының һәм сәнгать эшлеклеләренең зур бер төркеме, 1968 елны Шәһри Болгарга сәяхәт ясадык. Шунда безнең «гид» Равил Фәхретдинов булды. Шул елларда гына «Казан утлары» журналында аның Болгар тарихы турында күләмле беренче мәкаләсе басылган иде. Ул чакта әле сирәк булган археология белгече, яңа яшь галим күпләрдә кызыксыну уяткан иде. Безнең ише яшь шагыйрьләр генә түгел, инде атаклы язучылар да – Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннурлар бар иде анда – Равилнең халкыбызның борынгы тарихы, Шәһри Болгар, урта гасырлар архитектурасы, җир астындагы таш-кирпечләр һәм чүлмәк ватыклары хакында дәртләнеп, ялкынланып, әмма ышандырырлык итеп сөйләү сәләтенә соклandылар. Без шул чакта археология фәненең киләчәгенә, аның ышанычлы кулларда булачагына ышандык. Һәм, шөкер, алданмадык.

Фәнни яшьлегендә – әүвәл студент, аннан аспирант, Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлаган елларда – Р.Фәхретдинов, Татарстан археология экспедициясенең разведка отряды җитәкчесе буларак, республикабызның яртысын, күрше республика-өлкәләрнең күп җирләрен йөреп чыга, 600 дән артык археологик истәлек (шәһәр, авыл урыннары, борынгы каберлекләр, хәрби ныгытмалар, бай хәзинәләр) табып өйрәнә. Татарстанның археологик картасын төзүгә зур өлеш кертә, фәндә беренче тапкыр буларак 2000 гә якын истәлектән торган Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының археологик картасын төзи. Бу моңарчы эшләнмәгән хезмәт була: һәр истәлек турында академик мәгълүмат – кайда урнашкан, кайсы чорга карый, кайчан һәм кемнәр тарафыннан өйрәнелгән, фәнни әдәбиятта, музейларда, архивларда 100 дән артык ел буена нинди байлык тупланган – һәммәсе бар. Равил докторлык диссертациясе яклаганда, аның төп оппоненты, күпмедер дәрәҗәдә үз-үзенә каршы килеп булса да, бу җыентыкны безнең фәндә әлегә күренмәгән уникаль хезмәт дип атарга мәҗбүр була. Әлеге 2000 гә якын истәлекнең күбесен Равил үзе табып-өйрәнеп, аларны фәнни юлга чыгара. Бүген Р.Фәхретдиновка каршы ямьсез көрәш ачкан, чынында Болгар тарихын өйрәнүгә әллә ни өлеш кертмәгән кара «болгарчы»ларның берьяклы беркатлылыгына хәйран калырлык.

Татар укучысының шул чор буыны, Равил Фәхретдиновның академик монографияләрен, аның «Ташлар моңы», «Мелодия камней» китапларын укып, тарихка шактый якын килде. Минем белүемчә, ул китаплар халыкта да, фәнни җәмәгатьчелектә дә яклау тапты, аларның

авторы ихтирамга лаек булды. Соңгы вакытта Равил Фәхретдинов, Болгар тарихын онытып, башка чорларны, мәсәлән, Алтын Урданы мактый башлады, диючеләр очрый. Мин аның былтыр гына дөнья күргән «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» исемле менә дигән дәреслеген укып чыктым. Зур бүлек итеп язылган Болгар тарихына аннан да зур бәя бирүче, гадел, хак сүз сөйләүче бармы икән әле бүген?

Ә тарихыбызның моңарчы йозак астында яткырылган чорлары – Бөек Төрки каганаты, кыпчак дәвере, ниһаять, Алтын Урда турында зурлап язарга тотынганы өчен (алар хакында Равил үзенең элекке китапларында да, ул еллар мөмкинлегеннән чыгып, әледән-әле язгалап килде) без аны, шиксез, олыларга тиешбез.

Яхшы хәтерлим: 1991 елның язында мәгълүм архитектор, сәнгать тарихчысы Фуад ага Вәлиевнең 70 еллыгына багышланган фәнни конференциядә – бу хәл «Казан» милли мәдәни үзәгендә булды – Р.Фәхретдинов татар халкы тарихында Алтын Урда дәүләтенең тоткан урыны хакында төп доклад ясады. Ә бит әле СССР да таркалмаган, КПСС та бетмәгән һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы каһәрле карары көчендә һәм ул карар белән Татарстанда Алтын Урда тарихын өйрәнү һәм пропагандалау, нигездә, тыелган иде. Йә, шушы түгелме галимнең гражданлык батырлыгы? Хәзер «геройлар», шул чорны сүгүчеләр күбәйде. Ә менә сез нәкъ шул заманда рәсми сәясәт, рәсми идеология кануннарына туры килмәгән фәнни доклад кына түгел, бер-ике сүз әйтеп кара идегез. Сугыш туктагач, йодрык янаучы «каһарманнар» күп була. Шуннан соң Равилнең Алтын Урда тарихын яктыртуга багышланган мәкаләләре газета-журналларда да, кечерәк китап-брошюралар булып та басылдылар. Халыкка моңарчы тыелган гына түгел, алар турында ямьсез караш тудырылган, яла ягылган Чыңгыз, Бату, Үзбәк, Туктамыш, Олугъ Мөхәммәд ханнарның исемнәре кире кайта башлады. Өстәбрәк әйтсәк, элекке иске фикердән арына алмыйча интегүчеләрнең кәефен кырып кайта башлады. Әдәбиятчылар, XX гасыр башы татар дөньясы тарихын өйрәнүче тарихчылар Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садрый Максудиларны кире кайтардылар, ә Равил Фәхретдинов, Марсель Әхмәтҗановлар XIII–XVI йөз татар ханнарын вә ханбикәләрне, безнең данлыклы чорларыбызны, җиңелгән генә түгел, ә күбрәк җиңгән, җиңелүнең нәрсә икәнен белмәгән заманнарны, Тукай әйткәнчә, «вакытында җирне селкеттек» дәверләрне хәтеребездә ныгыттылар.

Тарихта беренче тапкыр буларак Алтын Урда тарихына һәм мәдәниятенә багышлап 1993 елда Казанда Халыкара фәнни конференция уздырылды. Аның инициаторы, эшләрен башлап йөрүче, арбаны төпкә җигелеп тартучы тагын шул безнең тынгысыз Равил абзабыз булды. Аның өчен аңа шул вакытында рәхмәт укымадылар дип уйлыйсызмы? Укыдылар, бик укыдылар. Ләкин өстеннән язучылар да булмады түгел. Сөембикә манарасына ай кую мәсьәләсен күтәреп, шул хакта докладлар ясагач, үзе җитәкләгән тарихи Мирас комиссиясендә куркытулар да булды, ләкин ул курыкмады. Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстайның каберен табып, шуның өстенә таш куйдыртуны кем башлап йөрде? Тагын шушы тынгысыз җан. Бәләкәй Тукай турында халык арасында сакланып калган истәлекләрне беренче чиратта без – әдәбиятчылар җыярга тиеш идек, әмма аларны да ул – археолог җыйды. Археолог-галим Илһам Шакиров турында беренче китап язды. Язганын белгәч, башта бер аптырадылар, укып карагач, икенче бер аптырадылар һәм яхшы сүзләр әйттеләр, уңай рецензияләр бастырдылар (Рәис Даутов, Илбарис Надиров, Мәхмүт Нигъмәтҗановлар...). Минем үземнең дә ул китап турында җылы сүзләрне Сибгат ага Хәкимнән ишеткәнем булды. Ул әлеге китапка сүз башы да язган булган, Тукай, Сәйдәш, Илһам моңы турында язган, ләкин обкомда каршы килгәннәр, иртә әле Илһамны ул бөек шәхесләр белән янәшә куярга, дигәннәр. Ә нигә куймаска? Нигә берәүләр 25–27 яшьләрендә бөек була ала да, ә икенчеләре 35–37 ләрдә – юк?! Югыйсә гасырлардан килүче шул ук тирән сагыш, илаһи моң, олуг талант бит.

Ә археологка моң каян килгән? Әтисе Габдрахман абзыйның тәрәзә рамнары, өстәл-урындыклар, шкафлар ясаганда чыгарган ышкы тавышыннанмы, аның өздереп тальянда уйнавыннанмы, әнисе Нәгыймә апаның тутырып караган моңлы кара күзләреннәнме? Әллә тирәндәрәкме ул моң? Тарихтамы, ташлар моңында, Болгар хәрабәләрендә, ул казыган Иске Казанның тау итәкләрендәге әле бүген дә тарих исе аңкып тора торган юалы һәм какылы, сукаланмаган болыннардамы? Һәммәсендә дәдер...

Вакытлар уза, заманалар үзгәрә, җәмгыятьләр алышына, тарихка, үткән мираска караш киңәя бара. Дистә еллар буе тирән һәм караңгы базларда яткан, тыелган шәхесләр, тарихлар кире халыкка кайта, дөньяга чыга. Шул изге, бәрәкәтле эшнең алгы рәтендә минем чын адашым, якын замандашым Равил Фәхретдинов та тора. Ташлардан моң һәм илһам алып тарих язучы, яше 60 ка җитеп, чәчләре чаларган, тик бүген дә Казан артына, Тау ягына, Кама аръякларына чыгып, шул ташларны барлап йөрүче шушы затка озын гомер, җан тынычлыгы, яңа зур уңышлар телик. Яңа моңнар, яңа дастаннар, яңа тарихлар тусын, замандашым!

*1997*

## *ВӨҖДАНЫНА ТУГРЫ ӘДИП*

Тулы бер гасырның буеннан-буена диярлек гомер кичеп, җисмән исән-сау, рухани сәламәт булып кала алганнарга хәйраннар калырлык. Гасыры да нинди бит! Гел катаклизмнардан гына торган диярсең. Сынган-сындырылганнар, югалган-югалтылганнар никадәр! Шулай да шөкер итә дә белик: вөҗданнарына хыянәт итмичә, иманнарын саклап, идеалларына тугры калган бөек шәхесләребез дә юк түгел. Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт... Алар рәтеннән бүген дә безнең арада үзгә бер дәрт белән иҗат итүче мәшһүр әдибебез Әмирхан Еники бар. Ихтимал, Рәсәйдәге яшәү рәвешенә, яшәү мохитенә нисбәтән Табигать биргән талант-сәләтләренең бар куәте ачылып ук бетә дә алмагандыр аларның... Хәер, булганы, иҗатының халыкка ирешкән кадәресе дә сокланырлык, таң калырлык. Милләтебез өчен Ходай саклагандыр аларны. Дөрес, «Сакланганны саклармын!» дигән гыйбарә дә бар. Әмирхан ага үзе дә гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк.

Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул барыбер Вакыт галиҗәнаплары белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән Аңа үз исеме белән мөһер суга... Киләчәктә Идел-Урал тирәлегендә XX гасырның төрки прозасы турында сүз чыкса, иң беренчеләрдән булып Ә.Еники исеме телгә алыначак. Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый сабаклар да бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да) – язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, тормыш дөреслеген язарга тиеш.

Бу – Аның язучылык кредосы, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты. Тагын икенче бер гыйбрәтле сабак-нәтиҗә: хикәяләү, тасвирлау шигырь рухы белән сугарылмаса, чәчмә әсәр шигъри телле булмаса, чын проза әсәре юк ул. Әмирхан Еники – прозаның шагыйре ул.

Ә.Еники – олуг әдип, олуг фикер иясе. Ул инде бу фани дөнья хикмәтләрен күп күргән, кичергән, аңлаган кеше... Ни хикмәт, ул, кайбер «бар нәрсәне белгән» яшьрәкләрдән аермалы буларак, яшәү хәлләренә һаман гаҗәпләнә, теге яки бу хәлне аңларга тырышып гасабилана, икеләнә, киңәшләшә, үзенә һәм бүтәннәргә сораулар куя, борчыла, илдәге вакыйгаларны йөрәге аша үткәреп, үзенчә киләчәкне фаразлый...

Әмирхан Еники исән чагында данда коенып, иҗатына тиясеннән артыгын алган (андыйлар да булды!) язучы түгел. Чын бәһасе киләчәктә алыначак әдип ул. Әмирхан учагы әле дөрли генә башлады.

*1999*

## *НАРАСЫЙ ХӘКИМ*

Җәмгыятьне гел бимазалап, мәшәкать тудырып, Кеше дигәннең кешелеклелеген кытыклап тора Ходайның талантлы дигән бәндәләре. Холык-фигыльләре, эш-гамәлләре, уй-максатлары белән һич кенә дә гомумкысаларга сыймый үзләре. Яшәү рәвешенә үзгә карашлары; төсләр дә алар өчен җиде-сигез генә түгел, мең дә бер балкышта; авазлар да алар өчен мең дә фәлән аһәңдә... Шул ук бер Кояш, шул ук тулган Ай астында яшибез ләбаса! Ә дөньяны танып-белеп аңлаулары бүтәннәрнекеннән бөтенләй үзгә! Күз күреме бүтән, күңел тоемы бүтән... Аралаша-аралаша яшәгәч, күрә-күрә, ишетә-ишетә иҗатларының кайбер серләренә төшенгәч, гаҗәеп бер гүзәл дөньялары ачыла да куя! Бу дөнья гаҗәпләндерә дә, сокландыра да, сискәндерә дә... Шуңа күрә Ходай тарафыннан талант мөһере сугылган шәхесләр белән санлашырга туры килә. Хаким түрәгә дә, гап-гади хезмәт иясе – юксылга да, таш бәгырьле тәкәббер бәндәгә дә, нарасый күңелле изге җанга да. Әйе, санлашырга туры килә!

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов турында бер-ике кәлимә сүз әйтергә теләп кулыма каләм алгач килгән өзек-өзек уйлар бу. Күрәсең, юкка түгелдер. Әхсән дә бит югары кимәлдәге талант иясе. Ул да бит бүгенге дәрәҗәле мөнбәренә авыр һәм газаплы юл үтеп, танылу-танылмау баскычлары аша күтәрелгән шәхес. Искә төшерик: әле моннан унбиш-егерме еллар элек кенә аны югары даирәләрдә зур сәнгать вәкиле итеп санамыйлар иде. Һәрхәлдә, рәсми яктан шулай булды. Аның СССР Рәссамнар берлегенә фәкать 1983 елда, 44 яшендә генә кабул ителүе шуны раслый. Сәнгать белгече С.М.Червоннаяның (ул татар рәсем сәнгатен пропагандалауда күп хезмәт куйган галимә) шул елларда чыккан «Художники Советской Татарии» дигән библиографик белешмә китабын актарып карагыз. Анда сез Ә.Фәтхетдинов исемен иң ахыргы биттә кечкенә генә белешмә рәвешендә күрерсез. Ә Әхсәннән күпкә, шактый күпкә яшь рәссам егетләр – Ш.Шәйдуллин, В.Аршинов, З.Гыймаев һәм тагын бүтәннәр берничә бит урын алып, портрет-сурәтләре белән бик иркен утыралар бу китапта. Бу мисалны алар лаек түгел дип китерүем түгел, алар да сәләтле рәссамнар, чагыштыру өчен генә искә алуым. Ә бүген? Ә бүген исә, торгынлык чорындагы замандаш байтак апофеоз шәхесләр арткы планда тоныкланып калганда, Әхсән Фәтхетдинов иҗаты, аның шәхесе мәйданыбыз уртасына чыкты. Бүгенге татар милли сәнгатен аның иҗатыннан башка күз алдына китерү кыен. Күпләрнең – сәнгать белгечләренең дә, гади халык вәкилләренең дә – фикере уртак: Әхсән Фәтхетдинов – уникаль сәнгать әсәрләре тудырган олуг рәссам. Бу коры комплиментарь сүз түгел, әйтелгәнне расларлык дәлилләр күп. Ул – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984). Ул – Республикабызның иң абруйлы – Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1993). Ул – әлегә Республикабызда даими эшләп килүче бердәнбер шәхси галерея иясе (1997 елны ачылды)... Гомумән, Түбән Кама шәһәре, аның интеллектуаль дөньясы турында сүз чыкса, ирексездән Әхсән Фәтхетдинов бу каланың бер рухи символы булып күз алдына килә. Әйе, Кеше белән, талант иясе Кеше-Шәхес белән санлашырга туры килә. Соңарып булса да. Дөнья бу!

Кайсы яктан, кайсы туфрактан соң ул? Иҗат юлы ничек? Хезмәтләре нидән гыйбарәт? Башкалардан нәрсә белән аерылып тора да милли сәнгать үсешенә нинди өлеш керткән? Болар – табигый сораулар. Хәл кадәри шуларга җавап эзләп карыйк, мәгълүматлар укучыларыбызны да кызыксындыра дип ышаныйк. Татарстанда туып үскән егет ул. Тумышы – Чирмешән (ул вакытта Первомайский дип йөртелгән) районының Урманасты Үтәмеш авылыннан (милли җанлы икенче бер рәссам Канәфи Нәфыйков та шул төбәктән). Ишле гаиләдә үскән Әхсәннең малай, үсмер чаклары ничек үткәндер, анысын белмим, әмма Табигатьнең бөек сереннән кече яшьтә үк әсәрләнеп йөрүе турында үзе сөйләгәннәре истә. Табигатьнең нәни бер өлешен генә булса да – үлән-тирәкме ул, кошмы, болыт-төтенме – үзе ясап тудырырга ният итмә кели бит бу малай! Кул астына эләккән кәгазь кисәгенә ниндидер сызыклар сыза, сурәтләр төшерә, таякларны юна-юна сырлар уя, шакмак, такта кисәкләрен бергә укмаштырып нидер төзи...

Һөнәри белемне Әхсән Фәтхетдинов Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетында ала. Институтны тәмамлагач, берничә ел Әхсән Урал якларында эшли. Укыту белән дә шөгыльләнеп ала, иҗатка да ыргымнар ясап карый. Әмма... Әмма нидер җитми бит күңелгә! Торган җир үз түгел, мохит барыбер чит, ят... Ара-тирә артистлар килеп татар моңнарын ишеттергәндә, Казаннан алдырган татар китапларын, газета-журналларын укыганда, күңелдә аңлатып бетермәслек сагыш, хатирәләр зилзиләсе, җирсү... Ниһаять, 1969 елда Әхсән, тәвәккәлләп, хатыны Таисия белән Татарстанга кайта. Ул вакытта үзенең колачы, үсеш темпы белән бөтен союзга яңгыраган, яшьләр каласы дип дан алган Түбән Камага килеп

төпләнә бу яшь гаилә. Әйе, төпләнә. Тамырларын тирән җибәргән, ябалдашларын колачлы итеп мәгърур җәйгән имән шикелле, биек һәм бөек булырга кайтып төпләнә Әхсән. Түбән Камада 30 ел гомер. Иҗатчы өчен тулы бер дәвер. Үксегән чаклары да, иҗат һәм яшәү шатлыгыннан күк катларына менәрлек үсенгән чаклары да булгандыр. Һәрхәлдә, бүгенге милли сынлы сәнгатебезнең асыл бер өлешен тәшкил иткән әсәрләрне шушы шәһәрдә иҗат итте Әхсән.

Сәнгать белгечләре Әхсән Фәтхетдинов әсәрләрен, гадәттә, берничә төркемгә бүлеп карыйлар. **Агачка уеп ясалган декоратив бизәкләр** (балалар бакчалары, аэропорт, кунакханә диварларындагы бизәкләр). **Нәкыш сәнгате** («Тукай шигырьләре», «Түбән Кама җирендә», Хәсән Туфан, Бакый Урманче, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов портретлары). **Агачтан ясалган декоратив скульптура сыннары** («Сак-Сок», «Таһир-Зөһрә», «Ияләр», «Кабер ташлары», «Шүрәле», «Интеккәннәр» цикллары). **Монументаль язу үрнәкләре** (Түбән Камадагы төрле корылмалар (музыка училищесы, хастаханә, техникум һ.б.) диварларындагы бизәкләр.

Сәнгать фәненнән караганда, мондый бүленеш дөрестер һәм кирәктер дә. Ә бит көндәлек тормышта, үзара гадәти сөйләгәндә болай классификацияләп тормыйсың. Иҗатчының хәтерендә калган берничә төп эшен исеңә төшерәсең дә, ул эшләрнең материалына, сәнгати «чыраена» карап, Останың төп асыл сыйфатын үзеңчә шәрехлисең. Ә.Фәтхетдинов – агаччы. Агач җанлы Оста. «Агач җанлы» дигәнне гадәти сөйләмдәгечә берьяклы аңламыйк, «бала җанлы» дип әйтәбез бит әле. Бу очракта әнә шул мәгънәдәрәк аңлашылсын. Авторның күпсанлы гүзәл сыннарына карап, аларга Әхсән үз җанын биргән, ә агачларның җаны Әхсәнгә күчкән дип әйтә алмыйбызмыни («Каберенә агач үссә, ул аның җаны булыр...»)? Нәкыш портретларының рамнарына гына игътибар итегез, алтын йөгертелгән академик багетлар түгел, һәрберсе агачтан, бер-берсен кабатламас, әсәрнең органик өлеше булып, эчтәлекне тирәнәйтүче детальләр алар. Дөнья сәнгатендә Әхсәнгә кадәр гомер кичеп үткән аналоглар да бар барын: Эрзья (С.Д.Нефедов), С.Коненков, Б.Урманче... Урманасты Үтәмеш егетендә генә түгел, уйлап баксаң, табигать кочагында үскән безнең һәрберебездә күпмедер «агачлык» бар бит. Агач бишектән башлап ләхет уемындагы такталарга кадәр... Балачакта авыл өендәге сәкедә чалкан килеш түшәмдәге ботак киселешендәге сурәтләрне карап ятмадыкмыни? Ниндие генә, нәрсәгә генә охшаганнары булмый иде аларның! Үзенә күрә бер галерея. Түшәм галереясы. Кыскасы, Әхсәнне Агач кеше итте, Оста итеп дөньяга танытты. Икесенә дә рәхмәт! Шагыйрь Зөлфәт Әхсәнгә багышланган шигырендә тикмәгә генә болай дип язмагандыр:

...Остаханәңдә мин, Әхсән,
Өнсез булдым.
Кешене син бакый иткән бит...
Син – җан табигате генә түгел,
Табигатьнең җаны икән бит!

Ә.Фәтхетдинов сәнгате киң даирәгә 80 нче еллар башында таныла башлады. Казанда үткән беренче күргәзмәсе (1978) әле дә хәтердә. Рәссамнар өчен күргәзмә дигәннәре зур нәрсә. Биючегә мәйдан-сәхнә кирәк булган шикелле, рәссамга үз эшләрен кеше күзенә күрсәтү лазем. Яшьләр Үзәгендә (хәзерге «Ак барс» банкы бинасы) оештырылган иде ул күргәзмә. Күбрәк нәкыш әсәрләре – портретлар, пейзажлар, график эшләр, шулай ук бүгенге зур мирасның башлангычы – агач сыннар да бар иде анда. Казанлылар яратып калды Әхсәнне. Дуслары күбәйде. Язучылар, журналистлар үз итте. Арада, әлбәттә, сәнгатькярләр дә байтак иде. Фоторәссам Рифхат Якупов, композитор Шамил Шәрифуллин, бөек Бакый Урманче... Перифериядән килгән рәссамга рәсми «классик»лар тарафыннан өстәнрәк, бераз түбәнсетеп тә караучылар булмады түгел... Әмма татар милли сәнгатенең (агач җаны аша) бу төре үсешен ныклап башлап җибәрүче нәкъ Әхсән булачагына ышанучылар күбрәк иде. Дөрес, сынлы сәнгатьнең теге яки бу жанрында техник яктан заманча иҗат итүче сәләтле рәссамнар байтак. Алар йә Санкт-Петербург, йә Мәскәү мәктәбен үтеп, бертөрле тәрбия, бертөрле идеологик юнәлеш алып үскән рәссамнар. Алар кайда да – Псковта да, Уфада да, Магаданда да рәхәтләнеп яши, үзләре үткән мәктәп курсы рухында иҗат итә алалар (мисалы ерак түгел: Бондюг егете Әмир Мәҗитов әллә ничә еллар буе Ярославль Рәссамнар берлеген җитәкләде, хәтта Казанга кайтып та шул дәрәҗәле хезмәттә булды. «Чайка», «Барабанщик», «Сигнал»

кебек бөтен союзга киң таралган әсәрләр авторы булса да, мин аны чын мәгънәсендә милли рәссамыбыз дип таный алмыйм). Бәлки, осталыкның теге яки бу хикмәтендә Әхсән кемнәрдәндер калыша дадыр. Нишлисең, Ходай кемгә буй, кемгә уй биргән, ди. Миллилеге белән, беркемне дә кабатламый торган үзенчәлеге, алынган теманы философларча хәл итүе белән, ахыр чиктә Әхсән дигән шәхес булуы белән алдыра ул! Һәм ничек кенә әле!

Алда әйтелгәнчә, 1993 елда Әхсән Фәтхетдинов Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Рәссамнар берлегенә әгъза булып керүенә нәкъ 10 ел үткәч. Шул елның яз башында «Казан» милли-мәдәни үзәгендә гаять бай күргәзмәсе оештырылган иде аның. Вәт күргәзмә дисәң дә күргәзмә иде ул! Бусы инде без теләгән (күпләр теләгән!) Әхсән иде. Жанрлар төрлелеге ягыннан дисеңме, осталык, камиллек ягыннанмы, җаныбызда сыкрап яткан рухи катламнарны ачып күрсәтү ягыннан дисеңме... Бу күргәзмәдә иҗатының үзәген билгели торган төп цикл-төркем эшләре куелган иде.

«Шүрәле»ләр. Алар – үзе бер дөнья. Чиста, пакь дөнья. Шүрәлеләрнең берсе, бәлки, автор үзедер әле! Ул да безнең кылган гамәлләргә карап-карап тора да, хилафлыкларыбыз өчен бетереп үк ташламый, сынап-сынап карый да, аптырагач, шаяра, кытыклый, көлә... Ә «Интеккәннәр» циклы? Нинди генә йөз-чырайлар юк ул сыннарда! Алар – безнең үткән тормыш, безнең бүгенгебез. Әле яңа гына, 26 апрель – Шигырь бәйрәме көнендә, Камал театрында түбән камалыларның тантаналы концерт кичәсендә сәхнәдән торып Әхсән болай диде: «Минем ул сыннарның чытык, ямьсез йөзләренә карап гаҗәпләнмәгез, тормышларыбыз рәтләнеп китеп, хәлләребез яхшыргач, аларның да йөзләре үзгәрер, аларга да нур кунар...» Уйландыргыч сүзләр.

«Ияләр» циклы, мөгаен, Әхсән Фәтхетдиновның гомер хезмәтедер. Нинди генәияләрнең иясе булмады ул! Җир иясе, күк иясе, урман иясе, зират иясе, чишмә иясе, юл иясе, су иясе, йорт иясе, абзар иясе, капка иясе... Алар әллә ничә дистәгә җыйнала. «Ияләр» хакында матбугатта күп язылды. Абруйлы язучылар да, үз эшләрен камил белгән сәнгать белгечләре дә: Р.Шаһиева, Г.Сөләйманова, И.Саттаров, Р.Хисмәтуллин, Э.Гаделов, Д.Вәлиева... Рәссамның «Ияләр»ен төрлечә бәяләделәр, аларның тууын төрлечә фаразладылар. Ислам дине кабул ителгәнгә кадәрле чорны, мәҗүсилек дәверен, чыганак итеп күрсәтүчеләр булды. Берәүләр аның бу әсәрләрен «коммунизм төзү чорындагы» ялган рәсми сәнгатькә протест билгесе итеп тә карадылар. Еретик рәссам дип мөһер сугучылар да булды. Ни генә булса да, хаклы шауладылар, хаклы бәхәсләштеләр, хаклы бәяләделәр. Хаклы рәвештә Тукай премиясен бирделәр. «Иясез шатлык» булу бер нәрсә, ә һәрнәрсәнең, табигатьтәге һәр җанлының үз иясе булуы кирәк бу дөньяда! Ияле булсаң, кадерең була. Кадерсез булу яман ул...

Бу урында Әхсән Фәтхетдинов белән минем шәхси иҗади мөнәсәбәтләр турында да берничә сүз әйтү кирәк булыр. Әхсән иҗатының бер зур өлешен «Кабер ташлары» дигән цикл алып тора. «Татар иле» газетасында (1993, март, № 6) мондый юллар язылган иде: «Ә.Фәтхетдинов иҗаты соңгы елларда чын-чынлап чәчәк ату чорын кичерде. Равил Фәйзуллин шигырьләренә нигезләнеп иҗат ителгән «Кабер ташлары» рельефлы скульптуралар төркеме татар халкының кире кайтмас югалтулары һәм газаплары өчен тирән борчылу хисләре белән сугарылган. Бу – татар зиратының символик образы, анда халкыбызның тормышка ашмаган хыяллары күмелгән. Кешеләрнең рухи байлыгын, вөҗданын һәм хәтерен саклап калу өчен, безгә әле бик күп эшләр эшләп өлгерергә кирәк. Һәм шигырьләр – шагыйрь иҗат иткән эпитафияләр – биредә бигрәк тә дулкынландыргыч яңгырыйлар...» (А.Шакиров). Сүз берничә юллык кыска шигырьләремне Әхсән кулы белән агачка уеп язылган әсәрләр турында. 50 гә якын шигырь чокылган куна такталар алар. Дөрес, мин беркайчан да кайчандыр кабер ташларына (бу очракта агачка) уярлар дип иҗат итмәдем. Кыска шигырьләр – минем стихиям, бәлкем, асылымдадыр әле. Әмма олуг Останың һәрбер сүземне, һәрбер хәрефемне ырмау пычак белән агач бәгыренә уеп утыруын күз алдына китерик әле! Ничә көннәр, ничә айлар... Шагыйрь өчен әйтәсе дә юк, зур бәхет инде бу. Шунысы да мәгълүм: бу әсәрләр куелган күргәзмә кешеләргә нык тәэсир итә икән. Сүзләре дә, эшләнеше дә, агач булуы да... Гомумән дә уйландыра – зираттагы кабер ташлары нинди булырга тиеш? Һәрхәлдә, сурәт яки һәйкәли сыннар рәвешендә түгелдер. Сурәт белән таш кую безнең мөселман традициясе түгел. Безнең борынгы ташларда сурәт юк бит. Фотокүчермәдән кеше сурәтен ташка иңдерү соңгы чор, сәвит чоры галәмәтләре, ул гына да түгел, мәҗүси-христиан традицияләре. Уйлансаң уйланырлык: Чыңгыз ханның кабере

нәмәгълүм (инде гасырлар буе эзлиләр), Л.Толстойның каберендә сурәт-мазар юк, Истанбулдагы Г.Исхакый каберендә дә фәкать язулар гына... Борынгы төрки ядкарь – Күлтәгин ташларында да уйма язмаларны гына күрәбез. Сабый хәким – Әхсән Фәтхетдин төрлесен уйлап, киләчәккә карап уйгандыр ул сүзләрне.

Әхсән белән даими аралашып яшәгәнгә егерме биш еллап. Байтак гомер. Хәзер күрше белән күрше, туган белән туган юньләп аралашып яшәмәгән заманда Әхсән миңа хатлар яза. (Тапшырылмаган хатлар түгел, тапшырылган хатлар!) Ә ул хатлар хатлар гынамы соң әле! Кайберләре бер амбар кенәгәсе чаклы – машинкада 70–80 биткә җиткәннәре бар. Алар миндә 40 тан артык. Менә боларны укысаң, Әхсәннең җанынданиләр уйнаганын беләсең инде! Ул әле рәссам гына түгел, шагыйрь дә, әдип тә, философ та. Ходай боерган булса, ул хатлар (бераз өлеше генә булса да!) матбугатта бер күренер әле.

Сүз дә юк: Әхсән кебек намусны компас итеп алган шәхесләргә бу тормышта, безнең мохиттә яшәү җиңел түгел. Алар бәргәләнә, өзгәләнә... Ниндидер язылмаган кануннар бардыр инде: кемнәргәдер авыр булганда, кемнәргәдер җиңел була... Әмма барыбер бүген өзгәләнгәннәргә иртәгә җиңеллек киләчәк... Әхсән үткән юлга, тормышына, иҗатына карап шулай уйлыйм. Дөньяда үзеңнән яхшырак кешеләр барын тою яшәтә безне, турайта, өметләндерә, шактый ук уңган күзләребезне киләчәккә төбәтә.

«Казан утлары» журналында (1999, № 6) Әхсән Фәтхетдиновның «Сугыш еллары атлары» дигән сынының фоторепродукциясе чыкты. Редакциягә җибәргән хатында аның мондый сүзләре бар: «Соңгы зур күләмле «Ай шәүләсе астында» дигән эшемдә «Ияләр»не бергә җыйдым. Җир өстенә аларны күккә сибелгән йолдызлар кебек чәчтем, сиптем. Алар арасында байлар-ярлылар да, патша-коллар да юк, алар – тигезләр. Бу картина – үзем тудырган, үземә якын булган бер дөнья». Синең дөньяң безнең өчен дә бик зур дөнья, Әхсән туган! Озак, бәхетле яшәп, игелекле иҗатың белән сөендереп тор гел.

*1999*

## *ЗАМАНА ЯЗУЧЫСЫ*

Рауль Мир-Хәйдәров... Кем ул? Татар укучысы беләме, таныймы аны? Сорауга җавап шул: аз белә. Хәтта язучыларыбызның да шактые аны укып түгел, ишетеп кенә беләдер. Хәбәрдарларның берәүләренә ул – мавыктыргыч сюжетка корылган детектив романнар авторы, берәүләренә – хакимиятнең теләсә нинди югары даирәләрендә үз була алган супершома замана егете, берәүләренә – дөньяны чолгап алган җинаятьчел коррупция кармавычларын аяусыз кисеп торучы куркусыз шәхес. Ни генә димәсеннәр, ул – иң әүвәл безнең милләт баласы, рус телендә иҗат итүче татар язучысы. Тормыш кредосы, иҗат принциплары, эстетик карашлары турында фикер йөртер өчен язучы үткән тормыш юлын бераз гына булса да шәрехләү кирәк.

Рауль Мирсәет улы Мир-Хәйдәров 1941 елда Казакъстанның Актүбә өлкәсендәге Мартук поселогында туа. Үзе әйтүе буенча, аның әти-әнисе чыгышлары белән Оренбург ягыннан.

Раульнең үсмер-яшьлек еллары Актүбә шәһәрендә үтә. Ул биредә 1960 елны тимерюл техникумын тәмамлый. Соңрак төзүче-инженер була. Егерме еллап төзүче булып (прораб, участок начальнигы һ.б.) эшләү дәверендә аңа Советлар Союзының бик күп республикаларында, йөзләгән шәһәрләрендә булырга туры килә. Ир-егет чагында ике дистәдән артык ел Ташкентта яши. 30 яшендә «Полустанок Самсона» дигән беренче хикәясен яза һәм ул Мәскәүдәге «Родники» дигән альманахта басылып чыга. 1975 елда Р.Мир-Хәйдәров Яшь язучыларның бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырыла һәм тиздән, «Молодая гвардия» нәшриятында «Оренбургский платок» исемле китабы дөнья күргәч, ул СССР Язучылар союзына кабул ителә. Кырык яшеннән Рауль Мир-Хәйдәров төзелеш эшеннән китә һәм гомерен тулысынча әдәби иҗатка багышлый. Ул бүгенге көндә дистәләгән китаплар авторы. Әсәрләре чит ил телләрендә һәм СССР халыклары (казакъ, үзбәк, грузин, татар, каракалпак) телләрендә күп тапкырлар тәрҗемә ителеп басыла. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши.

Болар – Р.Мир-Хәйдәров биографиясенең кайбер штрихлары. Укучылар беркадәр мәгълүмат алсын дип язуым. Гадәти биография. Раульнекенә караганда әллә нинди катлаулы,

әллә нинди маҗаралы язмышлар бихисап бу дөньяда... Әмма ни гаҗәп – тормышта, әдәбиятта Рауль Мир-Хәйдәров феномены бар! Болай әйтерлек нигез бар. Беренчедән, ул – гаҗәп күп һәм нәтиҗәле эшли торган язучы. Һәр ел саен диярлек аның берәр калын романы басылып чыгып тора! (Язылып кына түгел, басылып!) «Пешие прогулки» (1988), «Двойник китайского императора» (1989), «Судить буду я» (1990) һ.б. Кемнәрдер бер-ике табаклык китабын дистә еллар чыгара алмый изаланган заманда бит бу! Икенчедән, аның романнары миллионлаган (!) данәләр белән нәшер ителә (танылган прозаикларыбызның әсәрләре 3–5 мең тираж белән чыга хәзер). Өченчедән, махсус филологик һәм әдәби белеме булмаган төзүче-инженер яза бу китапларны. Өстәвенә язу белән дә утыздан ашкач кына шөгыльләнә башлаган, нульдән...

Уйланырлык. Бу арада Р.Мир-Хәйдәровның романнарын җентекләп укып чыктым. Төрле уйларга этәрде алар. Кая бара дөнья? Киләчәктә әдәбият нишләр? Татар язучысының хәле ничек булыр? Тукай-Дәрдемәндләрне, Такташ-Җәлилләрне, Туфан-Хәкимнәрне, Юзәй-Шәүкәтләрне, Мөдәррис-Харисларны кемнәр укыр? Китапларыбызның тиражлары аз, укучылары сирәк... Ә менә Мирхәйдәров китапларын укыйлар. Русча әйткәндә, спрос бар. Хикмәт фәлән телдә язуда гына түгел. Әнә рус классикларының китапларына да бик ябышып ятмыйлар хәзер...

Сер нәрсәдә соң? Моңа төгәл җавабым юк. Фаразлый гына алам. Миңа калса, Р.Мир-Хәйдәров без шаһитлары булган бүгенге җәмгыятьнең, системаның, идарәчеләрнең яшәү рәвешен, кылган һәм кылырга теләгән гамәлләрен нindидер бер эчке сиземләү белән, рентген аша карагандай, ачык күрә, тоя, үлчи, бәяли. Ә җәмгыять, беләсез, бөтен организмы белән диярлек җинаятьчел вируслар белән агулы. Замана каһарманнары (әллә имгәкләре?) без күрергә теләгән идеалларның капма-каршылары булып чыкты. Оешкан җинаятьчелекнең хакимияттәге югары түрәләр белән үрелеп берегүе, бик күпләр өчен акчаның иманга әйләнүе, рухи кыйммәтләрнең очсызланып-кадерсезләнеп бетүе, бөтен нәрсәнең диярлек сатыла алуы – һәммәбезнең күз алдында. Р.Мир-Хәйдәров романнарындагы персонажлар менә шушы вазгыятьнең авансценасында төп рольләрне уйнаучы геройлар. Тәрбиябез буенча без күрергә теләгән хәләл хезмәт геройлары түгел, ә акыл-хәйлә, янау-үтерү белән дөнья кендеген тотучы яңа «геройлар» – Артур Шубариннар...

Р.Мир-Хәйдәров үз әсәрләрендә, теләсә – «законлы бур», теләсә – генпрокурор, теләсә «төнге күбәләк» булып табигый сөйләшә ала! Бу – профессиональ осталык. Ул моңа ничек ирешкән? Монысы минем өчен чыннан да сер.

Дөресен әйтим: Р.Мир-Хәйдәров әсәрләрен укыганда, гел ләззәтле генә хисләр кичермәдем мин. Ят дөнья. Ят гамәл-кыланмышлар. Без кинода гына күргән зур акчалар дөньясы. Психологик яктан аңлап бетермәгән йә аңларга теләмәгән нәрсәләр күп. Күрәсең, заманына күрә алынган тәрбия һәм дә өстәп үткән гомер консерватизмы үз хасиятен башкара булса кирәк. Әмма нишлик? Күңелең белән кабул итмисең, акылың белән килешергә мәҗбүрсең. Йә без артта калган, йә тегеләр бик «алга» киткән. Язучы «чырайсызлар» заманының чыраен дөрес күрсәтә. Каләм сукасы, эчке буразна эченә төшеп, шәп ерып бара... Гыйбрәт алу, нәтиҗәләр ясау – укучылар эше... Шунысы да бар: Р.Мир-Хәйдәров – бу җинаятьчел дөньяның елъязмачысыннан бигрәк, аның тикшерү-өйрәнүчесе... Бу бик мөһим момент: язучының социаль аналитик булуы зур нәрсә. Тормыш, дөньябыз ничек? Аның чагылышы безнең күзләрдә, идеалларда, җырларда, әсәрләрдә. Р.Мир-Хәйдәровтан, бәлки, Бунин яки Еники чалымнарын эзләү кирәкмидер, бәлки, Ж.Сименон яралгысы анда көчлерәктер...

Рауль Мир-Хәйдәров, әйткәнемчә, ординар булмаган, кабатланмас шәхес. Эш аты, әйткән сүзен үтәүче ир-егет, көяз-фанат (М.Мәһдиев, Рауль, иҗат йортларына килгәндә, берничә чемодан белән 15 тән дә ким энә-җептән төшкән костюмсыз килми ул, дия торган иде), сәнгатькяр. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп узыйк: Р.Мир-Хәйдәров – бик зур кыйммәткә ия нәкыш әсәрләре коллекциясе иясе. Сәнгатьне тирән тоючы белгеч буларак, ул җыйган картиналар әледән-әле төрле күргәзмәләрдә күрсәтеп торыла. Язучы кеше өчен бу да ят шөгыль түгел, һәрхәлдә, тарлык түгел, киңлек.

Әсәрләрне укыганда, авторның профессиональ осталыгы да уйландыра. Бүгенге укучы күңеленә эленке-салынкы җөмләләр, беркатлы наив фикерләр белән юл салып булмый хәзер. Стиль – кешенең нәкъ үзе инде ул дигән гыйбарә бар. Дөрес нәрсә. Язучы кемнәр яки нинди вакыйгалар турында язмасын, барыбер күпмедер дәрәҗәдә әсәрдә автор язмышы чагылмый

калмый. Раульнең стиле – логик төзек, динамик стиль. Сүзләрнең җегәре зур. Шул җегәрле сүзләр мавыктыргыч сюжет чылбырында гаять тээсирле көчкә әверелә. Укучыларны «тота» алуның бер сере шунда, минемчә. Тагын бер мөһим нәрсә, ул – төгәл сурәтләү. Язучы кайдадыр, кайчандыр үзе күргән кирәк детальләрне фотографик төгәллек белән кабатлап күз алдына китереп бастыра ала. Мәсәлән, «Пешие прогулки» романында Кырымдагы Күктүбә тирәсен тасвирлаган урыннар бар. Заманында мин үзем дә шул җирләрне күп таптадым. Хәзер дә әзме-күпме хәтердә. Ә менә Раульнең әсәрен укыгач, мин анда әле кичә генә барып күреп кайткандай хис иттем. Кирәк һәм иң характерлы деталь-штрихлар шулкадәр осталык белән тотып алынган. Афәрин, молодец! дияргә генә кала. Тарлык-киңлек сүзе чыккач, күңел түрендәге эчке уйлар да төртеп чыга: кемнәребез бар да, кемнәр юк! Кан яратылышы буларак, кемнәр кайда туып, нинди сыйфатта кем булып кайларга таралмаган! Үзем күреп белгәннәрне генә искә төшерсәң дә, байтакка җыйнала. Магаданда – Бөгелмә егы Альберт Фәттахетдинов, Красноярскида – Минзәлә егете Ринат Суфеев (Роман Солнцев), Чиләбедә – Рөстәм Вәлиев, Ташкентта – Әсхәт Мохтар, шунда ук Җәүдәт Ильясов... Кайберләре дөньяның фаниеннан бакыена күчтеләр инде... Кемдер әйтер: татарга нинди кагылышлы язучылар инде болар? Килешәм дә кебек. Шәкли яктан сүз дә юк, ерак качканнар. Явыз Иван Казанны алганнан соң, асыл ирләр еракларга киткән кебек... Әмма нишләргә соң? Сыркыдыдан яңа Һади Такташ, Пенза ягындагы Пешләдән Шәриф Камал, Нижгардан Кави Нәҗми, Оренбургтагы Мостафадан яңа Муса Җәлилләр килерме? Килмәсләр кебек... Шулай булгач, каннарында төрле иньекцияләр булса да, төбендә татарлыгы яткан, бүген бүтән телләрдә иҗат итүче егетләребезне нигә онытырга? Булган дәрт-рухларының, иҗат потенциалларының беразын гына булса да уртак генофонд тамырына нигә тоташтырмаска?

Рауль Мир-Хәйдәровны укучыларыбыз белми әле дип башта әйтсәм дә, хәл бөтенләй алай ук түгел. Моннан байтак еллар элек безнең журналда аның «Игълан белән танышу» исемле повесте басылып чыккан иде. Россиядәге зур афералар-алдашуларны тасвирлаган «За все – наличными» дигән яңа романының өзекләре «Республика Татарстан» газетасының биш-алты санында дөнья күрде. Һәм, ниһаять, «Казан утлары» Марс Шабаев тәрҗемәсендә аның «Иртәләгән сагыш» исемле романын тәкъдим итә. Бәлки, бу роман язучы иҗатының иң характерлы әсәре түгелдер. Әмма анда безнең язмышлар, безнең уртак сагышлар...

*2000*

## *НЕЧКӘ ХИСЛЕ, БАТЫР ЙӨРӘКЛЕ*

1989 ел. Эреле-ваклы китаплары чыккаласа да, ул вакытта Рәшит Әхмәтҗановның учта сизелерлек калын китабы юк иде әле. Юка тышлы китап чыгарып, зур шагыйрь саналып була микән? Рәшитнең максаты – иң яхшы әсәрләрен туплап, «Шигырь китапханәсе» сериясендә томлык чыгару. «Шигырь китапханәсе»ндә чыгу – үзе зур дәрәҗә, шигърияттә үз урының булуын билгеләүче бер күрсәткеч. Һәрхәлдә, бу сериядә басылу күпләрнең хыялы иде ул елларда. Өстәвенә шагыйрьнең 50 еллыгы да якынлаша...

Китап чыгу мәсьәләсе нәшриятта тәгаенләнгәч, ул миннән шушы томлыкка кереш сүз язуымны үтенде. Хәзер уйлап куям: озак көтелгән кадерле китабына баш сүз язуны нигә миннән сораган? Холык-фигыль белән дә, язу-стиль ягыннан да шактый аерылабыз, ул вакытта мин ирекле иҗатчы, профессионал, түрә-мазар да түгел, дәрәҗәле урын да биләмим... Дөрес, аның әсәрләренә төрле елларда берничә эчке рецензия (нәшриятта элегрәк шундый тәртип: компетентлы саналган язучы яки шагыйрь, авторлардан кергән кулъязмаларны укып, бәяләмә бирә иде) язганым бар иде. Бәлки, шуларны да истә тотып мөрәҗәгать иткәндер. Ризалык бирелде, «вәгъдә – иман» дигәндәй, дүрт-биш битлек мәкалә язылды, һәм ул 1991 елда Рәшит Әхмәтҗановның «Моңлану» исемле сайланма әсәрләр китабында «Күңел һәм җан сәфәре» исеме белән кереш сүз булып басылып та чыкты. Бүләк итеп биргән китабына болай дип язган: «Равил! Гомер шулай узды инде. Безнең бергә яшәүгә мин бер генә караңгылык та төшермәдем. Рәшит Әхмәтҗанов. 6 май, 1991 ел».

Бу хәлләрдән соң нәкъ ун ел гомер үткән. Әйтелгән, ташка басылган сүзләр әле ул арада гына искерергә тиеш түгелләрдер ләса! Шуңа күрә әлеге кереш сүздән озынрак булса да, кайбер өземтәләр китереп узам.

«Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле. Өч дистә елга якын шактый ук актив эшләп килсә дә, аның иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең аерым төпле фикере соңгы биш-алты ел эчендә генә ишетелә башлады. Бу хәлнең сәбәпләре нидә? Бәлки, тәнкыйтьчеләрнең исемлек кысасына үз вакытында керә алмый калуындадыр? Бәлки, шигъриятебездә берьюлы ике талантлы шагыйрь – ике Әхмәтҗанов (Роберт һәм Рәшит) булуның «файдасыдыр»? Бәлки, иҗатының артык үзенчәлекле булуындадыр? Яшермим, укый-өйрәнә торгач, Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь үзем өчен дә шактый ук «каты чикләвек» булып чыкты. Налим балыгы шикелле шома (яхшы мәгънәдә), тиз генә тоттырмый... аның шигъриятен «саңагыннан» әләктереп булмый... Шигырьләре техник яктан, Хәсән Сарьян «юнган агач» шикелле, бик нечкә зәвык белән эшләнгән; өстәвенә образ, чагыштырулар, эпитетлар һ.б. калфак чигешендәге энҗеләр шикелле бик мул сибелгән. Шагыйрьлекне аерым юл-строфалардан, исемләнгән шигъри башламнардан да тоеп була («Яшь чагында авыр ташлар – тау астында», «Төшләремә кердең каен булып», «Акка кызыл ачык булып төшәр», «Сандугач керде күңелгә», «Минем өчен дөнья – нәкъ дүрт гамәл», «Кошлар» бәйрәменә чакыру», «Салкын кышлар аккош булып кайтыр» һ.б.).

Яки менә бу дүртьюллыкны укып узыйк:

Муеныма аскан ташың – тау иде,
Мине тирән су төбенә салды ул.
Бүләк алып чыктым әле мин сиңа:
Сине сөйгәч – энҗе булып калды ул.

Рәшит Әхмәтҗанов – чын мәгънәсендәге татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул Р.Харис та түгел, Г.Рәхим яки Р.Мингалимов та түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М.Әгъләмов белән параллель куеп буладыр. Икесе дә Хәсән Туфан шигърияте тарафдарлары. Аларның төп эчкән чишмәләре – халык иҗаты, татар халкының эстетик традицияләре. Биредә сүз иҗатчының юнәлеше, кыйбласы турында бара. «Һәр сүз миннән бер матурлык сорый, мин фәкыйрьмен – алыйм кайлардан?..» дисә дә, шагыйрь, әйткәнемчә, сүзне, илһамны, җимне халык иҗатыннан, халык күңеленнән ала. Шуңа күрә дә аның шигырьләрендә безнең фольклорга хас бик күп традицион атрибутлар, образлар, тәгъбирләр тулып ята. Беренче карашка гади күренгән шигъри сүзберәмлекләр, шагыйрь күңелендә үзгәртелеп, яңа төсмерләр ала, образ-фикергә әйләнә:

Урман эчләрендә урман шаулый,
Урын тапмый болан үзенә.
И болан...

Йә сугарлар балам күзенә дип,
Ачык аланнарда төлке уйный,
Урманнарга кача яшь болан.
Кил, болан...

Урманнардан берни урламаган
Соңгы җан иясе – мин булам.

Кызганыч, безнең бүгенге яшьләребезнең күбесе халык иҗаты белән җимләнеп үсмәгәнгә, шагыйрь күңеле тудырган гаҗәеп бай һәм тылсымлы дөньяны тиешенчә танып, эстетик ләззәт ала алмый. Шәхес культы һәм торгынлык елларында бер-ике буын милли укучыларыбызны югалттык. Шулай да, үзебезне юатып, үзгәртеп коруларның нәтиҗәсе яңарышларга китерер дип өметләник.

Рәшит, үзенең шигърият өчен яратылганын сизеп микән, бүтән жанрларга сибелмичә, фәкать поэзиядә генә эшләп килә.

Ул бу яктан күпмедер дәрәҗәдә Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арслановлар юлы белән китте. Бөтен җегәрен бер ноктага – бу очракта поэзиягә юнәлтү, табигый, аны бу өлкәнең чын остасы итә. Шуңа күрә дә Р.Әхмәтҗанов, гармуннарның теләсә нинди төрендә уйнаган Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккининнар шикелле, шигырь жанрының теләсә кайсы биләмәләрендә виртуозларча иркен эш итә: шигырьләрнең озынын яки кыскасын булсын, менә дигән итеп коеп куя, поэмаларны да оста үреп чыга, моңлы яки дәртле җыр текстларын да үзенчәлекле итеп яза. Әйтик, шагыйрьнең «Акчарлаклар»ы классик җырлардан саналырга хаклы дип уйлыйм. Балалар өчен дә җыйнак һәм тәрбияви әһәмиятле итеп яза белә. Бу китапта шагыйрь иҗатының тулы чагылышы: давылларын җанына яшергән ир-егет әдипнең дөньяга түккән күңел байлыгы, кешеләргә әйткән фикер-хикмәтләре, хис-моңнары тупланган.

Поэмалар өлкәсендә дә актив эшли Рәшитебез. Бу китапта алар берничә: «Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», «Бишташ», «Аучылар кибетендә». Соңгы икесе авторның гына түгел, гомумән, поэзиябезнең казанышы саналырлык поэмалар. Бер караганда, бу поэмаларның сюжет җепләре өзелеп-өзелеп киткәндәй тоела. Алай түгел икән шул. Ул җепләр үзәк өзгеч моң белән тоташтырылганнар икән. Моң сихеренә ия булган шагыйрьнең үзенчәлеге, иҗади табышы итеп кабул итәргә кирәк моны.

Р.Әхмәтҗанов – үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә иҗат итә торган кеше түгел. Ул – ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь. Шигырьләрендә эчке моң саркып тора. Күңелдә бар булганны ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлекләр җитмәгән очракта (торгынлык елларында язылган шигырьләрен күздә тотып әйтәм), иҗатчы бүтән юлны сайлый – кинаяләр, катлауландырылган образлар аша тасвир итә. Тик шунысы хак: Рәшит Әхмәтҗанов нәрсә турында гына язмасын – авыр тойгылы уйлармы алар, якты-дәртле хисләрме – Шигъриятнең Матурлыкка һәм Гаделлеккә хезмәт иткәнен бер генә минутка да онытмый. Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып иҗат итә. Хәтерсезләрне уятыр өчен нәкъ менә шундый шагыйрь кирәк булгандыр да әдәбиятыбызга».

Югарыда әйтелгәннәр Шагыйрь турында бүгенге уй-тойгыларыма, инануларыма бер дә каршы килми икән. Моңа бик шөкермен. Әлбәттә, хәзер язылса, бераз бүтәнчәрәк, бәлки, тирәнрәк, анализлырак итеп язылыр иде. Әмма Шагыйрьгә төп караш, мөнәсәбәт элеккечә калган булыр иде.

Табигый хәл микән? Күбрәк яшәгән саен, хатирәләргә ешрак биреләсең. Шагыйрь әйтмешли, «җир өстендә дуслар сирәгәйде, җир астында дуслар күбәйде». Сәбәбе шулдыр. Еллар узган саен, гомереңсәхифәләрен инде дөнья кичкән танышларыңныкы, дусларыңныкы белән чагыштырасың да әллә никадәр уртаклыкларга тап буласың. Рәшит – безнең буын шагыйре, бер-ике яшькә аерма булса да, минем буын шагыйре. Әдәбиятка бер чорда килдек. Беренче китаплар да бер үк елларда чыкты. Төрле еллардарак булса да, бер үк шәһәрләрдә яшәдек – Әлмәт, Казан. Янә, еллары бергә туры килмәсә дә, бер үк шәһәрдә (Самара), бер үк частьта, бер үк казармаларда армия хезмәтен үткәнбез (солдаттан ул пеләшләнеп кайтты, минем дә чәчләр хисабына маңгай нык кына «үсә» төште ул елларда. Шунлыктан дип беләм, Рәшит күп чак баш киемендә йөрде: кышын – бүрек, җәен – берет, бүлмә-биналарда – түбәтәй. Күп фотоларда ул шулай сурәтләнеп калган да). Соңрак бер үк редакциядә шактый еллар бергә эшләү... Әйе, хәтердә казынсаң, үткән гомердәге янәшәлекләрне тагын да санарга була. Болары – тәрҗемәи хәлгә караган фактлар. Ә максат берлеге? Иҗаттагы уртаклыклар? Үзе әйтмешли, бергә-бергә үткәргән күңел бәйрәмнәре? Исәпләп китсәң... Бу очракта әле бер кешене, бер шагыйрьне хәтерләп искә алганда туган уйлар. Ә андый затлар аз түгел бит! Дистәләгән, хәтта күп дистәләгән. Хәтерләр хәл-вакыйгалар күп, яшьрәк буыннарга әйтерлекләре дә җитәрлек. Кыскасы, безнең буынга да мемуарлар язарга вакыт җиткән икән!

Рәшитнең фанилыктан бакый дөньяга күчүенә дә җиде ел үтеп китте. Хәтер офыгыннан китеп онытылу рәшәсендә эреп югалыр өчен ярыйсы гына вакыт. Юк, бу шәхес онытыла торганнардан түгел. Еш искә төшә, юксындыра... Бездә кайчак киткән затлар турында, тәүбәгә килгәндәй булып, ярым рия, ярым риясыз сөйләнүчеләр табыла. Янәсе, вакытында кадерен белмәдек, бәяләмәдек (дөресрәге, үзләре үк белмәделәр, бәяләмәделәр)... Вакытында фәлән исем бирелмәде, төгән премия алмады... Гадәттә, андый соңарып «гаделлек урнаштыручылар» хаклы булмый. Һәр конкрет очрак-фактның үз вакыты, үз сәбәбе, һәр төеннең үз чишелеше. Тормыш логик юрауларга караганда күпкә катлаулырак... Әйе, чыннан да, соңарулар

булгалый. Шулай да премияләрдән, мактаулы исемнәрдән фетиш ясарга да ярамый. Тарихта Вакыттан кристаллашкан Исем генә кала. Тукай, Такташ, Җәлил... Премияләре юк шикелле. Бүгенге замангарак күчсәк, «Әни килде»нең авторы, драматург Шәриф Хөсәенов – Тукай премиясе лауреаты Диас Вәлиевтән ким саналамыни? Яки Саҗидә Сөләйманова шигърияте Гөлшат Зәйнашеваныкыннан түбәнмени? Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты да кайбер исемле лауреатларныкыннан бер дә ким түгел; кайбер яклары белән өстенрәк тә әле.

Шагыйрь гомеренең байтак еллары «Казан утлары» журналы белән бәйле. 15 еллап эшләде ул бездә. 1991 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде. Соңгы елларда редакция вазифаларын күбрәк өендә утырып эшләде. Бергә эшләгәндә кешене шактый ук яхшы беләсең. Төрле яктан. Юк, фәрештә түгел иде шагыйрь Рәшит. Кешегә хас бөтен сыйфатларга ия иде ул. Кирәк чакта кыю һәм усал, кирәк чакта «сабыйларча» хәйләкәр... Тар иңнәргә утыртылган бу «якты башка» Ходай кинаяле, гаҗәп сыгылмалы төртмә тел биргән... Әмма, башкалардан аермалы буларак, бер үзгә сыйфаты бар иде, ул – нечкәлек. Һәрнәрсәдә: шигърияттә дә, мәхәббәттә дә, җор-мәзәк сүздә дә... Ә суверенитет өчен кискен көрәш көннәрендә, Азатлык мәйданында ачлык тотучылар белән бер рәткә басып, халкыбыз киләчәге өчен җанын фида кылырга да әзер көрәшче, милләтпәрвәр икәнен раслады.

Рәшит Әхмәтҗановның рухи яшәве дәвам итә. Әсәрләре чыгып тора. 1998 елда «Рухият» нәшриятында затлы китап рәвешендә аның янә бертомлыгы дөнья күрде. Иҗатын зурлаган мәкалә-очерклар басыла. Туган авылы мәктәбендә 1996 елда ачылган музей бүлмәсенә яңа буыннар аны яд итәргә килә. Казан зиратында Тукай белән янәшә үк диярлек күмелгән каберендә чәчәкләр өзелми...

*2001*

## *ЗАМАНГА ИШ ИҖАТ*

*(Шагыйрь портретына кайбер штрихлар)*

«60 нчы еллар буыны» вәкилләренә алтмышар яшь... Быел, гомумән, каләмдәшләр арасында «алтмышлылар» ишле: Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Фоат Галимуллин, Гәрәй Рәхим, Фоат Садриев, Рауль Мирхәйдәров, Ризван Хәмид... Исемнәрне дәвам итәргә мөмкин. Мәрхүмнәрдән – Рәшит Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди (бу юлларны язган кичне бакый дөньяга күчте, урыны җәннәттә булсын!). Исәпләсәң, һәр ай саен – берәр юбиляр. Һәм исемнәре нинди әле! Һәркайсы үз эшләренең зур осталары. Һәрберсенең әдәбиятта үзенең абруйлы урыны, дәрәҗәсе бар. Шулай да бу алтмыш яшьлекләр арасында әдәбиятыбызда «60 нчы еллар» дулкынын тәшкил итүчеләр берничә генә. Бу термин-атаманы, асылда, ул вакыттагы яшь шагыйрьләр тудыртты. Ул шагыйрьләр арасында иң күренеклеләренең берсе, һичшиксез, Ренат Харис булды.

Морза әдип Әмирхан Еники әйтмешли, значится, Ренат Хариска да алтмыш икән!

Ходай язган булган: әдәби мохиттә бергә-бергә кырык еллап иҗат гомере кичерелгән. Гомерләребезнең өчтән икесе бергә үтелгән. Әйтергә генә ансат. Кырык ел бит ул, кырык көн түгел... Яшь чакта кырык-илледәге кешеләр дә бик өлкән, алтмыш тирәләрендәгеләре инде бик карт булып күренә иде. Хәзер кемнәрдер безгә дә шулай карыйлардыр. Җырдагыча «минем елларым – минем байлыгым!» дип әйтергә генә кала. Хәер, Яшәү дигән Бөек Халәтнең табигый агышын тойган-аңлаган кеше артык уфтанмас. Гомер заяга узмаган бит! Утыртасы агачлар утыртылып ябалдашланган, балалар үсеп җитеп дөнья кендегенә тоташтырылган, салынасы йорт-диварлар салынган... Өстәвенә дистә-дистә китаплар язылган. Теләсәң, өеп куй да аларны, бала сөйгән кебек, тышлыкларын сыйпап иркәлә йә булмаса өсләренә утыр да бер, чиксез офыкларга карап мәңгелек турында уйлан... Ренат Харис, кайбер каләмдәшләре кебек, бу яктан тыныч һәм бәхетледер дип уйлыйм. Артта тынгысыз, әмма мул җимешле, мәгънәле гомер, татлы һәм газаплы иҗат еллары...

Табигать Ренатка талант оеткысын мулдан биргән. Төрле яктан. Ул, теләгәндә, әти-әниләре шикелле, мактаулы педагог була алыр иде (заманында, пединститут бетергәч, Арча педучилищесында укытып та алды), теләгәндә, оста рәссам (ул рәсем ясау белән һәрдаим шөгыльләнә, берничә ел элек Казан музейларының берсендә үз рәсемнәреннән күргәзмә дә оештырды), теләгәндә, музыкант та була алыр иде (нәселләрендә атаклы музыкантлар бар, үзе

дә гармуннарда көйләрне оста яңгырата)... Дөньялыкка ярарлык без белеп бетермәгән тагын бүтән сәләтләре дә бардыр. Әмма ул иң әүвәл шагыйрь буларак билгеле. Шагыйрь булу – бөек ләззәти биеклектер ул, мөгаен. Кешелек тарихын шагыйрьләр бизәкли. Гомер бакый шулай килгән. Ярты дөньяны яулап алган яугир ханнар, патша-корольләр дә Шагыйрь данына кызыккан. Һәр халыкта Шагыйрьнең үзгә бер символ-образы. Кызганыч, бездә шагыйрь образын стереотип рәвештә «тамга салынган» Ходай бәндәсе итебрәк күрәләр. Шагыйрь – Тукай яки Мөдәррис Әгъләмов кыяфәтенә, холык-фигыленә генә сыеп бетә алмый. Шагыйрьләрнең төрлесе булган – дәрвиш-чичәннәре дә, хәким-хөкемдарлары да, бае-ярлысы да, кәрләсе-баһадиры да... Үзебезнең әдәбияттагыларын гына күз алдына китерик: әрвахлар сакчысы Мөхәммәдъяр, гомерлек мосафир Акмулла, зыялы миллионер Дәрдемәнд, гыйсъянчы Такташ, мәхбүс риясыз Туфан, башбирмәс Баттал... Миңа калса, Р.Харис Гете тибындагы шагыйрьлекне үзенә өлге итеп алган. Шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе. Ай-һай! Бигрәкләр дә бөек биеклек! Бездә булырдай эшме бу?

Ренат Харис гомере буе җаваплы хезмәттә булды. Бер ел педагог булып эшләүгә, аны ВЛКСМ өлкә комитетына инструктор итеп алдылар. 60 нчы еллар ахырында «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы секретаре, аннан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, хәзергечә әйтсәк, рәис урынбасары, ун елга якын (1973–1982) Татарстан культура министры урынбасары, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире (1982–1989), соңгы дистә елларда КПССның Татарстан өлкә комитетында идеология бүлеге мөдире, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, Татарстан Дәүләт Советының рәис урынбасары. 1990 елдан бирле (рәттән өч чакырылыш) Татарстан халык депутаты... Безнең арада болай озак еллар буе дәүләти вазифалар башкарган шагыйрь юк та сыман. Халыкча әйтсәк: түрә шагыйрь. Белүемчә, бу статусның күп җайлы яклары белән бергә шактый үзгә кыенлык-тыенлыклары да бар: һәрдаим мәгълүм кысаларда тота торган рәсмилек, сәяси манипуляцияләргә әзер булу, мәҗбүри этикет... Тауның башынарак менгән саен, җилләр көчлерәк! Шундый юл сайлагансың икән... Әмма түрәлек китә торган нәрсә, шигырь кала, шагыйрь кала. Безгә шагыйрь Ренат Харис турында сөйләү дөрес булыр.

Иң әүвәл ретроспектив планда үткән еллар елъязмаларына күз салып алыйк әле. Моннан унбиш ел элек чыккан «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә (төзүчеләре – Р.Даутов, Н.Нуруллина) Р.Харис турында менә нәрсәләр язылган: «...Р.Харис – әдәбият мәйданына 60 нчы еллар башында килгән һәм беренче адымнарыннан ук шигърияттә үз сөйләү формасын, үз стилен булдырырга тырышкан үзенчәлекле шагыйрьләрдән берсе... Р.Харисның шигъри әсәрләре заманча үткен яңгырашы, интернациональ рухы, образлы фикерләүдәге яңача алымнары, кыю метафоралары һәм чагыштырулары, форма өлкәсендәге оригиналь табышлары белән җәлеп итә. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен төрләндерү, шигъри сүзнең җегәрен, эчке куәтен арттыру, чорның олы проблемаларын лирик чаралар ярдәмендә үтемлерәк итеп җанландыру юнәлешендә өзлексез эзләнә, фикер-хисне укучыга сурәтле итеп җиткерү өчен, халык иҗаты символикасыннан һәм әдәбият-сәнгатьтәге шартлы алымнардан мул файдалана.

Шагыйрь үзенең шигырь һәм поэмаларында халкыбызның тарихи яшәеше, кеше шәхесенең тормыштагы урыны, җәмгыять каршындагы җаваплылыгы, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның әхлакый, рухи, иҗтимагый күренешләренә, үзгәрешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык мөнәсәбәтен белдерә. Гомумән, халыкның тарихи үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге, кеше һәм табигать, аларның үзара бәйләнеше – шагыйрь иҗатында үзәк темалардан санала...»

Бу бәяләмәнең конкрет авторы кемдер, әмма төпле әйтелгән. Шагыйрьнең тоткан юлы, кредосы бүген дә шул. Бу Олы Юлдан баручы юлчы-мосафир гына бераз үзгәргән: гайрәтле ир-егеттән хәзер инде ул халык гамен күңеленә җыйган ил агасы – хәким-аксакалга әверелгән... Күп ил-җирләр күрелгән; дөнья тоткасы саналган күпме асыл затлар белән очрашылган, әңгәмә корылган; мәңгелек һәм бер көнлек кануннар турында күпме уйланылган; максат-идеяләрнең дөреслеген кат-кат исбатларга тырышылган... Һәм иң мөһиме: кайда гына, нинди вазифада булынса да, өзлексез язылган, иҗат ителгән.

Бүгенге Ренат Харис – төрле телләрдә чыккан утызлап китап авторы, Республиканың М.Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Каракалпакстанның мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Төрле жанрларда уңышлы эшләрлек сәләте булса да (матбугатта чыккан беренче язмалары тәнкыйть мәкаләләре иде), Ренат гомер буе шигырь язды. Тезмә әсәрдә булган бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, бөтен форма-төрләрен сынап карады. Озын шигырь, кыска шигырь, сонет, баллада, хикәят, либретто... һәм поэма. Поэмаларны күп язды шагыйрь. Утызлап бар бугай. Төрле рухтагылар: һәм лирик, һәм патетик, һәм эротик, һәм публицистик. Менә кайберләренең исемнәре: «Мулланур», «Камил Якуб», «Рәссам», «Җәлилчеләр», «1972 ел икмәге», «Ат иярләү», «Ант суы», «Өч үбешү», «Гармунчы», «Сәйдәш яры», «Борылышта», «Чехов базары», «Идегәй», «Бүре күзе»... Күп бит! Композитор өчен симфония язу нинди зур фундаменталь хезмәт саналса, шагыйрь өчен поэма да шуңа тиң. Бүгенге шигърияттә шулай күпсанлы поэмалар язучылар сирәк. (Дөрес, бу жанрда да зур активлык белән эшләүчеләр бар. Мәсәлән, үзләре әйтүе буенча, И.Юзеев – утызлап, Ә.Рәшитов – унлап, Ф.Гыйззәтуллина дистәдән артык поэма язган. Тик аларның һәрберсе дә поэма микән соң? Бу хакта байтак бәхәсләр булса да, жанр күпләр – һәм шагыйрьләр, һәм укучылар өчен һаман ачыкланмаган булып кала бирә.) Заманында поэма сымак берничә озын нәрсә язган булсам да, бу жанрның чын хасияте, бу очракта шагыйрьнең әсәрләре турында төпле сүз әйтеп, объектив бәяләмә бирә алмам. Бу эшкә көчем дә, вакытым да җитмәс. Махсус өйрәнүне сорый торган зур мәсьәлә. Каләмдәшләр хезмәтенә соклanырга һәм яхшы мәгънәдә көнләшергә генә кала.

Шагыйрьне җырлары буенча да яхшы беләләр. Аның сүзләренә йөзләп көй язылган. Арада менә дигән җырлар бар. Шулай булмый ни! Байтак еллар татарның иң талантлы композиторлары белән хезмәттәшлек итте бит ул. Н.Җиһанов, Р.Яхин, А.Монасыйпов, Р.Еникиев, Ф.Әхмәтов... Чагыштырмача яшьрәк буын вәкиле Резеда Ахиярова белән иҗади дуслыгы бигрәк тә нәтиҗәле булды.

Шагыйрьнең поэзиясе җыр-көйләрдән тыш музыканың катлаулырак сфераларына да үтеп керә алды. Аның либреттолары буенча дүрт оратория язылды. «Кеше» (М.Яруллин), «Казан» (Б.Мөлеков), «Кеше һәм машина» (И.Якупов), «Мулланур» (В.Кожевникова). Үз вакытында алар композиторларның пленум-җыелышларында яңгырап, җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнделәр.

Гомумән, шагыйрьнең иҗаты зур, бай, күпкырлы. Ул «кырлар» сәнгатьнең бүтән төрләре белән дә табигый тоташып китә, икенче төрлерәк әйткәндә, бер зур сәнгать икенче сәнгатьне кузгата, үстерә, ягъни бер-берсенә керешә. Әдәбият-сәнгать тарихында моңа мисаллар бик күп. Ул гына да түгел, аерым бер шагыйрь-иҗатчы аша (зур иҗатчы булса, әлбәттә) тулы бер чорның, бер буынның «кардиограмма»сын күреп була. Алда әйткәнемчә, Р.Харис – 60 нчы елларда килгән шагыйрьләр плеядасының күренекле вәкиле. Ирексездән, яшьлекне искә төшереп, бүгенгедән киләчәкне күзалларга тырышып, әлеге буынның әдәбияттагы урыны турында уйланасың. Уйланыр өчен җирлек зур. Язылмады түгел, байтак язылды бу буын турында, алга таба әле күбрәк тә язылыр.

Тарихи закончалыктыр: җәмгыятьтә мәгълүм иҗтимагый шартлар тугач, аренада милли-рухи алгарышны тизләтүгә сәләтле көчләр пәйда була. XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятында, бигрәк тә аның шигъриятендә, шундый көч 60 нчы еллар башында килгән бер төркем талантлы шагыйрьләр булды. «Кемнәр иде соң алар» дип баш ватып торасы юк, исемнәре яхшы мәгълүм: Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ һәм без фәкыйрегез. Шау-шулы төркемнең үзәгендә булмасалар да, бу рәттә Рәшит Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим, Кадыйр Сибгатуллин исемнәре дә бар. Хәзер, кырык еллар үткәч, бастырып әйтеп була: көчле булган икән бу буын! Берсе генә дә бит төшеп-югалып калмаган, һәммәсе, кем әйтмешли, үз казыгын каккан, үз биеклеген өйгән, арабыздан иртәрәк китеп барганнары да әдәбият тарихында җуелмас «автограф» – зур иҗади мирас калдырып киткән. Бу буынның иҗат башлангычы елларында – 50 нче еллар ахырында – татар шигъриятенең хәле шактый мөшкел иде. Чын мәгънәсендәге зур поэзия әсәрләре сирәк. Мәктәп елларында, күңел шигырьгә сусаган чорда, безгә күбрәк мөтәшагыйрьләрнең китапларын (ә китапларны су урынына «эчә» идек!) укырга туры килде. Дөрес, элгәрерәкләрдән Г.Тукай, Һ.Такташ, Ф.Кәрим бар иде. Ә студент елларында без «максималистлар» ул чорда бик күп шагыйрь саналганнар арасыннан С.Хәким, Н.Арсланов, Ә.Давыдов, З.Мансур, С.Батталларның гына кайбер әсәрләрен таный идек. Тик кайберләрен генә! Бездән бер баш өлкәннәрдән И.Юзеев, Г.Афзал, Х.Камалов, Р.Гәрәй, М.Шабаев, Ш.Галиевләр яшьләр арасында популярлашып барсалар да, кызганыч, безнең буын иҗатчылар өчен кумир булып, поэзиядә кискен борылыш,

сыйфат яңарышы ясый алмадылар. Аларда өлкән абыйларының бишмәтенә ябышу, дөресрәге, сталинчыл идеология традицияләреннән арына алмау көчле иде булса кирәк. Туфан, Җәлилләр әдәбиятка кайтып кына киләләр... Әлбәттә, бу ретропанорама, билгеле бер бәяләмә шул чор өчен. Соңгы 30–40 ел эчендә заманалар нык үзгәрде. Шөкер, уңай якка.

Кемнәр килүенә карамастан, әдәбиятта сыйфатый үзгәрешләр булу котылгысыз иде. Тормыш «көзгесе» – әдәбият тоныкланган яки күзне чагылдырырлык дәрәҗәдә көмешләндерелгән иде. Шул еллардагы шигырь китапларын алып карагыз. Баш өлешендә Ленин, Сталин, партия турында мәдхия куплетлары, аннан хезмәт, бәхетле яшәү рәвеше турында патетик шигырьләр, ахырдарак лирик-мәхәббәт шигырьләре, иң соңыннан әз-мәз юмор-сатира. Олылар шигърияте генә түгел, балалар поэзиясе дә бик нык идеологияләштерелгән иде шул. Тематик яктан грамоталы итеп укмаштырылган шигъри цикллар да сирәк иде (шулай да С.Хәкимнең «Суд залында», Х.Туфанның сайланмаларындагы цикллар хәтердә калган). Хөр фикергә иркен мәйдан булмаудан килгән күренеш. Күрәсең, күпләрнең фәлсәфи-эстетик платформалары, үз принцип-кредолары да анык булмаган. Шигырьнең куплет-шакмак калыбыннан чыгып, ирекле строфалар итеп язу шигырьне «бозу» санала иде, хәтта куплет эчендәге юлбаш хәрефләрне кечкенәдән башлау да гайре табигый кабул ителә иде. Нигездә, партия органнары булган газеталарда фикерле шигырьләрне бастыру үзе бер проблема. Ярый ла елына берничә шигырь бастыра алсаң! Эх, замана! Үткәнгә бүгенгедән торып, акыллы булып бәя бирү җиңел. Ә үзең, шул сугыш, культ тегермәннәрендә «тартылсаң», нишләр идең?

60 нчы еллар буынының элгәргеләрдән бер өстен ягы шул: алар гали белем алып, Шәрык һәм Гареп мәдәниятен ярыйсы ук үзләштереп, үз тарихыбызның моңарчы яшерелгән сәхифәләрен белеп, өйрәнеп, әдәбиятка зур әзерлек белән килделәр, шуңа күрә, беркадәр язу тәҗрибәсе туплангач, тиз арада үз эшенең чын профессионаллары булып җитешә алдылар. Аларның беренче китаплары ук, юка гына булуларына карамастан, эчтәлек ягыннан булсын, җыентыкны тезү-төзү, хәтта иллюстрация-бизәү ягыннан булсын, уңай якка аерылып тордылар.

Ренат Хариска 60 яшь. Шагыйрь өчен аз гомер түгел. Шагыйрьнең олпатлык юбилее. Юбилей димәктән, мин Ренатның теге яки бу зур залларда иҗат кичәләре, юбилей тантаналары үткәргәнен хәтерләмим. Мәһабәт театр биналарында кемнәр генә нинди генә кичәләр уздырмады соңгы елларда. Бер генә түгел, кат-кат, өч-дүрт мәртәбә. Теләсә, Ренат та үткәрә алыр иде. Иҗаты да бар, дәрманы-власте да бар иде. Күрәсең, фейерверклы шау-шуга караганда, сабыр гына язып ятуны мәгъкульрәк күргәндер. Бәлки, алтмыш еллыгы уңаеннан зур кичәләр узар? Узуын телибез, халык алкышлары зур иҗатыңа аваздаш булсын.

Һәр шагыйрь иҗатын төрле кеше төрлечә кабул итә. Р.Харис шигъриятен өнәп үк бетермәүчеләр барлыгын да беләм. Кемнәргәдер Р.Харис поэзиясе салкын, теле моңсыз тоелырга мөмкин. Хәтта «Шигырендә үзеннән дә акыллы булмакчы!» диючеләр дә бардыр. Стиль ул – Кешенең үзе! диләр. Нишлисең, тормышта Харис үзе ничек булса, шигыре дә шул була инде! Әмма беркем дә аның зур фикер иясе – шагыйрь икәнен инкяр итмәс. (Сүз уңаеннан Ренатка шуны да әйтәсе килә: татар әдәбияты тәнкыйтен кризис хәленнән чыгаруда өлеш кертергә иде бит! Синеке кебек теоретик әзерлекле, зур тормыш һәм язу тәҗрибәсе булган әдипләр үзләренең фәнни-тәнкыйди хезмәтләре белән активрак катнашсалар, әдәбияттагы хаос кими, иҗади атмосфера савыга төшәр иде. Шигырьдәгегә караганда тәнкыйтьтә идеолог булу отышлырактыр, бәлки.) Талантлар төрле була һәм аның һәрберсе ихтирамга лаек. Бездә артык шагыйрьләр юк. Максатлар бер булганда, һәркем үзенең кирәк урынында. Милләт, ил язмышы хәл ителә торган гасырда «Татар акыллары, татар шагыйрьләре, җыелыгыз!» дип кычкырасы килә. «Карурман» җырындагы «заманалар авыр, еллар ябык» дигән сүзләр көннән-көн актуальрәк яңгырый...

Әтисе Мәгъсум (шөкер, ул әле исән-сау!) сугышка алынганда, нәни Ренатка берничә ай гына була. Ата кеше сабыеның бердәнбер фоторәсемен үзе белән ала, фронтлар буйлап күкрәк кесәсендә йөртә. «Шушы сабый хакына исән үттем сугыш мәхшәрен», – ди Мәгъсум ага. Әнә шул сабый хәзер булдыклы ир, алтмыш яшьлек олпат шагыйрь булып XXI гасырга аяк басты. «Яшим, эшлим, раслыйм!» дип иҗат итә ул.

*2001*

## *ЯНА-ЯНА ИҖАТ ИТӘ*

Айдар Хәлим – үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феномен күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмеш-белмәмешкә салынамы – анысы мөһим дә түгел – әмма Вакыт галиҗәнаплары бу Шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә инде.

Әдәби даирәдә Айдар Хәлим (баштарак ул совет паспортындагыча Борис Хәлимов булып танылa башлады) исеме инде кырык еллап даими ишетелеп, аңга сеңеп килә. Элегрәк – 60 нчы елларда ул, башкалардан әллә ни аерылып тормыйча, дистәләгән яшь һәм башлап язучылар исемлегендә йөрде. Җәмәгатьчелекнең күз уңыннан югалгалап торган чаклары да булды. Әле Башкортстанда, әле Татарстанда, тагын әллә кайларда яшәп-яшәп алулары да, күрәсең, моңа сәбәп булгандыр. Ул шулай ук әдәбиятта «Фәйзуллиннар буыны» (мин чыгарган термин түгел!) дигән обойма-исемлектә дә саналып йөртелмәде. Гәрчә ул яшь һәм иҗат башлангычы потенциясе белән нәкъ шушы буынның табигый талантлы бер вәкиле булса да. Хәер, мондый шартлы дифференциянең хаҗәте дә шуның кадәр генә. Ахыр чиктә һәр Иҗатчы үзенең намусы, Вакыт һәм Халык алдында япа-ялгыз бергә-бер бит! Әнә тәнкыйтьчеләргә барлар өчен җайлы булган буын-төркемнәргә кермәгән Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, прозада Миргазиян Юныс һәм Адлер Тимергалиннар, драматургиядә Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллиннар үзләре бер тылсымлы иҗат дөньясы тудырмадылармыни?

Айдар Хәлим – бу дөньялыкта Яшәү казыгын нык каккан әдип. Таныйк: соңгы 10–15 ел эчендә ул халыкара масштабтагы фигурага әйләнде. Аны һәр даирәдә шактый ук яхшы беләләр: гади укучылар да, сәясәттәге эшмәкәрләр дә, хакимият-күзәтү вәкилләре дә, чит ил даирәләре дә... Хикмәт нидә? Шагыйрьлеген, язучылыгын таныган хәлдә, миңа калса, ул иң әүвәл бүгенге көннең иң актив милләтпәрвәр публицисты. Ул ике башына да ут капкан шәм шикелле. Өстәвенә уртасын да үзе үк бик теләп яндыра шикелле. Күрәсең, генетик коды шундый. Ул гүя МЧСның (Министерство чрезвычайных ситуаций) бер җаваплы идарә пультында. Кайда хәвеф, кайда бәрелеш, кайда яра – Айдарның каләме шунда. Соңгы ун елда чыккан китапларын искә төшерик: «Книга печали, или Записки аборигена», «Гомеремнең ун көне», «Этот непобедимый чеченец», «Минем түгәрәк имәнем»... Кайберләре, үзебездә мөмкинлек табылмагач, чит илләрдә басылган, суд-мәхкәмә чикләрен үткән... Аннан да кыюрак, зирәгрәк, гайрәтлерәкләр бар икән, әйдә, андый әсәрләрне үзләре язып күрсәтсеннәр! Бу китапларның берсе генә дөнья күргән очракта да, Тарихта урын дәгъва итәргә мөмкиндер ул.

Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары кимәлдәге профессиональ иҗат итеп була икән? Айдар Хәлим ике телдә – рус һәм татар телләрендә (теләгәндә, саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь (әле яңа гына чыккан «Милли шигырьләр» китабын укып карагыз!). Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын, – максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы – талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Пьесалар язуы да мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте ул – проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә генә дип беләм. Шулай да төп проза әсәрләре – «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Казыктагы тальян» – «Казан утлары»нда үз вакытында басылып чыктылар. Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия-бүләкләргә лаеклы әсәрләр.

Айдар Хәлим – һәр зур талантка хас булганча, гаять катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Дөрес, аны тирән беләм дип әйтә алмыйм, нык аралашып бер мохиттә яшәлмәде, холкын һәм гамәлен күзәтүләрем буенча шулай дип уйлыйм. Ярсулы, ашкынулы, каударр әдип. Җанындагын, күңелендәген әйтеп калырга өлгерә алмамдыр дип, бәргәләнә-кабалана да бугай ул. Кайчак уй-фикерләре, хис-тойгылары кирәк дәрәҗәдә «утырып» та өлгерми, алар инде ялкын йә хәнҗәр булып кемнәрнедер яндырып, яралап та өлгерә. Кайчак берәр затны өскә чөйгәндә, бүтән берничәне билгә кадәр батырып та куйгалый... Нишлисең, талант табигате хәлләре... Иман һәм талант хакына кайбер чиктән чиккә ташлануларны кичерергә дә туры килә. Әйе, ашыга Айдар. Ашыгырсың да шул: төрле төбәк-кыйтгаларда сүнеп бара торган

татар учакларына тын-сулыш өрергә өлгерергә кирәк! Бүген үк, хәзер үк! Иртәгә инде соң булуы бар... Ул гел юлда кебек миңа. Әле Урта Азиядә, әле Кавказда, әле Урал якларында, Оренбург далаларында... Сүз уңаеннан Айдар Хәлимнең соңгы биш елда татар халкының Милли Мәҗлес рәисе булуын да искә алып үтик. Дөресен әйтим, аның бу хезмәтенә, эшнең асылын һәм нәтиҗәлелеген тиешенчә белмәү сәбәпле, бәя бирә алмыйм. Милләт мәнфәгате өчен саулыгын, рух җегәрен кызганмый янып йөрүен генә беләм. Күрәсең, дөньялыкта һәммәсен дә колачлап бетереп булмый торгандыр. Бәлки, Милли Мәҗлес башлыгы өчен Садри Максудига хас сыйфатларга ия булырга кирәктер, халкыңның да XX гасыр башындагы кебек ишле һәм бердәм булуы шарттыр...

Айдар Хәлимгә 60 яшь тулган икән! Гаҗәп түгел, яшәгәч, яшь саны барыр инде ул. Иллесе дә, алтмышы да, җитмеше дә... Бу алтмыш еллык Олуг шәхес Айдар замандаш турында, аның иҗаты турында уйланып алу өчен бер форсат кына. «Алда гомер бардыр барын, сагындыра узганы» дисәк тә, шагыйрәбез Клара Булатова әйтмешли, «алда язлар әле!». Чын язлар, үткән гомер белән түләнеп алган язлар! Айдар Хәлим феномены безгә яңа хикмәтләр, яңа ачышлар күрсәтер әле.

*2002*

## *«ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК»*

Рәмис Аймәтнең 2000 елда чыккан «Шомырт салкыннары» дип исемләнгән китабы һәм соңгы елларда язылган шигырьләре (алар «Мәгариф» нәшриятында «Айның аръягында» исеме белән аерым китап булып чыгып килә) белән танышкач, бүгенге шигъриятебез, бигрәк тә яшьрәк шагыйрь-шагыйрәләр иҗаты турында төрле хисләр кичереп, уйланыбрак калдым әле. Уйланыбрак кына түгел, үз-үзем белән сөйләшеп дигәндәй, бәхәсле уйларга да тарыдым шикелле. Бусы да ярый. Димәк, битараф калдырмаган, уяткан, кузгаткан...

Рәмис Аймәт – шагыйрь, һәм дә профессиональ яктан шактый ук җитлеккән шагыйрь. Шигырьләре гамьле, мәгънәле; композицион яктан төзек, күбесе камил дәрәҗәдә. Рәссамнар өчен пространство һәм пропорцияне «үтәли күрү» ничек мөһим булса, шагыйрь өчен сүзнең куәтен һәм мәгънәви матурлыгын тоя алу иң кирәк зарурлык. Шуңа өстәп, әлбәттә, күңел генә үлчи ала торган чама хисе... Тырышып, өйрәнеп кенә булдырырга мөмкин нәрсәләр түгел; табигатьтән, тумыштан бирелә торган сыйфатлар алар. Йә бар, йә юк. Шөкер, шагыйрьлекне Рәмискә табигать үзе мул биргән. Өстәвенә Рәмис Аймәт көнкүреш-яшәештә дә булдыклы, үткен егет булып чыкты. Менә дигән журналист, шәп оештыручы буларак әдәби-иҗтимагый тормышта аның инде үзе сызган буразналары, ярыйсы ук саллы хезмәт-биографиясе бар. Әйтик, барлыгын да бик азлар гына белгән Шәриф Камал музеен янәдән халыкка танытты ул. Мөмкинлекләре чикле булса да, музейны үзенә күрә бер мәдәни учакка әйләндерә алды. Хәзерге көндә Габдулла Тукай музее директоры буларак нәтиҗәле, актив эш алып бара. Моннан җиде-сигез ел элек әле утызы да тулмаган яшь егет Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып та эшләп алды. Ул вакытта Берлек әгъзасы да түгел иде бугай... Матбугатта, бигрәк тә «Шәһри Казан» газетасында, аның күренекле каләм осталары белән төпле әңгәмә-язмалары һаман истә. Республика масштабындагы күпсанлы әдәби-музыкаль кичәләрнең истә калырдай булып узуында да аның хезмәте зур: сценарийлар яза, оештыра...

Ярый, хуш, болары шәп; шигъриятькә күчик. «Нәрсә ул Шигърият, нәрсә ул Поэзия?» дип, риторик сорау куеп тормабыз. Чөнки төгәл билгеләмәсен барыбер беркем дә әйтә алмас. Галимнәр матдә-төшнең үзәгенә үтеп өйрәнә алсалар да, хис һәм фикер төенен таркатып анализлап бетерү мөмкин түгел. Мәхәббәт шикелле, ачып бетерелмәгән серлелеге белән мәңгелектер дә ул. Ә сер булганда гөманга урын бар. Шуңа күрә һәркемнең үз аңлавы, үз мөнәсәбәте. Берәүнең берәүгә «син – үзең шигырь!» дигәнен ишеткән бар. Димәк, ул – кызык, бай, гомер буе өйрәнеп яшәрлек кеше! Үзебез дә бер сорау куйыйк әле: борынгы заман шагыйренең мәхәббәт шигырьләре бүгенге шагыйрьнекеннән нәрсәсе белән аерыла? Кайчакта фәлән гасырда язылган шигырьләр күбрәк тә тәэсир итә әле! Шулай булгач?.. Юк, һаман языла, язылачак мәхәббәт шигырьләре! Димәк, ул – кабатланырлык, кабат «янарлык» мәңгелек тема, мәңгелек яну мәйданы. Ә «заман улы», «бүгенге көн каһарманы», «чор елъязмасы» дигән төшенчәләр каян килгән? Без бер-беребезне рәсми йә нәрәсми рәвештә бүгенге көн сулышын тойдырткан әсәрләр язарга өндәмибезме? Хак нәрсәме бу, әллә

күпмедер дәрәҗәдә мәңгелеккә омтылуны чикләүме? Күз алдына китерик: каядыр – күренерлек ераклыкта – йорт-оя янып ята, кемдер ут эчендә, ә шул вакытта син, бернигә исең китмичә, мәхәббәт шедевры язып утырасың... Бер җирдә – фаҗига, бүтән бер җирдә – тантана. Вердикт чыгарып, хөкемдар булу кыен. Бер уйласаң, үлемсез әсәр тудыру – үзе могҗиза, үзе батырлык бит әле! Әй, дөнья! Кем шагыйре син? Кайда яшисең? Фәләстиндә яки Швед җирендәме? Франциядә яки Чечнядамы? Кояш бер булса да, болытлар төрле, җирдәге күләгә-шәүләләр төрле... Тамчы балкышлары бертөслерәк күренсә дә, чыкныкымы, күз яшенекеме икәнен сирәкләр белә.

Рәмис Аймәт шигырьләрен укыганда килгән сораулы уйлар бу. Иҗат кредосы, эстетик принциплары үткән гасырның икенче яртысында формалашкан, әдәбиятка 60 нчы елларда килеп, бүген 60 яшьлекләр рәтендә саналган, «поэзиябез кемнәр кулына кала» дип, җитди уйланып йөргән кеше башына килгән уйлар. Рәмис – бездән соң килгән буын, безнең балаларыбыз буыны. Кайсы заман шагыйре соң бу Рәмис Аймәт дигәннәре? XVIII яки XIX гасырныкымы, әллә XXI некеме? Рәмиснең үтә индивидуаль шигырьләрен укып моңа тиз генә җавап табу кыен. Ә беләсе килә! Заман чалымнарын сиземлисе, тоясы килә. Мине, сине борчыган проблемалар турында шагыйрьнең дә мөнәсәбәтен ачыклыйсы килә!

Ялгызлык – иҗатчының гомер юлдашы. Шагыйрь кеше ялгызлыкта Дөнья белән сөйләшә торган зат. Шуңа да иҗатта лирик «мин»нең булуы табигый хәл. Әмма... чама белән... Шагыйрьнең «лирик мин»гә тулы хакы булса да, фәкать тоташ «мин»гә генә хакы юктыр. Рәмиснең байтак шигырьләрендә «Дөнья һәм Мин» (бәлки әле, «Мин һәм Дөнья»дыр?) төп лейтмотив булып бара. «Мин Коръәннең әле бүгенгәчә язылмыйча калган аяте» (!), «Көтәм хәзер бары Үземне мин, кайтам хәзер бары Үземә», «Мин әле тумаган, ә инде Күкләрдә укыйлар җеназа», «Үз күчәрем тирәсендә үзем сәгать угы кебек әйләнәм», «Мин җирләргә төштем. Озаккамы?..» Мондый юлларга, һәр шигырьдә үк булмаса да, икесенең берсендә тап буласың, С.Рәмиевнең «Мин»е кечкенә булып кала...

Әллә Рәмис, «искәрмәсе булып кануннарның», моңарчы беркем дә белмәгән үзгә микро яки макродөнья тудырамы? Һәрхәлдә, егеттә моңа омтылыш бар. Амбиция дә, нарциcслык та, сәләт тә. Тудыра калганда кешеләргә (гавамга дип әйтсәк тә ярыйдыр) кызык һәм тансык булырмы ул дөнья?

Дөресен әйтим: Рәмис шигырьләрен кат-кат укып та, язганнарының җелек-үзәгенә үтә алмыйча шактый изаландым. Ә «ачкыч» «Шомырт салкыннары» китабының аннотациясендә ачык ята икән ләбаса. Анда болай язылган: «Китап – яшәү-үлем арасында бәргәләнгән мәңгелек җанның сыктау һәм тантана итү үзгәлеген тоя алучыларга багышлана...» «Мәңгелек җанның үзгәлеген тоя алучылар» күп булмаска да мөмкин. Әмма һәр кешенең шигырьләргә карата үз фикере булуы бик ихтимал. Мин, мәсәлән, шагыйрьнең кайбер шигырьләрен укыганда үзгә бер сәер хис (һәрхәлдә, дәртле, шатлыклы, «яшәргә котырта торган» хис түгел) кичердем: әйтерсең айлы төндә мәрмәр ташлар арасында – Мәңгелек йортта йөрим... Ялгызлык. Мәгъруpлык. Билгесезлек. Чарасызлык. Мизгеллек... «Зират җиле...» Шигырьләрдә төшенкелек мотивлары да җитәрлек. «Язмыш суккан имән кебек мин дә, аунап ятам җирдә – ни чара?», «Белмәдегез кадерем! Нурым хәрам! Җирдә – золым. Барыйм кая мин?», «Каракоштай атылыр гарешләргә, соң сулышым, соңгы сәламем», «Дөньямда тереклек юк инде, юк күптән», «Ах, арылган чиксез галәмнәрдә оча-оча бөтен көчемә», «Авып бара шәмем...», «Кәфенемне бирче ак бүз ертып, икмәк кебек, җаным төрергә»... Әгәр, С.Хәким әйтмешли, «Мусалар, Алишлар торып», Туфаннар, Батталлар, Исәнбәтләр уянса, яшь шагыйрьнең әлеге шигырь юлларын укып гаҗәпләнерләр иде кебек... Остазларча, көрәшчеләрчә (һәр көчле кеше көрәшче булмый, һәр пәһлеван мәйданга чыкмый икән!) сабак-киңәшләрен бирерләр иде... Автордан янә бер цитата: «зыр-зыр килеп мин үз күчәремдә, чыгармын күк тәмам чыгырдан». Чыгырдан ук (чамадан ук) чыкмаска иде бит!..

Алда әйтелгәнчә, Рәмис Аймәт – чын шагыйрь. Шигырьне шактый оста үрә белә. Табигать стихиясендә табигый «эри» ала. Ул үзен Җир, Су, Күкнең тере бер күзәнәге итеп тоя һәм шуны шигъри сурәттә раслый да. Яңгыр белән бәйләнешле берничә шигырьне генә укысагыз да, сез моңа инанырсыз. Үзеңне Табигать берлегендә тою зур нәрсә, шагыйрь өчен – бигрәк тә. Китапта поэтик күренешләр аша уйга салырлык строфалар шактый мул. Гомумән, шагыйрьнең потенциаль мөмкинлеге зур. Хәер, яше дә бәләкәй түгел: җитлеккән Пушкиннар, Байроннар яше. Татар шагыйрьләренең дә байтагы (Бабич,Тукай, Такташ, Кәрим, Җәлил...)

кырык яшьләренә кадәр тормышта һәм поэзиядә төп миссияләрен үтәгәннәр инде. Үрнәкләр, гыйбрәт алыр хәлләр җитәрлек.

Шәхси-интим хисләргә күп урын бирелсә дә, Р.Аймәт иҗатын тематик яктан тар дип әйтмәс идем. Мәңгелек категорияләр белән фикерләүгә омтылыш булгач, тар була да алмый. Мәсәлән, Ирек турында фәлсәфи шигырьләре бик тә гыйбрәтле. Шәхес Ирке фонында ил-халык Ирегe турында да тирән мәгънәле фикерләр әйтелә. Соңгы елларда язылган әсәрләрендә, үткән заман термины белән әйтсәк, гражданлык хисләре көчле. Шулай ук Р.Аймәт шигырьләрендә Такташ, И.Юзеев, Роб. Әхмәтҗан, Зөлфәт кебек шагыйрьләр иҗатына хас романтик юнәлеш тә уңышлы үстерелә дип беләм. Киләчәктә, шагыйрь иҗатының аңа гына хас асыл сыйфатларын күреп, аңа гына хас үзенчәлекләрен тәфсилләп анализлаучылар булыр әле. Шәхсән минем үземне Рәмиснең кайбер шигырьләре үлем-яшәү, мәхәббәт-хыянәт, хыял-чынлык, галәм-күзәнәк, җир-күк, җәннәт-кыямәт, рия-ихласлык, мәңгелек-мизгел кебек категория-төшенчәләр турында янә кайтып уйланырга мәҗбүр итте.

Шигърият дип җан атып тормаган бу заманда (андый заман юк та бугай) һәр талантның халык файдасына тулырак көчендә эшләве безнең өчен бик мөһим. Шигърият мәйданында, ир-егетләрдән бигрәк, кыз-кымыз мәш килгән чорда бигрәк тә.

Дөньяларның кайсы читендә мин,
Вакытларның кайсы чигендә,
Гомеремнең кайсы мизгелендә,
Хыялымның кайсы күгендә
Яшим икән?

Бу юллар Р.Аймәтнең «Икән?!» исемле шигыреннән. Шагыйрьгә үз сорауларына җавап табарга булышыйк.

Дөньяның читендә түгел, уртасында, көрәшче булып, ил гаме белән яшә! Вакыт эчендәге вакытны табып, халкыңа хезмәт ит! Гомереңнең иң матур чоры – хезмәттә яну чоры. Хыялыңның күге ил бәхетенә багышланган олуг иҗат булсын!

*2004*

## *БАТМАСКА ТУГАН БАТТАЛ*

Яңа салынган күпер аша Каманы чыгып, Биләр якларындагы атаклы Изгеләр тавына бару юлында Зур Тигәнәле авылы кала. Исеме Шәле, Әлдермеш, Кырлай кебек телдә гел яңгырап тормаса да, үзенчә данлы авыл ул. Ерак тарихи тамырларны барлап тормыйча, бер генә факт та шуңа дәлил була ала: биредә үткән гасыр башында Вазыйх исемле агайның өч угланы туган – Салих, Абдулла, Мөбарәк. Соңрак татар халкына дан китерә торган шәхесләр – шагыйрь, музыкант, каһарман солдат (һәр өчесе дә заманында солдат булып сугышта катнашкан, Абдулла дигәне Җәлилләр белән көрәштәш булып һәлак була). Тигәнәлене үтеп киткәндә, миндә һәрчак сораулы уйлар туа: авыл халкы үзенең данлыклы уллары белән тиеш дәрәҗәдә горурлана микән? Без – язучы-сәнгать кешеләре – аларны тиешенчә зурлый-бәяли алдыкмы? Һәм, ниһаять, яшь буыннар алар турында яхшы беләме? Сорауның беренчесе турында кистереп әйтә алмыйм, әмма соңгы икесенә җавабым шул: юк, тиешенчә бәһали дә алмадык, алар турында килер буыннар аңына тиешенчә сеңдерә дә алмыйбыз шикелле. Бу сүзләрне иң элек Салих Баттал мисалын күз алдында тотып әйтүем, утыз елдан артык әдип белән азмы-күпме аралашып, иҗатын беркадәр белгән каләмдәше буларак фикер йөртүем.

Исән булса, быел аңа йөз яшь тулган булыр иде. Салих ага Баттал, туксан ел яшәп, моннан ун ел элек гүр иясе булды (хезмәттәшебез шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән бер көннәрдә вафат булды ул). Салих Баттал гомере буе кабатланмас зур шәхес булып яшәде, зур шәхес булып иҗат итте, соңгы көннәренә кадәр үз вөҗданына, үз иманына тугрылыклы булып кала алды. Бездә Ходайдан талант бирелгән каләм ияләре шактый, әмма аларның һәммәсен дә зур шәхес дип тану кыен. Асылда, фәкать зур шәхес кенә тормышта тарихи эз калдыра аладыр ул. Салих Баттал, әйтелгәнчә, XX йөз башында дөньяга килгән. Искә төшерик: әдәбиятның

киләчәген белдерәчәк кемнәр туган дәвер соң бу? Һ.Такташ, Г.Бәширов, К.Нәҗми, М.Җәлил, Х.Туфан, А.Шамов, Ш.Маннур, Ә.Ерикәй... Болар – С.Батталның яшьтәшләре, чордашлары, буындашлары. Иҗатлары да саллы һәркайсының. Рәсми яктан да киң танылу алган (дөрес, кайберләре үлемнәре аша, төрмә-сөргеннәр аша...) әдипләр. Кайсы – герой-каһарман, кайсы – югары дәрәҗәдәге депутат, кайсы – лауреат, кайсы – рәис-җитәкче, кайсы – яшьләй үк орденлы шагыйрь... Ә Салих Баттал? Ул да танылу алды. Шөһрәтле рәсми исемнәрсез, үзе булып, шәхес булып, Салих Баттал булып кала алды. Калмый ни! Ике метрлы мәһабәт буй-сын, курку белмәс холык, халыкчан талант... Табигать аңа күпне биргән булган. Ул үзе дә бу дөньяга кем булып туганын яхшы белеп яшәгән, күрәсең. Кемгә дә баш имәде, кеше иреген тыйган тәртип-кануннарга җайлашмады. Сирәк очрый торган шәхес. Яшәү рәвешендә һәм иҗатында төп сыйфат-билгеләрнең берсе – колачлылык, масштаблылык, туры сүзлелек, хөрлек... Аңлашыла да, уналты яшеннән үк нык бәдәнле үсмер Мәскәү якларында батрак-зимагурлык мәктәбен үтә, егетлек чорында Ленинград, Оренбургларда укып, очучы-летчик була, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнеп, әсәрләрен бастыра... Үзе яшь, үзе очучы, үзе язучы. Экзюперидан кай җире ким?! Өстәвенә беренче буын совет язучысы, 1934 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Салих Баттал – күпкырлы талант иясе. Ул – шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы, сатира-юмор остасы, тәрҗемәче. Шулай да, минемчә, әдәбият тарихында шагыйрь һәм прозаик булып калачак ул. Заманында пьесалары Академия театрында спектакль итеп куелса да, аны драматург буларак яхшы беләм дип әйтә алмыйм. Театр белгечләре төгәлрәк әйтер. Чәчмә әсәрләреннән иң билгелеләре – «Сигезенчесе кем?» һәм «Баштан үткәннәр» дигән повестьлары. Беренчесендә беренче бишьеллыклар һәм Ватан сугышы чорында яшь очучының катлаулы язмышы сурәтләнсә (повесть детектив әсәрләргә хас мавыктыргыч сюжетка корылган), икенчесендә – «Баштан үткәннәр» дигән автобиографик әсәрдә – автор, гомеренең истәлекле, кызыклы вакыйгаларын искә төшереп, ил һәм чор турында уйлануларын, заманының атаклы шәхесләре В.Чкалов, А.Фадеев, Г.Ибраһимов белән очрашу тәэсирләрен бәян итә. Татар әдәбияты тарихында гыйбрәтле әсәрләр алар.

Салих Баттал беренче нәүбәттә, әлбәттә, шагыйрь, эпик жанрларны иярләргә сәләтле, фикерле шагыйрь, халыкчан шагыйрь. Үткән гасыр урталарында ул үзен шулай итеп таныта алды да. Совет чорындагы шагыйрьләрдән беренчеләрдән булып бөтенсоюз масштабында яңгыраш алды. «Олы юл буйлап» (икенче исеме – «Газзә») шигъри повесте «Новый мир» журналында басылып чыкты (сирәк хәл!). Аның иҗаты турында А.Твардовский кебек олуг шагыйрьләр язып чыкты. 50 нче еллар башында ул, мөгаен, татар поэзиясенең иң алдынгы сафындагы кеше булгандыр. Шул чорны фаразлап карыйк: поэзиябезнең горурлыгы булачак С.Хәким, Н.Арслановларның чын талантлары ачылып кына килә; Х.Туфан, М.Җәлилләр халыкка әле кайтмаган... Дөрес, Ф.Кәрим иҗаты да бик популяр иде ул чорда.

С.Батталның иң күренекле әсәре, әлбәттә, «Чирмешән ярларында» исемле шигъри романы. Соңгы дәвердә язылган беренче шигъри роман ул. Ни өчен соңгы дәвердә, дим, чөнки ул рәткә борынгы чордагы «Кыйссаи Йосыф», «Идегәй»ләрне дә шигъри романнар рәтенә кертергә буладыр. Заманында шигъри повесть, шигъри роман дип аталган озын әсәрләр чыккалады бездә: Ш.Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы», Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң»... Әле күптән түгел генә Р.Харисның «Исемсезләр» дигән күләмле әсәре аерым китап булып дөнья күрде. Бу әсәрләрнең кайсы – әдәби факт, кайсы – вакыйга, кайсы казаныш икәнен Вакыт галиҗәнаплары әйтә килә һәм әйтәчәк. С.Батталның «Чирмешән ярларында», жанр ягыннан ничек кенә аталмасын, классик әсәрләр рәтенә керергә лаек, минемчә. Р.Даутов, Н.Нуруллиналар төзеп чыгарган «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмәдә (1986) бу әсәр турында мондый юллар бар: «Халык җырларының форма үзенчәлекләреннән оста файдаланып язылган, шигъри детальләргә, үзенчәлекле күренешләргә, отышлы драматик ситуацияләргә бай булган бу әсәр 1905–1921 еллар арасындагы татар авылының катлаулы тормышын, кискен сыйнфый каршылыкларны, халык массаларының азатлык өчен көрәшен сурәтли». Дөрес әйтелгән. Шуны гына өстисе килә: бу әсәр яңа буын шагыйрьләренә осталык мәктәбен үтү өчен менә дигән кулланма да. Халык иҗатын үз әсәрләрендә менә ничек итеп оста файдаланып була икән! Мәңге өйрәнерлек «Идегәй» чалымнары бар бу әсәрдә.

Гомумән, Салих ага Батталның яшәү рәвеше дә, иҗат алымнары да, мирасы да гыйбрәт-сабаклар алырлык. Кодрәтле генга ия булып яратылу, җирне-күкне бер итеп дигәндәй,

алыпларча яшәү, сөю-сөелү һәм гаилә фаҗигаләре, рухи маяк-ориентирлар билгеләгәндә ялгышулар, үзе инанган принциплар өчен кирәк-кирәкмәскә көч түгүләр... һәм финал – ялгыз картлык (ни кызганыч, күктә очып янмаган, суда батмаган Салих ага ятакта, җылыткыч рефлектордан одеалына ут кабып, ис һәм ялкыннан буылып үлде)...

50 нче елларда әдәбият каһарманы булган Салих Баттал, гомеренең икенче яртысында элек алынган иҗади темпны саклый алмады. Совет-партия системасы корган күпсанлы барьерларны җиңәргә тырышып бихисап вакыты әрәмгә китте аның. Ахырда, Вакыт һәм Система башбирмәс Батталны да «почмакка терәде». Бирелүен бирелмәде Баттал, әмма кирәкмәгән ыгы-зыгы аның иң кадерле вакытын ашады, иҗат көчен таркатты, талантының тиешенчә үсүенә ирек бирмәде... Ул гына да түгел, заман идеологиясе басымы сәбәпле, әдипнең иҗаты тиешенчә өйрәнелмәде һәм бәһаләнмәде. Әдип иҗатын җитди өйрәнгән фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Замандаш каләмдәшләренең күбесе аңа битараф булдылар. Күпләр әдип гамәлләрен эчтән генә хупласалар да, аның белән ачыктан-ачык фикердәш булудан курыктылар. Дөрес, бик сирәк булса да, үзе исән чакта ук, аңа уңай мөнәсәбәт белдерүчеләр дә табылды. Мәсәлән, 1990 елда А.Гыйләҗев матбугатта язып чыкты: «Кичерә алсаң, кичер, Салих ага! Без синең арттан килүче, аз-маз кыен ашаган кешеләр дә сиңа терәк була алмадык! Безгә сабак, бездән соң килүчеләргә акыл бу!» Икенче бер зур әдип И.Нуруллин «Казан утлары»нда (1993) болай дип чыгыш ясады: «Салих Батталның шагыйрь буларак бүгенге көнгә кадәр тәнкыйтьтә үзенең тиешле бәһасен алганы юк. Мин шәхсән, совет чоры поэзиясеннән өч шагыйрьнең исемен атагыз, дисәләр, Такташ, Туфан, Салих Баттал, дияр идем».

Үзе исән вакыттагы кебек, хәзер дә аның иҗаты турында каршылыклы фикерләр ишетелә. Менә кичә-бүген генә әйтелгән кайбер яңа искәртүләр. «Безнең заман герое» дигән бәхәс уңаеннан Айдар Хәлим болай яза: «Безнең диссидентыбыз – бердәнбер диссидентыбыз – бөек шагыйребез Салих Баттал иде... Татар шагыйрьләренең Тукайдан кала беренче бишлегенә керә торган сирәктән сирәк шагыйрь». Ә тәнкыйтьче Р.Мостафин, аңа каршы килеп: «...һич тә бөек дип атап булмый. Шигъри осталыгы чамалы, метафоралары сай, поэмалары артык озын һәм күбесенчә коры сөйләмгә корылган. Беренче бишлеккә түгел, егерменче бишлеккә дә керүе шикле» («Казан утлары», 2005, № 5).

Менә шулай... Хәер, кем ни сөйләмәс! Атаклы җырчы Рафаэло турындагы фильм исеме искә төшә: русчасы – «Пусть говорят». Сөйләнсеннәр сәнә! Әдәбиятчы галимнәргә кайсы тишеккә, гафу, кайсы бишлеккә кертәсе турында баш ватканчы, әдипнең мирасын җыеп тупларга, томлыкларын бастырып чыгарырга булышырга иде! Юбилей уңаеннан табигый бер сорау: кайда икән Салих Баттал архивы? Бармы ул? Булса, ышанычлы куллардамы? Әйтик, шагыйрьнең «Батый ханга хат» дигән поэмасының тулы варианты кайда икән? 80 нче елларда Себердә чыга торган «Байкал» журналында кыскартылган тәрҗемә варианты чыккан иде. Үз телебездә басыла алмады шикелле ул поэма. Гомумән, С.Баттал иҗаты белән бәйләнешле сораулар байтак, һәм алар әледән-әле чыга тора. Яшәве гадәти, иҗаты шома булса, бәлки, сораулар, каршылыклы фикерләр азрак булыр иде.

Алда әйтеп үткәнчә, С.Баттал иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Төрле елларда аз-маз күренгәләгән мәкаләләр, нигездә, юбилей даталары уңае белән язылганнар. Р.Мостафинның шактый кискен сүзләреннән соң мин, кулым җиткән кадәр, С.Баттал турында моңарчы язылганнарны барлап чыктым. Әллә, мин әйтәм, шагыйрь иҗатын кирәгеннән артык бәялимме (чыннан да, С.Баттал иҗатында бәйләнерлек нәрсәләр җитәрлек!)? Бүтәннәр ни уйлый? Үзебезнең журналда моннан ун ел элек әдип турында мондый сүзләр укып тынычландым тагын. «Салих Баттал XX гасыр татар әдәбиятының иң мәртәбәле олы исемнәреннән берсе саналырга хаклы. Ул – безнең чор тормышын бөтен каршылыклары белән тулы чагылдырган күпсанлы шигырьләр, поэмалар, шигъри һәм чәчмә повестьлар, драма әсәрләре авторы. Ул барыннан да бигрәк халкыбыз, аның милләт буларак яшәве өчен иң кыен чорларда да каһарманнарча көрәшкән бунтарь, үзе дә легендага әверелгән зур шәхес» (редакцион кереш мәкаләдән өзек).

Язмамны Вазыйх атлы агайның Зур Тигәнәле (кайбер язмаларда Олы Тигәнәле дип йөртелә) авылында туып үскән өч улы турында әйтеп башлаган идем. Алда искәрткәнчә, бер улы – Абдулла дигәненең 1944 елда Җәлилләр белән бергә башы киселә. Салих абый моннан ун ел элек вафат булды. Мөбарәк дигәне – татарның атаклы гобойчысы – әле исән дип беләм.

Күреп танысам да, уйнавын ләззәтләнеп тыңласам да, шәхсән таныш түгелмен. Азмы-күпме аралашканым Салих ага булды. Ул чак яшьрәк булганмынмы, әллә акыл шәрифләре җитеп бетмәгәнме, аның белән дә аз очрашылган. Күп нәрсәләрне сораштырасы калган да бит!.. Шулай да Салих ага Баттал турында кайта-кайта уйланылган икән! Аңа бәйләнешле моннан 12 ел элек язылган истәлек язмам да бар. Бүгенге сүзләремә өстәп, анысын да укучыларга тәкъдим итәм. Кемнәргәдер, бәлки, гыйбрәтле булыр.

*2005*

*** * ***

«Мин монда бер булган идем күк...» дигән шикелле, бу кулъязманың тулырак вариантын (беренче нөсхәсе иде шикелле) егерме еллар элек бер күреп калган идем инде. Ни өчен күреп кенә калганмын? Эш болай булды. 1973 елның мартлары. Язучылар союзында җаваплы сәркатип (хәзергечә – рәис урынбасары) булып яңа гына эшли башлаган көннәр. И.Гази кинәт үлеп киткәннән соң, идарә рәисе булып З.Нури эшләгән дәвер бу. Көннәрнең берендә Зәки абый: «Бу папканы син дә карап чык әле!» – дип, кулыма шактый ук күләмле бер кулъязма тоттырды. «Салих Батталныкы бу. Мәскәү редакциясеннән җибәргәннәр (кайсы редакциядән икәнлеге хәтердә калмаган). Әсәрне оешмада тикшереп, авторга фикер җиткерүебезне сораганнар, мондый әйберне без баса алмыйбыз, дигәннәр». Эш бүлмәмә алып чыгып карый башладым. Сәер язма. Урыс телендә. Титул биткә Салих Баттал дип түгел, Иванов Иван Иванович дип куелган. Исеме – «Я отрекаюсь (исповедь)». Кулъязманың бер битендә газета-журналлардан алынган вак-вак кисемтәләр җилемләнгән. Кызыксынып укып киттем. Бәй, без укып күнеккән публицистика түгел икән бит бу! Кайбер абзацлары сискәндереп үк җибәрә.

Ай-һай хәтәр юллар, баш китәр фикерләр! Мондый уйлар күпмедер дәрәҗәдә безнең һәммәбездә дә бар барын... Тик болай итеп әйткән юк та, яза алган юк. Кара, без алтын манаралар итеп күргән офыклар рәшә-мираж гына түгелме соң? «Безнең иман – коммунизм!» дип басып торган нигезебез, мәрмәрдәй нык өслелектән бигрәк, тымызык бер сазлык кына түгелме соң?

Шул ук көнне идарә утырышы булды, соңрак бүлмәмә Илгиз Хәйруллин килеп керде. Партия өлкә комитетының культура бүлеге инструкторы, бүлекнең иҗат оешмалары белән эш итүче кураторы иде ул. Әзрәк сөйләшеп утырдык. Минем «җаваплы урында яңа кеше буларак» эшләрем белән кызыксынды. Өстәлдә ачык килеш яткан кулъязма да күзгә төртелде. (Ул вакытта андый әйбернең күз төшәрлек җирдә түгел, өстәл тартмалары тирәсендә торуы яхшырак булгандыр, бәлки.) Кулъязманы кулына алып, кайбер битләренә күз салгач, ул да тәэсирләнеп, кызыксынып китте. Бәлки, З.Нури аңа әлеге әсәр турында алдан әйткән дә булгандыр? Тик анысын тәгаен белмим. «Кая, мин дә укып чыгыем әле!» – диде ул. Хәзер кайтып уйлап карыйм: бирергә тиеш идем микән мин ул кулъязманы? Шунысы шиксез: әүвәл, әлбәттә, үземнең укып чыгуым кирәк иде! Партиянең өлкә комитеты вәкиле кызыксынгач, аның укып алуы ул заман этикасы өчен табигый нәрсә иде. Җитмәсә, Илгиз – замандаш, күп нәрсәләрдә фикердәш, әдәбият-сәнгатьне, кешеләрне яхшы белә. Төрле оештыру эшләрендә гел киңәшеп эшлибез... Болары – шулай шулаен. Кызганычы шул: кулъязма миңа бүтән әйләнеп кайтмады, 20–25 битен укыган килеш өзелеп калдым. Дөрес, атна-ун көннән соң кире сорап карадым мин аны. «Ул папка хәзер Вәлиевтә», – дип җавап кайтардылар. (М.Вәлиев – Брежнев хакимияте чорында байтак еллар Татарстан партия өлкә комитетында идеология буенча секретарь булып эшләде. Тарих фәннәре кандидаты. 1993 елда вафат.) Укырлар да әсәрне Союзга кайтарырлар дип йөрдем. Әмма мондый наив ышанычым юкка булган. Кулъязма КГБ киштәсенә барып кунаклаган икән. Берәр айдан соң Бауман урамындагы Союз катларында әлеге оешма хезмәткәре капитан Хуҗахмәтов пәйда булды. Базык гәүдәле, башкорт чырайлы, ипле генә татарча сөйләшә торган кеше иде ул. («Иде» диюем дөрес үк булмас: ул соңрак Казаннан Түбән Камага китеп эшләде, хәзер, мөгаен, пенсиядәдер.) Хуҗахмәтов миңа турыдан-туры болай диде: «Салих Батталның кулъязмасын Язучылар союзы КГБ карамагына тапшыра» дигән белешмәне басып, кул куеп бирегез!» – «Андый язуны бирә алмыйм, чөнки сез эшләгән оешмага бернинди кулъязма биргәнем юк», – дидем. Ул кабат миңа нәрсәдер әйтте, аннары дивана затка караган кебек карап торды да беркавым, күршедәге рәис бүлмәсенә кереп китте. З.Нури ялдамы, командировкадамы булып, аның

вазифасын вакытлыча Гази Кашшаф башкара иде. Эшне тиз тоттылар алар. 15–20 минуттан кирәкле белешмәне машинистка ханым басып та бирде. Гази ага кушканны бик тиз үти белде. Авыр туфрагы җиңел булсын!.. Шулай итеп, кем маллары кая китми дә, кемнәргә генә барып җитми икән... Күңелдә авыр тойгы калдырды бу вакыйга. Вакыт-вакыт гел искә төшеп җанымны кыйнады. Авторда яки дусларында берәр нөсхәсе сакланып калды микән? Бу аяныч вакыйга турында сер сыйган каләмдәшләремә дә әйткәләгән чаклар булды. Ни дисәң дә, бу әсәрнең эзсез югалуында минем дә өлеш бар бит! Минем кулымнан да үтте бит ул. «Гаепсездән гаепле генә син» дип, үземне юаткаласам да, әрнүле хис барыбер калды. 1989 елның ахырында бу әсәр турында Салих абыйның үзеннән дә сораштым, әмма ул, көлемсери төшеп, «кайчандыр бер язган идем бугай» дип кенә җавап бирде һәм сүзне бүтәнгә борды... Мин ирексездән 70 нче еллар ахырында аңа багышлап язган (соңрак китапларда да басылды) дүртьюллыгымны кабатлап куйдым:

...Бу дөньяда шуыша да
белми бит ул, булмаган!
Ул очар өчен туган шул,
сөйрәлергә тумаган!

Шулай да моның белән генә бетмәде әле бу әсәр тарихы. Яшьлектә бер югалтып, соңрак янә табылган кадерле кеше шикелле, язмыш кабат очраштырды мине бу кулъязма белән. 1993 елның сентябрь аенда, «Идел» журналында утырганда, баш мөхәррир өстәлендә икенче данәсе ята иде. «Кайдан? Ничек? Кемнән?» кебек өзек-өзек дулкынланып әйткән сорауларыма Фәиз Зөлкарнәй тыныч кына: «1994 елның башында басып чыгарырга әзерлибез», – дип җавап бирде. Бу әсәрне мин моннан егерме еллар элек белгәнемне, югалту тарихына «өлеш керткән шаһит» булуымны ишеткәч, ул минем шул хакта кереш сүз итеп язып бирүемне үтенде. Бу юллар шуңа җавап рәвешендә язылдылар да инде.

Сүз уңаеннан өстәп шуны гына әйтәсе килә: ачылып, өйрәнелеп, бәһаләнеп бетмәгән олуг шәхес, олуг талант иясе ул Салих ага Баттал. Якты дөньяда 90 нарга хәтле камил акыл белән яшәп, шул гомеренең 60 елдан артыгын актив иҗатка багышласа да, аның иҗаты системалы рәвештә өйрәнелмәгән әле. Шагыйрь буларак та, проза остасы һәм драматург буларак та. Кем гаепле соң? Әлбәттә, үзе! Талант кадерен белә торган заманда туа белмәгән, тоталитар режимга яраша алмаган, вөҗданына хыянәт итмәгән, башын имәгән, сүзен бирмәгән... Ул заманның әдәби даирәсендә Ә.Еники «ялгыз каз» саналып йөртелсә, С.Баттал, үзе әйтмешли, «Тигәнәле тилесе» булып кала бирде. Замандаш каләмдәшләренә, ул заманның түрендә хөрмәттә йөргән чордашлары да, Салих ага башына хакимиятнең идеологик чукмарлары төшкән чакта, аны яклап, саклап кала алдылар дип әйтмәс идем. Күбесе читтә торды, «диссидент корымы» тиюдән сакланды. Әмма яшьләр (70 нче елларда әдәбиятка килгән буынны әйтәм) арасында аның дәрәҗәсе һәрчак зур булды. Нәрсә генә димәсеннәр, ул безгә легендар шәхес булып тоела иде. Ике метрлы мәһабәт гәүдә, кыю очучы, оригиналь язучы, оратор, җыелышларда түрәләрдән Се-Ге-Бе (ТАССР Югары Советы Президиумы председателе С.Г.Батыев күздә тотыла) сүзләре белән көлә ала торган шәхес... Дөрес, үз заманының аерым бер рухи күзәнәге буларак, режим юлбашчылары чыгарган теорияләргә, тәгълиматларга ихлас ышанып, утопик хыяллар белән рухланып, артык мавыгып киткән чаклары да булды әдипнең. Мәсәлән, ул үзен партиядән чыгаруны бик авыр кичерде. «Коммунист» төшенчәсе аның өчен изге булган, күрәсең. Партия сафларына яңадан торгызылу артыннан байтак йөрде ул. Ленин хезмәтләрен яхшы белде. Цитаталарны яттан сибә генә иде. Гасырларның байтак акыллары үз вакытында «яхшы патшага» ышанган кебек, Салих ага да Ленинга бик ышана, аның өйрәтмәләрен бозалар, шуңа күрә дә милли мәсьәлә дөрес бармый, дип, еш кына тәкрарлый иде. Хәер, кем белә! Бәлкем, ялгышамдыр. Талантның кодрәте чиксез, диләр бит.

*1993*

## ***ӘЙДӘҮЧЕ***

*(Тәүфикъ Әйдинең күптомлыклары чыгу уңаеннан уйланулар)*

Кайчак уйлап куясың: адәм баласы нилектән язу эшенә тотына икән? Дөньяны танып белүдә минем үзгә карашым, ачышым бар дипме? Тирә-юньне бүтәннәр күрә алмаганча образлы-сурәтләү сәләтен раслау өченме? Сүз тылсымы белән Җир йөзендә Матурлык арттырып Гаделлеккә көч өстәргә теләвеме аның? Күңеле уйнаклавымы? Язу эше әллә аерым бер затларга гына бирелгән илаһи инстинктмы?.. Иҗат – бөтен нечкәлекләрен беркайчан да, беркем дә ачып бетерә алмаслык серле процесс, җанның үзгә халәте; шуңа күрә иҗатчыда әлеге саналганнарның өлешчә һәркайсы да булырга мөмкин. Кешелек дөньясы безгә кадәр тудырган бихисап китаплар хәзинәсенә баксаң, әлеге сорауларга дәлил-җавапларны күпләп табарга була.

Әсәр, әйтик, шигырь, котелмәгәндә, үзеннән-үзе җиңел генә туарга мөмкин. Икенче бер әсәрнең, хәтта кыска гына әсәрнең дә, газаплы кичерешләр аша, еллар дәвамында язылуы да бар. Кемнең ничек килеп чыга! Ярты гасыр буе диярлек язучылык иҗаты белән шөгыльләнгән кеше буларак, каләмдәшләрнең төрлесе күрелде: фидакарь затларны да, көнлекчеләрне дә, талантларын исраф итүчеләрне дә, аз сәләт белән күпне дәгъвалаучыларны да... Арада сирәк булса да үтә зирәк, киләчәкне күзаллап, гомеренең һәр сәгатен, язган һәр сүзен, һәр җөмләсен, гомумән, һәр кылган гамәлен үзе инанган иҗтимагый максатка юнәлткән язучылар да булды. Мәшһүр милләттәшебез Тәүфикъ Әйди әнә шундыйлардан иде. Ул нәрсә өчен язганын тәгаен аңлап, язганыннан нинди нәтиҗә чыгарга мөмкинлеген анык фаразлап иҗат итте.

Тәүфикъ Әйдинең тормыш һәм иҗат юлы җиңелләрдән булмады. Яратылышы белән зыялы һәм әдип зат булса да, шушы табигый барлык-булганлыкны дөньялыкта раслар өчен аңа биниһая көч, хезмәт куярга, «вакыт эчендәге вакытны табып» хәят кичерергә туры килде. Барысын да юклык ноктасыннан – нульдән башларга туры килсә дә, ничек тә юл ерырга, җиңелмәскә, максатка ирешергә! Моның өчен Вакыт – озын гомер кирәк. Ә Вакыт дигәннәре санаулы... Алтмыш еллап гомер кичереп, аның күпме өлешен чын иҗатка багышлый алды икән Тәүфикъ? Күпкә җыелмыйдыр. Башта кояш астында яшәү өчен хокук һәм урын даулау (ятимлек, качаклык, төрле мәктәпләрдә, төрле телләрдә белем эстәп йөрүләр), соңрак Ходай биргән сәләтнең ия-хуҗасы нәкъ ул икәнлеген эш белән раслау (китапханәче, эшләп укучы студент, укытучы, милиция хезмәткәре, журналист...) һәм, ниһаять, җан теләгән иҗат белән шөгыльләнеп, уй-фикерләреңне дөньяга җиткерү (ирекле профессиональ язучы)... Бу тормышта, ир-ат буларак, тормыш арбасын тартасы, балалар үстереп, аларны кеше итәсе дә бар бит әле! Татар язучыларының бөтенесе диярлек, классик сүзләренчә, «без тормышның төбеннән күтәрелдек» дип әйтә ала. Белүемчә, Тәүфикъ Әйди гомеренең фәкать азак елларында гына төп вакытын чын иҗатка бирә алды. Шулай да...

Тәүфикъ Әйдинең «Сайланма әсәрләр»ен янә актарып-карап чыгасың да «эшләп тә күрсәткән икән егет!» дип сокланып куясың. Унбер томлык хезмәт. Романнар, повестьлар, фәнни-популяр очерклар, юлъязмалар... Соңгы елларда күптомлыклар (күбрәк өч-биш томлыклар) күренгәләсә дә, әлегә унбер томы чыккан язучыбыз юк шикелле. Күләм дигәннәре күп нәрсә белдерсә дә, әлбәттә, хикмәт күләм-санда түгел, иң мөһиме – хезмәтләрнең мәгънәви көчендә, кирәклек дәрәҗәсендә, тарихи-иҗтимагый әһәмиятендә.

Дөньяда талантлы язучылар да, яхшы әсәрләр дә җитәрлек. Татар әдәбиятында да шулай бу хәл. Һәр һәйбәт әсәр кеше күңеленә тәэсир итми калмый. Димәк, ул әсәр үзенең тууын аклаган... Хәтер – хәтәр нәрсә, аннан качып булмый. Төрлечә искә алына элгәргеләр: кайберләре фәлән исемдәге әсәре белән хәтергә килә, кайберәүләре үзләре кызык шәхес буларак күз алдына баса. Ә менә кискен хәлләрдә, рухи сынауларда, тормыш һич тә «мәгънәсез, уен-көлке» булмаганда, бигрәк тә халык язмышы, киләчәк турында уйланганда, сирәк әсәрләр, сирәк шәхесләр искә төшә. Т.Әйди әнә шул сирәк әдипләрнең берсе инде.

Әгәр, Тәүфикъ Әйди иҗатының төп асылы, әһәмияте нидә, дип сорасалар, җавабым бер: мәгълүм бер чорда татар дигән халыкның дөньяда барлыгын раслауда үзеннән саллы өлеш кертә алуында. Татар – аның бәгырендә. Күпләр үз туган телен дә оныткан заманда, Т.Әйди халык киләчәгең үз балаларының язмышына тиң итеп карый белде, Дәрдемәнд сүзләре белән әйтсәк, «татарлыкта татар угълы татармын» булып калды. Иҗатың ихлас икән, анда һәммә нәрсә ярылып ята. Т.Әйди хезмәтләренең – мәкаләме ул, юлъязмамы – исемнәренә генә игътибар итегез: «Без тарихта эзлебез», «Бәхет бары туган илдә», «Төрки нигезне ныгытыйк», «Язмышыбыз үз кулыбызда», «Себер үзебезнеке», «Аһ, туган кавем газиз!», «Өмет – бары үзебездә»...

Инде томлыкларның төзелү тәртибе, эчтәлекләре турында берничә сүз әйтеп китик. Томлыкларның күбесе берничә әсәрдән гыйбарәт. Берсе, әйтик, сәяхәтнамәләр; берсе – мәшһүр шәхесләр турында тупланма; берсе – мәкалә-очерклар җыелмасы... Зуррак күләмлеләре, бу очракта романнар (алар өчәү), аерым томлыклар итеп бирелгән. Җөмләдән романнар турында берничә сүз. Т.Әйди четерекле, күпләр кузгатырга базмаган темаларга алынды. Менә 90 нчы елларда дөнья күргән «Елан угы» романы (икенче том). Вакыйгалар үткән гасырның егерменче елларына карый. Аннотация-аңлатмада болай язылган: «Сәяси детектив төсендә язылган бу әсәрдә милләттәшләребезнең Төркстанга революция экспортлауда катнашуы, сыйнфый көрәшне куертуның җирле халыкларга да, яңа битлек кигән колонизаторларга хезмәт итүче татарларга да бәхет китермәве, яңа фаҗигаләргә генә юл ачуы гәүдәләндерелә. Татарларның Төркстанда да ике тарафка аерылып, большевиклар һәм «басмачылар» сафында үзара көрәше, кан коюы тарихи саташу, адашулар нәтиҗәсе буларак сурәтләнә».

«Иблискә ришвәт» романы (өченче том) Икенче бөтендөнья сугышы вакытында немецларга әсир төшкән татар хәрбиләре турында. Мәгълүм булганча, өченче Рейх җитәкчеләре алардан Идел-Урал легионы төзеп, Советларга каршы көрәштерергә ниятли... Фаҗигаи хәлләр, гыйбрәтле язмышлар... «Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен легионга кергән? Әсирләрнең алман халкы белән бәйләнешләре нинди була?» – Автор әсәрендә әнә шундый сорауларга җавап эзли. Бишенче томга кергән әсәрләр – фәнни-популяр хезмәтләр җыелмасы. Анда «Гөлчәчәкләр илендә кара болыт» (Болгарстан), «Дунай буендагы кардәшләр» (Румыния), «Исәнме, Гагаузстан!», «Оҗмах утравы» (Кипр-Кыбрыз) исемле язмалар тупланган. «Үткән һәм бүгенге заман, гореф-гадәтләр һәм мәдәният, вакыйгалар һәм шәхесләр, ерак җирләрдә яшәп яткан милләттәшләребез һәм кардәш түрек халыклары» – Т.Әйдинең бу томдагы «иҗат кишәрлеге» әнә шулар. Мәшһүр милләттәшләребезгә багышланган очерк-мәкаләләр кергән томлыкның аңлатмасына күз салсаң, анда бик ачык әйтелгән: «Бу китапта Шәркый Төркстан, Үзбәкстан, Себер, Идел-Урал буйларында яшәүче милләттәшләребез сурәтләнә. Алар бу тарафларда кайчан тамыр җибәргән? Нигә шундый чиксез киңлекләргә таралган? Саннары күпме? Башка халыклар арасында нинди урын билиләр? Ят һәм кардәш милләтләр белән мөнәсәбәтләре нинди? Горурланырлык казанышлары бармы? Автор әнә шундый күп кенә сорауларга җавап эзли, табышларын укучылары белән уртаклаша». Әйе, бу – Тәүфикъ Әйди стиле. Төпле, бөртекчән Тәүфикъ стиле. Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах тиккә генә болай язмагандыр: «Татарстаннан читтәге татарлар турында җентекләп, тәфсилләп һәм даими рәвештә Тәүфикъ Әйди яза... Кем турында гына сөйләмәсен, автор һәр эшнең, һәр профессиянең асылына төшенеп, үзе тасвирлаган шәхесләрнең социаль, тарихи һәм профессиональ мохитен күз алдына китереп бастыра. Шунлыктан Тәүфикъ Әйди әсәрләренең тәэсир итү, ышандыру көче зур».

Язучының яртылаш язылып тәмамланмыйча калган хезмәтләренең берсе – моңарчы беркайда да басылмаган «Ак җилкән» әсәре. «Сайланма әсәрләр»нең дүртенче китабына кертелгән ул. Әсәрдә 20–50 нче елларда системалы рәвештә юк ителгән милли интеллигенция һәм алардан соң килгән «югалган буын» язмышы, һәм дә «курпы» булып калыккан яшь милли хәрәкәт хәлләре... Әйе, соңгы чор татар Ренессансы лидерларының берсе буларак Т.Әйдинең бу теманы күтәреп чыгуы табигый иде һәм көтелә дә иде. Шунысы игътибарга лаек: ул бу әсәрне үткән гасырның 80 нче еллар уртасында, партия диктатурасының бик ныклы чорында ук яза башлаган. Тема бик катлаулы һәм четерекле. Моңа тотыну өчен какшамас иманлы, курыкмас йөрәкле булу кирәк.

Башка томлыкларга килгәндә (санап китүемнең сәбәбе шул: бу мәгълүматлар, бәлки, кемнәргәдер томлыкларга юл күрсәткеч ролен үтәр), алардагы әсәрләрнең урнаштырылу тәртибе мондый: алтынчы том – авторның Алмания, Эстония, Әстерхан яклары турында сәяхәтнамәләре; җиденче том тулысынча Төркиягә багышланган; «Ах, туган каумем газиз!» дип исемләнгән сигезенче том чит якларда яшәп иҗат итүче мәшһүр милләттәшләребез турында; тугызынчы томда Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан турында язмалар; унынчы том янә атаклы милләттәшләребез турында; унберенче том төрле елларда көндәлек матбугатта чыккан мәкаләләр җыелмасы.

Язучы кеше, тумыштан талантлы булу белән бергә, үз заманындагы һәр үзгәрешләргә үтә сизгер, аның «күңел локаторы» һәрнәрсәне тота алырга тиеш. Бу сизгерлек, бәлки, талантның бер үзәк өлешедер дә әле. Хәзер дөньяда бер караганда табигый, икенче яктан сәеррәк тә процесслар бара. Шуның берсе – глобальләшү галәмәте. Кодрәтле җиһангирләрнең Кешелек Болынын тоташ сөреп, үзләренә хас бертөрле үлән-чәчәк (ягъни җәмгыять) булдырырга йөз тоткан дәвердә, икътисади яктан көчсезрәк, сан ягыннан азрак байтак халыклар ничек итеп үз йөзен, үз тарихын, үз генын саклау турында хәвефләнеп уйлана хәзер. Бу, әлбәттә, безгә дә кагыла. Мондый очракта, гадәттә, «мөтәпәйгамбәрләр» – «милләт аналары, милләт аталары» пәйда булучан. Шагыйрь әйтмешли, «кемдер, дин! ди, кемдер, мин! ди». Әлбәттә, исән-имин калуга булышкан һәр юл, һәр ысул, һәр идея файдалы. Әмма, ни генә булмасын, иң әүвәл нигез тамырларыңның ныклыгын, аларның яшәү көче дәрәҗәсен ачыклау фарыз. Бу очракта безнең өчен төп юл – төрки бердәмлекне ныгыту. Тәүфикъ Әйди моны бик күп акыллы башларга караганда алданрак тойган, аңлаган, гамәл кылган булып чыкты. Әдип иҗатын аркылыга-буйга карап-өйрәнеп чыксаң, моңа тиз инанасың. Ул кызыксынмаган, өйрәнмәгән берәр төрки халык бар микән? Дөресрәге, ул аяк басмаган төрки җирләр (ә ул җирләр иксез-чиксез!) калды микән? Мәсәлән, аз санлы гагауз дигән халык турында юньләп белә идекме? Ишетеп белсәк тә, алар тормышы хакында сирәкләребез хәбәрдар иде. Тәүфикъ Әйди яңача «ачып» күрсәтте безгә ул халыкны. Әлбәттә, үзебезгә дә сабак, гыйбрәт алырлык иттереп... Зуррак санда исәпләнгән үзбәк, казакъ, азәри, кыргыз кебек халыклар турында язуын әйткән дә юк. Ул алар белән нык аралашып, «тел-ләгать алмашып» яшәде, рухи тормышлары турында һәрдаим язып килде, атаклы кешеләрен үзенең хезмәтләрендә сурәтләде, аркадаш каләмдәшләренең әсәрләрен, турыдан-туры тәрҗемәләп, татар укучысына җиткерде. Иң мөһиме: уртак рухи байлыкны – тарихны, мәдәни ядкарьләрне туганнарча бәрәкәтле файдаланырга, үстерергә чакырды. Бу җәһәттән телебезне баету юнәлешендә үз иҗатында игелекле үрнәк тә күрсәтте: йөзләрчә төрки тамыры булган уртак сүзләрне әдәби әйләнешкә кертте, аларны янәдән тел хәзинәбезгә кайтарды.

Һәр чорның үз көе, үз җыры дигәндәй, әдәбият та бик нык үзгәрешләр кичерә хәзер. Эчтәлеге һәм иҗтимагый әһәмиятлелеге ягыннан гына түгел, шәкли-формалар үзгәрү ягыннан да. Әйтик, традицион жанрлар бер-берсенә керешеп, үзара синтезлашып яңалары туа, язу стиле торган саен лаконик төс ала бара. Үз вакытында Лев Толстойлар фаразлаганча, дөньяны танып белергә өйрәтә торган информация-белешмәгә бай әдәбият туды. Тәүфикъ Әйди бу хәлне дә күпләргә караганда алданрак тоемлаган булса кирәк. Тарихи даталар, исемнәр, саннар, атамалар һ.б. кирәкле белешмә-хәбәр бихисап аның әсәрләрендә. Укучылар, бигрәк тә яшьрәк буын өчен әһәмияте зур андый язмаларның. Кемнедер эстон яки латыш язучылары кызыксындыра, кемгәдер Кытай яки Төркиядәге татарлар турында мәгълүмат кирәк... Рәхим итеп, Тәүфикъ Әйди әсәрләренә мөрәҗәгать ит, кирәксенгәннәреңнең байтагын табарсың...

Әйе, Тәүфикъ Әйди бөтен дөнья буйлап татарны барлады, асыл зат ул-кызларын күтәрде, яшь буыннар үрнәк итәрлек маяклар эзләде. (Хәзерге вакытта нәтиҗәле эшләп килүче Бөтендөнья татарлары конгрессы миссиясе инде!) Ул яхшы мәгънәдәге чын милләтче иде. Кемгәдер, бәлки, парадокс булып тоелыр: асылда, чын милләтче генә чын мәгънәдәге интернационалист була ала. Үз баласын юньләп багып тәрбия итә алмаган кеше ничек итеп бүтәннәр баласын сөя алсын, үз милләт-кавемен кадерли белмәгән адәм ничек башка халыкларны хөрмәтли алсын! Җентекләбрәк укып карагыз Әйди әсәрләрен: татар кешесе турында яза, үзе бүтән милләт вәкилләрен – казакъмы ул, эстонмы, немец яки японмы – нинди ихтирам күрсәтеп бәян итә! Шигар формасында булмаса да, язучы-әдипнең төп эчке фикере шул: бу дөньяда халыкларыбызда булган иң яхшы сыйфатларны үзләштереп тату яши белик, үз милли йөзебезне югалтмыйча, киләчәк буыннарга уртак хәзинәбезне баетып калдырыйк! Ул әйтерсең лә безнең халыкның ЮНЕСКОдагы бер вәкиле. Чынлыкта да Тәүфикъ Әйди, шартлар булган очракта, берәр зур илдә татарның вәкаләтле илчесе булып торырлык иде: буй-сын, килеш-кыяфәт, белем-интеллект, сабыр холык, чама хисе... Бәлки, ул чакта рәсми даирәләргә ошап та бетмәгәндер, әмма факт: Т.Әйди өендә чит республикалардан, чит илләрдән килгән әдипләр еш була иде. Күрәсең, илгизәрләрдә формаль очрашулардан тыш, зур эрудицияле әдипләр белән ачыктан-ачык аралашу ихтыяҗы зур булгандыр. Әлбәттә, андый очрашулар эзсез үтми. Мәсәлән, 1989–1990 елларда Эстониядә Татар әдәбияты, Татарстанда Эстон әдәбияты көннәре узуында Т. Әйдинең өлеше зур дип уйлыйм мин.

Күп йөргән – күп белгән, диләр. Күп белгәннең, әлбәттә, фикерләве дә колачлырак, төгәлрәк, дөреслеккә якынрак була. Әгәр без авыз тутырып татар әдәбияты дибез икән, ул инде, табигый, бөтентатар әдәбияты булырга тиеш. Һәр төбәктә яшәүче татар – Себердә яки Пенза якларында яшиме ул, Нижгар яки Нугай далаларында гомер кичерәме, аның үз итеп укырлык әсәрләре булырга тиеш татар әдәбияты хәзинәсендә. Бу – безнең өчен, язучылар өчен иң җитди, иң мөһим проблемаларның берсе. Татарстанның халык язучысы, халык рәссамы яки артисты булу бер нәрсә, ә син менә бөтен татар халкының абруйлысы булып кара! Тормышка ашкан очракта, тарихи да, саваплы да, шөһрәтле дә миссия була инде ул. Тәүфикъ Әйди әсәрләрен укыганда, мондый уйлар күңелгә еш килә.

Талант – табигать бүләге. Иҗат кешеләре, алда әйтелгәнчә, үзләре бер дөнья тудырырга сәләтле, гаҗәп кызыклы, кабатланмас токым. Араларында төрлесе бар. Күзәнәкләренә нарцисслык сеңгәннәре дә җитәрлек. Андыйлар, гадәттә, халык язмышы, милли идея, иҗади миссия кебек «вак» нәрсәләр белән изаланып тормый: яздым – бетте! Калганы – алкышлар көтү... Иҗади эгоизм... Дәүләте, зур матди һәм рухи маясы булган халыкларга андый «иркәләр», сәерләр дә төстер... Французлар төрмә юлыннан башы чыкмаган Франсуа Вийонны да бөек ясаганнар. Ә безгә? Безнең язмыш, безнең юл бүтәнрәк, шактый ук бүтәнрәк шул... Тәүфикъ Әйди, боларны яхшы тоеп, халыкның егет улы буларак, аңлы рәвештә авыр юл сайлады. Уйлылар һәм күңеле нечкәләр өчен заманы да авыр иде. Демократия юк дәрәҗәсендә, рухи маяк – утопик һәм фальшь; асылда, берне сөйләп, икенче төрле гамәл кылып яшәгән заман. Хакыйкатьне ярып әйткәннең башыннан сыйпамыйлар. Күз-колак булучылар һәрвакыттагыча көчле һәм сизгер. Тәүфикъ Әйдинең тормыш рәвеше һәм иҗаты да һәрчак игътибар үзәгендә булды. Талкучылар да җитәрлек иде... Кайбер «бөек»ләр Сүз кодрәтен үз җанына нирвани халәт тудыру чарасы санаганда, Тәүфикъ Әйди Сүзне халыкның үзаңын үстерүдә бөек көч булганын раслар өчен яшәде. Аның өчен хак-тугры сүзнең кешеләр күңеленә барып ирешүе, гамәл-хәрәкәткә китерелүе кыйммәт иде. Язучының сүзе, билгеле, аның әсәрләрендә, басма китапларда, көндәлек матбугатта – газета-журналларда. Милли матбугатыбызны пропагандалауда Т.Әйдинең хезмәте әйтеп бетергесез зур. Эшчәнлегенең зур өлешен, бәлки әле, иң күп вакытын алган өлешедер әле ул. Хәтерлим: 60 нчы еллар урталарында, җәйләрен, аркасына биштәр тулы газета-журналлар төяп, ул Чуваш, Мордовия, Мари якларында велосипедка утырып сәяхәтләр кылып йөрде, татар матбугатын таратты, халыкны үгетләде, өндәде... Мондый акцияне фәкать фидакарьләр генә эшли ала. Матбугат таратучы сыйфаты мәгънәле бер шөгыль булса, асылда, ул әлеге халыкларның яшәеш хәлләрен – үткәннәрен, бүгенгеләрен өйрәнде, тарихи яссылыктан карап, аларның милләт буларак рухи потенциалларын ачыкларга тырышты. Һәр халыкның тарихы үзе бер онытмаслык мисал-гыйбрәт бит! Үз халкыңның киләчәге өчен җан атып көрәшкәндә, һәрнәрсәнең – һәр вакыйганың, һәр фактның кирәге чыгуы бар...

Тәүфикъ Әйди турында язганда, үзеннән-үзе дигәндәй, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны, роле турында да еш уйланылды. Без үскәндә, – үткән гасыр урталары була инде ул, – шактый еш сөйлиләр иде бу хакта. Тарихи вакыйгалар фонында шәхеснең ролен кечерәйтебрәк аңлаталар иде. Шәхес культының «чәчәк аткан» заманы югыйсә... Бәхәссез хакыйкать: теләсә нинди чорда да, билгеле бер шартлар булганда, әгәр бөтен җанын-тәнен, бар җегәрен бер максатка юнәлдерә икән, бер генә кеше дә (бер генә данә кеше дә!) күп эшли ала бу дөньяда! Тәүфикъ Әйдинең тормыштагы гамәлләре моңа мисал. Минемчә, Т.Әйди иҗатының, бу очракта мирасының, рухани мәгънәсе, икенче төрле әйткәндә, язылмаган васыяте шул: татарны фәкать татар үзе генә яклый-саклый ала; шуның өчен дә таралып яткан бу халык яһүдләр кебек тупланырга тиеш; иң әүвәл милләтнең асыл затларын барлап, алар аша халыкның хакыйкый урынын дөньяга таныту зарур. Бу максатка милли идеяне (ансыз ни халык, ни дәүләт, ни киләчәк юк) үстереп кенә ирешеп була. Аны үстерүнең бер ышанычлы чыганагы – ана телендәге матбугат. Ягъни татар телендәге басмалар – китаплар, газета-журналлар. Соңгы гасырларда халкыбыздагы дәүләтчелек геннарын югалттырмауда басма сүз, борынгыларча әйтсәк, китап сүзе төп рольләрнең берсен үтәп килде. Тәүфикъ Әйди киң катлауга, бигрәк тә яшь буынга, әнә шуны аңлатырга тырышты да. Бу җәһәттән милләтпәрвәрлеге, сәяхлеге белән аны күпмедер дәрәҗәдә Рәшит казый (Габдрәшит Ибраһимов) белән дә чагыштырып буладыр. Классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимов үзенең фамилиядәш адашын заманында «тарихи кыңгырау» дип бәяләсә, Тәүфикъ Әйдине исә без «тарихи бер

төен», «милләтнең ышанычлы, нык бер төене» дип әйтә алабыздыр. Т.Әйди үзе дә Рәшит казый турында сокланып язды, тормышы маҗаралар, кыю гамәлләр белән тулы шәхес турында бүгенге укучыларга шактый мәгълүмат бирде. Ә андый шәхесләр Т.Әйдинең иҗат картотекасында дистәләп җыйнала. Татар җирендә туып үсеп, төрки дөньяның мәшһүр галиме исәпләнгән Габделбари Баттал, Кытайда Мао Цзэ-Дун даирәсендә югары пост биләгән Борһан Шәһиди... Моннан ун еллар элек Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев Тәүфикъ әле үзе исән чагында болай дип язып чыккан иде: «Т.Әйди кадерле шәхесләребезне бергә туплап сурәтләп, укучыларда милли горурлык хисе тәрбияләүдә җитди өлеш кертеп килә. Ул берчакта да коры, буш сүз сөйләми, фикерләрен, йомгакларын катгый дәлилләр белән сипләп, ныгытып бара».

Тәүфикъ Әйди ниятләгәннәренең күбесен тормышка ашыра алмый китеп барды. Алда әйткәнемчә, табигатьтән бирелгәнне раслауга күп вакыты китте. Таяну ноктасыз башлаганнар язмышы. Юнәлеш анык булса да, юллар сикәлтәле, урау. Максатка ирешү юлында күпмедер дәрәҗәдә компромиссларга да барырга туры килә. Безнең чор каләм ияләре идеологик кайбер канун-тәртипләр белән исәпләшми булдыра алмый иде. Әйтик, фәлән төбәкнең, фәлән авылның үткәнен-бүгенгесен язар өчен генә дә җеп очы иң әүвәл райкомнар, парткомнарга тоташа иде. Журналистның, язучының ак кәгазьдәге каләме белән бергә партия күзе ияреп барды. Бу нәрсә, табигый, Т.Әйдинең дә кайбер мәкалә-очеркларында, репортаж-юлъязмаларында чагылыш тапмый калмады. Язучының кайбер юлъязмаларында һәркем күрә алган, шулай ук төрле энциклопедия-сүзлекләрдән, белешмә-конспектлардан алынган мәгълүматлар артыккарак китә. Илләрне-җирләрне беренче барып күргәндә, андый «Америка ачу»лар буладыр ул. Бигрәк тә чит илләргә «тимер пәрдә»нең яңа ачыла башлаган дәверендә... Хәер, беренче кичерешләрне, сабыйлар сүзе шикелле дөресрәк була дип тә әйтәләр. Бу очракта безнең әдәбиятка хас мәгърифәтчелек традицияләренең яшәвен дә искә алырга кирәктер, мөгаен.

Тәүфикъ Әйди – күпләребез шикелле журналист язучы. Яшәү һәм иҗат җепләребез көндәлек матбугатка бәйле. Бу урында «журналист язучы» төшенчәсенә ачыклык кертеп узыйк. Күпләрнең бу тәгъбиргә үз стереотип карашы бар: журналист язучылар алар – көндәлек тормышны оператив яктыртып, мәкалә, очерк, документаль хикәя-повесть һ.б. язучы каләм ияләре. Нигездә, дөрес. Әмма бүтән төрдәгеләре дә бар газета-журналларда эшләүче әдипләрнең. Алар, гадәттә, тирән белемле, аналитик фикер йөртүче зур язучылар. Аларның күбесе тереклек итү хакына матбугатта ялланып эшләргә мәҗбүрләр (әйтик, татар халык шагыйре Илдар Юзеев, пенсиягә чыккач та, соңгы көннәренә кадәр диярлек редакцияләрдә эшләде). Тәүфикъ Әйдигә килсәк, ул журналларда эшләүче галим язучы иде. Әсәрләрендәге тормышка карата дәлилле тарихи караш, фәннилек, документальлек, фәлсәфи анализ шуны раслый. Язучыларыбыз арасында милләт исеменнән халыкара трибуналардан чыгыш ясый алырлык шәхесләр күп түгел. Т.Әйди Европа һәм Азиянең шактый илләрендә булып, төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә, симпозиумнарда чыгышлар ясады. Фәнни яктан нигезле, тарихи фактларга бай чыгышларын ишетми, матбугатта, бигрәк тә төрки дөнья матбугатында басылган хезмәтләрен укып, галим-голәма аның фикерләре белән санлашырга мәҗбүр иде.

Т.Әйдинең байтак еллары Матбугат йортында («Идел-Пресс») узды. Кайбер редакцияләрдә («Татарстан» журналы, «Заман» газетасы) күпмедер хезмәт куйса да, гомеренең бастырып төп эшләгән урыны «Казан утлары» журналы булды. Күп көч куйды ул анда. Унике елдан артык эшләү дәверендә, шаблонрак сүз белән әйтсәк, якты эз калдырды. Журналның кайбер рубрикалары, әйтик, «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә», «Чит илләрдәге милләттәшләребез иҗаты», турыдан-туры Т.Әйди инициативасы белән булдырылды, һәм ул материалларны туплаучы да күп чак ул булды. Һәм, әйтергә кирәк, Тәүфикъның күпчелек үз әсәрләре дә шушы журналда басылды, халыкка ирешеп танылу алды.

Танылу димәктән, әйтергә кирәк, үзенә тиешле бәя-хөрмәтне алмыйча, аны тоеп сөенү ләззәтен күрмичә китеп барды Тәүфикъ Рамазан улы. Бу урында олуг галимебез Миркасыйм Госмановның «Табышмакка әверелгән истәлек» дигән язмасындагы берничә юлны китереп узу урынлы булыр: «...үзе исән чакта гомумэшчәнлеге, конкрет иҗаты тиешле бәһасен ала алмаган, бәлки мәгълүм көчләр тарафыннан шәхесе гел кыерсытыла, эзәрлекләнә килгән,

мәгәр шундый авыр шартларда да үз иманына тугрылыклы булып кала алган Тәүфикъ Әйди иҗаты алдында без һаман бурычлыбыз. Моны аңлый белү безнең аң дәрәҗәбезнең күрсәткече булыр».

Мин үзем – Тәүфикъ Әйди белән кырык еллап белешеп, аралашып яшәгән кеше. Шуның ун елга якыны «Казан утлары» журналы редакциясендә якын хезмәттәшлектә үтте. Табындаш әшнәләр булмасак та, күп мәсьәләләрдә фикердәшләр идек, сынауларда бер-беребезгә таяна алырлыгыбызны тоеп яшәдек. 2001 елның язында хастаханәдә каләмдәшләре арасыннан иң соңгы күрешкән кеше дә мин булдым шикелле. Хушлашыр алдыннан мин ишеткән иң соңгы сүзләре мондый иде: «Халкыбыз да безнең кырку шул, Равил...» Кырку... Бу сүзнең төп-төгәл мәгънәсен аңлап та бетмәдем ул чак. Хәзер дә тулысы белән аңлыйм, беләм дип әйтә алмыйм. Нинди мәгънәләр салып әйтте икән ул сүзне? Монысы инде ачылмаслык мәңгелек сер. Кырку... Тәүфикъ Әйди дигәч, еш искә төшә бу сүз. Сискәндерә дә, шомландыра да, уйландыра ул мине... Андый чакларда әдипнең китапларын кулга алам, борчыган сорауларыма җаваплар эзлим.

*2005*

## *АКСАКАЛ ӘДИП*

Моннан җитмеш еллар элек үк Казандагы мәшһүр Матбугат йортының (Бауман урамы, 19) Тукай клубында язучыларның җыелышлары, төрле кичәләре, юбилей бәйрәмнәре һәм башка чаралар үткәрелеп киленгән. Сугыштан соң, бигрәк тә 50 нче еллардан соң, клуб эше тагын да тернәкләнеп, җанланып киткән. 60 нчы еллар башында язучыларның бу клубында аена берничә мәртәбә әдәби-музыкаль кичәләр уза иде. Татарның атаклы шәхесләре катнаша иде ул кичәләрдә. Биредә шулай ук әдәбиятка, сәнгатькә юл ярырга омтылган яшь-җилкенчәкләр дә күп була иде. Университетта һәм пединститутта укучы байтак студент-шагыйрьләрнең, халык алдында беренче җитди чыгыш ясап, «чиркәнчек алулары» да шушы кичәләрдә булды. Ул елларда мондый зыялы аудитория бүтән җирдә юк иде дә бугай. Шуңа күрә гадәттә җомга көннәрендә уздырыла торган ул кичәләрне күпләр көтеп ала иде. Кемнәрне генә очратмый идең анда! Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мәхмүт Бөдәйле, Риза Газизов, Хәй Хисмәтуллин кебек XIX гасырда ук туган өлкән кешеләр дә, ул вакытта ук классик саналган, иҗатлары дәреслекләрдән өйрәнелгән Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким, классик ук саналмасалар да, һәммәбез өчен абруйлы фронтовиклар – Салих Баттал, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Шәрәф Мөдәррис... Биредә мәдәнияткә битараф булмаган өлкән һәм урта буын кешеләрен дә, авылдан килеп, тиз генә Казанның мәдәни төркеменә керергә ашкынган яшьләрне дә, әлбәттә, күзләү органнары вәкилләрен дә күрергә мөмкин иде. Инде илле еллап вакыт узса да, шунда катнашкан байтак кешеләрнең гәүдә-кыяфәтләре, йөз чалымнары әле дә күз алдында.

Залда даими булып, бер кичәне дә диярлек калдырмый торган бер кешенең төс-кыяфәте шактый ук ачык булып хәтердә калган. Безгә инде өлкән тоелган (үзебезне булачак шагыйрьләр дип йөргән күпләребезгә ул чакта әле егерме дә юк, ә аңа инде (!) утызлар тирәсе) бу кеше нишләп йөри монда? Безнең кебек сәхнәдән чыгыш та ясамый, килгән тамашачылар белән дә бик аралашмый... Безнең як кешесенә охшаган да, охшамаган да кебек. Аксыл йөзле, кысынкырак күзле. Борынгы бабаларыбызның бишеге булган Алтай ягы кешеләренә тартым... Кем бу? Яшь чак, төпченеп торырга вакыт та юк. Бу дөньяның кеме булмас!

Ун-унбиш еллар үткәч, бу кешенең кем булуы яхшы ачыкланды. Ул Хәмидуллин Лирон Хәйдәр улы булып чыкты. Сугышта һәлак булган фронтовик баласы. Гомере буе татар дөньясы даирәсендә әвәрә килгән милләт улы. Язучы. Хуҗалык эшләрен яхшы оештыручы. Бүгенге көндәге статусы – татар әдәбиятының аксакал әдипләреннән берсе. Кемнәр ничек кабул итәр, анысы икенче мәсьәлә, бу – минем шәхси билгеләмәм. Лирон ага Хәмидуллин турында үз фикеремне ачык итеп әйтергә хакым да бар кебек: чөнки ярты гасырлап аның белән азмы-күпме аралашып яшәлде, өч-дүрт ел Язучылар берлеге аппаратында бергә эшләп тә алдык әле. Лирон аганың иҗатыннан тыш минем өчен кызыклы, кирәкле бер ягы бар:

язучылар тормышының тышкы ягын да, эчке хәлләрен дә шактый ук яхшы белә ул. Унбиш елдан артык СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеген җитәкләде. Ул оешманың төп вазифасы – язучыларның матди-материаль базасын кайгырту иде. Ягъни, каләм ияләренең иҗатын стимуллаштыру, шартлар булдыру, ярдәм итү. Кемгә фатир, кемгә санаторийга яки иҗат йортына путевка-юллама кирәк. Кемгәдер шатлык килгән, кемнедер кайгы сарган... Юбилей-бәйрәмнәре дә, үлем-китем мәшәкатьләре дә, кунак каршылау-озатулар да, гомумән, язучылар яшәешендә төрле хәлләр, һәммәсе Әдәби фонд катнашында уза иде. Әдәбиятның җәмгыятькә кирәк, язучыларның кадерле чаклары иде ул еллар! 60 нчы еллардагы язучылар тормышын яхшы белгән кешеләр бик сирәк калды хәзер. Яше 75–80нәргә җиткәннәр ике дистәдән артмый. Аларның һәммәсе дә язучылар тормышының үзәгендә – казанында кайнамаган бит әле! Редакциядә еш кына үткән гасыр урталарына яки аннан ераграк елларга караган язмалар, фотосурәтләр белән эш итәргә, редакцияләргә туры килә. Кайчак теге яки бу фактны төгәлрәк ачыклыйсы, теге яки бу сурәттәге кешене таныйсы, кемлеген беләсе була. Кемнән сорарга? Кем белергә мөмкин? Р.Мостафин? М.Госманов? Ш.Галиев? Л.Ихсанова? Алардан яшьрәкләрдән Р.Батулла? Г.Рәхим? Р.Харис? Менә шундый чакларда Лирон ага Хәмидуллинга мөрәҗәгать итәм мин. Шөкер, күп чакта сорауларыма җавап та табам. Язучылар берлеге тарихын чагылдырган «Гыйбрәтле үткән юл» дигән хезмәтемне язганда һәм бүтән очракларда (мәсәлән, «Аккош күле» иҗат йорты турында материаллар туплаганда) өлкән каләмдәшемнең ярдәмен күп тойдым. Шуңа күрә мин аны әдәбиятыбызның сирәк калган аксакал әдипләребезнең берсе дип саныйм да.

Лирон Хәмидуллин (Л.Хәйдәр) турында библиографик әдәбиятта беркадәр белешмә-материал булса да (мәсәлән, Р.Даутов һәм Н.Нуруллина әзерләгән «Татар совет язучылары», 1984), аның тормышы һәм иҗат юлы турында киң катлам укучылар тиеш кадәр белмиләр дип уйлыйм. Шуңа күрә аның хакында беркадәр мәгълүмат бирү урынлы булыр.

Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 1932 елның 10 ноябрендә Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1941 елда шул авыл мәктәбенә укырга керә, башлангыч белемне анда ала. Унбер яшьтән әнисе туган Иске Белогор авылында (Оренбург өлкәсе) яшәп җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннары укуын Казакъстанның Актүбә шәһәрендә тимерьюлчылар техникумында дәвам иттерә. 1951–1954 елларда Мәскәүне һава һөҗүменнән саклаучы гаскәрдә радиолакаторчы булып хезмәт итә. Аннан кайткач, Орск (Оренбург өлкәсе) һәм Уфа шәһәрләрендә төп белгечлеге буенча эшли. Мәскәү политехника институтының Орск филиалында югары техник белем үзләштерүен дәвам иттерә (1960 елның июленә чаклы дүрт курс тәмамлый). Шул елда Уфа университетының татар филологиясе бүлегенә керергә талпынып карый. Һәм ярты ел чамасы шул шәһәрдә эшли. Орск шәһәрендә яшәгәндә, татар-башкорт яшь һәвәскәрләре белән бергә әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда катнаша.

1961 елдан Казан шәһәрендә яши.

1961–1967 елларда шәһәр транспорты оешмасында тимер юл бүлеге инженеры, баш инженеры, партком секретаре була.

60 нчы еллар урталарыннан башлап Л.Хәмидуллинның тормышы турыдан-туры әдәбият, язучылар даирәсе белән бәйле. Әдәбиятка бирелгән, шул ук вакытта хуҗалык эшләрендә дә зур тәҗрибә туплаган ир-егетне Язучылар берлеге аппаратына эшкә чакыралар.

Л.Хәмидуллин – 1967 елдан СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. Ул дәртләнеп яңа эшкә керешә. Ә ул яңа эш дигәннәре шактый ук дәвамлы булып чыга. Уналты ел эшләү дәверендә Язучылар берлеге идарәсе рәисләре Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Зәки Нури һәм Гариф Ахунов белән бергәләп язучыларның тормыш-көнкүрешен җайлауда байтак игелекле гамәлләр башкарыла. Әдәби фондның Мәскәүдәге җитәкчеләреннән дәлилләп-даулап алынган акчалар исәбенә берничә дистә язучының фатир шартлары уңайлаштырыла.

Лирон Хәмидуллин 1977 елны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. Бу инде җәмәгатьчелекнең язучы итеп тануы дигән сүз. Бу урында әдипнең иҗади хезмәтләре турында тәфсилләбрәк сөйләү алдыннан беркадәр ретроспектив планда чигенеш ясап алу кирәктер. Һәрбер аерым язучы хакында уйланганда, гомумәдәби хәрәкәт турында фикер йөртми мөмкин түгел.

Еш кына татар әдәбиятын зур Иделгә тиңлиләр. Иделгә төрле тарафлардан эреле-ваклы бихисап күп елгалар һәм чишмәләр килеп кушыла. Аларның куе урман төпкелләреннән

каралып агып чыкканнары да, тигез-иңкүлек яктан сабыр гына агып төшкәннәре дә бар. Һәрбер елгачыкның үз куәте, үз төсе һәм тәме булган кебек, татар әдәбиятына төрле тарафлардан килеп кергән иҗат әһелләренең дә үзләренә генә хас сыйфатлары һәм үзенчәлекләре сизелеп тора. Әйе, зур Иделгә тиң татар әдәбияты мохитенә килүчеләр дә язмышлары һәм иҗатлары белән төрле-төрле. Бу хәл, бигрәк тә бу төрлелек узган гасыр әдәбиятына хас иде. Аңа төрле тарафлардан үзенчәлекле үз биографияләре һәм тормыш тәҗрибәләре белән бик күпләр килеп кергән, илһамланып иҗат иткән. Өлкән буын әдипләребезне тудырган җирлек бик киң. Күренекле язучылардан Шәриф Камал белән Кәрим Тинчурин – Пенза губернасында, Габдрахман Әпсәләмов белән Һади Такташ «Тамбов урманнары» төбәгендә туып үскәннәр. Гадел Кутуй мәктәп тәрбиясен – Самарада, Сәгыйть Рәмиев, Шамил Усманов һәм Муса Җәлил Оренбург шәһәрендә алганнар. Ибраһим Салахов, Нури Арслан, Мәхмүт Хөсәен – ерак Казакъстан җире балалары. Әнвәр Давыдов белән чордашым Рөстәм Мингалим күрше Самара өлкәсе авылларыннан. Себер-Урал тарафларында үскән Сәрвәр Әдһәмова белән Абдулла Әхмәт, Нижгар якларында туган Кави Нәҗми һәм башка бик күпләр татар әдәбияты мохитенә урау юллар белән килгәннәр. Ләкин шунысы хак: башлангыч милли белемне алар үз туган төбәкләрендә үзләштергән шәхесләр. Үз авылларында, үз калаларында башлангыч белем алгач кына Казан җирлегендә белемнәрен камилләштерә төшеп, язучы буларак танылганнар. Хәзер Татарстаннан читтәге төбәкләрдән (Башкортстанны санамаганда) килеп, татар әдәбияты дөньясына кереп китә алырдай каләм әһелләре бик сирәк. Чөнки ул төбәкләрдә хәзер татар мәктәпләре бетерелгән, бик күпләр өчен үз милли телендә белем үзләштерү мөмкинлеге бик тә чикләнгән. Никита Хрущевның милли мохтариятьләрдән читтә урнашкан мәктәпләрне ябуга юнәлтелгән мәгълүм карары чыкканчыга чаклы үз телендә бераз булса да белем үзләштергән кайбер олырак буын вәкилләре генә ара-тирә күренгәләп куя. Шундый язмышлы язучылардан без бүген берничә исемне генә атый алабыз. Алар арасында Лирон ага Хәмидуллин да бар. Әйе, быел җитмеш биш яшен тутыручы язучы Лирон Хәмидуллин әнә шундый соңгыларның берсе инде.

Әдәби фондтагы хезмәтеннән соң Л. Хәмидуллин ун елдан артыграк вакыт Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият мөхәррире булып эшләде. Татар укучысы кулына кергән йөз иллеләп китапның саф әдәби телдә, зәвыклы булып чыгуы өчен тырышты. 1998–2005 елларда Татар энциклопедия институтында өлкән фәнни хезмәткәр вазифасын башкарды. Энциклопедияләрнең татар телле вариантын әзерләп чыгаруда катнашты. (Энциклопедик сүзлектә һәм томнарда егермеләп үз мәкаләсе дә бар.)

Аңа 1982 елны «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Лирон Хәмидуллинның әдәби әсәрләре 60 нчы еллар урталарынан күмәк әдәби җыентыкларда, газета-журнал битләрендә күренә башлый. Яшь һәм башлап язучыларның «Яшьлек таңы», «Кайнар хисләр» җыентыкларында дөнья күргән һәм башка хикәяләре җирлегендә 1968 елда аның беренче хикәяләр китапчыгы басылып чыга. 1971 елда тимер юл төзүчеләр тормышын сүрәтләгән «Дала иртәсе» повесте басыла. Бу китапларда дөнья күргән әсәрләргә карата үз вакытында вакытлы матбугатта уңай фикерләр әйтелә. Мәсәлән, 1972 елда басылган бер мәкаләсендә Хәсән Сарьян, каләмдәше иҗатына тукталып, түбәндәге сүзләрне яза: «Бүген үк инде күз уңыннан төшермәс яшь иҗатчыларыбызның берсе – Лирон Хәмидуллин. «Дала иртәсе» повесте аның икенче китабы... Әдәбиятка ул, кайбер яшьләребез кебек, институт яки университетның филология факультетыннан гына сикереп төшми, ә тормышның эченнән үз дөньясы белән килә. Бу да язучы өчен бик кирәкле шәйдер... Автор күзәтә белә, шул күзәтүләрен детальләр аша уйлый белә, шуларга үз сүзен таба белә».

Проза үзенчәлекләрен яхшы белүче әдәбият тәнкыйтьчесе Фәрваз Миңнуллин да соңрак язучы Л.Хәмидуллин хикәяләрен уңай бәяләп язды. Аның 1989 елда нәшер ителгән «Затлылык» китабында мондый юллар бар: «Матур әдәбият дөньясында «бу мин» дип, әллә каян кычкырып торган талантлар арасында һәрвакыт тыныч һәм салмак кына үз эшен эшләп, шуңардан тәм һәм ямь табып яшәүче тыйнак язучылар була. Лирон Хәмидуллин – шундыйларның берсе. Ул безнең әдәбиятның күгәрчен күзе үләне... Әйбәт тәрҗемәче булу белән бергә, Лирон Хәмидуллин үзенчәлекле прозаик та... Үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Ышандырырлык һәм тормышчан булулары өстенә аның әсәрләрендә тел белән сөйләп, аңлатып бирүе кыен булган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә торган үзгә

бер моң, настроение, эчке көй бар. Әйтик, «Кыш үткән юл буйлап...» яки «Буранда» хикәяләрендә...»

Л.Хәмидуллин үз иҗатының кимендә яртысын тәрҗемә эшенә багышлагандыр, мөгаен. Шуңа күрә аның ул өлкәдә башкарган кайбер хезмәтләрен дә барлап үтү кирәк шәйдер. Заманында, ягъни Язучылар берлегендә эшләү дәверендә, аңа кардәш әдәбиятлар белән элемтә тоту, тәрҗемә эшен җайга салу бурычлары да йөкләнә. Ун ел чамасы ул тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе булып эшли. 70–80 нче елларда ул Казакъстанда – татар повестьлары китабын, Үзбәкстан белән Каракалпакстанда хикәя җыентыкларын туплап чыгара. Күренекле казакъ әдипләреннән Абайның шигырь һәм чәчмә хезмәтләре җыентыгы «Абай»ны, Әнүәр Әлимҗановның ике повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» китабын, Сайын Моратбәковның повесть һәм хикәяләрен туплаган «Әрем исе» җыентыгын, Мохтар Магауинның «Кара кыз» повестен, үзбәк телендә иҗат итүче милләттәшебез Әсгать Мохтарның «Чинар» романын татар укучысы бүген Лирон Хәмидуллин хикәяләвендә укый. Мәшһүр белорус әдибе Василь Быковның сугыш темасына багышланган ике повестен берләштергән «Һәйкәл» китабы да Лирон аганың зур хезмәте булып саналырга лаек.

Бу уңайдан тәрҗемә турында язучының үз фикерләрен искә алып узу да кызыклы. Бүгенге көндә милли телләргә тәрҗемә итү эше – бик актуаль һәм шул ук вакытта бәхәсләргә дә сәбәп булган мәсьәлә. Моннан берничә ел элек хәбәрченең «Татар укучысына бүген дә тәрҗемә әсәрләре кирәкме?» дигән соравына Лирон аганың җавабы мондый: «Бик кирәк. Бер генә әдәбият та үз-үзенә бикләнеп кенә яши алмый, һәркемгә башкалар белән көндәлек аралашу зарур булган кебек, әдәбиятлар да үзара аралашмыйча зур уңышка ирешә алмый. Ә казакъ әдипләре әсәрләренә өстенлек бирелүнең ике сәбәбе бар. Беренчедән, авыл мәктәбеннән соң мин дүрт ел Казакъстанда укыдым, казакъ яшьләре белән дә аралаштым. Икенчедән, мәктәп елларыннан бирле мин тарихи әдәбиятка өстенлек бирә килдем. Борынгы төрки дөнья мине элек-электән кызыксындыра. Татар әдәбиятында төркиләр тарихын чагылдырган әсәрләргә юл ябык булган елларда, казакълар бу өлкәдә алда баралар иде. Шул сәбәпле мин иң әүвәл казакъ әдәбиятына мөрәҗәгать иттем... Бүген дә тәрҗемә әсәрләре бик кирәк. Шул ук төркиләр тарихына багышланган әдәби яки иҗтимагый эчтәлекле күпме китап басылып чыга хәзер. Бездә аларны язардай әдипләр дә, галимнәр дә сирәк. Ул өлкәне яхшы белеп һәм бирелеп эшләгән Миркасыйм Госманов, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйть Хәбибуллиннар гына ул эшне башкарырга өлгерә алмыйлар».

Тарих һәм әдәбият галиме, академик Миркасыйм Госманов Лирон аганың эшчәнлегенә багышланган мәкаләсендә болай дип яза: «Аның әдәби иҗатында махсус тәкъдир итүгә лаек бер юнәлеш бар. Ул – элекке чор күренекле әдипләребезнең тормыш юлларын, мирасын өйрәнүгә багышланган эзләнү һәм бастырып чыгару эшләре. Мәгълүм драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзи белән атаклы шагыйребез Дәрдемәнд хакында махсус эзләнүләр башкарылу, шул максат белән алар эзеннән йөреп, Башкортстандагы Җиргән, Юлык авылларына, Баймак шәһәренә барып чыгулар, Чиләбе өлкәсендәге Балкан, Требия авылларында, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә эзләнүләр, әлеге әдипләрнең оныкларын, туганнарын эзләп табу, алар белән хат алышулар, ниһаять, архивларда казынулар. Шулар нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән «Офыктагы рәшәләр» китабы һәм «Галиябану туган якларда» исемле юлъязмасы барлыкка килә... Бал корты кебек гел эзләнүләрен, шау-шусыз гына нәтиҗәле эшләвен дәвам итә».

Әйе, Оренбург өлкәсенең Орск шәһәрендә эшләү дәверендә үк Лирон Хәмидуллин тормыш-яшәешләре шул шәһәргә бәйле булган кайбер олуг шәхесләрнең иҗаты һәм мирасы белән кызыксына, аларны белгән кешеләр белән аралаша. Шул рәвешле үзенчәлекле шагыйрь, атаклы нашир һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев –Дәрдемәндкә, күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзигә, узган гасыр башында «Таңчылар» хәрәкәтендә актив катнашкан, Г.Исхакый, Г.Тукайларга сердәш-дус булган Шакир Мөхәммәдъяровка, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең Орск, Оренбург чоры эшчәнлегенә мөнәсәбәте булган документаль әсәрләре барлыкка килә. Ул хезмәтләрнең бер өлешен язучының 1989 елда нәшер ителгән «Офыктагы рәшәләр» китабында урын алды. Дәрдемәндкә багышланган «Офыктагы рәшәләр» документаль повестен үз вакытында «Казан утлары» журналы да бик теләп бастырып чыгарган иде. Соңрак шул вакытта тупланган язмалар һәм Дәрдемәнднең дүрт оныгы белән аралашулар нәтиҗәсе буларак «Тарихта үз эзләре бар» һәм «Рәмиевләр матбагасы»

документаль очерклары да языла. Алар «Бертуган Рәмиевләр» күмәк җыентыгында дөнья күрде. (Күпсанлы фотолар белән баетылган ул җыентык Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә 2002 елда нәшер ителә.) Дистә еллар дәвамында Дәрдемәнд баскан эзләрдән йөрү, аның рухы сакланган җирләрдә һәм архивларда булу нәтиҗәсендә Дәрдемәндкә багышлап фотоальбом чыгару хыялы туа. 2003 елда, ниһаять, ул хыял да тормышка аша, «Дәрдемәнд» альбомы басылып чыга. Альбомдагы төп текст авторы Лирон ага Хәмидуллин.

Лирон Хәмидуллинның соңгы ике китабына кергән яки вакытлы матбугатта, шул исәптән «Казан утлары» журналында басылган соңгы дәвер әсәрләренең төп темасы милләт язмышын кайгыртып яшәгән шәхесләр эшчәнлегенә бәйле. Үз милләтенең киләчәге өчен җан атып яшәгән зыялыларыбыздан Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Габделбари Баттал, Йосыф Акчура, Камил Мотыйгый һ.б. багышланган документаль повесть, очерк, эссе кебек әсәрләрен автор, минем карашымча, шулай ук үз халкына файда китерим дигән максаттан чыгып башкарды. Әйе, әсәрләре геройларына хас рәвештә, авторның үзенең дә тоткан төп мәсләге – үз халкына хезмәт итү. Узганнар мисалында яшь буынга дөрес юл күрсәтергә тырышу. Хәер, һәр житди иҗат иясенә хас – прозаикмы ул, шагыйрьме, абруй казанган журналистмы – бер изге максат инде ул. Кулына каләм алган күпчелекнең хыялында халкы күңеленә хуш килердәй әсәр иҗат итү. Алда әйтелгәнчә, һәркем ул максатка үз юлы белән килә. Зур Иделгә койган инеш-елгалар төрле булган кебек, һәр каләм иясенең дә иҗат юлы төрлечә булуга карамастан, төп максаты әдәби мохит дигән зур диңгезгә халкы өчен мәгънәле дип тапкан үз сүзен ирештерергә теләү. Лирон аганы шул максатына ирешүгә якын торучылар исәбенә кертеп буладыр, шәт. Иҗат юлын иртәрәк башлаган булса, бәлки, иҗат хәзинәсе күбрәк тә булган булыр иде... Нишлисең? Язмыш. Булганына шөкер итеп, куанырга кала. Шунысы куандыра: ул һаман эштә, хәрәкәттә, иҗат юлында. Аның әле башлам чорын үткән, әмма дөнья күрергә өлгермәгән хикәя һәм повестьлары да бар. Киләчәктә алар да дөнья күрер дип өметләник.

Кеше, әгәр дә ул шәхес дәрәҗәсендә икән, аның максаты – иманнан, сүзе эшеннән аерылмаска, үткәне хыялдагы киләчәгенә табигый һәм эзлекле тоташкан, гамәлләр төене бербөтен булырга тиеш. Бу җәһәттән Лирон аганы мин шәхес дип саныйм. Ул үзенең гаиләсен, якыннарын да, үз кыйбласына юнәлтә алды. Хатыны Дания ханым гомере буе әдәбият-сәнгать кешеләрен хөрмәт итеп яшәде, озак еллар Язучылар берлегендә эшләде, исәп-хисап эшләрендә булдыра алганча язучыларга ярдәм итәргә тырышты. Бер сүз белән әйткәндә, үзебезнең кеше. Улы Булат Хәмидуллин хәзер инде үзе күренекле зат. Ул – галим, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Фән» нәшриятының баш мөхәррире. Күп кенә фәнни хезмәтләр авторы. «Народы Казанского ханства» дигән зур хезмәте Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та чыкты. Ул шулай ук, әтисе кебек үк, тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Кызы Зөһрә Хәмидуллина, КДУны тәмамлап, дәүләт оешмасында эшли, милли рухта балалар үстерә... Күренеп тора: гаиләдә, уртак максатта дәвамчылык бар. Димәк, киләчәккә өмет-ышаныч бар.

*2007*

# *КАЗАННЫҢ ИҢ БАЙ ЕГЕТЛӘРЕ*

Иртән тор да чиста-пакь күлмәк ки,
һәм дусларны арттыр дөньяда!

Язмамның исем итеп куелган сүзләрен укыгач, долларлы миллионнарга ия кайберәүләр сискәнеп, сәерсенеп тә куярлар: кемнәр икән ул байлар (хәер, юкка борчылам: татар фамилиясе йөрткән замана байларының абсолют күпчелеге, вакланып, әби-бабалары, әти-әниләре сөйләшкән телдә газета-мазар укып маташмас...)? Сискәнмәсеннәр дә, гаҗәпләнмәсеннәр дә, сүз алар аңлаган байлык турында бармый. Байлык – адәм балаларының акылын саташтыра торган нәрсә, катлаулы төшенчә. Бу очракта үзем аңлаган байлык, рухи дөньяга бәйле кыйммәтләр, аларга турыдан-туры мөнәсәбәте булган шәхесләр турында.

Башкалабыз үзәгендә ике зур мәһабәт бина бар. Бездә башка күркәм биналар да җитәрлек. Әмма бу икесе халкыбыз тарихында миссиясе һәм әһәмияте ягыннан аерым статуска ия. Аларның берсе – Г.Камал театры, икенчесе – «Казан» милли мәдәният үзәге. Бу биналарның хуҗалары, ягъни директорлары – бертуган Закировлар (бу юлларны язганда, Дәрдемәнднең чын исеме Закир, ә Н.Исәнбәтнең чын фамилиясе Закиров булуы искә төшеп алды). Шамил Зиннур улы Закиров Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасы төзелгәннән башлап, ягъни 1985 елдан бирле эшли, ә Ринат Зиннур улы Закиров – 1988 елдан башлап «Казан» милли мәдәният үзәге (1984–1990 елларда В.И.Ленин Үзәк музееның Казан филиалы) бинасында директор.

Закировлар хуҗа булган бу биналар безнең өчен үзенчә изге (бигрәк тә Камал театры); бирегә күңел кушуы белән килеп, җанга «азык алып», шатлыктан сөенеп, аяныч хәлләрдән көенеп, әмма рухи яктан яңарып һәм тураеп чыга торган мәккәи урыннар. Укып-ишетеп беләбез: үткән гасыр башында Казан татарларының мәдәни учагы булып «Шәрекъ клубы» эшләп алган. Анда Тукай заманы зыялылары җыелган, спектакльләр куелган, китапханәләр эшләгән, «Сәйяр» труппасы җыйналган... Кыскасы, клуб ул чорда яңа яралып килүче милли сәнгатьнең үзенә күрә бер бишеге булган. Бүгенге Камал театрын һәм Милли мәдәни үзәкне «Шәрекъ клубы»ның дәвамчылары санап, аналогия үткәреп буламы? Була кебек. Чөнки тарихи максат шул ук: халыкны милләт буларак саклап калу, рухи үсешен тәэмин итәргә тырышу. Масштаблар гына бүтән, тәрбия ысуллары гына үзгәрәк. Әйтик, «Шәрекъ клубы»на илле-алтмыш кеше йөрсә, Закировлар идарә иткән биналарда, көн саен яки көнаралаш дигәндәй, уртача бишәр йөз кеше тамаша кыла. Кемнәр йөри соң бу залларга? Монда бит мал бүлмиләр! Асылда, Үткән белән Киләчәкне өзеклексез әхлакый тоташтыру зарурлыгын аңлаганнар йөри бу залларга. Рухыбыз сау булсын өчен, телебез бетмәсен өчен, көй-моңнарыбыз саклансын өчен. Шундый мәркәзи биналарны (бу сиңа ярым криминал казино-мазино йортлары түгел!) үз кулларында тоткан, хуҗа була белгән егетләрне ничек итеп иң-иң байлар дип атамыйсың!

Закировлар – тумышлары белән Чистай ягы кешеләре. (Чистай ягы Гаяз Исхакый, Әмирхановлар ягы инде ул.) Төгәлрәк әйткәндә, Нарат-Елга авылында ишле гаиләдә туып үскән егетләр. Мәктәпне тәмамлагач, Казанның химик-технология институтына юл тотканнар, кергәннәр, укыганнар (бу очракта шуны да искәртеп үтәсем килә: беренчедән, башлы булган егетләр! Татар мәктәбен бетергәннәргә техник вузларга керү бик авыр иде; сәләтле күпме татар егет-кызлары рус теленнән сочинение аркасында киселеп калдылар! Икенчедән, техник белем алсалар да, милли мәсьәләләрне нечкә аңлауда, аларны чишү өчен тырышуда, гуманитар белем алган байтак мөтәтатарлардан Закировлар күп башка өстеннәр!). Институтны бетергәч, табигый, һәр кешенең индивидуаль, үзгә хезмәт юлы башлана. Тәртип-холыклар белән бер-берсеннән шактый аерылсалар да, Шамил белән Ринатның тормыш елъязмаларында охшаш яклар да байтак, һәр икесе дә вуз бетергәннән соң да укуларын дәвам итәләр. Шамил Ленинградта аспирантура (техник өлкәдә түгел, культура институтында!) тәмамлый, Ринат күптән инде фәннәр кандидаты. Икесе дә комсомол-партия мәктәбен үтәләр, ягъни район һәм өлкә комитетларында эшлиләр. Икесе дә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре... һәм, ниһаять, алда әйтелгәнчә, икесе дә директорлар.

Бертуган Закировларны мин кырык еллап беләм. Өлкәне Шамил белән, табигый, алданрак таныш. Ныклабрак танышу 1968 елны булды. Шамил – КХТИ студенты, активист, сәхнәпәрвәр. Институтның актлар залында татарның яшь әдәбият-сәнгать вәкилләре белән очрашу оештырды ул. Без дүртәү чыгыш ясадык: җырчы Илһам Шакиров, композитор Ренат Еникеев, язучы Роберт (ул вакытта әле Рабит түгел) Батулла, яшь шагыйрь сыйфатында – мин. Ул кичә мәңге онытылмаслык тамаша булды. Халык залга, коридорларга сыймады. Милициягә дә эш булган ул кичне, урамда калган яшьләр ишекләрне каерып, тәрәзәләрне ватып залга үтмәкче булган. Торгынлык чорының башлангыч еллары булса да, сәяси «җепшеклек» кайтавазы көчле булган әле ул вакытта. Шамил инициативасы белән оешкан бу кичә төрле вариантларда Казанның байтак вузларында шаулап узды. (Ул еллар турында олуг әдибебез Рабит Батулла тәфсилләп язып чыгарга да ниятли дип беләм. Батулла ул чорда «Ядкарь» иҗади яшьләр хәрәкәтен җитәкләде.) Оештыру сәләте студент елларында ук булган инде Шамилнең. Закировларга бер нәрсә хас: әгәр үзләре инанган максат өчен кирәк булса (беренче чиратта милли мәнфәгать), алар вазифаи кысаларга гына сыя торган затлар түгел.

Бер карасаң, студент-химикка ул кичәне оештыру мәҗбүри ихтыяҗ түгел бит. Ә бит оештырган! Димәк, аның бу гамәле күңел таләбе, җан таләбе булган. Мондый мантыйк белән фикер йөртсәң, Шамил әфәнденең гомере буе кылган бар хезмәтләре күңел таләбе белән башкарылды шикелле. Эшне җаны-тәне белән бирелеп үтәү – бу аның тормыш кодексы, кредосы. Чирек гасырга якын театрда директор булып торганда, бихисап эшләрнең байтагын, бәлки әле, яртылабындыр, эшләмәскә дә булыр иде. Беркем дә бәйләнмәс иде. Дөньяда инструкция-устав буенча төп-төгәл үз вазифасын гына башкарып, тыныч кына бәргәләнмичә яшәп, карьера яулаган җитәкчеләр буа буарлык. Соңгы дистә еллар эчендә Шамил Зиннурович инициативасы һәм турыдан-туры катнашы булган театрдагы зур башлангычларның кайберләрен генә санап үтим: өлкән яшьтәге ветеран артистларның «Инсаният» труппасын төзү, яшьләр өчен «Балачак» студиясе оештыру, «Яңа татар пьесасы» конкурсын үткәрү, театр һәм артистлар турында китап-альбомнар бастыру, шактый озак еллар өзеклектән соң ерак өлкәләргә һәм чит илләргә янәдән гастрольләргә чыга башлау. Театр эчендәге иге-чиге, очы-кырые булмаган хуҗалык һәм ремонт эшләре... Ярый, бу гамәлләр театр эшчәнлегенә, директор вазифасына карый диик. Ә менә соңгы елларда Кызыл Байракта (Югары Ослан районы) гөрләп уза торган «Сәйдәшне искә алу» тантанасын, Яуширмәдә (Чистай районы) үткәрелүче «Исхакый укулары»н, театр мәйданында «Туган тел» бәйрәмнәрен оештыруга алынуын ничек аңлатасың? Кушып эшләтә торган гамәлләр түгел болар. Сәйдәшкә багышланган бәйрәмне сабантуй шикелле үк зарыгып, сагынып көтеп алалар хәзер. Бу бәйрәм елдан-ел масштаблы төс ала. Безнең күз алдында республикакүләм яңа бәйрәм туды. Әлбәттә, бу чараларда Мәдәният министрлыгы, театр, иҗади оешмалар, җәмәгатьчелек тә актив катнаша. Әмма, ни генә дисәк тә, бу очрашу-тантаналарны Шамил Закировсыз күз алдына китерү кыен. Күп нәрсә аның фидакярлегеннән, тынгысыз тырышлыгыннан тора. «Байлык тынгы бирми ул!» дигәннәре әллә дөрес микән? Әллә рухи байлык иясенә дә карый микән бу тәгъбир?

Шамил Закиров. Кемнәрдер аны «изге җандыр ул» диләр. (Төрле телләрдә йөзәрләгән Коръән тупланмасын булдыру да нәрсәдер аңлата шикелле.) Мин үзем, мәсәлән, аның байтак язучыларга ярдәм кулы сузганын беләм. Ул шулай ук халкыбызның төп журналы булган «Казан утлары»ның да якын дусты, аны таратуда булышып тора. Кайчак уйлап та куям: бу кешенең дошманнары, һич югы, көралмаучылары бар микән? Бардыр. Озак еллар җитәкче булган кешене өнәмәүчеләр булырга тиеш. Шулай да андыйларның дәлилләре аздыр. Үлчәү тәлинкәсенең яхшырак ягы дигәне шапылдап аска тартадыр... Мәшһүр артист Ринат Таҗетдинев әле быел гына узган үзенең юбилей кичәсендә болай дигән иде: «Шамил Зиннурович исән-имин эшләгән чакта җирләнергә насыйп булсын иде!» Артистларча, бераз эффектны да онытмыйча әйтелгән булса да, бик тә гыйбрәтле, моңсу сүзләр!

Шамилне кайчак арыган, алҗыган кыяфәттә дә күрергә туры килә. Кеше тимер түгел, көне-төне чабып, янып эшләгәч, арырсың да... Алсу йөзле, тук кыяфәтле, вәкарь белән генә сөйләшүче, кәнәфиендә канәгать оеп утырган Шамил Зиннур улын күрергә насыйп булмады инде. Һәм булмас та. Ул шулай – Үзе булып яратылган.

Шамилнең туганы Ринат турында берничә сүз. Хәер, бу шәхес турында берничә сүз белән генә булмый: ул башкарган эшләр аерым тикшерүләргә, аерым хезмәтләргә лаек. Ринат Зиннурович белән дә күптәннән таныш. 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш елларында бигрәк тә еш очраша идек. Аңарчы да, партия өлкә комитетында иҗат оешмалары белән кураторлык иткән елларында да шактый күрешелде, кайбер уртак эшләр дә башкарылды. Хәзер дә аралар өзелмәде. Әмма һәрберебез өчен Вакыт дигән нәрсә цейтнотның синонимына әверелеп бара хәзер...

Ринат Зиннурович – конкрет, стратегик эшләр кешесе. Ахыр максатлар абыйсыныкы кебек булса да, максатка бару, аңа ирешү юллары шактый ук аерыла да. Шамилнең гомерлек хезмәте эмоциональ иҗат кешеләре – артистлар, язучылар, композиторлар белән үтсә, Ринат тормышының байтак өлеше рәсми кешеләр – төрле рангтагы җитәкчеләр, чиновниклар даирәсе белән бәйле. Бу хәл, әлбәттә, аның эш стилендә дә чагылыш таба. Ул бүгенге җәмгыятьтәге үсеш динамикасының нечкәлекләрен яхшы белә, киләчәкне конкретрак күзаллап яши. Кыскасы, заманының гыйлемле зирәк улы, актив хадиме. Үз вакытында байтак еллар комсомол-партия структураларында эшләү, чарлану, шул чор идарә итү мәктәбен үтү

аңа файдага киткән дип уйлыйм. Нинди генә шигарләр астында яшәмик, дөньяда яшәү рәвеше кисәк кенә үзгәрә алмый, асылы аның, нигездә, шул ук кала.

Ринат Закиров – хәзерге татар дөньясында иң билгеле шәхесләрнең берсе. Аның хезмәти вазифасы белән дә бәйле бу хәл. Ул – Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе. Мөгаен, бөтен дөньяга сибелгән татарларның яшәешен иң яхшы белгән кешедер ул бүген. Татар дөньясы – бик катлаулы, четерекле, күп катламлы дөнья. Аны бербөтен милләт итеп сакларга тырышу – ифрат авыр миссия. Миңа калса, милләтне берләштерү процессы әлегә уңышлы бара. Бу тарихи хәрәкәттә, һичшиксез, Р.Закировның роле зур. Ринат Зиннурович конгресс җитәкчесе буларак та, халык депутаты буларак та абруйлы җитәкче. Бер генә мисал: моннан өч ел элек Казанга Россия Президенты Владимир Путин килгән иде. Ул республика җитәкчелеге һәм татар җәмәгатьчелеге белән Казан Кремлендә очрашты. Бик югары дәрәҗәдәге очрашу. Анда күрше республика президентлары да бар иде. Татар халкының рухи үсешендәге борчыган мәсьәләләрне күтәреп, Ренат Закиров кыю чыгыш ясады. Нотык, аңлавымча, Республика исеменнән, татар халкы исеменнән иде. Кайчак зур җитәкчеләргә күтәрергә кыен мәсьәләләрне җәмәгатьчелек вәкилләре әйтсә, кулайрак була...

Нинди генә дәрәҗәле постлар булмасын, беркөн алар бетә: рәислекләр дә, депутатлыклар да... Тормышның аяусыз, гадел кануны. Сайланып куелу белән бәйле вазифалардан тыш, кешенең, әгәр ул шәхес булса, күңел куеп, җегәр салып тудырган хезмәт-ядкарьләре дә калырга тиештер. Бу уңайдан Ринат Закировның әлегәчә алыштыргысыз директор буларак, «Казан» милли мәдәни үзәгенең эшчәнлеге турында да әйтеп китү дөрес булыр. Үткән гасырның 80 нче еллар уртасында шәһәр үзәгенең Казансу буенда корылган бу бина, шул заман хакимнәре уенча, Ленин тәгълиматларын пропагандалау үзәкләренең берсе булырга тиеш иде. Дөнья куласа, заманалар үзгәреп, коммунистик идеяләр тарату урынына бу мәһабәт бина Милли үзәккә, милли мәдәният, милли идеяләр үзәгенә әверелде. Моннан ике ел элек «Казан» милли мәдәният үзәгенең унбиш еллык юбилее да уздырылды. Шул вакытта фәнни-гамәли конференция дә узды. Конференциянең исеме үк күп нәрсә аңлата: «Милли мәдәният үсешендә һәм иҗтимагый аң формалаштыруда «Казан» милли мәдәният үзәгенең роле». Төп фикер шул булды: ифрат зур! Күпләребез үзәкне иң әүвәл концертлар, төрле кичәләр, күргәзмәләр, конференцияләр, симпозиумнар үткәрү урыны дип белә. Ул шулай да. Әмма Үзәкнең төп байлыгы – аның Милли мәдәният музее икәнен күпләр белеп җиткермәскә дә мөмкин. Берничә сан китереп узыйк: музей тупланмаларында археология, этнография, нумизматика, картография һәм театр, музыка, рәсем, декоратив-гамәли сәнгать төрләренә караган утыз алты меңгә якын экспонат бар! Шуларның унике мең чамасы төрле тарихи документлар һәм сирәк очрый торган китаплар. Кыска гына вакыт эчендә никадәр байлык тупланган!

Үзәкнең шәһәр филармония составына кергән сәнгать коллективлары аерым игътибарга лаек. Алар – «Казан нуры» халык уен кораллары һәм «La Primayera» камера оркестрлары, «Казан» бию ансамбле. Бу коллективларны дөньяның күп илләрендә яхшы беләләр. «La Primayera» турында күп язылды, ә «Казан» бию ансамбле турында аерым әйтәсе килә: Татарстанның җыр һәм бию ансамбленә көндәш коллектив ул. Җитәкчесе Чулпан Закирова (Р.Закиров һәм актриса Р.Мотыйгуллиналарның кызы) куйган биюләр тамашачы күңеленә бик хуш килә. Мескенлек юк аларда! Биючеләрнең нәфис пластик хәрәкәтләре матур эстетик тойгылар, горурлык хисләре уята. Сәхнәдә түбәтәй киеп, кәҗә бәтиләре кебек сикергәләп йөрү заманнары узды. Чулпан куйган биюләрне күргәч, «Браво! Афәрин!» дип оран саласы килә.

Ринат Закиров җитәкләгән Үзәк үзе бер мәдәни дәүләт ул. Коллективта эшләүчеләрнең саны гына да ике йөз утыздан артык, ә кылган зур гамәлләр саны – меңләгән!

...Бертуган Закировларның эшчәнлеге сокландыра да, уйландыра да. Бер максатны кыйбла итеп алып эш иткән бертуганнар элек тә булган. Әйтик, Рәмиевләр, Шәрәфләр... Хәзер дә булырга тиеш, һәм беркадәр бар да алар. Күңел күбрәк булуларын тели. Әгәр халкыбызның һәр улы-кызы бертуган Закировлар эшләгән эшләрнең бик аз өлешен генә башкарсалар да, милләтебез тормышы шактый камил булыр иде.

Шамил һәм Ринат Закировлар турында бер-ике кәлимә сүз әйтергә күптән кыҗрап йөри идем. Язмам башындагы берничә җөмлә моннан ике ел элек язып та куелган иде. Ниһаять, теләгемә ирештем шикелле. Ничек килеп чыккандыр, анысы икенче мәсьәлә. Үзем өчен иң мөһиме – күңел тынычланып калды. Язарга форсаты да чыкты шул: бу көннәрдә Ренат Зиннур

улы Закировка 60 яшь тула. Исәнлек-саулык, олуг эшләрендә уңышлар телибез аңа. Шундый ук теләкләр Шамил Зиннур улы Закировка да ирешсен.

*2008*

## *СИН САЗЫҢНЫ УЙНАДЫҢ*

*(Мәрсия урынына)*

Нәкый ага вафат...

Үлем дип аталган Илаһи Кара Канатның башларыбыз өстеннән сискәндереп үтәсен сизенгән булсак та, без аның килеп җитәсенә әзерләнеп җитмәгән булганбыз икән... Җан өшеткеч бу хәбәрне ишеткәндә, без – бер төркем каләмдәшләр – Язучылар йортында идек. Мәһабәт бинаның (хәзерге Мөштәри урамы, 14) ишегалдында мәш килеп кино төшерәләр. Без тамаша кылып кырыйдан карап торабыз. Сәер очрак: кызык та, кызганыч та. Тирә-якта ясалма төтен, янгынчыларның кызыл машиналарыннан сиптерелгән ясалма яңгыр, актерларның (күбесе Н. Исәнбәт спектакльләрендә каһарман рольләрен уйнаган артистлар) ясалма киемнәре, ясалма көлү-елмаюлары... һәм Бөек Шәхеснең фани дөнья белән саубуллашу мизгелләре...

Төтен... Ясалма яңгыр... Тотрыксыз сәясәт... Ә чыны – көз. Сирәк була торган кояшлы, җылы көз татарның бөек улы Нәкый Исәнбәтне (чын фамилиясе – Закиров) мәңгелек юлга озатырга үзенчә әзерләнгән кебек. Тирә-юньдә моңсу олпатлык... Шәфәкъка тоташкан сарылык.

Нәкый аганың, һәр олуг шәхеснеке кебек, тормыш һәм иҗат юлы фаҗигаләр һәм тантаналар белән үрелеп барган. Яшьлек хыялларындагы бөеклеккә үрләткән биеклекләр дә, күңелдә җәрәхәт калдырган абыну-егылулар да, кыерсыту-эзәрлекләүләр дә (заманында КПСС ҮК ул әзерләгән «Идегәй» дастанын тыю турында махсус карарны тикмәгә генә чыгармаган инде!); олы язучы булып саналган елларда кочегар – мич ягучы, ишегалды себерүче кебек тузанлы-корымлы кара эшләрдә йөрергә мәҗбүр булулар да, алкыш һәм чәчәкләргә күмелеп (аның пьесалары буенча куелган кайбер спектакльләр зур сәхнәләрдә берничә мең мәртәбә уйналган!) данда тибрәнүләр дә... барысы да булган.

Нәкый Исәнбәт – тарихи фигура. Андыйлар сирәк. Табигатьнең асыл заты буларак, дөньялыкта үз миссиясен аңлаган кеше. Халык рухының, халык иҗатының энҗеләрен, такыя кебек үреп, килер буыннарга тапшырган зат. «Татар халык мәкальләре»нең өчтомлыгы үзе бер бөек хезмәт. Күләмле кереш сүзе генә дә әллә ничә диссертациягә торырлык. Һәр татар кешесе бу хезмәтләр белән танышып, аны җанына сеңдерсә, без җир йөзендә бик абруйлы милләт булыр идек... Ә ул төзегән сүзлекләр? Татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихы турында күләмле хезмәтләр? Кызганыч, аларның байтак күп өлеше әлегәчә дөнья күрмәгән. Ул төзегән «Идегәй» дастаны – үзе бер эпопея. Зур шәхесләр төрле яктан талантлы була шул. Ул – энциклопедик белемгә ия галим, сәхнә остасы, драматург, шагыйрь. «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Илкәем» кебек җырлары гына да ни тора!

Күптән түгел аның 90 еллык юбилее булып узган иде. Тантанада ул үзе катнаша алмады. Кадер-хөрмәт күрсәтеп бирелгән бүләкләрне, иясенә тапшырырмын дип, улы Празат Исәнбәт алган иде... Хәзер инде аңа бернәрсә дә тапшырып булмый. Үзен генә җир куенына тапшырырга кала... Сүз җаеннан әйтәсе килә: юньледән юньле нәсел кала. Нәкый аганың улы Празат – татар театрының олуг режиссеры, хикмәт иясе; кызы Йолдыз – татар музыка сәнгатенең зур белгече, сәнгатькяр кеше... Үзеннән соң эшеңне дәвам итүчеләр булу – үзе зур бәхет.

Газраилгә һәркем тигез. Аңа патша ни дә, мәхлук кол ни! Туганбыз икән, һәммәбез бер юлда, чакрым баганалары гына төрлечә... Әмма һәр Бөек Акт тетрәндерә, ми генә түгел, бөтен тән кымырҗып куырылып ала кебек. Зур Кеше китеп бара. Аны кем алыштырыр? Әлбәттә, беркем дә алыштыра алмас. Шулай да хәтерле кешеләр, яшьләр аның эшен дәвам иттерә алалар. Тиешләр. Һәммәбезгә онытмаска иде: ул үзе яшәгән чордагы татар халкының рухи анатомиясен язып-күрсәтеп китте. Үзенә күрә бер күрсәтмә-харита...

Без бу арада митинглар шаукымында яшибез. Гомер үткәч, бу еллар гаҗәеп еллар булып искә төшәр әле! Татар соңгы ничә гасырдан соң үзен «Дөньяда без дә бар!» дип күтәрелеп

чыкты, үз тавышын ишеттерә башлады. Ә каян килә соң бу уяну, бу күтәрелеш? Әлбәттә, Тукайлардан, Исхакыйлардан, Нәкый ага Исәнбәтләрдән! Ул, хәл-вазгыятьне тирәннән аңлауда, замандаш һәм хәким зат буларак, дәүләтчелекне (ата-анасыз йортта тәртип булмый ул!) торгызу юлындагы хәрәкәттә төп фигураларның берсе иде. Таяну нокталарыннан тора бу Дөнья!

Нәкый Исәнбәт вафат. Шул сәбәп белән хисләнеп уйлануларым болар. Меңләгән бүтән милләттәшләребезнең фикерләре, бәлки, бүтәнчәрәктер. Тирәнрәктер... Уртак максат юлында барганда, һәрнәрсә аклана. Хәтта үлемне дә аңлап була кебек...

...Казан уртасында кино төшерәләр. Литфонд егетләре җеназа хәстәрләре белән йөри. Без, бу сәгатьтә конфузия алган кешеләрдәй гаҗизләнеп, Казан уртасында басып торабыз. Бөек кеше китә. Тарихның асыл бер сәхифәсе ябыла.

Безгә, әлегә исән-сау, сәламәт егетләргә, тамаша кылып торырга гына түгел, саф башындагыларның әләмен алга – алгарышка илтергә кирәк. Бүтән юл юк.

Рухың тыныч булсын, Бөек Татар Улы!

*1992*

****

Моннан 17 ел элек, Нәкый Исәнбәтнең үлеме хәбәрен ишеткән сәгатьтә теркәлгән язма бу. Үлем-китем көннәрендә мин аны беркая да бирмәдем,      шуңа күрә көндәлек матбугатта күренмәде дә. Язмада импульсивлык, чарасызлык, гаҗизләнү (әлбәттә, шәхес өчен горурлану да) сизелеп тора. Хис фикердән алдарак җилдерә кебек. Автор, сулышы капкан кешедәй, бик күпне тиз генә әйтергә теләсә дә, әйткәне тирән һәм салмак ритмда чыкмый. Вакытын, вакыйгасын искә алсаң, бу хәл табигый дә. Хәер, ничек язылган – шулай язылган. Әйе, шул көннән соң байтак вакыт үтте. Шул елларда Нәкый Исәнбәткә бәйләнешле нинди хәлләр булган, аның иҗатын мәңгеләштерү юнәлешендә нәрсәләр эшләнгән, язмамда хисләнеп әйтелгән теләк-юрамалар никадәр тормышка ашкан?

Кызганыч, күкрәккә сугып әйтерлек зур эшләр бик эшләнмәгән. Дөрес, әдипнең 100 еллыгы уңае белән (1999) Камал театрында истәлек кичәсе уздырылды. 2000 елны 30 нчы елларда Н.Исәнбәтләр гаиләсе торган йортка (Мөштәри урамы) мемориаль такта куелды. Сирәк кенә булса да (нигездә, төрле юбилейлар уңаеннан) сәхнәдән яки экраннардан спектакльләр күренгәләп ала... Иң кызганычы шул: соңгы 20 ел эчендә әдипнең әсәрләре басылмады диярлек. (110 еллыгы уңае белән биш томлыгы чыгып җитәргә тиеш дип беләбез. Афәрин!) Кемгә ничектер, миңа Н.Исәнбәт иң әүвәл бөек галим, фольклорчы, сүзлекләр иясе буларак кадерле. Сүзлекләр җыелмасы – һәр халыкның иң төп рухи байлыгы. Заманында актуаль һәм популяр булган кайбер әсәрләр, әйтик, пьесалар, еллар узгач төссезләнергә, әһәмиятен җуярга да мөмкин. Н.Исәнбәт туплаган өч томлык «Татар халык мәкальләре» ул – үлемсез хезмәт. Беренче чиратта әнә шул хезмәтне (ул 1959–1967 елларда төрле тиражда басылды, хәзер инде сирәк очрый торган библиографик басмага әйләнде) халыкка кайтарасы иде! Моны эшләү әдипнең шәхесен мәңгеләштерү юлында конкрет гамәл, үзенә күрә бер һәйкәл салу булыр иде. Моннан 20 ел элек «Казан утлары» журналында басылган әңгәмәсендә әдип болай дигән иде: «Сынатмаска кирәк, җегетләр!» Чыннан да, бөекләрне онытмаска, сынатмаска кирәк безгә!

*2009*

## ***«ДӨНЬЯДА ПУШКИН БАР...»***

Һәр халыкның үз бөекләре була. Бөеклек ул – рухи һәм акыл биеклеген билгеләүче күрсәткеч. Халкың бөеклегенең ни дәрәҗә биеклеген бүтән зур биеклекләр белән чагыштырып белеп була. Пушкин – әнә шул чагыштыру эталонына әверелгән зур биеклек, һәрхәлдә, элеккеге СССР киңлекләрендә яшәүче халыклар өчен тәгаен шулай булды. Сибгат Хәким тикмәгә генә «Күтәрел югары, мен биек, Мактаулы исемнәр кушсыннар... Инде шул чиге дип уйлама: Дөньяда Пушкин бар, Пушкин бар...» дип язмагандыр.

Дөресен әйтим: моңарчы Пушкин иҗатына тотынырга куркыбрак йөрдем мин. Вакыт җитмәүгә сылтап, бер җае чыгып, җентекләбрәк өйрәнермен әле дип, үз-үземне юаттым бугай. Менә форсат чыкты да, беркадәр Пушкин дөньясында яшәп алдым. Бер дә куркасы булмаган икән! Җиңеләеп һәм баеп калдым. Ул да, илаһи талантка ия булса да, адәм балаларына хас бик тә табигый сыйфатларга ия булган бер зат икән ләбаса!

Бу язмамда Пушкин турында ниндидер яңа сүз әйтермен дип уйламыйм. Ул минем вазифам да түгел. Ике гасырдан артык вакыт эчендә әллә ничә мең галим-голәма тау-тау хезмәтләр язганнар инде. Минем эшем – татар әдәбияты. Ә менә Пушкинның безнең рухи дөньябыздагы урыны турында уйланып алу ярый. Тарихи чагыштыруларның да гыйбрәтле булуы бар. Пушкин яңа рус әдәбиятына нигез салучы санала. Ә безнең әдәбиятта бу миссияне кем яки кемнәр башкарган? Рус әдәбиятында Пушкинга кадәр кемнәр булган? Ә бездә? Әйтик, шигърияттә? Тарих китапларына күз салыйк: А.Кантемир, В.Тредиаковский, А.Сумароков, Г.Державин... Болар, нигездә, XVIII гасыр вәкилләре. Боларга кадәр мирас, асылда, чиркәү, православие диненә бәйле кыйссалар, елъязмалар... Шуңа күрә дә иске рус әдәбияты дигән термин да бик урынлы түгелдер... Ә бездә? Шөкер, без XIII гасырдан башлап борынгы чорларның вәкилләре итеп аерым исемнәрне санап китә алабыз: Кол Гали, С.Сараи, Мөхәммәдъяр...

Безгә Пушкинны балачактан сеңдереп үстерделәр. Мәктәптә кече сыйныфларда ук шигырьләрен русча яттан өйрәтә иделәр. Бөтен мәгънәне аңлап бетермәсәк тә, рус сүзләрен боза-боза сөйли идек: «Буря мглою небо кроет, вихри снежные крутя...» Кемнәргә ничек булгандыр, шигырьләреннән бигрәк, проза әсәрләре якынрак иде безгә. Чөнки туган телдә, татарча укыйбыз, һәммәсе аңлашыла. «Дубровский», «Капитан кызы»... Ничек кенә булмасын, «Пушкин – бөек!», «Пушкин – рус әдәбиятының кояшы!» дигән фикер балачактан ук күңелгә уйдырылып салынды. Шагыйрь биографиясенең кайбер сәхифәләреннән тыш, без аның шәхси тормышын, яшәү рәвешен юньләп белми дә идек. Бәлки, мәктәп баласына шагыйрь тормышының нечкәлекләрен белү кирәк тә булмагандыр. Хәзер, олыгая төшкәч, иҗатын, хатларын, замандашларының истәлекләрен, әдәбият белгечләренең хезмәтләрен беркадәр өйрәнгәч, шундый нәтиҗәгә киләсең: шактый ук каршылыклы, фаҗигаи шәхес булган икән Пушкин хәзрәтләре! Шул заман җәмгыяте, беренче чиратта хакимияте өчен бер дә ипле булмаган үзе. Төп «кимчелеге» – ирек сөю, хаклык даулау, патша-түрәләргә баш бирмәү (үтергеч эпиграммаларын гына искә төшерегез!)... Хәер, бу сыйфатлар бөек шагыйрьләрнең һәммәсенә диярлек хас шикелле.

Пушкинга үтәргә тиеш бик күп сынауларны насыйп әйләгән язмыш: ялгызлыкны да, чын дуслык тоюны да, хыянәт ачысын татуны да, дан-шөһрәтне дә, кимсенү-эзәрлекләүләрне дә... Әмма шунысына шагыйрь рәхмәтле булгандыр дип уйлыйм: иҗат дәрте ташып торган елларда Ходай аны табигатьтән, мәхәббәттән мәхрүм итмәгән, гади халык вәкилләре белән аралашып яшәү мөмкинлеге биргән (юкса халык иҗаты җәүһәрләренә тиң шигъри әкиятләре, табигатьнең илаһи күренешләрен тасвирлаган шигырьләре, мәхәббәткә багышланган гүзәл әсәрләре туа алыр идеме!). Сөргендә яшәгән җирләрен генә искә алыйк: Кавказ, Кырым, Бессарабия, Одесса, Михайловское... Безнең шагыйрьләргә бу җирләрне күреп кайту да (сугыш чорында кайберәүләр солдат булып күргән бу җирләрне...) татлы хыял хәзер.

Пушкин галәми шагыйрь кебек. Кан-геннары белән эссе Африкадан килеп, салкын Русь иленең иң милли шагыйре була алган зат. Элегрәк мин аны, бездәге кебек, бөтен дөнья белә, данлый дип уйлый идем. Яши-яши, дөньяның байтак ил-җирләрен күргәч, хәлнең алай ук түгел икәнен аңладым. Бер халыкның чын мәгънәсендәге милли шагыйре яки әдибе бүтән халыкларның да милли үз шагыйре үк була алмый икән. Күпмедер белергә, танырга, аңларга мөмкиннәр, әмма үзеңнеке үзәктә дигәндәй, барыбер ул чит ата-ана баласыдай, күңел түрендәге асыл кош түгел... Беркавым ул үз дә булып алырга мөмкин. Ләкин вакытлыча, үз

даһиларың туганчы гына. Моңа Тукай мисалында да инанырга була. Бу хәл Пушкин галиҗәнапларына да кагыла дип уйлыйм.

Пушкин томнарын актарам. Аның шигърияте үзе бер гаҗәеп дөнья! Ул кәгазьгә төшкән шагыйрь сүзенең алтын бәясе торган чорында иҗат иткән. Шагыйрьнең бәхете бу. Хәзер, җәмгыятьтә әдәбиятның кадере беткән Россия шартларында яшәп иҗат итсә, ул нинди казанышларга ирешер иде икән? Кистереп җавап бирү дә кыен. Бер генә мисал: быел Үзәк телеканалда Россиянең иң мәшһүр бөек шәхесләрен барлап оештырылган сораштыруда алдагы урыннарны шагыйрь Пушкин түгел, тиран Сталин, реформатор-шовинист Столыпин кебекләр яулады. Сүз сәнгате юлбашчыларының, рухи кыйммәтләренең бүгенге бәһасен шуннан чамаларга була.

Татар дөньясында Пушкин кайчан мәгълүм була башлаган дигән табигый сорау туа. Аның замандашлары кемнәр? Иң әүвәл Габделҗәббар Кандалый (1797–1860) исеме хәтергә килә. Аннан – Утыз Имәни (1754–1834), Һибәтулла Салихов (1794–1867)... Аларның Пушкин иҗаты белән хәбәрдар булу ихтималы турында фаразларга гына мөмкин. Алай гына да түгел, Пушкиннан соңрак дәвердә яшәгән Акмулла, Гали Чокрый, хәтта Шәехзадә Бабич иҗатларына да рус шагыйренең йогынтысы булгандыр дип уйламыйм. Татарның рухи мохите һәм Пушкин даирәсе – икесе ике дөнья. Күпмедер эзәрлекләүләр кичерсә дә, Пушкин – империяле дәүләт вәкиле, шул дәүләт шагыйре, ә безнекеләр — дәүләтсез, ярдәмчесез, хокуксыз халык вәкилләре. Пушкин рәсми басмаханәләрдә китаплар чыгара, калын журналларда басыла алса, әдәби салоннарда дөрләп, балларда бөтерелеп йөри алса, безнең рухани зыялыларыбыз – әдәби тарихны булдыручыларыбыз – кульязма китаплар язып, халыкка вәгазь укудан ары китә алмаганнар. Бу – табигый хәл. Әсәрләренең дә шактые гарәп яки фарсы телендә иҗат ителгән. Әйтик, шул ук Кандалый дәүләтле ил улы булса, ул, кем белә, бәлки, дөньякүләм билгеле шагыйрь булыр иде. Әле шул шартларда да Кандалый татар шигъриятен дөньяви мотивлар белән баетып, аны яңа баскычка күтәрә алды.

Пушкинның татар җәмәгатьчелегендә чын мәгънәсендә пәйда булуы XX гасыр башына туры килә. Әлбәттә, рус мәдәнияте белән беркадәр таныш булган мәгълүм зыялылар катламы Пушкинны күпкә элегрәк белгәндер. Әмма төп халык массасына Пушкин Тукай аша килде. (Аңа кадәр дә аерым тәрҗемәләр булырга тиеш. Әдәбият тарихчылары төгәлрәк беләдер.) Тукай – Пушкин иҗатын яшьли үк шактый җентекләп өйрәнгән кеше. Җаекта яшәгәндә үк Мотыйгулла хәзрәт аны Апуш (А.Пуш.) дип тикмәгә генә атамаган инде. Тукай Пушкинның кайбер шигырьләрен турыдан-туры тәрҗемәләсә, кайберләрен тәкълид (ияреп язу) формасында файдаланган.

Совет чорында, бигрәк тә Язучылар союзы оешкач, Пушкинны (шулай ук чит ил һәм рус әдәбиятының күренекле әсәрләрен) тәрҗемә итү эзлекле бер системага салына. Шагыйрьнең күләмле әсәрләренең бөтенесе диярлек татарчага тәрҗемә ителгән.

Тәрҗемә эше XX гасырдагы күренекле байтак әдипләребез иҗатының табигый бер өлеше санала ала. Үткән гасырның 30–80 нче елларында кемнәр кемнәрне генә тәрҗемә итмәгән! Ихтимал, тәрҗемә китаплары ул чорда чыккан барлык китапларның өчтән бере чамасын тәшкил иткәндер. Чит ил һәм рус классикасы мирасын берничә буын халык ана телендә укып үсте. Димәк, ул чорда телебезнең функциональ куәте шактый югары булган. Хәзер исә әсәрләрне автор язган оригинал телендә уку хәерлерәк ул дип юанырга кала...

Инде янә Пушкинга кайтыйк. Аның кайбер әсәрләре хәтта берничә тапкыр төрле авторлар тарафыннан тәрҗемәләнгән. Әйтик, Евгений Онегинны Ф.Бурнаш 1939 елда ук татарчалаштырган булган, сугыштан соң шул ук әсәр Ә.Исхак һәм Ш.Маннурлар тарафыннан янәдән тәрҗемә ителде. Пушкинны татар укучысына җиткерүне Тукайның җиңел кулыннан соң бик күп татар әдипләре дәвам итте: М.Максуд, А.Шамов, С.Баттал, Н.Арсланов, Г.Шамуков... Күрәсез, тәрҗемәчеләр, нигездә, үткән гасыр кешеләре. Бу китапка да алар калдырган мирасның бер өлеше урнаштырылган. Пушкинны оригиналда укыган кеше өчен дә аның бүтән телдә, бу очракта татарча ничек яңгыравын белү филологлар өчен генә түгел, әдәбият белән кызыксынган һәр зыялы кеше өчен кызык булачак дип уйлыйм.

*2009*

*Әдәбият һәм сәнгатьне үстерергә телибез икән,*
*табигый ки, телне сакларга, үстерергә кирәк.*
*Сәнгатьнең күп төрләре сүз сәнгате белән бәйле:*
*әдәбияты да, театры да, музыка-эстрадасы да...*

## АХЫР ЧИКТӘ ТЕЛ – ХАЛЫКНЫҢ, МИЛЛӘТНЕҢ ЖАНЫ...

## *РУХИ ГАЛӘМДӘ ЯШӘРГӘ*

*(Президент Минтимер Шәймиев белән әңгәмә)*

**Равил Фәйзуллин**. *«Быел фәлән җанвар елы, быел фәләннеке» дип йөртүләр борынгыдан гадәткә кергән. Соңгы дәвердә, иҗтимагый төсмер биреп, Аналар елы, Сәламәтлек елы, Балалар елы кебек әйтүләр дә булды. Галәми фикер йөртсәң, еллар алай «тамгаланып» кына бер-берсеннән әллә ни аерылмыйлар. Фасыллар табигый рәвештә яңарып, алышынып тора. Кеше туа, үсә, картая... Яңа буыннар килә... Вакыт дигәннәре бернәрсәгә исе китми ага да ага... Шулай да 2006 елның Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүе мине ихлас сөендерде. Димәк, быел әдәбият һәм сәнгатькә, гомумән, иҗатчыларга аерым бер игътибарлы караш булачак! Күпләребез шулай уйлый, уңай үзгәрешләргә өметләнә. Бу фәрман-указны ни өчен нәкъ менә шушы елга атап чыгарырга булдыгыз?*

**Минтимер Шәймиев.** Һәр яшәлгән ел – рух, иҗат һәм хезмәт елы, гомумкешелек хәзинәсенә өлеш кертү елы булырга тиештер ул. Цивилизацияне кеше акылы, кеше таланты казанышлары тәшкил итә ләбаса. Үткән тарихны без борынгылар калдырган гаҗәеп корылма-биналар, илаһи көйләр, бөек китаплар аша беләбез. «Кеше китә, җыры кала» диләр. «Гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып» дип язган Җәлил дә. Әнә шул Җыр дигән могҗизага яшәү мәгънәсе сыйгандыр, мөгаен.

«Еллар бер-береннән әллә ни аерылмыйлар» диюегез белән килешеп бетмим. Гомумән, һәркайсыбыз һәр киләсе елны үзенчә көтеп ала, һәр ел ниндидер вакыйгасы белән хәтергә уелып кала. Мәсәлән, 2000 елны үзенчәлекле ел түгел дип һич кенә дә әйтә алмыйбыз. Гасырларны гына түгел, меңьеллыкларны ялгаучы ел! Ата-бабаларыбыз, ата-аналарыбыз, күпмедер өлешендә без дә яшәгән бөтен бер гасырны тәмамлап, балаларыбыз, оныкларыбыз, аларның оныклары яшәячәк яңа гасырга һәм өченче меңьеллыкка аяк басу нәкъ менә безгә насыйп булды бит. Бу, әлбәттә, киләчәк хакында, кыласы гамәлләребез турында, тарихның шушы мизгелендә безгә зур җаваплылык салынуы турында уй-фикерләргә этәрә. Уйлы-гамьле кеше шуның белән яши дә инде. Менә 2005 елны алыйк: Казаныбызның 1000 еллык юбилей елын берничек тә гадәти ел дип булмый. 2005 елда без күпме язмышларга кагылган дәһшәтле Бөек Ватан сугышында миллионлаган кеше гомере бәрабәренә яуланган Җиңүнең 60 еллыгын да билгеләп үттек.

2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүнең дә үз хикмәте бар. Беренчедән, чыннан да быел республика тормышында зур юбилейлар күп: Габдулла Тукайның тууына 120 ел, Муса Җәлилнең тууына 100 ел, Татар театрына нигез салынуга 100 ел... Натан Рахлин, Сара Садыйкова, Александр Ключарёвларның 100 еллыклары. Фатыйх Әмирхан, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Габдулла Кариев, Хәлил Әбҗәлилов, Николай Фешин, Гали Ильясов кебек күренекле шәхесләребезнең юбилейлары. Нинель Юлтыева, София Гобәйдуллина өчен истәлекле ел бу. Сез мөхәррирлек иткән «Казан утлары» журналының меңенче саны чыгу... Әле болардан башка да истәлекле даталарыбыз күп. Әйтик, бу елны һичсүзсез Тукай елы дип атап булыр иде. Андый тәкъдимнәр дә булды. Әмма безнең Җәлилебез дә бар! Мондый бөек шәхесләребез булу – бәхетебез, алар рухи-мәдәни тормышыбызның алтын баганалары. Шуңа күрә мин 2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итик, дидем. Һәм барыбыз да җиңел сулап куйдык – бөтен истәлекле вакыйгаларыбызны берләштерә торган вариант табылды.

Икенче сәбәбе шул: инде әйткәнемчә, узган ел без башкалабыз Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иттек. Без үзебезне дөньяга дус, тату, иҗтиһат итүче халык итеп күрсәтә алдык. Беләсез, бәйрәмгә дәрәҗәле кунаклар: хәзерге бәйсез дәүләтләр, элеккеге союздаш республикалар башлыклары, илебез төбәкләре җитәкчеләре, чит ил вәкилләре килде. Алар Казанны күреп хәйран калып киттеләр. Алай гынамы, эшләнгән эшләребезгә без үзебез дә шаккаттык. Булдырабыз икән бит!

**Р.Ф.** *«Булдырабыз!» дип әйтү милли идеянең бер чагылышы инде ул.*

**М.Ш.** Әйе, рух ныклыгын күрсәтә ул. Без үз көчебезгә ышандык, бәйрәм көннәрендә барыбыз да горурлык хисе кичердек. Мин, әлбәттә, бервакытта да гел милли фикер генә юллап йөргән кеше түгел. Әмма Камал театрында куелган «Баскетболист» спектакле минем һич башымнан чыкмый. Хәтерлисездер, аның герое Сократ авыл җирендә, безгә «Уникс» командасын җиңәргә кирәк дип, авыл малайларын 167 сантиметрлы тактага салып үлчәп йөри, тәки җыя бит команда! Мондый команда белән җиңеп булмаслыгын аңлагач та күңелен төшерми, безгә опера йолдызлары булырга кирәк дип, авылдашларыннан хор оештыра. Безнең халыкның мөмкинлеге чикле булганда да хыялы бар, рухы бар. Ә тарихта, мәгълүм булганча, омтылышлы, рухлы халыклар гына эз калдыра. Казанның 1000 еллыгын уздырганда, без рухи күтәрелешкә ирештек һәм, менә шушы күтәрелешне саклап калган тәкъдирдә, безгә әдәбиятыбыз, сәнгатебез алдында торган мәсьәләләрне хәл итү җиңелрәк булыр кебек тоелды миңа. Сүз дә юк, икътисад үсәргә, төзелешләр дәвам итәргә, тормыш дәрәҗәсе күтәрелергә тиеш – болар безнең көндәлек эшебез. Дөресен генә әйткәндә, тормышта игътибарны рухи дөньядан читкә юнәлдерүче факторлар җитәрлек. Ә Казанның 1000 еллыгы исә безнең барыбызны да уртак рухи галәмгә җыйды. Һәм без алга таба да, үзебез дә сизмәстән, шушы галәмдә, иҗат атмосферасында яшәргә тиешбез. Моның өчен, әлеге уңай мизгелне кулдан ычкындырмыйча, кешеләрне рухи хәзинәләргә күбрәк җәлеп итәргә, моның яңадан-яңа формаларын уйлап табарга кирәк. Шөкер, безнең халыкта әдәбиятка, сәнгатькә омтылыш зур, аны үстерергә ярдәм итү – дәүләт җитәкчеләренең дә, мәдәният әһелләренең дә бурычы. Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүдә әнә шулар да күздә тотылды.

**Р.Ф.** *Мәгълүм хакыйкать: теге яки бу халыкны иң әүвәл аның бөек шәхесләре, үзегез әйткәнчә, «Җыр» калдыра алган илбашлары, галимнәре, әдәбият-сәнгать даһилары аша беләләр. Мисалны еракта эзлисе юк, соңгы дистә елларда Сезнең исем аша Татарстан дөньякүләм дәрәҗәдә шактый ук танылa алды... Шулай ук бу җәһәттән Тукай, Җәлил, Сәйдәш, Урманче исемнәре дә тонықланды дип уйламыйм. Сез әдәбият-сәнгать дөньясын, аның нечкәлекләрен белеп-тоеп яшәгән җитәкче буларак (сәяси-икътисад өлкәсендә генә түгел, сәнгать дөньясында да дөньякүләм дәрәҗәле исемнәр тикмәгә генә бирелмәгән!) яхшы беләсез: талант – табигать бүләге, һәм ул һәрчак аңлауга һәм яклауга мохтаҗ. Халык яклавына да, дәүләт яклавына да. Җәмгыять байларга һәм ярлыларга аерымланган бу заманда әдәбият-сәнгать әһелләренә яшәү җиңел түгел. Мәскәү күзенә карап торган милли республика шартларында бигрәк тә. Иҗатыңа җәмгыятьтә ихтыяҗ булмау, кылганың бәһаләнмәү – иҗат кешесе өчен иң кыены шул. Әгәр чын талант бәһаләнми икән, димәк, җәмгыять үзе бигүк төзек (бозык ук дип әйтәсем килми) түгел булып чыга түгелме соң?*

**М.Ш.** Иң элек шуны әйтеп китим: иҗат кешеләре, чыннан да, Аллаһ кешеләре. Аллаһ Тәгалә безне яхшы якка үзгәртер өчен, игелеклерәк, камилрәк итәр өчен аларны җибәрә. Бу дөньяда аларның үзләренә дә җиңел түгел һәм бүтәннәргә дә гел уңайлыклар гына тудырып тормыйлар. Төптәнрәк уйлап карасаң, халыкның вөҗданы инде алар. Ә вөҗданлыларга, бигрәк тә нечкә күңеллеләргә, беркайчан да җиңел булмаган. Тормышлары фаҗига белән тулы язмышлылар күпме! Шәрык тарихыннан да, Гареб тарихыннан да мисаллар җитәрлек. Ерак китәсе юк, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр да каберстан сакчысы вазифасында иҗат иткән түгелме соң? Үткән гасыр әдәбиятыбыз классиклары – шул ук Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәримнәрне искә төшерик: хәтта 40 яшькә дә җитә алмаганнар. Кайсына 27, кайсына 30... «Үлемнәре белән үлемсезлек яулаган» талант ияләре. Гомумән, минемчә, һәрбер зур талантның язмышында үз фаҗигасе бар. Шул ук Хәсән Туфан,

Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакыйларны алыйк... Ахыр килеп, иҗат итү өчен бар шартлар тудырылган сурәттә дә иҗат ул үзе үк газап, авыр хезмәт түгелмени?

Инде талантның бәһаләнү-бәһаләнмәү мәсьәләсенә килсәк, шунда ук сорау туа: ә кем бәһаләргә тиеш соң? Минемчә, бу үзе бер аерым тема. Әлбәттә, төп бәһаләүче – халык үзе. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләре халык өчен иҗат ителә, халыкны кызыксындыра. Халыкка киң таныла алу бәһаләнүгә керәме? Әгәр керсә, бездә үзенең һәм рәсми, һәм гаммәви бәһасен алган иҗат кешеләре байтак. Әдәбияттан һәм сәнгатьнең һәр өлкәсеннән исемнәр китерә алам. Алыйк әдәбиятны. Халык язучысы, халык шагыйре исеме алган әдипләр бәһаләнмиләр яки бәһаләнмәделәр дип әйтмәс идем. Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Ренат Харис... Сезнең үзегезне дә шул исемлеккә кертер идем. Алыйк театр дөньясын: Туфан Миңнуллин, Марсель Сәлимҗанов, Шәүкәт Биктимеров, Ренат Таҗетдинов... Рәссамнардан: Бакый Урманче, Харис Якупов, Әхсән Фәтхетдинов... Җыр өлкәсендә Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева, Әлфия Авзаловаларны әйткән дә юк, ә Азат Аббасов, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Идрис Газиевлар халык мәхәббәтен яуламадылармы? Алардан соң килгән Салават, Хәния Фәрхиләр дә бар.

Ә танылу өчен ни кирәк? Иң элек – талант, сүз дә юк, бу – хәлиткеч фактор. Аннан соң – иҗатының халыкка барып җитүе. Бу турыда ныклап уйлану зарур. Моның заманча гамәли ысуллары да табылырга тиеш. Хәер, Татарстанда танылу өчен мөмкинлекләр бар дип саныйм мин. «Йолдызлык» («Созвездие»), Илһам Шакиров исемендәге җыр конкурсы, «Җиде йолдыз», «Яңа татар пьесасы» бәйгеләре телемә килә. Заманасы кызык бит аның. Алыйк, мәсәлән, җырчыларны. Әлбәттә, элеккеге классик җырчыларыбызга һәм хәзерге эстрада җырчыларына карашыбыз төрлечә. Ләкин бүгенге эстрадада барысы да начар җырлый, тормышлары җиңел дип гадиләштерәсем килми. Иганәчеләр дә табылып тора, кызыклы гына башкаручылар да бар. «Казан егетләре» ансамблен карагыз, элеккеге җырларны яңача көйләп халыкка җиткерәләр бит. Хәзер бит ничек кенә теләсәң дә, яшьләрне, клубка җыеп, «Галиябану» көенә биетә алмыйсың. Тырышалар җырчылар, үзләрен таныталар, үз юлларын табалар. Алар тизрәк табалар, чөнки жанры шундый. Башка җанрларда танылу юлы озынрак булуы мөмкин. Әйтик, театр сәнгате. Яшь талантлар театр училищесын яки мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлыйлар, республикабыз театры сәхнәләреннән халык каршына килеп чыгалар. Күз алдыбызда таныла баралар. Мәсәлән, Камал театрында һәрвакытта да дәвамчылык яшәп килә. Буыннар алышына, яшь артистлар, Камал театрының югары таләпләренә туры килгән хәлдә, үз урыннарын табалар. Минемчә, таланты бар кеше конкуренцияне җиңә ала. Менә безнең опера җырчысы Михаил Казаков. Ул Димитровград шәһәреннән килеп консерваториядә укый башлаган иде. Глинка фестивалендә җиңеп, хәзер зур иҗат юлына чыкты, илебезнең Зур театрында эшли. Шул ук Чулпан Хамматованы алып карагыз. Нинди кискен конкуренция шартларында дөньякүләм дәрәҗәдәге актриса булып бара. Талант!

Аңлыйм, Сез хәзер бу бит дөнья, ил күләмендә, ә безнең татар язучыларына авыррак дип әйтәчәксез. Милли язучыларга, ничек кенә талантлы булмасыннар, элек тә җиңел булмады, хәзерге заманда яңа киртәләр барлыкка китерде. Милли әдәбият өчен нинди шартлар тудырырга? Бу – аерым проблема һәм без аның турында сөйләшергә тиешбез. Мин болай фикер йөртәм: безнең яхшы шигырьләребез, проза әсәрләре халыкка ни рәвешле барып җитәләр соң? Әйе, китапларның тиражлары кими. Бу – әлбәттә, дөньяви процесс, глобаль проблема. Мин ел саен китапларның, газета-журналларның тиражларын карап барам. Тиражлар кимү мәгълүмат артуга бәйле дип саныйм, ул гына да түгел, мәгълүматның башка, заманча чаралары барлыкка килде. Бу бер милләткә генә кагыла дип әйтмәс идем. Төп чара – чын әсәрне, эстетик кыйммәте һәм тәрбияви әһәмияте булган талантлы әсәрне (әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең бүтән өлкәләрендәге әсәрләрне дә күздә тотам) халыкка җиткерүнең отышлы, үтемле ысулларын табу. Беләм, әйтергә генә җиңел, эшләве авыр. Бу минем хәзер генә туган фикерем түгел, газета-журнал мөхәррирләре, радио-телевидение җитәкчеләре белән сөйләшкәндә гел әйтә киләм: табыгыз талантлы авторлар, җыегыз редколлегия һәм уйлашыгыз, дим. Мәсәлән, шигърият. Мин үзем шигырьләр яратам. Хәзерге заманда әдәби әсәрләр шулкадәр күп ки, барысын да укып бару мөмкин түгел. Ә шигырьгә кыска формада тирән фикер салына, ул үзенә җәлеп итеп тора. Миңа күп язучылар үз китапларын бүләк итәләр, күренеп тора: кызыклы китап, укыйсы килә. Әмма, ни үкенеч, вакыт җитми. Кеше

гомере шулкадәр кыска! Йөрәгем сыкрана, шундый яхшы әсәрләр бар, ә рәхәтләнеп укырга вакыт юк. Сүз уңаеннан, мин министр булып эшләгәндә, Югары Советта бер җаваплы хезмәттәшебез бар иде. Китаплар дефицит чакта ул бик күп китаплар җыйды. «Хәзер вакыт юк, пенсиягә чыккач укыйм мин аларны», – ди иде. Без дә аның аша китаплар алгалый идек. Шул рәвешчә бик күп классикларның том-том әсәрләрен тупладык. Ул пенсиягә чыккач, сорыйм: «Хәзер теге китапларны рәхәтләнеп укыйсыңдыр инде?» Ә ул: «Укып булмый шул, хәзер вакыт бар, әмма күз күрми», – ди. Заманында укып калмасаң, кире әйләнеп кайту кыен ул. Хәзер исә глобальләшү процессы бара, көн саен, сәгать саен мәгълүмат киңлегенә яңа әсәрләр килеп керә.

**Р.Ф.** *Кызык! Нечкә күңелле булуыгыз мәгълүм, ә шигырьләрне яратып укуыгыз турында бик үк белми идем. Капылт икеюллык искә килде. «Каргалар шигырь укыса, күгәрчен булыр иде!» «Карга» дигән сүзгә нindидер астыртын мәгънә салынган дип аңлашылмасын. Шулай туган ул икеюллык. Гомумән, шигырь укыган, шигырь яраткан кеше кадерле миңа. Шигырь кешене бәхетлерәк итә дип раслый алмыйм, әмма шигырь кеше күңелен нечкәртә, чистарта, табигый асылына кайтара... Әгәр шагыйрьнең шигырь язгандагы халәте укучының шигырьне укыгандагы күңел дулкынына тәңгәл килсә, шигырь сиңа фикердәш тә, җандаш та була ала...*

**М.Ш.** Әйе, сүзем шигырь турында иде бит әле... Мин әйтәм, әйдәгез телевидениедә, радио аша матур итеп, кеше күңеленә барып җитәрлек итеп шигырь укуны оештырыйк, дим. Автор үзе укысын йә булмаса артистларыбыз укысын, дим. Омтылып карыйбыз, башлыйбыз, тагын сүнеп китә бу эш. Без бит үзебез бар мөмкинлекләрдән дә файдалана, оештыра белмибез. Минем уйлавым буенча, татар шигырьләрен халыкка татарча гына түгел, русча да җиткерергә кирәк. Татарча ничек яңгырый ул, русча ничек? Акыллы кешенең башына керә ул. Мин үрнәк итеп «Культура» телеканалын китерә алам. Мин үзем, мәсәлән, дөньядан бераз онытылып торасым килсә, шушы каналны карыйм. Чүл уртасындагы оазис кебек ул, һәм бу фикергә күпләр кушыла. Тормышта һәркем үз өлкәсендә эшли, үз эшенә мавыгып яши. Аны әнә шул халәттән чыгарырга, игътибарын җәлеп итәргә кирәк. Хәтта мине – Президентны да үз эшеннән тартып чыгара торган булсын ул! Андый шигырьләр, тапшырулар, спектакльләр бар ул, димәк, моны эшләп була. Мәсәлән, 8 Март көнне «Яңа гасыр» телеканалыннан Туфан Миңнуллин әсәре буенча «Эзләдем, бәгърем, сине» спектаклен күрсәттеләр. Анда төп рольләрне Илсөяр һәм Рамил Төхфәтуллиннар башкарды. Өйгә, һәрвакыттагыча, эш кәгазьләре алып кайткан идем, аларны бер кырыйга этеп куеп, шуны карадым. Көпә-көндез, бөтен гаиләбез белән күз яшьләрен сөртә-сөртә карадык... Талантның халыкка тәэсире – зур көч! Мондый байлык бар ич бездә. «Мәскәү күзенә карап торабыз» дисез, биредә Мәскәү берничек тә комачаулый алмый. Бу мәсьәләдә тезгенне тарткан кеше юк. Чап та чап алга! Тик үзебез чаба алмыйбыз. Күп нәрсә үзебездән тора. Сезне гаепләү булып яңгырамасын, мин үзем дә бик борчылам бу хакта. Проза әсәрләрен җиткерүнең дә формаларын эзлисе бар.

**Р.Ф.** *Әйе, гел искечә генә язып булмый хәзер.*

**М.Ш.** Бүген бөтен дөньяда шулай: күләм – кыскалыкка, ә мәгънә тирәнлеккә омтыла. Мин Пауло Коэльо әсәрләрен укыйм. Алар бит зур түгел, әмма гаять үтемле, күңелеңне актарып чыгара. Әмирхан ага Еникине алыйк. Мәсәлән, «Кем җырлады?» хикәясе – искиткеч көчле хиссиятле әсәр. Эх, фильм төшерсәң иде, дим. Безнең андый әсәрләребез җитәрлек. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы дисеңме... Әйтик, Зөлфәт Хәкимнең «Телсез күке» әсәре. Мин аны укып та чыктым, спектаклен дә карадым. Ул бик тирән әсәр, аннан менә дигән фильм чыгар иде. Бүгенге көндә Татарстанның мондый формаларның матди ягын тәэмин итү мөмкинлеге бар. Теләк, омтылыш җитми безгә. Үзебезне күрсәтәсебез килә икән, без аны әнә шундый талантлы сәнгать әсәрләре аша эшли алабыз. Килешәм, бездән ярдәм кирәк, без андый чыгымнарга бара да алабыз. Ләкин аның киләчәккә эшли торган сизелерлек нәтиҗәсе дә булырга тиеш.

Сез дөрес әйтәсез, талант яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Без озак еллар социализм идеологиясе кысаларында яшәдек. Әмма мин ул чорга мәдәниятне, халыклар дуслыгын саклап калу ягыннан кире бәя бирмәс идем. Әлбәттә, башкача фикер йөртү, үзең тойганча иҗат итү

иреге юк иде. Кем әйтмешли, «үтерми дә, яшәтми дә» кебек булса да, иҗат кешеләре өчен, нигездә, ниндидер тотрыклылык бар иде дип саныйм. Ә менә үзгәртеп кору чоры, башка тормыш рәвешенә күчү чоры иҗат әһелләре өчен чыннан да бик авыр булды. Ул әле икътисад өлкәсе кешеләре өчен дә искиткеч кыен иде, чөнки без андыйга яраклашмаган. Чөнки барысы турында да хөкүмәт уйлаганга күнеккән. Аннан соң, үзгәртеп кору чорында, гомумән, иҗат әһелләре арткы планда кала. Кичә китап укый, спектакль карый, җыр тыңлый торган кеше бүген шул үзгәрешләр аркасында башка мәсьәләләрне кайгыртырга мәҗбүр. Икътисадның бөлгенлеккә төшүе, базар мөнәсәбәтләренә күчү иҗат кешеләренә бигрәк нык кагылды. Нәкъ менә шул чорда мин Бөгелмә шәһәрендә рәссамнар белән очраштым. Ачыктан-ачык сөйләштек. Алар әйттеләр: «Менә без, рәссамнар, үз икмәгебезне төрлебез төрлечә эшләп ала идек. Берәү үз картиналарын сата, берәү үзе өчен иҗат итә, ә кемдер иҗатына өстәп партия плакатлары эшләп тамак туйдыра иде... Хәзер ул система җимерелде, ә безгә ничек яшәргә?» Әлбәттә, аларның талант дәрәҗәсе төрлечә булгандыр. Әмма һәрбер очрак – кеше язмышы. Илнең астын өскә китергән үзгәрешләр килеп чыгуда аларның гаебе юк. Шунда минем башыма бер фикер килде: боларга ничек тә булышу ягын карарга кирәк, дим. Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният үсешенә ярдәм итү фонды әнә шулай барлыкка килде. Минем Президент буларак оештырган беренче һәм бердәнбер фондым шушы. Без иҗат кешеләренә дә, иҗади берлекләргә дә күпмедер күләмдә ярдәм итәбез. Бу чат саен сөйләп йөри торган гамәл түгел, әмма күпләргә булышып киләбез. Талантларның иҗатын бәяләүдә безнең тарафтан эш бармый дип әйтмәс идем. Бөтенесен дә санап тормастан, кайберләрен генә искә төшерик. Тукай премиясенең дәрәҗәсен күтәрдек. Җәлил премиясенең дә статусы зурайды. Республиканың иң югары бүләге – «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» дигән орден ияләре арасында да иҗат әһелләре әз түгел. Сүз дә юк, зур иҗатлары булган чын талант ияләренә төрле юлларын табып булышырга кирәк һәм шуны эшлибез дә. Бу уңайдан гонорарлар түләүне арттыруны күздә тотабыз, шулай ук сәләтле яшьләргә грантлар да булдырыла.

**Р.Ф.** *Әйе, үткән ел Казанның меңьеллыгын бөтендөнья күзе алдында зурлап үткәрү соңгы чор татар тарихында бөек вакыйга булды. Юкны күрсәтү мөмкин түгел, димәк, борынгы зур мирасыбыз бар. Шулай да эйфориягә дә бирелеп китәргә ярамыйдыр безгә. Югарыга менгән саен җилләр катырак булучан. Меңьеллык нигезен дип әйтикме, биеклеген диикме, ныгытасы да ныгытасы әле! Монда мин меңнең беренче биш йөз өлешен ныгытуны, ягъни шул чордагы рухи һәм матди мирасны өйрәнүне, дөньяга киңрәк танытуны күз алдымда тотып әйтәм. Башкалабыз юбилее уңае белән бик кирәкле уникаль басмалар чыкты: «Алтын Урда хәзинәләре», «Тартарика», «Сказание о Казани» һәм башка китап-альбомнар... Күптән түгел республикада «Мәдәни мирасны саклау буенча комплекслы программа» кабул ителде. Бәлки, әлеге программада тарихыбызның борынгырак өлешен киңрәк колачларга кирәк булгандыр... Меңьеллыклар турында сүз йөрткәндә, мәдәнилегебезне иң әүвәл язма әсәрләр, әдәби ядкарьләр дәлилли... Кыскасы, «ташларны җыяр чаклар» җитте. Бу очракта туры мәгънәдә, халыкча әйтсәк, хан заманындагы борынгы кабер ташларын да. Аларның байтагы Сезнең резинденциянең тәрәз төбендә бит...*

**М.Ш.** Узган ел ачылган «Хәзинә» милли сәнгать галереясы да, Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институты да минем резиденциядән ерак түгелләр. Аларның Сез әйткән милли язмалар, ядкарьләр, шул исәптән борынгы кабер ташлары белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләре бар дип беләм. Тарихыбызны барларга, мирасыбызны тупларга безгә беркем дә комачауламый. Эшлик! Җиң сызганып эшләргә җай вакыт килде. Ни дисәң дә, демократия ныгып барган җәмгыятьтә яшибез. Без үзебезне цивилизацияле дөньяга тиңдәш икәнлегебезне күрсәтә барабыз, хөр фикер йөртә башладык. Динебезне кайтардык. Димәк, тарихи бер үсеш этабын үттек. Әле кайчан гына шәһәр урамнарында татарча тартынып кына сөйләшәләр иде, сөйләшсәләр, шелтә-кисәтү ясаучылар да табыла иде... Хәзер андый хәл бетте бит.

**Р.Ф.** *Мәскәүдә, гадәттә, «милли» дигән сүзне рус милләтенә бәйләнештә генә кулланырга тырышалар. Гәрчә федераль дәүләттә милләтләр байтак булса да. Кызганыч, Россиядә тотрыклы милли сәясәт әлегә юк. Милли мәсьәләләр буенча махсус министрлык булмау да*

*шул хакта сөйли. Хәзер милли проектлар турында күп сөйлиләр. Әлеге проектлар башлыча авыл хуҗалыгына, сәламәтлек, мәгариф һәм торак төзелеше тармагына карый. Болары бик әйбәт. Әмма мәдәният турындагысы әлегә күренми. Татарстан кайбер юнәлешләрдә федераль башлангычлардан алданрак йөрүчән. Әдәбият һәм сәнгать елы дип Сез игълан иткән Указны безнең шартларда мәдәният өлкәсендәге өстенлекле проект дип санарга буламы?*

**М.Ш.** Һичшиксез. Мәдәният өлкәсендә без бервакытта да илкүләм фәрманнар көтеп тормадык, кулдан килгәнчә кайгырта килдек. Гомумән, игътибар итсәгез, игълан ителгән милли проектларның һәркайсы буенча республиканың эш тәҗрибәсе бар.

Инде милли сәясәт мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтәсем килә: без дәверләр дәвамында күпмилләтле илдә яшәдек һәм яшибез. Шуңа күрә Россиядә һәр халыкның икътисади, тарихи, мәдәни ихтыяҗларын кайгырта торган милли сәясәт һәм аны тормышка ашыра торган тулы хокуклы структуралар булырга тиеш. Мин бу хакта байтак еллар буе әйтеп киләм. Сүзләремнең дөреслеген тормыш үзе раслап тора. Франциядә милли җирлектә кабынган гаугалар тынып та җитмәде, дөньяда Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы ясалган карикатураларга бәйле ыгы-зыгы купты. Безнең илдә дә кешеләргә милләтенә карап һөҗүм итү очраклары булып тора. Шул сәбәпле Россиядә Милли сәясәт министрлыгы булдыру турында ешрак сөйли башладылар. Күптән түгел генә Россия Федерация Советы «Милли һәм конфессиональ сәясәт буенча берләшкән комиссия» төзү инициативасы белән чыкты. Бу мәсьәләләрне хәл итү сәгате сукты дип уйлыйм. Күрәсез, илнең иминлеге икътисад үсешеннән генә тормый. Европаның алга киткән илләрендә дә бу яктан барысы да ал да гөл түгел. Милләтләрне хөрмәт итүгә корылган илдә генә бәрәкәт була ала.

**Р.Ф.** *Әдәбият һәм сәнгатьне үстерергә телибез икән, табигый ки, телне сакларга, үстерергә кирәк. Сәнгатьнең күп төрләре сүз сәнгате белән бәйле: әдәбияты да, театры да, музыка-эстрадасы да... Ахыр чиктә тел – халыкның, милләтнең җаны. Халык язучысы Нурихан Фәттах болай дип язып калдырды: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә...»*

*Туган телебез язмышы өчен, әлеге язучыбыз кебек, без дә кирәк кадәр яна-көрәшәбез микән? Шул исәптән республика җитәкчеләре дә?*

**М.Ш.** Яну-көрәшүгә килгәндә, без үзгәртеп кору елларында татар телен аякка бастыру, саклап калу өчен аз эшләмәдек. Совет чорында Казанда бары тик бер генә татар мәктәбе калганын да онытмаска кирәк. Телләр турында закон кабул ителде, татар теле дәүләт телләренең берсе дип игълан ителде, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында татар теле укыту, татар мәктәпләре ачу мәсьәләсендә хөкүмәт тарафыннан ни кирәк – барысы да эшләнде.

**Р.Ф.** *Әйе, уңай үзгәрешләр күп. Аларны танымау сукырлык булыр иде. Чыннан да, 90 нчы елларда телебез күзгә күренеп тернәкләнә-үсә башлады. Кухнядан чыгып, урам-мәйданнарда, трамвай-поездларда, гомумән, җәмәгать урыннарында кыюрак яңгыраш алды. Парламент утырышларында татарча сөйли башладылар. Моннан кырык еллар элек «Минем телем» дигән шигырь язган идем. Анда «минем телем... конгресслар, парламентлар ачып йөрми» дигән юллар бар. Хәзер аңлыйм, ялгышканмын. Минем телемдә дә, шөкер, парламент, конгресс утырышлары да ачыла хәзер. Сирәк хәл: бу ялгышлыгым миңа борчу китермәде, әйткәнемнең киресе килеп чыгуы сөендерде генә. Шулай да реалист булыйк, соңгы елларда бу өлкәдә артка таба чигенеш башланды кебек. Сүземнең очы, табигый, мәктәпкә, мәгариф системасына барып тоташа. Сан ягыннан карасаң, татар мәктәпләре, гимназияләре дә, аларда укучылар да күп кебек. Ләкин соңгы вакытта аларда татарлык кимеп, шактые, асылда, рус мәктәбенә әйләнеп бара шикелле. Шәһәрләрдә, бигрәк тә Казанда, «ата-аналар теләге белән» дигән теге заманнар формулировкасы янә эшкә җигелә башлады. Татарча укытуга астыртын саботаж ясаучы мәгариф әһелләре дә юк түгел дип беләм. Күпме көч һәм вакыт сарыф итеп, җан тырмашып, бөртекләп ачылган татар мәктәпләрен җуя*

*башладык. Милли мәгариф бетсә, татар әдәбияты, татар сәнгатенең ни хәлдә каласы мәгълүм...*

**М.Ш.** Сез артка чигенеш дисез, ә мин бу хәлне башкача бәялим. Юк, артка китмибез, соңгы вакытта без авыр йөк тарткан ат кебек алга барудан кинәт кенә туктап калдык. Чөнки ирешкәннәрне ныгытып алга бару кыенрак булып чыкты. Махсус сыйныфлар оештырдык, тәрбиячеләргә, укытучыларга өстәмә хезмәт хакы билгеләдек, мәктәпләр ачтык, махсус укыту программалары эшләдек – болар берсе дә юкка чыкмады лабаса. Укыту процессында татар телен саклап калуга аяк чала торган мәсьәләләр бар икән, әйтегез, тәкъдим кертегез, боларын да хәл итәрбез. Тел язмышы турында сез дә, без дә дөрес борчылабыз. Әмма ул борчылу гаеплене эзләүгә кайтып калмасын иде. Әйе, Мәскәүгә, Татарстан хөкүмәтенә сылтарга була. Бу турыда сүз чыкканда мин Финляндиядә яшәүче татарларны искә төшерәм. Саклаганнар бит телне! Алынма сүзләр кыстырмыйча, чип-чиста итеп татарча сөйләшәләр. Чит җир, милли мохит юк дәрәҗәсендә, сан ягыннан әллә ни күп түгелләр, дәүләти мәктәпләре юк, туган тел белән карьера ясап булмый... Ә тел исән! Гыйбрәт алыйк без шуннан. Без һаман кемнедер гаеплибез, тик үзебезне түгел. Әйләнә-тирәбезне барлап, күрше-күләнне, хезмәттәшләрне, дус-ишләрне, туган-тумачаларны искә төшерик тә уйлап карыйк: кемнәрнеңдер балалары туган телләрен белми икән, моңа бүтәннәрне гаепләргәме? Һәрбер татар үзеннән башласын иде, үзе эшләгән, яшәгән урынында үз телен саклап калу өчен нәрсә эшли ала? Бу – халыкның үзаңы дәрәҗәсен күрсәтә торган фактор. Һич югы, үз гаиләсендә татарча сөйләшәме? Бу сорауларга хәзергә беркемнең дә төгәл җавабы юк, шул исәптән минем дә. Димәк, бергә-бергә эзләргә кала.

**Р.Ф.** *Сез, шәхсән үзегез, туган телне олылауга зур өлеш керттегез. Чыгышларыгызны тыңлап, көнләшеп тә куям: телнең бөтен нечкәлекләрен, тылсымын, мәгънәви көчен һәм моңын белеп сөйлисез. Шулай булырга тиеш тә. Үз телен камил белмәгән кеше Илбашы була ала димени! Сезгә карап, республикадагы эреле-ваклы байтак җитәкчеләр туган телгә мөнәсәбәтләрен үзгәрттеләр, хәтта кайберләре ана телендә ярыйсы гына сөйләшә дә башлады. Ләкин андыйлар күп түгел. Дәүләт Советы утырышларында да (рәсми очрашулар, хуҗалык киңәшмәләрен инде әйткән дә юк!) күбесе дәүләт теле саналган ана телендә чыгыш ясамый. Ә бит аларның байтагы чыкылдап торган татар авылы малайлары... Соңгы вакытта исә төрле дәрәҗәдәге җитәкчелеккә туган Тел һәм Моң төшенчәсен аңламаган яшьләр килә... Әйткәнегезчә, татар теле дөньяның абруйлы телләре исәбенә керә. Россия Президенты Путин да татарча сөйләп күрсәтте бит инде югыйсә! Ярый әле парламентта әлеге дә баягы әдәбият һәм сәнгать вәкилләре – язучылар бар, юкса анда кайбер милли мәсьәләләр бөтенләй күтәрелмәгән дә булыр иде... Бу җәһәттән Сез туган телнең киләчәген ничек күзаллыйсыз? Әйтик, кырык-илле елдан?*

**М.Ш.** Минемчә, бүгенге кыенлыкларга карамастан, телне саклап калу һәм үстерү өчен социаль шартлар өлгереп килә. Бу, гомумән, дөньякүләм процесс бит. Татар теленә генә түгел, күпмедер дәрәҗәдә рус теленә дә һәм башка телләргә дә куркыныч яный. Без озак вакыт аерым бер идеологиягә буйсындырылган җәмгыятьтә яшәдек, дөресен әйтик, рухи кыйммәтләр турында уйларга җаебыз юк иде безнең. Ә хәзер барыбыз да сизәбез: рухи кыйммәтләр алгы планга чыга башлады. Моны кешеләрнең дингә омтылышы көчәю дә ачык күрсәтә. Шөкер, без иманыбызга кайту юлында. Әлбәттә, тел мәсьәләсе авыррак. Моның чишелеше рухи кыйммәтләр яссылыгында ята. Ана телен белү горурлыкка, үз-үзеңне бәяләүнең, шәхес булуыңның бер билгесенә әйләнергә тиеш. Ана телен саклап калу балаларым, нәселем, милләтем алдындагы бурычым дип санаган кешегә бернинди чит тәэсирләр дә куркыныч түгел. Аның милли үзаң дәрәҗәсе югары дигән сүз. Кызганыч, бүген бу турыда уйлаучы аз. Мин татарлар үз телен белергә теләми дигән фикер белән килешмәс идем. Мәсәлән, кайсы республикага гына барма, татар кешеләре очрап тора. Хәтта чит илләрнең сәяси даирәләрендә дә бар алар. Күбесе үз шөгылендә шактый уңышларга ирешкән. Алар минем янга махсус килеп күрешәләр, татарча сөйләшә алмауларыннан уңайсызланалар. Димәк, җаннарында татарлык сүнмәгән. Казанның 1000 еллыгын үткәреп, без күпме милләттәшебездә йокымсырап яткан горурлык хисләрен уяттык. Бу – безнең зур

казанышыбыз. Мин моны Шәймиев Президент булган чорга туры килгән өчен генә әйтмим. Аллага шөкер, дөньябыз шулайга китте. Безгә шушы тарихи моментны тотып алып, һич сузмыйча кешенең аңына сеңдереп калырга кирәк. Татарларның үз туган җиренә, үз тамырларына бәйләнеше – каннарында, димәк, ул күпмедер дәрәҗәдә балаларына да күчә. Әлеге моментны ычкындырсак, туган телнең киләчәге шикле булырга мөмкин. Әйдәгез, уйлашыйк, моны ничек эшләргә? Бу – бик нечкә мәсьәлә, биредә зирәк, талантлы иҗатчыларыбыз сүзе кирәк, шунсыз булмый. Кешенең күңел кылларына кагыла белү тылсымы сезгә бирелгән дип уйлыйм.

Татар теле төрки телләр семьялыгыннан, бу телләрдә күп кенә илнең халыклары сөйләшә, алар күп милләтләрнең туган телләре. Шуңа күрә бу мәсьәләдә безгә барлык төрки дөнья белән бергә эш итү дә кирәк дип саныйм. Гасырлар буена һәр тел күпмедер дәрәҗәдә үзгәрә, ә менә телләр төркемен саклап калу – глобальләшү чорында безнең уртак бурычыбыз.

**Р.Ф.** *Ил тормышында күңелне борчый торган нәрсәләр шактый. Шулар арасыннан безгә, язучыларга, турыдан-туры кагылганнарының берсе – әдәбиятны укучылар, гомумән, укучылар саны кимүе, матбугатыбызның таралу сферасы кысылуы, милли зыялылар катлавының юкара баруы борчый мине. Һәр иҗатчы, табигый, йөрәгеннән чыкканның күбрәк кешеләргә ирешүен тели. Әсәр чыннан да эстетик һәм тәрбияви әһәмияткә ия икән, ул җәмгыятьтә үзенең лаеклы урынын алырга тиеш. Фикеремне җөпләр өчен үзем эшләгән «Казан утлары» мисалын гына китерәм. Әле генә аның меңенче саны чыкты. Зур сан, зур вакыйга. Горурланып әйтәм: Россиядә мондый санга ирешкән бүтән әдәби журнал юк. Редакциягә җибәргән котлавыгызда үзегез дә шуны танып, журнал эшчәнлегенә югары бәя бирдегез. Рәхмәт. Менә шул журнал, күпләр әйткәнчә, бик тә кирәкле басма, халыкта тиешенчә таралмый. Аны бөтенләй алдырмаган мәктәпләр, уку йортлары, мәдәният учреждениеләре, китапханәләр бар. Төрле ведомостволар турында әйткән дә юк инде. Сүз безнең журнал турында гына бармый; мәсәлән, заманында 500 меңләп данәдә чыккан «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») хәзер 13 мең чамасы, элек 300 меңгә якын укучысы булган «Ватаным Татарстан»ның – 20 меңләп әбүнәчесе бар. Сез, бәлки, әйтерсез, заманы шундый, бүтән халыкларда да шул хәл, диярсез. Алай дисәң, үзебезнең Татарстанда бер төбәктә бер төрле нәтиҗә, икенче җирдә бөтенләй бүтәнчә (бу хәл халык саны һәм милли составы бер чама районнарда). Кайбер районнарда китап кибетләре эшләп килә, кайберләрендә бөтенләй юк. Хикмәт, күрәсең, җирле хакимиятләрнең эшчәнлегенә, аңлавына, аерым кешеләрнең интеллектына, җаваплылыгына да бик нык бәйледер... Бәлки, җирле җитәкчеләрдән икътисади сан-процентлардан тыш, рух дөньясына караган күрсәткечләрне дә таләп итәргәдер? Булдырырдай нәрсәләр күп бит. Мәсәлән, районнарда ел саен төрле слетлар, уңыш бәйрәмнәре уздырыла. Анда алдынгыларга бүләкләр бирәләр: аракылар салынган пакеттан башлап машиналарга кадәр. Бу форсаттан хезмәтчәннәргә затлы китаплар, еллык подпискалар да кушып бүләкләргә була бит. Мәгънәсе, сәвабы булыр иде. Безнең түрәләр кушканны үтәргә күнеккән. Алар бит, иң ким дигәндә, берничә дистә ел Сезнең күзегезгә карап тордылар...*

**М.Ш.** Татар телендәге газета-журналларны таратуның яңа юлларын уйлап табу – уртак эшебез. Хәзерге заманда кешене теге яки бу журналга көчләп яздырып булмый. Һичшиксез, балалар матбугаты аерым игътибар үзәгендә булачак. Сез «Казан утлары»н мисалга китердегез. Чыннан да, ул журнал белән таныш булмаган укытучы бүгенге татар әдәбиятын ничек итеп сыйфатлы итеп укыта алсын икән? Әдәбият укытучыларына һөнәри дәрәҗә биргәндә, болар һәммәсе дә искә алынырга, таләп ителергә тиештер, бәлки? Шул ук вакытта, әсәрләр үзләре дә заман таләпләренә җавап бирерлек, әйткәнемчә, мәгълүмат ташкынында үзенә җәлеп итәрлек булсын иде. Көнүзәк проблемаларны күтәргән заманча әсәрләребез күп дип мактана алмыйбыз әлегә. Әйдәгез, тәкъдимнәр кертегез, әйтегез, нинди ярдәм кирәк? Мәсәлән, бүгенге көндә иҗат интеллигенциясеннән бу турыда нинди дер фикер ишеткәнем юк әле минем. Татарча журналларны методик әдәбият белән беррәттән укытучыларга, мәдәният хезмәткәрләренә таратырга кирәк икән – бусы безнең кулдан килерлек эш. Мәктәп китапханәләренә, гомумән, республиканың барлык китапханәләренә яздыру да хәл итәлә алмый торган мәсьәлә түгел. Газета-журналларны тарату мәсьәләсенең хәзерге заманда зур

игътибарга лаек башка ягы бар. Без республика мәктәпләрен 100 процент компьютерлаштырдык. Хәзер Интернетка көчеп барабыз. Бүгенге көндә һәрбер матбага үзенең сайтын булдыра. Мәсәлән, «Казан утлары» сайтын дөньяның теләсә кайсы почмагында ачып, анда басылган әсәрләрне уку мөмкинлеген тудыру өчен күп акча кирәкми. Әлеге дә баягы тел саклау мәсьәләсенә дә кагыла бу. Әгәр безнең тел Интернетта булмый икән, без дөнья мәгълүматы киңлегеннән төшеп калабыз. Күп очракта искечә фикер йөртү комачаулый безгә, без замана чараларыннан файдалана белмибез. Безнең матбугат татарлар яшәгән илләргә, мәсәлән, Үзбәкстанга, Казакъстанга барып җитми, дибез. Хәзер төргәк-төргәк газета-журналны поезд яки самолет белән ташу заманы узып бара. Интернетны тулысынча эшкә җигәргә кирәк. Белгечләр белән бергә җыелып сөйләшергә кирәк бу хакта. Ачыйк бер әдәби сайт, куйыйк шунда язучыларыбыз әсәрләрен, җырларны, шигырьләрне, тарихи язмаларны... Матди ягын үзебез карарбыз. Бу юнәлештә хәрәкәтләнергә кирәк дип уйлыйм мин. Хәрәкәттә – бәрәкәт.

**Р.Ф.** *Әдәбият һәм сәнгать турында әңгәмәләшкәндә, телевидение һәм радио һич кенә дә читтә кала алмый. Рухи хәзинәбез үрнәкләрен халыкка җиткерүдә аларның роле бәяләп бетергесез зур. Әмма әлеге гаммәви мәгълүмат чаралары бик үзгәрде хәзер, өстәвенә хуҗалары да күбәйде. Аларда, минемчә, дәүләти программа буенча эшләү җитенкерәми. Һәр иртәдә үз тапшыруларын республикабыз гимны белән башлый торган бердәнбер «Татарстан» радиосының да бүгенге көндә элегрәк халык көтеп ала торган, сәгатьләр буена рәхәтләнеп тыңлаган радиопостановкалар, спектакльләр яңгырату мөмкинлеге юк... Ә дистәләрчә (!) коммерция радиоларында бик күп эфир вакыты югары сәнгатьтән бик ерак җыр-көйгә (һәм шуңа иш җыр башкаручыларга), ике алып баручының тузга язмаганны сөйләп, телефоннан юк-бар сорауларга җавап биреп утыруына, дөресрәге, халтурага сарыф ителә... Масса культурасы цунами шикелле ишелеп килә! Телевидениебезнең «Татарстан» каналында исә дәүләт теле саналган татар телендә көндәлек хәбәрләр, яңалыклар да ишетә алган юк...*

**М.Ш.** Радио мәсьәләсенә килсәк, аның заманнар үзгәрү белән әһәмияте кимемәде, аның киләчәге зур. Чөнки кешенең нидер укырга, карарга вакыты җитми, ә радионы ул машинада барганда да, өй тирәсендә йөргәндә дә, ашау пешергәндә дә тыңлый ала. Әйе, соңгы вакытта радиостудияләр артты. Әлбәттә, бу өлкәдә конкуренция зур. Шуңа күрә үз тыңлаучыңа барып җитүнең үтемлерәк чараларын уйлап табу зарур, элеккечә эшләп булмый – бусы көн кебек ачык. Нинди генә радио булмасын, дәүләтнекеме ул, үз хуҗасы бармы аның – татар радиоларында тапшыруларның сыйфаты турында уйларга кирәк, Сез дөрес әйтәсез. Эфир вакытын милләт мәнфәгатьләрендә, булдыра алганча отышлы итеп файдалану ягын карарга кирәк. Әйтик, татарча сөйләүче коммерциячел радиоларның да хуҗалары татар балалары лабаса. Татарлар үзара сөйләшеп уртак фикергә килә алмаслар микәнни? Әйе, Сезнең белән килешәм, кайчак машинада барганда тыңлыйм, кабатлаулар, мәгънәсез сүзләр шактый. Алар бит моны үзләре дә яхшы белә: әдәби, сәнгати мәгълүмат җитми. Тәүлек буенча эшләүче радиолар бар. Барысы белән дә санлашып, бергә җыелып гәпләшсәгез, аларга матур итеп мәгънәле, зәвыклы, кызыклы тәкъдимнәр кертсәгез, минемчә, алар моны рәхәтләнеп кабул итәчәкләр. Гонорар да түләячәкләр әле үзегезгә. Әлбәттә, без бу мәсьәләдән читләшергә җыенмыйбыз, уртак эшебез булыр. Грантлар, гонорарлар – хәл итеп була торган мәсьәләләр.

**Р.Ф.** *Безнең буын – китап укып үскән буын, «Китап – белем чишмәсе» шигарендә тәрбияләнгән буын. Яшәвем белән үткән гасыр кешесе буларак, һаман да китаптан алган белем тирәнрәк була дигән фикер белән яшим. Шулай ук радио-телевидение дә безгә чит түгел.*

**М.Ш.** Чит кенә түгел, якын да булырга тиеш. Заманга каршы барып булмый. Бу яктан «Яңа гасыр» спутник телевидениесе булдыруыбыз дөрес адым булды. Без моны үз вакытында, чыгымнарның зур булуына кармастан, тып-тын гына эшләп куйдык. Кычкырып йөрүнең кирәге дә юк, юкса комачаулыклар килеп чыгар иде, бәлки. «Яңа гасыр» телевидениесе булмаса, без бүгенге көндә ничек яшәр идек? Күз алдына да китереп булмый. Беләсез, Россия

төбәкләре үз тапшырулары белән тәүлеккә нибары сәгать ярым гына эфирга чыга алалар. Яңалыклар да, мәдәни, икътисади тапшырулар да шул сәгать ярым вакытка сыярга тиешләр. Ә без күне буе татарча спектакль карап утырабыз. «Татарстан» телерадиокомпаниясенең мөмкинлекләре чикле икән, «Яңа гасыр» компаниясен күбрәк эшкә җигәргә кирәк. Чөнки максатлары уртак. «Яңа гасыр» телеканалы дөньяның бөтен татарын экран каршына җыя ала бит. Узган ел бөек җырчыбыз Илһам Шакировның юбилей кичәсен бөтен дөньяга трансляцияләдек. Ә Казанның 1000 еллыгы бәйрәмен телевидение аша чит җирләрдә яшәгән милләттәшләребезнең күбесе карады. «Үзебезне Казанда йөргән кебек хис иттек», – дип, рәхмәт хатлары яздылар. ТНВ тәлинкәләре әкренләп ил буйлап, дөнья буйлап тарала бара. Әлбәттә, хәзер милли телевидениене саклап калу өчен күп эшләргә кирәк. Башка каналлар белән конкуренция көчле. «Яңа гасыр» каналын тәнкыйтьләү җиңел ул. Әмма аның эшен яхшырту максатында иҗат әһелләре тарафыннан фикер, тәкъдимнәр кертеләме соң?

Менә Айдар Фәйзрахманов «Яңа гасыр» каналында «Җырлыйк әле!» тапшыруын оештырып җибәрде. Үзем дә карыйм, һәрвакыт җаен табарга тырышам. Каян гына чакырып китерми кешеләрне! Сәләте булып та, мәйданга чыга алмаган талантлы кешеләрне халык арасыннан табып, экранга чыгару да яхшы бит. Бөтен кеше профессионал язучы, җырчы булып китә алмый, һәркемнең үз язмышы. Бер генә булса да чыгып алу да ярый, аны кешеләр күрә, шул исәптән туган-тумачасы, балалары күрә, үрнәк ала... Авылга да бик тирән үтеп керде телевидение. Бервакыт туган якка кайткан идем, апам миңа әйтә: «Татарча телесериалның вакытын үзгәртеп булмый микән?» – ди. Шул сериалны карап, сыер саварга соңга калалар икән. Менә бит ничек тәэсир итеп була! Миңа калса, иҗат әһелләре, бигрәк тә милли иҗат вәкилләре телевидениедә җитәрлек дәрәҗәдә актив катнашмый әле. Ни өчен үз татар сериаллары барлыкка килми – кем гаепле соң бу очракта, кем комачаулый? Эш үзебездә бит...

**Р.Ф.** *Шөкер, рухи мирасыбыз биниһая зур. Сүз-көйгә бәйләнешлеләре дә, агач-ташта калганнары да... Минемчә, төп бурычларыбызның берсе – аларны хуҗаларча саклау һәм дөньяга таныту, ягъни пропагандалау. Бу җәһәттән соңгы ун-унбиш елда игелекле байтак гамәлләр башкарылды. Тарих институтын ачу, энциклопедияләр чыгару, Кремльдә музей комплексы булдыру... Милли мәдәни үзәкнең чын мәгънәсендә мәдәни-мәгърифәт учагына әверелүе... Мисалларны тагын китерергә мөмкин. Ләкин күптән төзекләндерергә яки торгызылырга тиеш булган тарихи истәлекле, җанга якын урыннар бар. Әйтик, Тукай язмышы белән бәйле «Болгар» номерлары, заманында Г.Исхакый, С.Максудилар укыган Учительская школа бинасы, 70 елдан артык газета-журналларыбыз, Язучылар берлеге штабы булган мәшһүр Матбугат йорты... Кайсы хәрабә хәлендә, кайсы хуҗасыз йорт кебек, каралмаган... Шуларга өстәп Китап палатасының мөшкел хәле турында да әйтеп үтәргә кирәк. 80 ел буе республикабызда чыккан бөтен матбугат басмаларын туплаган, тәртипкә китергән, библиографик күрсәткечләрен төзегән шушы мөхтәрәм оешманың үзләре җыйнаган хәзинәне, ягъни китапларны, газета-журналларны тиешле рәвештә саклау урыннары да юк. Бәяләп бетермәслек шул байлыкның ташландык хәлендә булуы бик аянычь, әлбәттә. Мирасыбызда булган кулъязма, китап байлыклары өчен әрмәннәрдәге шикелле Матенадаран төзергә күптән вакыт, минемчә.*

**М.Ш.** Моннан бер ун ел элек Казанның нинди хәлдә булуын әле хәтерлисездер. Ә бүген ул бөтенләй башка сурәткә керде. Шушы еллар эчендә без күп эшләдек дип уйлыйм. Сез санап киткән биналар безгә билгеле. Дөресен әйтим, без борчылып сөйләшкән тел, мирас, уку-укыту мәсьәләләрен хәл итүгә караганда, аларны төзекләндерү җиңелрәк. Моңа безнең хәлебез җитә, без боларга тотынырбыз да эшләп тә чыгарбыз, иншалла.

**Р.Ф.** *Тарихта үсеш спираль рәвешле бара, диләр. Хәлләребезне моннан бер гасыр элеккеге вазгыять белән чагыштырсаң, байтак охшашлыклар күреп була. Халыкның киләчәктәге язмышы, бигрәк тә рухи үсеше мәсьәләләре, хәзерге кебек үк катлаулы булган. Әмма шунысы факт: патша хөкүмәтеннән берниди ярдәм алмаган заманда да безнең халыкның шактый камил мәгариф системасы, күпкырлы матбугаты, көчле әдәбияты булган, театрлары барлыкка килгән. Россия күләмендә алганда, татар теленең асыл нигезе, тамырлары*

*бүгенгегә караганда ныграк булган. Бу өскорманың нигезен нәрсә тәшкил иткән соң? Халык үзе. Җаваплылык тоеп, киләчәген халык үзе кайгырткан. Әлбәттә, беренче чиратта халыкның матди һәм рухи байлыкка ия булган катламы кайгырткан. Шул чорның байлары мәчет-мәдрәсәләр төзеткән, нәшрият-басмаханәләр ачкан, талант ияләренә ярдәм күрсәтеп, мәдәният үсешен тәэмин иткән. Шул заманның атаклы меценатлары – Хөсәенов, Рәмиев, Юнысов, Кәримов, Апанаев, Яушевлар кебекләрнең исемнәрен атау да күп нәрсә аңлата. Рустагы Третьяков, Мамонтов, Стахеевлар кебек, татар дөньясында якты эз калдырган шәхесләр алар. Казанда, Уфада яки Оренбургта булсын, алар салып калдырган, заманында мәгърифәт учаклары булган корылмалар, биналар әле дә исәннәр. Бүгенге көндә әдәбият һәм сәнгатьнең һәр өлкәсендә ирешелгән зур казанышларны таныган хәлдә, рухи дөньябыз барыбер матди ныгуга мохтаҗ. XX гасыр башында милли мәдәният үсешендәге проблемалар бер яссылыкта булса, XXI гасыр башында да шул ук мәсьәләләр, асылда, кала бирә, масштаблары һәм мәгънәләре генә үзгәрәк. Яхшы беләсез, мәдәният сферасын бюджеттан тәэмин итү «калдык принцибы» белән бара. Шуңа күрә мондый финанслау ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. Хәлне яхшыртырга хәзер дә мөмкинлекләр бар, минемчә. Элеккеге уңай традицияләрне яңартырга кирәк. Соңгы дистә елларда бездә дә зур байлыкларга ия төркемнәр барлыкка килде. Сез аларны безгә караганда яхшырак беләсез, кайберләрен татар халкының XX гасырдагы мәшһүр кешеләре дип тә билгеләп үттегез. Әдәбият һәм сәнгатебезне үстерүдә беркадәр алар ярдәменә өмет итә алабыз микән?*

**М.Ш.** Чыннан да, һәр халык үз киләчәген үзе кайгыртырга тиеш. Бу аның бердәмлек дәрәҗәсенә, милли үзаңына һәм матди куәтенә бәйле. Базар мөнәсәбәтләренә күчүгә карамастан, хөкүмәт милли мәдәниятне, телне саклап калу мәсьәләләреннән читләшмәячәк. Әле ныклап тотынырга исәп. Бездә булдыклы, ярдәм итәрдәй татар кешеләре, зур предприятие җитәкчеләре, иң мөһиме – татар җанлы кешеләр күп. Бусы да очраклы хәл түгел. Чөнки 90 нчы елларда үткәрелгән хосусыйлаштыру чорында без мораторий игълан иттек, һәм читтән кул сузучылар безнең байлыкка хуҗа була алмады. Республикадагы мөлкәт татарстанлылар кулында калды. Бу Татарстанның алга таба үсеше өчен төп нигез булды. Казанның 1000 еллыгын үткәргәндә дә байтак химаячеләр юмартлык күрсәттеләр. Безне еш кына спортка зур игътибар биргән өчен тәнкыйтьлиләр. Шунысын әйтим: спортка бюджет акчасы китми, республикада спортны безнең татар егетләре тоталар, спорт биналарын да алар төзи. Соңгы елларда Татарстан үзенең яңа спорт корылмалары белән танылды. Премьер-лига командалары уенын, дөнья масштабындагы кубоклар ярышын Казанның кайчан күргәне бар иде әле? Дөнья күләменә әнә шулай чыгалар. Әйтик, шул ук эстрада җырчыларына, талантлы балаларга да ярдәм итүчеләр бар. Ләкин хәзергә татар эшкуарлары күңеленә тулысынча ачкыч табылганы юк шикелле. Биредә дә җаен белеп эшләргә кирәк, әйдә акча бир дип кенә түгел. Кеше бу гамәлгә үз теләге белән, үз җаны кушканга килергә тиеш. Менә Сезгә бер тәкъдим: җыелыйк бергә – язучылар, җырчылар, рәссамнар, иҗат кешеләре, зур предприятие җитәкчеләре, эшкуарлар... һәм сөйләшик. Клуб оештырыйк, аңа матур исем табыйк. Бәлки, Язучылар берлеге каршында оештыру кулай булыр. Гомумән, безнең бу әңгәмә кайтавазы, Сез әйткәнчә, замана байларына да ишетелер дип уйлыйм. Алар да уйлансын. Александр Македонский үләр алдыннан кулларын күтәреп учларын күрсәткән, ди, имеш: «Ярты дөньяның хуҗасы булсам да, күрегез, гүргә бернәрсә дә алып китә алмыйм».

**Р.Ф.** *Сез Галиәсгар Камал театры премьераларында еш буласыз. Опера һәм балет театрында куелган музыкаль спектакльләрне дә шулай хуш күрәсезме? Бу мәсьәләдә үз фикеремне дә белдереп узыйм әле. Татар операсы, татар балеты күз алдында юкка чыгып, үлеп бара. Сәбәпләрен төрлечә аңлаталар: татарга опера кирәкми, ул аның рухына ят нәрсә; бездә югары кимәлдәге музыкаль әсәрләр иҗат итүчеләр юк; тиешле әзерлекле татар җырчылары җитешми һ.б. Ә бит сәнгатьнең бу төре заманында театрда нульдән башлап диярлек бар ителгән. Җырчылар, биючеләрне Мәскәүдә махсус укытып, иҗат коллективлары оештырылган, дәүләт заказы белән милли әсәрләр иҗат ителгән.*

**М.Ш.** Безнең халыкта опера сәнгатенә, югары музыкага тартылыш көчле. Бусы бәхәссез. Зур концертлар залына да, Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына да халык йөри. Бу

– үзе бер куаныч. Үзебезне цивилизацияле халык дип санывбыз икән, башкача була да алмый. Безнең халыкның интеллект дәрәҗәсе дә, әлеге сәнгать вәкилләренә таләпләре дә югары. Безгә килгән артистлар үзләре үк шулай диләр. Минем бу хакта Ирина Архипова, Мария Биешу, Алибек Днишев, дирижерлар Валерий Гергиев, Фуат Мансуров кебек опера һәм югары музыка осталары белән фикер алышканым бар. Кешенең интеллект дәрәҗәсе үскән саен, аның музыкага омтылышы арта.

Татар операсы, татар балеты ни хәлдә? Аңа йөрерләрме? Әзерлекле тамашачыбыз бар икән, югары кимәлдәге әсәрләр тудыра алабыз икән, һичшиксез йөриячәкләр. Дөнья сәнгатендә опералар күп түгел, гасырлар буе бер үк опералар яки балетлар кабат-кабат куелалар, һәр яңа буын аларны үзенчә күрә. Сәнгати югарылыктагы опера-балет иҗат итү җиңел түгел. Күреп торабыз, дөнья музыка сәнгатендә яңалары да барлыкка килә, әмма күбесе төшеп кала. Ә классик опералар алар, чыннан да, бөтен халыклар өчен үрнәк булып торалар. Безнең дә электән үк иҗат ителгән әсәрләребез бар: «Алтынчәч», «Башмагым», «Шүрәле» һәм тагын берничә әсәр. Алар – вакыт сынавын узып, тамашачы мәхәббәтен яулаган әсәрләр. Минемчә, безгә дә шуларны кабат-кабат куярга кирәк. «Шүрәле»нең яңа куелышын карарга килмәсләр дип уйлыйсызмы? Киләчәкләр. Соңгы вакытта куелган яңа балет «Кыйссаи Йосыф»ка да халык бик кызыксынып йөрде. Тамашачы операга җырчыларның тавышын бәяләргә килә. Мәсәлән, классик операларны күбебез яттан диярлек беләбез, әмма без мәгълүм арияләрнең яңа яңгырашын ишетергә телибез, бүгенге җырчыларның башкару осталыгыннан ләззәт алырга дип барабыз. Операда тел мөһим түгел, операда тавыш хакимлек итә. Классик операларны да һәркем үз телендә җырлый бит.

**Р.Ф.** *Н.Җиһанов, Н.Даутовлар исән чакта, ягъни егерме-утыз еллар элек бу өлкәдә күтәрелеш бар иде. Хәзер? Театр, республика мәнфәгатьләреннән бигрәк, читтәге тамашачылар өчен күбрәк хезмәт итә. Җыелма труппа төзеп, төрле шәһәрләрдән яхшы тавышлы җырчыларны алалар да чыгып китәләр чит илләргә...*

**М.Ш.** Мин бу фикер белән килешә алмыйм. Егерме-утыз ел элек без чикләнгән дөньяда яши идек. Безнең үз җырчыларыбызны башкалар белән чагыштыру мөмкинлеге юк иде. Ул елларда Татар опера һәм балет театры чит илләргә гастрольләргә чыга ала идемени? Әйе, искиткеч җырчыларыбыз бар иде, алар арасында дөнья күләменә чыга алмыйча калган олы талант ияләре дә юк түгел. Әмма без башка җырчыларны күрмәдек, ул заманнарда телевидение дә киң таралмаган иде әле. Минем берәүне дә үпкәләтәсем килми, тик хәзер без дөнья киңлегенә чыктык, Лучано Паваротины, Пласидо Домингоны, Монтсеррат Кабальены ишеттек. Башкаларны күрдек, үзебезне дә күрсәттек. Бу нисбәттән Зөлфәт Хәким әсәрләрен искә төшерәсем килә. Зөлфәт, һич курыкмыйча, үз-үзебезне ачы итеп тәнкыйтьли ул. Кыргызларны тәнкыйтьләп, камчылап тәрбияләгән язучы Абай кебек. Әлбәттә, без тәнкыйтьне күп очракта күтәрә белмибез, үпкәлибез. Ләкин дөреслеккә күзебезне ачып карарга тиешбез. Европалардан йөреп кайткач, безнең башкаручылар үз-үзләренә бәһане бирделәр. Күрдек, аңладык, бар бездә лаеклы җырчылар, биючеләр, әмма барысына да үзебезнең генә көч җитми икән. Моны да танырга кирәк. Мин татар халкының үз театры эченә бикләнеп, кемнедер хурлап, кемнедер мактап яши торган халыкка әйләнүен теләмәс идем. Әйе, Татарстанда без беренче, ә читкә чыгып карасак? Бу башка өлкәләргә дә, икътисадка да кагыла. Дөнья ачык бүген – булдыра аласың икән, чык, эшлә. Булмый икән – тырыш, чарасын күр. Безнең Опера һәм балет театры ул – 800 ләп кеше, аны саклап калырга да, дөньяга күрсәтергә дә кирәк иде. Европа бездән башка яши ала ул, ә без Европадан башка? Федор Шаляпин исемендәге опера, Рудольф Нуриев исемендәге классик балет халыкара фестивальләре, «Европа-Азия» халыкара заманча музыка фестивале бездә – Казанда уза бит! Әйе, хәзергә барысы да үзебезнең көч белән генә эшләнми. Һичшиксез, милли опера һәм балет та кирәк. Ә иң мөһиме, безгә дөнья дәрәҗәсендәге үз җырчыларыбыз күбрәк кирәк. Хәзергә бездә көчле башкаручылар аз. Михаил Казаков турында әйтеп киттем, хәзер татар егете Владимир Васильев күтәрелеп килә. Мәскәүдә Гнесиннар училищесында бер төркем яшьләребез укый, алар арасында өметле башкаручыларыбыз бар. Эш бара, иң мөһиме, хәзер без үз казаныбызда гына кайнамыйбыз, иҗатның чикләре юк.

**Р.Ф.** *Әңгәмәбез ахырына якынлашканда Сезгә әйтәсе килгән тагын бер уй-фикер. Бөтен дөньяга таралган татарлар Казанны үзләренең рухи башкаласы дип таный, Татарстан Илбашын үзенеке саный, аның кылган игелекле гамәлләрен ихлас яклый, омтылышларына теләктәшлек белдерә. Аларны Татарстандагы авыл хуҗалыгы яки сәнәгать өлкәсендәге күрсәткечләрдән бигрәк, беренче чиратта, халкыбызның рухи өлкәдәге казанышлары кызыксындыра. Интеллектуаль дөньяда горурлык байрагы булырлык шәхесләр – әдәбият-сәнгать, фән-гыйлем каһарманнары кирәк аларга. Уйландыра: тагын ун, егерме, утыз елдан татар әдәбиятына кемнәр килер? Каян? Кемнәр сәхнә тотар, музыка иҗат итәр? Бу яктан хәлебез бик үк мактанырлык түгел. Татарча укып, татарлыкны сеңдереп үсүчеләр даирәсе кысыла бара. Россия төбәкләреннән яңа Такташлар, Җәлилләр, Кәрим Тинчуриннар, Рәшит Ваһаповлар, Җәүдәт Фәйзиләр килүгә исәп тоту читен. Татарстанда да вазгыять үзгәрде, яңа Гомәр Бәшировлар, Сибгат Хәкимнәр, Илһам Шакировлар бик күренеп тормый. Аяз Гыйләҗев әйтмешли, өмет белән өретелгән яшьле күзләр аша киләчәккә – яшьләргә карап торабыз. Минемчә, хәзер яшьләрне җитди, дәвамлы иҗатка җәлеп итәр өчен бик тә абруйлы гамәлләр кирәк. Бу, әлбәттә, һәммәбезгә карый. Әмма бүгенге көндә Сезгә күбрәк карый. Ни өчен икәне аңлашыла. Сезнеңчә алар нинди гамәлләр була ала икән?*

**М.Ш.** Безне ничек кенә тәнкыйтьләмәсеннәр, татар яшьләре арасыннан иҗат шәхесләре, зыялылар әзерләү, аларга ярдәм итү юнәлешендә берни дә эшләнми дип әйтү урынсыз булыр иде. Менә Татар дәүләт гуманитар университетын булдырдык. Аның педагогика университеты нигезендә оештырылуы да дөрес дип уйлыйм, чөнки тарихы, тәҗрибәле укытучылар, галимнәр коллективы бар. Без гыйлем юлына капканы ачып, төзеп куйдык, мөмкинлекләр тудырдык. Ә хәзер киңәшик, ничек эшлибез, яшь егет һәм кызлардан нинди иҗат төркемнәре туплыйбыз, бездән тагын нинди ярдәм кирәк? Без бу юнәлештә хезмәттәшлеккә әзер. Казанда консерватория, Мәдәният һәм сәнгать университеты һәм башка мәдәният уку йортлары эшли. Димәк, нигезебез бар безнең. Хәзер эш уңганлыгыбыздан, кулга-кул тотышып эшли алуыбыздан тора.

Президент әйткәнне көтеп тормыйча эшләнә торган нәрсәләр дә бар бит ул. Мәсәлән, Театр әһелләре берлеген карагыз. Әле ишетеп торам, кышкы салкынга карап тормаганнар, Шаһсәнәм Әсфәндиярованың каберенә чәчәкләр салырга барганнар. Башка иҗади берлекләр өчен күркәм үрнәк. Чөнки Хәтер һәм Дәвамчылык янәшә йөри. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрын инде телгә алып киткән идем. Аларның төп принципларыннан берсе – дәвамчылык. Безнең күз алдыбызда: Хәлил Әбҗәлилев, Хөсәен Уразиков, Фатыйма Ильскаялар буынын Празат Исәнбәт, Асия Галиева, Шаһсәнәм Әсфәндияровалар буыны алыштырды. Соңрак Щепкинчылар: Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакировлар... Алар белән бергә диярлек Наилә Гәрәева, Наил Әюпов. Алардан соң театр Рамил Төхфәтуллиннар буынын тәрбияләде, хәзер инде алардан да яшьрәк Искәндәр Хәйруллиннар буыны сәхнә тота. Менә шуңа күрә 100 ел яши дә ул безнең театр, иманым камил, әле 200 ел да, алга таба да яшәр. Шуңа күрә дә аларның киләчәге ышанычлы.

Игътибар иткәнсездер, әңгәмә барышында мин берничә тапкыр бергәләп эшлик, фикерләшик, уйлашыйк, дип әйттем. Моны үзенә тиешле эштән баш тарта дип аңламагыз. Минем мәдәнияткә, сәнгатькә мөнәсәбәтем барыгызга да мәгълүм. Әңгәмәдән күренгәнчә, фикерләребез уртак. Ахыр килеп, без һәммәбез үз урыныбызда иҗат итәбез түгелме соң? Эшкә ныклап керешер өчен безгә ниндидер импульс җитми, мөгаен. Әйдәгез, безнең шушы әңгәмә киләчәк гамәлләргә этәргеч булсын! Әмма ул журнал битләрендә генә калмасын иде. Бу әңгәмәдән соң иҗат әһелләрендә, гомумән, әдәбиятка, сәнгатькә битараф булмаган кешеләрдә күп фикер-тәкъдимнәр туар дип уйлыйм. Минем янга җыелып, ул фикерләрне уртага салып сөйләшергә кирәк безгә. Минем тарафтан Сез көткән абруйлы гамәлләрнең берсе шул булсын!

**Р.Ф.** *Сезнең сүзләрдән соң моннан утыз еллар элек язган шигырь юллары хәтергә килде. «Кирәк безгә!» дип атала ул. Кайбер юллары безнең әңгәмәнең рухына туры килә шикелле.*

*Тәкъдир шундый: бик аздан да*
*Олы шатлык*

*таба алырга,*
*сөенергә кирәк безгә.*

*Олимп уты ягар чакта,*
*сүнеп барган учагыңа*
*тын өрергә кирәк безгә.*

*Заманга иш булыйм дисәң,*
*Кем бер янса –*
*ун яшьнәргә,*
*ун янарга кирәк безгә.*

*Тормыш дигән халыкара Сабантуйда*
*батыр булып*
*калалырга кирәк безгә!*

*Илбашлары белән еш очрашып булмый. Һәркемнең үз эше, үз миссиясе. Мондый әңгәмәләр үткәрүдә тәҗрибәм аз. Шуңа күрә сорауларым да озынрак, киңәшләшү-уйлану рәвешендәрәк булып чыкты. Шунысына сөенәм: күңелдәгесен әйтеп, ихлас сөйләштек. Ышаныч артты. Үзегез әйтмешли, фикерләребез уртак. Димәк, Әдәбият һәм сәнгать елы да дәвамлы булачак, алга таба да һәр яңа ел иҗатчыларга ихтирам һәм игътибар еллары булачак. Шулай булырга тиеш тә! Әгәр кеше рухи яктан бай, көчле икән, андый зат тормышта да үз урынын тизрәк таба, дәртләнеп хезмәт тә итә, бәхетле дә була. Без шуның өчен яшибез түгелме соң? Рәхмәт Сезгә!*

**М.Ш.** Сезнең шигырьне болай дәвам итәр идем:

Ниятләгән зур эшләрне
Булдырырга кирәк безгә!

Үзегезгә зур рәхмәт. Күптән күңелемдә йөргән уй-фикерләремне дөньяга чыгардыгыз. Барчабызга исәнлек-саулык телим. Иҗат уңышлары юлдаш булсын!

*2006*

## *СЫНАЛАБЫЗ — СЫНМЫЙБЫЗ*

*(Татарстан Республикасы мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов белән әңгәмәләр)*

**Равил Фәйзуллин.** *Хөрмәтле Ислам әфәнде!*
*Сезнең министр булып эшләвегезгә дә инде биш ел икән. Бу еллар илләр тарихында, халыклар язмышында, хәтта аерым шәхесләр өчен дә гаять гыйбрәтле, истәлекле – бер яктан, рух өчен демократик иркенлекләр ачылса, икенче яктан, икътисад өлкәсендә, катаклизмга якын хәл-вазгыятьләр туды. Сез шушы чор эчендә, үз вазифагызны үтәү елларында халык өчен, басма китаплар, газета-журналлар өчен һәм дә аларны иҗат итүче язучылар, журналистлар, каләм ияләре өчен нинди уңай үзгәрешләр кертүгә ирештегез дип саныйсыз?*

**Ислам Әхмәтҗанов.** Эшкә тотынган көннәрдә матбугат өлкәсендә азау яраган күптәнге танышым «Һай, братук, акчаның дәрманы көн дә кысылган болгавыр заманда гәҗит-журналларың ябылып бетеп, япа-ялгызың ярык тагарак алдында утырып калмассыңмы?» кебегрәк сорау дип әйтимме инде, киңәш дипме, юллаган иде. Ачыклап китү максатында 1992 елда республикада 127 гәҗит-журнал нәшер ителүен дә әйтим. Бүген замананың ай-ваена, вакытлы мәшәкатьләренә илтифат итмичә, 377 басма, сайлаган кыйбласына тугрылыклы калып, халыкка үз сүзен, хак сүзен җиткерүдә хәлдән килгәнчә тырышып эшли. Хәбәрдарлыкның, демократик җәмгыятькә таба йөз тотуыбызның бер бизәге түгелмени бу? Кайдадыр матбугатны тезләндерергә, гаярь, туры сүзле журналистларны эзәрлекләргә тартынмаган бер заманда (андый мисаллар күп, хәтерегезгә генә төшерегез) Татарстанда ай саен диярлек яңа басмалар «борын төртә». Яңгыравык сүз рәвешендә кабул итә күрмәгез: сүз ирекен, матбугат ирекен соңгы елларның зур казанышы дип бәяләр идем. Моның бөтен асылын-мәгънәсен аңлау максатында яшьләр өчен «Идел» журналын чыгару теләге белән

Мәскәүдәге күн белән тышланган дәү ишек бусагаларын егерме еллап таптарга туры килгәнлеген, өстәге цензорларның күңеленә хуш килмәү сәбәпле, күпме кыю әсәрләрнең кәрҗингә ташлануын, күпме каләм әһеленең йөрәген тотып мендәргә авуын искә төшерергә кирәк.

Моны эшләдек, тегене булдырдык дип сөйләү, дөресрәге, лаф ору, ихластыр, табигатемә каршы. Куелган сорауларның берсе дә җавапсыз калмас, әңгәмә барышында һәркайсын бәйнә-бәйнә тикшерербез, әлегә, рәхим итеп, сорауның чираттагысына күчик.

***Р.Ф.*** *Матбугат ирегенүзегез ничегрәк аңлыйсыз?*

**И.Ә.** Матбугат ирегең, сүз ирегең, хәбәрдарлыкны соңгы елларның, демократик җәмгыятькә күчү елларының иң зур казанышы дип әйтә алам. Икътисадта хәл ителергә тиешле булып та, хәл ителмәгән мәсьәләләр, чишеләсе төеннәр аз түгел. Сәясәттә дә кул кушырып утырырга вакыт юк – өлгергән мәсьәләләр байтак. Ә менә матбугат ирегең, сүз ирегең, теләгән фикереңне курыкмыйча әйтү ирегең һәркайсыбыз тоеп, укып, ишетеп, шуның шаһиты булып яши. Матбугат ирегә һәм Россия, һәм Татарстан Конституцияләре тарафыннан гарантияләнә. Үзегез шаһит: безнең күптәннән инде «менә бу язманы басыгыз, тегесен төшереп калдырыгыз» ише фәрман-боерыклар белән мавыкканыбыз юк. Теге яки бу басма уңаеннан өстәл төюләр, «партбилет белән куркытулар» да бетте. Дөрес, редакцияләр белән без даими элемтәдә. Әлбәттә, ниндидер тәкъдимнәр, юл күрсәтү очраклары, «менә бу мәсьәлә республика өчен мөһимрәк» кебек киңәш тотулар булмый тормый. Әгәр дә теге яки бу язма белән килешмибез икән, безнең бик көчле коралыбыз бар; хокукый дәүләт шартларында ул төп чара булачак – судка мөрәҗәгать итү. Әйтик, кемнеңдер шәхесен кимсеткән, йә булмаса милләтләр арасындагы дуслык-туганлыкка чөй кагарга тырышкан, канкоешка яки конституцион хакимиятне бәреп төшерергә чакырган язмалар була икән, без, һичшиксез, чаралар күрергә тиешбез.

Матбугат ирегә һәм җаваплылык хисе журналист өчен аерылгысыз принцип булырга тиеш. Тиеш, әмма булып бетми. Карагыз безнең кайбер басмаларны. Беренче битеннән алып дүртенче битенә кадәр үтереш, кыйнау, көчләү, ягъни бүгенге болгавыр заманның гел кара, җитешмәгән яклары... Менә бу берьяклылык күңелне әрнетә. Әгәр дә иртәгә «Казанский телеграф» яисә «Крис» ише гәҗитләрдә «Татнефть» берләшмәсендә егерме бишенче миллион тонна «кара алтын» суыртылды» (димәк, нефтьчеләр тотрыклы эшли, димәк, бюджетның керем өлеше үтәләчәгенә өмет арта) яисә «Балтач районы хуҗалыкларында эш хакын түләүдә тоткарлыклар юк» (димәк, авыл кешесенә дә акчаны үз вакытында биреп барып була икән!) кебегрәк хәбәрләр басылып чыкса, ихластыр, аларның әбүнәчеләре, баш мөхәррирне алыштырмаганнардыр бит, дип, гаҗәпләнүдән иңбашларын сикертәчәкләр. Чөнки аларның кыйблалары башка – бармактан суырып язу, дөньяга «кара күзлек» аша карау... Дөрес, бүгенге тормышта проблемалар бар. Алар элек тә булган, киләчәктә дә булачак. Тормыш проблемаларсыз булалмый. Ләкин тормышның якты яклары да бар бит. Сүз ул – бик зур, бик көчле корал. Әйтер сүзеңне даруга да, агуга да манып әйтергә, сүз белән кешеләрне берләштерергә һәм сүз белән үк бәрелештерергә дә мөмкин. «Шаккатризм» чире татар телендә нәшер ителә торган кайбер басмаларга да хас. Юкны бар дип ышандырырга теләүчеләрнең гомере озын булмый. Ник дигәндә, бүгенге заманда кеше төгәл һәм туры сүзгә, хакыйкатькә мохтаҗ.

Укучының, бу иптәш тәнкыйть язмаларын өнәп җиткерми, күрәсең, дип уйлап куюы ихтимал. Дөрес түгел. Тәнкыйть кирәкле шәйдер, дип шагыйрь белеп әйткән. Тик ул нигезле, кире каккысыз дәлилләргә нигезләнгән тәнкыйть булсын.

Аннары, форсаттан файдаланып, шуны да әйтәсем килә: безнең басмалар чамадан тыш сәясәт белән мавыгалар. Социологик тикшеренүләр шуны күрсәтте: гәҗитләребез 30–40 процент мәйданнарын сәяси язмаларга бирә. Ә дөнья стандарты бер – 10–12 процент. Дөресен әйтик, халыкны сәясәт туйдырды. Халыкны тынычландыра торган, аның рухи дөньясын баета, базар шартларына яраклашырга өйрәтә торган язмалар күбрәк кирәк безгә. Тагын шуңа да игътибар итәсе килә: безнең матбугатта сәясәт берьяклырак яктыртыла. Сәяси, экономик проблемаларыбызны күтәрәбез, җитешсезлекләрне нык камчылыйбыз. Әмма шул төеннәрне чишү юлларын күрсәтмибез, эзләмибез...

**Р.Ф.** *Хәләл акчаңны түләп язылган журналның үз вакытында килеп җитмәвен матбугат ирегенә селтәнү рәвешендә кабул итәргә кирәктер?!*

**И.Ә.** Кайбер журнал-гәҗит редакцияләре – сүз Мәскәү басмалары хакында барганлыгын искәртим – әбүнәчеләрдән акча җыеп алалар да, ни хикмәт, алар хакында «оныталар». Янәсе, саллы сәбәпләр теге яки бу басманы үз вакытында, бүтәнчәләтеп әйтсәк, айныкын айга бастырып барырга һәм таратырга мөмкинлек бирми. Әлеге әңгәмәне әзерләгәндә, агымдагы елның апрель уртасына «Искусство кино», «Фотомагазин», «Трамвай», «Костер» ише журналларның бер генә саны да чыкмаганлыгы мәгълүм иде. Ике еллап «Театр» журналының бер санын да күрмәдек. ИТАР-ТАСС ике-өч көн элек аның яңадан чыга башлавын хәбәр итте. Бездә соңарып чыгу очраклары бөтенләй юк түгел, әмма ул бер-ике атнадан узмый. Дөрес, «Казан» журналының күпкәрәк соңарган чаклары да булды. Моның сәбәпләрен ачыклап, министрлыкта басманың баш мөхәррире белән җилле генә сөйләшеп тә алдык. Киләчәктә «озын тәнәфес»ләр булмас дип уйлыйм.

Инде сорауга әйләнеп кайтыйк. Әйе, мондый очракны үз укучыңны санга сукмау, алай гына да түгел, аларны алдау, төп башына утырту дип кабул итәргә кирәк.

**Р.Ф.** *Сез элеккерәк бер чыгышыгызда ике йөзләп яңа нәшрият ачылды дигән идегез. Әйтегезче, шуларның күпмесе татар телендә? Тиражлары? Кәгазь-күләмнәре буенча?..*

**И.Ә.** Итагатьлек саклап туктап калдыгыз шикелле. Дәвам итегез, яңа ачылган, буын нығытып килгән яисә күплелеге белән сез шапырынган нәшриятларның кайсысы газиз халкыбыз файдасына эшли соң, диегез. Кулга тотардай китаплары бармы дип тә сорый аласыз.

Нинди генә яссылыкта карасак та, яңа нәшриятлар ачылуны заманның уңай бер төсмере дип карыйм. Бездә теркәлгән 176 нәшриятның байтагында татар китаплары басыла. «Заман», «Иман», «Таң-Заря», «КамАЗ», «Татар китабы», «Мирас», «Идел», «Абак», «Шура», «Раннур», «Фест», «ГЖИ», «Дело», «Еникеева нәшрияты», «Хәтер китабы», «Фән»... Исемлекне тагын да дәвам иттерергә мөмкин. Хуш, исемнәре матур икән, ә менә узган ел, аннан алдагысында ниләр бастырдылар соң алар дип сорыйсызмы? Санап үтелгәннәрдән «Абак» нәшрияты, мисалга, теләсә нинди халыкара күргәзмәдә куелырлык һәм дә шикләнмичә әйтәм, саллы бүләк алырлык «Әлмәт җырлый» дигән җырлар китабы бастырып чыгарды. Унбиш мең тираж белән! Йә булмаса тәүге адымнарын ясый башлаган «Татар китабы» нәшриятының Мөхәммәт Мәһдиев турындагы истәлекләрдән һәм дә әдип әсәрләреннән торган «Кеше китә – җыры кала» җыентыгын (тиражы – 10 мең), Фәнис Яруллинның «Мирас» нәшриятында дөнья күргән өч томлы әсәрләрен алыйк. Әлеге китаплар рухи тормышыбыздагы олы бер вакыйга рәвешендә кабул ителергә тиеш иде һәм, шөкер, ул шулай кабул ителде дә!

Шулай итеп, узган елда Татарстандагы нәшриятларда (ә алар хәзер читтә дә бар, әйтик, Мәскәүдә, Төмәндә, Уфада) татар телендә 241 китап дөнья күрде. Күпме бу, азмы? Чагыштырып карау өчен: 1988 елда – 186, 1989 елда – 184, 1990 елда – 208, 1991 елда 127 исемдә татар китабы басылган. Димәк ки, бәрәкәтле хәрәкәтнең, бәйсез нәшриятларның мәйданга чыгып хәл җыя башлауларының шаһитлары без! Тиздән, бик тиздән аларның энциклопедик басмалар, балалар антологиясе, күренекле әдипләрнең сайланма әсәрләре, сүзлек-белешмәләр, күз явын алырдай альбомнар чыгару кебек бик җитди эшкә алыначакларына иманым камил.

Сүзең барда сөйләп кал дигәндәй, тагын бер нәрсәгә тукталмыйча булмас. Соңгы вакытларда абруйлы җыелыш-киңәшмәләрдә «китап басу сүнә, корый», «киләчәктә китапсыз калмагаек» ише аһ оруларны еш ишетергә туры килгәли. Берәүне дә сәбәпсез чаң кага, дип гаепләргә җыенмыйм. Әмма хакыйкать хакына бер-ике мисалга тукталу кирәк булыр. Чыгыш ясаучыларның кайберләре өлге рәвешендә 1990 елны атый. Ягъни рухи азыгыбыз – китап галиҗәнапларының төп «казаны» саналган Татарстан китап нәшрияты 1990 елда җәмгысы 259 исемдәге китап чыгарса, узган ел ул нибары 103 кә генә калган. Бәхәсләшергә җыенмыйм, бу өлеше дөрес. Тик бармакларны бөгә-бөгә менә нәрсәләрне игътибарга алыйк әле. Иң әүвәл 259 санының үз эченә нәшрият чыгарган дәреслекләрне дә «йотуын», әйтик, («Мәгариф» милли нәшрияты 1992 елда гына оешты). Димәк ки, алдарак аталган 103 кә «Мәгариф» җимешләрен

дә – ә алар узган ел 83 булды – өстәү шарт. Чамалыйсыздыр, барыбер «бил алышуы» авыр – ничек кенә әйләндереп карасаң да минус, артка китеш – 259 һәм 186!.. Чынлап та, ур-ра кычкырырлык, лаф орырлык бернәрсә дә юк икән бит. Шулай да ашыкмыйк. Татарстан китап нәшриятының 1990 елдагы тематик планын кулга алып, саный башлыйк. Чү, Ленин, партия, ярыш, остазлык, интенсификация, алдынгы тәҗрибә, «әйтер сүзем бар»... Авыл агаен ничек яшәргә өйрәткән китаплар дисеңме, партия вожакларының «акыллы сүз-киңәшләре» дисеңме... Менә кайберләре: В.Ленин «Кооперация турында», С.Чикин «Дмитрий Ульянов», М.Миролюбов «Где у коровы молоко», Коллектив «Без – үзгәртеп коручылар», Р.Алюшев «Водосборные сооружения земляных плотин», Р.Хәйретдинов «Рождение Советской Татарии»... Шушыларга охшаш утызлап китап санадым. Күпме көрпә, күпме кибәк, күпме буш, дөресрәге, ялган сүз! Теге минуслы арифметиканы болай да борып була бит. Тегеләйме-болаймы, бүген берәвебезнең дә мондый китапларга юлыкканы юк. Хуплыйк һәм сөеник шуңа!

**Р.Ф.** *Китап кибетләренә кергәч, безнең дәүләт нәшриятларында чыккан китапларга карагач, татар китабының карап торышка ук төс-кыяфәте, ягъни полиграфик эшләнеше шактый ук зәгыйфь икәнлеген күрәсең. Бу аннан башка да аерым рекламага мохтаҗ татар китабының «тез астына» нык суга. Бу хәлне төзәтү юнәлешендә дәүләт берәр төрле чара күрергә җыенамы?*

**И.Ә.** Әлеге тешле сорауны бер-ике ел элегрәк юллаган булсагыз, белмим, нindiрәк җавап кайтарыр идек. Былтырлы-быеллы дөнья күргән китапларның күбесенең төс-кыяфәтенә, бизәлешенә тел-теш тидереп булмый. Яшермим, сыйфат мәсьәләсе байтак вакытлар җанны бәләкләде. Төссезлеге, кулга алсаң таралырга торуы аркасында күпме китап «үтмәс товар» рәвешендә кибет шүрлегендә тузан җыеп ятты икән?! Ниһаять, хөкүмәт ишеген шакый, кулга каләм алып исбатлый-раслый торгач, гәҗит-журналлар нәшриятына Алманиянең «Зиглох» фирмасыннан 3,5 миллион долларлык (сумнарга әйләндерсәк, егерме миллиардлап була ул!) китап басу линиясе сатып алынды. Танылган фирма, техникасы камил, төгәл, ничә айлар эшләсә дә, чыгымчылап караганы юк. «Зиглох» машиналары сыйфат мәсьәләсендә революция-борылыш ясады дисәм, хакыйкатькә хилафлык китермәмен. «Татарстан Республикасының Кызыл китабы»н, Татарстан китап нәшрияты әзерләгән «Президент Минтимер Шәймиев», «Һәлакәт» (Вакыйф Нуруллин), «Кояш баер алдыннан» (Әмирхан Еники). «Ишан оныгы» (Атилла Расих), Илһам Шакировка багышланган «Илһам», «Фаҗига» (Рәмзи Вәлиев), шулай ук Сезнең «Кыска шигырьләр» кебек китаплар инде дөнья стандартлары кимәленнән бер дә ким түгел.

Үткән ел Министрлар Кабинеты 1997–2001 елларда республика полиграфиясен һәм китап басу эшен яңа баскычка күтәрү хакындагы максатчан программа кабул итте. Шактый озак әзерләнгән һәм шактый вакыт үз сәгате сукканны көтеп яткан программа ул. Бәһасе аның 279(!) миллиард сумга тигез. Программа нигезендә китап баса торган икенче төп базаны – Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатын – яңа машиналар белән җиһазлау да, дәүләт нәшриятларын компьютерлаштыру да каралган.

**Р.Ф.** *Без үскәндә гөрләп торган китап кибетләре хәзер сүнүгә таба бара. Аларның күбесе ябылды да инде. Дөрес, кайбер кибетләр почмагында китап сату бүлекләре күренгәли. Бу күренеш, безнеңчә, китапның халык күңелендә югала-тоныклана баруын раслый. Татар китабын югалту – милләтебезнең рухын-җанын да югалту дигән сүз. Бу хакта да Сезнең фикерне ишетәсе иде.*

**И.Ә.** Һәрбер язучының өч җан газабы бар, диләр. Беренчесе – иҗат газабы. Төн йокыларын качырган, көннәр буе тынгы бирмәгән, кайчагында иҗат кешесенең холкын бозган газап. Ләззәтле газап. Азау ярган язучы яхшы белә: бу газап әле чын газап түгел. Иң авыры – әсәреңне язып бетергәч, аны бастырып чыгаруга бәйле мәшәкатьләр. Язган, инде басылган китабыңны халыкка җиткерү, укыйлармы дигән шиккә җавап эзләү – газапның өченчесе.

Базар капкасын ачып кергәндә, төрле гаҗәп нәрсәләргә юлыгабыз. Табышсыз мал сылтавы белән кайчандыр гөрләп эшләп торган байтак китап кибетләренә йозак салыну – шундый гаҗәпләрнең берсе дияр идем. Базар мөнәсәбәтләренә күчкәнче китап сәүдәсе ике юнәлештә:

«Татпотребсоюз»га караган кибетләр һәм дә Татарстан китап сәүдә берләшмәсе («Таткнигообъединение») аша барды. Беренчесе, рухи азыкны, нигездә, авыл халкына җиткерсә, икенчесе – безнең министрлыкка караганы – шәһәр җирендә сәүдә итә. Моннан нәкъ ун ел элегрәк республика авылларында 71 махсус китап кибете һәм 540 китап почмагы булуын укыганым бар. Хәзер күпме алар, салада китап сәүдәсенең перспективасы бармы, дөресен әйтеп сөйләшик, турыдан-туры шөгыльләнмәгәч, мәгълүматым аз, шул сәбәпле сорауның бу өлешен бүтәннәргә калдырам.

«Таткнигообъединение»гә килгәндә исә шуны әйтергә мөмкин: тирә-як өлкә-республикаларда, шул хисаптан Башкортстанда да мондый берләшмәләр тәмам таркалып бетүгә карамастан, бездәгесе яши, базар таләпләренә яраклаша, халыкны китапка якынайту юлларын уйлый. Әле күптән түгел Дәүләт Советы депутаты Фәндәс Сафиуллин: «Кибетләрне таратасыз!» – дип дәгъва белдерде.

Фәндәс агага моның белән килешмәвемне белдердем. Ризалашмаска нигез дә бар: расланганнан, ягъни 1992 ел ахырыннан бирле, мәркәзебездәге бер генә кибетне дә елгыр алыпсатарларга, гомумән, чит кулларга биргән булмады. Шөкер, бу мәсьәләдә Минтимер Шәймиев тарафыннан да, Фәрит Мөхәммәтшин ягыннан да яклау бар – берәү дә китап кибетләренә кул сузарга тиеш түгел! Хәер, кайбер яңа байлар купшы сүзләр белән җәмәгатьчелекне «менә бу кибеттә җәннәт ясыйбыз» дип ышандырырга тырышалар. Чистай урамындагы «Төрки китап» кибетен дә җәннәт, рухият җәннәте ясарга вәгъдә иткән иделәр түгелме соң?! Үзәктәге бинаны кулга төшерү өчен башта «монысын эшлибез, тегесен булдырабыз» ише вәгъдә яудыралар. Аннары инде, кибетне кулга төшергәч, китапны төрле яклап кыса башлыйлар. Тора-бара китапны пәрәвезле почмакка таба кысрыклыйлар. Кайчагында әлеге кибетләрне даулаучылар урау юллары белән эш итеп, үз ягына мәшһүр зыялыларны да аударып, «татар» сүзе белән авыз чайкыйлар. Янәсе, без халык өчен чабабыз, биредә гел татар китабы гына булыр, арзан бәягә сатылыр ул. Юк инде, җәмәгать, берәү дә ике тиенгә юнәткәнен бер тиенгә сатарга ашыкмас. Булган хәл түгел ул!

Форсаттан файдаланып, Татарстан китап сәүдә берләшмәсенең узган ел халыкка 15 миллиард сумнан артык китап сатуын әйтеп узыйм. Күңелгә җылы өстәгәне шул: халык акрынлап кибеткә кайта, суынган эзләрне яңарта башлады. Татар китабына булган кызыксыну арту да – уңай үзгәреш.

Узган елгы парламент тыңлауларының – китап язмышына, китап сәүдәсенә багышланган тыңлауларның – шифалы йогынтысын тоеп яшибез. Ихластыр, сырхауның чын диагнозын билгеләргә ярдәм иткән әлеге җитди сөйләшү авыл җирендәге китап сәүдәсен дә җанландырып җибәрде. Эленгән йозаклар ачылды, китап юллап нәшрият сукмакларын таптаучылар ишәйде. Күптән түгел Биектауда китап бәйрәме оештырылганлыгын, анда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 32 миллион сумлык әдәбият сатылуын әйттеләр. Мондый күркәм үрнәк бер район кысаларында гына йомылып калмас дигән өметтә яшибез.

Сәүдә хакында сүз чыккач, кайчагында: «Китап кибетендә китап кына сатылырга тиеш», – дигән кискен фикерләр яңгырый. Хак, кибетләрнең кайберләрендә юлдаш товарлар, әйтик, каләм-ручка, калькулятор, глобус, офис кирәк-ярагы, магнитофон-диктофон, картиналар ише товарлар да сатыла. Сәбәбе мәгълүм: салымнар рәхимсез, аренда бәясе аяктан егарлык, ә егылырга ярамый, димәк ки, заманга яраклашып, үз көнеңне үзең күрергә өйрәнә башлыйсың. Дәүләтнең дә төпсез кесәсе юк лабаса! Әле кайчан гына Алманиядә нәниләрне кызыктыру теләгендә китап кибетләренең попугайлар белән маймыл тотуын, мавыктыргыч уеннар оештыруын язып чыктылар. Монда кергән сабый китап алдырмыйча чыкмый инде ул. Мәскәү, Санкт-Петербург, Ташкент калаларындагы китап кибетләре дә буш мәйданнан оста файдаланалар: кайсы валюта алыштыру пункты ачып җибәргән, кайсы фотография ясый, кайсы көндәлек матбугат сата. Җыйнап әйтсәк, базарга яраклаша...

**Р.Ф.** *Мөгаен, бу Сезнең өчен иң уңайсыз сораудыр. Дөньяда каләм хакы дигән сүз бар. Сез үзегез дә матбугатта озак эшләп, күренекле журналист буларак, берничә китап чыгарган кеше. Ул вакытларда матбугатта актив эшләгән кешегә, китаплар чыгара торган язучы халкына гонорар дигән хикмәт белән тормыш итәргә, һич югында, «җан асрарга» була иде. Ә хәзер? Каләм ияләребезнең гонорары кульязмаларын машинкадан чыгару бәрабәренә тиң дәрәҗәдә. Белүебезчә, Россиядә, байтак регионнарда, шул исәптән күрше Башкортстанда*

*каләм әһелләренә түләү бездәгегә караганда инде ничә еллар буе күп мәртәбәләр артыграк. Былтыр Сезнең дә бу хакта матбугатта ачынып язган мәкалә-чыгышыгыз истә. Ул күпләрнең, бигрәк тә язучылар күңеленә бик хуш килгән иде. Шул чыгыштан соң хәлләр үзгәрдеме?*

**И.Ә.** *Шагыйрь Рөстәм Мингалимнең менә мондый шигъри юллары бар:*

Дөнья безне сыный...
Утка терәп сыный...
Суга терәп сыный...

Дөньяны еламсырак бәбине буш имезлек биреп алдаган шикелле алдап булмый шул. Икътисадтагы киеренкелек, бәяләрнең котырынуы рухи дөньяга да бәреп керде. «Базар» сүзе иҗат әһелләре өчен беренче вакытларда «каравыл» рәвешендә кабул ителде дисәм, хата булмастыр. Элегрәк һәммәсе көйләнгән, җайлы гына тәгәри иде – яңа басылып чыккан китабың гонорарына рәхәтләнеп берничә ел яши аласың, әдәби фондны да онытып бетермисең, бушлай путевкалар... Ә базар ыгы-зыгысы башлангач? Эш хакы яшәү рәвешенә тәңгәл түгел, гонорарлар түбән, җитмәсә, хәләл эшләп тапканыңны да үз вакытында алып булмый. Базар зилзиләсе каләм осталарының кайберләрен шундый итеп ярга китереп сылады ки, бүгенгәчә хәлгә керә алмыйча интегүчеләре бар.

Ә хәзер сорауга әйләнеп кайтыйк. Сезнең өчен иң уңайсыз сораудыр дип, хәлгә керергә тырышуыгызга рәхмәт. Язмага «җим» туплап, куелган сорауга җавап эзләп йөргәндә, гонорарлар да артып куйды бит әле. Күпкә, өч-дүрт тапкырга артты. Моны раслау ниятендә Сез җитәкчелек иткән «Казан утлары» мисалына тукталып узыйк. 16,8 табаклы «Казан утлары» агымдагы ел башына кадәр авторларына бер санга 4 млн. 80 мең сум хисабыннан гонорар түләп килде (чагыштыру өчен: «Сөембикә» – 4 млн. 650 мең сум, «Идел» – 1 млн. 848 мең сум). Ә хәзер Министрлар Кабинетының 1996 ел, 30 декабрь карары белән «Казан утлары»ның бер саны 13 млн. 578 мең сумга бәрабәр («Сөембикә» – 15 млн. 486 мең, «Идел» – 8 млн. 52 мең).

Хәзер «Башкортстанда гонорар күләме берничә тапкыр артыграк» дигән сүзләрегезне ачыклап китик. Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер диләрме әле? Бу юлы да шулайрак килеп чыккан бугай. Күптән түгел генә Алабуга шәһәрендә Башкортстандагы хезмәттәшлә-ребез белән очрашып, бер-беребезнең хәлләрен белешкән идек. Сүзгә-сүз ялганып, гонорарлар хакында да фикер алыштык, һәм менәниләр ачыкланды: «Агыйдел» журналының (күләме 12 табак) бер санга гонорары 3 млн. 700 меңгә, «Башкортстан кызы»ның 1 млн. 540 меңгә, «Һәнәк»нең 2 млн. 125 мең сумга тигез. Күренгәнчә, күршеләрнең хәле күпкә өстен дип раслау өчен җирлек юк. Нәшриятлардагы гонорарлар да артты. Бүген-иртәгә бюджет өлкәсендәгеләрнең, димәк, сүз безнең хакта да бара, эш хаклары арттырылачак.

**Р.Ф.** *Теңкәгезгә тиеп дигәндәй, ай саен, декада саен без Сездән – Министрлыктан акча сорыйбыз. Сез үз чиратыгызда дәүләт бюджетыннан акча юлларга тырышасыз. Кыскасы, без барыбыз да – «бюджетниклар». Рәхмәт, дәүләт безнең ихтыяҗларны күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләндереп килә. Без еш кына Министрлыктан, шөкер, фәлән миллион сум акча күчергәннәр, дип сөенәбез. Әмма шул сумманы бухгалтерия аша бүлә башлагач, шунысы ачыклана: без 20 ләп дәүләт салымы түләргә тиешбез икән. Кыскасы, көч, вакыт һәм финанс ресурсларын болай исраф иткәнче, шушы процессны үтәүче йөзләгән чиновник-хезмәткәрләрдән тыш, тиешле кирәк акчаны турыдан-туры салымнарсыз гына финанслап булмый микәнни?*

**И.Ә.** Тәүге карашка бөтенесе дөрес шикелле: дәүләттән бер кулыбыз белән алсак, икенчесе белән салым рәвешендә кайтарып бирәбез. Әйтелгәнчә, тәүге карашка гына бу шулай. Гәҗит-журнал редакцияләре үз чыгымнарының берникадәр өлешен алынган керем-табышлары исәбенә каплыйлар. Керем подпискадан килә, игълан-белдерүләрдән, рекламадан, алыш-биреш итүдән (мисал рәвешендә «Сам хозяин» гәҗите редакциясенең узган ел 300 миллион сумлап яшелчә, җиләк-җимеш орлыгы сатуны оештыруын әйтә алам) килә. Һәм әлеге керем күләмнәренең ай саен, ел саен төрле сәбәпләр аркасында үзгәреп, «биеп» торулары ихтимал. Бездә елына рекламадан гына 700–800 миллион сумлап керем алучы шәһәр

гәҗитләре бар. Уйлашыйк әле: алар бу керемнән салым түләргә тиешләрме? Әлбәттә! Салым турындагы, бюджет турындагы законнар алдында һәркем тигез. Ә менә кемнең ничек һәм күпме түләргә тиешлеге – монысы башка мәсьәлә. Салым дөньясының үз сәясәте булырга тиеш. Берничә ел элегрәк сездәге – «Казан утлары»ндагы салымнар саны хәмер белән сату иткән кибетнекенә бәрабәр иде. Әлбәттә, моның белән ризалашуы кыен. Мәдәнияткә, рухи дөньяга турыдан-туры мөнәсәбәте булган коллективлар салым мәсьәләсендә мөмкин кадәр льготалардан файдаланырга тиешләр дип саныйм. Хәер, андый льготалардан файдаланабыз да. Әйтик, «Россия Федерациясендә массакүләм матбугат чараларына һәм китап бастыруга дәүләт булышлыгы турында»гы Закон нигезендә, мисалга, «Казан утлары» табышның федераль бюджетка күчерелергә тиешле өлешенә тиешле салымнан азат ителгән. Журнал тәрҗемә кылмыйча да яхшы аңлашылган НДСны да түләми. Болар бит арадагы иң саллы салымнар. Аннары, реклама, коммерция юлы белән килгән акчаның 40 процентын журналда эшләүчеләр мәнфәгатен канәгатьләндерүгә җибәрә аласыз.

**Р.Ф.** *Кызганыч, Сез әйткән бу өстәмә керемгә ирешү безнең журнал шартларында мөмкин түгел диярлек. Коммерция, реклама белән шөгыльләнгән очракта да файдалы эш коэффициенты бик түбән булыр иде. Үзегез беләсез, реклама оперативлыкка бәйле. Ә безнең журнал яртышар ел диярлек алдан әзерләнә. Әгәр дә без кайбер басмалар юлы белән китсәк, бүгенге «Казан утлары» татар халкының төп журналы саналган журнал да була алмас иде. Безнең максат – укучыларыбызны ишәйтү, тиражны арттыру, шушы юнәлештә матди аякка басу, ныгу.*

**И.Ә.** Сезнең белән өлешчә килешәм һәм башлаган сүземне дәвам итәм. Бүген Россиянең урта гасырлардагы салым фәлсәфәсен алга сөрүен күреп яшибез. Янәсе, салым күбрәк булган саен, казнадагы акча да артачак. Аһ, алай түгел шул! Алга киткән дәүләтләр башка төрлерәк фәлсәфәгә табына: налог та түбән, казнада да акча мул.

**Р.Ф.** *Кайвакыт безнең кайбер зыялы иптәшләребез авызыннан «Бөтен матбугат, нәшриятлар ирекле яшәп китәргә тиешләр» дигән сүзләр ишетергә туры килә. Мондый фикер белән һич килешеп булмый...*

**И.Ә.** Мин дә килешә алмыйм. Ни өчен дигәндә, читтә дә, бу очракта Көнбатышны күздә тотам, дотация алып яшәүче басмалар бар. Бу – балалар басмалары, бу – фәнни басмалар, яшьләргә, аз санлы милләтләргә исемләнгән басмалар, бу – дәүләт сәясәтенең асылын аңлатып бирүче рәсми басмалар. Әлбәттә, базар шартларына җайлашканда үз көнеңне үзең күрү әйбәт нәрсәдер, әмма матбугатның абсолют үзфинанслауга күчүе турында сүз алып барырга иртәрәк әле. Аннары медальнең икенче ягы да бар. Әйтик, рус телендә чыккан гәҗитләр бар, татар телендәгеләре бар. Аларның һәрберсе чыгымнарның бер өлешен реклама хисабына каплап барырга тырыша. Әмма бер хакыйкатьне дә онытмыйк: әлегә бүген бизнесмен-эшкуарларның күпчелеге рус телендәге басмаларның ишекләрен шакый. Күпсенеп әйтү түгел. Бу – традиция, бу – телләр турындагы законның тыйнак атлавы... Татар телендәге басмалар партия җитәкчелек иткән заманнарда икенче сортлыраклар рәтендә йөриләр иде. Әле бүген дә бу карашны бөтенләй бетерә алганыбыз юк. Әмма татар телендәге басмаларга мөнәсәбәт үткән еллар белән чагыштырганда нык үзгәрде. Уңай якка, әлбәттә!

**Р.Ф.** *Татар телендә иң күп тиражлы журнал кайда чыга икән дигән уй Сезгә дә килә торгандыр. Ул – Уфада чыга торган яшьләр журналы – «Тулпар». Тиражы – 55 мең чамасы. Ә безнең «Идел»нең, ике телдәгесен дә исәпләп, әбүнәчеләр саны 5000 данә дә юк. Бу хәлне Сез ничек аңлатасыз?*

**И.Ә.** Яшермим, тугандаш Башкортстанда яшьләр өчен журнал басыла башлауны куанычлы вакыйга рәвешендә кабул иттек. Өч ел чыгып килү дәверендә абруе торган саен артуга да шаһитбыз. 1994 елда дөньяга килүе хакында «аваз» биргән бу басма баштарак 6–7 мең данә белән таралып, аннан соңгы елда тиражын 15 меңгә җиткерә. Ә былтыр әлеге басманы 36 мең кеше яздыра. Килешик, теләсә кемне кызыктырырлык үсеш. Укучыларыбызда «сәбәп нәрсәдә икән соң» дигән сорау тууы ихтимал. Март ае азагында «Тулпар»ның баш

мөхәррире Римат Кашапов белән очрашып, нәкъ менә шушы хакта гәп корган идек. Мәгълүм ки, Башкортстанда бер миллион ярымлап татар яши, газиз телебездә укучылар саны тагын да күбрәк. Монысы булдымы бер. Икенчедән, күршеләребездә «Тулпар» – татар телендәге бердәнбер журнал, һәм андый басмага ихтыяҗ зур. Татарстанда исә журналлар байтак: «Казан утлары», «Идел», «Аргамак», «Сөембикә», «Татарстан», «Мирас», «Ялкын», «Мәгариф», «Казан», «Гасырлар авазы», «Чаян», «Салават күпере»... Журнал үзенең даирәсен киңәйтеп, авылда яшәүче гаиләләр, хатын-кызлар, социаль мәсьәләләр хакында махсус сәхифәләр оештыра һәм бу тиражга шифалы йогынты ясый. Монысы, миңа калса, өченче сәбәп.

**Р.Ф.** *Килешәм, басмалар күп. Әйдәгез карыйк әле: кайсы басма нинди тираж белән чыга? Бу мәгълүматлар сезгә дә, безгә дә яхшы билгеле. Берәүләрнең тиражы, әйтик, йөзләр белән генә исәпләнә, икенчеләрнең исә дистә меңнәр белән. Әмма штатлар дисеңме, эш шартлары (хәтта кайбер аз тиражлы журналларда эшләүчеләрнеке яхшырак та әле), хезмәт хаклары дисезме, нигездә, тигез. Нәкъ теге чаклардагы «уровниловка» шикелле. Бу, безнеңчә, нормаль хәл түгел. Хәтерегездәдер, 10–15 еллар элек басмаларның иҗтимагый әһәмияте, сыйфаты һәм халыкка таралуын исәпкә алып, гәҗит-журналлар категорияләргә бүленә иде. Бәлки, шул еллардагы тәртипкә яңадан кайтыргадыр?*

**И.Ә.** Тиражлар саегу белән килешмичә мөмкин түгел. Дөрес, бездә нәшер ителгән басмаларның тиражы Мәскәүдәгеләрнеке кебек үк «ишелеп» төшмәде. 90 нчы еллар башында «Знамя» журналының миллион данә белән басылганлыгын беләбез. Ә хәзер? Бер мең тапкырга (!) кимеде аның тиражы. «Новый мир»ныкы – мең ярым тапкырга! Ә безнең татар телендәге журналларны укучылар саны күпмегә кимеде дип беләсез? Дөрес, кимүен кимеде, әмма бу хәтле үк күпкә түгел, нибары биш-алты тапкырга. Кул астындагы саннар соңгы вакытларда кайбер басмаларның тиражы артуы хакында сөйли. Әйтик, шушы айларда үзенең 75 еллыгын бәйрәм итүче «Казан утлары» журналын алдыручылар саны берничә меңгә ишәйде. Шушы урында берникадәр читенеш ясап булса да татар халкының баш журналы дип йөртелгән мөхтәрәм басма хакында берничә җөмлә әйтмичә уза алмыйм. Баш журнал – ифрат та төгәл һәм дөрес бәяләмә бу. «Казан утлары»н XX гасыр дәвамында татар халкының рухи дөньясын: тарихын, әдәбиятын, телен, мәдәниятен, сәнгатен чагылдырган энциклопедик басма дип авыз тутырып әйтә алабыз. Журналның иҗтимагый абруе искиткеч дәрәҗәдә зур. Редакция даирәсенә әдәбиятыбызның талантлы әдипләре тупланган. Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев «Казан утлары» редакциясенә юллаган котлау сүзендә билгеләп узганча, татар мәдәниятенең рухи көзгесенә әверелгән басма элеккеге һәм бүгенге матур традицияләрне тагын да баетыр, республиканың мәдәни, иҗтимагый тормышы үзәгендә балкып торыр.

Хәзер башлаган сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. Бу хакта сөйләгәндә бөтенесен икътисадка гына әйләндереп калдырырга кирәкмидер. Бүгенге көн әдәбиятының сыйфаты, миңа калса, элекке еллардагыныкыннан берникадәр калыша. Укучыны алдавы кыен, кайда бөртек, кайда кибәк икәнлеген ул бик чамалый. Мәскәүдәге калын басмаларга хас чир атыш-үтереш, талау, җинаятьчеләр, фахишәләр дөньясын күрсәтүдән гыйбарәт.

Кайберәүләр әдәби калын журналларның заманы үткәндә калды дип расларга тырыша. Килешмим! Кискен итеп килешмәскә нигез дә бар. Сорос фонды узган ел 2500 китапханәдә «Кайсы өч журналны алдырыр идегез?» дигән сораулы анкета тарата, һәм бик мәгънәле җаваплар алына: 2500 китапханәнең 2495е – «Иностранная литература», 2100е – «Знамя», 2000е – «Новый мир», 1600е «Октябрь» белән «Дружба народов» журналларына яздыруларын сорыйлар. Без дә Милли китапханә белән бергәләп шундый хисап-кызыксыну уздырырга йөрибез.

Инде бердәй эш шартларына, хезмәт хакларына әйләнеп кайтыйк. Соңгысын, ягъни хезмәт хакын билгеләгәндә бөтенебез өчен закон бер – бердәм тариф челтәре, шуның нигезендә эшләнгән кулланма. Челтәрдә (уңайлык өчен шулай дип әйтик) журналда эшләүче һәркемнең нинди вазифа башкаруына, стажына, белеменә, эшкә мөнәсәбәтенә, гыйльми дәрәҗәсенә, булдыклылыгына, лаек бүләкләренә карап үз урыны, үз куышы, бүтәнчәләтеп әйтсәк, үз разряды бар. Ил буенча шулай бер канун нигезендә яшибез.

Штатлар республиканың Министрлар Кабинеты карары белән раслана. Әлбәттә, басманың күләме, әһәмияте, форматы, айга яисә атнага ничә тапкыр һәм нинди телләрдә чыгуы истә тотыла. Хезмәт хакын, эш шартларын тиражга бәйләү хакындагы тәкъдим белән килешә алмыйм. Һәм менә ни өчен. Ярый, шундый карарга килдек ди. Республикабыздагы чуваш туганнар өчен өч ел элек чыга башлаган «Сувар» гәҗитенең тиражы 2 мең тирәсе. Ә «Татарстан яшьләре»неке – 150 мең. Әгәр тәкъдим ителгән принцип нигезендә эшләсәк, «Сувар»га нибары бер бүлмә, 3 штат бирергә туры килер иде. Болай эшләгәндә, мәйданда бер-ике басманың гына калачагы көн кебек ачык. Дөрес булырмы бу, уйлашыйк әле.

Инануымча, һәр басма – аз тиражлымы ул, күп меңле укучылары булган басмамы – аерма юк. Әйбәт шартларда эшләп, җитәрлек акча алып яшәргә тиешләр. Элегрәк барча редакцияләрнең, китап нәшриятының Бауман урамындагы Матбугат йортына сыешуларын хәтерлибез. Аннары барча редакцияләр Пресса йортына күченде. Соңрак булганнарына Чистай урамындагы дәү йортның икенче каты, Язучылар берлегендәге бүлмәләр («Идел», «Салават күпере» журналлары редакцияләре) өстәлде. Шартларны кемнедер рәнҗетү бәрабәренә түгел, Пресса йортыннан кайбер редакцияләрне чыгарып, аларга башка җирдән иркен-әйбәт бүлмәләр бирү хисабына яхшыртырга исәп. Әлеге юнәлештә берникадәр эш башланды да инде.

**Р.Ф.** *Республикада берничә йөзләп гәҗит-журнал нәшер ителә, нәшриятлар саны артуын күреп-ишетеп торабыз, дип әйттегез. Гомерен матбага эшенә бәйләгән кеше бер-бере белән аралашмыйча, хәл-әхвәл белешмичә, очрашмыйча яши алмый. Аннары алар җылы сүзгә, хөрмәт-олылауга да бик мохтаҗлар бит. Элегрәк елына бер тапкыр булса да аларны җыеп котлыйлар иде...*

**И.Ә.** Тел төбегезне аңладым, Равил әфәнде. Әйтергә теләгән фикерегез белән килешмичә мөмкин түгел. Матбугат көнен без 1922 елдан алып 5 майда – коммунистик рухлы «Правда» гәҗитенең тәүге саны чыккан көндә бәйрәм иттек. Берничә ел элегрәк «Ведомости» гәҗитенең беренче саны чыккан көнгә – 13 гыйнварга туры китереп, Россиядә бәйсез матбага көне билгеләп үтелә башлады. Моннан соң «Татарстанның кайчан үз матбугат көне булыр?» ише сораулар ишетә, хатлар ала башладык, һәм Журналистлар берлегендә саллы сөйләшү уздырдык, матбугат тарихын өйрәнүче күренекле галимнәрне чакырып фикерләштек. Төрле тәкъдимнәр булды. Берәүләр, әйтик, Матбугат бәйрәмен Исмәгыйль Гаспралы мөхәррирлегендә дөнья күргән «Тәрҗеман» чыга башлаган вакытка билгеләргә кирәк, диделәр. Әлеге фикер белән килешеп булмый: гәҗит бит безнеке түгел, ул азәрбайҗанга якын сөйләктә чыккан. «Тәрҗеман»ның әһәмияте безнең милләтнең мәдәни һәм фикери үсеше өчен гаять зур, ләкин ул татар гәҗите түгел. Бүтәнрәк тәкъдимнәрне җентекләп тикшергәннән соң, күпчелек Матбугат көнен 1905 елда Петербургта татар телендәге беренче басма гәҗитне – «Нур»ны чыгаруга рәсми рәхсәт алу көнендә – 19 майда билгеләп үтәргә килеште. Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев тә хуплады бу тәкъдимне. Хәзер аны Дәүләт Советы аша рәсмиләштерәсе генә калды.

Матбагасыз, китапсыз халык – тарихсыз, телсез, чукрак халык, диләр. Шөкер, безнең бай тарихыбыз да бар, телебез дә исән, гәҗит-журналларыбыз, китапларыбыз да бихисап. Дөрес, бөтенесе ал да гөл генә түгел, хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дә байтак. Әмма мөхтәрәм журналны укучылар базар капкасын ачып кергәндә туган кыенлыкларның вакытлыча икәнлеген аңламыйлардыр дигән фикердән ерак торам, һәм аларның якын елларда хәл ителәчәгенә һич шик юк. Үткәнне – бүгенгегә, бүгенгене киләчәккә тоташтыручы матбаганың, китапның гомере озын булсын. Рухи азыксыз дөньясы сансыз бит аның.

*1997*

# Еллар үткәч тагын бер әңгәмә

**Р.Ф.** *Хөрмәтле Ислам әфәнде! Хәтерлисездер, 1997 елны, ягъни моннан 11 ел элек матбугатыбыз хәлләре турында әңгәмәләшкән идек, һәм ул әңгәмә журналыбызда матур*

*итеп басылып та чыкты. Сез ул елларда Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министры идегез. Хәзер Сез «Идел-Пресс» ААҖнең генераль директоры. Һәр вазифаның үз авырлыгы, үз җаваплылыгы. Миңа калса, хәзерге эшегез зурлыгы һәм җаваплылыгы ягыннан элеккегесеннән һич ким түгел. Бәлки, артыграктыр да әле. Сез – Китап дигән зур дөньяның безнең республикадагы короле. «Идел-Пресс» полиграфия һәм нәшрият комплексының эшчәнлеге турында укучыларыбызга беркадәр мәгълүмат бирсәгез икән.*

**И.Ә.** «Идел-Пресс» исемен ишеткәч кызык булып китте әле. Чит калалардагы заказчыларыбызның бөтенесе диярлек безне «Идеал-Пресс» дип йөртә, хатларга да шулай язалар. Үпкәләмибез, киресенчә, идеал булырга язсын дигән өмет белән яшибез.

«Идел-Пресс» СССР таркалганчы илдәге иң дәү ун нәшрият исемлегендә йөрде. Ә бүгенге «Идел-Пресс» – 120 (!) исемдәге гәҗит-журнал, ел саен 9–10 миллионлап китап дигән сүз. Альбом, буклет, дәфтәр ишеләренең исәбе-хисабы да юк. Болай әйтеп ялгыштым, өреп тутырылган саннар белән мавыкканыбыз юк анысы, һәрнәрсәнең исәбе дә бар, хисабы да... Юлыбызның догалы икәнлегенә ишарә рәвешендә бер сан: көн саен 2 миллион сумга якын рухи азык «пешерәбез». Үткән ел 408 миллион сумга җиткән бу. Чамалыймсыз, начар сан түгел бу! Җитмәсә, ел саен 25–30 миллион өстәлеп бара. Төп партнерларыбыз кемнәрме? Иң әүвәл үзебезнекеләрне – Татарстан китап нәшрияты белән «Мәгариф» нәшриятын атап узарга тиешмен. Мәскәүдәге 22 нәшрият әзерләгән китапларда «Казанда басылды» дигән мөһерне күрергә мөмкин. Екатеринбургтагы, Башкортстан, Самарадагы коллегаларыбыз белән мөнәсәбәтләребез нык. Якут телендәге әлифбаны да басабыз, чечен китаплары да безгә ят түгел. Бездә эшләүчеләрнең һәркайсы уч төбендә йөртерлек, зат-пирут йөреп чалбар туздыручылар бөтенләй юк. Алар булдыклылыгы белән предприятие бәрәкәтле үзгәрешләр кичерә – яңа җиһазлар ала, полиграфистлар әзерли (югары белемле полиграфистларның җитешмәве – элек-электән булган проблемалар арасында иң теңкәгә тигәне), туасы көннәр хакына фикри җегәр туплый...

Ибен-җаен белеп эшләгән хезмәт кешесенең мәнфәгате һәрчак үзәктә булды. Бүгенгә айлык уртача эш хакы 13 мең 679 сум. Ел ахырына кадәр аның тагын берәр меңгә артачагына һич шигем юк. Әбәтләп алу өчен көн саен утызар сум акча бирелә. Үзебезнең врач, шәфкать туташлары бар. Телисең икән, спорт залында шөгыльлән! Эшкә автобус китерә, автобус кайтарып куя. Һәр җирдә чәчәкләр, ял итә торган бүлмәләрдә аквариум, тутый кошлар... Җан кайнарлыгын салып эшләгәннәргә алда әйтелгәннәр әз, бик әз әле. Эш кешесе бернәрсәдә дә мохтаҗлык күрергә тиеш түгел, бу безнең өчен доминант – идея.

**Р.Ф.** *Илкүләм эзлекле гомумбер идеология булмаса да, рух дөньясы инерт халәт кичерми. Без теләгәнчәме, юкмы, тормыш барыбер дәвам итә. Без әңгәмәләшкәннән соң үткән еллар эчендә яшәвебездәге вазгыять нык үзгәрде. Язучыларның хезмәт нәтиҗәсе булган әдәби әсәрләргә (бу очракта аны китап дип атыйк) дә мөнәсәбәт үзгәрде. Китапны хәзер дә Галиҗәнап Китап дия алабызмы? Сезнеңчә, җәмгыять тормышында Китапның роле ничегрәк хәзер? Бәһасез хәзинәме ул, әллә беренче чиратта товармы? Сүз, әлбәттә, яхшы китаплар турында бара.*

**И.Ә.** Китап ул борын-борыннан могҗиза булды һәм, иманым камил, киләчәктә дә шулай булып калыр. Китап сине исертергә дә, айнытырга да мөмкин. 30 нчы елларда кино һәм 50 нче елларда телевидение барлыкка килгәннән соң да «Китапның киләчәге бармы?» кебегрәк сораулар туганлыгын беләм. Белгеч-галимнәрнең ничәмә-ничә еллар дәвамында альтернатив ягулык тирәсендә ду-чат килеп бәхәсләшүләре һәркайсыбызга билгеле. «Бүген-иртәгә» кебегрәк вәгъдәләр хәйран, ә автомобильләр, элеккегечә, бензин «ашый».

Кәгазь китапның киләчәге өметсез дип тәкрарлаучылар белән һушымнан язганчы бәхәсләшергә әзер. Электрон китапларны да, аудиокитапларны да хурларга җыенмыйм. Әмма, инде әйтеп узганымча, Галиҗәнап Китапны беркайчан да бернәрсә дә алыштыра алмастыр. Кулыңа тотуга хисләнә башламагач, геройлары белән кайгырмагач-сөенмәгәч, күңелеңә хуш җырләрен кайта-кайта укымагач, шушы да булдымы китап уку! Укый-укый черемгә китеп баручыларны, бакчаның күләгәле почмагында кичке тынлыкка сыенып уку ләззәтен аудиокитап алыштыра алыр дисезме? Хаталанмыйк. Минем өчен пунктуациянең нинди булуы

да кыйммәт. Нокталы өтер белән күп ноктaларны үз күзләре белән күреп хозурланучылар да бер мин генә түгелдер. Еллар тузанын кага-кага уку тәмен Интернет бирә аламы икән? Дөрес аңлый күрегез, Интернет, электрон китапханәләргә дә күсәк күтәрергә җыенган кеше юк. Анысында мәгълүмати-белешмә әдәбият, сүзлекләр туплансын. Тормыш сынавын узганнары, әлбәттә.

Китапка күпме генә мәдхия җырласак та, китап укудан берникадәр читләшү үзен сиздермичә калмый. Әмма аһ орырга, «укымыйла-а-ар» рәвешендә чаң кагарга иртәрәк әле. Рәсәйгә йә булмаса татарларга гына хас чир түгел бу. Юккамыни, инглизләр, яшьләрнең Шекспирда гамьнәре юк, рухи яктан гарип булып үсәләр түгелме соң алар, дип, парламент мөнбәреннән кызып-кызып бәхәсләшәләр. Франциядә француз телен коткару (әйе-әйе нәкъ менә шулай) максатында оешкан гомуммилли комитет эшли. Алманиядә булганда дәүләтнең балаларда китап уку теләген үстерү өчен ел саен 4 миллион евро акча бүлеп бирүен ишеткән идем. Ә американнар бәйге оештырганнар! Ниндинеме? Балаларның китап укып йоклап китү бәйгесен. Галиҗәнап Китапның киләчәге хакында сөйләүче мисаллар түгелмени бу?

**Р.Ф.** *Сезнең кабинетның албүлмәсе стенасында төрле-төрле дипломнар, Мактау кәгазьләре, бүләкләнү турында указлар эленеп тора. Түр бүлмәдә дә ул призларның сыннары, медаль-билгеләре җитәрлек. Алар хезмәттә ирешкән уңышларның символлары бит инде. Кайсылары аеруча кадерлерәк?*

**И.Ә.** Иң әүвәл диплом йә булмаса мактау кәгазьләренә кагылышлы бер нәрсә сөйләп узыйм әле. Ел төгәлләнергә берничә ай кала берләшмә-предприятие җитәкчеләре исеменә Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, хәер, алай гынамы, кайчагында Кейптаун, Сидней кебек калалардан затлы ялтыравык кәгазьләргә алтын буяулар белән басылган чакыру-тәкъдимнәр «ява» башлый. Сиднейдан җибәрелсә, дә урысча язылган булыр алар. Һәркайсында диярлек «игезәк» сүзләр: «Мөхтәрәм Фәлән иптәш Фәләнов! Сез җитәкчелек иткән предприятие соңгы берничә елда икътисади яктан нык сикереш ясады, илкүләм шөһрәт казанды. Безнең халыкара үзәк Сезне 2007 елның иң яхшы компаниясе дип таный һәм Мәскәүнең Президент-отелендә узачак тантанага чакыра». Утсыз, төтенсез, кинәт ялкын! Күзгә бәрелми генә урталыкта атлап кил дә, көннәрдән бер көнне илкүләм танылу ал әле син! Билләһи, башларың әйләнеп китәр. Тагын бер нәрсәне әйтеп китү зарур. Ялтыравык кәгазьнең икенче ягында враграк хәрефләр белән диплом белән медальнең, тантанада авыз итәсе шампанның 2978 еврога төшәчәге күрсәтелгән. Рәсәй акчасына әйләндерсәк, 110 мең сумнарга тарта түгелме соң әле бу? Халыкара хезмәттәшлекне үстерү юнәлешендә эшләүче 35 сессия Лондон–Нью-Йорк–Сан-Франциско–Гавай–Токио маршрутын тәкъдим итеп 790 мең (!) сум сорый. Янәсе, алтын орден белән мактау дипломы өчен. Һәм әзрәк аркаңны кыздырып алу хакына, әлбәттә, хәләл җефетеңне дә ияртергә ниятләсәң, әлеге бәһане икегә тапкырлап куй. Узган елның соңгы берничә аенда без шуңа охшаш 22 тәкъдим-чакыру алдык. Дан тагарагыннан берәр калҗалы кисәк эләктереп калырга теләүчеләр беткәндер дигән фикердән ерак торам мин. Шулай булмаса, әледән-әле гәҗит битләрендә кемнәрнеңдер «дөньяның иң мәшһүр заты», «Рәсәйнең иң күренекле җитәкчесе» дигән исем алуларга кагылышлы хәбәрләргә юлыкмас идек. Шөкер, итәк астыннан дан сатып ятучылар белән безнең беркайчан да алыш-бирешебез булмады, күптән мондый күз буяуларга ясин чыгылган.

Ә безнең албүлмәдәге диплом-мактауларга килгәндә, шуны әйтә алам: аларның берсен дә ифрат зур акчага да сатып алып булмый. Әйтик, «Рәсәйнең мактаулы салым түләүчесе» дигән диплом. Әгәр син салымнарыңны көннекен-көнгә түләп бара алмасаң, моның ише бүләкләр хакында хыялыңны җылытып йөрергә мөмкинме соң?! Мәгълүм ки, республика җитәкчеләренең рәхмәт хатларын да сорап алып булмый. Дин әһелләренең дә күзгә төтен җибәреп утырганын ишеткәнем юк. Сабан туйларын оештыруга өлешебез кергән, милиция белән багланыш ныгыган – дипломнар күп нәрсә хакында сөйли. Күптән түгел Рәсәй күләмендә «Нәшрият һәм полиграфия өлкәсендә тармак әйдәүчесе» дигән диплом тапшырдылар. Акча түләп түгел, маңгай тирен түгеп алдык. Соңгысы булмастыр, шәт.

**Р.Ф.** *Казансу буендагы без бергә-бергә эшләгән «Идел-Пресс» бинасы төзелгәнгә дә кырык елга якын гомер узды. Сезнең дә гомернең байтак еллары биредә эшләп үтте. Инде без дә олыгайдык, шулай ук бина да «картайды». «Идел-Пресс» территориясе тирәсендә яңа бина-*

*корпуслар төзү планнары бармы? Баумандагы Матбугат йортыннан нәшриятлар, редакцияләр кайсы кая таралып беткәч, матбагаларны бер үзәккә туплау уе күпләрдә бар. Бәлки, аларны «Идел-Пресс» тирәсенә җыю кулайдыр? Бу хакта Сез ничек уйлыйсыз?*

**И.Ә.** Матбугат йортыннан башлыйк әле җавапны. Аның төп хуҗалары – китап нәшриятлары – шәһәр читенә «башка чыккач», «Мәдәни җомга» гәҗите безгә – «Идел-Пресс»ка «йортка кергәч», аннан килеп, мәркәзебездәге иң дәү китап кибетенә йозак элентәч, миңа калса, Бауман урамы гармунсыз авыл, сандугачсыз урман шикеллерәк булып калды. Бер чаты китек аның хәзер. Башкаланың рухи кәгъбәсенә менә торган атаклы баскыч төбендә гөлдерәп гәп коруларны, исемнәре дәреслекләргә кергән каләм ияләренең тәмәке көйрәтүләрен дә күрмисең инде. Баумандагы олы күченешнең шаукымы безнең тарафларга да килеп җитеп, көнаралаш диярлек, озын колаклар аша, кемнәрнедер кушалар икән, кемнәргәдер үз хәлләрен үзләре күрергә тәкъдим ителгән икән ише сүзләрне ишетә башладык. Җае килгәндә, безнең тел төбендә нәрсәләр ятканлыгын белешеп алуларын да әйтим. Әлеге мәсьәләдә ашыгу-каударлану килешмәс, җиде кат үлчәгәннән соң гына кулга кайчы алу хәерле булыр, дидек. Белүемчә, хәзер хөкүмәттә «Идел-Пресс»ны киңәйтүнең берничә варианты карала. Беренчесенең төп идеясе гәҗит-журнал редакцияләре урнашкан ундүрт катлы бина күршесенә аңардан да биегрәк икенче бер корпус күтәреп, киләчәктә шәһәрнең төрле почмакларына сибелгән барча редакцияләрне бер түбә астына туплаудан гыйбарәт. Ә хәзерге бина сүтеләчәкме, дип сорарсыз. Сүтелмәс дип уйлыйм, шәпләп-сипләп яңартылыр, аннары инде мондый бинага хуҗа табылмый калмас. Икенче тәкъдим «Ак Барс банкы» белән бәйле. Ул, төп инвестор (акча чыгымын үз җилкәсенә алучы дип аңлыйк) сыйфатында эш итеп, типография ягын элекке «Тасма» берләшмәсеннән бушаган мәйданнарга – «Химград» шәһәрчегенә күчерергә ниятли. Ә редакцияләрнең «Ак Барс банкы»ның бүгенге төп бинасына (элеккеге Яшьләр үзәгенә) күчү ихтималы бар. Сезнең белән әңгәмә корып утырган дүрт гектарлы мәйданнарда банк хуҗалыгы булыр дип фаразлана. Бүгенге проектларыбызның берсенә дә соңгы нокта куелганы юк. Бизмәндә дистәләгән коллективларның язмышы. Әйткәнемчә, мондый эштә кабалану нигезсез.

**Р.Ф.** *Әлбәттә, зур хуҗалык җитәкчесенең вакыты бик чикле. Шулай да, Сез, галим-журналист буларак, кайбер әсәрләрне күздән кичерәсез дип уйлыйм. Бүгенге татар әдәбиятында яратып укырлык әсәрләр бармы? Нинди жанрлар Сезгә якын? Гомумән, татар әдәбияты, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында берничә сүз.*

**И.Ә.** Берьюлы биш сорау юлладыгыз, кыскача гына җавап биреп булырмы... Хезмәтем матбугат, китап басу белән турыдан-туры бәйле булганга, үзебездә дөнья күргән әсәрләрне хәлдән килгәнчә укып барырга тырышам, кайбер шигырьләрне хәтта куен дәфтәренә дә күчереп куям. Беләбез ки, бүген күп языла, әмма аз укыла торган заман. Һәр укылган әсәр хәтергә уелып кала димәс идем. Үземә тарихи романнар, документаль чыганакларга нигезләнеп язылган мәгълүматлы әсәрләр ныграк ошый. Чын мәгънәсендә матур әдәбият кануннары белән иҗат ителгән мәхәббәт повестьларын да көтеп алам. Яшьлегебездә китаплары кулдан төшмәгән Г.Әпсәләмов, Ә.Еники, М.Әмир, Ф.Хөсни, Н.Дәүли, М.Мәһдиев, Г.Афзал кебек мәшһүр шәхесләр юлын дәвам итәрлек язучыларыбыз аз түгел. М.Хәбибуллин, Ф.Садриев, Ф.Бәйрәмова, К.Кәримов, В.Имамов, М.Әмирхан романнары нәкъ менә бүгенге укучы өчен һәм киләчәккә атап язылган дип икеләнмичә әйтә алам.

Һәр үткән гасыр әдәбият тарихына яңа мирас өстәп тора. Ләкин һәр язган әсәр мирас булып кала алмый. Әйтик, узган гасырның 90 нчы елларга чаклы өлешен алып карыйк. Хәтерем ялгышмаса, ул чорда 170 ләп татар язучысы бар иде. Күпчелегенең кулдан каләмне төшермәвен беләм. Иҗатлары өчен орденнар алган, мактаулы исемнәр яулаган, Дәүләт премияләренә лаек булган язучыларыбыз күп иде... Кызганыч, без инде ул шәхесләрнең күбесенең исемен онытып барабыз, өебездә сакланган калын-калын китапларын Хәйрия елында авыл китапханәләренә илтеп тапшырдык. Бүген безнең рәсми рәвештә теркәлгән 300дән артык язучыбыз бар. Киләчәк шуларның күпмесен хәтеренә теркәп калыр?

Мине бер тенденция сагайта – тарихи романнар язу модага керде түгелме? (Мин инде милиция хезмәтеннән алып язылган бер генә детектив әсәрне дә үзәккә алып сөйләшә алмыйм, гафу итәрсез, алар бездә басылган «ширпотреб»ны хәтерләтә.) Нурихан ага Фәттах исән

чагында кайда булган алар? Үсеп җитмәгәннәр, яшьрәк булганнармы? Алай дисәң, тарихи романнар «коеп» торган бүгенге әдипләребез арасында өлкән яшьтәгеләр дә бар. Каләм белән язарлык, цензурасыз, фикер ирегенә ирешердәй кыю заман җитмәгән булган, диярсез. Әйе, килде ул кыю заман. Ә кая соң кыю тарихи әсәрләр? Бөтен булганы игезәкләр кебек охшаш, ханнар ызгышы, бозык гыйшык, рус дәүләтенә яраклашу һәм тиранлык стихиясе белән булган таныш вакыйгаларның компилятив варианты. Күренеп тора ки, материалларның архивларда саклана торган байлыкларга мөнәсәбәте юк, ә зыялы укучы әллә кайчан укып чыккан җиде-сигез букинистик китаптан гына алынган.

Нурихан Фәттахның Сез җитәкләгән басмада узган елның ахырында басылып чыккан «Аклан» романын гына алыйк. Ул төгәлләнмәгән килеш калган... Борын-борын заманда Җир шарында тик бер генә – Аклан иле (Атлантида) дигән ил генә булган, аның халкы безнең борынгы бабаларыбыз һәм алар бары тик төрки телдә генә сөйләшкәннәр. Ә бит роман моннан 40 ел элек язылган. Йә, шул чор өчен кыю фикер түгелме бу?!

Тагын бер тенденция борчый. Матур әдәбият кысрыкланды. Чәчмә әсәрләргә публицистика үтеп керде. Калын-калын романнар үзенең күләмен югалткан очеркларны хәтерләтә. Автор вакыйгаларны тормыштагыча сөйләп чыга да яңгыравык исем куя. Ә сурәтләү чаралары, сюжет, образлылык турында бөтенләй оныта. Андый романнар һәм повестьлар тиз ялыктыра. Минем «Таң җиле» (Фоат Садриев), «Ком сәгате» (Камил Кәримов), «И, кылгам догам минем» (Марат Әмирхан) кебек романнар укыйсым килә.

Авторларыбыз арасында хатын-кызларның күбәюен 90 нчы елларда балкыган сәяси яңарышларның уңышы дип карарга кирәк. Һәм киләчәк турында җитдирәк уйлаганда, кызлар «тудырган» чәчмә әсәрләрдә ир белән хатын арасындагы конфликтларны, Бразилия сериалларындагыча чуалган интригаларны, бер сөяркәнең икенче сөяркәгә оештырган бәрелешләрне генә түгел, ә социаль яктан мөһим булган һәм әдәби эшләнеше матур әдәбият дәрәҗәсенә җиткән язмышлар күрәсе килә. Үзәк матбугат, аның телевизион каналлары шыплап тулган байлар «нужасы» белән генә мавыкмыйча, гади хезмәт кешесе турында да тагын язарга вакыт җиткәндер, бәлки.

**Р.Ф.** *Сез – озак еллар матбугатта эшләгән кеше. Заманында «Татарстан яшьләре» газетасын җитәкләдегез, «Социалистик Татарстан»да («Ватаным Татарстан») җаваплы вазифа башкардыгыз. Баш мөхәррир чакларыгыз сагындырамы? Хәзер берәр басманың баш мөхәррире булсагыз ниләр эшләр идегез? Хезмәттәш буларак, бездәйләргә киңәшләрегез дә бардыр?*

**И.Ә.** Киңәш бирергә бөтенебез оста анысы, ә менә өр-яңа гәҗиткә фатиха биреп, шуның тиражын ике-өч елда 100 меңгә җиткереп кара син! Берничә ел элегрәк матбугатның бүгенге хәле турында бәхәс чыккач, күптәнге хезмәттәшем шулай дигән иде. Күзгә бәреп әйткәненә үпкәләмәдем. Ихластыр, киңәш, «рецепт» бирүчеләр байтак, менә шулайрак эшлиләр аны, туганкаем, дип үрнәк күрсәтүчеләр юк дәрәҗәсендә. Инде килеп, Сезнең сорауга әйләнеп кайтыйк. Социологик тикшеренүләр шуны раслый: гәҗитләрнең 32–36 процент мәйданы сәяси язмаларга бирелә. Дөнья стандарты – 10 процент! Укучы рәсми хәбәрләргә мәйданын кызганмаган басмаларга йодрык күрсәтеп, җан азыгына урынны мул биргән басмаларга өстенлек бирә башлады. Кайбер гәҗитләрнең тиражлары ике-өч елда 30–40 меңгә җитүе шул хакта сөйли түгелме соң? Берәү дә рәсми хәбәрләрдән бөтенләй баш тартырга өндәми. Җитәкчеләрнең сәяси очрашуларын да бүтәнчәрәк язып була бит. Үрнәге дә бар. Моның өчен «Коммерсант» гәҗитендәге А.Колесников язмаларын уку да җитә. Иманым камил, рәсми хәбәр шундый рухта языла калса, укучы дүртенче битне онытып, беренче битне күзли башлар иде. Кайчагында проблеманы өйрәнү урынына тырнак астында казынуга тап буласың. Йә язманы күп нокталар белән йомгаклап куялар. Нәтиҗәсен үзең яса, янәсе, ахыргача уйлап бетер! Аннан килеп, укучыга тәти сүздән бигрәк, төгәл сүз кыйммәт. Бертөрле сөйләп, икенче төрлерәк яшәү рәвешен алга сөрүне ул өнәми. Тәти сүз дигәннән, гәҗитләребезнең теле ташка үлчим. Кайда телебезнең аһәңе, моңы, табигый агышы? Журналист аларның итәгенә ябышып түгел, ә аларны үзе җитәкләп барырга тиешле. Ә бәлки, алган акчасы биш-алты меңнән артмаган журналисттан бүтәнне көтәргә дә кирәкмидер?!

**Р.Ф.** *Үткән ел дәүләт канаты астында булган күпчелек редакцияләр «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенә керде, дөресрәге, керергә мәҗбүр булды. Акционерлык – үзегез беләсез, берләшеп, акча арттырып, үзбаш яшәү дигән сүз. Күпчелек редакцияләр, әлбәттә, үз кереме хисабына көн күрә алмый... Газета-журналларда эшләүчеләрнең бу мәсьәләгә җавапка караганда сораулары күбрәк әле бүген. Сездән, Матбугат дөньясын эчтән дә, тыштан да, идеологик һәм икътисади яктан да яхшы белгән, бу эштә «елан аягын кискән» кешедән ишетәсе килә: бу гамәлләрнең ахыры ни белән бетәр икән?*

**И.Ә.** Дәүләт, байтак вакытлардан бирле, без матбугатка киләчәктә дә ярдәм итәргә әзер, әмма акрынлап чыгымнарның бер өлешен үзегезнең җилкәгә салырга өйрәнегез, дип искәртеп килде һәм килә. Бергәләп уйлашыйк әле: чыгымнарны, дөресрәге, дәүләттән килә торган ярдәм – дотацияне ничек итеп киметергә кирәк? Фикер-тәкъдимнәр күп, хәл итү юлы бер – рекламаны түргә уздырып. Ә игълан-реклама сиңа килергә ашкынып тормаса әгәр? Чөнки ул һәр басма алдында баш ияргә ашыкмый, аны беренче чиратта тираж кызыксындыра, бүтәнчәләтеп әйтсәк, реклама ничәләп кешенең күзенә чалыныр, басманың таралу биографиясе – каладамы, авылдамы – шул кызыксындыра. «Без – яхшы, без – бердәнбер» дигән шигар белән генә аларны үзеңә каратуы кыен. Ә тираж мәсьәләсе – матбугатны сызлатып торган нәрсә. «Татмедиа», дәүләт карамагындагы барча басмаларны бер түбә астына җыеп, гомуми тиражны реклама хуҗасын кызыктырыр дәрәҗәгә җиткерергә ниятләгәндер дип беләм. Хәзер реклама барча район-шәһәр гәҗитләрендә дөнья күреп, республика басмаларында кабатланып, 300 ләп мең тираж белән дөнья күрә. Аннары, Акционерлык җәмгыяте кредитлар алып, кайсыдыр бер басманы үстерү концепциясен алга сөрергә мөмкин, икенчеләренең кыйбласын үзгәртә ала. Нинди генә яссылыкта карасак та, әлеге үзгәрешләр басмаларны агач атка атландырып калдырмаслар дип уйлыйм. Бигрәк тә милли матбугатны. Милли матбугат, балалар матбугаты, хатын-кызларга адресланган матбугат бик күп илләрдә, шул исәптән көнбатыш илләрендә дәүләт тарафыннан финансланып килде һәм килә. Татарстан кебек республикада да милли матбугатка булышлык итү мәсьәләсенә «аннан соң» дигән караш була алмый. Ник дигәндә, сүз тел, мәдәният, халык язмышы турында бара лабаса.

**Р.Ф.** *Сезнең «Идел-Пресс» коллективының хәйриячелек эшчәнлеге турында еш ишетеп, укып торабыз. Шәхсән Сез үзегез дә мәктәпләргә, китапханәләргә әледән-әле ярдәм итеп торасыз. Бу җәһәттән туган ягыгыз буалылар бигрәк тә рәхмәтлеләр дип беләм. Безнең «Казан утлары» журналына да шәфкать күзе белән карыйсыз. Безнең яшь авторларның беренче китапларын чыгаруда булышасыз. Коллектив исеменнән рәхмәт Сезгә! Базарча кырыс һәм мәрхәмәтсез заманда миһербанлылык аерым игътибарга, хөрмәткә лаек. «Идел-Пресс»ның хәйрия эшчәнлеге турында без дә язып чыккан идек. Мәрхәмәтлелек акцияләре һаман да дәвам итәме?*

**И.Ә.** Ничек кенә итеп әле! Мисал – 3 миллион 755 мең сум. Узган елда хәйриячелек, иганәчелек юнәлешендә шушы кадәр акча тотканбыз. Китаплар бүләк иткәнбез, үзебезнең хисапка җиде китап бастырып чыгарганбыз, мәктәп-гимназияләргә, балалар бакчаларына булышлык иткәнбез, милициянең терәк пунктын шефлыкка алганбыз, стипендиантларыбызны булдырганбыз, күп балалы гаиләләргә, колониядәге тоткыннарга ярдәм кулы сузганбыз, мәчет-мәдрәсәләрне дә онытмадык. Яшермим, дәрт бар, дәрман юк дигәндәй, бөтенесенә ярдәм итеп тә булмый. Үпкәләүчеләр, ишекне каты итеп ябып чыгучылар да юк түгел. Үземнең андыйларга да үпкәләгәнем юк. Мәҗлес уздырырга сорамый бит, китап бастырырга... Хәер, гозернең дә төрлесе була. Бервакыт миңа Уссури юлбарысларын саклау фонды төзибез дип килделәр. Төзегез, минәйтәм, кем комачаулый соң? Акча юк, диләр болар. Әйтерсең лә Татарстанның үзенең киек һәм кош-кортлары ярдәмгә мохтаҗ түгел!

**Р.Ф.** *Белгән, аралашкан кешеләр иң әүвәл Сезнең кешелек сыйфатын бәялиләр: ул – егет кеше, ул – булган кеше, диләр. Үзем дә шуңа инанганмын. Менә шул шәхескә 60 яшь тулып килә. Күп күргән, күп кичергән, министр да, журналист, мөхәррир дә, зур хуҗалык җитәкчесе дә булган, балалар үстергән, шул ир-егет үзенең үткәненнән канәгатьме? Эх, шуны эшлисе калган, теге вакытта менә болай итәсе булган икән дигән уйлар килгәлиме?*

**И.Ә.** Килми! Яшермим, абынган-сөрлеккән чаклар да булмыйча калмагандыр. Вакыты-вакыты белән борын да канагандыр, җан да җәя бавы кебек тартылгандыр. Кемгәдер охшап бетмәгән гамәлләр эшләгәнемне дә беләм. Әмма бернәрсәгә дә үкенмим. Димәк, Ходай шулай язган. Бөтенесе шома гына, җайлы-ипле генә тәгәрәсә, сагынып сөйләргә ни калыр? Минем өчен шул ачык: байтак елларны сыйдырган гомеремдә йөз кызартырлык гамәл кылганымны хәтерләмим.

Иртәгә – яңа көн, яңа туган көннәр мәшәкатьләре дә газиз халкым мәнфәгатьләре белән үрелеп барыр дигән өметтә яшим.

*2008*

## *«ТАЯНЫЧ УЛ — ХАЛЫК...»*

*(Драматург Туфан Миңнуллин белән әңгәмә)*

**Равил Фәйзуллин.** *Туфан Абдуллович! Бу әңгәмә барышында мин Сиңа «Сез» һәм «ага» сүзләре белән мөрәҗәгать итмәкчемен. Ихтирамым да зур, беркадәр яшь аермалары да бар...*

**Туфан Миңнуллин.** Алай итмик әле, Равил! Төрки-татар дөньясында үзара якыннар һәрвакыт Син дип сөйләшә. Без бит замандашлар, әдәбиятка да бервакыттарак килдек, кочаклашып йөрмәсәк тә, бергә дустанә гомер кичердек, иҗат иттек, балалар үстердек, иң мөһиме – фикердәш була алдык. Шуңа күрә бу әңгәмә инде акыл утырткан ике өлкән әдип сөйләшүе булсын.

**Р.Ф.** *Килешәм. Син безнең журналыбыз кунагы бүген, шуңа күрә сүз, нигездә, Синең иҗат һәм аңа бәйләнешле мәсьәләләр тирәсендә булыр, хуҗа сыйфатында сорауларны мин бирәм булып чыга инде.*

*Моннан нәкъ ун ел элек (Алмалы ел иде ул! Быел да шуңа охшап тора.) Синең туган ягың Кама Тамагында, туган авылың Олы Мәрәтхуҗада татар әдәбияты-сәнгатенең кабатланмас бер бәйрәме булган иде. Япь-яшь Туфанга нибары 60 яшь. Татарстанның гаҗәп матур урыны – Идел белән Каманың тоташкан урынында, биек ярда (ялгышмасам, исеме Айгыртау) татар рухын биеккә күтәргән Дуслар Учагы дөрләгән иде. Көн матур, чакырылган кунаклар берсеннән-берсе күркәм, бәйрәм хуҗасы – бөек... Матур сүзләр, мәңгелеккә омтылыш... Шул вакыйгадан соң ун ел гомер үткән дә киткән. Ул бәйрәм Синең үзеңә дә ошагандыр дип уйлыйм. Мөгаен, гомерем булса, ун елдан соң фәләннәрне эшләрмен дип уйлап хыяллангансыңдыр, дөньяда фәлән уңай үзгәрешләр булыр дип фараз кылгансыңдыр... Йә, Туфан ага, XXI гасырның 5 нче елында кәефләр ничек? Үзеңнән, дөньядан канәгатьме?*

**Т.М.** Минем яшьтә кәеф иң беренче чиратта саулык-сәламәтлек белән бәяләнә. Ул яктан Ходайның биргәненә шөкер әлегә, кем әйтмешли, әкрен генә йөгереп йөрибез. Аннан инде безнең кәеф иҗат белән нык бәйләнгән. Анда да, иншалла, тик торган юк. Өйдә дә иминлек. Димәк, үземнән канәгать, зарланырга хакым юк.

Дөньядан канәгать дип әйтә алмыйм. Мин һәм син теләгәнчә әйләнми дөнья тәгәрмәче. Иң авыр кичерелгәне – 90 нчы еллар башында Рәсәйдә шәйләнгән демократиянең бетүгә таба баруы. Бигрәк тә күсәкнең юан башы безнең тарафларга төшә. Ничәмә-ничә гасыр хыялланган дәүләтчелеккә ирешү юлында җилкенеп алган идек, Суверенитет турында Декларация кабул иттек, Төп законыбыз Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты. Үзен татар дип санаган кайсы кешенең йөрәге әрнемәс бу хәлгә. Шуңа каршы тора алмау чарасызлыгы җанны каезлый. «Нишләргә?» дигән сорауны үземә еш бирәм, тик җавабын таба алмыйм. Сүз шәхсән үзем турында гына бармый. Минем күңелемнән «татарның үз дәүләте булырга тиеш» дигәнне беркем дә тартып ала алмый. Мине яратмаган илне мин Ватаным дип әйтә алмыйм. Ничек һәр татарның күңеленә шул хисне сеңдерергә? Нишләргә?

**Р.Ф.** *Язучы эшчәнлегенең ахыр нәтиҗәсе – китап. Хезмәтләре театр, спектакльләр белән бәйле булган драматургларның китапка карата фикерләре шагыйрьләр яки прозаикларныкыннан, бәлки, беркадәр үзгәдер. Ни генә булмасын, китап барыбер китап инде ул! Берничә ел элек Синең ун томлык әсәрләрең басылып чыкты. Сирәк була торган куанычлы*

*хәл. Соңгы дәвердә безнең заман язучыларыннан бары Т.Әйдинең генә мондый санда томлыклары чыга алды. Үткән заман классик әдипләрнең дә күптомлы сайланма әсәрләре әзерләнә дип беләм. Әйе, язу – бер хикмәт, китап итеп чыгару – үзе бер тарих, ә менә укучы күңеленә барып ирешү... Менә шул соңгысы – китапның кешеләргә барып ирешүе яки ирешмәве турында Синең фикерне беләсе килә. Хәтереңдәдер, әле май аенда гына булып үткән язучылар съездында да байтак сүз булды бу хакта. Китап – безнең тарихыбыз, данлы үткәнебез. Китап безнең киләчәгебезме?*

**Т.М.** Бүгенге көндә чын һәм хәтта чын ук булмаган язучыга да китап чыгару зур проблема түгелдер. Республика җитәкчеләре ярдәмнәреннән ташламыйлар. Бүген төп мәсьәлә – чыннан да, китапның укучыга барып җитүе һәм укылуыдыр. Монда проблема баштан ашкан. Китап укучылар азайды. Бу татарда гына түгел, күпсанлы урыста да шулай. Аларның китап, журнал тиражлары бик түбән. Күрәсең, мондый хәл заман шаукымыдыр. Бүген кешенең йөрәге һәм башыннан алда корсагы йөри. Корсак кайгысы белән генә яшәүченең билгеле инде рухы ярлы була. Рухы ярлы кешегә китап кирәкми. Ләкин бу вакытлы фаҗигадер. Кешеләребез, күңеленә азык җитмәвен тоеп, эзләнерләр һәм китапка килеп юлыгырлар дип өметләнәм.

**Р.Ф.** *Театрсыз милләтне күз алдына китерү кыен. Дөньяда без аңлаган классик мәгънәдә театрлары булмаган, әмма яшәгән һәм яшәячәк милләтләр дә бардыр, бәлки. Безнең шартларда театр – халыкның милләт булып яшәвенең бер билгесе. Әйтик, халыкны рухи берләштерүдә, телебезне саклауда театрның роле бик зур. Шуннан чыгып, беләсе килә: театрларыбызның бүгенге хәлләре ничек? Әйтик, тагын 15–20 елдан аларны ничек күз алдына китерәсең?*

**Т.М.** Дөньяда театры булмаган милләт юк. Театрның формалары төрле-төрле. Без ияләшкән, рәсмиләштерелгән театрның формасы бердәнбер түгелдер. Татарда рәсми исем алган театрга хәтле күңел ачулар булмаганмы? Туйлар театр түгелмени? Кич утырулар да театр. Иң зур театрыбыз – Сабан туе. Анда милләтне милләт итеп саклый торган компонентлар тулып ята. Тел осталарының ярышлары да даими булып торган. Әйтик, казакъ, кыргыз халкында айтыс дип аталган бәйгеләр бүген дә үткәрелә. Татарларда да булган ул, әле без Мәскәүдә укып йөргәндә Измаил паркы дип аталган җирдә Нижгар, Тамбов, Пенза төбәкләреннән чыккан татарларның яшьләре кара-каршы такмак әйтешәләр иде. Шулай итеп телләрен саклыйлар һәм чарлыйлар иде. Егет белән кызның кара-каршы басып такмак әйтешүе – менә дигән театр. Профессиональ театрыбызга килгәндә, ул, әлбәттә, яшәячәк. Нинди булуы мине әллә ни борчымый. Татарча сөйләшүче, татарча фикерләүче, татар җанлы театрыбыз гына булсын.

**Р.Ф.** *Хәтердә, 80 нче еллар уртасында «Әлдермештән Әлмәндәр»не Бөтенсоюз телевидениесеннән күрсәттеләр. Без, бер төркем язучылар, Пицунда иҗат йортында идек. Җыелышып утырдык телевизор каршына. Бүтән милләт язучылары да байтак җыелды. Карыйбыз: экранда үзебезнең яраткан артистлар, үзебезнең тел, җанга якын мохит... Күз яшьләрен китерер дәрәҗәдә горурлык! Күңел бәйрәме! Менә шундый матур сәгатьләр бүләк иттең Син безгә ул чакта! Хуш, болары – үткән заман. Татар драматургларының, шул исәптән Синең әсәрләрең бүтән илләр, халыклар сәхнәләрендә куеламы хәзер?*

**Т.М.** Әгәр без СССРдан аерылып чыккан союздаш республикаларны мөстәкыйль ил дип кабул иткәнбез икән, аларда минем пьесалар куелгалап тора. Бигрәк тә Казакъстанда, Үзбәкстанда. Россиядәге башка милли театрларның репертуарында мин язганнар бар. Бигрәк тә Төньяк Кавказ республикаларында мин популяр. Урыс театрларында – юк. Хәтта Казаныбыздагы урыс телле театрларда да мине драматургка санамыйлар. Хәер, мине генә түгел, гомумән, татар драматургиясен алар санга сукмыйлар. Күрәсең, безнең дәрәҗәгә «төшәселәре» килми. Урыс әйтмешли, черт с ними. Миңа үзебезнең театрлар да бик җиткән, алар бер дә урысныкыннан (урысныкы микән әле бүгенге урыс театрлары) ким түгелләр.

**Р.Ф.** *Соңгы елларда Камал театры инициативасы белән «Яңа татар пьесасы» дигән конкурс-ярышлар (нишләптер конкурсларны соңгы вакытта «бәйге» дип яза башладылар. «Бәйге» сүзе, минемчә, ул күбрәк ат чабышларына карый) оештыралар. Әлбәттә, җиңүчеләр*

*билгеләнә. Бу конкурсларга Синең карашың? Һәм өстәп: татар драматургиясенең киләчәге кемнәр кулында?*

**Т.М.** Конкурсмы, бәйгеме – миңа барыбер. Тегесе дә монысы да ярышу инде аның. Мондый гамәлне мин хуплыйм, ярышырга яратам. Элеккеге ярышларда катнаша идем, соңгысында катнашмадым. Чөнки конкурсның шартлары канәгатьләндермәде. Анда, урыс телендә язылачак драма әсәрләре дә кабул ителә, диелгән иде. Татар телендә язылмаган пьеса татарныкы була алмый дип саныйм. Чөнки тел – әдәбиятның төп үзәге, умыртка сөяге. Татар телендә яза белмәгән язучы татарларны да мин татар язучысы дип атамыйм. Гафу итсеннәр. Татар язучылары буласылары килсә, татарның теленнән җирәнмәсеннәр, объектив сәбәпләр эзләп акланмасыннар. Ана телсез милли әдәбият ул – яһүдләр теориясе. Алар безне кыйб-ласызлыкка өндәп, үзләре Израильгә карыйлар. Без башка халык, ни кызганыч, безнең Израилебез юк, без үзебезне үз телебез белән сакларга мәҗбүр ителгән. Әлегә, дип тә өстәп куйыйм. Драматургиябезнең киләчәге кемнәр кулында дигәндә, татарча камил язучы татарлар кулында булыр дип өметләнәм.

**Р.Ф.** *Фараз итеп, әгәр Камал театры, байтак дистә еллар аның төп хуҗасы М.Сәлимҗанов дөньяда булмаса, бүгенге Туфан Миңнуллин шушындый зур була алыр иде микән?*

**Т.М.** Мин Марсельне татарның бөек режиссеры дип саныйм һәм аның белән бергә иҗат итү бәхете тигәнгә язмышыма рәхмәтле. Әмма Марсель булмаса, мин дә булмас идем дип әйтергә телем әйләнми. Мин үземне мөстәкыйль фикер йөртүче шәхес дип исәплим. Кемнеңдер итәгенә ябышып дәрәҗәгә ирешү минем өчен ят нәрсә. Мин, драматург буларак, режиссерлар Сабир Өметбаев, Равил Тумашев, Гали Хөсәеновларга рәхмәтемне әйтеп торам. Сабир абый Өметбаев, мәсәлән, Минзәлә театрында беренче пьесамны куйды. Әсәр буларак шактый ук йомшак булса да куйды. «Үзең язганны үзең сәхнәдән кара, үз ялгышларыңны күрсәң, драматург булачаксың, күрә белмәсәң, театрга пьеса күтәреп килмә» диде. Аны ничек онытасың...

Әлбәттә, Марсельнең миңа тәэсире зур булды. Ул чын укымышлы, эрудицияле шәхес иде. Ләкин ул да мин язганнарга мохтаҗ иде. Төп мәсьәләләрдә фикерләр берлеге безне якынайтты, берләштерде. Һәр драматургның бәхете – аны аңлаган режиссерның язмышына туры килүе. Бүген мин Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев белән уртак тел табарга тырышам, Түбән Кама театры режиссеры Рөстәм Галиев белән дә борчагыбыз пешә.

**Р.Ф.** *Син бөтен табигатең-холкың белән карьера өчен яратылган кеше түгел. Гөбедән чыккан тавыш белән турыдан ярып сөйләшү, ачымы-төчеме, хакыйкатьне ярып салу... Син дипломатик кануннарның бөтен нечкәлекләрен белеп бетергән кеше дип уйламыйм. (Ә кем белә, бәлки, киресенчәдер...) Шулай да... Син, карьера кешеләренә хас булганча, хакимият-власть тирәсеннән беркайчан да китмәдең. Язучылар оешмасы парторгы, соңрак шул оешманың рәисе. СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Дәүләт Советы депутаты... Хәзер дә Татарстан Дәүләт Советында даими комиссия рәисе урынбасары... Малың бар, даның бар дигәндәй... Нигә Хемингуэйлар кебек табигать стихиясендә ял итеп, кирәк чакта бар вакытны фәкать иҗатка гына биреп яшәмәскә?*

**Т.М.** Килешеп бетмим, Равил. Карьерага омтылмаган кеше шәхес була алмый. Ә мин үземне шәхес дип саныйм. Ләкин нинди карьерага омтыласың бит. Мине иҗат карьерасы һәрвакыт камчылап торды. Бүген әйтергә ярыйдыр инде, мин Туфан Миңнуллин дигән исемне алу өчен тырыштым. Кайберәүләр бит язган әйберләре астына фамилияләрен куялар да Татарстанның атказанган фәләне дип өстиләр. Шул өстәмәләрсез генә кем икәнемне белсәләр, мин максатыма ирешәм дип шатланам. Әйе, ул яктан чын карьерист мин. Ләкин мин кемнәрнеңдер садакасы хисабына, «служебный карьера»га ирешергә теләмәдем. Андый карьерага ирешер өчен әллә ни тырышырга кирәкми бит, кемнәргәдер ярый белергә генә кирәк. Минем дәрәҗәле исемнәрем шактый, һәм алар миңа язучылык һөнәре өчен мин нә-чәлство тирәсендә буталып йөри башлаганчы ук бирелгәннәр. Хезмәтемне вакытында күреп

алып бәяли белгәннәргә рәхмәт. Депутат булып сайлануларым да шуңа бәйләнгәндер дип уйлыйм.

Власть башында утыручыларга «ярый белүем»нең хикмәте нидәндер, өзеп әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, ялагайланудан түгел. Күпләр хакимияттә утыручыларның психологиясен аңлап бетерми. Анда ялагайларны өнәп бетермиләр. Чөнки ялагайлар – ышанычсыз кешеләр. Алар, җае чыкса, үз туганнарын да саталар. Өстәгеләр мөстәкыйль шәхесләрне хөрмәт итәләр. Әлбәттә, ул мөстәкыйль шәхес өстәге икенче мөстәкыйль шәхеснең урынын биләргә тырышса, ул чакта аңа каршы көрәш башлана. Җиңелгәнне анда кызганмыйлар. Мин берәүнең дә урынын алырга тырышмадым, берсенең дә тәхетенә кызыкмадым, әйтәсе сүзем җанны борчыганнан әйтелә, ихластан сөйләнелә. Нәчәлство без уйлаганча ук акылсыз түгел, нәрсәнең ни өчен әйтелгәнен бик яхшы аңлый.

Ә инде Хемингуэйча яшәп иҗат итүгә килгәндә, мин алай да яшәп карадым. Ләкин без яшәгән ил Хемингуэйлар өчен түгел. Кешенең кадере булмаган илдә алай яшәп булмый, кычкырып ачтан үләсең. Телиме-теләмиме, кеше үзе яшәгән мохиткә яраклаша. Без нихәтле генә мөстәкыйль булырга тырышсак та, имгәтелгән буын – безгә үзебезчә яшәргә тулы ирек бирелсә дә, югалып калабыз, ирек өчен көрәшүебез үзара сукранышудан узмый.

**Р.Ф.** *Сүз җебенең очын югалтмыйча, әңгәмә башын искә төшерик әле. Син «Суверенитет турында декларация кабул иттек. Төп законыбыз Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты» дисең. Ә кем гаепле?*

**Т.М.** Үгезнең мөгезен эләктерәм дисең инде. Кем гаепле? Ялгышмасам, урысның бер зыялысы да заманында Россиянең мөшкел хәлгә төшкәненә «Кто виноват?» дигән сорау куйган булган. Кемнәрнедер гаеплисе дә килми. Бардыр инде, Алтын Урда империясен саклый алмаганбыздыр. (Хәер, һәр империянең таркалырга тиешлеген тарих исбатлап тора.) Болгар дәүләте җимерелүендә дә үз кулыбыз юк түгелдер, Казан ханлыгын да бар төркиләр бергә җыелып яклый алмадык. Яулап алучы дәүләт, табигый хәл, үз кагыйдәләре белән эш йөртә. Шуның өчен яулап алган бит инде ул, татарга яхшы булсын дип бәреп кермәгән. Бер тарихи факт мине өметләндерә – дүрт гасыр ярым албасты астында яшәсәк тә, милләт буларак югалмадык. Берничә тапкыр үзебезнең саклану иммунитеты исән икәнлекне күрсәтә алдык. Бигрәк тә соңгысы – Декларация кабул иткән көннәрдә дәррәү уянуыбыз өметне көчәйтте. Без бүген каршыбызда кем торганны күреп чигендек, кем гаепле? Әлбәттә, кайбер конкрет мәсьәләдә кемнедер гаепләп тә буладыр. Ләкин, зинһар, кирәгеннән артык каты кагылып бер-беребезне рәнҗетешмик. Тарихи ситуацияне дөрес бәяләп чигенә белик. Әмма һәрдаим көрәшкә әзер булырга кирәктер. Әйткәнемчә, рухыбызның сәламәтлеген сакларга өйрәник. Әмма болар гына төгәл һәм тулы җавап түгел. «Кем гаепле?» дигән сорау кала бирә. Бәлки, аңа Син дә, бүтән дә җавап эзләр. Кем гаепле?

**Р.Ф.** *Нигә депутатларның берәрсе җитди политик акция ясамады? Әйтик, протест йөзеннән мандатыннан ваз кичмәде? Парламентның яртылабы элекке состав, ягъни 90 нчы еллардан бүгенгегә кадәр депутат булып торучылар бит. Заманында үзләре үк чыгарган законнарны үзләре үк сүттеләр. Депутатлары шундый булгач... Глобаль уйлаучы даирәләр, дөнья җиһангирләре диюем, «бу халыкны теләсә нишләтеп тә була» дип тә уйлыйлардыр, бәлки?*

**Т.М.** Бу – чын шагыйрь соравы. Сәясәтче мондый сорауны бирмәс иде. Мин дә сәясәтче түгел. Шуңа күрә җавабым да үзебезчәрәк булыр инде. Бәлки, ул җавап та түгелдер, уйлану гынадыр. Син әйткәнчә, минем дә протест ясап депутат мандатыннан демонстратив рәвештә баш тарту уе башыма килгәли. Соңгы елларда бу теләк көчәя төште. Ләкин шунда әтинең әнигә әйтә торган бер сүзе искә төшә. Әни нигә дә булса ризасызлык белдереп тузына башласа, әти: «Тукта, кызма әле син, Халисә», – дия иде. Әни бераз сүрелгәч, икенче төрлерәк уйлый иде. Ярый, синеңчә булсын, мин депутат мандатын атып бәреп, әйтәсе сүземне әйтеп, сессиядән чыгып киттем ди. Шуннан ни була? Ни үзгәрә? Ни кызганыч, берни дә үзгәрми. Берәүләр мине яклап дуларлар, берәүләр кызганырлар, берәүләр ялгышты диярләр, дурак дип әйтүчеләр дә табылыр. Заманында мин Минтимер Шәрипович президентлыкка сайланганда

аның яклаучысы (доверенное лицо) булдым. Шунда миңа, президент Дудаев кебек булсын иде ул, дип әйтүчеләр була иде. Мин аларга, президент Дудаев кебек булсын өчен халкың чечен кебек булырга тиеш, дип әйтә идем.

Суверенитетның беткәннән-бетә баруын күреп дулыйм да, күмерем бераз сүрелгәч, уйлыйм: «Тукта әле, дим, минем протест ясап китүемә караганда, сүземне туктаусыз трибунадан әйтеп тору отышлырак түгел микән?» – дим.

**Р.Ф.** *Син – «Татар кодексы» Кануннамәсенең төп авторы. Аның тезислары ун еллар элек «Казан утлары»нда да чыкты. Соңрак, тәфсиллерәк итеп (яңадан редакцияләнгән варианты диикме), «Идел» журналында басылды. Миңа калса, бик җитди Кануннамә ул. Яһүдләрнекен әйткән дә юк, Төрекмәнбашы Ниязовның да (ул, мөгаен, коллектив хезмәттер инде) «Рухнамә»се дә гыйбрәтле. Аның белән татар укучысы да танышса, файдага гына булыр. Әлбәттә, һәр халыкның үз карашлары, үз кануннары, үз идеаллары... «Татар кодексы»н халык аңына сеңдерү өчен нишләргә кирәк?*

**Т.М.** Төгәл генә белмим. Без өстән әйтелгәнне хакыйкать дип кабул итәргә өйрәтелгән. Милләтне саклауның эчке динамикасын үзләштермәгән. Татар теле нигә кирәк, татар теле белән кая барып була, дип сөйләнүче татарга җан иреге турында сөйләп, ни эш кырып була икән? Милли хисләре булса да, хакимият башында утыручылар гына милләтне саклый алмыйлар. Аларга таяныч кирәк. Ә таяныч ул – халык. «Мин – татар» дигән хис һәр татарның җанында булмаса, Мәскәүне сүгүдән ни файда? Әгәр җаныбызда татарлык була икән, Мәскәү дә, Вашингтон да пычагым да кыра алмый. Менә шуны аңлатырга тырыштык Кодекста. Аны мәктәпләрдә өйрәтеп яшь буынның җанына сеңдерә алсак иде. Ни кызганыч, мәктәптә укытучылар арасында аны аңлатырдайлары күп түгел. Татар дигән сүзне кычкырып әйтергә курыкканнар үзләре кебекләрне тәрбияли. Югыйсә татар булып татар өчен көрәшүнең ни начарлыгы бар? Мин, мәсәлән, татар дип әйткәндә бүтәннәрне түбәнсетмим, үземне генә зурлыйм.

**Р.Ф.** *Без, язучылар, күп дистә еллар Язучылар оешмасына елышып яшәдек. Шунда җыелдык, утырышлар уздырдык, мактаныштык, тәнкыйтьләдек һәм тәнкыйтьләндек... Оешмасыз иҗади яшәүне күз алдына китерү кыен иде. Чөнки күбебезнең иҗади язмыш (иҗади яктан бәяләнү, китаплар чыгаруга булышлык, исем-премияләр алу, югары органнарга, сайлауларга тәкъдим итү һ.б.; шулай ук көнкүреш-матди хәлләр – фатир, пенсия, путевка-юлламалар алу һ.б.) Язучылар оешмасына бәйле иде. Хәзер вазгыять бүтән. Шулай да гадәт-менталитет белән без һаман да оешмага ниндидер өмет белән карауны дәвам итәбез. Гәрчә иҗтимагый оешма буларак Язучылар берлегенең мөмкинлекләре чикле хәзер. Синеңчә, оешманы язучылар үзләренең туган йорты кебек күрсеннәр өчен яңа сайланган җитәкчеләргә һәм, гомумән, язучылар коллективына ниләр эшләргә кирәк?*

**Т.М.** Төрле хәлләр булды. Язучылар оешмасы коммунистлар оештырган кыса диючеләр табылды. Бәлки, шулайдыр. Күпләргә Язучылар берлеге кирәкмидер дә. Миңа да шәхсән аның практик яктан кирәге юктыр. Ләкин без бер һөнәр кешеләре буларак очрашып сөйләшмәсәк, фикер уртаклашмасак, кирәк чакта үзебезнең катгый сүзләребезне әйтмәсәк, ни булыр? Җыр да бар бит:

Агай-эне – ак мыек,
Бер-беребезне какмыек.
Каккан-суккан чакларда да
Бер-беребезне яклыек.

Без барыбыз да аерым-аерым, «качып» эшли торган һөнәр ияләре. Озак «качып» йөргәннән соң агай-энеләрнең нишләп йөргәнен, ни уйлаганын беләсе килә. Үзең турында сөйлисе килә. Менә шундый чакта бергә җыелып аласың да рәхәтләнеп сөйләшәсең. Өнәп бетермәгән кешеләреңне дә сагынган буласың. Кеше – табигатьтә көтү инстинкты белән яшәүче җан иясе. Көтү булып яшәсәк тә, көтүчеләрне яратып бетермәүче «кәҗәләр» без. Шуңа күрә безнең рәисләребез дә үзләрен чыбыркы аскан көтүче дип хис итмәсеннәр иде. Ә андый көтүчеләр булгалады арабызда. Көтүче роленә кергәч, үзләрен зур язучы дип тә уйлады

кайбер бахырлар. Мин Язучылар берлеген без татарларга бигрәк тә кирәк оешма дип саныйм һәм аның җитәкчеләре безне татарлык идеясе тирәсендә берләштерергә, яшь талантларны барларга, аларга юл ачарга булышырга тиешләр дип уйлыйм.

**Р.Ф.** *Кеше, телиме-теләмиме, барыбер кемгәдер, нәрсәгәдер хезмәт итә («нәрсәгәдер» дигәнне ниндидер идея-максатка дип әйтүем). Ахыр чиктә Синең иҗат та, минем һәм фәләннең иҗаты да җәмгыятьнең билгеле бер ихтыяҗларына хезмәт итә. Элек коммунистик партия әгъзалары идек... Хәзер дә төрле партияләр җитәрлек. Ялгышмасам, Син хәзер «Бердәм Россия» фиркасе әгъзасы. Депутат булып та шул партиядән үттең шикелле. Классик драматург, депутат, элеккеге коммунистның (берәр ел Язучылар оешмасының парторгы булып та тордың бит әле) бүгенге идеологик кредосы нидән гыйбарәт?*

**Т.М. «**Идея» дигән нәрсә бар. Шул сүз тамырыннан чыккандыр – «идеал» дигән төшенчә бар. Янә дә сәясәтчеләр ясаган идеология дә бар бит әле.

Белгәнем кадәренчә, коммунистик идеянең бер генә начарлыгы да юк. Кешеләр, кайсы расадан, кайсы милләттән булуларына, тормыш баскычының кайсы басмасында басып торуларына карамастан, тигез хокуклы булырга тиешләр. Начармыни? Байлыкка шул байлыкны җитештерүчеләр хуҗа булырга, теге яки бу табигый шартлар аркасында кеше эшкә яраксыз икән, андыйлар җәмгыять тарафыннан якланырга тиешләр. Начармы? Безне бердәнбер сагайткан нәрсә – коммунистик идея дөньяны кирәгеннән артык материальләштерә, кешеләрне диннән аера. Коммунистик идеянең кешеләрнең аңына үтеп керә алмавының сәбәбе, бәлки, шундадыр да. Ул идеал була алмады. Кешене рухыннан аерырга ярамый. Һәр идеяне дә яхшы яки начар максатта файдаланырга була. Рухы ярлы, белеме сай, күңеле саф булмаган кешеләр иң изге китабыбыз Коръән Кәримнән дә әшәкелек эзләделәр. Авыр булса да әйтергә туры килә, безнең бер өлкән язучыбыз «Коръән серләре» дигән әсәр язып, изге китапны пычратты.

Коммунистик идеяне большевикларваклады, аңардан үзләренең диктатурасын кертү идеологиясе ясадылар. Идеяне әкияткә әйләндерделәр. Без аңа ышанмый башладык. Коммунизм төзү идеясе мәзәк-анекдотлар материалына әверелде. Экономика законнарын белмәгән надан җитәкчеләр хәерче СССРда егерме елдан коммунизм булачак дип игълан иттеләр. Хәер, кем белә, бәлки, ул наданлыктан да булмагандыр, алданырга өйрәтелгән халыкны тагын бер тапкыр алдау өчен махсус уйланылган сәясәт булгандыр. Андый алдаулар күп күрелде шул. Шуны бүгенге сәясәтче «демократлар» бик оста файдаланып, властька менеп утырдылар. Коммунистик идеягә халыкны каршы куеп, коммунистлар партиясен тараттылар. Әлбәттә, алдау ысулы белән эш йөрткән партия кайчан да булса бер таралырга тиеш иде. Ләкин мин чын күңелемнән ышанып әйтәм, коммунистик идеянең төп тәгълиматлары яшәргә тиеш. Ерткыч капитализмның акулаларына каршы үзенең дәлилле сүзен әйтеп барырлык көч яшәргә тиеш. Чөнки халыкны алдау бүген дә дәвам итә. Ләкин коммунистик идея өчен көрәшүчеләр, Дума депутатлары кебек, үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен генә идея хисабына яклаучылар булырга тиеш түгел.

Күзәтүләрдән чыгып шундый нәтиҗәгә дә килдем әле мин: Рәсәй дигән дәүләттә нинди генә идея белән кайсы гына партия хакимияткә килмәсен, тулаем гомумхалык файдасына берни дә үзгәрми. Барысы да халык исеменнән властьны эләктереп алалар да халыкны оныталар. Шундый илдер инде бу, күрәсең.

**Р.Ф.** *Син – матди яктан каләм ияләре арасында иң хәлле (бай дисәң дә ярыйдыр) язучы. Газетадан укып белдем: бер елны Синең еллык керемең 1 млн. сумнан артык булган икән. Моңа Син хәләл хезмәт һәм булдыклылыгың белән ирешкәнсең. Бик әйбәт. Язучы халкына да гел хәерче булырга димәгән. Акчаны ирекkә юл диләр. Асылда, иҗат кешесе иректә булырга тиеш тә. Матди бәйлелек мескенлеккә тарта. Бер шагыйребез юкка гына болай язмагандыр:*

*Илһамлы каләме өстеннән*
*гомере буе*
*карап торды ипи күзе.*

*Син, минемчә, моннан азат. Ирек, иҗат, җәмгыятьтәге урын кебек категорияләр (бәлки, төшенчә дип әйтергәдер) турында Синең кебек шәхес ни уйлый икән? (Иҗат кешеләре дә төрле бит әле: музыкант, сынчы-архитектор, рәссам, артист һ.б.) Хәерче килеш олы сәнгать тудырып буламы?*

**Т.М.** Әйе, булмый. Хәерче, теләнче шәхес була алмый, ә шәхес булмаган кеше иҗат итә алмый. Әмма байлык та иҗат итәргә бердәнбер гарантия түгел. Бай хәерче, бай теләнчеләр дә була – шуны да онытмыйк. Син мине бай дип атыйсың. (Шулай язып өйгә рэкетирлар җибәрмә тагын! Өебездә чын караклар кызыгырлык әйберләр юк.) Әлбәттә, мин акчасыз кеше түгел. Ләкин мин аңа табынмыйм. Кергәнен «туздыра» барам. Ничек туздырганымны оныкларым беләә. Минем дә бит муеннан бурычка батып акчасыз утырган елларым бар иде. Акча миңа мирас булып калмады. Ул чакта да мин хәерче, теләнче булмадым. Иң авыр сугыш елларында ачлыктан шешенгәндә дә әни безне теләнергә чыгармады. Аңардан берәр әйбер сораганда да, «җыламыйча, шыңшымыйча сора» дия иде. Бик тә яшәргә теләсәң, тырышасың инде ул, акчасы да табыла. Мин бит авыл баласы, бүген тапканны бүген кабып бетерүче түгел. Алдагысын да уйлыйсың. Бүген, мәсәлән, чын картлыгым турында да уйлыйм. Дөньяда мәгънәле итеп яшәргә тырыштым – шул гына.

«Ипи күзе» бөтенебезгә дә карап тора. Татарда хәерче язучы юктыр ул. Акчасы чамалылар күп, хәерчеләр юк, Аллага шөкер. Гомумән, хәерчелек, теләнчелек татарга хас сыйфат түгел. Җыламыйк.

Җан биргәнгә җүнен бирә –
Үзе яраткан Ходай, –

дип җырлыйлар безнең авылда.

**Р.Ф.** *ПЕН-клуб эшчәнлегеннән бик азлар хәбәрдар. Халыкара бу оешма бүлегенең Татарстанда оештырылуына да ун елга якын. Оештырылган көннән башлап Син аның президенты саналасың. Бу оешма һәм аның эшчәнлеге турында укучыларыбызга беркадәр мәгълүмат бирсәң икән...*

**Т.М.** Бу турыда, минемчә, байтак язылды инде. Гәҗит укыштырып, радио тыңлаштырып баручылар беләдер. Укымаганнарына сүз әрәм итеп сөйлисем килми, барыбер укымаячаклар. ПЕН-клуб – безнең язучыларыбызны, турыдан-туры чит илләр даирәсенә чыгып, татар әдәбияты, татар тарихы, татар кешесе белән бүтәннәрне таныштыручы оешма ул. Безне чит илләрдә белмиләр. Мәскәү безне чит илләр күзеннән яшереп саклады һәм саклый. ПЕН-клубның бердәнбер вазифасы шул. Арабызда шул оешмага каршы көрәшеп маташучы ахмаклар да булды. Нишләтәсең, анысы да татарлык.

**Р.Ф.** *Син Язучылар оешмасында рәислек иткән чорда, «Татарстанның халык язучысы», «Татарстанның халык шагыйре» дигән исемнәр булдырылды. Югары оешмаларны шушы исем кирәклегенә күндердең. 1986 елдан башлап унсигез кешегә бирелде бу исем. Шуларның унбере вафат, җидесе исән. Синең үзеңә дә бу исемне күптән бирергә кирәк дигән фикерләр булды. Имеш, Син үзең теләмисең икән... Хикмәт нәрсәдә? Гомумән, бу исем турында фикерең?*

**Т.М.** Имеш, димә, Равил. Теләмәгәнемне Син үз колагың белән ишеттең. Роберт Миңнуллин «Безнең дәрәҗәгә төшәсе килми Туфан абыйның» дип төрттереп тә куйды. Аңардан сенсация ясарга кирәкми. Сәбәбе бик гади – без андый исемне булдырырга йөргәндә, аны бик сирәк язучыларга гына бирерләр дип уйлаган идек. Күп дигәндә өч-дүрт шагыйрь һәм язучы булыр дигән идек. Андый югары дәрәҗә өчен унсигез кеше күп ул. Мин ул исемне йөрткән беркемне дә кимсетергә теләмим. Бары тик шул өч-дүрт арасына керергә үземне лаек түгел дип кенә саныйм. Әйткәнемчә, бүген миңа Туфан Миңнуллин дигән исем бик җиткән. Дан өстәмәгән бүләккә кызыгырлык яшьтән узганмындыр, ахрысы. Бөтен бүләкләрне, дәрәҗәле исемнәрне үзең белән алып китәргә язмасын иде.

**Р.Ф.** *Без әдәбиятка килгәндә, ягъни үткән гасырның 60 нчы еллар башы була инде бу, тулы бер аксакаллар төркеме бар иде. Г.Бәширов, Х.Туфан, Ш.Маннур, А.Шамов, И.Гази, С.Хәким, М.Әмир... Тагын биш-алты исем санарга була. Алар безнең өчен зур абруйлы шәхесләр иде, әйткән сүзләре дә канун кебек катгый иде. Без алардан беркадәр шүрли дә идек шикелле. Кылган гамәлләрне, язган-сызганнарны алар күзе белән дә карап бәяли идек... Аксакаллар бит! Алар ни әйтер? Хәзер кайтып чагыштырып карыйм: аларга ул вакыт 50–60 яшь булган икән! Хәтта бүгенге бездән дә яшьрәк! Әйе, без дә шактый озын гомер кичереп киләбез, яшьләребез дә зур, ә аксакал була алдыкмы соң? Ата-бабаларыбыздан калган әхлак нормалары сакланамы хәзер? Замана бүтән булгач, без үзебез дә бүтәнме, яшьләребез дә без теләгәнчә түгелме? Мин бу хакта еш уйланам. Синең фикерне дә беләсе иде!*

**Т.М.** «Без яшь чакта сыерлар да мөгрәп кайталар иде көтүдән» дип әйткән ди колагы катыланган бер әбекәй. Дөнья шулай үзгәреп торадыр инде ул. Минем үземә дә еш кына андый уй килә. Без, өлкәннәр, вакландык бугай, элеккеләр саллырак фикерле белә, үзләрен мәртәбәлерәк итеп тоталар иде дип уйлыйм. Без, яшьләр, тәртиплерәк, әдәплерәк идек дип тә әйтәсе килә. Уйлап-уйлап торам да элеккеләрнең дә кәефебезне җибәргән кайбер гамәлләре искә төшә. Мисаллар эзләмик, үткәннәргә селтәнүне мин егетлеккә санамыйм. Инде бүгенгегә килсәк, мин үземә аксакал дип караучы шактый яшьләрне беләм. Күп кенә язучылар синең шигырьләрдән өзек алып үзләре язганнарга эпиграф итеп куялар. Кеше олыгайгач үзенә күбрәк игътибар өмет итә. Элеккеләр әйбәтрәк иде дип фикер йөртү шуның нәтиҗәседер ул.

**Р.Ф.** *Син – көндәлек (вакытлы дип тә әйтәләр) матбугатта иң актив язышкан әдип. «Кызыл тышлы дәфтәр»дән сәхифәләр иң тиражлы, тәрбияви әһәмияте зур булган басмаларда бик еш басыла. Мин үзем аларны яратып укыйм. Халык та яратып танышып барадыр дип уйлыйм. Син аларны үз иҗатыңда нинди урын тота дип исәплисең?*

**Т.М.** Үз иҗатына зур эш итеп караган язучының көндәлек алып бара торган дәфтәре бардыр ул. Чөнки бар күргәнне, ишеткәнне хәтердә саклап тору мөмкин түгел. Кемнәрдер көндәлеген күрсәтми, мин исә күрсәтердәйләрен матбугатка биреп барам. Мин аларны әдәби яктан эшкәртеп тә тормыйм. Тора-бара бу әдәбиятның публицистика дип аталган жанрында эшләү рәвешен алды. Аларны дөньяга чыгаручыларга рәхмәт, ошатып укучыларга рәхмәт.

**Р.Ф.** *Син – кырык елдан артык «Казан утлары» журналының даими авторы. Озак еллар буе аның редколлегия әгъзасы да. Утырышларда, Синең белән аерым очрашуларда гел әйтә киләм: баш редактор буларак, ярты вакыт подписка-тираж мәсьәләләре белән шөгыльләнеп үтә. Хәзерге 6–7 мең тираж – бик күп оештыру эшләренең нәтиҗәсе. Шуңа да карамастан кимү тенденциясе дәвам итә. Шактый көч куеп чыгарган журналны күпләр укуын теләү – табигый хәл. Тираж – әдәбият язмышын күрсәткән фал. Син журналда эшләсәң, бу юнәлештә нинди гамәлләр кылыр идең? (Шуны да өстәп әйтим: туган ягың Кама Тамагында да журналны бик аз алдыралар. Чагыштырыр өчен: Сабада – 300 данә, Кама Тамагында – 27 данә.)*

**Т.М.** Соңгы җөмләне хакимият укый торган гәҗиткә дә яз әле. Бәлки, файдасы тиеп, күбрәк язылырлар. Нишләтим инде ул язылмаганнарны. Мин, мәсәлән, татар телен һәм әдәбиятын укытучылар «Казан утлары»н укып барырга тиешләр дип саныйм. Бу – аларның профессиональ мәҗбүри бурычлары. Районлардагы һәр китапханә журналны алдырырга тиеш. Еламасыннар укытучылар, «Казан утлары»н алдырырлык кына акча түләнә аларга. Аңламаган укытучыларга хакимият аңлатырга тиеш. Әгәр дә әдәбият укытучысы бүгенге әдәби процесстан хәбәрдар түгел икән, аның әдәбият укытырга хакы юк. Ә инде калган Кама Тамагы татарлары сабалылардан бераз көнләшсеннәр иде, бигүк надан түгел лә инде без.

**Р.Ф.** *Классик Туфан Миңнуллин шәкертләр үстердеме? Булса, алар кемнәр?*

**Т.М.** Шәкерт үстерү минем эшем түгел. Гомумән, әдәбиятта остазлыкны һәм шәкертлекне өнәмим. Һәр язучы әдәбиятка остаз сүзен кабатламыйча, үз сүзен әйтер өчен килергә тиеш. Без, өлкән буын, аларга үз сүзен әйтер өчен шартлар тудырырга тиеш. Минем яратып әйтә торган бер сүзем бар: миннән яхшы язучыны яратып бетермим (чөнки көнләшәм), ә миннән

начар язучыны җенем сөйми. (Чөнки ул әдәбиятның әче дошманы.) Мин киләчәк буынга фәлсәфи карыйм. Әгәр бездән соң татар язучылары килмәсә, безнең кирәгебез юк, без язганнарның кирәге калмаячак. Безне алыштыручы яшь буын бездән талантлырак булырга тиеш, бу – табигать законы. Һәр талантлы татар язучысы минем өчен бик тә кадерле. Талантлылар арасында үзеңне кеше итеп тоясың. Сәләтсез һәм өстәвенә әрсез язучылардан Ходай сакласын.

**Р.Ф.** «*Дус» сүзе бар. Бер иҗекле генә...*
*Ә мәгънәсе – чиксез һәм тирән.*
*Әй, кыен шул асылын бу сүзнең*
*дөрес итеп аңлап бетерү! –*

*дип язган идем мин «Сәйдәш» поэмасында. «Дусларыңа карап үзеңә бәһа бирерләр» дип тә әйткәлиләр. «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә!» дип җырлаган борынгыларыбыз һәм хәзер дә җырлыйбыз. Фикердәшләрең бармы, булса, дуслык мөнәсәбәтләре нинди критерийлардан чыгып корыла?*

**Т.М.** «Дуслык» дигән төшенчә гомер үткән саен үзенең төсмерен үзгәртеп тора. Яшь чакта күп кешегә дус дип эндәшәсең. Шуңа күрә дусларның саны да күп була. Яши-яши кемнәрдер арбадан төшеп кала, йә син алар белән бер арбада утырып барырга теләмисең, йә сине утыртмый башлыйлар. Чөнки тормышка карашың җитдиләнә барган саен, сайлана башлыйсың. Шешәдәшләр, эшнәләргә түгел, фикердәшләргә мохтаҗлык арта. Дуслык бит ул корбан да сорый торган нәрсә. Дустың дип санаган кешеңә син һәрвакыт бурычлы. Ул бурычны дус дигәнеңнән түләтергә телисең икән, димәк, анда дуслык булмаган. Дус ул синең иң яшерен серләреңнең дә сандыгы. Шуңа күрә дусларым бар минем дип әйтергә күңел базмый. Якын иткән фикердәшләрем бар, Аллага шөкер. Табындашларым да аз түгел. Кешеләр арасында кешеләрчә яши беләмдер, ахрысы. Эш кешеләрен хөрмәт итәм, үзен шәхес дип санаганнарга якынаям. Кайчандыр дус булып йөреп тә, тормыш аерган замандашларымны онытмаска тырышам. Әйткәнемчә, бүген дустанә аралаша торган даирәм тарая бара. Марсель Сәлимҗанов та вафат булды, Илдар Юзеев та юк инде, Шәүкәт Галиев белән дә сирәк очрашабыз, Альберт Яхинны да телефоннан гына ишетәм. Ләкин мин аларны һич онытмыйм. Гариф абый Ахуновны да сагынам. Әдәбият дөньясына кергәндә, алар минем таянычым булдылар.

Бүген күбрәк үземнән яшьрәкләр белән аралашам. Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова... Алар белән миңа кызык.

Тормыш бит ул кызыклы нәрсә. Шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов белән мин, мәсәлән, бер табын артында кочаклашып утыра алмыйм. Ләкин талантлары өчен хөрмәт итәм. Синең белән дә шулай. Алда әйтелгән шагыйрьләр белән аналогия үткәрергә теләмим. Әмма без икебез ике холыктагы кеше. Синең белән җәелеп сөйләшеп утырган юк диярлек. Син һәрвакыт каядыр ашыгасың, Син безне каядыр үтеп барышлый гына күрәсең. Синең вакытың минутлап бүленгән. Җыелышларның, мәҗлесләрнең дә башында гына күренәсең дә югаласың. Син берәү белән дә якалашмыйсың, киеренке мөнәсәбәтләрне уратып үтә беләсең. Ә мин – болганчык кеше. Син акыл белән яшәсәң, мин күбрәк хис белән яшим. Синең турыда төрле сүзләр дә ишеткәлим. Әмма мин Сине хөрмәт итәм. Син – талантлы милләттәшем. Милләт мәсьәләсендә, әдәбиятка караш та безнең фикерләр һәрвакыт диярлек тәңгәл килә. Татарның талантлы баласын холык-фигыленә игътибар итмичә хөрмәт итәргә тиеш без.

Ә инде якын итмәгәннәргә килгәндә, алар турында сөйләп торасым килми. Бар андыйлар. Ясалма кешеләрне яратмыйм. Киеренке мөнәсәбәтләрдә әдәп кагыйдәсен онытып пычракта аунарга яратучыларны җенем сөйми. Үзен дөньяның кендеге дип санаучылар да миңа юлдаш түгел. Алар еш кына мине үртәп, мине бәхәскә тартып кертергә маташалар. Андыйлар белән бәхәскә кереп вакланмыйм. Мин аларны күрмим генә. Минем өчен алар юк бәндәләр. Читтән караганда, бәлки, баламут кебегрәк күренәмдер, әмма корсакка төртеп сөйләшә башласалар, усалланам.

**Р.Ф.** *Менә мең елга бер туры килә торган (шөкер, ул безнең гомергә туры килде!) Казан юбилее да үтеп китте. Бу бәйрәм төрле кешедә төрле хис калдыргандыр. Әмма Казанның бу олуг юбилее тарихка гына күз төбәү түгел, киләчәк турында ныклап уйлану өчен бер җай да. Син Олы Мәрәтхуҗа улы булсаң да, Казан кешесе бит инде. Балалар белән, гомер белән шушы шәһәргә береккән. Казан – бөтендөнья татарларының карап торган мәркәзе. Киләчәк гасырларда да ул шулай булып калырмы?*

**Т.М.** Әлбәттә, Казан – безнең башкалабыз, мәркәзебез. Күзне төбәп карап торган үзәгебез. Аның тарихы да татар халкы тарихы. Дан тоткан, үзен якларга тырышкан, яклый алмаган, татарлыгын нык югалткан, тагын бер дәртләнеп селкенеп алган, янә дә сүрелә башлаган. Мең ел дип ничә ел шаулыйбыз. Шулай кирәктер, зур юбилей бит. Әмма мин бүген ул бәйрәмне таралып, куанып бәйрәм итә алмыйм. Әллә ни булды минем белән, бәйрәмнәр кызык булмый башлады. Күбрәк уйландыра. Без үз-үзебезне юатыр өчендер инде, Болгар дәүләтен, Алтын Урданың бөеклеген еш искә алабыз. Билгеле, тарихны белергә кирәк. Әмма үткәннәр белән генә яшәү – бәхетсезләр шөгыле. Кызык түгел. Рәсәйне мин Ватаным дип әйтә алмыйм инде. Мине кирәксенмәгән ил миңа Ватан була алмый. Республика, җөмһүрият дип тә горурланырлык сәбәпләр кими бара. Соңгылары бигрәк күңелне төшерде. Латинга кайтуны сузып-сузып килдек тә баш казыгы куйдык. Милли югары уку йорты дип сөйләндек, ул идеяне дә үтерделәр. Үземне мин алданган кеше итеп хис итәм. Мәскәүне гаеплибез, гел Мәскәү генә дә түгелдер инде. Көрәшергә теләмәгән үзе егыла. Хәерле булсын. Казаныбыз 1000 еллык «исконный урыс шәһәре» булып калмагае. Мәскәүнең ул юбилейны зурлап бәйрәм итүе дә шуңа ишарәле шикелле. Бүтән мәсьәләләрдә безне зурларга ашыкмый бит. Ләкин мин апатиягә бирелмәскә тырышам. Шагыйребезнең «Кисмәк өстенә каракош иттифакый кунган ул» дигән өмет белән үземнең рухи халәтемне саклыйм.

**Р.Ф.** *Әдәбиятта, сәнгатьтә «тәнкыйть» дигән төшенчә бар. Төшенчә генә түгел, тәнкыйтьче дип аталып йөрүче һөнәри төркем бар. Алар үзләренчә хәрәкәттә: язалар, сөйлиләр, китаплар чыгаралар... Безнең турыда да – Синең белән минем иҗат турында диюем – байтак яздылар. Игътибарлары өчен рәхмәт, әлбәттә. Шулай да... Син үз иҗатыңда тәнкыйтьнең реаль тәэсирен, ягъни булышлыгын тойдыңмы? Гомумән, бүгенге көндә әдәби тәнкыйть Синеңчә нинди булырга тиеш?*

**Т.М.** Кайдан килеп керде икән татарга бу сүз? Үзенеке микән? Төп мәгънәсе нәрсәне аңлата икән: кемне дә булса салып таптаумы, әллә үтереп мактаумы? Бүген минем үземнең шәхсән тегесенә дә монысына да исем китми. Буласы, начармы-яхшымы, булган. Әдәби тәнкыйтьнең мин әйткән һәр ике формасы әдәби мохиткә яңа кереп баручыларга куркыныч. Иҗат кешесен таптап та, мактап та үтерергә мөмкин. Мисалларны Син дә, мин дә беләбез. Нинди генә булса да тәнкыйтьнең төбендә кешелеклелек ятарга тиештер. Тәнкыйтьнең оператив формасы бар. Ул рецензияләр рәвешендә языла. Моны мин реклама дип кенә кабул итәм.

Әдәби тәнкыйтьнең чын асылы – анализдыр. Әйтик, язучыны теге яки бу әсәрне язарга нинди сәбәпләр этәргән, максатына ирешә алганмы язучы, ирешә алмаса, ни комачаулаган, бүгенге җәмгыять күзлегеннән караганда әһәмиятлеме язылган әсәр, язучы үз фикерен ни дәрәҗәдә осталык белән әйтә алган. Гомумәдәби процесста үз урыны бармы әсәрнең һәм башкалар, һәм башкалар. Мондый тәнкыйть-анализ теләсә кемне уйландыра. Син язучылык хезмәтенең ничаклы җаваплы икәнен янә бер тоясың, ягъни үз эшеңә читтәнрәк карап бәя бирәсең. Бер кызыклы факт. Мин язган пьеса буенча куелган спектакльне карап утырам берзаман. (Кайсы икәнен әйтмим.) Шунда үзем дә сизмәстән онытылып китеп «болай язмыйлар!» дип кычкырып куйдым. Анализлы тәнкыйтьтән соң ул язучы «чыннан да болай язарга ярамый икән, төзәтергә кирәк» дип уйлансын яки үзенең «дөрес язганына» инансын иде.

**Р.Ф.** *Мәгълүм булганча, Татарстанда татарларның чиреге чамасы гына яши. Республикадан читтә яшәүче шул күпчелек кавем турында Син нәрсәләр уйлыйсың? Аларның күбесен милләтебез балалары санап без үз-үзебезне алдамыйбызмы? Байтагы үз телен*

*оныткан, тарихи, рухи тамырлар өзелгән... Аларны янә җыю мөмкинме? Мөмкин булса, нишләргә?*

**Т.М.** Безнең кыска гына әңгәмәдә бу турыда нидер әйтү бик авыр. Бигрәк тә «нишләргә?» дигән сорауга җавап эзләве катлаулы мәсьәлә. Мин аңа җавап та бирә алмамдыр, ахры. Татарның язмышыдыр инде ул сибелеп яшәү. Атилла бабаларыбыздан башлап Болгар, Алтын Урда дәүләтләренең чиге дә очсыз-кырыйсыз. Алтын Урдадан ничә ханлык кына бүленеп чыккан. Бүген татар кайда гына яшәсә дә, нигездә, үз җирендә яши – килмешәк түгел. Мин инде Америка, Финляндия, Австралия ише илләрдә гомер кичерүчеләрне әйтмим. Аларны язмыш җиле сипкән. Үз илеңдә генә төпләнеп яшәүгә канәгать булмыйча кая да булса бару борынгы бабаларыбыздан калган инстинкттыр, күрәсең. Менә шул татарны ничек татар итеп сакларга? Ничек бер идея тирәсенә тупларга? Безнең кебек үк Җир шарының бөтен почмагында диярлек яшәгән яһүд халкы моңа иреште. Аңа инде югалу куркынычы янамый. Глобализация турында күбрәк алар сөйләсә дә, алар бу эпидимиягә эләкмәячәк. Киресенчә, дөнья белән үзләре идарә итәргә җыеналар. Бәлки, безгә алар моделен кулланыргадыр? Заманында бит «Татар үткән җирдә яһүдигә эш юк» дигәннәр. Бу сыйфатыбыз безнең әле дә күпмедер дәрәҗәдә саклана дип уйлыйм. Кайда, кем булып эшләсә дә, татар югалып калмый, җаен, хәйләсен таба. Ләкин, ни кызганыч, татарлыгын яһүд кебек саклап калырга хәйләсе җитми. Бигрәк тә урыска үзен «ашата». Яһүд марҗага өйләнсә дә, татарга кияүгә чыкса да яһүд туа, татардан урыс туа. Югыйсә эчке тотрыклылыгы ягыннан урыс татардан көчсезрәк.

Без татар-башкорт мөнәсәбәтләрен куертып сөйләргә өйрәндек – татар башкортлаша, дибез. Ә мин моңа әллә ни борчылмыйм. Татарның маңгаена башкорт дип язсаң да, ул башкорт була алмый. Ә башкорт бик тиз татарлаша һәм урыслаша. Бүгенге башкортларны шул хафага сала да инде. Мин аларның хәлен аңлыйм. Чуаш та, мари да була алмый татар. Инглиз, французга да әйләнмидер. Ә менә урыска әйләнә дә куя! Әллә соң урыс үзе дә татарга әйләндеме дип уйлап куям кайчакта. Бик тиз уртак тел табалар бит. Тел киртә булып тормый. Мин проблеманың сәяси ягына махсус кагылмадым. Чөнки Россия дигән илдә безне милләт буларак сакларга теләүче хакимият булмады һәм булмас та шикелле. Әлегә бездән «котылу» сәясәте көчәйгәннән-көчәя бара. Шушы шартларда саклану юлын табарга иде. Бу Татарстаннан читтә яшәүче татарларга гына кагылмый, бу – барыбыз өчен дә уртак проблема. Бездә «Берләшик!» дигән чакыру еш әйтелә. Шул берләшүнең тормышка ашыру юлларын табарга, һәр форсаттан файдаланырга иде. Иң мөһим бурычларыбыз, бүгенге көндә иң актуале, минемчә, Мәскәүнең безне төрле этник төркемнәргә бүлеп таркатуына каршы торудыр. Әгәр дә, без – Казан татары, без – мишәр, без – себер, әстерхан татары, без – типтәр, без – керәшен, дип сөйләнсәк, тиз арада беребезнең дә калмавы бик ихтимал. Башкортлар белән бәхәсне тирәнгә җибәрмәскә иде. Экстремизмга һичничек юл куярга ярамый. Аларның югарыда әйтелгән проблемасын безгә аңларга һәм аңлашырга кирәктер.

Бер куаныч – читтәге бик күп татарларыбыз Казанны үзләренең дә башкаласы дип саный. Шулай булгач, Казанны чыннан да бөтен татарларның кыйбласы дәрәҗәсендә тотарга иде. Татарның иҗтимагый фикере, мәдәнияте бары тик үзе таныган рухи башкаласында гына формалаша ала. Моны үзебез дә аңларга һәм бүтәннәргә дә аңлатып торырга тиешбез.

Бүген диннең йогынтысы көчәя бара. Мөселман татарлар да, керәшен татарлар да дингә милләт күзлегеннән дә карарга тиешләрдер. Төп динебез безнең ислам дине. Шул дин тирәсендә берләшкән хәлдә, үзебезнең гарәп тә, иранлы да түгеллегебезне онытмасак иде. Бүген мәчет-мәдрәсәләребезгә урыс теле кереп бара. Татар мәчетендә бөтен мөселманнарга уртак телдә – Коръән телендә булса, калган сөйләшүләр бары тик татарча гына булырга тиеш дип саныйм. Миңа, мәсәлән, керәшен татарларының үз чиркәүләре булуы ошый. Бер керәшен апасының «ярый әле үз чиркәвебез булды, урыска әйләнеп бетә язган идек» дигәнен мин еш искә алам. Без бит интернационализмны башкаларны олылап, үзебезне түбәнәйтү дип аңлый башладык.

**Р.Ф.** *Гадәттә, әңгәмә ахырында бирелә торган традицион сорау: алдагы көннәргә нинди уй-планнар корып яшисең?*

**Т.М.** Бер җыр искә төште:

Агыйделнең аръягында
Күтәрелде томаннар.
Аерылырга түгел иде
Безнең корган планнар.

Әдәбияттан, театрдан аермасын иде Ходай. Яшьлектә язмасаң да, «кызыклар» күп. Урам тулы чибәр кызлар – кайсына сүз кушсаң да килешә, мәҗлесләрдә «Алмагачлары» көенә дә сиптерәсең, дусларның хисабы юк, сәламәтлек – корычтай. Картайгач... Әйтеп тормыйм инде. Бердәнбер кызык – язудыр. Хәтта әдәбият белән кызыксынып карамаганнар да картайгач яза башлыйлар. Язу бит әле ул үз-үзең белән сөйләшү дә, чөнки сине үзеңнән башкалар тыңламый башлый. Кешеләр дә тыңлый алырлык әсәр язасы килә. Туктап булмастыр инде. Ул «чир» үзем белән бергә генә китәрдер. Әле менә дәртләнеп кино өчен сценарий язам. Рамил Төхфәтуллин «куябыз!» ди. Авызына бал да май. Тагынмы? Тагын да бар эшләр... Ходай гына күпсенә күрмәсен.

*2005*

## *«ЫШАНЫЧ ЗУР, ХЫЯЛ КӨЧЛЕ ИДЕ...»*

*(Шагыйрь һәм публицист Рәфикъ Юнысның*
*Равил Фәйзуллин белән әңгәмәсе)*

**Әңгәмәгә кереш сүз**

1960 елның җәе. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә дип имтиханнар биреп йөрим. Бирдем, конкурсны да үттем, мин хәзер – шанлы уку йортының тулы хокуклы студенты! Тик... алай гына түгел икән бит әле. СССР башында Хрущев атлы гаҗәеп бер реформатор тора иде ул чакны. Аның тынгысызлыгының җиле миңа да тиде. Ике ел эш стажы булмаганнар беренче уку елын заочниклар кебек эшләп укырга тиеш икән бит! Мондыйлар безнең арада дүрт-биш кеше җыелды бугай. Мин үзем киң маңгайлы Равил атлы малайны гына хәтерләп калганмын... Минем ничектер шунда дәрт сүрелде. Монда укытучылар әзерләнгәнен белү исә котны ук алды.

Кыскасы, ошбу арбадан төшеп калдым мин. (Бөтен группабыздан бер (!) укытучы чыккан, диделәр. Шамил Маннапов, Фарсель Зыятдинов, Фирдәвес Гарипова, Шәриф Асылгәрәев, Флера Баязитова, Әнвәр Шәрипов, Рүзәл Йосыпов кебек группадашларым бөтенләй башка даирәдә шөһрәт казандылар.)

Тормышымның әнә шул вариантыннан баш тартып, ниләр җуйдым икән? Бу турыда кат-кат уйланганым бар минем. Һәр юлы гел бер фикергә киләм: югалтуларымның иң зурысы Равил Фәйзуллин янәшәсендә иҗат итмәвем булгандыр.

Ике ел эшләп, өч ел армиядә хезмәт итеп 1965 елда янә беренче курска (бу юлы журналистикага) кергәндә, Равилебез инде иң күп мактала һәм иң күп сүгелә торган, ягъни иң популяр шагыйрьгә әйләнеп өлгергән иде. Моңа аның шул елны «Казан утлары»нда чыккан, иркле алым белән язылган «Нюанслар иле» дигән кыска шигырьләр циклы да сәбәп булды... Шул чордарак мин «Татарстан яшьләре» гәҗитенең Равил җитәкчелек иткән әдәби берләшмәсенә дә йөреп алдым әле.

Ни дип сөйлимме боларны? Шул елларда Равилнең бер күркәм сыйфаты күренде. Киң күңеллелеге. Булачак классик безнең шул ничә көнлектер танышлыгыбызны да олылап, миңа гел якын танышы, сабакташы итеп карады, кирәк чакта ярдәм дә итеште әле. (Айдар Хәлим соңрак болай дип язар: «Ул бик кешелекле, рухи һәм матди юмарт. Эшчән. Кешене бервакытта да кимсетмәс, хурламас. Арага кермәс, интригалар, чуар интереслардан ерак торыр...») Мин исә, табигый ки, сабакташымның тормыш һәм иҗат юлын бик тә дикъкатьләп күзәтеп бардым.

1967 елда беркая да бирмәгән мәкаләмдә болай дип язганмын: «Яшьләр потларга табынырга яратмый алар. Нык алданганлыкларын, нindидер бер бәндәне (Сталинны) Алла урынына күргәнлекләрен аңлагач, алар ачулы-тәнкыйтьчел караш белән бөтен дөньяны күздән кичерделәр, һәрнәрсәгә яңа бәһаләр куеп чыктылар. Шуны белгән хәлдә иҗекләр санауга корылган традицион шигырь калыбының яңа буын шагыйрьләргә катып калганлык

символы, тере хисне буып торучы зиндан диварлары булып күренүенә гаҗәпләнергә кирәк микән?.. «Фетнәче» дип иң әүвәл саф башында барган Равил Фәйзуллинны атадылар, һәм аңа яңа шигърияткә дигән кусәкләрне дә, беренче булуның романтик тәмен дә мул татырга насыйп булды... Фәйзуллинның үзенчәлеге нидә? Талантлы булудан тыш, күзәтүчән, дөньяны образлы күрә, абстракцияләүгә һәвәс...»

Моңа өстәп хәзер шуны да әйтәсе килә: Равилнең иреклe шигырьдән китүе качу да, чигенү дә булмады. Ул анда сугышлы разведка үткәреп, традицион шигырьгә ниндидер бер хөрлек, табигыйлек, тормышчан интонацияләр алып кайтты.

Карама күзгә – тонгандыр,
Карама йөзгә – сулгандыр...

Татар шигырендә болай иркен сөйләшкәнне ишеткән юк иде кебек әле. Шагыйрьнең тудыручы, үстерүче һәм үтерүче куе-тыгыз вакыт ташкыны фонында яшәешне берьюлы образлы-символик итеп тә, шулкадәр гади-тормышчан итеп тә сурәтли алуы күңелгә ниндидер сихер-тылсым кебек тәэсир итә иде.

Инде күптән җәй икән!
Җанда моң әллә ниткән...
Өлгергән бодай кырыннан
кыз бала йөгереп үткән, –
йомрыланган тезләреннән
орлыклар чәчрәп киткән...

Эре адымнар белән әдәбиятыбызның түренә узган яшьтәшем гел сөендереп кенә тормады. Аптыраткан, уйга салган чаклары да була иде.

Шактый каршылыклы дөнья бит ул Фәйзуллин дөньясы. Иркенәя торгач, бөтенләй иркенәеп китеп, шигырь калыбында көндәлек язып баруны гына хәтерләткән нәмәрсәләр дә төшкәләде Равилнең каләменнән. Ташып торган дәрт-дәрманын кая юнәлтергә белмичә, «Көрәш! Көрәш!» дип тә тәкрарлады бит әле ул. Ә бу – саф җилләр искән, яңарыш барган илдә яшәү иллюзиясе тудыра иде, ягъни ул чактагы сөрсегән режим өчен кулай эш иде. (Шөкер, иҗат гомеренең 30 еллабы тоталитар заманда үтсә дә, режимга майлы калҗалар тәтемәде Фәйзуллиннан. Биштомлык әсәрләрен чыгарганда аңа бер генә шигыреннән дә баш тартырга туры килмәде бугай, бер-ике шигырендә 2–3 хәрефне алыштыру да бик җитте.)

Вөҗданым белән сөйләшәм, –
шул минем шигъриятем!

Равилнең девизга тиң ошбу юлларын тәнкыйтьчеләреннән кем генә сокланып кабатламады икән? Минем исә кайчакта болай дип әйтәсе килә башлый иде: «Хатын-кыз заты, гыйшык-мыйшык турында сөйләшеп туймас нинди вөҗдан булды инде бу!»

Шигырьдә «лирик герой» дигән нәрсә дә бар бит әле. Ул шагыйрьнең үзе белән тәңгәл килергә дә, килмәскә дә мөмкин. Р.Фәйзуллинга кадәр лирик геройлар шигырьгә бизәнеп-ясанып, фәрештә кыяфәтендәрәк чыгалар иде. Равилнеке исә бик макталмаган якларын да яшереп-нитеп тормый. Менә мондый лирик геройны күргәнегез бар идеме сезнең?

Бишмәт эләктерелгән бер төймәгә генә.
Теләк тә, хәл дә юк...
...Шамук мәчеседәй кайтып киләм...

Аталар һәм балалар. Катлаулы, кайчакта газаплы мәсьәлә. Буыннар алышынган сикәлтәләрдә шактый рухи байлыгы коелып калган татар өчен аеруча четерекле ул. Ата-ананың баланы хаталардан аралап каласы, үз копияләре итәсе килә. Баланың исә «далада» беркайчан да булмаганны – үзенекен табасы килә. Алгарыш та булсын, дибез бит. Фәйзуллин ошбу мәңгелек мәсьәләгә ачкыч юнәткән түгелме?

Үз иманың булсын.
Тик ул иман
сызып ташламасын минекен.
Мин – этиең.

Равил үзенең фамилиясен кыскартмады, Әхмәт Фәйзи белән Җәүдәт Фәйзиләрне кысрыкларга уйламады. «Фәйзуллин»да, бигрәк тә аның басым белән әйтелә торган урта иҗегендә, ниндидер бер егәр бар. «Приватизацияләп», шагыйрь бу фамилиягә анда моңарчы беркайчан да булмаган көч-куәт салды. «Гамзатов», «Айтматов»лар кимәлендә яңгыратырга да ымсынды бугай. Мескенлектән гарык татар да шуны ук теләп торды. Ләкин нидер җитми калды. Бәлки, җитмәгән нәрсә талант та булмагандыр... Бик тә, бик тә җиткерергә теләү үзе төп сәбәп булмады микән әле?

Фәйзуллин бит ул шигърияткә авызлыкланмаган ярсу Пегаска, дөлдөлгә атланып килеп керде, шуңа да иң биек үрләренә шул беренче елларда менде ул. Тагын да биеккәрәк меним дип, иҗатының нәтиҗәсе турында күбрәк уйлый башлау, нәтиҗәне планлаштыруга артык зур әһәмият бирү бәйсезлеген киметә төшмәде микән? Нәтиҗәне тәэмин итәргә мөмкин шартларга һәм кешеләргә бәйли башламадымы икән? Һәрхәлдә, иптәшләре шагыйрьдә конформизм, юл куючанлык чалымнары күренә башлаганын сизми калмады.

Ләкин шунысы да хак: санаулы язучылар рәтендә озак еллар Мәскәү «обойма»сында йөрсә дә, Равил Фәйзуллин «служилый шагыйрь»гә әйләнмәде, Мәскәү Кремленә дә, Казан обкомына да бил бөкмәде.

Хәтта киресенчә дә әле.
Космополит түгел,
шөкер,
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын:
татарныкы диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга.

«Минеке» дип бүлмим көкне, айны,
мөһер сукмыйм ел фасылына...
Милләт исемен такмыйм урман-суга,
агач-ташның иң асылына...

Бу шигырь 1969 елны язылган. Аны нинди ләззәт кичереп укыганымны һич онытасым юк. Җанны гына түгел, тәнне дә басып торган милли мескенлек каядыр олакты – җилкәләр үк тураеп китте. Урыс шовинизмының яңагына безнекеләрнең болай чалтыратып сукканы юк иде әле.

«Колонизатор әлифбасы» дигән шигырь исә 1975 елны язылган:

Куа да,
бүтән ыру адәмнәрен
җиреннән-суыннан,
үз хатыны, балалары алдында
хозурланып әйтә тиран:
«Җиңдем!..» – диеп.

Бераз вакыт үткәч,
оныкларына тукый:
«Бу җирләрне азат иттем!..»

Соңрак –
иске зират урыннарын абзар ясагач,
оныкларының балалары:
«Ватаным!..» – дип шигырь яза.

Бусы инде җитдирәк гамәл, системаның үзенә кизәнү. Кырым җирлегендә язылган, ләкин безнең тарихка да бик мач килә...

Әдәбияттагы күрше басуларга – проза белән драматургиягә генә кереп чыгудан да тайчанган, шагыйрь булуны барыннан да өстен куйган Фәйзуллин гомерендә бер тапкыр депутат булып карады. Татарстан Югары Советында. Җаны түзмәгәндер инде: республикабызга Суверенитет бирәчәк XII чакырылыш иде бит бу. Декларация игълан ителәчәк 30 август көне Югары Советта аның ялкынлы һәм акыллы чыгышы белән башланып китте... Ләкин актив депутат чыкмады шагыйрьдән. Аның ниндидер без белмәгән уйлар белән иелгән авыр башы «татар» һәм «культура» дигән сүзләр яңгырагач кына калкынып куя иде.

Бераздан бу барлы-юклы мөстәкыйльлекне дә җую башланды. Иҗатында чагылмагач, шагыйрь боларны күрмиме, әллә күреп тә күрмәмешкә салышамы дип йөрсәм, тегесе дә түгел, бусы да түгел икән. 1999 ел азагында ул «Идел»гә «Идея» дигән бик тә үткен, кыю шигырен китерде. Шунда мондый шаян уй килгән иде башка: «Казан утлары»нда борганнардыр, бәлки?» Шагыйрь Равил Фәйзуллин баш мөхәррир Равил Фәйзуллиннан тәвәккәлрәк бит! Хәер, тегесен дә йөрәксез димәс идем...

Куркаклар күп ләкин. Хәбәрчеләребез язуынча, татар өчен хәлиткеч мәлдә, халык исәбен алу әзерләнгәндә, Башкортстанда татар телендә чыга торган «Кызыл таң» һәм «Өмет» гәҗитләре татарга каршы да эшләгәннәр. Татар телендә чыга торган «Тулпар» атлы яшьләр журналы исә, Татарстан чиген дә үтеп кереп, Нәбирә Гыйматдиновага «татар-башкорт язучысы» дигән мөһер суккан! Нәбирәбез, Башкортстанның кай якта икәнен дә белмәгән, мишәр кардәшләрен дә коткыга бирелмәскә, татар дип язылырга өндәп мәкаләләр чыгарган Нәбирәбез, күргәч, егылып китә язды... Үткән заманның чукындыру осталары Малов, Ильминскийлар искә төшә. Алар да бит татар җанына аның үз теле аша үтеп керергә омтылганнар.

Ә безнең үзебездә җилнең кай яктан исә башлавын сизү белән кинәт өнсез калганнар яки, матбугатта урын билләп, башкаларны өнсез калдырганнар азмы әллә? Иң кызыгы шул тагын: тегендәгеләре дә, бездәгеләре дә вазгыятьне аңлап хәлгә керүне сорый бит әле. Теләктәш булуны! Шаккатудан гаҗиз калып ни әйтергә белми торганда, кинәт, рәхәт бер ташкын булып, хәтер түреннән сүзләр агыла:

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга-өркергә
җай бар ул һаман да...

Менә ул шигъри сүз егәре!

Бик сирәк була торган хәл: Р.Фәйзуллин исеме турында бәхәсләр барган беренче елларда шагыйрьләр һәм тәнкыйтьчеләр генә түгел, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Роберт Бикмөхәммәтов, Рифкать Әхмәтҗанов кебек прозаиклар һәм галимнәр дә, җылы сүз әйтеп, аның иңенә иңнәрен куйдылар. Тикмәгә түгел бу. Уйлавымча, Равил Фәйзуллинның шау-шу куптарып шигърияткә килүе тарихта һәм археографиядә – Нәкый Исәнбәт, Равил Фәхретдинов, Миркасыйм Госманов, тарихи прозада – Нурихан Фәттах, җыр сәнгатендә – Илһам Шакировлар эшчәнлеге, сөргеннән Хәсән Туфан кайту, янә «Кыйссаи Йосыф» басылып чыгу, Марсель Сәлимҗанов килгәч Г.Камал театры тернәкләнеп китү кебек татарның милли аңы уянуны әзерләгән олы гамәлләргә килеп ялгана...

Күптән түгел «Мәгариф» нәшриятында «Равил Фәйзуллин: заман, иҗат, шәхес» дигән китап дөнья күрде. Бер иҗат әһелен шулай бөтен яклап тасвирлау, шундый да әтрафлы-тирән «стереопортрет» тудыру юк иде әле бездә.

Шулай да Равил үзе генә җавап бирә алырлык сорауларым да калган иде минем.

Сезнең алда Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Равил Габдрахман улы Фәйзуллин** белән әңгәмә.

*– Син, Равил, «Менә без дә үсеп җиттек, әни!» дип язган идең. Әле «кайчан гына». 35 ел элек кенә. Хәзер бөтенләй дә үсеп җиттең инде, әйеме?*

– Артыгы белән! *(Көлә.)*

*– Алтмыш яшеңне каршыларга җыенасың. Күп әйберләр бар. Кырык китап. Шанлы исемнәр. Кәгазьгә язып биргән исемнәрдән тыш абруй бар. Кәефләр ничек соң синең?*

– Кәефләр ару болай. Алга таба шушы алган юлдан тайпылмыйча, темпны киметмәскә тырышып эшләргә инде. Темп анысы кимер инде ул бераз. Чөнки күзләр уңа төшә. Гаҗәпләнү хисе кими – еллар үткәчтен... Ләкин бүтән юл юк безнең. Алга барырга! Максат бар бит.

Максат – халыкка хезмәт итү. Мин дөрес юл алдым дип исәплим. Бүтән эшне бик белеп тә бетермим, шушы әдәби эшкә кече яшьтән үк кердем һәм уңга-сулга тайпылмыйча шул юлдан барам шикелле, кырык елдан артык инде.

*– Мин сине, беләсеңме, кайчаннан бирле беләм? Мин, син дә инде 10 нчы класста укыган чак бу, «Пионер» журналы бер әдәби кушымта чыгарган иде. Шунда синең «Туган йорт» дигән шигырең дә бар иде. «Кара син аны, язып та күрсәткән бит!» дип, сокланып исемеңне күңелгә бикләп калдым. Үзем дә язгалыйм бит инде.*

– Әйе, хәтерлим. 1959 елны булды шикелле. Сыек алсу төстә чыккан иде ул кушымта. Кушымтасы ук сакланмаган, ләкин үземнең шигырьне кисеп алганмын.

*– Беренче тапкыр университетта очраштык бит.*

– Әйе, имтихан биргәндә.

*– Иң әүвәл мин сиңа теге шигырьне язган малай буларак игътибар иттем, шул икән инде Равил Фәйзуллин дип. Төс-кыяфәтеңә дә дикъкать ителде. Үзең язганча, болын хәтле булмаса да, киң маңгай. Үз-үзеңне тотышың, атлап йөрүләреңнән үк ниндидер бер үзенчәлек, шәхес чалымнары сиземләнә иде. Менә шул тырпаеп торган «мин»ең бөтен киләчәк язмышыңа тәэсир иткәндер дип уйлыйм мин. Син әдәбиятта куптарган шау-шулар, шигырьдәге үзенчәлекле урының таланттан да әүвәл менә шуннан килеп чыккандыр ул.*

– Дөньяны яхшыртырга дигән зур теләк бар иде. Безнең саф, наив, чиста вакыт бит инде. Өлеш кертәсе килә иде. Ул чакта әле коммунизмны якынайтасы килү теләге дә булгандыр.

*– Ул заман өчен табигый бу. Ләкин минем әйтәсе килгәнем бүтән иде. Тукайлар, Такташлар, Туфаннардан соң дистә еллар буена ниндидер иссез-төссез, системага дан җырлауга гына корылган шигырьләр ташкын булып агылды. Моң да юк, шагыйрь шәхесе дә юк анда. Кайбер искәрмәләр-чыгармалар булган булуын. Аннары, дөньялар бераз үзгәргәч, ихлас шагыйрьләр килә башлады. Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗанов... Талант ягы шәп. Шәхес тә бар. Ләкин алар һаман да әле үзләрен күпләр эчендәге «мин» дип хис итәләр иде кебек. Күпләрнең берсе, күмәклекнең өлеше итеп. Ә син бөтенләй башкача килеп кердең: башта – мин, аннары калган бөтен дөнья! Шулаймы?*

– Анысын миңа әйтүе кыен, ләкин ышаныч һәм хыял бик көчле иде.

*– Менә шул «мин»ең биргәндер дә инде ул ышанычны. Син иркен язып киткәнсең, беркемгә һәм бернигә карамыйча.*

– Аның чоры шулай туры килде инде. Дөньясы иркенрәк иде. Син әйткән ул «мин»лек булган булса, аны күрсәтергә мөмкинлеге дә ачылган. Иҗтимагый шартлар дигән нәрсә. Аннан, син әйтә башладың бит әле, иссез-төссез поэзия, дип. Безнең, яшь студент шагыйрьләрнең, бик ачу килә торган иде шуларга. Исемнәрен әйтеп тормыйм инде.

*– Әйтсәң-әйтмәсәң дә мәгълүм инде алар: Нур Гайсин, Галимҗан Латыйп, Мөхәммәт Садри... Тәнгә чыккан кызамык тимгеле кебек, алар бөтен татар шигыренең хәлен чагылдырдылар... Теге синең «мин»леккә кайтыйк әле, Равил. Каян ул синдә? Нәселдән килмиме? Бәлки, сезнең «нәселнең күзе яшел»дер?*

– Безнең әни затлы нәселдән. Бай да булганнар. Ул хәтта миңа кайчакта әйтеп тә куя иде, йөрмәле шул хәерче малайлары белән, дип. Бет иярмәсен дип әйткәндер инде, бет иде ул вакытта. Чагыштырмача хәлле яшәдек, әти – колхоз председателе.

*– Ә-ә-ә! Бусы бик зур әйбер. Кемнәргәдер баш иеп яшәү булмаган, димәк, авылда.*

– Мәктәптә дә, «бишле»гә укыгач, председатель малае булганга яклыйлар, дип әйтәләр иде. Әзрәк кыйнаштыргалыйлар да иде. Чөнки... Ул вакытта хезмәт көненә эшләү бит. Әти отчет-сайлау җыелышында әйтә инде, тырышып кына эшлик, быел икмәкне хезмәт көненә 200 граммнан түгел, 300 граммнан бүләбез, дип. Ел үтеп китә, колхоздан тагын себереп алып

бетерәләр ипине. Әтинең вәгъдәсе үтәлмәгән була. Тагын алдады, диләр инде авылда. Олылар сөйләшкән сүз миңа да килеп бәреләләр... Ниндидер бер сыйнфый аерымлыкны, безгә карата сыйнфый ачулы мөнәсәбәтне тоя идем мин. Эзе кала бит инде моның. Аннары әни озын тәнәфескә дип бер кисәк май ягылган ипи бирә иде. Класста ипи алып килә торган тагын өч-дүрт кенә малай бар. Мин кайбер дус малайларга өлеш чыгарам, әлбәттә. Тик ул ипинең бөтенесен дә биреп бетереп булмый бит инде. Тегеләре дә рәхмәт әйтеп кенә тормый әле. Такмак та чыгарганнар иде хәтта:

Әче башы урманында
Ике ябалак уйный.
Бирмә, Равил, ипиеңне,
Барыбер тамагым туймый.

Менә болар бар да беркадәр аерымланырга мәҗбүр иткәндер инде. Мин болар кебек түгел дигән уй булган. «Бишле»гә укыйм бит, укытучылар да мактап, күңелне үстереп тора. Ары китәсемә, үземнән «кеше» чыгасына ышанганмын инде.

*– Бусы аңлашылды алайса. Инде сәләт-талант ягы. Нәселдән килмиме?*

– Кистереп әйтә алмыйм. Бала чакта бик сизмәдем. Хәер, әти язгалый иде, хәзер дә язгалый. Хәтта матбугатта актив язышкан өчен Балык Бистәсе район гәҗите Кадыйр Сибгатуллин премиясен дә бирде. Энем Рөстәм Фәйзуллинның да (Акъегет) шигъриятта урыны бар инде. Кем белә, бәлки, ерак нәселдә дә каләм ияләре булгандыр.

*– Тәнкыйтьчеләрең беравыздан сине, өйрәнчеклек чорын үтеп тормады, диләр. Алай ук түгелдер түгелен. Мин үзем сине чын мәгънәсендә шагыйрь дип 23 яшеңдә язган «Карт балыкчы» дигән шигыреңнән соң таныдым. Шулай да бик тиз җитлеккәнсең. Университетка килгәнче кайда, нинди шигырь мәктәпләре үттең?*

– Ботинкадан башланды бар да. Мин бәләкәй әле – 7–8 яшьләрдәдер. Безнең авылга баянчы Гани Вәлиев килде, Җәвабирә Сәләхова белән. Утырам концертта шулай – качып кергәнмендер инде. Миңа уены да, җыры да әллә ни тәэсир итми, мин боларның ботинкаларын карыйм. Елык-елык килеп торган, лакланган ботинка! «Зур үскәчтен шундый ботинка киеп йөрсәм шәп булыр иде, – дип уйлыйм. – Авылга шуны киеп кайтсаң, әти белән әнигә дә шатлык була бит инде». Андый ботинка киеп йөрерлек зур кеше булыр өчен нәрсә кирәк? Мин – китап укыган бала, минем өчен язучы иң зур кеше. Күңелдән шигырь төртеп торгандыр инде, тора-бара «Шагыйрь булам!» дип йөри башладым. Дүртенчедә укыганда микән, бишенчедә микән, директорыбыз Гариф абый Шәйдуллин кулыма «Әдәбият теориясе» дигән китап тоттырды. Әтиләр белән бик дус иде, минем ни дип хыялланып йөргәнне белә. Габдрахман Сәгъдинең бу китабы латин шрифтында язылган иде. Шигырьнең рәтен беләсе килә бит – өйрәндем бу шрифтны, ерып чыктым китапны!

*– Дәрт көчле, әйеме?*

– Дәрт көчле! Мин аның яртысын аңламадым да инде, силлабик система ни дә силлабо-тоник система ни анда – аермыйм, белмим, ләкин кайбер нәрсәләрне чамалый башладым. Менә шул булды минем шигырь мәктәбе. Бусы да теге син әйткән «мин»леккә тәэсир итми калмагандыр инде... Аннары район газетасында шигырьләрем басыла башлау, анда эшләгән Рәшит Гарипов, Хәмзә Зариповларның киңәшләре... Университетка килгәч, ярты еллап Даут Сөнгатов чабуына ябышып йөрдем. Талантлы гына яшь шагыйрь бар иде бит, минем якташ, бәлки, беләсеңдер.

*– Беләм Даутны, ачы язмышын да беләм. Аракы әсирлегенә эләгеп юкка чыккан талантлы шагыйрь.*

– Даут мине бик күп татар шагыйрьләре белән таныштырды. Шул даирәгә керәсе килә бит инде... Язучыларның Тукай клубына йөрибез, бер «Әдәби җомга»ны да калдырган юк. Бер-ике елдан анда үзебезгә дә чыгыш ясау насыйп булды. Университетның әдәби берләшмәсендә катнашучылар буларак.

*– Син ул берләшмәнең җитәкчесе дә булдың бит әле.*

– Әйе. Аннары – китте, мин сиңайтим! Буа ерылган кебек булды. Гәҗит-журналларда басыла башладым, нәшриятка да илтеп бирдем кульязмаларны. 1964 елда «Казан утлары»нда теге «Нюанслар иле» чыкты.

*– Ай үсәсен көн үскән Камыр батырларның куркыныч ягы да бар бит.*

– Нәрсә? Ничек?

*– Гел көчләре артканны сизеп тора алар. Шуны күрсәтәсе, сыныйсылары килеп, беләкләре кычытып тора. Әле кичә генә көче җитми иде берәүгә – бүген ничек икән? Синең әдәбиятта шулай тиз үсүең дә психологик яктан бик кызык. Бер шигырең дә бар бит әле:*

*Дуамал күтәрермен дә,*
*уңайсыз төшәрсең күк...*

– Анысы соңрак аның. Хәсән Туфанга бу. Мин Хәсән агага шигырьләремне илтеп биргән идем. Ул теге яшел карасы белән бөтенләй бетереп ташлаган иде. Бик күңелем төшеп чыктым. Бер дә яхшы сүз әйтмәде ул миңа. Әз генә булса да өмет калдырмады. (1970 елда Р.Фәйзуллин Хәсән аганың юбилее уңаеннан бик җылы мәкалә бастырачак.)
*– Бу кадәресен үк көтмәгән идем. Хәсән агага шулай...*

– Ул чакта бернинди авторитетлар белән исәпләшми идек. Максималист чак. «Безнеке дөрес!» дигәнгә нык инанганбыз.

Җир җимермәк идек!
Күкне ватмак идек!
Мәңгелеккә балкыр
Утлар якмак идек!

*– Шундый чак инде бу сезнең, алайса.*

– Әйе. Без инде Назыйм Хикмәтләрне, Уитменнарны, Балтыйк буе шагыйрьләрен укыйбыз. Межелайтислар, Айтматовлар Ленин премияләре ала анда. Безнең дә шулай зураясы килә. Булмый ул Галимҗан Латыйплар белән, үзебез яңача язып чыгабыз, милләтне күтәрәбез, дибез. Без инде дөнья әдәбиятын беркадәр өйрәнеп, чын хакыйкать сүзенең тәмен тоя башладык.

*– Амбицияләр зур, димәк. Тукайлар күлмәген киеп карау булдымы?*

– Нишләптер ул чакта Тукайга мөкиббән кителмәде. Ул безгә кадимирәк булып күренә иде. Күрәсең, Тукайның асылын аңларга өлгермәгән булганбыз.

*– Аяз Гыйләҗев әйткән булган, салават күперенең бер башында – Тукайны, икенче башында Фәйзуллинны күрәм, дигән. Дөресен генә әйткәндә, мин дә синнән шуны көткән идем. Безнең заман Тукае булырсың дигән идем. Талантыңны, кыюлыгыңны, үз-үзеңә ышанычыңны күреп. Үзеңчә итеп әйтсәк, син «болай да бәләкәй түгел», бик күпкә ирештең. Ләкин син Тукай була алмадың.*

– Әйе. Минем бит исемем бүтән.

*– Язу процессыннан тыш эшләр белән артыграк мавыгып ташладың бугай син. Үзең җитештергән продукциянең барып ирешүе, нәтиҗә бирүе, резонанс туу синең өчен үтә мөһим иде. Бик табигый нәрсә үзе, бер гаебе дә юк. Хәзер базар заманында хәтта мактала да бу. Ләкин, ни генә булмасын, ул синең төп эшеңә бераз зыян салды бугай. «Һәр табуда күпме югалтулар» дип язган идең бит әле, шуның кебек инде менә.*

– Бу – субъектив фикер. Бәхәсле әйбердер. Беренчедән, мин Тукай булырга беркайчан да теләмәдем. Мөдәррис Әгъләмовтагы кебек, андый чир булмады миндә.
*– Ярар, Тукай түгел ди, татарның бүтән бер бөек шагыйре ди...*

– Синең сүзеңдә хаклык бар. Ничек әдәби мәйданга чыгып була, зуррак булып чыгып була – бу хакта, әйе, уйлана идек. Үрнәкләре бар бит. Айтматовлар, Көгелтиневләр ничек күтәрелде әнә, Мостай Кәримнәр. Безнең дә олы мәйданга чыгасы килә иде, яшерен-батырын түгел. Аның өчен нәрсә кирәк? Аның өчен урысча басылырга, бүтән телләргә тәрҗемә ителергә кирәк... Минем ул чакта шигырь теле чамалырак иде. Урысча китапларны да күп укыгач, урысча фикерләү өстенлек алган, күрәсең... Тәрҗемә иткәндә иң әүвәл ни кирәк? Фикер кирәк. Телбизәкләр бик күчми анда. Тел хисабына, күбрәк фикер сөрешенә игътибар ителә иде шул... Һәм шушы тәрҗемә эшләрен оештыру, чыннан да, байтак кына вакытны ала иде. Бу – сверхзадача куеп эшләү инде.

*– Вакытны да ала, ихласлылыкны да киметергә мөмкиндер әле.*

– Табигыйлеген дә кимәтә торгандыр, әйе, чөнки тәрҗемә өчен эшләү булып чыга бит инде. Бу нинди яңгыраш, нинди резонанс алыр икән дип уйлыйсың.

*– Тукайны үрнәк итмәсәң дә, бөеклек юлы турында уйлангансың бугай син. Бер шигыреңдә болай дип язасың:*

*Шагыйрьләрне үлемсез итә*
*халкы өчен яну.*

*Ә бит үлеп үлемсезлек яулау –*
*бердәнбер юл түгел тормышта.*

*Монысы да син, 1968 елда. 1981 елда исә фикерең никтер үзгәрә:*

*Корбан була алсаң гына*
*тибрәнер исемең*
*мәңгелек рәшәсендә.*

– Бардыр инде андый әйберләр.

*– Бөеклек дигәндә, талантлы, үтә талантлы кешегә дә нindидер бер чикне үтү кирәктер. Үз-үзеңне аямау чигеме икән бу? Тукай була алу-алмау бер хәл, шул ягы да бар: Тукай буласы киләме әле кешенең. Миңа, әйтик, Тукай талантын бирделәр дә ди, әмма язмышын да өстәп. Алырмын микән әле мин?*

– Әйе, минем дә уйлаган бар моны. Миңа Ленин язмышы кирәкми. Тукай да буласым килми. Аннары, Тукай турындагы фикерләрем бик каршылыклы минем. Тукай – халыкның бәгырендә, монысы һичшиксез шулай. Ләкин аны рәсми рәвештә дә күтәрделәр ич. Мәскәү дә дигәндәй...

*– Нәрсәсе начар соң моның?*

– Аны күтәргәч, бөтен игътибар аңа китте. Аның янәшәсендәгеләр, әйтик, Исхакый, аннан акылсызрак булмаган, милләт мәсьәләсендә акыллырак та булган әле.

*– Мәскәү, син әйткәнчә, Тукайны күтәргәндә, Исхакый кайда иде соң?*

– Кая булсын? Чит илдә иде. Гомумән, татар әдәбияты тарихы юньләп өйрәнелмәде бит. Борынгылары да, соңгы чорлары да. Хәтта Тукай үзе дә халыкка берьяклы гына тәкъдим ителде. Ул чорда рәсми үзәк һәр халыктан берәр шәхесне күтәрүне мәгъкуль күрде. Ясалма рәвештә казакъта – Җамбул, лезгинда – Сөләйман Стальский, осетинда – Коста Хетагуров... Әгәр дә без Галимҗан Латыйпларны гына түгел, Галимҗан Ибраһимовларны, Тинчуриннарны, Исхакыйларны да укып, Мәрҗани, Риза Фәхретдиннәрне дә белеп үскән булсак, безнең әдәбият хәзер гел бүтән булыр иде.

*– Тегеләрен алганнар бит аның бездән, Равил. Инде Тукай да булмаса? «Тукай» дигән байрак булмаса? «Туган тел»не гимн итеп җырлап, киләчәккә өметне саклау булмаса? Татарстаннан читтә, хәтта башка илләрдә дә Тукай җәмгыятьләре оешмаган булса?*

– Яхшы, хәзер менә бер гасырдан соң да һаман аңа гына табынабыз икән, нинди прогресс булырга мөмкин ди? Минемчә, бөекләргә табынудан бигрәк, хезмәтең белән алар эшен дәвам итү файдалырак һәм саваплырак.

*– Тукайлар, Такташларны ябырылып укыган халык берзаман шигырь укымый башлады. Кызыл пропаганда язып күңелен кайтардылар халыкның, шигырьдән биздерделәр. Шәп лириклар буыны килеп, хәлне бераз үзгәртте үзгәртүен. Ләкин гади юл белән генә халыкны янә шигырьгә кайтарып булмый иде инде, күрәсең. Менә шунда син куптарган шау-шу бик тә ярап куйды.*

– Безнең төркемнең роле булды дип уйлыйм, әйе. Шигырьгә игътибар артты. Ул бездән генә тормады, безгә вакыты шулай туры килде инде.

*– Бәлки, җаныңның ваклыгын гына түгел, олылыгын да тулаем заманга гына сылтап калдырырга кирәкмидер? 80–90 нчы елларда әнә иҗтимагый җанлану, хөрлек хәттин ашкан иде. Кемнәр килеп ни күрсәтте соң?*

– Монысы дөрес, әйе, дальше.

*– Дальше дан турында сөйләшеп алыйк. Кинәт ишелеп төшкән дан ничек аяктан екмады сине? Япь-яшь малайны?*

– Анысын мин белмим инде.

*– Белгәнсең! Бу турыда кат-кат уйлангансың син. Шигырьләреңнән күренә бу. Болай дип тә язгансың:*

*Аңладым: Дан атын*
*тезгенләү – көч икән!*
*Тыңлату дәвасы –*
*эш икән, эш икән!*

*Сөбханалла, син гел аякта нык басып тордың. Ә бит барлы-юклы даннарын аракы белән кушып эчеп япь-яшь килеш дөньядан ук киткән шагыйрьләр дә булды безнең. Бер генә дә түгел.*

*Сезнең теге төркем дә шактый тотрыклы булып чыкты ул яктан. Ул «бишлегегез» турында Марсель Галиев гаҗәп шәп итеп язган иде. Кайбер нәрсәләрне генә ачыклыйк. Әмәт тавына ничек килеп урнаштың син?*

– Общежитиедә яшәп карадым да 2 нче курста киттем аннан.

*– Нигә киттең?*

– Анда-а-а! Дүрт кеше бәләкәй бер бүлмәдә! Минем төнлә утырасы килә, даһи шигырьләр язасы килә – хут юк.

*– Аралашырга кеше күп аның каравы.*

– Университетта да аралашып туйган көне буе. Миңа ялгызлык кирәк. Миңа бөеклекне раслар өчен көч тупларга кирәк! Әмәт тавында бүлмә таптым – подвал шикелле кап-караңгы бүлмә. «Ниһаять!» дидем шунда үз-үземә. Минем кәгазем минем өстәлемдә кайтуыма нәкъ шул үзем калдырган килеш тора! Капланып җыладым мин шатлыгымнан.

*– Өйнең бер бүлмәсе инде бу, әйеме?*

– Бер бүлмә, өйнең хуҗасы бар. Соңыннан без ул йортны сатып та алдык. Әтиләр күчте. Аның мунчасы бар иде, алмагачлары. Үзе шәһәр уртасында, үзе – авыл! Өч кенә тукталыш «Кольцо»дан.

*– Сезнең ул «бишлек»тә син инде, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис...*

– Рөстәм Мингалим белән Гәрәй Рәхим килеп кушылды... Андагы ул хөрлек, фикер очышлары! Ул сүгүләр теге мөтәшагыйрьләрне, ул үзебезнең бөеклек турында уйланулар, хыялланулар! Просто котырып бетәдер идек. Бу инде Язучылар союзы да түгел, башка да түгел. Штаб, чын штаб иде – яшь әдәбият штабы. Булмаган кеше калмады анда. Мәһди (Мөхәммәт Мәһдиев. – *Р.Ю.*) дә килде – язучы түгел әле ул чакта. Мәһдигә рекомендация биргән кеше мин (көлә). Бүген аксакал булып йөрүче күп агайлар ул заманда әдәбият офыгында күренмиләр иде әле. Шул чор эчендә бик күпләрне Язучылар союзына алышуда катнашырга туры килде: Мөсәгыйть Хәбибуллин, Мансур Хәсәнов, Сафа Сабиров, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин...

*– Элек татар зыялылары дөньяга тоташкан булган. Чит илләрдә укыган кешеләребез дә шактый. Совет чорында бетә бу. Шуңа күнеккәнбез дә инде. Сибгат агабыз әнә шигырь дә язды, Англиягә барырга кыстыйлар, бармыйм, арышларның баш кысканын күрми калырмын, дип.*

– Әйе! Мин аны көлеп сөйли торган идем инде.

*– Син менә күп йөрдең Союз буйлап та, дөнья буйлап та.*

– Бик күп йөрдем! «Обойма»га керә башладым бит Мәскәүдә дә. Бөтен СССРны айкап чыктым, чит илләрдә дә булдым. Берәр зур әдәби бәйрәм үткәрелсә, әдәбият көннәреме анда, фәләнме, шушы Идел буе – Урал төбәгеннән Мостай Кәримне ала торганнар иде, мине ала торганнар иде. Аңа кадәр Зәки абый Нури шактый йөргән, Гариф абый Ахунов йөрде инде...

*– Ни бирде бу сиңа?*

– О-о-о! Бик күп нәрсә бирде! Син менә әйтәсең миңа, нигә Тукай булмадың, дип. Тукай буласы килмәү шуннан да әле ул. Була алмаган да булыр идем, эш анда түгел. Тукайның бөек шагыйрь икәнен соңрак та аңлаганмындыр әле. Бу йөрүләремдә дөньяда бүтән зурлыклар бар икәнен күрдем мин.

*– Синең өчен сине читтә белүләре бик тә мөһим булган кебек. Шундый шигырең дә бар бит:*

*Шагыйрь булсаң, дөнья өчен*
*даның, януың кирәк.*
*Януыңны халыкларның*
*күмәк тануы кирәк.*

– Яшермим, әйе, Союз күләмендә танылу теләге бар иде. Хәзер бүтәнчәрәк уйлыйм, теге вакытта олы максат шул иде... Мин ул чорның бик күп бөек язучылары белән аралаша алдым, шулардан күп нәрсәгә өйрәндем.

*– Нәрсәгә, мәсәлән?*

– Иң әүвәл, фикерләүгә... Микола Бажан, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Эдуард Межелайтис, Василь Быков, Давыт Көгелтиневләр, Мостай агалар бит үз халыкларын да күтәрәләр, үз әдәбиятларын дөнья әдәбияты белән бәйли беләләр иде. Безгә шул җитмәде.

Ул совет әдәбияты кумирлары белән аз-маз аралашкач, аларның үсеш юлын беркадәр чамалагач, шуны аңладым мин: үз халкыңның телен һәм тарихын юньләп белми торып, барыбер болар кебек булып булмый икән. Чөнки син үз халкыңның илчесе була алмыйсың... 1972 елда, күпме кешене аптырашка салып, Ибраһимов институтына аспирантурага керүемнең төп сәбәбе шул аның. Халык иҗатын өйрәндем. Үз халкыңны аның теле җәһәтеннән дә, фикерләү рәвеше, образлар системасы ягыннан да шәбрәк белим дисәң, иң кулае – шул.

*– Дөрес, әйе... Равил, син бит болай дип язган идең:*

*Бездә шигырь – аңлаганга –*
*башың Себер китәрлек.*

*Пафос көчле монда синең. Себер китүгә лаек булу шагыйрьнең буй җитмәс тәвәккәллеге сыман бәяләнә... Хәсән агабызның Публий Овидий Назон турында бик матур шигыре бар әнә – ике мең еллап элек Римнан сөрелгән шагыйрь. «Вөҗданы белән сөйләшкән» язучылар Себер юлына гел әзер торырга тиештер инде ул. Бер Аурупа шагыйре, француз бугай, репрессияләнгән совет шагыйрьләреннән көнләшүен әйтә. Шагыйрь сүзенең көчен күрсәтә бит бу, ди... Яулап алынган, җәберләнгән татар халкының шагыйрьләренә каләмне очлы тоту һич хәрәм булмас иде югыйсә. Ләкин өлкән буын язучыларыбыз сәяси ирек мәсьәләсенә дә, милли азатлык мәсьәләсенә дә бөтенләй кагылмадылар кебек. Кемнәрнедер Себер җибәргәннәр, төрмәгә япканнар яки хәтта атканнар икән, моның өчен түгел, ниндидер ялган чебеннәрдән фил ясап. Күп кенә татар шагыйрьләренең чәче золым системасына шигъри рәхмәтнең татлырагын эзләп агарды.*

*Инде күктән фани җиргә төшеп уйлансак... син хаклы да кебек... Син искәрткәнчә, ул усал заманда урыслар да әллә ни майтара алмаган әнә. Ә бит юкса... Бәлки, беләсеңдер, шундый әйтем кебек нәрсә бар икән: «Мәскәүдә тырнакны киссәләр, Киевта бармак чабалар». Казанда кул кисәләр дип өстәгәндә дә ярыйдыр, Казанны гел Куликово кырының дәвамы итеп карадылар бит.*

*Тыелган чикне кемнәр үтә алды бездә? Салих Баттал. Аның Мәскәү редакцияләренә җибәреп басылмаган, КГБ кулына эләккән «Я отрекаюсь» дигән памфлеты соңыннан «Идел»дә чыкты синең кереш сүз белән. Себерне инде бер урап кайткан Хәсән агабызның татар теле турындагы «Алмаз» дигән шигыре һәм Искәндәр Рушан исеме белән басылган, Табеевның җен ачуын чыгарган берничә шигыре. Наҗар Нәҗминең «Татар теле» дигән шигыре. Разил Вәлиевнең «урыс капкасы» турындагы строфасы. Әхсән Баяновның «Шаһгали» дигән шигыре. Илдар Юзеевның Тукайның патша белән сөйләшүе турындагы шигъри әсәре. Батулланың кайбер әкиятләре... Беткәндер дә, бәлки? Бу фонда син нык аерылып торасың. Синең берүзеңнең унлап «хәтәр» шигырең бар. Аларның кайберләре әле хәзер дә бик җилле яңгырый.*

*Шигырь юлы арасына милли эчтәлекле мәгънә салу сезнең буында һәм соңрак егетлек, үзенә күрә бер кыюлык модасы санала башлады. Ләкин... аңлыйлар идеме соң моны? Синең теге шигырьдә дә бит, «башың Себер китәрлек» алдында, «аңлаганга» дигән сүз тора.*

*Чернышевский үзенең «Что делать?» дигән романына мондый аскы эчтәлекне, Батуллача әйтсәк, астарны мул салган. Аңласыннар өчен «проницательный читатель» дигән өстәмә образ кертә ул, ара-тирә, шуңа мөрәҗәгать иткән булып, җеп очын күрсәтеп ала. Безнең күбесенчә бер күзәнәкле әсәрләр генә укып өйрәнгән укучы синең кинаяләреңне генә түгел, тел яшерми әйткән «крамола»ларыңны да аңлап җиткермәде бугай. Кәефеңне кырмый идеме бу нәрсә?*

– Юк, ул вакытта кәеф кырылмый иде. Шигырь укучы күп бит. Арада аңлаучылары да була. Шул җитә иде... Искәргәнлекләре миңа да килеп ирешкәли иде. Хәзер менә – да! Хәзер күрмәүләренә, аңламауларына аптырыйм да, кимсенәм дә.

*– Синең белән бергә Күктүбәдә Иҗат йортында булганда, мин синең Кырым татарлары дип ут йотып йөргәнеңне күрдем. Байтагын белә, аралаша да идең бугай. Кырым татарларын яклап язган көчле-көчле шигырьләрең дә бар. Ул чакта бу да «хәтәр» тема иде бит.*

– Монысы табигый инде аның. Кырым татарларын илләреннән сөрүне хуплап та әсәрләр язылды. Мин менә шуңа шаккатам.

*– Бездә түгелдер ич?*

– Бездә түгел дә, барыбер совет әдәбиятында инде. Дүрт-биш язучыны атый алам...

*– Акчага, әйбергә кызыкмадың бугай инде. «Мин һаман да мөлкәтсез-малсыз килеш», – дисең. Ә менә җитәкче урыннарга ымсынган чаклар булмадымы?*

– Юк, ымсынмадым. Мине шуңа әзерләгәннәр иде үзе. Язучылар союзы председательлегенә. Башта Әлмәткә җибәрделәр әле, андагы Язучылар оешмасын җитәкләргә.

Ә анда бу урынга өметләнеп торган кеше булган икән. Малай гына әле мин ул чакта. Күпләр шунда карап торды. Көтте: нишләр икән бу? Аннары Юныс Әминовлар, Гамил Афзаллар, булдыра алганымны күрепме, ярдәм итә башладылар. Биш еллап эшләгәч, әйткәнемчә, үз теләгем белән Әлмәттән китеп, аспирантурага кердем. Вәлиев, өлкә комитеты секретаре, ачуланып ташлады үземне: «Ты что, мы готовим тебя, а ты!..» Союз председателе урынбасарлыгыннан да үзем киттем. Бер үк вакытта яхшы шагыйрь дә, яхшы администратор да була алмасымны аңладым. Аннары 13 ел профессиональ шагыйрь булып бик иркен яшәп алдым мин. Анда инде исем дә бар иде, китаплар да чыга – яшәп була! Соң гына торам, төне буе утырам. Табигатькә чыгып хозурланып кайтам... Менә син дә бер килеп киткән идең миңа.

*– Әйе, өчәүләп урманда чаңгыда йөреп кайттык: син, мин, Миңлебикә ханым.*

– Әйе, шулай өч-дүрт сәгать урманда чаңгыда йөреп кайта торган идем. Аннары малайлар белән күрешергә чыгам – атнага бер-ике тапкыр. Бераз кәефләнеп утырабыз – бөеклекләр турында сөйләшеп. Дөресен әйтим, байтак эшләп калынды ул елларда.

*– Равил, бер шигыреңдә син болай дип тә әйтәсең: «Безнең бу – савапка торырлык гөнаһлар».*

– Әйе-әйе, бар андый шигырь.

*– Синең лирик герой анда, бәлки, ике җәннәтлек савап эшләп яткандыр, анысын белмим. Беләсем дә килми. Хәзер бер олы темага күчәргә телим мин. Татарның язмышы кыл өстендә. Әхлак та калмаса, бөтенләй бетәбез... Менә син, Равил, татар өчен җан аткан кеше, әйт әле: татар зыялылары, аларның да каймагы булган язучылар, журналистлар, галимнәр, сәнгать әһелләре, ягъни халык үзе өчен үрнәк санаган, гел күз уңында торткан катлам – без – халыкның әхлакый хәле өчен үзебезне җаваплы санарга тиешме? Әллә битараф кына күзәтеп тора алабызмы? Бусы муллалар эше аның дип?*

– Битараф кала алмыйбыздыр инде.

*– Алайса, без халыкка әйтергә тиештербез бит. Йә Ислам әхлагы буенча яшик дип. Йә халкыбызның шактый дәрәҗәдә шул ук дини әхлакка нигезләнгән әхлакый традицияләре буенча дипме шунда. Йә әхлак ул инде искергән нәрсә, һәркем үз күңеле кушканча яшәсен дипме? Нәрсә булса да әйтергә тиештербез ләбаса.*

– Әхлак, әхлак... Киңрәк алыйк әле бу мәсьәләне. Сүз бит милләт язмышы турында бара, әхлак – аның төп нигезләреннән берсе. Хәзер әгәр дә дөньяда милләтне саклап калу буенча берәр рецепт бирүче кеше булса, ул бөек кеше булыр иде. Милләтне әхлак белән генә саклап калып булмый.

*– Мин әхлак белән генә димим бит. Тагын күп нәрсәләр кирәктер. Әхлак бит аларның юлын кисми. Ләкин, әхлак бетсә, башкалары таяныч була алырмы безгә?*

– Әхлаксыз булмый инде, сүз дә юк. Әгәр дә мөстәкыйль дәүләтебез булса, үз әхлагыбызны урнаштырыр идек... Минем хәтта Төрекмәнбашын да гаеплисем килми. Аның үзенә күрә идеяләре-ниләре бардыр, ул нәрсәгә булса да омтыладыр. Гарәп илләрендә, Иранда да нәрсә дә булса бардыр, белеп кенә җиткермибездер... Ә менә без – кеше арбасындагы кеше. Баракта яшәп, үз бүлмәңдә менә дигән әхлак нормалары булдыра алмыйсың.

*– Омтылырга кирәктер бит?*

– Кирәк, сүз дә юк.

*– Тукай була алмадың дигәнемнең тагын бер мәгънәсе шул: синнән милли лидер чыга ала иде бит, Равил. Җиңелүебез лидер булмаудан да ул. Мондый кешенең сәяси көрәш башында торуы да мәҗбүри түгел. Рухи лидер булуы да җитә. Халык гөж килер иде: «Фәйзуллин болай дип әйткән!», «Фәйзуллин тегеләй дип әйткән!» Менә шундый Фәйзуллиннан мәхрүм калдырдың бугай син безне, Равил!*

– Бәлки, безнең җирлектә андый лидерга чыгарга хут бирмәгәннәрдер? Безнең татар бик тә үзенчәлекле халык бит ул... Аннан, тегеләр – Айтматовлар, Мостай агалар – алар бит чагыштырмача «чиста кыр»да калкып чыкканнар. Ә бездә бит әдәбият бай. Үтә зурлар, алыплар булмаса да, тигезрәк талантлар күп. Алар бер-берсенә бик калкынырга ирек тә бирми бит әле... Татарның бердәм булмавы бик борчый мине. Адәм көлкесе бит: галимнәребез урыс гәҗитендә мәш килеп сугышып яталар! «Адәмнәр имин булсын өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән затлар» – галимнәрең өерелеп талаша икән, нинди әхлак булырга мөмкин ди?

Мине бик борчыган тагын бер нәрсә хәзер – татарның үз телендә укымавы. Язучының төп иҗат нәтиҗәсе китап бит инде. Китапны язу бер авыр, чыгару – янә авыр, инде чыккан китабың да халыкка барып ирешми икән – бусы иң аянычы...

Мин үземнең язмышымнан бик канәгать болай. Чөнки теге бәләкәй чакта алган максатка туп-туры, артык тайпылышлар ясамыйча бара алдым, бу – бер, икенчедән, язылган әйберләрнең байтагын китап итеп чыгара алдым. Бик зур эш бу... Иҗат ягыннан ниндидер биеклеккә ирешелгән инде. Биеклектә калу дигән нәрсә дә бар бит әле. Ходай саулык биреп, шул биеклекне саклый алсам әгәр...

*– Ул саулык дигәннән, заманында спорт белән шулай яратып Җәлил шөгыльләнгән бугай. Безнең чорда син инде менә.*

– Синнән кала.

*– Ай-һай, алай микән? Шәп йөзәсең – диңгездә синең койрыкны гына күреп кала торган идем мин. Зур теннис уйнаганыңны сокланып күзәткән бар, үзем моңа шул синең тирәдә өйрәнә башладым бит инде... Башкалар чыдамаганда рәхәти чыдап, «ләүкә-тәхеттә» дә янәшә утырган булды әле безнең.*

– Әйе, булды.

*– Утыз еллар элек, алдан ук запаска диптер инде, менәниләр язып куйгансың син, Равил:*

*Күз алдымда күпме картайдылар!*
*Бер без бирешмәдек шикелле.*
*Тагын:*
*Ә шулай да без – без булырбыз гел!*
*Дәрте калыр, дәрман бетсә дә!*

*Бәлки, әңгәмәне шушы шигырь юллары белән очларбыз?*

– Яхшы булыр. «Мин» димәгәнмен бит, «без» дигәнмен.

## *«ЗАМАНГА ИШ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...»*

*(Разил Вәлиев белән әңгәмә)*

**Разил Вәлиев.** *Равил туган, мин сине инде кырык елга якын беләм: кылган гамәлләреңне дә, иҗатыңны да һәрдаим кызыксынып күзәтеп барам. Бер мин генә алай эшләмимдер, чөнки син күпләр өчен кызыклы шәхес, ил күзендәге кеше.*

*60 нчы еллар уртасында ук инде син татар шигърияте ндә мәйдан тоткан шагыйрь, җәмгыятьнең игътибар үзәгендәге гайяр егет идең. Әдәбият тирәсендәге безнең кебек яшь-җыркыннар гына түгел, олпат-олпат язучылар да нигәдер синең янга тартыла, синең белән әңгәмә корырга атлыгып тора иде. Чөнки син ул чакта ук инде саллы фикерле, зирәк акыллы, тумыштан зыялы зат идең. Еллар үткән саен, билгеле, холкыңда да, фигылеңдә дә үзгәрешләр булгандыр. Әмма син үзеңнең әлеге асыл сыйфатларыңны югалтмадың, киресенчә, аларны камилләштердең генә кебек.*

*Нәкъ кырык ел элек очрашкан-сөйләшкән чакларны искә төшереп, бүген дә сүзебезне шигърият, әдәбият язмышы, милләт һәм дәүләт язмышы, һәм шулай ук үзебезнең язмыш турында алып барсак, әйбәт булыр иде. Әйдә, иң элек шуларның соңгысыннан – үзебездән*

*башлыйк әле... Синең язмыш үзең уйлаганча, үзең теләгәнчә бара дип санныйсыңмы? Гомер башындагы – бала чактагы хыялларың, теләкләрең тормышка аштымы?*

**Равил Фәйзуллин.** Зурлап әйткән сүзләрең өчен рәхмәт. Сорауга җавап шул: язмышка рәхмәтлемен. Кайчак уйлап та куям: Ходайның яраткан бәндәләренең берсе булып чыктыммы әллә? Бала чактагы хыялларымның байтагы тормышка ашты. Малай чакта көндәлегемә болай дип язып куйганмын: «Шагыйрь булып, китабыңны тотып кайтсаң иде Туган ягыңа!» Чынга ашты бит! Китаплар да байтак чыкты. Татарчасы, русчасы дигәндәй... Гомумтиражлары – миллионга якын. Азмы-күпме үз укучыларым даирәсен булдыра алдым. Кыскасы, кече яшьтән үк анык максатым булды, төрле якка сибелмичә, юнәлгән кыйблага барырга ихтыяр көче табылды, һәм – бик мөһим нәрсә – максатка ирешү юлында шарт-мөмкинлекләр дә булмады түгел.

**Р.В.** *60–70 нче еллар белән чагыштырганда, бүгенге көндә әдәбият-сәнгатьнең җәмгыять һәм дәүләт мәйданында тоткан урыны шактый кечерәйде, тарайды кебек. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсың?*

**Р.Ф.** Төп сәбәп Вакыт факторында. Дөнья гел үзгәрештә. Моннан кырык-илле еллар элек булган вазгыять бүгенгедән бик нык аерыла. Ни дисәң дә, бу вакыт эчендә ике буын диярлек алышынды инде. 1960–1970 еллар әдәбиятын, сәнгатен, асылда, сугыш чорын күргән, күп сынау-михнәтләр кичергән буын вәкилләре тудырды. Бу әдәбиятны укучы да, нигездә, шул чорда тәрбияләнгән кешеләр булды. Ул елларда төп тәрбия чыганагы – китап, аннан кала – радио. Телевизор әле яралып кына килә. Компьютер кебек могҗизаларның исе дә юк... Китап – тәхеттә! Рухи яктан кешеләрнең, шул исәптән безнең һәм бездән алдагы буыннарның үзгә бер бәхетле чоры! Гомумән, уйланып хисләнү, гаҗәпләнеп хыяллану – әдәбият-сәнгатьнең үзәген тәшкил итүче компонентлар. Хәзер дөньяны прагматик акыл басты. Техник белем артты, Җир-планетаның сере кимеде, кешеләрдә гаҗәпләнү тойгысы саекты... Уенчыгы күп бала үзенчә бәхетсез бит ул – аны нәрсә беләндер кызыктыру кыен... Читкәрәк кителде шикелле. Үзебезнең хәяттан бер мисал: үткән гасырның 30–50 нче елларында татарның рухи мохитен, бигрәк тә авыл мохитен, Такташ шигъриятеннән тыш күз алдына китереп була иде микән? Мөгаен, юктыр. Ә менә XX гасыр ахырын татар гавамының күпчелеге Такташсыз тәмамлады дип тә әйтеп буладыр. Мөкиббән китеп, яшьләр егылып укыймы хәзер «Мокамай»ларны, «Алсу»ларны?.. Шәһәр яшьләре күбрәк «Һади Такташ» дигән җинаятьчел төркемне беләләр... Такташ үзенең бөек шагыйрь булуыннан туктамады лабаса! Уйланырлык нәрсәләр күп...

Һәр заманда, һәр җирдә «кеше җаны өчен көрәш бара»! Хәзер бу көрәшкә безнең буын кешеләре өчен беркадәр ят бүтән ысуллар, информациянең бүтән төрле чаралары тартылды...

**Р.В.** *Атлаган саен без: «Тормышлар авырайды, катлаулы заманда яшибез», – дип зарланабыз. Кайчандыр син үзеңнең бер шигыреңдә: «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга», – дип язган идең. Шулай булгач, иҗат кешесенең, әдәбият-сәнгать әһелләренең шундый хәлдә калуына бүгенге заманны гына гаепләү дөрес микән? Талантлы шагыйрьләр, язучылар бүген дә җитәрлек, ә 60 нчы еллардагы күтәренке иҗат рухы, иҗат халәте нишләптер сүрәнәйде. Шагыйрь буларак та, җәмәгать эшлеклесе – баш мөхәррир буларак та син бу борчулы халәтнең сәбәпләре һәм аның нинди нәтиҗәләргә китерәчәге хакында еш уйланасыңдыр инде...*

**Р.Ф.** Барыбер заман факторын исәпкә алмау дөрес булмас. Мәгълүм дастанда әйтелгәнчә, «Заман кемнең заманы?» Кызганыч, хәзер акча заманы (дөресрәге, хәзергә акча заманы, тормыш гел генә кыргый базар көенә бармас). Безнең чорда, нигезе дөресме-юкмы, барыбер иман заманы иде. Исеме нинди «изм» белән генә аталмасын, халыкта якты киләчәккә ышану бар иде. Ул ышанычны кешеләр күңеленә иңдерүчеләр кемнәр иде соң? Искерәк терминология белән әйтсәк, идеология хезмәткәрләре – укытучылар, язучылар, сәнгатькярләр... Ышаныч тудыручыларның абруй-дәрәҗәләре дә зур иде. Гомумән, без үскәндә укытучы кеше – изге, язучы кеше Алла кебек кабул ителә иде. Ә хәзер?.. Вазгыять

бөтенләй бүтән! Кем гаепле? Минемчә, гаепнең бер очы – бүгенге дөнья җиһангирләренә – зур сәясәт башында торучыларга тоташа. Алар халыкны кат-кат алдадылар, гади кешеләрнең өметен кистеләр. Сүзләре бер, гамәлләре икенче төрле булды. Халык, нигездә, бернәрсәгә дә ышанмый башлады. 60 нчы елларда, мәсәлән, бездә – әдәбиятка яңа аяк басучыларда – шигъри сүз белән дөньяны яхшырта алабыз дигән тирән инану бар иде. Бездә генә түгел, миллионлаган әдәбият-сәнгать сөючеләрдә дә... Хәзер язучы халкы үзе дә «шигырь – бер нәрсә, дөньяны әйләндерүче чыгыр икенче нәрсә» икәнен бик яхшы төшенде инде...

Ә иҗади мохит, иҗади атмосфера, иҗади рух мәсьәләсенә килсәк, бу очракта байтак нәрсә иҗатчыларның үзләреннән дә тора. Әйе, бездә сәләтле, хәтта талантлы, эшсөяр каләм ияләре аз түгел. Берничә дистә исем санап китәргә мөмкин булыр иде. Алар – безнең байлыгыбыз. Әмма безгә максади берлек җитенкерәми. Әлбәттә, һәр иҗат кешесе аерым бер дәүләт кебек; сүз иҗади эзләнүләр, иҗат стиле берлеге турында бармый. (Без төрле реализмнар тарафдарлары булып яшәп карадык инде.) Сүз – милләт язмышында стратегик берлек турында бара. Өстәвенә кайберәүләрдә шәхси амбицияләр дә кирәгеннән артык булып чыкты: кемдер үзен Тукай дип саный; кем Наполеон яки Гете сыйфатында хис итә; кемдер мәхәббәт лирикасында үзен, ким дигәндә, Петрарка дип исәпли; кайбер кемсәләр, түрә булгач, мин язучыларның иң кәттәсе – беренчесе дип уйлап саташа... Тормыш ыгы-зыгысына бирешеп, көнкүреш ваклыкларыннан күтәрелә алмыйча, Бахус бабай хозурында үзен югалтканнар да аз түгел...

Шулай да борын замандагы бер хаким-җиһангир сүзләрен ара-тирә искә алу да ярыйдыр. Гаскәрләре белән сугыш-орышка керер алдыннан ул әйткән, имеш: «Ишәкләр белән шагыйрьләрне саклагыз! Алар безгә сугыштан соң да кирәк булачак әле». Өстәп әйтергә генә кала: шагыйрьләр тарих өчен дә кирәк бит әле!

**Р.В.** *Халык, милләт язмышы турында уйламаган, кайгыртмаган кешедән язучы да, олы шәхес тә чыкмый торгандыр. Ә бүген милләтебезне саклап калу, аның гомерен озайту өчен иң беренче чираттаниләр эшләргә кирәк дип саныйсың?*

**Р.Ф.** Әгәр бу сорауга гамәлгә ашырырлык анык җавап бирә алсам, минем гражданлык статусым аерым дәрәҗәгә ия булыр иде... Әңгәмәбезнең иң мөһим һәм иң авыр соравыдыр бу. Моннан 30 ел элек язылган «Кирәк безгә» дигән шигыремне хәтерләп үтсәм, читләтеп булса да, өлешчә җавабым саналыр, бәлки.

Тәкъдир шундый: бик аздан да олы шатлык
таба алырга,
сөенергә кирәк безгә.
Олимп уты ягар чакта,
сүнеп барган
учагыңа тын өрергә кирәк безгә.
Заманга иш булыйм дисәң –
кем бер янса –
ун яшьнәргә,
ун янарга кирәк безгә.
Тормыш дигән халыкара сабантуйда
батыр булып
калалырга
кирәк безгә!

Азмы-күпме булган дәүләтчелегебезне сакларга, ныгытырга, көчәйтергә тиешбез. Яшәешебезнең хәзерге этабында бу – мәҗбүрият. Аның өчен халыкның милли үзаңы югары булуы кирәк. Бу изге гамәлдә язучыларыбыз шактый өлеш кертә ала дип уйлыйм.

**Р.В.** *Соңгы елларда безнең җәмгыятебез бик нык, хәтта кирәгеннән артык нык сәясиләште кебек. Иҗат әһелләребезнең шактые сәясәт урманына кереп адашты. Син үзең дә замананың иң болгавыр чорында – 90 нчы еллар башында, Югары Совет депутаты булып, ул карурманга кереп чыктың. Менә хәзер, сәясәттән бераз читләшкәч, бу мәсьәләгә ничегрәк карыйсың? Иҗат кешесе сәясәттәнерактарак торырга тиеш дип саныйсыңмы? Шигърият белән сәясәт бер-берсеннән нинди ара калдырып яши алалар?*

**Р.Ф.** Сәясәттән ераклашкан саен,
Табигатькә ныграк елышам.
...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
елан үтеп киткән юл аша.

Моннан чирек гасыр элек язылган бу дүртьюллыкта да куелган сорауга җавап сыман ишарә бар кебек. Сәясәт дигән төшенчәгә кем нинди мәгънә сала бит! Бар – агымдагы тактик максат, бар – стратегик максат. Әгәр иҗат кешесе бүгенгесен бүген үк бетереп бара торган сәясәттә «үсә Казан, үсә нурланып, башкалабыз Москвадан якты нур алып» җыры көенә «әреп бетә» икән, ул кеше – кызганыч. Әгәр талантлы кеше, үзенең иҗади шәхси йөзен саклап калып, халыкның киләчәген кайгыртып сәясәттә катнаша икән, аны хупларга кирәк. Безнең язучы депутатларның күбесен соңгылар рәтенә кертер идем. Шундый сорау да туа: үз милләте, үз халкы өчен җанатар кешене сәясәтче дип атап буламы? Мин шәхсән үземне сәясмән дип санамыйм. Шул ук вакытта җәмгыятебездә булган хәлләргә битараф кала да алмыйм. Әйтик, мине үзебезнең Илбашын сайлау хокукыннан мәхрүм итәләр икән, сүзләремне кәгазьгә мин теләгән алфавит белән язуны тыялар икән, ни җан белән тыныч калмак кирәк! Сәясәтче булу-булмау икенчел нәрсә, ә шагыйрь әйтмешли, гражданин булу мөһим, зарур, хәтта мәҗбүри...

**Р.В.** *Элеккерәк елларда күп кеше сүз ирege юклыктан, цензура кысуыннан зарлана иде. Инде сүз ирege дә игълан ителде, цензура да бетерелде, әмма аңа карап зарланучылар иҗатта әллә ни майтара алмадылар, журналистика да, әдәбият-сәнгать тә дәррәү күтәрелеп, берничә башка үсеп китмәде. Әллә соң ул «сүз ирege» дигән нәрсә шигърияткә зыян гына китерә микән? Демократия азрак булган саен, шигырь теле – эзоп теле көчәя генә бара бит... Әнә Муса Җәлил үзенең иң яхшы шигырьләрен Моабит төрмәсендә язган...*

**Р.Ф.** «Сүз ирege» дигән сүздә күпмедер шартлылык бар. Нинди генә заман, нинди генә катылыклар булмасын, Сүзне тыю мөмкин түгел. Уйны богаулап булмый бит! Дөрес, кеше җанына курку салып, Сүзнең канатын кисеп, вакытлыча аның яңгырау, таралу, басылу сферасын чикләп була. Тарих күрсәткәнчә, диктаторлар идарә иткән чорларда була андый хәлләр. Әгәр, үзебезнең җирлеккә якынрак килеп, татар әдәбиятына күз салсак, шуны әйтә алабыз: төрле гасырларда – бик борынгы заманда да, ханнар заманында да, патшалар заманында да булган әдәбиятыбыз һәм хәзер дә бар! Ниндидер шартлар булмаса, әдәбият та, сәнгать тә туа алмый! Кысулар, чикләүләр, икенче төрле әйткәндә, цензура булмаса, әлбәттә, Әдәбият Агачы кәүсәлерәк, ябалдашлары мәхәббәтлерәк күренер иде. Шул моментны да искәртеп узыйк. Күп нәрсә шәхескә, талантның зурлыгына бәйле. Пәһлеваннар белән һәркем исәпләшә! Зур талантлар торгынлык дигән заманда да менә дигән әсәрләр яза алдылар: Ә.Еники, С.Хәким, С.Баттал, А.Гыйләҗев, Ш.Хөсәенов, Г.Афзал, М.Мәһдиев, М.Юныс, Т.Миңнуллин, И.Юзеев һ.б.

**Р.В.** *Синең үзеңне дә шулар рәтенә кертәсе килә. «Космополит түгел», «Гөмбәзләре кояшмыни!», «Тәкъдир язган эшләр...», «Колонизатор әлифбасы», «Дошман – сигез, без – тугыз», «Шайтан каласыннан КамАЗларга карап», «Әлмәттә җир тетрәү» һәм башка дистәләгән, заманы өчен шактый кыю шигырьләрең цензура көчле саналган заманда язылды бит.*

**Р.Ф.** Хәтерләвең өчен рәхмәт. Сүземне дәвам итеп шуны гына өстисе килә: кулымнан килсә, хөр фикергә түгел, халтурага цензура кертер идем мин. Азмы-күпме такмак чыгара алган, кесәсе калын булган һәркем «китап» чыгара ала хәзер. Элек мөмкин булмаган эш. Чын китапның кадерен җибәрүдә искиткеч зыян салды бу үзешчәннәрнең «китаплары»! Нигездә, бихисап саналган хосусый нәшриятлар чыгарды аларны...

**Р.В.** *Әйе, бүгенге көндә Татарстанда төрледән төрле эреле-ваклы ике йөздән артык нәшрият бар. Шулай ук яңа журналларыбыз, гәҗитләребез дә пәйда булды. Болары яхшы. Әмма ул китапларның, гәҗит-журналларның тиражлары, гадәттә, берничә меңнән артмый. Җиде миллион халыкка бер тамчы гына бит бу! Китап кибетләребезнең күбесе*

*ябылып бетте, хәзер инде китапханәләргә дә кул сузучылар күренә башлады. Укучысы булмаса, киләчәктә әдәбият үзе дә әкренләп юкка чыга барырга мөмкин бит. Без бу мәсьәләне Дәүләт Советында кат-кат күтәрәбез, таләп итәбез. Ә җитәкчеләр: «Заманалар үзгәрде, хәзер халык китаптан читләште, компьютерга бирелде», – диләр. Мисал итеп көнбатыш илләренә төртеп күрсәтәләр. «Әдәбият-сәнгать ул халыкның кечкенә бер өлешен генә кызыксындыра», – дип тә куя*лар. Менә син үзең ул агайларга ничегрәк җавап бирәсең?

**Р.Ф.** «Пәри – башка, җен – башка» диләр безнең халыкта. Россия гомер-гомердән читләргә кызыгып, читләрдән өлге алып яшәде. Әйтик, дин тәгълиматы византиялеләрдән кергән булса, дәүләт төзелеше системасы – Алтын Урдадан... Хәзер дә әнә, Европа күзенә карап, Америкага иярмәкче... Дистәләгән милләтләрне бетереп, тоташ Россия халкы (дөресрәге, рус халкы) ясамакчы. Янәсе, Америкадагы халыклар американы дип йөртелә бит... Аңлапмы, аңламыйчамы, мондый «прогресс» карашлылар безнең җирлектә дә бар. Әдәбият-сәнгатьнең, бигрәк тә әдәбиятның, безнең рухи тормыштагы гомер бакый алып торган урынын белер өчен, аз гына артка – үткәнгә, тарихка борылып карау кирәк. Мең еллык әдәби тарихыбыз бар, дибез. Әйе, бу шулай. Болгар яки Алтын Урда чорымы, Казан ханлыгы яки соңгырак чорлармы – һәр дәвердән конкрет шәхесләр, конкрет әдәби әсәрләрне санарга була. Йә, мондый байлык күп халыкларда бармы? Русларныкымы яки нибары ике йөз еллап тарихы булган американыларныкымы? Шуңа күрә безнең халык язмышында әдәбиятның үзгә роле, үзгә миссиясе. Әдәбият, җыр-моң – безнең төп байлыгыбыз. Төптән уйласаң, безнең бүтән милли байлыгыбыз – матди байлыгыбыз юк та бугай әле... Шунысын да искәртик: иң авыр гасырларда да дәүләтчелекнең кайбер функцияләрен (тәрбия, мәгърифәт, хөкем кануннарын...) теге яки бу күләмдә әдәбият саклап кала алды бит. Әгәр – диниме, дөньявимы – әдәбиятыбыз булмаса, бездә бүгенгәчә исән калган дәүләтчелеккә омтылу хисе дә булмас иде. Әгәр чыннан да «әдәбият-сәнгать ул халыкның кечкенә бер өлешен генә кызыксындыра» икән, бу – безнең фаҗигабез. Без һәммәбез дә – син олы түрәме, гади мөгаллимме – халыкка тарихи чынлыкны аңлатып, милли үзаңны күтәрү юнәлешендә эшләргә тиешбез. Үзләрен дөнья кендеге дип санаган, болганчык чорда зур байлык (кызганыч, ул байлыкны милли байлык дип санап булмый. Хәер, ул мал-мөлкәтнең язмышы алда ничек булып бетәр бит әле. Дөнья бу!) туплаган, әлегә зур дәрәҗә йөрткән агайларга яки энекәшләргә әйтер сүз шул: кайдан чыкканны онытмаска иде!

**Р.В.** *Иҗат кешесен дә, гомумән, милләтне дә иң беренче чиратта өмет яшәтә. Әмма ләкин буш хыяллар, ялган өметләр белән гомер кичереп, үзең дә сизмичә, ярык тагарак янында калуың мөмкин бит. Безнең әдәбиятның, безнең милләтнең киләчәккә ныклы өмете, төпле ышанычы бар дип саныйсыңмы? Һәм ул нидән гыйбарәт? Нәрсәгә таяна?*

**Р.Ф.** Сораулар җитди. Яшәешебезнең асылына бәйле сораулар. Иң әүвәл шәхсән яктан чыгып җаваплыйм: әгәр әдәбиятның, милләтнең киләчәгенә өмет, ышаныч булмаса, иҗат эшенә алыныр идемме? Ышаныч нидән гыйбарәт? Чагыштырмача зур санда халык бар (хәтта яртылабы милләт гаменнән читләшкән, космополитлашкан һ.б. «лашкан» булса да), димәк, милләт бар; аңлаганнар өчен зур һәм гыйбрәтле тарих (ул бик нык бозып өйрәнелгән һәм аңлатылган; объектив өйрәнгәндә, тарихның бик күп сәхифәләре безнең милләт файдасына булачак) бар. Күпләребезнең геннарында «без дәүләтле халык булган һәм киләчәктә дә булырга тиеш» дигән эчке бер горур тойгы яши...

**Р.В.** *Әйдә, дөнья гамен бер читкәрәк куеп, үзебезгә кире кайтыйк әле... Безнең халык сине зур шагыйрь һәм мәртәбәле «Казан утлары» журналының баш мөхәррире буларак белә. Заманында син, күпләребезне көнләштереп, казна эшендә эшләмичә, шактый вакыт чып-чын шагыйрь булып кына яшәгән идең. Хәзер шул елларны сагынмыйсыңмы?*

**Р.Ф.** Сагынам, әлбәттә. Кеше буларак – яшьлекне, ир кеше буларак көчле, дәртле ир-егет чагымны сагынам. Гомумән, мәшһүр язучыларның күбесе гомерләренең билгеле бер өлешен фәкать иҗат эшенә генә багышлаганнар. Мисаллар күп, үзебезнең әдәбиятта да, бүтән халыклар әдәбиятында да. Казна эшен дә, иҗат эшен дә ал да гөл итеп югары дәрәҗәдә алып бару мөмкин түгел диярлек. Гомер – кыска, Вакыт – цейтнот...

**Р.В.** *Син гомер-гомергә һәр урында беренче булып килдең. Шигъриятттә дә, җәмәгать эшләрендә дә, китап бастыру, премияләр алу өлкәсендә дә иң элек өлгерә, яшьтәшләреңнән гел алда бара идең. Хәтта суда йөзү, чаңгы шуу ягыннан да сиңа тиңнәр табылмый иде. Син һәр эшне җаның-тәнең белән бирелеп, булсынга дип, ахырына кадәр җиткерәм дип эшлисең. Хәтта шигырь язганда, җитди нотык тотканда да маңгаеңнан тирләр тамып тора. Ә тормыш гел эштән генә тормый бит ул. Күңел бәйрәм дә сорый. Күңел бәйрәмнәрең нидән гыйбарәт синең?*

**Р.Ф.** Пенсия яшендәге кешегә җылы сүз кирәк ул дипме, артыграк мактап ташладың шикелле. Күңел бәйрәме дигәннәре хәзер күбрәк нәни улыма бәйле. Хәзер аңа дүрт яшь. Кызык чагы. Аңа дөнья кадәр вакыт һәм көч сарыф итәргә кирәк. Әмма ул биргән шатлыкны берни белән дә үлчәп бетереп булмый.

**Р.В.** – *Синең шигырьләреңә дистәләгән композиторлар тарафыннан бик матур көйләр язылган. Шулар арасыннан халык күңеленә мәңгелеккә уелып калырдайлары да шактый. Ә үзеңә аларның кайсысы аерата якын, аерата кадерле? Ялгыз чакларыңда күбрәк кайсы җырыңны авыз эченнән көйләп йөрисең?*

**Р.Ф.** Җыр димәктән, Разил туган, мин сине җырлар короле дип саныйм. Бу өлкәдә минем хезмәт зур түгел. Махсус җыр текстлары язганым да булмады. Заманында шактый ук исемле композиторлар аерым шигырьләргә берәр-икешәр (нигездә, берәр) көй яздылар язуын. Әмма алар күп түгел. Кайберәүләр «Аккошлар» (Ф.Әхмәтов көе) җырын яхшы диләр. Минем үземә сүзләре бик үк ошап бетми. Ш.Шәрифуллинның «Иясез шатлык» дигән бер җыры бар. Аны радиодан сирәк кенә биргәлиләр. Ошый ул миңа, сүзләреннән канәгатьмен. Шушы җырны кайчак авыз эченнән мыгырдаштыргалыйм...

**Р.В.** *Сүзебез ахырында соңгы вакытта кылган гамәлләрең һәм киләчәккә ниятләгән эшләрең турында берничә сүз әйтсәң икән.*

**Р.Ф.** Үткән елда төп эшләремнең берсе Татарстан Язучылар оешмасы тарихын язу булды. Архив документларына нигезләнеп, аерым фактларга һәм вакыйгалар нисбәтендә соңгы чор татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен ачыкларга тырыштым. Бу хезмәт аерым китап рәвешендә чыкса да, алга таба мин аны тулыландырырга телим. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүчеләр өчен бер кирәкле кулланма булсын, дим.

Соңгы ун елда язылган шигырьләремнең аерым китап булып дөнья күргәне юк. Элегрәк ике елның берендә (кайчак хәтта ел саен!) яңа шигырь китапларым чыга иде. Монда берәүнең дә гаебе юк. Нәшриятка җыйнап, әзерләп биргәнем булмады. Яңа дигән шигырьләрем, алар арасында бик кыскалары да, поэмага тартым озыннары да бар. Җыенысы ун табак чамасы булыр. Шуңа өстәп – вакыт җитте бугай – истәлек-хатирәләр дә язасы килә. Гыйбрәт алырлык, күргән-кичергән хәлләр шактый. Әдәби мохиттә байтак яшәлде бит.

*2003*

**V**

*Сәясәттән ераклашкан саен,*
*Табигатькә ныграк елышам.*
*...Тәгәрәде кызыл кыргый алма*
*Елан үтеп киткән юл аша.*

## *АГЫМСУЛАР БУЙЛАП ТУГЫЗ КӨН*

Әй, җылы, ямьле җәй! Терек ияләре өчен мәрхәмәтле фасыл! Безнең якларга тансыклатып киләсең дә, ашыгыбрак китеп тә барасың. Суыклар килгәч, җитмирәк калганлыгың бигрәк тә сизелә... Җәннәт дисәләр, кышкы кар көртләре, боз челтәрләре түгел, җәйнең чәчәкле-җимешле матур күренешләре күз алдына килә. Көн итү, яшәү өчен җаен шарт-мөмкинлекләр,

сихәт-рәхәтлекләр күбрәк шул! Кояш нурлары күзләрдә чагыла, талгын җилләр битләреңне иркәли, җылы яңгырлар дөньяны чәчәкләп яшеллеккә төрә... Тирә-юньдә – туган җирнең назланып пешкән нигъмәтләре... Чишенеп-туарылып, хозурланып җиңел киемдә йөрисең. Теләсәң – үләндә ауна, җиләген өзеп кап, теләсәң – кызынып ят, елга-күлләрдә коен, чишмә улагыннан аккан су толымына йөзеңне куй...

Бу язмам су белән бәйләнешле, дөресрәге, елга буйлап үтелгән сәяхәткә бәйләнешле. Җәй турында берничә җөмлә язуымның очы да суга, аның бөеклегенә барып тоташа. Чөнки әйләнә-тирәбездәге сулыклар – елга-күлләрнең тулы хасиятен, бәрәкәтен без фәкать җәйдә генә тоя алабыз. Кышын суны көндәлек яшәешнең хаҗәте, таләбе белән генә файдаланабыз бугай. Нишлисең, бөтен дөньяны кар каплаган, галиҗәнап Су калын боз астында...

Ә бит төптәнрәк уйласаң, безнең җисми асылыбыз да судан гыйбарәт ич. Кеше организмының өчтән икесе судан тора, диләр. Мин үзем – елга-күлгә, диңгез-суга кечкенәдән бирелгән кеше. Балык йолдызлыгында тумасам да, йөзәргә яратам. Заманында Казансуда хәйран чакрымнар йөзелгәләде дә. Ә үткән җәйдәге йөзү (бу юлы байдаркага утырып, ишеп йөзү) бөтенләй бүтәнчә, моңарчы күрелмәгән, сынап карамаганча булды. Мари Илендәге Кокшага дигән, шактый ук киң һәм ярсу агымлы елга буйлап байдаркада 200 чакрым ара-юл үтелде. Үзем өчен гыйбрәтле булды бу сәяхәт. Шул хакта бәян итмәкчемен. Бәлки, кемнәргәдер кызык булыр.

# Беренче тәэсирләр

Автобус безне Новожильски дигән поселок бистәсенә китереп җиткерде. Кокшага елгасы аша салынган күпер яны бу. Йөзә башлау шушыннан башланачак. Финиш түбәндә – Кокшаганың Иделгә кушылган җирендәге күпер янында булачак. Транспорт фирмасыннан ялланган автобусыбыз тугыз көннән әнә шул икенче күпердә безне каршы алырга тиеш. Бер күпердән икенче күпергә булып чыга. Язмамның исемен «Күпердән күпергә» дип куйсам да дөрес буласы икән.

Бушаткач, капчык-рюкзаклар хәйран күп булып чыкты. Өч гаиләнең йөге (без җәмгысы сигез кеше) чирәмдә өч өем булып тора. Утырып йөзәсе байдаркаларыбыз да чехолланган килеш шул өемнәрдә. Бу өемнәр, хуҗалары теләгән тәртиптә, байдаркада үз урыннарына урнашырга тиеш. Эш башланды! Беренче мәртәбә байдарка җыюым. Шактый хикмәтле хезмәт. Бихисап әлүмин торбалар, болт-шөрепләр, эләктергечләр... (Өстәвенә мондый эшләрдә үземне бик маһир дип әйтә алмыйм.) Шулардан каркас ясап, сумалаланган брезент сүрү белән төреп, көймә итәргә кирәк. Нык һәм батмас булуы шарт. Үзебезне һәм йөкләрне исәпләгәндә, һәр байдарка 20 потлап йөк белән йөзәргә тиеш! Мәш килеп, бер-беребезгә булышып, бер сәгать дигәндә байдаркаларны җыеп бетердек. (Байдарканы кайберәүләр, кыскартып, байда дип тә йөртә, мин үзебезчә аны каек дип язармын.) Үзе тар, ә озынлыгы 5 метр чамасы көймә-каек инде ул байдарка дигәннәре.

Әчке бер тантаналы хисләр кичереп, каекларыбызны суга төшердек. Йөкләрне төядек. Каекның уртасына саргылт жилет кигән 6 яшьлек улыбызны (экспедициянең иң яшь әгъзасы!) утырттык. Капчыклар, рюкзаклар уртасына чумган Газиз ояда баскан казны хәтерләтеп куйды. Каекның алгы башында Наилә, ә артка үзем урнаштым. Киң елга киңлегендә өч каектан торган «флотилия»! Өч гаилә-оя – сигез кеше. Алты ишкәк. Як-ягыбызда – ике яр. Елга – бер. Максат бер – 200 чакрымны туктала-туктала йөзеп үтү. Ишкәкләр белән беренче талпынып-селтәнеп ишүләр. Аллага тапшырдык, хәерле сәгатьтә!

Ишә белсәң, шактый кызу бара икән бу очлы борынлы каек. Биш минут эчендә елганың ике борылышын үтеп тә өлгердек. Ян-яктагы күренешләр бер-бер артлы алышынып тора. Гаҗәеп манзаралар! Өстә аяз күк булып кояш көлеп торса, тагын да шәп буласы да бит!.. Нишлисең, көн сүрән. Сүрән генә түгел, яңгыры да сибәли, изүләрне чишү түгел, сәдәпләрне төймәләргә туры килә. Хәрәкәттә талгын уйларга бирелү кыен (армиядә солдатларны тикмәгә генә тик тотмыйлар!). Шулай да уйланыла. Өлкән яшьтәге кешеләргә хас фәлсәфәгә дә тартылыныла. Әлегә бик гади сорау-уйлар башта: бу сәфәргә бала белән чыгу дөрес булды

микән? Хәвеф-хәтәр генә була күрмәсен! Сәфәр ахырында сөенечләрем күбрәк булырмы? Әллә... Дусларым артырмы, кимерме? Шәфкатьлерәк булып кайтырмынмы өемә, әллә...

Кокшага – Мари Илен иңләп агучы матур бер елга ул. Безнең Ык елгасына охшаса да, аннан киңрәк, ярсурак. Мари урманнары дигән тәгъбир һәркемгә билгеле. Бу республиканың яртысын диярлек (45 процент чамасы) урманнар били әлегә. Әнә шул урманнарны ерып агучы елга инде ул Кокшага. Ага-ага, ишә-ишә карап барасың: нинди илаһилык. Табигый сафлык! Кеше дигәннәре әлегә бу тирәләрне пычратырга, имгәтергә өлгермәгән. Үзгә бер тантаналы тынлык. Үзгә бер илаһи шау. Зур шәһәр ыгы-зыгысыннан соң кая әләккәнеңә ышанып бетү дә кыен. Мөгаен, Себердә, Ерак Көнчыгыш якларында гына саклангандыр мондый табигать. Шунысы куанычлы, хәтта гаҗәп: бу җирләр Казаннан машина белән барганда нибары ике сәгатьлек юл. Элеккеге Казан ханлыгы биләмәләре...

Бер җаен алгач, курку-шөбһәләнү хисе кими икән: фаҗига-мазар булмас, Алла боерса, дисең. Яр да бик үк ерак түгел, андый-мондый хәлдә, мәче тырнагыннан үз баласын җибәрмәгән шикелле, ничек булса да, сабый Газизне эләктереп, агымнан кыйгачлап йөзеп чыгармын дигән ышаныч бар... Менә шулай! Кеше дигәннәрендә йә чиксез өмет-нәфесләр, йә гап-гади нәрсәләр белән карусыз ризалашулар... Кемнең, кайчан, кайда, ничек! Ишә-ишә уйланам менә: хәзерге төп байлыгым очлы борынлы, брезент сүрүле шушы тар көймәгә сыеп беткән икән ләбаса! Яшәр өчен, хәят итәр өчен хәзергә бөтен нәрсәм шушында икән бит!

Дөрес, без тугыз гына көнлек юлга чыктык («Яшәү» дигән сәяхәткә күпмегә чыкканны берәү дә белми.) Тугыз көн дә гомернең бер кисәге (Бер кич кунып, гомергә тол калып, ир хатыны саналып, шул бер төн хакына үз вөҗданына тугры калган җаннар да бар!). Гомумән, кеше дигәннәренең нәфес бизләре нык үсте бугай соңгы заманда. Ә гомер озынаймады! Булганына разый булып, тапканыңны сакла да бит!.. Кыскасы, «сүз – озын, гомер – кыска!» Каекка утырып беренче чакрымнарны узганда килгән килде-киттеле уйлар бу.

Без каекта өченче булып, «койрыкта» йөзәбез. Тәртибе шундый: балалы экипаж салынган «эз» буйлап барырга тиеш. Алда барганнарны күзәтү кызык. Алдан барган ике пар ишкәкчеләрнең синхрон хәрәкәтләре үзе бер шигъри күренеш. Бер-берсенең тән хәрәкәтен тоеп ничек уйнаталар ишкәкләрне! Тормыш юлларында да шулай тәңгәл микән аларның гамәлләре? Кем белә!..

Ишү – рәхәт авырлыкны тойдырта торган ирләр эше. Кул-терсәкләр ритмик селтәнә, иңбашлары ритмик калкына. Кешенең очарга омтылышы бугай бу хәрәкәтләр. Кызу барыйм дисәң, әлбәттә, көчне җәлләмәскә кирәк. Ишү – шактый авыр эш. Хәер, җиңел эш юктыр да ул. Ни дисәң дә, шахтер эше түгел инде! Күзләреңә табигать матурлыгын сеңдереп, тән-күзәнәкләреңә куәт арттырып йөзәсең бит. Тереләй җир астына кереп хәрәкәтләнмисең, күк астында, кояш астында рәхәтлек тоеп йөзәсең. Шулай да, кыбырсык уйлар да килеп китә: менә без яңгыр астында каекта чыланып йөзәбез. Аста да, өстә дә су дигәндәй. Кемнәрдер бу минутта өйләрендә җылы ванна керәләрдер инде, йомшак диван өсләрендә кырын ятып китап укыйлардыр, телевизор карыйлардыр, тагын әллә нинди рәхәтлекләр чигәләрдер... Көнләшү хисе бу, каһәр, чагыштырып көнләшү хисе!

Бер сәгатьләп йөзгәч, Ходай рәхмәте, яңгыр туктады, болытлар офыкка таралды, кояш чыкты. Көн кичкә авыша бара. Яңгырдан соңгы табигать сафлыгын һәркем белә булыр. Мондагы әкияти сафлык, гүзәллек минем өчен бөтенләй өр-яңа, бөтенләй бүтәнчә! Шушы матурлыкларны күрер өчен генә дә дөньяга килү ярыйдыр ул.

Елганы урталай ярып йөзгәндә, күз алдында төп ике күренеш: бер якта – текә ярлар, икенче якта – уем-уем тигез комлыклар; борылмаларны үткән саен, алар алышынып тора: кызгылт ярлар әле уңда кала, әле сулда... Текә ярлар вакыт үткән саен әкренләп ашалып, ишелеп тора. Язгы ташу вакытында бу ишелү бигрәк тә көчәя. Яр өстеннән мәтәлеп авып төшкән юан-юан нарат агачлары бик күп, оч ботаклары – суда, тамыр-төпләре – дулкыннар өстендә. Кайбер агачлар ярым егылганнар, ярда кармак сабы кебек эленеп калганнар. Су астын күз алдына китерәм: чып-чын агачлар каберлеге инде анда. Ул күренешләрне кино яки фотога төшереп алсаң (шунда ассистент булып, Су кызлары да булышса!), һичшиксез, уникаль кадрлар ясап булыр иде. Хәер, су өстендә дә тырпаеп яки күренер-күренмәс кәүсәләр, тамырлар җитәрлек. Зур балык яки берәр су җәнлеге сырты дип ымсынып куясың. Резин көймәләр, байдаркалар өчен хәтәр нәрсәләр ул ботак-чыбыклар. Агымны югалтып,

чамаламыйрак ишсәң, төртелеп, көймә төбен тиштең дигән сүз. Шуңа күрә дә клей, ямаулыклар көймәчеләрнең һәрчак кул астында була.

Елга өслеге гел үзгәреп, төрле рәвешкә кереп тора. Бар – җәелеп тыныч кына аккан урыннары, бар – баш чөеп дигәндәй ярсып-бөтерелеп, ташкын булып аккан җирләре. Тарлавыкларда үтә сак булу кирәк. Каек янтаеп әллә ниләр булуы бар. Дөрес, күп нәрсә резин капчыклар эчендә. Шулай да каек өстендә ачык яткан әйберләр дә җитәрлек. Авыз ачып, күктәге кошларны санап барсаң, берәр кирәк әйбереңнең елга төбенә китүе дә ихтимал... Йөрерсең аннары «Мәдинәм-гөлкәем» көенә «кульяулыгым икәү иде, берсе суларда акты» дип җырлап!

Ике сәгатьтән артык йөзәбез. Егерме биш чакрымнар чамасы ара үткәнбездер. Ниһаять, алдагы каек яр буена төртелеп тукталды. Димәк, төшәбез, димәк, бу җирдә урнашып төн куначакбыз. Әле яңа гына төягән әйберләрне янәдән ярга ташыйбыз. Кырмыскалармыни – мәш киләбез! Әй, дөнья! Ничәмә-ничә мең еллар элек тә кемнәрдер, күз күрмәгән яңа җирләргә туктап, шулай ташынганнардыр. Яңа утрауларга, яңа кыйтгаларга кемнәрдер беренче мәртәбә аяк баскан бит инде! Замана бүтән дә хис-тойгылар бүтән. Кояш астындагы Җир шул ук: иске дә, яңа да. Кеше үзе моңарчы күрмәгән, белмәгән җиргә аяк баса икән, бу инде аның үзенчә, үзе өчен бәләкәй бер Америка ачуыдыр ул.

Палаткалар тиз корыла хәзер. Җаен гына белергә кирәк. Зур күләмле авыр брезент палаткалар заманы үтте. Хәзергеләре җиңел: күп дигәндә өч-дүрт кило булыр. Агач төймәле бәйләвечләр беткән хәзер. Палатка сүрүенең бөтен җирендә «молния». Селтәнеп, «сызып» кына җибәрәсең, җөйләр йомыла, палатканңа җил дә, чебен-черки дә керә алмый. Шул «молния» дигәннәрен уйлап тапкан кешегә Нобель яки аннан да зуррак премия бирерлек, валлаһи! Бөтен дөньядагы әйберләрдәге – сумка, кием-салым һ.б. – молния озынлыгын исәпләсәң, ничә миллион чакрымнарга җитәр иде икән?!

Урнашылды. Учак ягылды, казан асылды, ашасы ашалды, чәй-мәе эчелде... Хәзер төн. Өч палаткада өч гаилә. Без дә өчәү. Тиз генә йоклап китеп булмый. Гомумән, яңа җирдә йоклап китү кыен. Палатка асты да ияләнелгән түшәк түгел. Тынлык. Күрше палаткадан сирәк-мирәк йөткергәләгән авазлар ишетелеп куя. Тагын тынлык. Юк, бөтенләй үк тынлык түгел, су тавышы, төнге елга авазы бар. Табигать авазы... Ара-тирә каты гына шапылдау яңгырап ала. Монысы эре балык сикерүе. Шәп бит! Кем белә, бәлки, иртәгә берәрсен кармакка эләктереп булыр? Аучыларга хас шундый ерткыч уйлар, көне буе җыелган яңа тойгы-тәэсирләр, матур иртәгесе көн турында татлы хыяллар белән үзең дә әкрен генә йокы патшасы – Морфей бабай җәтмәсенә кереп китәсең...

## Тукталышлар. Маркитан...

Ике йөз чакрым араны без дүрт тукталыш ясап йөздек, ягъни дүрт җирдә тукталып, кунып-төнеп ятып, палатка-тирмәләр корып, казан асып... Бер тукталышыбыз белән икенчесенең арасы якынча илле чакрымлап. Гадәттә, бу араны өч-өч ярым сәгатьләп ишеп йөзәсең. Хәер, күзең күргән, күңелең теләгән һәр җирдә – үз иркең – туктала аласың. Әмма аерым бер җайлы, ямьле урыннар (аларны тәҗрибәле туристлар яхшы белә!) бар. Яшәү урының, син анда бер яки өч көн торасыңмы, уңайлы һәм ямьле булсын. Көймәләрне ярга чыгарып киптерү өчен сөзәк яр кирәк, шунда ук су кереп кызыныр өчен комы да булсын. Балык тотар өчен тирән һәм тыныч култык кирәк. Палатка тирәсе ышык һәм җиләс булса яхшы. Андый җирдә черки-чебен азрак була. Җиләкле, гөмбәле җир булса, тагын да яхшы... Кыскасы, адәм баласына шәплекләр бик күп кирәк! Ә бар андый урыннар!

Йолдызлы күк гөмбәзе, янып торган учак ялкыны, дәрья-су агышы кешене ялыктырмый, күзне талдырмый, диләр. Дөрестер. Әмма бертөрле күренешләр озакка китсә, аларга битарафрак та була башлыйсың. Чөнки соклану-гаҗәпләнү тойгысы кими... Күзгә яңалык кирәк. Икенче төрле әйткәндә, шушы табигать эчендә сирәк-мирәк булса да йорт-мазарлар, кешеләр күрәсе килә. Алар да бит шушы табигый гүзәллекнең гармоник күренешләре була алыр иде. Картадан карыйм (ә топографик карта бик төгәл: хәрбиләр өчен эшләнгән, һәр чокыр, һәр калкулык ачык билгеләнгән), әһә, безнең маршрутта ике авыл бар икән! Берсе –

Маркитан, икенчесе – Долгая Старица. Безнеңчә, Озын Иске үзән була инде. Маркитан дигәненең мәгънәсен әлегә белә алмадым, «мари» сүзе белән бәйләнешле булса кирәк. Картада түгәрәк белән билгеләнгән ул торак пунктларының һәр икесен дә күрергә туры килде. Маркитан дигәнендә, үтеп барышлый гына туктап, нибары бер сәгатьләп кенә булдык, ә Долгая Старицада ике тәүлектән артык тордык. Дөресрәге, елганың икенче ягында, каршы якта тордык. Икесе дә мари авыллары алар. Дөресрәге, кайчандыр авыл булганнар. Маркитанда төтен чыга торган бер генә йорт калган. Анда җитмеш биш-сиксән яшьләрдәге Серафима исемле карчык тора. Элегрәк елларда биредә берничә мәртәбә булган юлдашларым, аның исән-сау икәнлеген күргәч, сөенеп куйдылар. Кайчандыр аннан сөт ала торган булганнар. Хәзер инде сыеры юк икән... Әби йорты тирәсендә берничә ир-ат та бар. Бүрәнә өстендә утырып тәмәке тарталар, сөйләшәләр. Балыкка яисә урманда берәр эш майтарырга килгәннәрдер инде...

Зират өстеннән йөргән кебек, кайчандыр урам-тыкрык булган җирдән атлыйм. Беткән авылның фаҗигасен аны күреп кенә беркадәр аңлап буладыр. Үлән каплаган нигез урыннарындагы ташларда кәлтәләр шуыша. Кайчандыр электр чыбыклары сузылган баганалар авып, череп ята, берничәсенең ташаяклары да калган. Кайбер йортларның түбә-түшәмнәре җимерелеп, бура кысалары кычыткан, алабута өчен зур бүрәнә тартмалар булып калган. Бер йорт яр өстендә яртылаш эленеп тора. Аста – су... Кайчандыр ярдан шактый ерак булган бит инде ул. Икенче бер йортның ишек тупсасында күгәргән дага күзгә чагылды... Бер генә исән йорт калган булса да, бөтенләй үк бетеп бетмәгән әле Маркитан. Җәй көннәрендә генә булса да, сукмаклар бар, машина үткән эзләр дә очрый. Балыкчылар, аучылар төрле яклардан килеп әзме-күпме җан кертәләр әле бу җиргә. Хәтта кемнәрдер тавык тәпиендә басып торган әкияти өй кебек кечкенә генә часовня да ясап куйганнар. Эченә кереп карадым. Тәрәзә уемы булса да, рам, пыяла-мазар юк. Шулай ук өйчекнең бер почмагында кемдер Гайсә сурәте төшерелгән төсле кәгазьне ябыштырып киткән...

Берничә күренешне фотога төшерәбез дә ары китәбез. Гаҗәеп манзаралар! Балалар өчен чыккан китапларда әкияти матур рәсемнәр була бит! – монда да шулай. Рәссамнар да кайчандыр, кайдадыр шундый күренешләрне күреп ясаган инде үз эшләрен!

«Бигрәк матур җирләр! Монда килеп, яшәп гомер кичерергә теләүчеләр табылырмы?» Бу соравыма яр буена туктап, көймәсенең нәрсәсендер рәтләп маташучы бер ир-ат болай җавап бирде: «Путин марилардан казачество төзиячәк. Менә шунда яхшы тормыш башланачак бу җирләрдә!» Кеше дигәнеңнең наив хыяллары!

Долгая Старица, ягъни Озын Иске үзән дигәне, Маркитан белән чагыштырганда «гигант» инде! Монысында каралты-курасы булган кырыклап йорт бар! Шуның унбишләбендә хәтта кышын да торалар икән. Монда электр бар, түбәләрдә антенналар, димәк, телевизор да бар. Әйткәнемчә, монысы да мари авылы. Кайчандыр мәктәбе, клубы, пекарнясы, балалар бакчасы гөрләп торган зур авыл булган. Хәзерге хәле шулай ук аянычлы. Әлегә җаны чыгып бетмәгән бу авыл эчендә сәгатьләп йөрдем мин. (А.Чехов искә төште. Заманында Сахалинга барып, анда яшәүчеләрнең тормышын өйрәнеп «Сахалин» дигән бөек хезмәт язган ул. Сорау да туа: Мәскәү-Кырым җирләрендәге рәхәт тормышын ташлап, табиб-әдип ни уй белән йөргән ул япон-кытай якларында? Гыйльми-этнографик иҗади кызыксыну, әллә урыслыкны раслау идеясе беләнме?)

Каян килеп, нишләп йөри икән бу ят кеше дип күзләп торучы юк шикелле. Бер йорт белән икенчесенең арасы шактый ерак. Кая күз атсаң да, әрнүле тойгылар уята торган күренешләр. (Боларны Рифхәт Якупов кебек оста фотограф килеп төшерсә, «Җан бирүче авыллар» кебегрәк исем белән гаҗәп тәэсирле альбом эшләп булыр иде.) Карап торырга исән, торырлык кебек йортларның күбесендә йозак. Тәрәзләр эчтән пәрдәләр белән капланган. Коймалар каерылган кош канатыдай сыгылып, янтаеп яталар. Кайчандыр яшь кызлар, килennәр йөзе чагылган коелар ләмләнеп, боткаланып, тынчып беткән. Элекке пекарняның җимерелгән мич кырларында берничә сыер ышкына. Кайчандыр койма-читән белән тотып алынган бакчалардагы алма, груша агачлары кыргыйланган, җимешләре вак һәм әче. Кайбер йортларның болдырларындагы тартмаларда коры утыннар, каен тузлары тора. Димәк, хуҗалары кайткалый, учак тергезергә ягулык әзер... Урамда казлары каңгылдап йөри торган – димәк, монда кешеләр тора – бер йортның капкасын ачып кердем. Баскыч төбендә өч карчык утыра. «Кибет кайда икән монда? Ипи-сөт, сигарет-чәй кирәк иде» дип сорадым. Ярым

урысча, ярым марича, ярым әллә кемчә сөйләшүче бу карчыклар, яңа кеше күргәнгәме, шактый ук ачылып сөйләшеп киттеләр. Кызыксындырган байтак сорауларыма җавап алдым алардан. Сүзләренең төп мәгънәсе, авыл бетә, диләр...

Дөресе шул. Әмма күз өчен бүтән күренешләр дә юк түгел икән. Авыл читендәге үләнле-чәчәкле яланда берәүнең мәһабәт йорты балкып тора. Биек койма белән тотып алынган җир гектардан да ким түгел. Капкада йозак. Кызыксынып койма ярыгыннан карыйм: биләмәнең бер матур төшендә зур мунча, ял итү корылмалары, волейбол мәйданы... Димәк, бу җәннәт җирләренә, ял итеп китәргә булса да, кемнәрдер килә. Димәк, бөтенләй үк хуҗасыз түгел бу җирләр. Күрәсең, кемнеңдер яшәве өчен кемнәрнеңдер кол булуы яки бетүе кирәк... Әллә бу хәл кешелек яратылганнан бирле киләме?

Кибет дигәннәре бер тол хатынның йортында, төгәлрәге, шул йорттагы бер бүлмәнең почмагында булып чыкты. Өйдә яшүсмер бер малай. Товар үрнәкләре өстәлнең бер почмагына тезелгән. Целлофан пакет белән тышланган кәгазьдә булган әйберләрнең бәяләре язылган. Ассортимент: сигарет, карамель кәнфит, сыра, презерватив... «Әни товарга китте» диде үсмер малай. Бәлки, тагын кайбер кирәк әйберләр кайтадыр бу «кибет»кә. Шул ук йорт ишегалдында биш-алты яшьлек кызчык бөтерелеп йөри. Ап-актан үзе, әйләнмә якалы, челтәр итәкле матур күлмәк кигән. Чәчләрендә ал бантик. Берүзе өй тирәли әйләнгәләп йөри, биеп-биеп тә ала. Күренеп тора: уйнарга иптәше юк... Киемнәрен, телевизордан яки бүтән җирдән күреп кайтып, әнисе теккәндер дип уйладым. Авылда төрле яштәге биш-алты баланы биредән кырык чакрым ераклыктагы райондагы интернат мәктәпкә илтеп укыталар икән.

«Зиратыгыз кая? Карап чыгар идем!» дим карчыкларга. «Юк бездә зират. Мәрхүмнәрне моннан унбиш чакрымдагы бүтән авылга илтеп җирлибез» диделәр. Зиратсыз авыл! Авылның бетәчәген алдан белеп кылынган зирәклекме бу? Әллә бүтән берәр сәбәпме? Авыл бетеп, зират калу яхшымы? Әллә, яңа авыл корып, беркадәр вакыт зиратсыз яшәү яхшыдыр? «Безнең янга яшәргә килегез, өй салыгыз» ди карчыкларның берсе. Җавап урынына көлемсерәп куйсам да, уйландыра. Бүгенге көндә Россия киңлекләрендә күпме качаклар бар, җир-суга интегүчеләр күпме! Миллион адәмнәр, океаннан ярга ташланган диңгез җанварлары кебек, шәһәргә ыргыла. Кешеләрдән торган «кырмыска оясы» һаман ишәя, биегәя... Иң аянычы: мегаполиста аларның күбесе бәхетсез хәлдә. Ни яшәү нигезләре юк, ни рухи таянычлары... Ахырзаманмы? Ә биредәге җәннәт җирләре кеше тавышына зар-интизар. Күргәннәрдән тулышкан халәткә диссонанс булса да, хәтергә Сәгыйть Рәмиевнең онытылмас юллары килә: «Әй, авыл! Син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш!»

Авыл хәлләренә тирәнрәк кереп киттем, ахры, сүзем тукталышлар турында иде бит! Суда күңелле булса да, анда ишеп, хозурланып йөзеп кенә була, ә яшәү барыбер җирдә, аның өслегендә! Тукталышларда ял итәсең, ашап-эчәсең, төн кунасың, уйланасың. Борынгы бабаларыбыз искә төшә, дөресрәге, алар тормышын күз алдына китерергә тырышасың. Күчеп-күчеп йөреп нинди генә җирләрдә тирмә кормаганнардыр! Кем белә, бәлки, менә хәзер без утырган шушы төштә дә кайчандыр, кемнәрдер учак тергезеп утыргандыр?..

Бәлки, бәлки... Шулай да, килешикме-юкмы, заманында ярты дөньяга хуҗа булган бөек төрки бабаларыбыз нигәдер диңгез-су дөньясын киләчәк буыннарга мирас итеп беркетеп китмәгәннәр... Игътибар итәргә ярый: соңгы берничә гасырда җиһангирлек иткән империя-хәлифәтләрнең һәммәсе үз вакытында (һәм хәзер дә!) диңгез тоткан! Дөнья сулыкларына хуҗа булу тойгысы белән яшәгән. Безнең бабайларда Бөек Суга ыргылыш булмаганмы?.. Глобус дигәннәрен әйләндереп карасаң да, шуңа инанасың. Җирдә – Кояш астында хуҗа кебек иркенләп яшәргә телисең икән, синең диңгезләрең булырга тиеш. Ерак Көнчыгышта Татар бугазы исеме булу гына аз... Төркиягә баргач, шуны да ишеттем: XX йөз башында бездән киткән мөһаҗирләргә диңгез буйларында урнашырга да тәкъдимнәр булган, имеш. Безнекеләр, мал-туар асрарга җайлы булсын дип, япан җирләргә күчеп киткән. Хәзерге Иске шәһәр тирәсендәге җирләр. Хәер, мөһаҗирләрнең сайлау-сайлану хокукы да шуның кадәр генә булгандыр инде. Заманында бик тә мәшһүр булган (үз илендә хәзер дә мәшһүрдер) «Котып китабы» («Ледовая книга») авторы, Ленин премиясе лауреаты, эстонлы Юхан Смуул бер әңгәмәсендә болай дигән иде: «Дөньяның диңгез-океаннарында эстон кешесе булмаган зур кораб дөньяда юктыр ул, безнең халыкның рухында – диңгез җаны». Кемгә – диңгез дулкыны, кемгә – кылганның диңгездәй дулкынлануы... Икесе дә – кылганы да, дулкыны да

булса, ул бөек хәлдер, әмма аерым бер халыкка төп бер генә холык-сыйфат биреләдер, күрәсең...

Гыйбрәтләр алырлык җирләр ул тукталу (стоянка) урыннары. Монда үзгә тәртип. Кешеләрнең табигатькә сакчыл һәм ихтирамлы карашы сокландырды мине. Кешеләр үзләреннән соң чүп-чар калдырмый, киресенчә, киләселәр өчен бу урынны җайлабрак та китә әле. Гадәттә, берәр ышык урында коры утын да була. Учак урыннарында аерчалы казык-таяклар кагылган. Ут тергез дә казаныңны ас. Көрәк сабы юанлыгындагы киртәлекләрдән тезеп беркетелгән өстәлләр дә күрдек. Кайбер урыннарда өсте ябылган ышыклану урыннары да бар, озынча эскәмияләре булган беседкалар да очрый. Ник бер консерв банкасы яки берәр шешә аунап ятсын. Читтәрәк, аулаграк урында чокыр-баз казылган. Чүп-чарны шунда ташлыйсың. Яна торган чүпләр учакта көлгә әйләнә... Экологик тәрбия, культура шул була торгандыр инде. Кешенең зыялылык дәрәҗәсен аның үзен тудырган Табигать-анага мөнәсәбәте билгели. Бүтән җирләрдә ничектер, без күргән җирләрдә тәртип шундый иде.

Шуңа да игътибар иттем: яр буендагы кайбер тукталышларның исемнәре дә бар. Дөресрәге, яр өстендәге биек агач кәүсәләренә язулы такталар кадаклап киткәннәр. Шуңа күрә исемле дип әйтәм. «Яна», «Вера»... Безнеңчә исемнәр очрамады. Шулай ук дөньяның фанилыгы турында уйлата торган эпитафик язулар да күренгәләде. Кемдер ничектер биредә һәлак булган, димәк. Якыннары, дуслары, бирегә янә килеп, ташка уелган шигъри сүзләр беркетеп киткәннәр. Сәяхәттә җан тәслим кылырга берәр җитди сәбәп булу кирәк, әлбәттә.

Тукталышлар, гадәттә, су өсләре, тирә-юнь матур итеп күренә торган җирдә була. Елгадан үткән һәр көймә, һәр байдарка яки катамаран синең күз алдында. Әмма алар сирәк. Көненә күп булса алты-җиде көймә уза. Шундый гадәт: йөзеп баручы кешеләр ярдагыларны сәламләп үтә, ярдагылар шулай ук сәлам кайтара, кул болгый, хәерле юл тели. Нindидер эчке якынлык, туганлык... Әнә бер байда-каекта ике кеше. Ирле-хатынлы булса кирәк. Уртада – этләре. Өлкәннәр инде бу кешеләр, яшьләре җитмешләрдән узгандыр.

Әнә бер яшьрәк кеше берүзе резин көймәдә. Ишкәге белән агымга көйләнеп кырын ятып бара. Ник дип юлга чыккан ул берүзе? Беркөнне бала-чага төялгән ике зур катамаран узып китте. Су өстендә берничә минут күңелле чыр-чу булып алды. Катамаранга әләм дә беркеткәннәр. Татарстанныкы булып чыкты. Куллар болгаштык. «Казаннан сәлам!» – диделәр. Күңелле булып китте. Сүз дә юк, сәях кешеләр үзгә холыклы алар. Өлкән яшьтәге бер галим көчле агымга каршы әллә ничә чакрым үргә таба йөзгән, дип тә сөйләделәр. Көн-төн телевизордан сериаллар карарга яраткан кешеләр, әлбәттә, күрәләтә мондый мәшәкатьле сәфәрләргә чыкмастыр.

Озын Иске үзән тукталышында торганда, хәтергә нык сеңеп калырлык хәл – адашып йөрүләр дә булды әле. Без туктаган урыннан дүрт чакрым чамасы ераклыкта, урман эчендә бер зур күл бар икән. Игорь дигән юлдашыбыз аны белә дә булып чыкты. Шунда барып, күлне күреп, суында коенып, йөзеп кайтсаң? (Су эчендә диярлек яшәп су җитмәгәнме!) Киттек дүртәүләп. Малайны да алдык. Урман сукмаклары буйлап, сазлыклар үтеп баруын бардык, таптык күлне. Күл чыннан да зур, матур. Исеме дә Якты күл (Светлое озеро). Су коендык. Фотога да төштек. Күл буенда учак урыннары, басмалар бар. Аучылар, балыкчылар килгәләп йөри торган җир. Барганга һич үкенерлек түгел. Тик... Кайтканда адаштык бит, әй! Тукталышыбызга чыгу сукмагын югалттык. Барганда ботаклар сындырып, сукмакларга төрле билгеләр куеп барган идек тә... Болайга барып карыйбыз, тегеләйгә... Яңгыр төшкәли башлады. Газиз дә арыды, ун чакрымлап йөргәнбездер. Муенга атландырып (аныңча «атка утырту») ял иттерәм. Өстән төшкәч, бераз бара да тагын «арыдым!» ди. Күреп торам, чыннан да арыды, аяклары чалыш-чолыш килә башлады. «Ат»ка да җиңел түгел... Хәтергә рәссам К.Маковскийның «Дети бегущие от грозы» дигән картинасы килде. Күпләр беләдер: кыз бала үзенең нәни энесен күтәреп өенә ашыга... Эңгер-меңгер төште. Күңелгә хәвеф корты керә башлады. Бу урманнарда аюлар да бар бит инде... Паник халәтне бер-беребезгә сиздермәскә тырышабыз. Шаяру сүзләре дә әйткәләп куябыз әле. Курку галәмәте юк, янәсе! Берәр сәгать уралып-уралып йөргәч, кирәк сукмагыбызны таптык, ниһаять! Палаткаларыбыз янына чыгып, учак тирәсендәге юлдашларыбызны күргәч, сөенүләрнең чиге булмады! Менә шулай, кычытса, кычытмаса да, кемгәдер «Әстерхан» дигәннәре бик ерак түгел икән ул...

Түмен тапкан кешегә бик кызык һәм рәхәт сәяхәт. Күчмәлекнең мәшәкате, ыгы-зыгысы бихисап булса да, ял сәгатьләре дә юк түгел! Тәүлегенә берничә сәгать чыгадыр. Ирек! Кем

нәрсә тели! Кем балык тота, кем җиләк җыеп килә, кем черем итә, кем туп тибә йә шахмат уйный... Мин үзем, җай чыккан саен, яр буендагы берәр аулаграк урында ялгыз калырга тырыштым. Ятасың берүзең сузылып комлыкта. Кәгазь-каләм кесәдә: уй-фикерләрең туса, теркәп куясың. Якында беркем юк. Рәхәт! Янәшәңдә ярларны тутырып чип-чиста елга агып ята. Баскан-яткан урының чип-чиста ак ком. Теләсәң бөтенләй үк чишенеп ят, ауна. Йә, тагын кайларда бар икән мондый аулак хозур җирләр? Кара яки Урта диңгез буйларындагы пляжлардамы? Ай-һай... Үзебезнең Идел яки Казансу буйларындамы? Мөхәммәт Мәһди әйтмешли, едва ли! Хәер, бездә дә бар иде мондый җәннәт урыннары. Хәтер балачак аланнарына әйләнеп кайта. 50 нче елларда Ерак болынга чыгалар иде безнең якларда. Кама буенда – Чистай турындагы, каршы яктагы җирләр. Авылның таза ир-егетләре, яшь-җилкенчәкләр, кыз-киленнәре Кама буендагы болынлыкларда шалаш-куышлар корып, яшәп, җырлап-уйнап печән әзерли иде. Артык та, ким дә түгел – чын Хезмәт туе инде! Ул чакларны сагынып кына искә алып була хәзер. Ул болыннар күптән су астында калды... «Үткән бөеклеккә кайтып булмый, сагынып кына була!» Монысы инде настальгия... Ә без әлегә Мари Илендәге Кокшагада йөзүдә. Урысчалап әйткәндә, сплавта.

## Агымсуларга карап...

Халык җырларындагы күңелгә якын бу сүзләрне мөхтәрәм язучыбыз Шәйхи Маннур үзенең әдәби әсәре исеме итеп тә куйды. Агымсулар күптөрле уйларга тарыта ул. Уйлар, гадәттә, таркау, чуар, әллә ни эзлеклелек юк, әмма шул эзлексезлекнең үз бер мантыйгы бар. Асылда, уйның төбендә өч төшенчә: Су, Җир һәм Без. Чыны да шул, без – борын-борыннан киң далаларга һәм зур сулыкларга ия булган халык. Дала кылганнары дәүләтле, шанлы чакларыбызда иелеп дога кылган булса, соңрак Идел камышлары әсир Сөембикә-ханбикә утырган көймәләрне сагышланып озатып калган. Ерак бабаларыбыз япан далаларда янган йөз-битләрен Байкүлләрнең (Байкал) көмеш суларында юган. Вакытлар үткән, далалар киңлеген кардәш халыклар кочагында калдырып, соңрак дәвердә зур суларга елышканрак халык без.

50 нче елларда «Казан – биш диңгез порты» дип еш сөйлиләр, еш яза иделәр. Шигырьләр-җырлар чыгардылар ул заманда. Хәзер алай дип әйткәнне ишеткән юк... Еш кына бер уй бимазалый: нигә бөтен яктан диярлек су белән чолганган борынгы Казанның халык иркенләп ял итәрлек яр буйлары юк соң? Идел буендагы бүтән шәһәрләр белән чагыштырып карагыз – Сембер, Волгоград, Сарытау... Һәммәсендә әллә ничә чакрымнарга сузылган, паркларга тиңләшерлек менә дигән яр буе урам-бульварлары бар. Шәһәр халкының мәһабәт Идел киңлекләренә хозурланып, кинәнеп ял итә торган урыннары алар. Ә бездә Иделгә чыгу юллары хуҗалык объектлары, төрле-төрле базалар, әллә нинди корылмалар белән томаланган. Хикмәте ни? Колониаль сәясәтнең эзләре дә бар инде монда... Үткән ел ахырында гына Казанның яңа генераль планы кабул ителде. Карап чыктык ул документны. Анда «Иделгә тәрәз ачу» буенча кайбер чаралар каралган. Яхшыга юрыйк. Шулай да проекттагы кайбер ният-гамәлләр хәзер үк шөбһәләндерә. Әйтик, Казансу буйлатып, күп катлы йортлардан торган зур бер район төзелә икән (ул инде хәйран төзелде), тарихи елгабыз тиздән ярым үлек, иң пычрак елгаларның берсенә әвереләчәк.

Бездә маринистика (мари урманнарында бу сүз шигъри яңгырый) бармы? Булырга тиешме? Булса, нинди дәрәҗәдә ул? Куйган сорауларыма үзем үк җавап бирәм: әлбәттә, андый әдәбият булырга тиеш! Әмма бездә кирәк дәрәҗәдә үсеш алмаган әле ул. Кызганыч, әлбәттә. Заманында халкыбызны зур су тирәсенә якын китермәү кануннары да үз ролен үтәгәндер. Шулай да халык иҗатында, бигрәк тә җырларда дәрья (бу очракта зур су, диңгез дип аңлыйк) турында җырлар дөнья кадәр! Идел, Агыйдел, Кама-Чулман, Җаек, Дим, Ык һәм башка елгалар турында җырлар меңәрләгән. Шулай ук Кара диңгез, Әдрән диңгез, Байкал күле кебек зур сулар турында да җырлар бар. Халык җанында дәрьялык бетмәгән. Ә язма әдәбиятка килгәндә, әсәрләр ул кадәр күп түгел, әдәбиятның бу кишәрлегендә бастырып эшләүче язучылар бик аз. Мин белгән чорда япа-ялгызы диярлек бердәнбер Миргазыян Юныс шәхесе тора. Ул бездәге маринистик әдәбиятның пионеры да, классигы да саналырга хаклы. Искә төшерсәң, кайбер әсәрләр бар ул барын. 50 нче елларда, «без үскәндә», Гариф Гобәй

повестьларында «маякчы кыз»лар күренгәләде. Сафа Сабиров әсәрләрендә Идел тормышы чагыла, дип яздылар ул вакытта. 70 нче елларда Рафаэль Мостафинның «Экватор буйлап», Марс Шабаевның «Салда сәяхәт» кебек язмалары дөнья күрде. Рәфикъ Юныс, Иделнең башлангычына кадәр җәяү барып, тәэсирнамәләр чыгарды... Шигъри әсәрләрдә диңгез-су мотивлары кергән әсәрләр байтак анысы. Авторларны дистәләп санап була. Тормышлары күпмедер дәрәҗәдә диңгезгә бәйле каләм ияләренең кайберләрен атап үтәм: Салих Баттал, Әдип Маликов, Фаил Шәфигуллин, Локман Бадыйкшин, Илдар Низамов, Әхәт Хәбибуллин... Исемлекне дәвам итәргә мөмкин.

Бу җәһәттән, уйлансаң уйланырлык нәрсәләр бар инде ул. Заманында (әле бик ерак дәверләр түгел, «Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары) Идел суы тулысы белән диярлек безнеке булган. Бабаларыбыз сәүдә итеп, яу чыгып йөргән бит инде бу киңлекләрдә! Без хәзер бу хакта нәрсә беләбез? Урыс ушкуйникларының яр буе шәһәрләрен талап йөрүләре турындамы? Кая безнең бабаларыбызның данлы яки хурлыклы гамәлләрен чагылдырган сәхифәләр? Кемнәрдер болар турында да язып чыгарга, бүгенге һәм килер буыннарга ирештерергә тиештер бит! Кызыксынган, эзләнгән кешеләр өчен дөньяда чыганаклар җитәрлек. «Суга баткан Гайшә» бәетен генә белү аз ул...

Йөзгән көннәрдә нигәдер Байкал якларында яшәп иҗат иткән таныш (хәтта дус!) каләмдәшләрем Ренат Суфиев (Роман Солнцев), Александр Ванпиловлар (хәзер инде икесе дә мәрхүмнәр) искә төште. Ниләр уйлап, ни хикмәт эшләр кылып йөзделәр икән алар ул Себер елгаларында? Ә бит табында бергә утырган чакларда, бер-берләрен бүлә-бүлә, дәртләнеп сөйлиләр иде бит йөзүләре хакында! Кызганыч, сөйләгәннәре хәтердә калмаган...

Яшәвебез, шул исәптән рухи яшәвебез дә су дөньясына шактый ук бәйле булгач, бу хәл гыйльми-эзләнү хезмәтләрендә дә чагылыш табарга тиештер ләбаса? Татар әдәбиятында диңгез-су образ-символлары үзе бер кызык һәм мәгънәле тема, тирән мәгънәле тема. Су өстендә чирәм үсмәсә дә, кинаяләп әйтәсе килә: Су темасы – безнең әдәбиятта «күтәрелмәгән чирәм». Бәлки, мин белеп үк бетермимдер... Шулай да күптән түгел күңел сөендерерлек бер гамәл булды булуын: шагыйрә Луиза Янсуар «Татар поэзиясендә «Кораб» символ-образы» дигән гыйльми хезмәт язып, кандидатлык диссертациясе яклады. Афәрин, «карлыгачлар» ялгыз гына очмасын, ишле булсын! Мәйдан – офыктан офыккача. Әйе, бер шигырьдә әйтелгәнчә, «диңгезләре булган халык кол була алмый»!

## Команда яки озын-кыска сәфәр

Озын-озак та, кыска-тиз дә булды бу сәяхәт. Яшәү тамырың береккән җирдән, хәбәрләшүдән-сөйләшүдән мәхрүм булып, унлап көнгә югалып тору хәзерге заманда гайре табигый хәл. Казан белән, гомумән, дөнья белән бернинди элемтә юк. Радиоалгыч алмадык. Кесә телефоннары эшләми. Бу урман арасында аларны эшләтә-тоташтыра торган маш-корылмалар юк. Йорт-җир исән-иминме? Әтинең хәле ничек? Туганнар, каләмдәш-коллегалар ни эшләр майтара икән? Уйламыйм дисәң дә, килә инде башка мондый сораулар. Сәфәрдәшләр никадәр генә шәп булсалар да, дөнья алар белән генә чикләнми шул. Әйе, яхшы иптәшләр, зыялы иптәшләр. Әмма мондый сәфәргә бергәләп беренче чыгу бит әле. Гомер яшәп тә күп чак кешене аңлап бетереп булмый...

Бу урында команда турында берничә сүз. Элегрәк «команда» сүзе күбрәк хәрби тормыш белән бәйләнештә әйтелә иде. Хәзер бу сүзне сәясәтчеләр дә, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр дә, башлыклар да еш әйтә. Бу очракта, әлеге сүзнең компания мәгънәсен күздә тотам. Мондый сәяхәт-экспедициядә команданың бер рухлы булуы мөһим. Командада, гаиләдәге шикелле, татулык, армиядәге шикелле, дисциплина кирәк. Әмма ул тәртип-дисциплина боерык биреп булдырыла торган нәрсә түгел. Һәркем – олымы-кечеме – аз санлы бу күчмә төркемдә үз урынын, үз вазифасын белергә, тоярга тиеш. Яңа җиргә күчеп, бер сәгать эчендә тирмә-палаткалар корып, учак тергезеп, табын әзерләп яшәү шартлары булдыру өчен һәр кешегә шөгыль җитәрлек. Берең эшләгәндә, икенчең кул кушырып тора алмый. Үзеннән-үзе күмәк

эшкә кушылып китәсең. Берең утын әзерли, берең казан аса, берең бәрәңге әрчи, балык чистарта (яңа тотылган балык төп ризыкларның берсе булды), берең су ташый, табак-савыт юа... Тәрбия җәһәтеннән балалар өчен бик файдалы мондый сәфәр-сәяхәтләр. Олылар кул арасына кереп, эшкә, мөстәкыйльлеккә өйрәнәләр алар. Гомумән, учак янында бала-чаганың чыр-чу килеп йөрүе күңелле инде! Үзеңнең дә балачак турындагы татлы хисләр, төтенгә кушылып, күкләргә үрли... Безнең командада, әйткәнемчә, өлкәннәрдән тыш студент егет, укучы үсмер малай һәм сабый бала бар иде. Һәммәсенә эш табылды. Мәсәлән, алты яшьлек Газиз, нык итеп тарттырып куя алмаса да, палатка җыя ала хәзер. Искә төшеп китте: элегрәк авылда ат җигә белмәгән малай белән санлашмыйлар да иде.

Әйе, юлдашларым – тәҗрибәле туристлар, мөхтәрәм кешеләр. Алтаен да, Тянь-Шанен дә, Кавказын да айкаган затлар. Өстәвенә бик булдыклы кешеләр. Бер генә мисал: поход шартларында, табада белен пешереп, эченә кызыл уылдык сылап, деликатес ризык әзерләп ашатсыннар әле!.. Дөрес, үзем дә тау-диңгез күрмәгән егет түгел. Барыбер аерма бар, болар – яшьтән үк, бергә-бергә күп походларда булып, бер-беренә керешеп, үзләшеп беткән кешеләр. Алар арасында чит-ят булмадым шикелле. Яшь ягыннан иң өлкән булуны да искә алынгандыр инде (әдәбиятта әллә ничә дистә еллар буе иң яшь шагыйрь, иң яшь делегат, иң яшь лауреат дип йөртелгән Равилме соң бу! Әй Дөнья, әй Вакыт!..). Шулай да, Әмирхан Еники әйтмешли, «ялгыз каз»лыгымны да сизмәдем түгел. Кичләрен учак янына җыелабыз. Кемдер берәр көй-җыр башлый, икенчеләре кушыла. Аларга рәхәт, үзләренә якын җырлар, үткән гомерләренең кадерле сәхифәләре бит. Ә минем өчен ят. Күңелемә сеңгән көйләр түгел. Бергә узган гомерләрендәге төрле мәзәк хәлләр сөйлиләр, көлешәләр... Аларга кызык, ә миңа?.. Сүз-җыр тоташ диярлек рус телендә. Дөрес, без – хатын, малай, мин татарча да сөйләшәбез. Әмма бу хәл күбрәк үз тирәбездә генә. Тегеләр янында да сөйләшәбез сөйләшүен. Аңламасалар да, аңлаганга салышалар... Тугыз көн буе күңелдә хыялый бер уй йөрде: эх, өч-дүрт каекка җыелсын иде серләшерлек үзебезнең каләмдәш егетләр! Түр көймә-каекның башында астына бәләкәй мендәр салып булса да утырсын иде Миркасыйм Госманов кебек берәр ил агасы. Сөйләп барсын иде тарихи гыйбарәләрне! Җырлый-җырлый ишкәкләрен уйнатсын иде шәп егетләр! Тукталышларда яңгырасын иде үзебезнең газиз көйләр! Хәер, чынлап тотынсаң, бер дә булмастай гамәл түгел бу. Мондый сәфәргә чыгарлык егет-кызларның барлыгын беләм мин. Теләк һәм бердәмлек кенә кирәк.

Еш кына бик табигый сорау да туа: нигә дип кеше күнегелгән җайлы өен, ванналы-мунчалы җылы учагын, компьютер-телевизорын, машинасын, заман тудырган башка уңайлыкларны ташлап, мәшәкатьле, авыр (хәтта хәтәр!) сәфәрләргә чыгып китә икән? Кемнәрдер, япа-ялгыз яхта-көймәләргә утырып, диңгез-океаннар кичеп, Җир шарын урап чыга. Кемнәрдер, чаңгылар сөйрәп, мәңге туң котып тарафларына юнәлә. Кемнәрдер, чакрымнарга сузылган җир асты юлларыннан кәлтә кебек шуышып, дөм караңгы мәгарәләрдә яшәп ала. Кемнәрдер ут атар янар тауларның очларына үрмәләп менә... Бугазларыннан буып алган ихтыяҗ да юк югыйсә. Язмышларын су – диңгез-океан белән бәйләгән мәшһүр Жак Ив Кусто, Тур Хейердал кебек бөекләр искә төшә. Язучы Эрнест Хемингуэй да су стихиясенә гашыйк җан булган... Әйткәнемчә, боларның гамәлләре һич тә мәҗбүрият кушканнан түгел. Минемчә, яшәешнең экстремаль формаларына омтылучыларны берләштерә торган бер уртаклык бар: ул – кешенең табигать баласы, аның аерылгысыз бер өлеше икәнлеген үзеңдә физик тою, анда «эрү» һәм күпмедер дәрәҗәдә аның серләрен ачу.

Бөек ачышларның байтагы сәяхәт-экспедицияләр белән бәйле дә. Фәннең асылы – дөньяны танып белү, аны өйрәнү, нәтиҗә ясап киләчәк өчен мәгънә-файда чыгару... Әлбәттә, зур сәяхәтләр белән чагыштырганда, безнең бу йөзү шәхси тормышларыбызның, яшәвебезнең тере бер декоратив бизәге генә. Әмма барыбер бер сәяхәт, үз-үзеңне раслау акты, «хәрәкәттә – бәрәкәт!» дигән бөек хакыйкатьне раслау. Безнең Президент халыкның бер мәкален еш әйтә: «Мич башында ятып бүре куып булмый!» Дөрес сүзләр.

...Нәкъ тугыз көннән соң Кокшага елгасының Иделгә якынлашкан жирендәге күпер янында идек инде без. Каеклар янәдән сүтелеп, чехолларга төрелде. Рюкзаклар җиңеләйде – азык-төлек бетте диярлек. Шулай да биштәр-төеннәр барыбер җитәрлек. Йөз-битләр (бөтен тән инде) кояшта янган, яңаклар бераз суырылган. Тәннәр ныгыган, гәүдәдә артыклык юк кебек. Күңелдә нииндидер эчке канәгатьлек, җиңү хисе. Сынау да, сыналу да, чыныгу, ныгу да булды бу сәфәрдә. Олы юл ягына чыккач, кесә телефоннары да эшли башлады. Туганнар,

дуслар, җанга якын кешеләр һәммәсе исән-сау, борчылырлык ул-бу юк. Дөнья – түгәрәк! Казанга кайтабыз, без татарныкы дип уйлаган башкалабызга кайтабыз. Аңарчы Аккош күлендәге дача йортында төн кунабыз әле. Рәхәтләнеп бер изрәп йоклыйм, Алла боерса (солдатта чакта йокыны тансыклау шулай була иде)! Әйе, арылган. Янәдән тиз генә мондый сәфәргә чыгасы килеп тормас инде...

*P.S.: Адәм юрый, Ходай юллый, диләр. Тормыш дигәннәре кеше ягәешенә төзәтмәләрне гел кертеп кенә тора. Кокшагадагы йөзүдән кайтып ике ай үткәч, алдан һич ниятләмәгәндә, Сочи тирәсендәге Мзымба дигән ярсу тау елгасында рафтингта (сплавта, ягъни көймәдә йөзүдә) катнашырга туры килде әле!..*

Хәзер кыш. Яз якынлашкан саен, ярсу агымлы елгалар буйлап җәйге йөзүләр ешрак искә төшә. Төшләргә дә керә соңгы вакытта. Күңел кытыклана. Әллә «йөзү өянәге» башлана башланды инде?..

*2008*

## *ӘДИПЛӘРНЕҢ ГАМЬ БИШЕГЕ*

Дөресен әйтим, язучылар яши торган «Аккош күле» дачалары турында иркенләбрәк, тәфсиллерәк, күләмлерәк итеп язарга ниятем бар иде. Ул теләкнең хәзер дә кимегәне юк. Фотосурәтче Рифхәт Якупов белән без аны альбом-китап итеп күзаллаган идек. Бу җәһәттән беркадәр эш башкарылган да иде. Дөньяның көтелмәгән яңа мәшәкатьләре көн саен диярлек туа торып, ниятләгәннәр һаман чигерелә торды. Без шулай сузып-тарткалап йөргән арада, хөрмәтле «Мәгариф» нәшрияты «Аккош күле» турында күмәк китап әзерләп өлгергән дә икән! Афәрин! Көнләшеп сокланырга гына кала. «Мәгариф» белән санлашмыйча булмый. Әле күптән түгел генә безләр өчен бик тә кадерле булган Казанның мәшһүр Матбугат йорты турында менә дигән китап чыгарып куйдылар. Ихтимал, татар өчен тарихи әһәмияткә ия ул бина һәм аның кешеләре хакында да безнең кебек берәр хезмәт язарга хыялланып йөрүчеләр булгандыр. Инде китапның әлегесендә (дөрес, элгәргесендә дә бәләкәй генә язмам бар иде) – «Аккош күле» – илһам аланы»нда – миңа да катнашырга тәкъдим булгач, бик теләп ризалаштым.

Татар әдәбиятының соңгы ярты гасырын «Аккош күле»ннән башка күз алдына китерү кыен. Чөнки бу җирдә заманның күренекле шәхесләре – зур әдипләр яшәгән. Йортлар саны ике дистәгә дә тулмаган шушы бәләкәй «авылда» әдәбиятыбыз тарихында калырлык күп әсәрләр язылган. Әнә бу йортта поэмалар туган, тегесендә фәлән роман язылган, өченчесендә, әйтик, пьесалар, гыйльми хезмәтләр әзерләнгән, кемнәрдер дөнья халыкларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән...

Кызганыч, «Аккош күле»нең иҗади гөрләп яшәгән «егет» чагына туры килә алмадым мин. «Язучылар оясы»на күченеп килгәндә, бу җирнең аксакал хуҗалары Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Нәби Дәүли, Фатих Хөсни, Зәки Нури, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Хәсән Хәйриләр бирердә юк иде инде. Килүем 1989 елда булды. Фин йорты дип йөртелгән өйнең миңа дигән өлешендә элегрәк Мәҗит Рәфыйков, Гәрәй Рәхимнәр яшәгән булган. Баштагы бер-ике елда нигәдер сирәк киленде, мич ягып җылытырлык йорт булса да, кышларын бөтенләй йөрелмәде. Идел буендагы элек яшәгән Займище сагындырдымы, әллә бүтән сәбәпме, кисәк кенә үзләшә алмадым. Ә менә соңгы унбиш елда шулкадәр беректем бу җиргә, аерыла алмас дәрәҗәгә килдем бугай инде. Шушы елларда бирердә байтак шигырьләр, публицистик мәкаләләр, эссе-уйланулар рәвешендәге күп хезмәтләр язылды. Китапларга кергән кайбер шигырьләрем ахырына «Аккош күле», фәлән елда язылган» дигән искәрмәне күргәч, шул елларга караган күп истәлекләр яңара. Шулай да «Аккош күле»нә ун ел, кимендә биш-алты ел алданрак килмәгәнемә үкенәм. Теләсәм, мөмкинлекләр бар иде.

Совет чорында СССР территориясендә язучыларның иҗат йортлары дистәләгән иде. Переделкино, Ялта, Күктүбә, Дубулты, Гагра, Пицунда, Малеевка, Дүрмән... Союздаш

саналган республикаларның һәрберсендә диярлек язучыларның иҗат йортлары, ял итү базалары бар иде. Үз вакытында Татарстанда да бөтенсоюз статусындагы иҗат йорты булдыру юнәлешендә талпынышлар булып алды. Барып чыкмады. Хәер, ул вакытта оешкан булса да, бу заманның байлык җыю осталары – елгыр егетләре, мөгаен, аны үз кулларына төшергән булырлар иде... Алда саналганнарга бик үк охшамаса да, «Аккош күле» үзенчә бер иҗат йорты инде. Үзенчәлеге шунда: биредә путевка-юллама биреп яшәтү тәртибе булмаган. Гадәттә, бер килеп урнашкан кеше, гомерлеккә төпләнеп калган. Берәүләр үзләре йорт җиткергән, икенчеләр, казна йортын үз итеп, хуҗаларча яшәп ятканнар. Йортлар Әдәби фонд карамагында булган. Теге яки бу нәрсәне төзергә яки төзәтергә кирәк булса, Язучылар оешмасына буйсынган әнә шул Әдәби фонд вәкилләренә мөрәҗәгать иткәннәр. Хөкүмәтнең язучы хезмәтенә хөрмәт белән карауның гаҗәп формалары булган ул заманда! «Аккош күле» Россиядәге иҗат йортларының Переделкино дигәненә күбрәк туры килә бугай. Анда да бер төркем язучылар үзләренә билгеләнгән йортларда гомер буена торып иҗат иткәннәр.

«Аккош күле»нең оешуына иң күп өлеш керткән кеше – Гомәр Бәширов. Ул – үткән гасырның 50 нче елларында республиканың иң абруйлы кешеләрнең берсе. СССР Верховный Советы депутаты, Сталин премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар союзы рәисе. Югары даирәләрдә сүзе үтә торган чагы. Ул заманда хәзерге «Аккош күле»ннән ерак түгел генә җирдә – аралары күп булса бер чакрым булыр – Татарстан өлкә комитетының ял итү базасы булган. Халык аны обком дачалары дип йөрткән. Ул вакытта Беренче секретарь – Моратов Зиннәт Ибәтович. Татар мохитен яхшы белгән, күңеле белән татар җанлы кеше булган Салих Гыйлемханович Батыев та ул заманда республика җитәкчелегендә зур түрә кеше. Г.Бәширов шул кешеләр аша язучыларга җир алуга ирешкән. «Язучылар – партия булышчылары, алар белән якын булу комачау итмәс» дигәннәрдер инде. Әмма янәшәлек гомере озакка бармый: 50 нче еллар ахырында оргсинтез заводы төзелә башлагач, обкомчылар бу җирдән Идел буена – Боровое Матюшинога (бу сүзнең татарчасын ишеткән юк, бәлки, ул тирәләрдә безнең тел гомумән гамәлдә дә түгелдер) күчеп китәләр. Җитәкчеләр сәяси мәсьәләләрдә генә түгел, экологик тоемга да бик сизгер. «Аккош күле»нең оешу тарихы шулайрак. Гомәр агага рәхмәт, урыны җәннәттә булсын. Моннан өч ел элек кенә Бәшировлар йорты (анда берара М.Мәһдиев тә яшәп алды) исән иде. Бүрәнәдән салынган җыйнак кына бу йорт шактый нык, таза иде әле. Һәрхәлдә, мемориаль йорт итеп сакларлык иде. Бетерделәр. Ул урында яңа кешеләр яңа пулат-сарай салдылар. Ә бетмәскә тиеш иде Гомәр Бәширов нигезе! Варислары да рухи дөнья кешеләре юкса: улы Зөфәр – күренекле фоторәссам, кызы Лилия – педагог – М.Мәһдиевнең хатыны, оныгы Гәүһәр – редактор-язучы. Нидә хикмәт: ваемсызлыктамы, әллә вак меркантиль исәп-хисаптамы? Бу җәһәттән күренекле журналист, шагыйрә Асия Юнысова «Ватаным Татарстан» газетасында (2006, 2 июнь) кайчандыр Х.Туфан, С.Хәкимнәр яшәгән йортларның аяныч хәлдә икәнлеге турында әрнеп язып чыкты. Чарасызлыктан ул әрнүләргә кушылырга гына кала.

Сөйләүләренә караганда, 60–70 нче еллар «Аккош күле»нең гаҗәеп матур чоры булган. Табигать хозурлыгы, сафлык һәм тынычлык (машиналар юк диярлек, дөрес, ул вакытта юньле юлы да булмаган), иҗат өчен идиллик шартлар. Яши торган йортлар да бер чамарак: хәзерге кебек бер-берсен уздырып салган таш яки агач пулатлар юк. Чагыштырмача социаль тигезлек. Кешеләр иҗат иткән, киртәсез-нисез ачык түтәлләрдә чәчәкләр, гөлләр үстергәннәр. Уңган хуҗаларның яшелчәләре дә мулдан булган. Көзләрен уңыш бәйрәмнәре уздырганнар. Атаклы беседкада (ул кайбер фоторәсемнәрдә сакланып калган) язучылар җыелышып яңа язылган әсәрләрен укыганнар, фикер алышканнар. Бердәнбер уртак мунчага (хәзер һәр йорт янәшәсендә шәхси мунча!), чиратлашып ягып, бер-берсен дәшкәннәр. Ул чәйгә йөрешүләр, кунак бүлешүләр... Зур сарайны клуб сыман итеп яше-карты бергә телевизор караулар... Күмәклек, бердәмлек, кешелеклелек хисләре көчле булган. Йортларның хуҗалары – күбесе сугыш кичкән асыл ир-атлар. Тыныч тормышның, гаилә иминлегенең, табигать күркәмлегенең кадерен яхшы белгәннәрдер.

Кемнәр яшәгән дә кемнәр иҗат итеп яткан бу җирләрдә? Үткән ел Фарук ага Сабиров (Язучылар дачалары салына башлаганнан соң утыз еллап биредә бу җирнең «хуҗасы» – коменданты булган кеше) белән шушы илле елдан артык вакыт эчендә «Аккош күле»ндә яшәгән (кайберләре биредә озак яшәгән, кайберләре берәр ел яки берәр җәй генә торып киткән) кешеләрне барлап, искә төшереп утырдык. Әдәбият тарихын өйрәнүчеләр өчен, бәлки,

кирәге чыгуы бар дип, исемлек китереп узыйм (тулы булмавы да мөмкин). Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Әхмәт Фәйзи, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Хәсән Хәйри, Гариф Гобәй, Зәки Нури, Абдулла Әхмәт, Сафа Сабиров, Гали Хуҗи, Салих Баттал, Шәүкәт Галиев, Мария Елизарова, Шәрәф Мөдәррис, Ләбибә Ихсанова, Нил Юзиев, Фәнил Мансуров, Алексей Талвир, Габделхәй Сабитов, Мәҗит Рафиков, Рафаэль Мостафин, Рөстәм Кутуй, Галимҗан Латыйп, Мөдәррис Әгъләм, Фаил Шәфигуллин, Фәннур Сафин, Ризван Хәмид, Рәдиф Гаташ, Габдулла Шәрәфи, Мәгъсүм Насыйбуллин, Гәрәй Рәхим, Ринат Мөхәммәдиев, Роберт Миңнуллин, Сафуан Муллагалиев, Камил Кәримов, Рифкать Закиров, Рөстәм Мингалимов, Наис Гамбәр... Бүген яшәп ятучы язучыларны һәм төрле елларда җәйләрен дуслары хозурында айлап-айлап яшәп алган Булат Сөләйманов, Мөхәррәм Каюмов, Эдуард Мостафин, Марат Закиров, Илгизәр Солтан, Әхәт Гаффар кебекләрне дә бергә исәпләсәң, алтмышлап исем килеп чыга. Нибары ике гектар чамасы гына булган бу алан өчен зур сан бу.

Казан язучыларының бакча-дачалар рәвешендә күмәк яши торган җирләре берничә: «Займище, 774 км» дип йөртелгән Идел буендагы һәм Биектау-Киндерле җирләре, тагын Васильеводан ерак булмаган, элек «чегән хуторы» дип аталган урын. Займище дигән җиргә журналист-язучы халкы 60 нчы еллар уртасында килеп урнашты. Анда – Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Газиз Мөхәммәтшин, Әхсән Баян, Вакыйф Нуруллин, Рәис Даутов, Диас Вәлиев, Ибраһим Нуруллин, Яхъя Халитов, Адлер Тимергалин, Әхәт Мушинский... Үземнең дә унөч елга якын яшьлек гомерем шунда узды. «774 км» дип йөртелгән җир – Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Нури Арсланов, Гөлшат Зәйнашева, Хисам Камал, Ләбибә Ихсанова, Марс Шабаев, Лирон Хәмидуллин, Фәрваз Миңнуллин...; Васильево – Мөхәммәт Мәһдиев, Фәнис Яруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәфкать Кәрами, Җәүдәт Дәрзаман, Рәшит Әхмәтҗанов, Зәет Мәҗитов, Әхмәт Рәшитов, Кояш Тимбикова, Шамил Маннапов, Роза Мулланурова, Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Мансур Шиһаповлар; ә Биектау-Киндерле җире, белүемчә, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Рафис Корбан, Рашат Низами, Газинур Морат, Рәфикъ Юныс, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон исемнәре белән бәйле. Бу җирләрдә дә язучылар яшәгәннәр, иҗат иткәннәр, җәйләрен гомер кичергәннәр һәм кичерәләр. Әмма күпләр өчен язучыларның төп иҗат урыны дип барыбер «Аккош күле» санала. Тарихи үткәне белән дә, язучыларның ишлелеге белән дә, җырларга кереп калган исеме белән дә. Бүтән дачалардан аерып куярлык өстенлекләре дә бар шул. Казанга якын. Каены-чыршысы, юкәсе-имәне үсә торган урман. Якында гына ике матур күл – Тирән күл, Кече тирән күл... Шуңа өстәп җиләге, гөмбәсе дигәндәй. Килеп беренче күргән кешеләр «җәннәт урыны икән бу җир!» дип сокланалар. Язучыларның кишәрлек җирләре алай күп түгел түгелен: уртача биш-алты сотый чыга торгандыр. Алай да сер бирмибез, кайчак, бераз мактанып, бу кишәрлек җир өй салыр өчен генә бирелгәне, ә безнең төп биләмәләр әнә ничаклы дип, урман-күл якларын күрсәтәбез. Бу сүзләрдә хаклык та бар: капкаңны ачып чык та урман сукмаклары буйлап чыгып кит. Кинәнеп йөр, табигать белән хозурлан, хыяллан, яңа әсәрең өчен хикмәтле сүзләр уйлап йөр... Һәм шулай йөргәннәр дә әдипләребез. «Туган ягым – яшел бишек», «Кырыгынчы бүлмә», «Үлем белән яшәү арасында», «Гүзәл гамь», «Онытылмас еллар», «Тукайга хатлар» шулай йөреп-уйланып язылганнар дип уйлыйм.

Территориясе бәләкәй генә булса да, язучылар «авылы»ның үз бүленешләре бар: Югары оч, Түбән оч... Кесә телефоныннан яхшырак ишетелсен өчен Түбән очтан Югары очка менәләр. Түбән оч – байлар, машиналылар ягы. Югары оч, нигездә, «җәяүле кеше сукмагы»н үз күрүчеләр. Әүвәл ничек булгандыр, белмим, хәзер шулайрак. Мин үзем дә Югары очта яшим. Кайчан түбәндәгеләргә шаяртып әйтеп куям: «Сез кирмәннең бистәсендә, капка төбендә яшисез. Посад-бистә нык булырга тиеш! Сез нык булсагыз, Югары оч – Үзәк яхшырак сакланыр!» Көлемсерәп куялар, каршы әйтмиләр тагын үзләре... Әйтергә кирәк, Түбән очны язучы булмаган кешеләр белән тутыруда Ренат Харисның катнашы зур.

Вакыт – һәрнәрсәне үзгәртүче бөек көч. Яшәгән саен шуңа инана барасың. Кешеләр үзгәрә, буыннар алышына, авыллар, шәһәрләр еш кына танымаслык хәлгә килә. «Аккош күле» авылы да бик нык үзгәрде. Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәрим, Сәйфи Кудашлар торып басса, тел шартлатып, танымый торырлар иде. 50 нче елларда салынган йортлардан хәзер фәкать өчесе генә калды. Алары да ташландык хәлдә. Хәзергечә әйтсәк, «тузган торак» истәлекләре. Якындагы елларда алардан берни дә калмастыр инде... Ә татар җаны өчен бик

кадерле йортлар югыйсә. Берсендә Х.Туфан, А.Шамов яшәгән, икенчесендә – С.Хәким, И.Гази, өченчесендә – Н.Дәүли... Нигә шундый хәлгә калганнар соң алар? дигәнгә кистереп җавап бирү, кемнедер гаепләү кыен. Иң әүвәл бу җирнең әлегә төгәл статусы билгеләнмәгән: дәүләтнекеме, әллә хосусыймы? Шулай да әле әйтеп үткән йорт һәм аның тирәлеге өчен беренче чиратта варислары – балалары, туганнары кайгыртырга тиештер. Күбесе шунда үскәннәр бит. Мәсәлән, атаклы сәясәтче Рафаэль Хәкимнең әтисе (һәм үзе дә!) яшәгән йортны карап, аны истәлекле мемориаль йорт итеп саклап калырга мөмкинлекләре юк түгел ләбаса!

«Аккош күле»нең мин дә шаһиты булган унбиш-унсигез елында да үлем-китемнәр, нигез югалтулар байтак булды. Нил Юзиев, Габдулла Шәрәфи, Фәннур Сафин, Хәсән Хәйри, Наис Гамбәр, Мөдәррис Әгъләм гүр ияләре булдылар бу елларда. Әйткәнемчә, элеккеге йортлар урынына язучылык эшенә катнашы булмаган яңа кешеләр нигез-фундаментлар корып куйдылар, яңа пулатлар салдылар. Соңгы ике елда гына бу мохит өчен сәер күренгән, бер карасаң мәчеткә, бер карасаң клубка охшаган яңа бер галәмәт зур бина пәйда булды. Кайчандыр тынычлык хөкем сөргән табигать кочагында краннар, «КамАЗ»лар тавышы хәзер сирәк тынып тора. Ярый, дөнья гел бер урында тормый, төзесеннәр, корсыннар да ди, яңару яхшы гамәл. Шулай да тарихи традицияләрне онытырга ярамый. Әйтик, бульдозерлар, краннар белән шактый ук имгәтелгән төп керү капкасын үзеңнән соң рәтләп калдырырга була бит инде! Авылча гади, матур гына капка өстендә «Аккош күле» дигән язу да бар иде. Күпләр өчен истәлекле, фотога төшәр өчен генә булса да истәлекле урын. Аның каравы җир кишәрлекләрен тотып алган яңа шәхси капкалар, җил үтмәслек тоташ коймалар калыкты. Яңа заман, яңа кешеләр, яңа әхлак, яңа тәртипләр...

Әйе, тормыш алга бара... Куанычы да, хәсрәте дә җитәрлек. Иң кыены – якын кешеләрне югалту. «Аккош күле»ннән мәңгелек йортка беренче озатылган кеше 1958 елда Әхмәт Фәйзи булган... Табигый, ярты гасыр эчендә кемнәр килеп китмәгән бу дөньяга! Шул исәптән «Аккош күле»нә дә. Соңгы елларда минем өчен иң авыр югалтулар – Мөдәррис Әгъләм һәм Наис Гамбәр вафатлары булды. Икенчесе биредә әллә ни озак яшәмәде, ә инде Мөдәррисне чын мәгънәсендә «Аккош күле» кешесе дияргә була. Кеше буларак та, шагыйрь буларак та ул бу җирдән аерылгысыз: алтмыш ел гомеренең төгәл яртысы биредә узган. Мөдәрриснең яшәү рәвешенә төрле кеше төрлечә караса да, ул бу җирнең бизәге булган икән. Һәрхәлдә, минем өчен шулай. Күршеләр идек без. Иң аралашкан кешем дә ул булды. Иртән торып ишекне ачуга, Мөдәррис яки Наис торган йортларга төбәләсең: торганнармы, ишекләре ачыкмы? Кичләрен дә шулай: кайттылар микән, утлары бармы? Төрлечә яшәде Мөдәррис, «җен алыштырган» чаклары да булмады түгел. Ләкин беркайчан да, беркем алдында да шагыйрь икәнен, татар баласы икәнен онытмады.

Мөдәррис катлаулы кеше иде, кайчагында сүзенең чынмы, ялганмы икәнен аңлап бетереп тә булмаган кебек, аны бер яклап кына аңлап яки аңлатып та булмый. Әйтик, аның соңгы еллардагы «Аккош күле»нә, йорт-җиренә мөнәсәбәтен кабул итү кыен. Гөл кебек тотасы урында, торган йортын карамады, ташландык хәлгә җиткерде. Ә бит бу җир аны олы иҗатчы иткән. Үләренә берничә ел кала ул «Аккош күле»ннән китте яки китәргә мәҗбүр булды. Соң-рак өен җимереп ташладылар, кишәрлек җире күршеләр җирләренә кушылып «эреде»... Хәзер ул төштә Мөдәррис истәлеге булып ике карт алмагач калды. Берсенең алмалары бигрәк тә тәмле, сусыл. Исән булсак, киләсе җәйләрдә дә авыз итәрбез. Әмма ул алмалардан өстәмә бер тәм, ачы сагыш тәме дә килер инде...

Наис Гамбәр миңа үзенчә якын иде. «Казан утлары»нда хезмәттәш булып байтак еллар бергә эшләдек. Шагыйрь һәм гыйлемле редактор буларак, ул әдәбиятны, бигрәк тә шигъриятне бик нечкә тоя, аңлый иде. Үземә бәйле рәвештә дә моны раслый алам: иҗатым турында язылган йөзләгән мәкаләләр арасында Н.Гамбәрнең хезмәте төплелеге, тирәнлеге белән бүтәннәрнекеннән бер башка аерылып тора. Еш искә төшәсез, сагындырасыз, дусларым!.. «Аккош күле» ул Агачлар, Кешеләр, Күлләр иле генә түгел, Сагыш, Гамьнәр җире дә...

Без һәм бездән элгәре буыннар өчен «Әдәбият – халыклар дуслыгы» дигән шигар бар иде һәм ул изге төшенчә иде. Хәзер дә бу шигарне бөек саналырлык шигар дип исәплим. «Аккош күле»ндәге тормыш рәвеше бу девизга гел тугрылыклы булып килде. Нинди генә халыкның нинди генә асыл кешеләрен кабул итмәгән ул! Биредәге һәр йортта диярлек күренекле затлар кунак булган, «тел вә ләгать алмашып» сайрашкан! Һәр очрашу һәркем өчен бәйрәм дә,

тормыш дәресләре дә булгандыр дип уйлыйм. Әйтик, Гомәр ага Бәшировларда, Хәсән Туфан яки Сибгат Хәкимнәрдә кемнәр генә булмаган да, нинди генә сүзләр сөйләнмәгәндер! Бу җәһәттән әллә ни мактана алмасам да, минем йортта да күңелемә якын кешеләр байтак булды. Кайчак искә төшереп утырам, туган-тумачадан, хезмәттәш коллегалардан тыш халкыбызның әдәбият-сәнгатьтәге атаклы кешеләре – рәссамнар Әхсән Фәтхетдинов, Рәшит Имашев, Абрек Абызгильдин; җырчылар Илһам Шакиров, Вафирә Гыйззәтуллина, Рафаэль Сәхәбиев; композиторлар Алмаз Монасыйпов, Шамил Тимербулатов; галимнәр Вил Мирзаянов, Миркасыйм Госманов... Үзебезнең күренекле язучылар турында әйткән дә юк инде! Кунак булган җирдә бәрәкәт арта, диләр. Бәлки, ул чыннан да шулайдыр...

Бүгенге көндә «Аккош күле»ндә унлап язучы яшәп ята. Кемнәр дигәндә, санап китәм. Түбән очтан башлыйк: Ренат Харис, Җәүдәт Сөләйман, Зиннур Хөснияр, Флүс Латыйфи... Югары очтагылар – Зиннур Мансур, Мөдәррис Вәлиев, Равил Фәйзуллин, ягъни мин, Мансур Вәлиев, Ркаил Зәйдулла, Фоат Галимуллин. Төрле төбәкләрдә туып биредә тамыр җибәргән төрле яшьтәге, төрле холыктагы кешеләр. Әмма кайсын алсаң да, татар әдәбияты елъязмасында, сәяси, мәдәни, гыйльми дөньяда үз урыннары бар шәхесләр.

Бүгенгесе шулай. Моңа кадәр әдәбият учагы булып килгән бу «Язучылар аланы»ның киләчәге нindirәк булыр? Табигый сорау. Мин дә уйланам бу хакта. Уйланам да мондый нәтиҗәгә киләм: ул, мөгаен, ун-унбиш еллап узгач элеккеге язучылык данын йөртерлек җир була алмастыр. Чөнки бүген яшәп иҗат итүчеләр олы яшьтә. Яшьләре, уртача алганда, алтмышлар тирәсе. Яшәеш үсеше өчен буыннар гармониясе кирәк. Әйтик, моннан утыз еллар элек биредә Гомәр Бәширов кебек өлкәннәре дә, Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев кебек урта яшьтәгеләре дә, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләм кебек яшьрәкләре дә булган. Әйткәнемчә, хәзер хәл бүтән. Хәзерге язучыларның балалары гел генә язучы яки рухи дөнья хезмәткәрләре булып китмәс. (Мәрхүм әтиләре китапханәсендәге култамгалы китапларны чүплеккә чыгарып ташлаган «варислар»ны да күрергә туры килде.) Бу йортларда бүтән буын яшәр. Телләре, көй-моңнары инде бүтән булыр. Нишлисең, кыйтгалар да үзгәрә, империяләр җимерелә, халыклар юкка чыга... «Аккош күле» генә үзгәрми торып кала алмас шул. Шунсына разый булыйк: ул Вакыт дәрьясының аерым билгеле бер чорында татар әдәбиятының бишеге, милли рухның үзенә күрә бер үзәге булып кала алган.

«Аккош күле» табигатьнең һәр фасылында үзенчә матур, үзенчә гүзәл. Хәер, табигать илаһи матурлыкның үзе бит инде. Аннан аерылмаганда, үзеңне аның белән бербөтен хис иткәндә, кеше күңелендә дә ямьсезлеккә урын калмыйдыр. Җәй башында алмагачлар, чияләр чәчәк аткач, алар агач-куак түгел, күбекләнеп торган ак болытлар гүя. Көчлерәк җил исеп куяр да зәңгәр күккә ашарлар кебек. Таңнарын сандугачлар берсен-берсен уздырып өздереп сайраганда, уянып китсәң дә исәрләнеп татлы уйларга таласың, яшь чакларның сәгадәтле сәгатьләре искә төшә... Кышларын үзенчә әкияти дөнья. Тоташ аклык дәрьясында ак каеннарның төз, сылу гәүдәләре җаныңа янә бер аклык өсти. Бәсле куакларга кунган кызылтүш – миләш чыпчыклары үзе бер могҗиза! Рәссам бул да, кәгазьгә төшер дә куй. Кай көннәрне иртәнчәк мич торбаларыннан талгын гына төтен баганалары күтәрелә. Димәк, кемнәрдер мунча яккан. Мөгаен, кемдер ләүкәдә хәл беткәнче чабынып, чөгендердәй кызарып чыгар да яңа яуган карда аунар... Апрель башларында каен сулары төшкән көннәрне бәйрәм кебек көтеп алабыз. Гаҗәеп манзара: кар әле китеп бетмәгән, җир ала-кола, күк җете зәңгәр, бөреләр җегәрле тулышлы, сулаган һава тәнеңә бальзам...

Мин үзем тәүлекнең берәр сәгатен урманда үткәрергә тырышам. Җәй айларында, гадәттә, шулай килеп чыга да. Капканы ачып чыгасың да үзең белгән сукмаклардан китәсең. Монда сиңа һәр агач, һәр куак-үлән иптәш, сердәш. Алар арасында уйланып йөрергә яхшы. Ниләр генә уйланылмый табигать кочагында! Мәрхүмә дәү әнием «Минут эчендә әллә ничә тапкыр Мәскәүләргә барып кайтам мин!» дия торган иде. (Үзе Мәскәүнең кайсы якта икәнен дә белми!) Мин дә кайчак аңа охшаш булып куям. Төп уй, әлбәттә, әдәбият турында. Иҗатташ каләмдәшләр, әсәрләр турында... Күңелдән алар белән сөйләшәм, бәхәсләшәм, ниндидер фикерләргә киләм, планнар корам... «Әңгәмәдәшләрем» бүгенгеләр генә түгел, кайчак бик зур тарихи шәхесләр дә була. Кол Гали, Кандалыйлар да, Тукай, Такташлар да... Җиңелгәннәре өчен борынгы бабайларга да «эләгә» кайчак. Бүгенге хаким-хөкемдарлар да кырыйда калмый... Иҗат процессы дигәннәре шул буладыр инде. Һәрхәлдә, нидер – берничә шигъри юлмы, берәр «даһи» фикерме ияреп кайтмый калмый урманнан. Үз кочагында шулай

уйландырып, хисләндереп, яшәртеп һәм матур картайтып кеше итеп йөрткәнең өчен рәхмәт сиңа, «Аккош күле»!

Әйе, «Аккош күле» Казан үзәгеннән ерак түгел. Хәер, ул үзе дә Казан эче, шәһәрнең парк зонасы санала. Кремль тирәсеннән исәпләп Мәскәү ягына таба машина белән юыртсаң, 20–25 минутта барып та җитәсең. Матур җирләр. Самолеттан караганда Идел белән янәшә каймаланып барган урманнар еракка-еракка сузыла. Унбиш чакрымнар ары китсәң – атаклы Раифа монастыре, тагын да арырак – Зөя яклары, Идел эчендә Явыз Иван салдырган Свияжск кальгасы. Татар тарихы өчен хәтәр җирләр! Нинди гүзәл җирләрне яулап килгән баскыннар... Хәтәр җирләрдә хәтерле булу бик тә кирәк! Менә без әлегә табигатьнең җәннәткә тиң шушы җирендә басып торабыз. Үзебезчә хуҗа булып. Бу тойгы минем өчен дә горурлык һәм дәрәҗә. Шулай тиеш тә. Бу бит минем Туган җирем, тарихи Ватаным!

*2007*

# *ЭЧТӘЛЕК*

**I**

Гыйбрәтләр алырлык үткән юл .........................

**II**

Кояш астында без дә бар ............................
Китап гасыры китәме? ..............................
Иман безне ташламасын! ............................
Иле барның теле бар ...............................
Яңа елда яңарган уйлар .............................
Йә, нишлибез, газиз каләмем? ..........................
Язучылар өчен дә мәктәп булды ........................
Узды шаулап бөек бәйрәм ............................
Юллар текәрәк, еллар җаваплырак ......................
Юк, җибәрми мине гамьле уйлар ........................
Рухи елъязма ..................................
Еллар узган саен, гамь арта ...........................
Бердәм булсак – җиңәрбез ...........................
Сүтеләбезме? ..................................
Тел бирмәк – җан бирмәк ............................

**III**

Үлемсезлек символы *(Г.Тукай)* ........................
Ә горурлык хисе һаман шул... *(М.Җәлил)* ..................
Халыкчан шагыйрь *(Г.Афзал)* .........................
Олы шагыйрь, киңәшче шагыйрь *(С.Хәким)* .................
Очрашулар *(Ш.Хөсәенов)* ...........................
Ак рояль хуҗасы *(Н.Җиһанов)* ........................
Егет әдип *(Г.Ахунов)* ..............................
Зураеп калу *(Г.Ахунов)* .............................
Хәзинәләр хуҗасы *(Ә.Кәримуллин)* .......................
Горурлыгыбыз *(Б.Урманче)* ..........................
Яну йөрәктән башлана *(З.Мансуров)* ......................
Бар шундый бер Батулла... *(Р.Батулла)* ...................
Аның яшәү рәвеше *(М.Госманов)* .......................
Туңма, туган! *(М.Әгъләмов)* ..........................
Чатыртау – биек тау... *(М.Галиев)* ......................
Җиңәргә яратылган *(Ф.Яруллин)* .......................
Әле без һаман да замандаш *(Р.Фәхретдинов)* .................
Вөҗданына тугры әдип *(Ә.Еники)* .......................
Нарасый Хәким *(Ә.Фәтхетдинов)* .......................
Замана язучысы *(Р.Мир-Хәйдәров)* ......................
Нечкә хисле, батыр йөрәкле *(Р.Әхмәтҗанов)* ................
Заманга иш иҗат *(Р.Харис)* ..........................

Яна-яна иҗат итә *(А.Хәлим)* ..........................
«Чикле чиксезлек» *(Р.Аймәт)* ........................
Батмаска туган Баттал *(С.Баттал)* ......................
Әйдәүче *(Т.Әйди)* ................................
Аксакал әдип *(Л.Хәмидуллин)* ........................
Казанның иң бай егетләре *(Шамил һәм Ринат Закировлар)* .........
«Син сазыңны уйнадың...» *(Н.Исәнбәт)* ...................
«Дөньяда Пушкин бар...» *(А.Пушкин)* ....................

**IV**

Рухи галәмдә яшәргә ..............................
Сыналабыз – сынмыйбыз ............................
«Таяныч ул – халык...» .............................
«Ышаныч зур, хыял көчле иде...» .......................
«Заманга иш булыйм дисәң...» ........................

**V**

Агымсулар буйлап тугыз көн ..........................
Әдипләрнең гамь бишеге ............................

Литературно-художественное издание

**Файзуллин** Равиль Абдрахманович

***РАЗДУМЬЯ***

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Фәйзуллин** Равил Габдрахман улы

***ИЛБАГАР УЙЛАР***

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.12.2010.
Форматы 70r100 1/16. Шартлы басма табагы 33,80.
Тиражы 1500 д. Заказ О-1830.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru.**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.